РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ
АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ



# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ, ТАРИХ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

УКУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ СТУДЕНТЛАРНЫҢ
XIV БӨТЕНРӘСӘЙ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ
МАТЕРИАЛЛАРЫ

АЛАБУГА – 2023

02 ноябрь

ББК 81.632.3
УДК 811.512. 145.
Т 23

Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының Гыйльми советы карары белән басыла
(берткетмә № ___________)

**Бәяләүчеләр**:

**Галиуллин Р.Р. –** филология фәннәре кандидаты, Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты.

**Шаймарданова М.Р.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты доценты.

**Редколлегия:**

**Камаева Р.Б. -** филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы профессоры.

**Габидуллина Ф.И**. – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Даутов Г.Ф. -** филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Хәйруллина Ә.С.** – филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты Алабуга институтының татар филологиясе кафедрасы доценты.

**Т23 Татар теле һәм әдәбияты, тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге:** укучыларның һәм студентларның XIV Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференция материаллары (Алабуга, 02 ноябрь, 2023 ел). – Алабуга: КФУның Алабуга институты нәшрияты, 2023. – 252 б.

*«Татар теле һәм әдәбияты, тарих: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» фәнни-гамәли конференциясенең материаллары тупланган җыентыкка укучыларның, студентларның фәнни тикшеренү язмалары кертелде. Рәсәй Федерациясенең Пермь крае. Башкортостан һәм Татарстан республикаларында яшәгән укучыларыбызның фәнни мәкаләләрендә татар теле һәм әдәбиятының актуаль проблемалары, тарихның күпләрне борчыган һәм дулкынландырган мәсьәләләре, татар әдипләре иҗатында милли яшәешнең ни дәрәҗәдә яктыртылуы турындагы тикшеренү нәтиҗәләре урын алган.*

©Авторлар коллективы, 2023
© КФУның Алабуга институты, 2023

# ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ БИРҮДӘ УЕННАРНЫҢ РОЛЕ

Арсланова А.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.

Экология дөньякүләм әһәмиятле, мөһим мәсьәләләрнең берсе. Кешелекнең табигать белән бәйләнеше – хәзерге заманның актуаль мәсьәләсе. Чөнки киләчәк буыннар язмышын фән-техника казанышлары түгел, ә җир-суларның экологик торышы хәл итәчәк. Җитештерү эшчәнлегенең тизлеге арткан саен, экологик проблемалар да күбәя бара. Экология проблемасы глобаль проблема булып, аның үзебез яшәгән урында да чагылуы укытучыларда борчылу тудыра, төрле педагогик эшчәнлеккә этәрә.

Экологик тәрбия максатчан укыту нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла. Укучыларның төрле фәннәрне өйрәнү процессында экологик белемнәре арта. Экологик тәрбия акыл эшчәнлеген үстерү, хезмәт тәрбиясе эстетик юнәлештәге тәрбия белән аерылгысыз бәйләнештә тормышка ашырыла.

Укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, уртак йортыбыз булган Җир планетасы язмышына җаваплылык хисе булдыру –экологик проблемалар кискенләшкән чорда аеруча әһәмиятле һәм ул максатчан алып барылырга тиеш. Кеше табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә,бер генә минут та яши алмый. Шуңа күрә дә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек ук гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш. [Хуҗиәхмәтов 1999: 309]

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә уеннар зур роль уйный. Уен-бәйгеләр, гадәттә, комплекслы характерда, төрле ярышлар, чыгышлар белән үрелеп алып барылырга мөмкин.

“Табигать белгечләре” турниры. Бу бәйге берничә этаптан торырга мөмкин:

1.Табигать серләрен иң яхшы белүчегә конкурс (бер серне ачуга карата үз гипотезасын күрсәтергә кирәк).

2."Табигатьне саклау билгеләре" рәсем конкурсы (командаларга лагерьда, “Урманны саклау” зонасында, “Экологик сукмак”та төрле табигать саклау билгеләре ясарга тәкъдим ителә).

3.Эрудитлар эстафетасы (ул чылбыр белән үткәрелә: беренче команда-икенчегә, икенче – өченчегә һ. б. сорау бирә).

4. “Табигатьнең Кызыл китабы" темасына телдән хикәяләр конкурсы (турнирда катнашучылар, алар фикеренчә, Кызыл китап битләренә эләккән флора яки фауна вәкилләре турында сөйләргә тиеш). Конкурс өчен түбәндәге темаларны да тәкъдим итәргә мөмкин: “Безнең якның иң матур почмагы”, “Гаҗәеп үсемлек (хайван)”һ. б.

5. “Табигать тавышларын танучылар” бәйгесе (командалар кошлар, башка хайваннар тавышлары белән магнитофон язмасын тыңлыйлар. Хайваннарның исемнәрен аларның тавышлары яңгыраган тәртиптә язарга кирәк).

6. “Табигать турында китаплар” рекламасы.

7. Персонажлары үсемлекләр яки хайваннар (җәнлекләр) булган мәсәлләрне иң яхшы сәхнәләштерүгә конкурс. Шәхси һәм команда беренчелегендә җиңүчеләрне турнир нәтиҗәләре буенча билгелиләр.

Экологик белем бирү табигатьтә уңышлырак алып барыла. Лагерь шартларында да татар теле һәм әдәбият дәресләре үткәрергә мөмкин. Бу вакытта әйләнә-тирәлекне саклау буенча фәнни-фантастик проектлар конкурсы һәрвакыт зур уңыш белән уза. Укучыларга “Тыюлык җире”, “Киләчәктә кеше һәм табигать арасында мөнәсәбәтләр”, “Җир планетасы – 3000 ел”, “Башка планеталар һәм хайваннар дөньясы” кебек проектлар тәкъдим итәргә мөмкин. Проектларны яклауның яхшы шартларда узуы бик мөһим. Лагерь шартларында күзәтүчәнлекне, хәтерне үстерүгә, ориентлашуга, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәүгә юнәлтелгән уеннарны практикалау уңышлы була. Табигатьне саклау буенча тәрбия дәресләре укучыларның яшь үзенчәлекләрен испкә алып оештырыла [Хуҗиәхмәтов 1999: 309].

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, уртак йортыбыз булган Җир планетасы язмышына җаваплылык хисе булдыру –экологик проблемалар кискенләшкән чорда аеруча әһәмиятле.

**Әдәбият**


1. Лихачев Б.Т. Экология личности // Педагогика. – 1993. – №2. – С.19.
2. Дәрес эшкәртмәсе үрнәкләре. Татар теле һәм әдәбият. 1 кисәк. – Казан: РИЦ “Школа”, 2005. – 500 б.
3. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Гомуми педагогика: педагогик уку йортлары, коллиятләр, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 1999. – 504 б.
4. Экология. Википедия. – URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/Экология (мөрәҗәгать итү датасы: 16.10.2023).


## БАШНЯ СЮЮМБИКЕ В КАЗАНИ


Антонова А.Г.
МБОУ «Родниковская СОШ» Алексеевского МР РТ
Научный руководитель: Рахматуллина Р.Р.


Башня Сююмбике — один из символов Казани и Республики Татарстан, важная достопримечательность и «жемчужина Казанского Кремля».

Туристы из разных городов России и путешественники со всего мира едут в Казань, чтобы увидеть таинственную падающую башню, загадать возле нее свое заветное желание, и услышать легенды о гордой красавице Сююмбике.

**Башня Сююмбике**

Башня Сююмбике построена из кирпича, занимает площадь 140 кв.м., здание состоит из семи ярусов, общая высота достигает 58 м.

Башня наклоняется на северо-восток на 1,98 м. Почему башня падает? Окончательного ответа пока нет, существует несколько версий: ошибки,

допущенные при строительстве, неоднородность культурного слоя, неудачное расположение на холме, влияние метро.

Для предотвращения дальнейшего наклона башни нижний ярус в 1914-1916 годы охватили железным поясом, чтобы сдержать падение и сохранить существующий уровень наклона. Несколько раз укреплялся фундамент: в 1941-1955 годы, в 1977-1978 годы и с 1985 по 1991 годы.

**Строение башни**

Башня Сююмбике по мнению исследователей представляет собой уникальный симбиоз татарской и русской архитектуры XIV-XVII веков. Архитектура башни Сююмбике напоминает Боровицкую и Спасскую башни Московского Кремля, но с элементами восточной архитектуры (шпиль, сквозные ворота, полуовальные окна, полуколонны). У ворот есть секирный замок, их стукала в форме голов львов – оберегов, отпугивающих злых духов.

Фундамент башни — дубовые сваи, которые с течением веков опустились на глубину свыше 2 м. Стены кирпичные на известковом растворе, а грани украшают кирпичные валики. Строение насчитывает 7 ярусов, первые 3 из которых квадратные, а остальные восьмиугольники.

В разновысотных «кубах» трех нижних ярусов устроены галереи гульбища, характерные для русской архитектуры, их «глазницы» использовались для наблюдения за территорией.

«Восьмерки» — следующие два яруса — построены так, чтобы менее быть подверженными влиянию ветров на высоте.

Шестой ярус башни выполнен в виде усеченной пирамиды или граненого шатра, седьмой — восьмигранная дозорная башня. Конструкцию башни венчает шпиль зеленого цвета, на нем красуется мусульманский полумесяц (до 1918 года — двуглавый орел). Существовала легенда, что в шаре на шпиле башни хранятся некие документы ханского периода, — шар проверили, но документы не обнаружили.

Интересный факт: в 2003 году в башне поставили декоративные кованые ворота “День и ночь” (изготовлены по эскизу архитектора Р.М. Забирова). Арка ворот «смотрит» на восход Солнца в день зимнего солнцестояния. Это объясняет наличие символических изображений Солнца и Полумесяца, лучей и звёзд, отражающих смену дня и ночи.

Ворота украшают изображения легендарных и мифологических животных: птица Сирин — символ сказочной страны; лебедь – образ чудесного спасения царицы Сююмбике; сокол, который напал на лань, – образ власти (башня стоит у Ханского дворца); перевёрнутая уточка, несущая в клювике кусочек глины, напоминает о создании мира.

**Название**

В письменных источниках наиболее ранним упоминанием башни Сююмбике считается зарисовка голландского путешественника Корнелиса де Брюйна, которую он выполнил в ходе путешествия по Волге в Персию.

Название «Башня Сююмбике» впервые появилось в 1832 году в казанском журнале «Заволжский Муравей». Прежние известные названия

башни: «башня Азиатской Архитектуры», «старинная башня», «коменданская башня».

«Сююмбике» переводится как «любимая госпожа». Башня называется в честь доброй и мудрой царицы Сююк (единственной царицы за всю историю Казанского ханства). Царица запомнилась людям отменой многих налогов.

Символизм этой семиярусной башни очень ясен, он олицетворяет силу мощного, исламского государства средних веков — Казанского ханства… Семь — очень значимое число в Исламе, и в преданиях в стихотворной форме татарского народа, в «бэет»ах, это всегда упоминается, что царица Сююмбика построила семярусную башню, рядом с могилой своего любимого мужа, которая выделялась и была видна издалека… Вот это и есть основная историческая роль этой башни, она и сейчас также прекрасно смотрится, соединяя прошлое с настоящей мощью Татарстана и столицы республики города Казань.

**Строительство**

Ученые не могут точно сказать, когда была построена башня Сююмбике — одна из главных достопримечательностей Казани.

Существуют предположения о примерной дате строительстве падающей башни Сююмбике в Казани:

- Башня была воздвигнута в XVII веке уже в российский период истории.
- Здание было построено в годы правления легендарной царицы Сююмбике.

С этой версией связана красивая легенда.

Якобы Иван Грозный узнал о красоте царицы, и направил в Казань сватов, — он предложил ей стать его женой и царицей Московского государства. Сююмбике ответила отказом, и разъяренный царь со своим войском подошел к Казани, и пригрозил стереть город с лица земли. Сююмбике испугалась за свой народ и приняла предложение Ивана Грозного, попросив у него необычный свадебный подарок — самую высокую башню города.За неделю была возведена 57-метровая башня — каждый день она вырастала на один ярус. Во время свадебного пира поднялась Сююмбике на верхний ярус, чтобы полюбоваться городом, и поняла, что не может покинуть родину, — тогда царица расплакалась и бросилась вниз. В память о доброй царице башню назвали ее именем.

**Как загадать желание у башни Сююмбике?**

Путешественники знают, что у падающей башни в Казани можно загадать желание! Если пожелать самим себе везения в любви или просто загадать свое заветное желание, то надо прислониться к башне или дотронуться лбом до ее стен.

**Экскурсии к башне Сююмбике**

По территории Казанского Кремля проходят обзорные экскурсии, во время которых можно увидеть падающую башню Сююмбике, и сфотографироваться на её фоне.

Вход на территорию Кремля свободный, попасть туда можно круглосуточно. Вечером и ночью башню освещают прожекторы, и включается красивая подсветка.

В саму башню Сююмбике зайти не удастся – туристы могут осмотреть ее только снаружи.

На территории Кремля путешественники могут купить сувениры с изображением одной из главных достопримечательностей столицы Татарстана.

**Литература**


1. Казань в памятниках истории и культуры. Под ред. С. С. Айдарова, А. Х. Халикова, М. Х. Хасанова, И. Н. Алеева. – Казань, 1982.
2. Саначин С. Иконография и планы Казанского Кремля о возрасте Сююмбекиной башни // Казань. – 2002. – № 9. – С. 37-47.
3. Халиков А.Х., Алишев С.Х. История Казани. Книга I. – Казань, 1988.


## МИЛЛИ ҖАНЛЫ ШАГЫЙРЬ (ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВ ШИГЪРИЯТЕНДӘ МИЛЛИ ПРОБЛЕМАЛАРНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ)


Арсланова Энҗе

Актанышның 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Солтанова И.Р.


Бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт күрсәткән, милләт борчуларын үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре шактый күп: Утыз Имәни, Габдулла Тукай, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый... Минем әлеге исемлекне милләт өчен җан атып яшәүче якташыбыз Фарсель Зыятдинов исеме белән дәвам итәсем килә. *“Безнең гомер” шигырь һәм поэмалар җыентыгы белән танышып чыкканнан соң, Фарсель Зыятдиновны милләтче шагыйрь буларак күз алдына китердем...*

Милләт язмышы... Безнең әдәбиятта милли проблемаларны яктырткан әсәрләр күп. Үз милләтен кайгырткан, аның үткәнен, бүгенгесен бөтен барлыгы белән чагылдырган язучы-шагыйрьләрнең иҗаты да онытылмый. Якташыбызның татар милләте өчен куйган хезмәтләрен санап бетерерлек түгел. Аның киңкырлы иҗатындагы төп үзенчәлек – ул халыкчанлык.Ф. Зыятдинов шигъриятенең үзәгендә торган лирик герой үзенең милли асылы, теле, тарихы, бүгенгесе һәм киләчәге хакына көрәшкә күтәрелгән милләтпәрвәр зат буларак күз алдына килеп баса. Халкының киләчәге турында кайгырткан галим ерак тарихка күз сала, татарның көчле тамырларын барлый.

Кыр казлары кебек каңгылдашып
Кайта татар изге иленә.
Тамыр төпкелләре тарта аны
Геннар тарта Болгар җиренә. (*“Кайту” 1994)*

Татарстан китап нәшриятында 2006нчы елда басылып чыккан “Безнең гомер” китабына кергән “Кайту”, “Бүленмәс бербөтен”, “Маңкорт монологы”, “Рәсәем минем”, “Манежда”, “Шовинист монологы”, “Әсир тургай” шигырьләрендә милли чарасызлык тасвирлана.

Ләкин турыдан-туры түгел, ә нечкә юмор, читләтеп әйтү, субъектив эчтәлек аша бирелә әлеге мәгънә.

Әче җилләр,
Кар бураннар куркытмады,
Гашыйк идең туган җиреңә...
Илләр сыкрап, җилләр елаганда,
Ышандың син
Бәхет тулы язның килеренә, - дип яза шагыйрь Г. Тукайга багышлап, 1964 елда.

Якташыбыз иҗатын өйрәнгәндә мин шигырьләрдә Тукай эзләре күрдем...

Туган җирен, үзенең милләтен ачуланып яратучы шагыйрь эзләре ул. “Сулкылдап тибә йөрәгең синең” шигырендә:

Күз яшьләренә ышанмый беркем –
Күпме яшәргә бил бөгеп, өркеп?
Үз **байлыгыңа** үзең бул хуҗа –
Тик шунда гына бетәр бу нужа.
Әйләнеп кара – үткәнең анда:
Гасырлар йөзә кайгы һәм канда, - дип Тукай кебек милләтебезгә киңәш бирә.

Беренче карашка юмористик рухта язылган“Әсир тургай” шигырендә шагыйрь Әтәч, Тургай аллегорик образларын куллана. Әтәч образы аша Россия хакимиятен, ә ireккә омтылучы Тургай образында татар милләтен күрсәтә, минемчә.

**Бөтенлек**не бетерәсең,
Һәлакәткә китерәсең...
Канунда юк һич мондый эш,
Очма, әй, тинтәк, кире төш!
Ә **тургай** бүген күктә – ирektә,
**Әтәчне** бирми ул элеп тә.
Кетәк таралыр – бармас күпкә:
Әсир кошлар талпына күккә! (*1995)*

Туган ил, милләт өчен борчылуы шигырьләрендә чарасызлык, сызлану, яшәешнең камил булмавы һәм шул камиллекне аңлы рәвештә җимерүне күреп тору,яшь аралаш көлү белән бергә усаллык та, үз хокукларыбызны якларга кушу да сизелә.Милләтебезнең бүгенгесе, киләчәге өчен әдипнең эче поша, йөрәге яна.

“Яңа коммунарлар”,“Маңкорт монологы” шигырьләрендә илебез язмышы, кыйбласыз яшәвебез, милли сыйфатларны югалту чагылыш таба.
Милләтләрме? Исемнәре белән
Җисемнәре бетте буталып.
Татардан да калып бара илдә

Маңкорт дигән уртак бер халык.

*(“Яңа коммунарлар”1997)*

Тирән мәгънәле шушы шигырьләрдә милләт язмышы, туган телнең киләчәге, бөтен җаваплылык, милләтебезнең зурлыгы да, хурлыгы да үзебезнең кулда булуын уйлап борчылган шагыйрьнең эчке авазы чаң кага…

Бүре кебек чәйнәп өзәр идем
“Милләт” диеп йөргән кешене.
Ягез әле, уйлап карыйк менә:
Паспорт бирү алар эшеме?
Милләт, телен язма, исемен боз –
Онытсын ул каян килгәнен...
Йөрсен: “Империя гражданы мин –
Укыгыз,
белегез,
көнләгез! – дип, ялгыш юлга баскан кешеләрне асылына кайтырга өнди.
*(“Маңкорт монологы” 1997)*

Татар халкы ничәмә-ничә еллар буе милли азатлык турында хыялланып яшәгән. Бу зур хыял Ф. Зыятдинов иҗатында да чагыла.

**Ю гөнаһың! 1998**

Күпме гасыр гадиләргә
Сан булмады бу илдә.
Изелгәннәр гел изелә –
Шаһит моңа Идел дә
Казан башка чыкмый торып,
Бәхет килмәс бу илгә.
Афәт кенә килә торыр –
Гөнаһың ю Иделдә!

**“Бербөтен” сүзе берничә шигырьдә кабатланып милли бердәмлек мәгънәсен ала**. “Бүленмәс бербөтен”шигырендә шагыйрь миләттәшләрне бердәмлеккә чакыра.

Аксак кәҗә йоткан ак гөлләр дә,
Ирекле һәм ирексез көннәр дә –
Барысы бүленмәс **бербөтен**,
Менә шулай, татар Бөркетем!...

Озак еллар дәвамында әнә шундый җитди: милли һәм рухи азатлык турында хыялланып яшәгән шагыйрь мактаган булып җәмгыятьтәге тәртипләрне хурлый. “ Рәсәем” шигырендә дә моны ачык күрәбез:

“Рәсәем”
Нинди гадел минем Рәсәй илем,
Тоеп яши моны халык та.
Парламентын утка тоткан илләр
Булды микән, сора халыктан.
Булыр микән тагын тарихта?!

**Ул үзенең иҗаты аша бүгенге көн проблемаларын, милләт язмышы хакында уйлануларын укучыга нечкә тоем аша җиткерә.**Аның

милләтпәрвәрлек хисе белән сугарылган шигырьләре халкыбызны гамьсез йокыдан уянып, уйланырга мәҗбүр итә.

Тере килеш йотар кебек бары,
Сыгыла калсаң әгәр, бил бөксәң,
Кыя ташы булып калыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм,
Менәреңне әгәр мин белсәм...(“Кыяташлар булып” 1998)

Шагыйрьнең шигырьләрендә милләткә карата чагылдырган проблемалар хәзер дә актуаль. Ләкин милләт, туган телнең киләчәге өчен битараф булмаган яшьтәшләрем дә бар. Бүгенге конференция дә – моның ачык мисалы. Димәк, халкы өчен яшәгән, тир түккән Габдулла Тукай, Шиһабетдин Мәрҗани, Гаяз Исхакый, Муса Җәлил һәм башка язучы, галимнәребезнең хезмәтләре заяга булмаган. Фарсель Зыятдинов кебек шәхесләребез әсәрләре яшәгәндә, милләтебез дә яшәр. Телне белгән яшьләр, балалар бар икән – ул сакланачак. Тел сакланса милләт тә, сәнгать тә, әхлак та сау калачак!

**Әдәбият**

1. Зыятдинов Ф. Безнең гомер. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006.
2. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2004.

## ТӘМЛЕ ТЕЛЛЕ БУЛЫЙК!

Ахунҗанова М.И.
Алабуга шәһәре Инженер-технология лицее укучысы
Фәнни җитәкче: Әхмәдуллина Р.Ф.

Тел, сөйләм – безнең байлыгыбыз, милли культураның бер өлеше. Сөйләм – кешенең гомумкультура дәрәҗәсен күрсәтүче билге дә.

“Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел”, “Тән ярасы төзәлә, җан ярасы төзәлми”, “Җылы җил бозны , яхшы сүз җанны эретә”, “Яхшы сүз - җан азыгы, яман сүз - баш казыгы”, - дигән халык . Әйе, сүз кешене сөендерә дә, көендерә дә, дәртләндерә дә.

«Сөйләм этикеты”– сөйләмдә иң еш очрый торган тәгъбирләрне куллану кагыйдәләре. Бу – сәламләү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, теләкләр белдерү, тәбрикләү, үтенү, киңәш бирү, чакыру, гафу үтенү, юату һәм башка тематик ситуацияләргә караган гыйбарәләр системасы.

Сәламләү формалары: Исәнмесез! Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич! Хушлашу формалары: Сау бул! Сау булыгыз! Исән бул! Исән булыгыз! Хуш! Хуш булыгыз! Кичкә кадәр! Иртәгәгә кадәр! Хәерле сәгатьтә! Хәерле юл! Ак юл! Юлың уң булсын !

Рәхмәт белдерү сүзләре: Рәхмәт! Рәхмәтләр укыйм! Аягың-кулың сызлаусыз булсын! Рәхмәт яугыры!

Яңа кием белән тәбрикләгәндә ( Котлы булсын! Җылы тәнеңдә тузсын! Рәхәтен күрергү насыйп итсен! Игелеге белән булсын! Өстеңдә киеп туздырырга язсын! һ.б. ) теләкләр белдерәләр.

Ашап утыручыларга (Ашларыгыз тәмле булсын! Сихәтле булсын! Һ.б.) теләкләр әйтелә.

Йортка килен килеп төшкәндә (Җиңел аягың белән! Бәхетең, тәүфыйгың белән! һ.б) сүзләр белән каршы алалар.

Эш башлаучыга гадәттә "Кулың җиңел булсын", -диләр. Эшләүчеләрне күргән очракта:"Алла ярдәм бирсен! Эшләрегез уңсын!"- дип теләк белдерәләр. Эшне башлап җибәргәндә:"Аллага тапшырдык, хәерле сәгатьтә ",-дигән сүзләр әйтелә.

Гафу итү сүзләренә *зинһар, гафу итегез,кичерегез* кирә. Үтенеч гадәттә боерык фигыль, -чы/че, -санә/-сәнә, -ла/лә кисәкчәләре һәм зинһар модаль сүзе кушылуы нәтиҗәсендә белдерелә: бирче, керсәнә, әйт,зинһар. Шулай ук эле, инде кисәкчәләре кулланыла: бирегез әле. Үтенечнең югары дәрәҗәдәгесе *үтенәм, ялварам* кебек сүзләр белән белдерәләр. Мондый үтенечләргә җавапны *ярый, ярар, әлбәттә, булдыра алмыйм, була* сүзләре белән бирәләр.

Татар халкы – кунакчыл халык. Өйгә кеше килеп кергәндә: Әйдүк! Рәхим итегез! Ашаган вакытта кеше килеп керсә," Мактап йөрисез икән, утырыгыз!"- дип әйтәләр. Кешене хуплаганда (Сез бик матурсыз! Сезгә бу кием бик килешә! һ.б.) сүзләр кулланалар.

Мөрәҗәгать итү сүзләре: Иптәшләр! Егетләр! Кызлар! Дуслар! Туганнар! Кардәшләр! Милләттәшләр! Якташлар! Һ.б.

Татар теленең үзенчәлеге булып туганлык терминнарын кулланып мөрәҗәгать итү тора: апа, абый, энем, апам, сеңлем, җизни, балдыз, әби, бабай.

Татарларда якыннарга, яраткан кешеләргә эшдәшүнең бербөтен системасы булдырылган. Алар игелеклелек, эмоциональлек белән аерылалар:кадерлем, сөеклем, алтыным, күгәрченем, былбылым, акыллым, аккошым, җаным.

Татар халкында шулай ук рус теле йогынтысында официаль аралашуда исем һәм әтисенең исеме формасы белән эндәшү таралган.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, әйдәгез, дуслар, татар телебезнең һәм халкыбызның матур, үрнәк булган сөйләмен саклыйк, күтәрик. Этикет формаларын онытмыйк, тәмле телле булыйк. Татлы тел ташны да эретә, тимер капканы да ача, диләр. Шулай ук яхшы сүзнең җан азыгы булуын да онытмыйк!

Ф.Яруллин: «Тел- халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау кагылмасаң чыңламый»,- дип язган. Әйдәгез әле әнә шул кыңгырауны ешрак чыңлатыйк!

Туган телне кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – мәдәниятле, зыялы һәр кешенең изге бурычы.

**Әдәбият**

1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре . – Яр Чаллы: КамАЗ, 1997. – 127 б.

2. Гыйззәтуллина Л. Татар телендә комплиментлар әйтү гыйбарәләре // Милли мәдәният. – 2008. - №15. – 44-45 б.

# ГӨЛЗАДА ӘХТӘМОВА ИҖАТЫНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ОБРАЗЫ

Әхмәдгалиев Ш.Р.
Алабуга шәһәренең 8нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Тимофиева Л.Г.

Әхтәмова (Ягъфәрова) Гөлзадә Хаҗи кызы Татарстанның Әгерҗе районы Исәнбай авылында 1941 нче елның 17 ноябрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә.Исәнбай урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Гөлзада бераз Сарапул шәһәрендә эшли һәм яши. Берникадәр вакыт сатучы, балалар бакчасында тәрбияче һәм мөдир булырга туры килә. Язмыш җилләре аны Алабуга шәһәренә китерә. 1969 нчы елда пединститутның филология факультетын тәмамлый, 1975 нче елга кадәр институт китапханәсендә библиограф булып эшли. Аннан соң Гөлзадә апа гаиләсе белән Себер якларына чыгып китә. 1984 нче елда Алабуга шәһәренә кайта. Башта шагыйрә экскурсияләр бюросында методист булып, ә инде 1986 нчы елдан урта мәктәптә татар теле укытучысы һәм китапханәче булып эшли. Шушы хезмәт еллары тарихи эзләнүләргә, язучылык эшенә зур этәргеч була.

2004 нче елда, зур хезмәт нәтиҗәсе буларак, “Йөрәктәге яшен” исемле зур шигырьләр җыентыгы басыла, һәм шагыйрә Татарстан язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителә.

Аның күңелендә һәрвакыт моң, җиткерәсе килгән кичерешләр, хисләр, гамь яши, һәм алар, үзлегеннән бәреп чыккан саф чишмә шикелле, шигъри юллар булып кәгазьгә күчә. “Халкымның үткәне йөрәгемне әрнетә, балаларга булган мәхәббәтем тормышыма ямь бирә, туган халкымның киләчәге борчый, табигать гүзәллеге сокландыра, илдә барган вакыйгалар битараф калдырмый,”- ди шагыйрә үзе. Нәтиҗәдә “Борынгы Алабуга”, “Мәхәббәтле иреннәре”, “Бүләк”, “Табигать сәйләннәре”, “Гөлчәчәк”, “Җәйге кар”, “Тылсым йорты” кебек күләмнәре зур булмаган китаплары дөнья күрә.

1996 нчы елда Гөлзадә Әхтәмованың 55 яшьлек юбилеен зурлап билгеләп үтелде.Марина Цветаеваның “Хөкем итмә син ашыгып...” дип исемләнгән китабы татар теленә Г.Әхтәмова тәрҗемәсендә басылуы да шагыйрь эшчәнлегенә карата зур соклану уята.

Минем кулыма аның “Тукай эзе “ дип аталган шигырьләр җыентыгы килеп керде. Бу китап 2011 нче елда Алабуга шәһәрендә, исеменнән күренгәнчә, Тукай елы уңаеннан басылып чыккан.

Гөлзада Әхтәмова – бөек Тукайның иҗатын һәм тормыш юлын җентекләп өйрәнгән кеше, чөнки ул үзе дә, Тукай кебек, барлык авырлыкларны үз көче белән җиңеп, алга атлаучы, халкын яратучы иҗади шәхес.

Гөлзадә Әхтәмова Габдулла Тукай иҗатына югары бәя биреп, аңа соклануын яшерми, аны тулган ай белән тиңли. Тукайның татар халкы өчен зур рухи байлык, маяк булуы турында ассызыклап әйтә, аның бүген дә “ сүрелмәс кояштан нур”лылыгын исбатлый. “ Без синең белән горур!- ди. Әйдәгез, бергәләп әлеге китап белән танышып үтик.

Аның беренче бүлеге, сабый чорыннан башлап, нәни Апушның күңеленә якты эз салган, даһи шагыйрь –Бөек Тукай булып үсеп җитүенә этәргеч биргән изге күңелле иң якын кешеләренә багышлана. Автор “Шагыйрь анасына”, ”Мәмдүдә абыстай”, “Мөхәммәтгариф хәзрәт” дип исемләнгән шигырьләрендә дөньяга нинди олы шагыйрь бүләк итүләрен дә белмичә бик яшьли вафат булган әти-әнисенең яхшы кешеләр булуын искә алып уза. Ятим калган Габдуллага ярдәм кулы сузучы, кочагына алып иркәләүче бердәнбер җан - әнисенең сеңлесе Саҗидә апасына халкымның иң җылы хисләрен җиткерә:

Рәхмәтебез бүген барып җитсен,
Дога кылыйк аның рухына:
“Сабый Габдулланың
Аз булса да хәлен җиңеләйткәнсең,
Саҗидә апа! Зур рәхмәт сиңа!”

Китапның икенче бүлеге “Тукай эзе” дип исемләнүе юкка түгел, Гөлзада ханым Тукайның, милләт шагыйре буларак, халык күңелендә калдырган эзен шигъри юллар белән ачып бирә:

Еллар узар, тик онытылмас Тукай,
Һәр шагыйрьнең йөрәгендә эзе.
Ана телен, үзенең туган телен
Яраттыра алыр газиз сүзе (“Тукай эзе”) [Әхтәмова 2011 : 17].

Автор бөек шагыйребезне “шундый гади, шундый гадел, шундый туры” дип сыйфатлый, шул ук вакытта “уяткан халык күңелен пәйгамбәрләрдәй булып”, дип, аның “күпне күргән, күпне белгән”леген әйтә. ”Нәкъ безнең халык шагыйре, татарга тигән өлеш” дигән сүзләре уйланырга мәҗбүр итә, дөнья халыклары арасында татар милләтенең хәзергә бербәнбер горурлыгы Тукай булуын аңлыйсың кебек.

Яз - халыкка Тукайны бүләк иткән һәм мәнгелеккә тартып алган ай. Нәкъ Равил Фәйзуллин әйткәнчә: “Яздан аерып булмый Тукайны!” Язны Тукайдан, Тукайны яздан башка күз алдына китереп булмый. Китапның өченче бүлеге дә “Язлар була Тукайлы” дип атала.

Габдулла Тукай нибары 27 ел гына яшәсә дә, безгә, киләчәк буынга, шундый тирән мәгънәле иҗади мирас калдырган. Гасырлар узса да, халкыбыз күңелендә ул югалмый, ул – мәңгелек!

...Халкым туган телен зурлап,
“Тукай көне”н үткәрә.
“Очты дөнья читлегеннән” шагыйрь...
Ә халкына калды зур мирасы [Әхтәмова 2011 : 28].

Китапның дүртенче бүлеге – нәтиҗә дияргә була, минемчә. “Халык шагыйре Тукай” ул – автор уйланулары, эссе. Аны тыныч кына укып булмый, чөнки авторның Тукайга булган керсез мәхәббәте, олы ихтирам, хөрмәт хисләре, аны чын күңелдән яратуы, горурлануы, хыял-омтылышлары – барысы да шулкадәр ихлас күңелдән язылган, ул самими хисләр укучы күңеленә дә кереп урнаша, йөрәкләр, бер-берсенә кушылып, ”Тукай” дип тибә башлый. Шагыйрәнең үз сүзләре белән дәвам итәсе килә:

“Милләтәшем Тукай! Синең иҗатыңа бәя биреп, зыялылар тарафыннан хәтсез генә китаплар чыгарылды, мәкаләләр язылды, фәнни эшләр башкарылды. Ә мин исә төрле елларда кыска- кыска шигырьләр яздым. Шулай итеп, бер цикл барлыкка килде. Мин – кеп-кечкенә бер шагыйрә. Бар язганнарым - сине чын күңелемнән ярату хисләремнең чагылышы, синең иҗатыңа сокланып баш июнең галәмәтеннәндер.

Җыентыкка күзәтү ясаганнан, өйрәнгәннән соң, шундый нәтиҗәгә килдем: Гөлзадә Әхтәмова, Габдулла Тукай турында шигырьләр язып, безне халык күңеленә тагын да якынайта. Безгә аның иҗатын тирәнтен өйрәнергә һәм аңларга ярдәм итә. Гөлзада Әхтәмова иҗатының тәрбияви әһәмияте бик зур. Рәхмәт сезгә, Гөлзада апа. Сез миңа Тукайны яңача ачарга, аның тормыш һәм иҗатына башкача карарга өйрәттегез.

Гомумән алганда, Гөлзада Әхтәмованың һәр әсәре - үзе бер сихри дөнья, үзе бер яңа ачыш. Мин Гөлзада Әхтәмованың иҗатын бик яратам, хөрмәт итәм, аның үзебезнең шәһәр кешесе булуы белән чын күңелән горурланам. Бүгенге көндә ул үз иҗат эшен дәвам итә. Хәзерге татар әдәбиятын менә шундый җирле иҗат итүчеләрдән башка күз алдына китерүе кыен.

Кыю фикерле көрәшче шагыйрь Габдулла Тукайның бер генә максаты:

“Татар бәхете өчен җан атармын:

Татар бит мин, үзем дә чын татармын,” – булган кебек, Гөлзада Әхтәмова –Ягъфәрова да татар бәхете, аның киләчәге өчен җан атып яшәүче шагыйрә, олуг зат- хатын-кыз!

Әдәбият


1. Әхтәмова Г. Алабугам минем. – Яр Чаллы: “КамАЗ” нәшрияты,1995.
2. Әхтәмова Г. Җәйге кар. – Яр Чаллы: “КамАЗ” нәшрияты, 2000.
3. Әхтәмова Г. Мәхәббәтле иреннәр. – Яр Чаллы: “КамАЗ” нәшрияты,1995.
4. Әхтәмова Г. Тукай эзе. – Алабуга, 2011.


## ӘХЛАК ҺӘМ ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯ ТУРЫНДА ТӨШЕНЧӘ


Әхмәдиева А.Ф.

КФУның Алабуга институты студенты.

Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Һәр кеше шәхес буларак формалашу чорыннан башлап әхлак субъекты буларак карала. Моңа бәйле рәвештә, балаларның әхлакый үсеше конкрет гаилә өчен генә түгел, ә дәүләт күләмендә белем бирү сәясәтенең төп бурычларының берсе булып тора (2025 нче елга кадәр чорга Россия Федерациясендә тәрбия бирүне үстерү стратегиясе). Шунысы да мөһим, хәзерге җәмгыятьтә бер төркем сәбәпләргә бәйле төстә әхлаклылык кискен торган мәсьәләләрнең берсе. Әлеге сәбәпләр рәтендә: “әхлак” төшенчәсенең чикләре “юылу”, яшь буынның приоритетлары алышыну, социаль челтәрләрдә, телевидениеда һ.б.ларда эчтәлеге түбән сыйфатлы булган мәгълүматны җиңел табу һ.б.лар. Аталган сәбәпләр җәмгыятьнең әхлакый йөзендә, балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыруда негатив чагылыш таба. Алай гына да түгел, дөньяда даими

рәвештә көтелмәгән үзгәрешләр (мисал өчен, COVID-19 пандемиясе чорында белем бирү өлкәсе белән бәйле үзгәрешләр) һәм әһәмиятле вакыйгалар килеп чыгып тора, шуңа күрә, әхлак формалаштыру, әхлакый тәрбия мәсьәләсе аеруча да мөһим мәсьәләләр рәтендә кала килә.

Әхлак төшенчәсе турында фикер йөрткәндә, аның шактый катлаулы төшенчә булуын искәртергә кирәк. Ул бер-берсенә бәйле булган, шулай да җитди рәвештә аерылып торган ике аспекттан тора:

- бер яктан, ул шәхесне характерлаучы сыйфатларны үз эченә ала (гаделлек, иманлылык, шәфкатьлелек һ.б.лар);
- икенче яктан, ул әхлакый нормалар, кануннар һәм таләпләр җыелмасы буларак аңлашыла (“үтермә”, “урлама”, “алдашма” һ.б.лар) [Хуҗиәхмәтов 2013].

“Татар теленең этномәдәният сүзлеге” буенча “халкыбызның буыннан-буынга бирелеп киленгән сыйфатлары – олыны олы, кечене кече итеп тану, сүздә, биргән вәгъдәдә тору, эшкә җаваплы карау, өмет, ышаныч, намус, вөҗдан кушканча, дус, күрше белән белән тату яшәү, гаилә нигезләрен ныгыту, укуга, бәхеткә омтылу һ.б.ш. – әхлак кодексы сыйфатлары булып тора” [Татар теленең этномәдәният сүзлеге 2017: 27].

Белгечләр “әхлак” төшенчәсенең эчтәлеген тагын да төгәлләштереп, аның үз эченә түбәндәгеләрне алуын искәртә:

1. Ватанга мөнәсәбәт (патриотизм, ватанпәрвәрлек) – туган илгә, тарихка, гореф-гадәтләр, йолалар, телгә мәхәббәт, ихтыяҗ туган очракта Ватанны сакларга әзер булу.
2. Хезмәткә мөнәсәбәт (хезмәт сөючәнлек) – хезмәтнең үзең һәм җәмгыять өчен файдасын аңлау, хезмәт күнекмәләре һәм осталыгы булу һәм аларны камилләштерүгә омтылу.
3. Җәмгыятькә мөнәсәбәт (коллективизм) – үз теләкләреңне башкаларның теләкләре белән килештерә, яраштыра белү.
4. Үз-үзеңә мөнәсәбәт – үзеңне хөрмәт итү, намуслылык һәм тугрылык, әхлакый чисталык, тыйнаклык.
5. Гуманлылык (гуманизм) [Габидуллина 2021: 353].

Һәр чорда кешеләр әхлак тәрбиясен югары бәяләгәннәр. Әхлакый тәрбия – өзлексез процесс булып тора, ул кешенең туган көненнән башлап бөтен гомере буена дәвам итә. Мондый тәрбия кешенең үз-үзен тотыш кагыйдәләрен һәм нормаларын үзләштерүгә юнәлдерелә. Әхлакый тәрбия төрле яклап үсеш алган шәхес формалаштыруда әйдәп баручы рольне уйный; ул акыл үсешенә дә, хезмәт әзерлегенә дә, физик үсешкә дә, эстетик хисләр тәрбияләүгә дә зур йогынты ясый. Белгечләр тарафыннан әхлаклылык тәрбияләү үз эченә түбәндәге компонентларны алучы комплекслы процесс буларак карала:

– кешенең әхлакый йөзе (кече яшьтән үк сабырлык, гуманлылык, миһербанлылык, шәфкатьлелек тәрбияләү);
– кешенең әхлак позициясе (төрле тормыш кыенлыкларын җиңеп чыгуда кыюлык, батырлык һәм ихтыяр көчен күрсәтү, яхшыны яманнан аера белү);

– кешенең әхлакый хисләре (намус, бурыч хисе, Ватанга мәхәббәт, өлкәннәргә кадер-хөрмәт);

– кешенең әхлакый тәртибе (тәрбиялелек, әдәплелек, күндәмлек, үз-үзеңне тота белү) [Хәйруллина 2018: 416].

Шулай итеп, әхлак төшенчәсенең нигезе булып гомумкешелек кыйммәтләре, идеаллары, кануннары тора. Әхлак тәрбиясе үсеп килүче буында шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, киң күңеллелек, рәхимлелек, ярдәмчелек, ихлас күңеллелек, гаделлек, өлкәннәргә хөрмәт-ихтирам, Ватанга мәхәббәт кебек уңай сыйфатлар формалаштыруны күздә тота.

**Әдәбият**

1. Габидуллина Ф.И., Шафикова З.Ф. Фәнис Яруллин хикәяләрендә әхлакый идеал чагылышы // Духовный мир мусульманских народов. (XVI Акмуллинские чтения): Материалы Международной научно-практической конференции, Уфа, 14 – 15 декабря 2021 года. Vol. III. – Уфа: Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы, 2021. – Б. 352 – 354.

2. Татар теленең этномәдәният сүзлеге: кешенең интеллектуаль һәм әхлак дөньясы лексикасы / Төзүче авторлар: Р.Р. Җамалетдинов, Р.С. Нурмөхәммәтова, М.Р. Саттарова, Ф.Р. Сибгаева. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2017. – 188 б.

3. Хәйруллина А.С., Латыпова И.Р. Татар теле дәресләрендә әхлак тәрбиясе // Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии: IX Международная тюркологическая конференция, Елабуга, 13–14 апреля 2018 года / Ответственный редактор Р.Б. Камаева. – Елабуга: Казанский (Приволжский) федеральный университет, 2018. – Б. 415 – 418.

4. Хуҗиәхмәтов Ә.Н., Насыйбуллов Р.Р. Педагогика: аңлатмалы сүзлек. – Казан: ТРИ “Школа”, 2013. – 196 б.

## БОЛГАР – ҮТКӘННӘРДӘН КИЛӘЧӘККӘ КҮПЕР

Әхмәдиева Р.Ф.
Алабуга шәһәренең 10нчы күппрофильле лицей укучысы.
Фәнни җитәкче: Нуриева З.М.

Болгар сүзен ишетүгә, милли үзаңы исән булган татарның җанында нindидер бер горурлык, рухи үзгәрешкә омтылу, халкыбызның шанлы үткәне белән танышу теләге туадыр кебек. Шулай булмаса, ел саен бу изге урынга меңәрләгән туристлар агылмас, анда булуны кече хаҗга барган кебек горурланып сөйләмәсләр иде. Мин үзем дә кечкенә вакыттан ук әти-әниләрем белән бу калага берничә тапкыр сәяхәт иттем һәм килгән саен анда үзем өчен яңадан-яңа ачышлар ясадым, бу каланың һәрчак үсеш-үзгәрештә булуын тойдым. Болгар турында проект эше эшләргә алынгач та, китап-белешмәләрдәге мәгълүматлар белән генә чикләнеп калмыйча, яңадан бер кат бу изге җирләрдә булырга, инде хәзер сәяхәтче буларак кына түгел,

тикшеренүче-эзләнүче буларак, бу гүзәл каланың һәр почмагын айкап чыгарга, бүгенге Болгарны рухым белән тоярга карар кылдым. Юлга кузгалганчы, лицеебыз укучылары, яшьтәшләрем арасында сораштыру үткәрдем һәм бу теманың бик актуаль булуын, зур кызыксыну уятуын, әмма күпчелек укучыларның Болгарыбыз турында аз мәгълүматлы булуын, бу шәһәрчекнең халкыбыз тарихында тоткан урынын, бүгенге әһәмиятен аңламауларын ачыкладым. Шушы проблеманы хәл итү максатыннан, фәнни эшебезнең темасын "Болгар – үткәннәрдән киләчәккә күпер" дип атадык.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендәге өч объект ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасын саклау оешмасы исемлегенә кергән. Болар: Казан кремле, Свияжск утравындагы Успенский соборы һәм Болгар шәһәре археологик комплексы.

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы — Татарстан АССРның Спас районы территориясендә 1965 нче елда оештырылган музей-тыюлык. Ул Татарстан Республикасында иң борынгы истәлекләрдән санала. Биредә Идел Болгарстаны 922 нче елда рәсми рәвештә Ислам динен кабул итә, дип санала. Әмма галимнәр арасында бу фикер белән килешмәүчеләр дә шактый. Алар фикеренчә, Болгарда ислам дине моңа кадәр үк шактый таралыш алган, дәүләт башлыгы да мөселман була. Ничек кенә булмасын, Болгар дәүләт музей-тыюлыгы татарстанлылар өчен генә түгел, бөтен Россия мөселманнары өчен дә изге урын булып тора.

Ак мәчет – яшь архитектура һәйкәле булуына карамастан, инде бүген ул Болгар шәһәре мәдәниятының алыштыргысыз бер өлеше булып тора. Ул 2012 нче елда шәһәргә керү урынына якын бер җирдә төзелгән. Ак мәчет төзү өчен 2400 тоннадан артык ак мәрмәр кулланылган. Бинаның купшылыгы һәм бөеклеге сәяхәтчеләрнең игътибарын җәлеп итә, ә шәрыкъ рухы һәм мәчетнең эчке бизәлеше шәрыкъ әкиятләре атмосферасын тудыра. Мәчет төзелешендә өлге буларак ислам дөнья архитектурасының иң яхшы үрнәкләре кулланылган. Ак мәчет ансамбле 88 шәрыкъ баганасыннан корылган аркадалы намаз уку мәйданчыгы, нәфис манаралар һәм оста башкарылган витражлы төп гөмбәздән гыйбарәт. Мәчетнең эчке бизәлеше бер дә ким түгел: намаз уку залы ярым айлы биек баганалар белән уратып алынган, диварлары Коръән аятьләре белән бизәлгән.

Коръән музее - Идел буе болгарларының Исламны кабул итү истәлеге билгесе. Зәвыклы итеп эшләнгән Коръән китабы һәркемнең игътибарын җәлеп итә, бизәлеше белән ислам диненең бөеклеген дәлилли. Коръән китабы Гиннесның рекордлар китабына кертелгән, 632 битле, авырлыгы 800 кг. Тышлыгы асылташлар белән бизәлгән .

Ак пулат - Болгар шәһәрендәге элеккеге мунча хәрәбәләре, халкымның чисталыкка мөнәсәбәтенә тарихи дәлил. Ак пулат әле 20 гасырның 60 нчы елларына кадәр сакланып килгән. Аннан соң ул бөтенләй җимерелеп, җир белән тигезләнгән. Археологлар аның бар кадәресен генә яңадан казып чыгарганнар, хәзер торгызу эшләре алып барыла.

Кара пулат - Болгардагы 14 нче гасыр урталарында төзелгән бина. Ул хәзер дә яхшы гына сакланган. Дүрт катлы бу таш корылманың түбәсе гөмбәз

рәвешендә эшләнгән. Аскы катның күп өлеше инде җиргә сеңгән. Аның як-ягында кечкенә генә бүлмәләр булган. Икенче катның дүрт ягында да икешәр, ә көньяк диварында өстәмә тәрәзәләр уелган. Өченче катта һәм сигез почмаклы итеп җиткерелгән дүртенче катның һәр ягында берәр тәрәзәсе бар.

Кече манара - Болгарның иң яхшы сакланган архитектура һәйкәле. Янындагы мәчет инде күптән җимерелеп беткән. Хан мәчетенең Олы манарасыннан аермалы буларак, халык аны Кече манара дип атаган. Аның биеклеге 12 метр чамасы, 48 басмалы әйләнгеч таш баскыч өскә алып менә. Баскычны яктырту өчен стеналарда кечкенә генә тәрәзәләр уелган.

Габдрахман сәхабә коесы Идел елгасы буенда, Болгар шәһәрлеге территориясендә, Татарстан Республикасы Спас районы Болгар шәһәре янындагы Идел буе бистәсенең төньяк-көнбатыш ягында урнашкан. Габдрахман сәхабә коесы бик яхшы төзекләндерелгән, территория койма белән әйләндереп алынган, юылган, эскәмияләр, беседкалар урнаштырылган, барысы да бик матур.

Җәмигъ мәчетеннән көнчыгышта Көнчыгыш мавзолей урнашкан. Болгарның башка һәйкәлләре кебек үк, аның да кабатланмас тарихы бар. Көнчыгыш мавзолей Болгар югары катламының каберлеге.Көнчыгыш мавзолей Төньяк мавзолей белән бергә шәһәрнең үзәк архитектура ансамбленә керә. Бина үзгәртеп корылган, реставрацияләнгән, ремонтланган. XVIII гасыр башында православие монастыре булу сәбәпле, ул яңадан төзелгән һәм чиркәү буларак кулланылган.

XIV гасырның 30 елларында җыелма мәчетнең төньяк фасадының төп керү урыны каршында Төньяк мавзолей төзелә, ул әдәбиятта «монастырь базы» исеме белән билгеле, чөнки ул Успение монастыренда азык-төлек саклау өчен кулланыла. Бай кешеләр каберләре өстендә мавзолейлар төзү мөселман дөньясында, шул исәптән Болгарда да киң таралган булган.

Фәнни-эзләнү эшебезнең башында без: “Болгар элек-электән милләттәшләремнең изге җир буларак табыну урыны булган һәм киләчәктә дә милли рухыбызны саклауга хезмәт итәчәк”, - дип фаразлаган, - “Бүгенге Болгарны яшь буын күзлегеннән сурәтләү, аның милли үзаңыбызны, халкымның генетик хәтерен саклаудагы әһәмиятен билгеләү”, - дигән максат куйган идек. Эзләнү эше барышында Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының оешу тарихын өйрәндек, моның өчен күп кенә чыганакларга мөрәҗәгать итәргә, шактый каршылыклы фикерләрне анализларга, бүгенге көн күзлегенннән караганда тормышчан дип табылганнарына тукталырга, дәлилләр эзләргә, Болгар тарихына күзәтү ясарга, Болгардагы һәр тарихи истәлекнең тарихын, ни өчен шулай аталуын ачыкларга туры килде. Бу теманың шактый кызыклы булуын, бәхәсләр уятуын күрдек.

Әлеге тыюлыкның юкка гына ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Исемлегенә кертелмәвен, Идел Болгарстаны, Алтын Урда тарихында гаҗәеп әһәмиятле ядкарь, күз карасы кебек сакланып, татарлар, ягъни безнең тарихыбызны киләчәк буыннарга җиткерерлек ачык һавадагы һәйкәл булуын ачыкладык.

## **Әдәбият**

1. Җәмил Мөхәммәтшин,тарих фәннәре кандидаты,“Болгар” музей-тыюлыгы хезмәткәре. Шәһре Болгар ташлары тарих сөйли... https://dumrt.ru/articles/society/society_7665.html
2. Объекты Всемирного наследия ЮНЕСКО в России Л. Б. Волкова, М. Ф. Лужковская, сост., Санкт-Петербург гос. университет, 2017.
3. Фәхретдинов Р.Г. Татарстан һәм татар халкы тарихы. – Казан: Мәгәриф, 1995.

## ДӘРЕСЛӘРДӘ УЕННАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

**Әхмәтҗанова Р.И.**
КФУның Алабуга институты колледжы студенты
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Укыту системасында уеннарның әһәмияте бәхәссез. Белем бирү процессы һәрвакыт гадидән катлаулыга таба барырга тиеш. Шул форсаттан файдаланып, дәрестә дә теманың нигезен тәшкил иткән материалга нәкъ менә уен ярдәмендә якын килергә кирәк. Шулай итеп мөгаллим укучыда туган теленә карата кызыксыну, мәхәббәт уята. Татар теле дәресләрендә катлаулы тема аңлатканда да уен элементларын кертеп, дәрескә дөрес якын килсәң, укыту методларын саклап эш итсәң, укучының теманы кабул итү мөмкинлеге күпкә җиңел була.

Уеннар баланың шул фән белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, зирәклеген, тапкырлыгын үстерә, аны милли бердәмлек рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә.

Уеннарның эчтәлегенә күз салсаң, аларның тормыш-көнкүрешнең һәм хезмәт төрләренең бер чагылышы икәненә ышанасың.

Уен дигәннән, кешелек җәмгыятенең үсеш дәверендә хезмәт формаларын чагылдыру рәвешендә барлыкка килгән, яшь буынны физик һәм әхлакый, эстетик яктан тәрбияләү вазыйфасын һәм шулай ук олылар өчен күңел ачу, вакыт үткәрү һәм көнкүрештә берәр эш-шөгыльне, йоланы үтәү вазыйфасын башкаруы мавыктыргыч чаралар системасын аңларга кирәк.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен арттыруда, аларның үз фикерләрен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, укыту һәм тәрбиянең бердәмлегенә ирешүдә, шулай ук балаларны тел фәне белән кызыксындыруда уеннарның әһәмияте гаять зур. Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар укучыларның эшчәнлеген активлаштыра, аларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә һәм иҗади халәт булдыра. Уеннар вакытында фән нигезләрен үзләштерү белән бергә укучы үз фикерләрен дәлилли белү күнекмәләре дә ала.

Шулай итеп, уеннар бала тормышында әһәмиятле урын алып торалар, белем һәм тәрбия бирүдә мөһим чыганак булалар.

Дәресне тулысынча уен формасында үткәрергә дә, моңа аның бер өлешен генә багышларга да мөмкин. Яңа теманы өйрәнгәндә гадәттә дәреснең бер өлешенә генә уен элементы кертеп җибәрәләр, ә тулаем бер бүлекне

төгәлләгәндә, кабатлау дәресләрен сәяхәт-уен дәресләр итеп оештырсак күпкә отышлы була.

Аеруча кече яшьтәге балага белем һәм тәрбия уен аркылы бирелә, уйналган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала. Шуның өчен укытучы, татар теле фәненнән белем һәм тәрбия бирү бурычын күздә тотып, тел дәресләрендә балаларның уеннарын максатка ярашлы итеп оештырырга тиеш [Волкова 2004: 66].

Татар теле дәресләрендә, аерым тел фактын өйрәнгәндә, сөйләү һәм язу күнекмәләре биргәндә, мавыктыргыч уеннар белән читенлек ситуациясе тудырылырга, уен элементлары кертеп, проблемалы сорау һәм мәсьәләләр куелырга тиеш. Аларны чишү балада үз көченә ышану тойгысы уята, аннан зуррак эшләрне башкаруга, катлаулы күнегүләрне эшләүгә дәртләндерә, максатка ирешүдә бернинди киртәләр алдында да тукталып калмау сыйфатын формалаштыра.

Дәрестә уеннар оештыру – укытучының актив формалары һәм методларыннан файдалану ул.

Шулай итеп, уен формаларының дәрестә актив кулланылышы иң беренче чиратта, әлеге теманың педагогогик өлкәдә дә, уку-укыту сферасында төп рольне алып торуы белән, хәзерге заманда яңа укыту стандартлары пәйда булуы белән бәйле.

Әдәбият

1. Волкова Р., Гарәфетдинова Р. Башлангыч мәктәптә татар телен чит тел буларак өйрәтүдә уен алымнарын һәм методларын куллану. – Казан: Мәгариф, 2014. – 128 б.
2. Саттарова Н. Шәхесне тәрбияләүдә уен // Мәгариф. – 2004. – № 2. – Б. 42-44.

## М.МӘҺДИЕВ ИҖАТЫНДА МӘДӘНИ МИРАС САКЛАНЫШЫ БУЛАРАК ҖЫРЛАР

Әхмәтҗанова Х.Д.
Арча районы, Утар-Аты төп гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Касыймова З. Г.

Якташ язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев укуларына бирелгән әлеге тема белән танышкач, иң беренче эшем итеп, аңлатмалы сүзлектән мәдәни мирас сүзен эзләп таптым. “Мәдәни мирас ("милли мирас" яки "мирас") — бер төркем яки җәмгыятьнең элекке буыннардан калган, бүгенге көндә яшәүче һәм киләчәк буыннарның файдасы өчен сакланылган мәдәни кыйммәтләр”,-дип аңлатылган анда. Җәмгыять белеме дәресләрендә без “мирас” төшенчәсен өйрәнеп үткән идек. Ул вакытта өйрәнелгән мирас сүзе әлеге конференциядә катнашырга әзерләнгәндә миңа бөтенләй башка яктан ачылды.

Мирас... Ул буыннан-буынга, гаиләдән-гаиләгә, ата-анадан балага күчеп килә торган байлык. Матди мирас кайчандыр бер бетәргә, югалырга, тузарга мөмкин. Ә менә мәдәни мираска керүче төрле йола, гореф-гадәт һәм

бәйрәмнәребез югалмаган да, бетмәгән дә, чөнки алар безнең рухи мирасыбыз, халыкның яшәешен күрсәтеп торучы төп билге.

Минем халкымның мәдәни мирасы бик зур, бик күп төрле. Бик авыр булган заманнарда да үзенең әһәмиятен һич киметмичә бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән бит ул! Татар халкының мәдәни мирасы безгә, яшьләргә дә, киләчәк буыннар өчен дә кызыклы, аңлаешлы.

Мәдәни мирасыбызга якташ язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев аеруча күп мөрәҗәгать итә. Аның әсәрләрендә татар халкының бар яшәеше картина кебек күз алдына килеп баса. Сугышка кадәрге авыр елларда татар авылларының тормышы, сугыш чорында кешеләрнең җиңүгә зур өмете куренә бу әсәрләрдә. Ничек кенә авыр еллар булмасын, халык үзенең гореф-гадәтләрен онытмый, шулар белән яши, авырлыкларны җиңеп чыга.

Мәһдиев иҗатында мәдәни мирасыбызның сакланышын ачыклар өчен, мин авторның берничә хикәясе белән танышып чыктым. Шуңа игътибар иттем, Мөхәммәт Мәһдиев үз хикәяләрендә халык җырларын да, төрле авторлар тарафыннан язылган җырларны да күп файдаланган. Кайбер җырларның сүзләрен дә үзенчә итеп үзгәртеп җибәргән. Ә кайберләрен бер дә үзгәртмичә кертеп, тулы бер хикәя иҗат иткән. Мин укыган “Арслангали” хикәсендә Мөхәммәт абый без хәзер дә яратып җырлый торган “Матур булсын” җырын куллана. Бу хикәя 1968 нче елда язылган. Автор бик җиңел тел белән мәктәп тормышын сурәтли. Аның һәр җөмләсе елмаю тудыра, укыган саен укыйсы килеп тора. Хикәянең төп герое –укытучы Мәлик. Ул һәрвакыт дәрескә соңга калып килүче, гел “аркылыга” үсүче Арыслангалине тәртипкә өйрәтергә тели. Нинди генә чаралар кулланып караса да, уңышсыз булып чыга. Укытучыны Арыслангалиның җыр яратуы коткара! Мөхәммәт Мәһдиев татар халык җырын Арыслангалидан шулкадәрле матур итеп җырлата, әсәрне укыганда шул җыр колакка ишетелә дә, үзең дә сизмәстән, кушылып җырлап җибәрәсең!

...Илебезнең халыклары
Матур тормыш коралар.
Тыныч булсын, тыныч булсын,
Тыныч булсын дөньялар!..

Инде танылган артист булгач та, Арыслангали татар халкының “Матур булсын” җырын зур сәхнәләрдән башкара. Карт укытучы Мәлик радиоалгычтан шушы җырны башка бер тапкыр да дәрескә соңга калып килмәүче Арыслангали башкаруында тыңлый.

Мөхәммәт Мәһдиев бу хикәясенә башка бер җырны да кертә алган булыр иде. Тик халкыбызның тынычлык яратуын ул шушы хикәясендә тагын бер тапкыр искә ала. Хикәя үзе дә, халкыбыз җырлары да бүгенге көндә бик актуаль шул. Башка бик күп әсәрләрендә дә Мөхәммәт Мәһдиев җырларга мөрәҗәгать итә. Мәдәни мирасыбыз булган җырлар Мәһдиев әсәрләре аша безгә килеп җитә. Менә мин буген, шыпырт кына шушы җырны көйләп йөрим:

Тыныч булсын, тыныч булсын,
Тыныч булсын дөньялар!..

1.Мәһдиев М.Әсәрләр. 10 томда. Том 10. – Казан: Татар кит. нәшр., 2019.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ҺӘМ ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЧАРАЛАРДА Р. ФӘХРЕДДИН ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯШЬ БУЫНГА ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ БИРҮДӘГЕ ӘҺӘМИЯТЕ

Әхмәтшина И.И.
Лениногорск шәһәренең 4 нче урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Мортазина А.Ф.

Туган ягыбызның мәгърифәтчесе Риза Фәхретдиннең әсәрләрендә яшь буынны тәрбияләү мәсьәләләре, гаилә белән мәктәп, тәрбия белән хокук мөнәсәбәтләре игътибар үзәгендә булган.

Мәсәлән, борынгы римлеләр, балага иң яхшы, иң камил тәрбияне тик гаилә генә бирә ала һәм гаилә генә бирергә тиеш, дип уйлаганнар. Борынгы греклар исә мондый өстенлекне мәктәпкә биргәннәр.

XVIII гасырда яшь буынны тәрбияләп үстерүгә караш үзгәрә башлый. Күренекле татар мәгърифәтчеләре Ш.Мәрҗәни, К.Насыйри, Р.Фәхреддиннәр фикеренчә, бала тәрбиясе өчен гаиләнең бердәмлеге, ныклыгы, ананың бала җанлы, укымышлы, мәдәниятле булуы төп шарт.

Р.Фәхреддин кеше тәрбияләүне һәм камилләштерүне үзенең асыл максаты итеп саный. Хезмәтләрендә, милләтне аң-белемле, һөнәрле итү белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур иътибар бирә. Моңа дәлил итеп, аның тарафыннан тәрбия, әхлак мәсьәләләренә багышланган унбер исемдәге җитмештән артык китап язылуын күрсәтергә мөмкин. Октябрь инкыйлабына кадәр барлык татар мәдрәсәләрендә тәртип, әдәп, әхлак, этика, эстетика дәресләре укытылган һәм Ризаэддин бине Фәхреддиннең элеге китаплары шул дәресләрдә кулланылган.

Олуг галим Ризаэддин Фәхреддиннең тәрбия темасына багышлап язылган хезмәтләре кешелек дөньясы өчен әйтеп бетермәслек зур кыймматкә ия. Бу хезмәтләр- бөртекләп җыелган җәүһәрләр. Р.Фәхреддиннең әдәплелек дәресләрендә өйрәнелә торган “Тәрбияле бала”, “Тәрбияле ана”, “Тәрбияле ата”, “Үгет-нәсыйхәт” китаплары барлык яшьтәгеләр өчен дә, мәдәният һәм мәгърифәт әсәрләре буларак, тәрбия өлкәсендә алтын фондны тәшкил итә.

Аның чын мәгънәсендә күпкырлы галим булуына ышаныр өчен ул күтәргән мәсьәләләрне атап чыгу да җитә: әхлак, тәрбия, тормыш-көнкүреш, гаилә, никах, дуслык, дошманлык, сугыш, тынычлык, хөкүмәт һәм аның җитәкчеләре, дәүләт эшлеклеләре, суд эшләре, коллык, хөррият, шагыйрьләребезнең җыр һәм шигырьләре, халык җырлары, кунак булу, кунак итү, ашау-эчү әдәпләре, тәмәке һәм аракының зыяны, яхшы холыклар, бозык һәм яман холыклар, милләт, миллият, фәлсәфә һәм тарихы һәм башкалар.

Р.Фәхреддин үзенең әсәрләрендә җәмгыятьтә шәхес тәрбияләүнең никадәр авыр, катлаулы һәм дәвамлы эш икәнлеген ассызыклап яза. Яшүсмерләрдә кешелеклелек сыйфатлары формалаштыру- бик мөһим проблема. Халык педагогикасының да төп бурычы булып халыкны кешелеклелеккә, мәрхәмәтлелеккә өйрәтү тора бит.

“Адәбе тәгълим” исемле китабында Р.Фәхреддин болай яза: «... Тәрбия – акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер... Сабанчы вә бакчачылар – орлык чәчмәстән вә җимеш икмәстән элек җирләрен ни кадәр игътибар белән йомшартулары, чүп вә бозык үләннәрнең хәтта тамырларына кадәр чыгарып ташлаулары мәгълүмдер. Бу исә җир тәрбиясе булып, җир эшкәртү ысулынча мөһим бер шарттыр. Бу төркемнән бөек вә гүзәл кеше итәчәк кемсәләрне сабый вакытларында тәрбия итү тиеш килер. Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә – гүзәл кеше дә җитешмәс.Шулай икән, тәрбия - иң кирәкле бер эш булачактыр...» [Миңнегулов 1998: 8].

Тәрбия эшенең нечкәлекләренә һәм үзенчәлекләренә тукталып, галим аны чорларга бүлеп карый һәм шәхес тәрбияләүдә гаилә, мәктәп һәм җәмгыятьнең рольләре гаять зур икәнлегенә басым ясый. Гаиләдә булган тәрбия – “беренче” тәрбия. Мәктәптә булган тәрбия – “икенче” тәрбия. Аннан соң булган тәрбия – “өченче” тәрбия ди. Аның фикеренчә, һәр кеше гадел булганда гына максатына һәм теләгенә ирешә алачак. “Гүзәл холыкларның иң гүзәле– гаделлектер”- дип яза галим. Галимнең “Тәрбияле бала” хезмәтен һәр уку йортының диварларына алтын хәрефләр белән язып куяр идем мин.

Үзенең “Тәрбияле бала” исемле китабында остазыбыз Р.Фәхреддин болай дип яза: “Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык китерер, дөнья байлыгына бирелми, берни белән дә алыштырылмый” [Миңнегулов 1998].

Р.Фәхреддин һәртөрле бозыклыкларга, аеруча, эчүчелеккә каршы гомере буе көрәшә, кешеләрнең начар юлга басуы аны хафага сала. Үзенең “Юаныч” исемле хезмәтендә яшь буында эчүчелеккә карата нәфрәт хисләре тәрбияләүнең үтемле чараларын күрсәтә. Ана буласы кызларымның тәрбия мәсьәләләренә аеруча игътибар итәм. Галимнең кыз балаларга мөрәҗәгать итеп язган сүзләре дә гыйбрәтле: “Холкы гүзәл булган кыз бала – бөтен гаиләсе өчен олуг байлык вә бәхеттер,... укыган вә холкын тәрбияләгән кыз – алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр,... мондый кызлар карендәш- кабилә өчен генә түгел, бәлки бөтен милләт вә бөтен дөнья халкы өчен дә мактаныч булыр” . Галимнең тәрбия китапларында пакьлек, төрле авырулар, ашау-эчү кагыйдәләре, өс һәм аяк киемнәре һәм башкалар хакында мәгълүмат һәм киңәшләр китерелә. Бу олуг галимебезнең һәр сүзе хикмәт һәм могҗиза белән тулган.

Мәшһүр мәгърифәтче галим Ризаэддин бине Фәхреддин нинди генә вазифа башкарса да һәм нинди генә фән тармаклары белән шөгыльләнсә дә, аның игътибарыннан уку-укыту һәм тәрбия-әхлак мәсьәләләре беркайчан да читтә калмый. Бу эше белән ул гомере буе шөгыльләнә һәм педагогика мәсьәләләренә багышлап 77 китап бастырып калдыра.

Дөнья нинди генә катлаулы һәм каршылыклы булмасын, кешелекнең киләчәге кешегә, аның әхлакый сыйфатларына, рухи байлыгына бәйле. Ә гуманлылык шәхеснең әхлак сыйфатлары җыелмасы буларак, кешелеклелекнең иң югары үлчәү берәмлеге булып тора. Безнең тарихыбыз булган Р.Фәхреддин

хезмәтләрен без онытмаска, шәхес тәрбияләүдә иң мөһим һәм кирәкле чыганак дип санарга тиеш.

Әдәбият

1.Миңнегулов Х. Ризаэтдин Фәхретдин/ Х. Миңнегулов, Ш. Садретдинов// Урта гасыр һәм 19 нчы йөз татар әдәбияты. – Казан: “Китап” нәшр.,1998.

2.Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. 2 кисәк. – Казан, 2006.

3. Ризаэддин бине Фәхреддин: Тормыш юлы, иҗади мирасы. Дәреслек-хрестоматия/ Төз.-мөх. Р. Шаһиев. – Казан: РИЦ “Школа”, 2007.

4. Фәхреддин Р. Нәсыйхәт. – Казан:"Мәгариф", 2005.

5.Хәйри Ә. Ризаэтдин Фәхретдин әсәрләрендә тәрбия-әхлак мәсьәләләре.- Әлмәт: ӘлМИ нәшр., 2004.

## ФОЛЬКЛОР - КҮҢЕЛ КӨЗГЕСЕ

Әхтәмҗанова А.И.
Алабуга шәһәре Инженер-технологик лицее укучысы.
Фәнни җитәкче: Шакирҗанова Н.Г.

Без югары технологиялар заманында яшибез. Бүгенге чорның төп сыйфатлары – ыгы-зыгылык, кабалану, максатсыз ашкыну.... яшәү шартларының үзгәреше, гомумкешелек кыйммәтләре алышыну адәм баласының рухи дөньясына да тәэсир итмичә калмый. Җир йөзендә яшәп килүче меңнәрчә халыкларның үз йөзен саклап калу мәсьәләсе бүгенге көндә халыкара мәдәни оешмаларның үзәк проблемаларына әйләнде.

Татар фольклоры, ягъни татар халык иҗаты дип нәрсәгә әйтәбез – шуны ачыклап үтик. Халык вәкилләре тарафыннан телдән иҗат ителеп, күп еллар, хәтта гасырлар буе халык хәтерендә сакланып килгән чәчмә яки шигъри әсәрләр җыелмасын халык иҗаты дип атыйлар. Аерым алганда , сүз риваять, легенда, әкият, мәзәк, дастан, җыр , бәет, мәкаль, әйтем, табышмак кебек әсәрләр һәм аларның барысын гомумиләштереп атау хакында бара. Татар фольклоры халыкның рухи дөньясында бик үзенчәлекле урын алып тора, чөнки анда халыкның яшәү мәгънәсе чагыла. Әхлаклы булырга өндәүче изге уй-ниятләр, өмет-ышанычлар күренә.

XX гасырның уртасына кадәр фольклор бары тик телдән иҗат ителгән бер тармак буларак кына каралган.

Фольклор барлыкка килгәннән бирле ул күп тел белгечләренең, галимнәрнең, язучыларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Халык авыз иҗатын тирәнтен өйрәнү XX гасырның 50-60 елларына туры килә. Нәкъ тә шушы елларда аерым бер фән тармагы – лингвофольклористика барлыкка килә. Ул халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, бастырып чыгару һәм өйрәнү белән шөгыльләнә. Әлеге тармак барлыкка килгәнче тарихи-филологик, этнографик һәм башка яклардан аерым гына өйрәнелгән. Фольклорны икенче төрле

өчпочмак дип тә атап була, ул үз эченә лингвистика, тел белеме һәм этнографияне алган.

Тулаем алганда, татар халык иҗатының XX гасырдагы тарихи язмышы зур тикшерү сорый. Аны өйрәнү барышында халык иҗаты мәгълүматларына гына төртелеп калу ярамый.

Халык һәм ил тарихын, анда булган җитди, кискен үзгәрешләрнең нигезләрен тиешле дәрәҗәдә аңлату бугенге фольклор фәненең әһәмиятле бурычлары булып тора.

Киләчәк буынга халкыбызның гасырлардан гасырларга тапшырылып килгән тәҗрибәсен, зирәк акылы тудырган иҗат җәүһәрләрен тапшыру – безнең бурычыбыз.

Халык исән булганда, аның фольклоры да яшәр. Халыкның милләт буларак яшәеше турында кайгыртырга кирәк. Бу – безнең уртак бурычыбыз.

Әдәбият


1. Габдрахманов Н. Халык традицияләре җирлегендә. – Мәгариф. – 1998, - №1.
2. “Түгәрәк уен” журналы. – 2011, – №1.
3. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2002, - 335 б.


## ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ОХШАШ ЯКЛАРЫ.


Бадикова Ә.Р.
Алабуга шәһәре Инженер-технология лицее укучысы
Фәнни җитәкче: Җиһаншина М.И.


Бүгенге көндә безнең мәктәпләребездә берничә тел өйрәнәләр. Шуларның берсе - рус теле һәм икенчесе - татар теле. Татарстанның барлык мәктәпләрендә дә бу ике телне өйрәнү мөмкинлеге бар. Аларны өйрәнүдә бернинди дә кыенлыклар килеп чыгарга тиеш түгел, чөнки бу ике телнең дә охшаш яклары бик күп. Мин үземнең эшемне татар һәм рус телләрендәге исем һәм сан сүз төркеменә багышлыйм.

Ике телдә дә сүз ясалышы, яңа сүзләр ясалу ысулларын, аның төзелешен, төрләнешен, сүзләрне төркемнәргә бүлеп, шул сүз төркемнәрен өйрәнә торган тел белеменең морфология бүлеге өйрәнә.

Исем сүз төркеме рус телендәге кебек үк предметны белдерә, кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә һәм төрле җөмлә кисәге булып килә ала. Татар телендә исем сүз төркеме рус теле белән чагыштырып караганда, ике үзенчәлеккә ия. Беренчедән, татар телендә род категориясе юк, икенчедән татар телендә исемнәр тартым белән төрләнә. Соңгы категориягә аерым игътибар бирергә кирәктер.

Исем сүз төркеме татар телендә алты килеш белән төрләнә. Ләкин аның рус телендәге исем сүз төркеменнннән аермалы яклары бар. Беренчедән, татар телендәге килешләр баш килеш һәм төшем килешеннән кала рус телендәге

килешләр белән туры килми, икенчедән, татар телендәге килеш кушымчалары бер генә мәгънә белдерәләр.

Татар телендәге исем сүз төркемен рус теленеке белән чагыштырганда тагын бер үзенчәлек ул тартым категориясе һәм исемнең үзгәрешсез тамырына төрле кушымчаларның ялгану тәртибе. Мәсәлән:

Минем китабым – моя книгаБезнең китабыбыз – наша книга
Синең китабың – твоя книга      Сезнең китабыгыз – ваша книг
Аның китабы – его (ее) книгаАларның китабы – их книга
Исемнең тамыры тартык авазга тәмамланганда да кушымчаларда үзгәрешләр күзәтелә. Бу очракта тамыр белән кушымчаны ялгау өчен -ы, -е сузыклары өстәлә. Ә өченче затта тамырга сузык аваздан соң -сы, -се кушымчалары ялгана. Рус телендә исем сүз төркемнәре зат-сан белән төрләнеп килгәндә, аларга кушымчалар ялганмый.

Татар телендә сан категориясе рус теленеке белән тулаем алганда тәңгәл килә. Ләкин бер аз үзгәрешләр бар. Ул –лар, -ләр; -нар, -нәр кушымчалары ярдәмендә барлыкка килә. Төп аермалар менә шунда:

Татар телендә кушымчалар тамыр исемгә билгеле бер тәртиптә ялганалар. Мәсәлән, тамыр + сан кушымчасы + тартым кушымчасы + килеш кушымчасы. Китапларымда – в моих книгах. Кайбер очракларда тартым кушымчасы белән килеш кушымчасы икесе бергә ялгана. Китапларым(г)а – китапларыма, в мои книги, к моим книгам.

Менә без исем сүз төркеменең татар теле белән рус теле арасындагы уртак якларны һәм аермалыкларны күзәттек. Һәм гомумән алганда, рус телендәге имя существительное белән татар телендәге исем сүз төркеме арасында әллә ни үзгәрешләр юк дигән нәтиҗәгә килдек.

Ә хәзер сан сүз төркемен карап үтик.Алда әйтеп киткәнемчә, мин бүгенге эшемдә саннар турында аларның ясалышының ике телдә дә  охшашлыгын язып үтәрмен.

Сан(имя числительное) – ике телдә дә предметның төгәл исәбен, санау тәртибен, чама белән әйтелгән микъдарны белдереп килүче сүз төркеме.

Татар телендә тамыр саннар – утызлап кына, башка сүз төркемнәре белән чагыштырганда, бу бик аз. Мәсәлән: бер,ике, ......., триллион һ.б.Бу саннар ике һәм аннан күбрәк компонентлардан торган бик күп яңа саннар ясауда катнашалар.

Ике компонеттан торган саннарны кушма саннар (унбиш, егерме ике, ике йөз һ.б.). Кушма саннар ике телдә дә  һәрвакыт кушылып языла: унөч – тринадцать.Компонентларының саны икедән артык булганда  - тезмә саннар дип йөртелә. Ике телдә дә  тезмә саннар аерым язылалар: утыз ике – тридцать два.

Татар телендә ясалма саннар түбәндәге юллар белән барлыкка килә:
100 гә кадәрге саннарның компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушу юлы белән, мәсәлән: ун+бер = унбер, ..., егерме+биш=егерме биш,..., туксан+тугыз=туксан тугыз;

100 дән соңгы саннарның компонентлары ияртүле бәйләнеш нигезендә тапкырлау юлы белән, мәсәлән: бишХйөз (биш+йөз түгел) = биш йөз, икеХмең (ике+мең түгел) = ике мең һ.б.

Без өйрәнә торган ике телдә дә саннар мәгънә һәм морфологик билгеләре буенча берничә төркемгә бүленәләр:
-микъдар саннары – количественные числительные (мәсәлән: бер –один, ике-два һ.б.);
-җыю саннары - собирательные числительные (мәсәлән: өчәү – трое, дүртәү – четверо һ.б.);
-тәртип саннары – порядковые числительные (мәсәлән: бишенче – пятый, җиденче –седьмой, унынчы – десятый һ.б.).

Татар телендә, болардан тыш, бүлем (биш+әр, җиде+шәр һ.б.) һәм чама саннары (мәсәлән: егерме+ләп, ун+лап, мең+ләгән һ.б.) да бүлеп чыгарыла. Ә рус телендә мондый бүленеш күзәтелми.

Ике телдә дә микъдар саннары (количественные числительные) башка сан төркемчәләрен ясауда нигез булып тора.

Димәк, мәгънәләре һәм кулланыштагы үзенчәлекләре буенча татар һәм рус телләрендәге саннар арасында күпмедер күләмдә охшашлыклар бар, шуңа күрә аларны өйрәнгәндә кыенлыклар килеп чыгарга тиеш түгел.

Әдәбият

1. Камчатов А.М.,Николина Н.А. Введение в языкознание: Учебное пособие: Для студентов, асперантов, преподавателей-филологов. – М.,Флинта: Наука,1999. – С.145-146.
2. Татар грамматикасы: Өч томда. Т.I. – М:Инсан; Казан:Фикер,1998.

## БАТЫРЛЫКНЫҢ ЮЛ БАШЫ

Басырова Д.В.
Иске Юраш урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Юнусова Л. М

Тарих... Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш – меңнәрчә елларның нәтиҗәсе. Тарих – ул еллар шаһиты, халык хәтере. Ул элек булган ялгышларны кабатламаска, азатлык өчен көрәштә башларын куйган җаннарны онытмаска, бердәм булырга өйрәтә. Тарихыбызга күз салсак, әле кайчан гына коточкыч канлы сугыш – Бөек Ватан сугышы булып узган, илебез күгендә дүрт ел буе үлем шәүләсе эленеп торган. Сугыш бер генә кешене дә читләтеп узмаган, һәр кешенең йөрәгендә төзәлмәслек яра, ачы күз яшьләре калдырган. Инде Бөек Җиңүгә дә 78 ел тулды, әмма хатирәләр онытылмый. Аны кеше хәтере мәңгеләштерә [https://kpfu.ru/portal/docs].

Бөек Ватан сугышына безнең Юраш-Илмәт авылларыннан гына да 700 гә якын кеше киткән, 500 гә якыны кире әйләнеп кайта алмаган. Алар каты яраланганнар: кулсыз, аяксыз калганнар, әмма дошман каршында тезләнмәгәннәр. Ил өчен гомерләрен дә кызганмаганнар. Бу батырларның

исемнәре мәрмәр ташларга уелып язылган. Тыл тормышындагы авылдашларыбыз да барлык ил халкы белән бергә көрәшкә күтәрелгән. Алар чын мәгънәсендә фашизмга каршы сугыш алып барганнар. Аларны да үлем куркытмаган. Бар көчләрен Җиңү өчен кулланганнар. Шуның бәрабәренә Бөек Җиңүгә ирешкәннәр дә.

Ветераннарыбызның саны көннән-көн кими бара. Бүгенге көндә Иске Юраш үзидарәсе җирлегендә - 2, Илмәт үзидарәсе җирлегендә 3 тыл ветераны исәпләнә. Җиңүнең 75 еллыгын каршылаганда алар 28 булган. Өлкән яшьтәге авылдашларыбызның саны көннән-көн кими бара. Димәк, берничә елдан аларның эше теркәлмичә калырга мөмкин. Шуңа күрә безгә, сугыш каһарманнары исән чакта, аларның үткән юлын, тормыш тәҗрибәсен өйрәнеп, туплап калырга кирәк. Ә аларда күпме тормыш тәҗрибәсе, күпме асыл әхлак сыйфатлары...

Бүгенге көндә илебездә махсус хәрби операция эшләре алып барыла. Без анда катнашучы геройларыбызның исемнәрен, башкарган эшләрен, батырлыкларын яхшы белергә, аңларга, аларга һәм гаиләләренә тиешенчә ярдәм күрсәтергә тиеш.

Еллар үтә, буыннар алмашына. Белем алып, киләчәк тормышта хыялларыбызны тормышка ашыру өчен дә безгә дәүләт тарафыннан бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Без боларны “шулай тиеш” дип кабул итәргә күнеккән. Ә шушы матур тормышны безгә бүләк итүче халкымның сугыш чорындагы батырлыгын, алар үткән авырлыкларны бөтен ваклыклары белән beләбезме соң без?

Әйе, без бу турыда беләбез: сугыш турында кинолар да карыйбыз, китаплар да укыйбыз. Аңлыйбыз да: сугыш коточкыч нәрсә, безгә мондый хәлләрне күрергә язмасын. Әмма сугыш китергән михнәтне бөтен ваклыклары белән күз алдына китереп бетерә алмыйбыз икән.

Күптән түгел без тыл каһарманнары белән очрашу үткәрдек, аларның хатирәләрен тыңладык. Менә монысы бөтенләй башка нәрсә... Алар сугыш чорында күргәннәрен бүген күргәндәй сөйләделәр, гүя бу 78 ел аралык бөтенләй булмаган. Бу хәлләр аларның йөрәкләренә еллар үтеп тә җуелмаслык булып кереп калган. Каршыбызда утырган, без күреп белгән бу - чәчләренә ак бәс сарган әби-бабайларыбыз - безгә “зур батырлыкияләре” булып күренделәр. Чыннан да, бу шулай. Аларның һәркайсы, Җиңүне якынайтам дип, нинди генә зур батырлыкларга тиң эшләр эшләмәгәннәр! Ә үзләре нинди тыйнаклар. Без “менә шулай эшләдек” дип күкрәк кагып та йөрмиләр. Булган хәлләрне сөйләгәндә дә, “Җиңүдә безнең дә өлешебез зур” дип тә мактанмыйлар. Аларның исемнәре батырлар исемлегендә дә юк. Ә үзләре Бөек Җиңүгә үзләреннән нинди зур өлеш керткәннәр!

Чарага махсус хәрби операциядән ялга кайткан авылдашыбыз Рамиль абый да килгән иде. Ул да сугышның вәхшилеге, сугышчыларның батырлыгы турында сөйләде, без биргән сорауларга тыйнак кына итеп җавап бирде.

Әңгәмәдән сугышның коточкыч мәрхәмәтсезлеген һәм туган илне саклау хакына гомереңне дә кызганмаска кирәклеген аңладык. Батыр сугышчыларыбыз белән горурландык.

Боларны тыңлау күңелдә тыеп булмаслык хисләр өермәсе куптарды. Әсәр һәм кино геройлары безнең арадабызда икән бит! Аларның барысының да: өлкәненең дә, яшенең дә бер максат – туган илне үз-үзеңне аямыйча яклау һәм саклау. Минем кызыксынуым чиксез нык артты. Башлангыч итеп, мин өлкәннәр белән әңгәмә үткәрергә булдым.

Сугыш чоры турында 5 тыл ветеранынннан, 2 сугыш чоры баласыннан мәгълүматлар тупладым. Аларның һәрберсе үзенчәлекле, берсе дә кабатланмый. Әмма нинди генә авыр шартларда калсалар да, кешелекнең күркәм сыйфатларын: туган илеңне, торган җиреңне өзелеп ярату, батырлык, тырышлык, уңганлык, уен-көлке белән яшәү, авырлыклар алдында каушап калмау, аларны җиңә белү, ярдәмләшеп яшәү кебек сыйфатларны югалтмаганнар алар.

Миңа авылдашларым белән очрашу, аларның сугыш чорында кылган эш-гамәлләрен белү тарихны, сугыш вәхшәтен яхшырак күз алдына китерергә булышты. Тыныч тормышның, өлкәннәрнең кадерен белергә ярдәм итте. Һәм мин тагын бер мөһим нәрсәне аңладым: батырлыкның юл башы ечкенә чактан башлана, әби-бабайлардан буыннан- буынга тапшырылып дәвам итә икән.

Бүгенге көндә дә илебез нәкъ менә шундый бай рухлы, иле һәм халкының бәхетле тормышы өчен җанын корбан итәргә әзер торучыларга мохтаҗ. Туган илем батырларының барысына һәйкәл куярлык!

## ДИМИ-ТАРЛАУ ГӨРЛӘП ЯШИ ИКӘН ЙОЛКЫНМАГАН, ДИМӘК, ТАМЫРЫ...

Бәдертдинова А.Р.
Сарман гимназиясе укучысы.
Фәнни җитәкчеләр: Мәтҗанова Р.Г., Нәҗметдинова Ч.М.

Сарман районының Дими-тарлау авылында минем апам яши. Мин каникул саен шушы авылга кайтам. Авылның кызыклы үзенең бай тарихы бар икән. Укытучым белән авыл тарихы буенча бик күп материаллар карадык, авыл аксакаллары белән очрашып, аларның истәлекләре белән таныштык.

1996 нчы елда Дими-Тарлау авылына татарлар килеп урнаша башлауга 250 ел тулган. Авылдашыбыз Ногман ага Яһудин язмаларына караганда, 1746 нчы елда хәзерге Әгерҗе районы Салагыш авылыннан бирегә 7 гаилә килеп урнаша. Беренче килгән кеше Мөхәммәтрәхим Туктамышев (Яһудиннәр бабасы) була. Соңыннан инде ул үзенең таныш-белешләрен, туган-тумачаларын да үз янына чакыра, күрәсең. Бүген дә авылыбызда яшәүче Яһудин, Мофаздалов, Галиевлар үзләрен Салагыштан килүчеләр нәселеннән дип саныйлар.

Аңа кадәр бу кешеләргә җир Мортыштамагыннан бирелсә дә, алар анда калмыйлар, монда киләләр дигән риваять тә бар. Әле тагын Каташ-Каран һәм Азалак авылына да Салагыштан килүчеләр булган. Болары бу авыл тарихында язылган.

Еш кына "Нәрсә соң ул Дими-Тарлау?" – дип сорыйлар. Әле 1973 нче елда профессор Гомәр Саттаров бу авыл тарлавыкка урнашкан һәм аңа Тарлау

дигән исем бирелгән дигән фикер язган иде. Чынбарлыкта исә безнең авылда бернинди тарлавык юк. Дамир Гарифуллин язганча, ул имеш Дөмәй Тарлавы, ягъни Дөмәй исемле старшинаның ат асрау урыны булган. Авылдашыбыз Нәкыйп абый Борһановның мәтбугатта чыккан язмасына күз салсак, бу авылга Демид Орлов нигез салган булып чыга. Ә Әнәс Миннегалиев фикеренчә, бу авылга нигез салучылар чирмешләр (хәзерге марилар) булган һәм аларның өлкәнрәгеме, баемы Димитрий булып, тора-бара Димит-Дими формасында кыскартылган.

Инде дә Димиткә килсәк, Ногъман Яһудин язганча, әле 1746 нчы елда Димит исән була, соңыннан: “Мөселманнар күбәйде”,- дип авылдан киткән имеш. Йомгак ясап, “Дими-Тарлау-Димитнең мал (туары) утары көтүлеге булгандыр диясе килә. Бу утар (тарлау) авылыбызның Сарман ягында, Сәйфетдинов, Фазуллин, Шәфигуллиннар бакчасы урынында булган, диләр. Әле дә аларның бакчасын тирәнрәк сөрсәң, калын тирес катламы чыга, ди тракторист  Рәмзи абый Корбанов. Әлеге авыл исемен 1773 нче елгы тарихи документта очратырга мөмкин.

1889 нчы елларда безнең авылга Иске Әхмәт типтәрләренең күпләп килүе билгеле. Әле дә Җамалетдинов, Нәбиуллин, Зиннәтуллин, Харисов, Хөснимәрдәнов, Нуртдиновлар үзләрен әхмәтлеләр дип саныйлар.

1893 нче елда исә Башкортстанның Бишкурай авылыннан байтак кына башкортлар килә. Алар башлап нигез коручыларны да, соңыннан килүче типтәрләрне дә инешнең Петровка ягына куып чыгаралар. Шулай итеп, авылда ике төрле халык: башкортлар һәм типтәрләр яши башлый һәм ыгы-зыгыга, чуалышларга юл ачыла. Әле 1940 нчы елга кадәр дә бер як халкы белән икенче яклар берсен-берсен үртәшү кебек гадәт сакланган.

Авылыбызда колхоз 1930 нчы елда оеша. Аның беренче рәисе Маликов Сабур була. Аннан соң күп-күп алышынулар булып, 1941-1945 нче елгы сугыш азагына 21 яшьлек Хафаза Гәрәева эшли. Ул бу вазифаны 1946 нчы елда фронтовик Нурулла Төхвәтуллинга тапшыра.

Авыл аерым колхоз булып (“Хезмәт” колхозы) 1958 нче елга кадәр яши. Аннан соң ул Сарман, Яңа Әхмәт, Иске Әлмәт авыллары белән кушыла. Инде 1966 нчы елда авылыбыз Петровка совхозының бер бүлекчәсе итеп калдырылды һәм хәзер дә шул рәвештә көн күрә.

Авыл бик зур булган. 3 мәхәллә, 3 мәчет эшләп торган. Бу мәчетләр каршында мәдрәсәләр дә булган. Мулла булып үзебезнең авылныкылар да, читтән килгәннәр дә эшләве билгеле. Ә бу муллаларның берсе Сәгыйдь бине Габделҗәлил бине Заһит Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләренә дә кереп калган.

Мәчет манаралары 1939 нчы елда киселгән. III мәхәллә мәчетен сүтәләр. Аның урынына яңа мәчет салдылар. Элек ул мәктәп, балалар бакчасы булып торды. Бу мәктәптә Нурмый апа, Маликова Сәлимә апа, Сахапов Мирсәет абый, Фәйзелхак Искәндәровлар эшләде. Иң озак эшләгәне Мирсәет абый булды. 25 елдан артык белем бирде.

Авылыбызның өлкән кешеләре, бигрәк тә Әнәс абый Миннегалиев авыл тарихын өйрәнүгә зур өлеш керттеләр. Авылыбызның тарихи истәлекле урыннары күп. Шулар турында язып китәсем килә.

**Айтуган сызасы.** Айтуган – бу урын үзенә күрә риваятьләр белән бәйләнгән

1. Имеш, ике туган печәнгә баралар. Печән төягәннән соң берсе югарыга бастырык эләктерергә менә. Бастырыкны бастырган вакытта бау өзелеп китә, бастырык бер туганны бәреп төшерә, җан тәслим кыла. Үләр алдыннан “Ай, туган”, - дип кенә әйтә алган.

2. Имеш, ике туган сыер сатканнар. Базардан кайтканда туганнар акча бүлешә алмыйча, берсен-берсе үтерә. Үләр чиктә: ”Әй, туган!”- диеп кенә әйтеп өлгерә, үлә.

3.Бу тирәләрдә элек тә сазлык була, хәзер дә сазламык. Берәү баткан һәм кычкыра икән: ”Әй, туган,коткар!”-дип.

4. Сазлык суында яңа ай ялтырап күренгән. Берәү гаҗәпләнеп:”Ай туган, ай туган!”- дигән имеш.

**Әхмәтҗан күле.** Ишем тавы белән Дими Тарлау җирендә күл. Имеш бу күлдә Дими Тарлау кешесе Әхмәтҗан үрдәк ата торган булган.

**Олы әрәмә.** Илексаз белән Дими Тарлау арасындагы әрәмә-таллык. Кешеләре каен себеркесен дә шуннан җыялар. Балан да, шомырт та, кызыл карлыган да, бөрлегән һәм балтырган һ.б. ашый торган бик күп үсемлек үсә анда. Төрле колхозлар һәм районның бик күп оешмалары җәй көне аннан терлек азыгы хәзерлиләр: себерке бәйлиләр, кычыткан уралар.

**Карлыганлы куак.** Олы әрәмә тирәләрендә булган урыннар. Бүгенге көндә бу исемнәр кулланылмый, картлар телендә генә калган.

**Җиләкле күл** булган. Ул “Бүләк” басуы уртасында булган булса кирәк. Урман киселгәч, бу күл дә кипкән. Бүгенге көндә бу басуда шактый зур үзәнлек бар. Байтак вакыт тора.Чәчүне дә бу үзәнлектә соң гына чәчәләр.

**Илҗә урманы – Француз урманы** дип тә йөртәләр. Стахеев дигән алпавытның леснигын Илья исеме белән йөрткән булсалар кирәк. Авылдан көнбатышка, Күктау белән Дими Тарлау арасында урнашкан урман. Борынгы урманнарның дәвамы. Нарат Астына кадәр сузыла. Илҗә - Илья француз булган диләр. 1812 елгы сугышта пленга эләккән французлар нәселеннән булгандыр күрәсең. Минем уйлавымча, туган нигезгә, төбәккә, ата-аналарга, халыкка, аның гореф-гадәтләренә ихтирам – тарихны өйрәнүгә омтылыш.

Кеп-кечкенә туган авылым Елларда да нигезең сакланды.
Сине күреп күңелем шатланды, Дими-Тарлау гөрләп яши икән
Халкың әйбәт синең, шуңа авыр Йолкынмаган, димәк, тамыры...

Эшемдә Сарман төбәгенә, Дими – Тарлау авылына багышланган төрле мәгълүматларны кулландым. Алар белән танышу төбәк халкына гына түгел, ә бәлки милләтебезгә булган хөрмәтне арттырды. Тарихи хәбәрләрнең әһәмияте авыл тарихы белән генә чикләнмичә, бөтен бер милләт тарихына караган чыганакка әйләнде. Үз халкың, туган илең белән горурлану хисе дә әнә шулай чал тарихны белүдән туадыр, минемчә. Эшемдә максатыма ирештем, дип уйлыйм. Алга таба да бу турыда материаллар җыярга исәплим. Шуның аркылы үземнең дә зыялы, игелекле, зәвыклы буласым килә.

Әдәбият

1. Гарифуллин Д. Сарман районы энциклопедиясе. – 2 нче китап.– Чаллы, 2006.
2. Архив материаллары: Миннегалиев Ә. архивыннан; Петровка авыл советы архивы материаллары; Искәндәров язмалары; Яһүдин Н. язмаларыннан.

## ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Борһанова Л.И.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

«Халыкның телдән сөйләнә торган поэтик әсәрләре халык авыз иҗаты яки фольклор дип атала. Фольклор – инглиз теленнән кергән сүз, “халык акылы” дигәнне аңлата” [Хәсәнова, 2017: 12]. Халык авыз иҗаты текстларындагы тел мәгълүматлары халыкларның рухи мәдәнияте тарихын өйрәнү һәм торгызу өчен киң кулланыла. Халык авыз иҗаты әсәрләре халыкның тормыш-көнкүреше, тарихы, шул исәптән, тел-сөйләм үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә тора. Фольклор теле мәдәниятнең мөһим элементларын яңадан торгызырга, халыкларның беренчел яшәү урыннарын һәм мохитләрен, тарихның төрле этапларында үзара мөнәсәбәтләрен анықларга мөмкинлек бирә.

Халык авыз иҗатының башка жанрлары белән чагыштырганда мәкальләрнең төзелеше үзенчәлекле. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә мәкальгә түбәндәгечә билгеләмә бирелә: “Мәкаль *и. гар*. Җәмгыятъ тарафыннан үз ителеп уртак кулланылышта йөргән кыска һәм тирән мәгънәле, гадәттә, нәсихәт бирә торган калыплашкан тәгъбир, тапкыр сүз” [ТТАС 2005]. Мәкальләрнең күбесе ике бүлектән тора. Беренче өлеше шарт яки хәбәр төсендә килсә, икенче бүлектә нәтиҗә, йомгак ясала, төп фикер әйтелә. Мәкальләрнең кайберләре гади җөмләләрдән, ә кайберләре кушма җөмләләрдән гыйбарәт. Мәкальләрнең күпчелеге кушма җөмләләрдән тора. Алар арасында тезмә кушма җөмләләр дә, иярченле кушма җөмләләр дә бар.

Тезмә кушма җөмләләрдән теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр өстенлек итә:

Алып анадан туар, аргамак биядән туар. Ана күңеле балада, бала күңеле далада. Аш ташны эретә, Ялган башны черетә.

Тауга кычкыр, ул да сиңа кычкырыр.

Белгән уңар – белмәгән туңар.

Ач күп ашар, ачулы күп сөйләр.

Ачма серең дустыңа,
Дустыңның да дусты бар,
Ул да сөйләр дустына.

Тикшерелгән мәкальләрдә иярченле кушма җөмләләрнең берничә төре очрады:

1) иярчен ия җөмлә:

Кем сабыр, шул эшнең җаен табар.

Кем эшләми, шул ашамый.

Беләге юан берне егар, белеме күп меңне егар.

2)  иярчен хәбәр җөмлә:

Түләве нинди, эше шундый.

3) иярчен аергыч җөмлә:

Күз җитмәгән җиргә сүз җитәр.

Эше барның ашы бар.

Иле барның теле бар.

4) иярчен тәмамлык җөмлә:

Кемнең белеме бар, шуның кадере бар.

5) иярчен вакыт җөмлә:

Эш беткәч,  уйнарга ярый.

Сугыш беткәч, батыр күбәер.

Балыкчы итәгенә гөмбә төяп кайтканда, “шәп каптымы?” дип сорамыйлар.

Кеше туй сөйләгәндә, ул җеназа сөйләгән.

6)иярчен урын җөмлә:

Ат аунаган җирдә төк кала.

Җил кайдан исә, болыт та шуннан килә.

7) иярчен рәвеш җөмлә:

Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы.

7)иярчен сәбәп җөмлә:

Бал татлы дип, бармакны йотмыйлар.

8) иярчен шарт җөмлә:

Анаң үги булса, атаң үзеңнеке булмас.

Басыйм дисәң, җир күп,

Сөйлим дисәң, сүз күп.

Галим булсаң, Галәм синеке.

Ачулыга дәшмәсәң, ачуы кырын китәр.

Ач эткә аш бирсәң, тук эт шыңшый.

9) иярчен кире җөмлә:

Авызың кыек булса да, сүзең туры булсын.

Авызым иләк булса да,  сүзем сирәк.

Уты сүнсә дә, кисәве кала.

Сыйлар сыебыз булмаса да,

Сыйпамага телебез бар.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, мәкальләрдә төзелешләре ягыннан җөмләләр гади дә, катлаулы да. Гади җөмләләрнең күбесе тиңдәш кисәкләр, аерымланган кисәкләр белән катлауландырылган. Кушма җөмләләрдән бигрәк тә иярченле кушма җөмләләр өстенлек итә.

Әдәбият

1.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2005. – 848 б.

2. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар

өчен).5 нче с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кисәк/ Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева].– Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2017. – 151 б.

## ИСТОРИЯ ГОРОДА КАЗАНИ

Бугрова А.В.
МБОУ «Алексеевская СОШ№2»
Научный руководитель: Васильева А.В.

Где бы я ни был,
Всегда будешь сниться
Ты мне, Казань, дорогая моя,
Город любви, красот столица,
Родина, где был так счастлив я.

Казань – город, расположенный на левом берегу реки Волга, столица Республики Татарстан, важный экономический и культурный центр России. Это не только древний город с многовековой историей, но и место встречи Европы и Азии, православия и ислама.

Существует несколько легенд, связанных с названием города. По самой распространенной из них «Казань» происходит от татарского слова «казан» - котел. Легенда гласит, что город был заложен на том месте, где без огня закипела вода в котле, врытом в землю. Символом города, изображенным на гербе, является мифическое драконоподобное существо Зилант.

«Герб Казани». Татарская легенда гласит, что Казань была построена на месте, обильном всеми благами земными. Одно лишь было препятствие – многочисленные логовища, полные змей. Множество змей заполонило прекрасную землю, а во главе всего гнездился страшный крылатый змей Зилант, пожиравший людей и животных. Все избегали это «змеиное точевище» и обходили его дальней дорогой, чтобы не слышать жуткое, леденящее кровь шипение змеиное.

Жалко стало татарскому хану Саину отказаться от мысли поставить на облюбованном им месте город. Расстроился хан. Но тут явился ему на выручку старый деревенский колдун и поклялся, что очистит эту прекрасную землю от гадов. Силой чар своих собрал он всех змей в одну кучу, обложил со всех сторон сеном и хворостом, полил смолою и серою и поджег! Погибли все змеи в огне, но от костра того пошел такой удушливый смрад, что мертвыми пали находившиеся недалеко от огня люди, кони и верблюды. Погибли змеи, но змеиный царь поднялся на своих огромных крыльях в воздух и улетел на соседнюю гору Джилантау (Змеиная гора).

На очищенном от гадов месте построил хан Саин красивый город и крепко полюбил основанную им Казань – дело рук своих. Но змеиный царь Зилант затаил злобу на прогнавших его людей и решил крепко мстить им. Не давал покоя ни днем, ни ночью, наводил ужас. «Змей летит!» — кричали несчастные люди и спешили спрятаться кто куда. А змей хватал их когтями, уносил на свою гору и пожирал. К счастью, жил в городе могущественный

волшебник Хаким, который сумел тайным хитрым колдовством убить жестокого Зиланта.

В память об этом счастливом событии изображение Зиланта и попало в городскую эмблему.

«Каменная сказка». А вот и холм – древнейшее место в Казани – Казанский Кремль. Белокаменные стены как будто обнимают Кремль и охраняют его от бед и невзгод.

В Кремль мы попадаем через проезд в Спасской башне. Спасская башня – главная башня кремля. Своё название башня получила от Спасской церкви, которая находилась примерно на том же месте. Когда-то эту башню украшали необычные часы, циферблат которых вращался вокруг неподвижной стрелки. Позже на ней были установлены часы, при бое которых башня стала озаряться малиновым светом.

А вот ещё одна знаменитая башня – башня Сюючбике, названная в честь последней казанской царицы – одной из самых прекрасных и просвещённых женщин своего времени.

А это что за башня вдалеке?
Не та ль, которую зовут Сююмбике?
Нас красотой и статью покорила.
А по легенде вот как дело было.
Сююмбике, прекрасная царица,
Красой Ивана Грозного пленила.
Решил царь на красавице жениться
И на Казань пошёл военной силой.
Чтобы войну от града отвести,
Она царю велела башню возвести.
И прыгнула с вершины башни той,
Не став Ивана Грозного женой.

«Улица Баумана». Для многих казанцев и гостей столицы любимым уголком стала улица Баумана, в старину – Большая Проломная. Здесь расположены драматический театр, старейшие кинотеатра города, десятки магазинов, уютные кафе. Улица Баумана – единственная пешеходная улица города. Здесь ты можешь увидеть единственный в мире памятник знаменитому оперному певцу Фёдору Шаляпину, настоящую карету императрицы Екатерины Второй, фонтан «Водяная» и др.

В самом центре города радует своей живительной прохладой и искрящимися фонтанами Булак. В старину эта река была судоходным. Купцы доставляли товары по ней прямо к городским стенам. По берегам Булака шумели ежегодные ярмарки.

Малая родина – это старт к большой жизни. Любить Казань – это значит знать ее.

Литература

1. Стили и формы татарской архитектуры Казани второй половины XVIII-начала XX века // Нияз Халит.–Казань: татар. кн. изд-во, 2014. -391с.

2. Старая Казань и её окрестности // А.И.Дубин.–Казань: Заман– татар. кн. изд-во, 2011. - 208с.
3. http://www.iske-kazan.ru/ Старая Казань.
4. https://vk.com/findkazan FIND Kazan– публичная страница об истории Казани. Автор:Э.И.Шайдуллин.

## ТУГАН АВЫЛЫМ - ГҮЗӘЛ САРМАНЫМ

Вагизова А.И.
Сарман гимназиясе укучысы.
Фәнни җитәкчеләр: Мәтҗанова Р.Г., Нәҗметдинова Ч.М.

Туган җир, туган туфрак, туган нигез... Бу тирән мәгънәле төшенчәләр һәркем өчен изге һәм кадерле сүзләр. Кеше кайда гына булмасын, нинди генә урыннарны күреп сокланмасын, аның күңелен һәрвакыт газиз җире, туган нигезе үзенә тарта. Туган ягымның тарихы белән мин кечкенәдән кызыксынам. Китапханәдән үзебезнең авылыбызның тарихын яктырткан китапларны алып укыйм.

Сарман авылы исеме аны нигезләүче Сарман карт исеменнән килә дип фаразлана. Күрәсең, ул кыю һәм тәвәккәл кеше булгандыр, исеме тирән ихтиримга лаек буларак тарихта калган. Азнакай,Түбән Кама якларында соңрак табылган шәҗәрәләрдә Сарман исеменең очравы шул хакта сөйли.

Сарман исеменең төшенчәсенә күз салыйк. Сарман топонимының асылында Сарман дигән кеше исеме ята. Борынгы болгар-татар һәм чуваш кеше исемнәре арасында Сарман, Сарманай ,Сармандай, Сармандей кебек исемнәр урын ала. Пермь татарларында Сарманай исеменәнигезләнгән Сарманаев фамилиясе бар.

Сарман исеме сары +ман компонентларыннан гыйбарәт. Сары өлеше төсне белдерә, ә ман өлеше "кеше"(мин) яки "елга"(гомумән предмет) төшенчәсен белдерсә кирәк. Сары сыйфаты борынгы төрки кеше исемнәре составында шактый еш кулланыла: Сарыбуга, Сарыбай, Сарыкай, Сарыбулат , Сарытай, Аксары һ.б. ”Ман” сузе дә борынгы төрки антропонимнар составында байтак очрый: Сарман, Сарманай, Акман, Сайман, Шайман, Тайман, Айман, Атаман, Карман һ.б. Кургәнебезчә,Сарман бу исемнәр белән бер система тәшкил итә.

Казакъ теле белгече Т.Жанузаков Сарман исемен монгол теле белән бәйли, беренче компоненты монголча сар - "ай" (луна) дигән мәгънәсен белдерә, дип карый. В.Н.Попова Сарман атамасы, Иран телләре белән мөнәсәбәтле булып,"югары елга" мәгънәсен аңлата дип саный.

Галимнәр монгол телендәге Сармандав дигән шәхси исемгә дә бәйләп аңлаталар. "Сар"ның татарчасы -"Ай",ә "мандав"-"Чыкты" дигән сүз була.

Курәсең, ай чыкканда, яки ай туганда дөньяга килгән баланы шулай атаганнар.

Сарман карты Фәйзелхак бабай Һадиуллин түбәндәге кыйммәтле тарихи мәгълүматларны хәбәр итә: "Сарман карт бу урынга килеп утырганчы, әле

безнең якларга Чыңгыз, Батый чирүләре килгәнче, Агыйдел тамагы, Ык буйлары, Мәллә һәм Минзәлә елгалары тирәләре куе урманнар белән капланган, елгалары тирән сулы, күп балыклы, табигый аланнарга, болыннарга бай булган. Ул кош-корт, җәнлекләрнең исәбе-чуты юк. Менә шушы урыннарда байлар, буләр дигән башкорт ыруглары күченеп йөргәннәр. Алар иркен яшәгәннәр. Тапкан азык, мал-мөлкәт уртак булган. Менә шулай әйбәт кенә яшәгәндә Болгар илен басып алырга баручы Батый хан чирүе бу якларга килеп чыга һәм халыкны аса-кисә ,мал-мөлкәтен талый башлый.Узенең елкы көтүләре белән Минзәлә һәм Ык елгалары арасында күчеп Карагай-Атай ыруы аеруча зур кайгыга дучар була. Чирү башлыгы алдында бил бөкмәгән көмеш сакаллы Карагай-Атайны бөтен нәсел-нәсәбе алдында суктыралар. Арба көпчәге биеклегеннән зур булган барлык ир затның башын өзәләр. Алма кебек пешеп килүче кызларны әсир итәләр. Барлык мал-мөлкәт, елкы көтүләрен тартып алалар.

Шул вакыт сунардан Карагай-Атаның олы улы-Бикчура кайта. Ул башта аландагы гаҗәеп хәлләрне күреп тораташ булып катып кала.Карт әнисенең бертуктаусыз елап сөйләвеннән ул вакыйгаларны күзаллый һәм барлык нәселе алдында, туганнары, карт әтисе каны аккан җирне үбеп, биләүдәге Габдерәшит исемле малаен кочып, Батый хан чирүеннән үч алырга ант итә. Ул аргамакка менеп, байлар, лачын, бүре ыругларына чаба, үз тирәсенә батыр, ут-су кичәргә әзер торучы егетләрне туплый һәм алар белән Болгар шәһәренә һөҗүмгә баручы Батый хан чирүе отрядларын, засада корып, бер-бер артлы кыра. Батый ханның Болгарга беренче һөжүме барып чыкмавына бигрәк тә әнә шул Бикчура егетләре сәбәпче була да инде.

Ике-өч елдан соң, Батый хан Болгар иленә гаять зур гаскәр ташлый. Бикчура узенең егетләре белән бу якларда аларга бик нык каршылык курсәтә. Бер бәрелештә ул каты яралана һәм Әхмәт исемле җан дусты белән, Текәй дип йөртелә торган таулар аша дошман әзәрлекләвеннән качып китә. Бераз баргач, Бикчураның хәле авырая һәм ул хәзерге Яңа Әхмәт авылы зираты урынында үлә. Җан дусты Әхмәт аны шунда җирли һәм шул урында утрак тормышка күчә.Дошман чирүе ераклашкач, ул Карагай-Атайның хатын-кызлар һәм нәни балалар гына калган ыругын да үз канат астына ала һәм Бикчура малае Габдерәшитне үз улыдай күреп тәрбияләп устерә.

Хан сүзе безгә шул Чыңгыз, Батыйлар чирүеннән соң килеп кергән. Ул нигездә ил башлыгын ,гаскәр башлыгын ,командирны аңлаткан. Бикчурага хан сүзен иң әүвәл Батый хан чирүе башлыклары үзләре, аның батырлыгына, осталыгына һәм хәйләкәрлегенә таң калып кушканнар. Аннары бу исем әкренләп Бикчура кул астындагы төрле ыруг егетләре авызыннан "ил батыры Бикчурахан"дип аталган һәм аның даны бөтен тирә-якка таралган.

Сарман картның нәсел җебе менә болай: Карагай-Атайнньң каһарман улы Бикчурадан калган Габдерәшитне Әхмәт карап үстерә, дидек. Габдерәшитнең Дулабуга, Чучил һәм Мрка дигән өч улы була. Сарман авылыньң төп кешеләре Чучил белән Мркадан киләләр. Җиденче буында Дулабуганың нәселе туктый: Кайбулла, Боерган, Кукбүре, Күзкәй, Әхмәт, Хафиз, Кунакмай, Кунакмайдан ир балалар булмый. Чучил Сарман картның иң карт бабасы

санала. Чучилдән соң ыруг башында аның улы Никаз була,Никаздан соң Булатхужа, аннан Хужагол, Тулбай, Бәк Текәй. Бәк Текәй-безнең Сарман картның әтисе. Сарман картның Калмак һәм Сөләйман исемле ике малае булган. Сөләйман нәселе 6 нчы буында туктый. Ә Сарманның Калмак исемле малаеның нәсел җебе хәзер дә дәвам итә.

Сөйләүләргә караганда, 1774 нче елларда Пугачёв восстаниясе вакытында Сарман карт әле исән булган. Патша солдатлары-драгуннар эзәрлекләвеннән качып килүчеләрне ул үз ишек алдына яшергән һәм драгуннарны мылтыктан атып каршылаган. Драгуннар Текәй тау итәгендәге урманга чигенгәннәр. Ләкин аларга анда Сарман картның Сөләйман һәм Калмак исемле уллары тынычлык бирмәгәннәр, еш-еш һөҗүм ясап торганнар. Драгуннар таралганнар.Аларның берничәсе хәзерге Бикмәт авылына килеп урнашкан. Шуннан Драгун-Бикмәт авылы барлыкка килгән. Хәзер алар татарлашып беткәннәр. Аңарчы монда япа-ялгыз Бикмәт карт ихатасы гына утырган.

Кайбер белешмәләр буенча, Сарман бабайның якынча туган елы 1675-1680 нче елларга туры килә. Әйтеп киткәнчә, ул Пугачёв явы вакытында да исән була. Сарман бабай яңа җиргә килеп утыргач, аның янына беренчеләрдән булып шул ук Бикчура хан нәселеннән булган Ишмәт карт, тора торган җирендә чишмәсе кипкәч, килеп утырган диләр. Әле хәзер дә Мортыштамак белән Сарман арсында Ишмәт сызасы дип аталган урын бар. Ишмәт картның улы Әҗмәкәй, оныгы Ишкуәт исемле була. Ишкуәттән ишле нәсел тарала. Язучы Аяз Гыйләҗевның дә ерак бабасы әнә шул Ишкуәт була. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Фәридә Сафина, Җәлилдә яшәүче куренекле табиб Әдип Ибраһимов менә шул нәсел кешеләре.

Тарихи хәбәрләрнең әһәмияте авылым тарихы белән генә чикләнмичә, бөтен бер милләт тарихына караган чыганакка әйләнде. Үз халкың, туган илең белән горурлану хисе дә әнә шулай чал тарихны белүдән туадыр.

### Әдәбият

1. Гарифуллин Д. Сарман районы энциклопедиясе. 2 нче китап.– Чаллы, 2006.

2.Гарифуллин Д. ”Шәҗәрәләр”, 2002.

3. Саттаров Г. Авыллар тарихы” – Казан.

4. Сафин М. “На берегах Древней Мензели” – 2000.

5. Хайруллин Х.“Бакыр базы серләре”, 1973.

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ХИКӘЯСЕ: ТЕМА ТӨРЛЕЛЕГЕ һӘМ ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Вәлиева В.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Әдәбият галимнәре, мәсәлән, Г.Р. Гайфиева, XX гасыр ахырыннан башлап татар әдәбиятында хикәя жанры яңадан чәчәк ату чорын кичерә башлый дигән фикерне белдерәләр һәм әдипләрнең "кечкенә аша зурны күрсәтү үзенчәлеген үстерүләре"н махсус ассызыклыйлар [Гайфиева 2010: 227 – 228].

Чынлап та, хәзерге татар әдәбияты тематик яктан гаять төрлелеккә ия булган хикәяләрне күпләп тәкъдим итә. Язучыларның игътибар үзәгенә алынган темалардан әхлакый-этик нормаларны саклау (Фәрит Яхин, "Ялгышасыз, җәмәгать!"; Айгөл Әхмәтгалиева, "Баланнарда бал тәме"), туган тел, ил һәм милли мәдәният (Галимҗан Гыйльманов, "Бүреләр һәм Иоһан Себастьян Бах"), милли фаҗига (Айдар Хәлим, "Эңгер"), дин һәм иманга кайту темасы (Айгөл Әхмәтгалиева, "Яулык") кебекләрне атап үтәргә мөмкин.

Хәзерге татар әдәбиятында юмористик һәм сатирик хикәяләр дә үсеш ала. Әмма алар көлкеле ситуацияне бәян итеп, укучыда көлү, елмаю уятуны гына максат итеп куймыйлар, әхлакый-фәлсәфи төшенчәләр турында уйланырга чакырылар. Мәсәлән, Фәрит Яхинның "Ялгышмагыз, җәмәгать!" әсәрендә үзәккә Гатаулла дигән кеше куела. Тексттан аңлашылганча, ул кечкенәдән тырыш, хезмәткә омтылучан, ягъни татар кешесенә хас уңай сыйфатларны үзләштергән була. Әмма җәмәгать аннан канәгать булмый, һәр эшеннән гаеп таба. Ахыр чиктә, үзенең "сөйкемле сөяге" булган бу ягын Гатаулла яшерергә тырыша башлый. Әмма хәзер, башта үз эшен караган, аннары, вакыт калган очракта гына башкаларга ярдәм итә торган кешегә әверелгәч, аны инде "ялкау" дип яманатын тарата башлыйлар, гәрчә эшнең иң авыр өлешен һаман да ул башкарса да. Сатирик яңгыраш шунда чагылыш таба: Гатаулланы яклап сүз алган хикәя герое – шушы кешенең абыйсы булып чыга. "Сез көне буе чокчынып ятканны Гатаулла бармак уйнатып кына башкарып ташлый! Ә-ә, беләсезмени? Әле сезне дә онытмасын, ярдәм дә итсенмени? Алай икән!.. Юк инде, анысын ук өмет итмәгез! Әнә, әүвәле миңа кушылган эшне бетерсен, аннары күз күрер! Ярар-ярар, әйтермен! Тыңлар-тыңлар! Тыңламаса – тыңлатырбыз! Кая барсын, ул бит минем энекәш! Хәзер колагын борам мин аның! Кырыкны узып бара дип тормам!", – [Яхин 2004: 99]. Бер яктан, хикәяләүченең сөйләме укучыда елмаю уята, икенчедән, йомшак, тырыш, кистереп сүзне әйтә белмәүчеләргә карата заманның кырыс булуын да искәртә.

Күп кенә хикәяләрне психологик әсәр дип атарга була, аларда геройларның кичерешләре, тегe яки бу гамәлне башкарырга этәрүче сәбәп һәм гамәлләрнең нәтиҗәләре детальләп тасвирлана. Бу яктан Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты ("Яулык", "Өч тиен", "Баланнарда бал тәме", "Капка", "Таң чыкларын җил үбә" һ.б.) игътибарга лаек. Яшәешне тасвирлауда Айгөл Әхмәтгалиева үзеннән элгәреге әдипләр Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Фатих Хөсни традицияләрен дәвам итеп, эчке монолог, аң агышы кебек психологизм алымнарына мөрәҗәгать итә. Эчке монологлар, укучыга мөрәҗәгатьләр, "автоматик язу" алымы әсәрләргә лиризм алып килә һәм вакыйгаларны гомумкешелек трагедиясе яссылыгына күчерә. Мисал буларак, әдибәнең "Таң чыкларын җил үбә" хикәясенә мөрәҗәгать итеп үтик. Биредә психологик чара – эчке монолог геройларның тарихы трагиклыгын көчәйтүгә хезмәт итә. Ярты гасыр үткәч үзләре өчен кадерле булган кешенең елында

очрашып, бер-берсен көчкә таныган элеккеге гашыйклар, бер сүз дә эндәшмичә, мәхәббәт трагедиясен эчтән генә кичерәләр. Гөлчирә колхоздан ашлык “урлаган” әнисе “гаебен” үз өстенә алганы өчен урман кисәргә җибәрүләрен сөйләмәсә, Әнвәр Гөлчирәнең шушы ук “гаеп” тагылган энесе гаебен үз өстенә алганы өчен утыруын сөйләми. Гөлчирә авылга кайтып, сөйгәнен күрергә дип Әнвәр йортына баруы, бусагада аны Әнвәрнең әнисе каршы алуы, “тиң түгел” дип куып җибәрүе турында эчтән генә уйлана. Гомер үткән, бу авыр хатирәләрдән дә бигрәк, аларның исән килеш очрашуы, бер-берсе белән янәшәдә булуы мөһим.

Аерым хикәяләрдә публицистик аһәң дә үтемле яңгырый. Р. Фәтхрахманов публицистик хикәяләрдән Айдар Хәлимнең “Эңгер” әсәрен атый [Хәлим 2005: 6]. Бер яктан, ул хикәяләргә хас сурәт тудыруның бар үзенчәлекләрен саклый: биредә гыйбрәтле вакыйгалар (журналист Җәүдәтнең авылга Сабан туена кайту вакыйгасы һәм аның истәлекләре белән бәйлелектә бирелә) тасвирлана, әсәрдә сурәтләү чаралары үтемле, сәнгатьчә югарылыкта кулланыла, символ буларак күз, сукыраю, эңгер образлары, күренешләре файдаланыла. Икенче яктан, публицистик рух совет чоры яңа кешесе үзләштергән шаблон сыйфатлар, башка милләтләргә кимсетеп карау, иманга каршы чыгу кебек күренешләр тасвирында урын ала.

Җыеп кына әйткәндә, хәзерге татар хикәяләре кызыклы вакыйга, укучының күңелен күтәрү максаты белән язылмый, алар укучыны вакыйгаларда хикмәт эзләргә этәрәләр, җәмгыять өчен актуаль тема һәм проблемалар күтәрәләр.

Әдәбият


1. Гайфиева Г.Р. Основные этапы становления жанра рассказа в татарской литературе // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. – 2010. – № 4. – С. 223 – 229.
2. Фәтхрахманов Р. Күңелне кузгаткан моң // А. Хәлим. Кыйбла: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 5 – 19.
3. Хәлим А. Кыйбла: хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 382 б.
4. Яхин Ф. Сөйкемле сөяк: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 191 б.


## ТРАДИЦИОН БУЛМАГАН ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ


Вәлиева В.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Традицион булмаган дәресләрнең күп төрләре укыту процессында уңышлы кулланыла. Педагогика теориясе һәм тарихы буенча галимИ.П. Подласый традицион булмаган дәресләрнең берничә төрен аерып күрсәтә. Аларның исемнәре мондый дәресләрнең максатлары, бурычлары, методикасы турында берникадәр күзаллау тудыра. Укытуны оештыру формаларының төп

классификациясенә каршы килмәгәннәрне китерәбез: Дәрес-эшлекле уен, дәрес-уен, дәрес-конференция, дәрес-консультация, дәрес-ярыш, дәрес-иҗат, дәрес-аукцион, дәрес-зачет, катнаш дәрес, дәрес-концерт һ.б. [Подласый 2015:531].

Галим-педагог Ф.Ф.Харисов традицион булмаган дәресләрнең дәрес-рольле уен, дәрес-шоу, дәрес-аукцион, дәрес-уен, дәрес-эшлекле уен төрләрен тәкъдим итә [Харисов 2002: 266].

Дәресләрне оештырганда, иң беренче чиратта укытучыга шуны истә тоту мөһим – дәрестә башкарылган һәр эшчәнлек максатчан һәм нәтиҗәле булырга тиеш. Моны аңлап кабул итү өчен безгә көндәлек тормышыбызга игътибар итү сорала. Белем алу ул – бурыч түгел, ә куанычлы, күңелле бер чара булырга тиешлегенискәртә.

Укытучы заманча дәрес төзү өчен түбәндәгеләргә игътибар итәргә тиеш*:* 1.Төп максат: укучының шәхси үсешен тәэмин итү. 2. Укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаштыру. 3.Укучыларның эзләнү эшчәнлеген дөрес итеп оештыру һәмтанып-белүэшчәнлегенүстерү*(*укучыларныңбелемнәре мөстәкыйль эзләнү эшчәнлегенең нәтиҗәсе булсын өчен*)* [Мөхәммәтҗанова 2015: 28].

Традицион булмаган дәресләрне йомгаклау дәресләре буларак үткәрү уңышлы. Дәрес нәтиҗәле үтсен өчен укытучы дәресне әзерләүгә иҗади якын килергә тиеш. Дәресне уңышлы әзерләү өчен укытучы фәнне һәм методиканы яхшы белергә. Уку процессында актив эшчәнлеккә ирешү өчен укытучы дәресне үткәрүнең гадәти булмаган формасы белән эш итә. Дәреснең традицион булмаган формалары – ул иҗади сәләтне һәм шәхси сыйфатларны үстерү, белемнәрнең ролен бәяләү һәм аларны практикада куллануны күрү, төрле фәннәрнең үзара бәйләнешен тою мөмкинлеге булып тора.

Традицион булмаган дәресләрне сайлауда чама да кирәк. Укучылар гадәти булмаган эш ысулларына ияләшәләр, кызыксынуларын югалтырга мөмкин. Гомуми системада традицион булмаган дәресләр урыны укытучының үзе тарафыннан конкрет ситуациягә, материалны карап тоту шартларына һәм укытучының шәхси үзенчәлекләренә карап билгеләнә. Дәрескә әзерләнгәндә, укытучы түбәндәгеләрне истән чыгармаска тиеш: дәреснең максатын дөрес һәм ачык кую, укыту метод һәм алымнарын, укыту формаларын, чараларын дөрес сайлау, төрлеләндерү, аларның үзара чиратлашуын билгеләү; укучыларны белем алу, укый белү (план төзү, конспектлар төзү һ.б.) һәм танып белү (анализ, синтез, чагыштыру, дәлилләү һ.б.) күнекмәләренә өйрәтү, проблемалы ситуацияләр тудыру, укучыларны проблемалы сораулар куярга, үз фикерләрен дәлилли һәм башкаларның ялгыш фикерләрен күрсәтә белү һәм башка күнекмәләргә өйрәтү мөһим. Билгеле, югарыда күрсәтелгән таләпләрне үтәү өчен, укытучы үзе фәнни һәм педагогик-методик яктан әзерлекле булырга тиеш, аннан зур осталык сорала. Аның, укучыларның эчке рухи дөньясын, ихтыяҗын, хәтерен һәм фикерләү дәрәҗәсен даими рәвештә өйрәнеп, аларны үстерү өстендә эшли белүе дә кирәк.

**Әдәбият**

1. Мәхәммәтҗанова А.Х. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар/төз. А.Х.Мөхәммәтҗанова, Р.Б.Камаева. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. – 68б.
2. Подласый И. П. Педагогика: учебник для прикладного бакалавриата. – 3-е изд., перераб. и доп. –М. : Издательство «Юрайт», 2015. – 576 с.
3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367б.

## АВЫЛЫМ БӘЕТЛӘРЕ

Вәлиева Р.Р.
Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкчеләре: Вәлиева Г.М., Набиуллина Л.З.

Бәет-татар халык аваз иҗаты әсәрләрнең үзенчәлекле лиро-эпик жанры. Бәетләрдә гәүдәләнгән образларның күбесе чынбарлыкта булган тарихи шәхесләргә – прототипларга нигезләнәләр. Еш кына бәетләрдә фаҗигале вакыйгалар үзәккә алына.

Бәетләр әдәбиятыбызның үзенчәлекле, серле сәйләннәре. Алар ата-бабаларыбыз мирасын, халык иҗаты традицияләрен саклау һәм үстерүдә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Бәетләр кеше күңеленә нык тәэсир итүе белән әһәмиятле. Кешеләрнең бәгыреннән, күңел түреннән сызылып чыккан, зар-моңны аңларга, күп гасырларның тарихын белергә, тормыш сабаклары алырга, уй-фикерне чистартырга, күңелне сафландырырга бәетләр ярдәмгә килә. Дөресерәге, моң, хәсрәт - халык күленнән үзе шигъри тезмә булып бәреп чыга һәм күпмедер вакытка кадәр кеше кайгы-хәсрәттән арынып тора. Бәет – ул булган бер вакыйга турында сөйли. Ул йә бер кеше, йә бер гаилә, йә авыл язмышы турында.

Тирсә авылында иҗат ителгән “Һәдия бәете”, “Раил бәете”, “Әбүгали бәете”, “Лилия бәете”, “Рәмзия бәете” бәетләренә тукталасым килә. Эчтәлекләренә һәм пафоска мөнәсәбәттә алар фаҗигале, ә тематик яктан көнкүреш төрләренә бүленгән. Бәетләр аерым шәхесләрнең трагик язмышларын сурәтлиләр.Беренчедән, шушы җирлектәге вакыйга бирелә, икенчедән, таныш шәхесләр сурәтләнә.

Тормышта төрле фаҗигале хәлләр һаман булып тора. Еш кына мондый хәлләр китергән авыр югалтуларга карата кеше үзенең мөнәсәбәтен белдереп бәет иҗат итә, дөресрәге, моң, хәсрәт белән сугарылып ул үзе халык күңеленнән бәет булып чыга, яшәешнең, язмышның бер өлешен чагылдыра.
“Әбүгали бәете” авылдашы рухына багышлап, Камилә Афзалетдин кызы иҗат иткән. Бәет фаҗигага дучар булган кеше исеменнән сөйләнелә. Әбүгали, яз көне Вятка елгасын чыкканда, боз ватылып, машинасы белән суга бата. Бәетнең үзәгендә кайгыртучанлык ята. Үзе үлсә дә , лирик герой үзенең ятим калган балалары өчен борчыла. Лирик герой үзенең бозлы суда ун көн ятуын әйтә:

Су эчендә ун көн ятып,
Күзләремне кан алды.

Лирик герой бозлы су астында да башкалар өчен кайгыртучанлык күрсәтүе аның чын кеше булуын дәлилли. Әбүгали туган җанлы кеше, ул туганнарын юата һәм туганнарын яратуын әйтә. Әбүгали үзенең туган ягына кайта алмавына, әнисе белән саубуллашмыйча китүенә үкенә:

Әнкәем сагынган идем,
Күрә алмадым үзеңне

Туган якка, балалары, туганнары янына кайта алмаса да үзендә юаныч сүзләре табарга көч таба һәм болай ди:

Әле сезгә ярты кайгы:
Гәүдәләрем акмады.
Бергә төшкән иптәшемнең
Сөяге дә кайтмады.

Чыннан да, машинада Әбүгали абый Валиев Альберт абый белән булган була. Альберт абыйның гәүдәсен тапмыйлар.

Бу бәет озын, 34 куплеттан тора, 8-7-8-7 үлчәмендә язылып, рифмалашкан дүртюллык.Бәет чыгаручы эпитет, кабатлаулар кулланып, үз хисләренең тирән мәгънәсен белдерә. Үкенечле үлем белән дөньядан киткән кешененең якты истәлегенә багышлана. Бу шәхси фаҗигага багышланган бәет.

“Һәдия бәете”Тухватуллина Һәдия Шәех кызына багышлана. 1973 нче елның җәендә 45 яшьлек Һәдия апаның гомере фаҗигале төстә өзелә.

Төшләремә дә керде бит
Җир астыннан юл салдым.
Төшем киресенчә булды
Поезд астында калдым.

Һадия апа – Татарстанның атказанган зоотехнигы, Почет билгесе, Октябрь орденнары кавлеры, ике бала анасы. Автор түбәндәге юлларда яраткан хезмәте хакына гомере өзелүе, балаларының, әнисенең ятим калулары хакында сөйли. Ана күңеле, җаны балалары өчен борчыла, ул халык арасында таралган “Сак-Сок” бәетендәге ана белән балалар аерылышуын үзләренеке белән чагыштыра. Түбәндәге юллардан без лирик геройның кеше буларак уңай сыйфатларын беләбез:

Кайгылы кешеләргә дус идем,
Аларга моңдаш идем.
Ферма эшчеләре өчен
Ай идем, кояш идем.

Ана җаны тагын балалары өчен өзгәләнә, олы улы Аликка теләк васыятен җиткерә. Төпчеге Хәмитнең язмышы өчен дә җаны сызлана. Лирик герой соңгы юлларда балаларына әбиләрен юатуны васыять итеп калдыра.

Бәетнең төзелеше төзек. Бәет дүрт юллыклардан тора, 8-7-8-7 үлчәмендә язылган, ләкин кайбер строфаларда бу үлчәмгә туры килми. Ул тормышта булган фаҗигале вакыйганы тасвирлый.Бәеттә сүрәтләү чараларыннан чагыштыру, эпитет, эндәш сүз, антонимнар кулланылган. Автор “карт әнкәем”, “матур җәйләрдә”, “караңгы гүр”, “матур агачлар”, “тәмле сүз”, “моңлы күз”

кебек эпитетлар һәм “идек”, “идем”, “корган идем”, “сөйләшер идек”, “гөрләшер идек” шикелле кабатлаулар кулланып хиснең зурлыгын күрсәтә. “Шатланышып” , “моңаеп” кебек капма-каршы мәгънәле сүзләр куллану да балалар өчен әниләрен югалтуның зур фаҗига булуын раслый. Бәетне Һәдия апаның туганы Икълимә апа Гатауллина язган

“Рәмзия бәете”н кызы Рәмзиягә багышлап, әнисе Асия апа Муллахметова чыгарган. Бу бәет фаҗигага очраган бер гаилә кешеләренең хисләре турында. Тирсә авылында 25 яшьлек Рәмзия апа бала тудырганда вафат була:

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Бакчадагы гөлләргә .
Егерме биш яшьләремдә
Барып кердем гүрләргә.

Бәет Рәмзия исеменнән сөйләнә. Аның хисләре, кичерешләре чагыла.Бәеттә төп тема булып, Рәмзия апаның үз туганнарын юату, аларга васыятен җиткерү, үкенү хисләрен белдерүШулай ук ул алардан аны еш искә алуларын, догадан калдырмауларын да үтенә, аларга бәхет, сәламәтлек, тыныч тормышта шатлыкта , муллыкта яшәүләрен тели.Әнисен дә, ирен дә юата, аларга сабырлык тели.Туганнарына улы Русланны тәрбияләүләрен васыять итеп калдыра:

Җизни, апа, сезгә әйтәм
Русланны сез карагыз, -ди ул.

Бәеттә халык җырларыннан өзекләр дә алынган. Бәет чыгаручы кызына булган кайнар мәхәббәтен дә, баласын югалту кайгысын да матур, үзенчәлекле итеп тасвирлый. Бәет 58 куплетлы, дүрт юллы строфадан тора.

“Лилия бәете”1998 нче елда юл һәлакәтендә вафат булган Тирсә авылы кызы рухына багышлап, авылдашыбыз бәетче Кадыйрова Зәнфирә апа чыгарган. Башламда Лилия яшәү мәгънәсе турында сөйли.

Күпме генә яшәсәк тә
Беркем яшәүдән туймас.

Исән вакытында күргән төшен үзенең үлеменә юрап, үзен юата. Лилия яңа өендә чәчәкләр үстерә алмавына, яңа кофтасын кия алмавына да үкенә. Яшәү фәлсәфәсен дәвам итеп, лирик герой үзен борчыган сорауларга җавап эзли. Автор тормышта тырыш, уңган кеше булуы һәм яшь чагында барысына да җитешергә теләве хакында горурлана. Лирик герой үзенең туганнары белән саубуллаша, кечкенә кызы өчен ана җаны сыкрый:

Кызым кала, шунысы үкенечле
Кемнәр аны назлап юатыр.

Бу шәхси фаҗигагә багышланган бәет. Бәетләргә хас традицияләр саклана.

Бәет озын, дүртәр юллы 22 строфадан тора. Төзелеше төзек. Лирик геройның хисләрен күрсәтү өчен эндәш сүзләр, эпитет һәм метафора алымнары кулланылган. Бәеттә төрле чорда иҗат ителгән бәетләргә хас алымнар бар.

Кадыйрова Зәнфирә апаның икенче бәете “Раил бәете”. Бәет Раил исеменнән сөйләнелә. Ул әнисенә, туганнарына мөрәҗәгать итә: аны догадан калдырмауларын, аны искә алуларын тели. Үзенең Афган сугышыннан исән-

имин кайтуын, кар өстендә төнге сәгать унберләрдә җан бирүен берничә кат кабатлый.

Канауларга егылып төштем,
Төшкәч үрмәләп мендем.
Их! Әнкәем кала диеп
Шул кадәр үкендем.

Бәеттә халык арасындагы ышануларга да урын бирелә: “Өйгә күбәләкләр керсә, тимәгез, минем җан булыр, яки җыелган күз яшьләренә мине суга салмагыз”. Бәет 19 куплетлы, дүрт юллы строфадан тора.

Бәет үзәгендә яшәү белән үлем фәлсәфәсе, лирик һәм фаҗигаи фондагы сурәтләр белән “мин” исеменнән кешенең гүзәл сыйфатлары тасвирлана. Бәетләрнең иҗат ителү максаты - иң якын кешеләренең изге рухына дога булып барып ирештерү теләге. Бәет - халык иҗатының бик борынгы жанры. Алар халыкның моң- сагышы, күңел көзгесе. Бәетләр чыгару җиңел эш түгел. Кеше кайгысын үз кайгысы кебек аңлаучы, ярдәмчел, нечкә күңелле шәхесләр генә аларны чыгара аладыр.

**Әдәбият**

1. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйлаҗев, Н.М.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
2. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1990. – 238 б.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1977.
4. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: ТКН, 2001.
5. Җирле фактик чыганаклар.

## УЕН ТЕХНОЛОГИЯСЕ АША БАЛАЛАРНЫ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮ

Вәлиева К.А.,
Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты.
Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.

Уен технологиясе – заманча педагогик технология, бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз бер өлеше. Тәрбия чарасы буларак, ул балаларның камилләшүенә, шәхес буларак формалашуына, үзгәрүенә этәргеч булып тора. Балага белем һәм тәрбия уен аркылы яхшырак бирелә. Ул уйнаган вакытта бик күп нәрсәләрне таный, үзенә күнекмәләр ала. Уен формасында оештырылган дәресләр фән белән кызыксынуны көчәйтә, баланың мөстәкыйльлеген үстерә, аларны белем алуга дәртләндерә.

Беренче чиратта уеннарны эшчәнлек төре буенча берничә зур төркемгә бүлеп карарга кирәк: хәрәкәтле уеннар, интеллектуаль уеннар, психологик уеннар, иҗтимагый уеннар.

**Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә** түбәндәге уен төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин:

- дидактик уеннар (бу төр уеннар укучыларда белем-күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып-белү эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлтелгән);

- тәрбияви уеннар (әхлак тәрбиясе бирү, рухи сыйфатлар, сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү максатыннан үткәрелә);

- иҗади уеннар(укучылар бигрәк тә рольле уеннарны яраталар. Рольле уеннар укучыларның коммуникатив эшчәнлеген активлаштыра, үзара ярдәмләшү теләге тудыра);

- коммуникатив уеннар (укучыларның сөйләм телен үстерүдә, эзлекле фикер йөртү сәләтләрен формалаштыруда ярдәм итә) [Харисов 2002: 35].

**Үткәрү методикасы буенча уеннар** бик күп төрләргә бүленә:предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.

**Төрле фәннәргә бәйле рәвештә уеннар** берничә төргә бүленә:математик уеннар, химик уеннар, физик уеннар, экологик уеннар, музыкаль уеннар, әдәби уеннар, спорт уеннары һәм башкалар.

Уеннар яңа теманы үзләштерү, белемнәрне ныгыту, гомум уку күнекмәләрен формалаштыру, иҗади сәләтләрен үстерүдә куелган бурычларны уңай хәл итүдә зур мөмкинлекләргә ия.

Башлангыч сыйныфларда уен – татар теле дәресләрендә уку эшчәнлеген оештыруның югары нәтиҗәле чарасы. Аны белем бирүнең барлык этапларында да кулланып була. Ул әзерләнгән һәм әзерләнмәгән сөйләмне формалаштыру һәм үстерү өчен уңай шартлар тудыра, кыенлыкларны җиңү шатлыгын тоярга булыша, коллекивизм рухы тәрбияли. Уен балаларның фикерләвен, сөйләмен һәм хәтерен үстерә.

Балаларны кечкенәдән үк үз халкының , үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру, гомум кешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Безнең бурыч – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү, бала тәрбиясенә этнокультур өлеш кертү.

Әлбәттә, шөгыль вакытларында балаларга яшәгән төбәгебездә нинди хайваннар,үсемлекләр, кошлар барын, нинди халыклар яшәвен, аларның нинди телдә аралашулары, гореф гадәтләре, киемнәре, иҗаты, мәдәнияты, күренекле шәхесләре белән таныштырып үтәбез. Бу танышуны әңгәмә белән генә түгел, төрле уен технологияләрен кулланып үткәрәбез. Мондый әңгәмәләрне виртуаль экскурсия вакытларында үткәрсәң бик отышлы килеп чыга. Мәсәлән, поездга утырып, яки автобус белән Казан шәһәренә юл тотабыз. Юлда барганда тәрәзәдән күзәтәбез. Әйләнә тирәбездә үскән агачлар, кошлар турында, елга, шәһәрләр турында сөйли – сөйли барабыз (экранда күрсәтә барабыз). Казанга барып җиткәч, башкалабыздагы борынгы биналарны (Кол Шәриф мәчете, Спасс башнясы, Сөембикә манарасы турында мәгълүмат), андагы бизәкләргә игътибар итеп кызыклы тарихи вакыйгаларны сөйләп китсәң балаларга аеруча кызык була (берәр музейга вертуаль экскурсия үткәререгә була). Инде әңгәмәләр үткәреп, төрле китаплар укып, картиналар, рәсемнәр карап,

балаларны халкыбызның, яшәеше, көнкүреше, үткәне, гореф-гадәтләре, мирасы белән таныштырганнан соң, төрле уеннар уйнарга була.

Уенны оештырганда, түбәндәге максатларны күз алдында тоту мөһим:

1) укучыларның аралашу (коммуникатив) эшчәнлеген активлаштыру;

2) сөйләм эшчәнлеге дәрәҗәсенең төрле булуын истә тотып, рольләрне дөрес бүлү;

3) тормышта укучыларга яхшы таныш булган ситуацияләрдән файдалану;

4) үзара ярдәмләшү, телдән дөрес актив аралашу мөхите булдыру [Харисов 2002: 36].

Туган тел (татар теле) дәресләрендә фонетик, лексик, грамматик материалны үзләштерү белән берлектә укучыларны иҗади эшләргә, мөстәкыйль, креатив итеп уйларга өйрәткәндә, хәрәкәтле, рольле һәм компьютер уеннары ятатып кулланыла («Яшерелгән сүзне тап», «Йорт хайваннары һәм кошлары атамаларындагы сузыкларны тап», «Кем тизрәк укый?», «Алма жыю», «Яңа ел чыршысы», «Сабантуйга бәйле рәсемнәрне кара һәм парларын табып яз»).

Шула итеп, укытуда уен технологиясен куллану укытучы-укучы мөнәсәбәтен ныгыта, уку-укыту эшчәнлеген җанлы итә. Уен технологиясенең нигезен тәшкил итә торган эшлекле, рольле, имитацион уеннар укучыларның оештыру сәләтен, икътисади фикерләү дәрәҗәсен, экологик культурасын үстерергә ярдәм итә. Урынлы, оста итеп оештырылган уеннар балаларда телгә карата кызыксыну уята.

**Әдәбият**

1. Айдарова С. Белемгә уеннар аша. – Казан: Мәгариф, 1999. – №1. – Б. 40-41.

2. Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр. – Казан: Мәгариф, 2002. – № 8. – Б.33-36.

## ӘДӘБИЯТТАН СЫЙНЫФТАН ТЫШ ЭШЛӘР

Вәлимөхәмәтов К.И.
Әлмәтнең “Адымнар-Әлмәт” күптелле гимназиясе укучысы.
Фәнни җитәкче: Даутова А.Х.

Безнең гимназиядә әдәбияттан сыйныфтан тыш эшнең бер формасы буларак кичәләр актив кулланыла. Әдәби кичәләр бай мөмкинлекләргә ия. Укытучыларыбыз аларны оештыруда бу мөмкинлекләр тулысынча файдалану өчен, әдәби кичәне алдан ныклап уйлап үткәрергә тырышалар. Шулай ук аның класстан тыш чараның специфик формасы буларак үзенчәлекләрен дә исәпкә алалар.

Безне, укучыларны, әдәби кичәдә катнаштыруга тарту өчен, иң элек кичә эчтәлеге белән аның үткәрелү рәвешенең ярашуына ирешү тиеш саныйлар. Кайбер очракта әдәби кичәләргә танылган язучы, артист, җырчыларны чакыралар.

Укытучыларыбыз кичәнең мавыктыргыч, кызыклы булуына омтылалар. Бу укучылар белән тырышып эшләү нәтиҗәсендә туа да инде. Чөнки әдәбияттан сыйныфтан тыш эшләр укучыларның барысы өчен дә әһәмияткә ия. Мондый шартларда гына әдәби кичә укучыларга канәгатьләнү, шатлык хисләре бирә. Бу чит уңышларны күзәтүчеләрнең түгел, ә үзләре ирешкән нәтиҗәләрне күрүчеләр шатлыгы булыр.

Кичәнең темасын сайлап алу да җаваплы эш булып тора. Әдәбияттан дәрес һәм дәрестән тыш эшләрнең органик бәйләнеше теманы дөрес сайлауга бәйле.

Һәр коллетив, класс үзенчәлекләргә ия. Тема сайлаганда бу үзенчәлекләр исәпкә алынырга тиеш. Шулай ук сыйныф алдында торган проблемаларны, укучыларда үсеш алган күнекмәләрне, моңарчы сыйныфның нәрсә белән шөгыльләнүен дә белергә кирәк.

Гимназиядә  төрле сыйныфтан тыш чаралар уздырыла. Габдулла Тукай, Муса Җәлилгә багышланган чаралар бик кызыклы итеп оештырыла. Туган телгә багышланган КВН, кичәләр онытылмаслык та. Халык авыз иҗатына багышланган төрле чаралар, кич утырулар, фольклор-хореографик күренешләр безгә бик кадерле чаралар.

Әдәби кичәләр, зур тәрбияви максатларга җавап бирсен өчен, аларның тематикасын төрләндерү  мәҗбүри.

Тема сайлау кебек үк аның проблемасы да игътибарга лаек.

Әдәби кичәләр берничә төргә бүленә: уен-кичә, киң программалы кичә, уку кичәсе, сорау-җавап кичәсе. Аларның һәрберсе үз спецификасына ия. Бу төрләрнең кайсын да булса сайлау конкрет бурыч һәм шартларга бәйле.

Уен-кичәнең эчтәлеген әдәби уеннар алып тора. Күбесенчә укучылар аларда бик теләп катнаша. Ләкин теләсә нинди уен укучыларны кызыксындырыр дип уйларга ярамый. Дөрес оештырылмаган уеннар, әдәби уеннар бернинди дә файда бирмәячәк. Укытучылар да, укучылар да, чараларны оештырганда, бу хакта уйлап эш итәбез. Чараларны без бергә планлаштырып, уздырабыз.

Уен-кичәнең тематикасы алда торган бурычларга бәйле. Алар белемнәрне тикшерү һәм ныгыту, игътибарлы укуны стимуллаштыру чарасы буларак кулланылырга мөмкин. Материал берничә язучы яки бер язучы иҗаты буенча туплана. Уен шулай ук бер әсәр тексты буенча да төзелергә мөмкин.

Уеннар төрле типта булган саен, ул уңышлырак була бара. Мәсәлән, викторина гына куллану, сорауларга җавап бирү укучыларны ялыктыра. Шуңа күрә викторинадан тыш кроссворд, әдәби лото-домино куллану яхшы нәтиҗәләр бирә.

Уен-кичәдә әзер әдәби уеннар куллану мөмкин. Шулай ук без, укучылар үзебез уйлап тапкан уеннар оештыру яхшы нәтиҗәләр бирә.

Сорау-җавап кичәсе алдан билгеләп куелган сорауларга нигезләнеп төзелә. Бу сораулар биографик фактлар, язучы иҗатындагы күтәрелгән проблемаларга карарга мөмкин. Җавапны без, укучылар үзебез әзерлибез. Кирәк булса, укытучыбыз ярдәмгә килә.

Сәнгатьле уку кичәләре аерым бер әдәби әсәр укуга багышлана. Мондый кичәләр укучыларга яхшы аңлашылган максатлар белән үткәрелә. Аерым бер язучы иҗатына сыйныфта төрле карашлар яши икән, шул язучы әсәре буенча кичә үткәрү яхшы нәтиҗәләр бирә. Бу кичә әкренләп диспут характерын ала.

Язучының иҗаты белән тирәнрәк танышу максатын алган кичә икенче төс ала.Бу очракта укытучы материал сайлауга игътибар бирә, сәнгатьле уку эше белән шөгыльләнә.

Әдәби кичә - коллектив эшчәнлек. Ул күп сандагы укучылар көче белән оештырыла. Кичәнең уңышы һәр кеше башкарган эшкә бәйле. Кичәләргә укучылар берләшеп материал туплый, аның турында фикер алыша. Бер кеше генә җибәргән ялгышлык кичәгә зыян китерергә мөмкин. Шунлыктан мондый мохиттә коллективизм хисләре туа һәм үсә.

Әдәби кичәгә әзерлек укучыларны мөстәкыйль эш башкарырга күнектерә. Материалны әзерләгәндә алар кешеләргә, музей, китапханә, театрларга мөрәҗәгать итәләр. Болар барысы да әһәмияткә ия.

## 9 СЫЙНЫФТА ШИГЫРЬЛӘРНЕҢ ТӘРБИЯВИ ПОТЕНЦИАЛЫН ӨЙРӘНҮ ПРОЦЕССЫНДА УКУЧЫЛАРДА ШӘХСИ УУГ ФОРМАЛАШТЫРУ АЛЫМНАРЫ

Вәлиуллина А.А.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Р.Б.Камаева

Мәктәптә “Татар әдәбияты” предметын укыту кысаларында укучыларның универсаль уку гамәлләрен (УУГ) үстерергә мөмкин: шәхси, регулятив, танып-белү, коммуникатив [Сластенин 2002: 182]. Әлеге мәкаләдә 9-нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресләрендә поэзия бүлеген өйрәнү процессында укучыларда шәхси УУГ формалаштыру һәм үстерү өчен типик биремнәр мисалларын карап узарбыз.

Шәхси УУГ укучыларда рухи кыйммәтләр формалаштыруга (эшләрне һәм вакыйгаларны кабул ителгән этик принциплар белән бәйләү сәләте, әхлак нормаларын белү һәм тәртипнең әхлакый аспектын аңлау сәләте) һәм шулай ук җәмгыятьтә кабул ителгән шәхес-ара бәйләнешләрне урнаштырырга юнәлеш бирә [Фундаментальное ядро..., 2009: 14].

Әдәбият дәресләре укучыларда шәхси УУГне үстерергә булышлык итә. Әдәби әсәрләрне анализлау барышында укучылар үзләрендә шәхси УУГ формалаштыра ала. Бу эш әдәби әсәрне анализлау процессында төрле күнегүләр башкару аша тормышка ашырылырга мөмкин.

Мәкаләбездә мисалларны рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен 9нчы сыйныф дәреслегеннән алырбыз [Хәсәнова 2017].

Мәсәлән, эпиграфлар белән эш. Конкрет мисалда карап узыйк: Рөстәм Мингалимнең “Үпкәләрмен кебек” шигырен өйрәнер алдыннан: “Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык” татар халык мәкален эпиграф итеп алыйк. Әлеге эпиграфка карата түбәндәге сорауларны формалаштырырга мөмкин:

- эпиграфны ничек аңлыйсыз?
- туган якның үзгә ягы нинди?
- эпиграфны тасвирлагыз (туган ил – кеше өчен дөньядагы иң кадерле җир).

Эпиграфка нигезләнеп, укучылар дәреснең темасын һәм укыту максатын формалаштыралар (Тема: “Туган җир – алтын бишек”. Максат: Р.Мингалим иҗатын өйрәнү процессында туган җирнең кеше тормышындагы әһәмиятен ачыклау).

Эпиграфлар белән икенче төр эш: ике эпиграф бирелгән, укучыларга алар арасында уртак үзенчәлекләрне табарга кирәк.

*Дусыннан аерылган җиде ел җылар,*
*Иленнән аерылган гомер буе җылар.*

Һәм:

*Җир-суы бар җирен сөйләр,*
*Ил-йорты бар илен сөйләр,*
*Ил-йорты юк ниен сөйләр?*

Укучылар шәхси әһәмиятле нәтиҗәгә киләләр: һәр кеше өчен үзе туып-үскән җир әһәмиятле. Туган җиреннән аерылган кеше – оясыннан аерылган кош сыман. Аны гомере буе туган җирен сагыну, юксыну кебек хисләр озата барачак.

Укучылар дәрес темасына нигезләнеп, аның өчен эпиграфны мөстәкыйль сайларга тиеш була (өй эше буларак бу бирем алдан бирелә). Мисал өчен, Р.Мингалимнең “Үпкәләрмен кебек” шигырен өйрәнү өчен түбәндәге темаларны аерып чыгарырга мөмкин: туган якны ярату, хөрмәт итү, шәхес өчен туган ягының дөнья үзәге булуы, шәхес өчен туган ягының иң матур җир булуы.

Укучылар тәкъдим ителгән эпиграфлардан дәрес темасына туры килгәнне сайларга тиеш. Үзләренең сайлаган эпиграфын аргументларга тиеш. Мисал өчен, Гамил Афзалның “Өф-өф итеп” шигырен өйрәнү дәресенә түбәндәге эпиграфлар тәкъдим ителгән:

*Ата баласы аз рәхәткә, күп хәсрәткә түзәр (Татар халык мәкале).*
*Аттан тай узар, Атадан бала узар (Татар халык мәкале).*
*Акылсыз атка менсә, атасын танымас (Татар халык мәкале).*
*Ким козгындин туар козгын,*
*Атасыннан булыр узгын. (Г.Кандалый)*
*Атадан күргән ук юнган (Татар халык мәкале).*

Эпиграфлар белән эшләп, укучылар тема формалаштырып, максатлар куеп кына калмыйлар, шулай ук үзләрендә сәнгатькә, тарихка, Ватанга һәм кешелек кыйммәтләренә уңай караш үстерәләр.

*Әсәр исеме белән эшләү*. Әсәр исеменә нигезләнеп, укучылар текстның эчтәлеге турында фаразлыйлар. Укыганнан соң, алар исемгә кире кайталар һәм аларның фаразлары текст эчтәлегенә туры килдеме-юкмы дигән сорауга җавап бирәләр.

Мәсәлән, Рәшит Әхмәтҗановның “Сандугач керде күңелгә” шигырен өйрәнер алдыннан, укучылар шигырь исемен укып, бу әсәрдә ни турында сүз

барачагы турында фаразлый. 9нчы сыйныф укучылары бу шигырьдә сүз ирек, сагыну, туган якка булган мәхәббәт, мәхәббәт темаларына булырга мөмкин дип фаразлый ала. Әлеге темаларны сайлауларын алар сандугач образыннан чыгып асоциацияләүләренә бәйле төстә аңлата ала. Сандугач – ирек, туган як җырчысы символы, шуңа күрә дә бу шигырьнең темасы лирик геройның туган якны сагынуы, туган ягына мәхәббәт хисен белдерү буларак шәрехләделәр. Шушы ук идеяны дәвам итеп, сыйныфта тема буенча аралашу процессында, укучылар бу шигырь мәхәббәт турында булырга мөмкинлеген фаразлый алалар.

Шигырь белән танышканнан соң, бу әсәр чыннан да мәхәббәт турында икәнлеген, ә шигырь исеме – метафора булуын аңлатабыз. Бу әсәрдә сандугач символик образы укучылар өчен яңа мәгънә белән баетылган булуын ачыклыйбыз. Сандугач – әдәбиятта мәхәббәт җырчысы, мәхәббәт символы да була ала икән, дип нәтиҗә чыгарабыз. Әлеге анализны башкару укучыларда шәхси УУГ формалаштырырга мөмкинлек бирә. Аерым алганда әсәр исемен анализлау аша укучыларда әхлакый-этик нормалар формалаша ала.

*Сенкан.* Синквейн кебек үк, ул алынган мәгълүматны, хисләрне, эмоцияләрне кыскача аңлатма итеп формалаштырырга ярдәм итә. Мәсәлән, Газинур Моратның “Шагыйрь авылы” шигырен укыганнан соң, әсәрдәге хис-кичерешләрне түбәндәге сенкан буенча күрсәтергә мөмкин:

Беренче юл – шагыйрьнең (Рөстәм Мингалимнең) Йолдыз исемле авылы юкка чыккан.

Икенче юл – шагыйрь өчен авылын югалту – космик ялгызлыкка хас.

Өченче юл – туган авыл – шагыйрь өчен иң газиз хатирәләр, иң якын кешеләре белән бәйле урыны булган.

Дүртенче юл – шагыйрьнең туган авылы җырларда гына калган.

Бишенче юл – туган авылны юксыну.

Бу алым аша әсәрне анализлау укучыларның киләчәктә әхлакый сайлау ситуацияләрендә дөрес юл сайларга өйрәтә, аларда дөньяга, укуга, яшәешкә мәгънәви караш формалаштыра.

*“Ачкыч сүзләр” алымы.* Дәреснең мотивацион этабында “Ачкыч сүзләр” алымын кулланырга мөмкин. Укытучы дәрес темасы һәм әсәр идеясы белән бәйле сүзләр тәкъдим итә. Аларны кулланып, укучылар тема, дәрес материаллары турында фаразлар ясыйлар һәм мөстәкыйль рәвештә проблемалы сораулар формалаштыра алалар. Мәсәлән, Гамил Афзалның “Өф-өф итеп” шигырен өйрәнү барышында түбәндәге ачкыч сүзләрне аерып чыгарырга мөмкин: *малай, өф-өф итеп, “Казбек”, папирос, шиблет, костюм, лап-лоп, голт-голт, дөп-дөп.*

Әлеге сүзләрнең нинди уртак яклары бар? Бер өлеше аваз ияртемнәреннән гыйбарәт (өф-өф, лап-лоп, голт-голт, дөп-дөп), икенче төркем сүзләр предмет атамалары (“Казбек”, папирос, шиблет, костюм). Бу ике төркем сүзләр дә малайга кагыла дигән нәтиҗәгә киләбез. Алга таба һәр сүзнең мәгънәсен аңлатмалы сүзлектән карап, шәрехлиләр. Ахырдан, шигырь белән танышканнан соң, бу сүзләрне динамик тәртиптә урнаштыралар һәм ни өчен шундый тәрбиясез бала үсү сәбәбен аңлаталар: әти-әнисе аны өф-өф итеп

үстергән, артык очындырган, һәр теләген шундук үтәгән, шуңа бала әрәмтамак булып үскән. Үз фикерен алар тексттан өзек китереп, дәлилли:

*Малай туды безнең. Нинди шатлык!*
*Икебезгә уртак бәхет таптык.*
*Сокланабыз аңа исебез китеп,*
*Өф-өф итеп, өф-өф итеп.*
...
*Матур кызлар белән перәнник ашый,*
*Акча сорап, безгә допрос ясый,*
*Бирми торсаң, хәзер кыйнап ташлый*
*Дөп-дөп итеп, дөп-дөп итеп.*

Бу шигырьне "ачкыч сүзләр" алымы аша анализлау укучыларда белем алу процессында төп тезисларны аерып чыгарырга, план төзергә һәм шул рәвешле үз белем алу процессын көйләргә өйрәтә.

Йомгаклап әйткәндә, карап узылган алымнар 9нчы сыйныф укучыларының татар әдәбияты дәресләренә кызыксынуын арттырырга, текстны анализлау сәләтен үстерергә, УУГ формалаштырырга булышлык итә. Яхшылык, вөҗдан, ихтыяр, мәхәббәт һ.б. кебек мәңгелек төшенчәләрне исәпкә алып, аларга карата үз шәхси мөнәсәбәтләрен белдерү, әдәбият текстыннан алынган мисаллар белән фикерләрен расларга өйрәнү берьяктан 9нчы сыйныфны тәмамлаганда оештырыла торган йомгаклау сочинениесына әзерлек этабы да булып тора.

**Әдәбият**

1. Сластёнин В.А. и др. Педагогика: Учеб. пособие для студентов высших пед. учебных заведений / В.А. Сластёнин, И.Ф. Исаев, Е.Н. Шлянов; Под ред. В.А. Сластёнина. – М.: Издат. Центр «Академия», 2002. – 576 с.
2. Фундаментальное ядро содержания общего образования / под ред. В.В. Козлова, А.М. Кондакова. – М.: Просвещение, 2009. – 59 с.
3. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 9 нчы с-ныф. Ике кисәктә. 2 нче кисәк / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: "Мәгариф – Вакыт нәшр.", 2017. – 191 б.

## БАЛАЛАРНЫ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЙОЛАЛАРЫ, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ, БӘЙРӘМНӘРЕ ҮРНӘГЕНДӘ ТӘРБИЯЛӘҮ

Вахитова Л.Р.
Беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәп укучысы.
Фәнни җитәкче: Мтеева З.Ш.

Җәмгыятебезнең киләчәге бүген мәктәптә укучы егет һәм кызларның гражданлык сыйфатларына, чын патриотлар булып үсүенә бәйле. Үз иле, үз халкы белән горурланган кеше генә башка халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын хөрмәт итә. Бик тә аяныч хәл - балаларыбызның туң йөрәкле, үз

мәнфәгатен бөтен нәрсәдән дә өстен куючы затлар булып үсү куркынычы килеп басты. Галимнәр әйтүе буенча, кешедә ике төрле авыру булырга мөмкин. Берсе матди (физик), икенчесе - мәгънәви (рухи) авыру. Физик авыруны күз яки прибор белән күреп була. Ә менә икенче авыруыбыз - сөйләгән сүзләрдә, ясалган хәрәкәтләрдә күренә һәм бу авыруны төзәтү өчен көннәр, айлар, еллар таләп ителә.

Рухи-әхлакый тәрбия бирү, белгәнебезчә, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бик уңышлы тормышка ашырыла. әдәбият укучыны олы тормышка әзерли. Яшәргә, кешеләр белән аралашырга, теге яки бу хәлдә үз-үзеңне ничек тотарга өйрәткән әдәби әсәрләрне укучылар бик кызыксынып үзләштерәләр. Әдәбият программаларында һәр сыйныф өчен фольклор әсәрләре тәкъдим ителә. Дәреслекләргә кертелгән мәкаль, табышмак, әкият, мәзәк, әйтем, җыр, шигырь, хикәяләр укучыларга татар халкының бай рухи дөньясын тирәнрәк һәм тулырак аңларга, күп гасырлар буена тулыландырып, туплап килгән югары әхлак-әдәп нормаларын, күркәм гореф-гадәтләрен яратырга һәм үзләштерергә ярдәм итәләр.

Әдәбият укытучылары, халкыбызның гасырлар буе тупланган тормыш тәҗрибәсен, зирәк акылын, тапкыр фикерләрен, үзенчәлекле тәрбия алымнарын, әхлак нормаларын, яхшы гамәлләрен бала тәрбияләүдә бик оста кулланалар. Мәсәлән, бер генә мисал: халкыбызның авыз иҗатында буыннан - буынга, телдән - телгә күчеп килгән уңай традицияләре яңа чордагы яшь кешенең яңа сыйфатларын тәрбияләүдә ярдәм итә. Халык авыз иҗатының иң мөһим тәрбияви көче менә шунда да инде. Халыкның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә әйдәүче әкиятләре, киң колачлы җырлары, тирән мәгънәле әйтемнәре, тапкыр һәм үткер мәкальләре, үзенчәлекле табышмаклары һәм башка күп төрле иҗат җимешләре яшь буынны яңа рухта тәрбияләүдә хәзинә булып торалар. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмас кебек. Халык бәйрәмнәре, йолалары – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Эш шунда ки, без, Чувашстан җирендә яшәвече мишәрләр, ул бәйрәмнәрне мәктәптә укытучылар белән берлектә уздырабыз. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үсә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә һәм милли тәрбия ала.

Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, сынамышлар, такмаклар, әкиятләр, бәетләр, моңлы бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак. Халык бәйрәмнәре ул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе.

Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Безнен якта татар халкының ***Сөмбелә, Сабантуй, Нәүрүз, Нардуган, Корбан гаете,Ураза бәйрәме, каз өмәсе, никах-туй йоласы, бәби туйлары сакланып калган.***
Шушы бәйрәмнәрнең кайберләре безнең мәктәптә дә үткәрелә.

***«Аулак өй»***нең нәрсә икәнен мөгаен һәр кеше дә беләдер, чөнки бу гореф-гадәт бик борынгыдан килә. Нәкъ менә шул «Аулак өй» татарларның гореф -

гадәте булып киткән. Аулак өй – халкыбызның борынгыдан килгән йоласы, яшьләр өчен аралашу, сөйләшү, киңәшү, танышу урыны булган. Яшьләр генә катнашкан бу традицион күңел ачуларның һәм андагы уеннарның тотрыклы бер тематик юнәлеше бар: анда үзеңә пар сайлау, яшьләр җәмәгате алдында үзеңнең уңганлыгыңны-булганлыгыңны, зирәклегеңне күрсәтү төп урынны алып тора. Гадәттә, кызның әти-әнисе күрше авылга кунакка киткәндә, ул алардан кызлар чакырыр өчен рөхсәт сорап калган. Хуҗалар киткәннән соң, кызлар кул эшләрен алып, шушы йортка җыелганнар. Алар җырлап, биеп, мәзәкләр сөйләп чигү чиккәннәр, бәйләгәннәр. Бу хәбәрне ишетеп, авыл егетләре гармуннар белән әлеге өйгә килгәннәр. Ишек шакып, ишек аркылы кызлар белән капма-каршы әйтешкән сүзләре кызыклы һәм бүгенге көнгә кадәр сакланып калганнар. Ә аулак өйләрдә уйнала торган уеннарның иң киң таралганы: йөзек салыш, күз бәйләш яки сукыр тәкәле, җәза бирелә.

Әлбәттә, мондый бәйрәмнәр уздыру  өчен яшьләргә дөрес тәрбия бирергә, алар белән татар халкы рухында аралашырга, тарихы белән таныштырырга, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын аңлатырга, туган телнең матурлыгын һәм кыйммәтен җиткерергә кирәк.

Яңа уку елына аяк басу белән, уңыш бәйрәме, алтын көзне каршылау ***“Сөмбелә”*** бәйрәме белән башланып китә. “Сөмбелә” уңыш бәйрәме. 21нче августтан 22 нче сентябрь аралыгы халык телендә Сөмбелә айлыгы дип йөртелгән. Әлеге бәйрәм уңыш җыелып алганнан соң үткәрелгән. Бәйрәмгә алдан ук әзерләнә торган булганнар:өйләрне, ишегалларын җыештырганнар, татар халык ашларыннан чәк-чәк, бавырсак, өчпочмак, бәлеш пешергәннәр, кунаклар чакырганнар. Халык бу көнне көне буе бәйрәм иткән, җырлаган, биегән, төрле уеннар уйнаганнар. Сөмбел  сүзе *“сары башак”* дигән мәгънәгә туры килә. Безнең ата – бабаларыбыз  Сөмбеләне  уңыш җыеп алу ае итеп кенә түгел, ә шул айның уңыш алиһәсе - алтын сары толымлы, *“сөмбел чәчле”*  кыз итеп тә күз алдына китергәннәр. Сөмбелә  бәйрәме 15 нче сентябрьгә, көн белән төннең көзге тигезләшкән чорына туры килә.

Сабантуй – олы бәйрәм һәм аңа хәзерлек алдан ук башланган. Хатын-кызлар өй җыештырган, бөтен нәрсәне чистартканнар. Ирләр исә ишегалдын, урам тирәләрен себергәннәр, чүп-чарны  җыештырганнар, бәйрәм көнгә лаек нигъмәтләр әзерләгәннәр.

Сабантуй иртә яздан башлап үткәрелә торган тулы бер йолалар, күңел ачулар, ярыш-бәйгеләр тезмәсе икәнлеген исбат итәләр. Алар язын кар эреп җир ачыла башлаган көннәрдән алып язгы чәчүгә кадәр үткәрелгән. Инде борынгыдан калган йолаларга килсәк, анда каз өмәсе  билгеле бер урын алып торган.

Яшьләр өмәгә бик теләп барган, авыр эшләрне дә бәйрәм кебек итеп башкарып чыга белгән. Йолкыган казларны көянтәгә асып кызлар чишмәгә, су буена юл totканнар. Анда барып казларны  салкын чишмә суында чайкый-чайкый юганнар. Чишмәгә бару-үзе бер йола белән бәйле. Кызларга, гадәттә, гармуннарын алып, егетләр ияртә торган булган. Монда да җыр, такмак әйтү, чишмә буенда биюләр башкарылган.

Казларны юып кайтуга хуҗабикә каз маенда бик әйбәтләп коймак, я тәбикмәк пешереп, чәй әзерләп көтеп тора. Ә аш-бәлешләр кич белән була. Кичке мәҗелес тәмамлануга, шул йортта төрле уеннар оештырылган.

Улы яки кызының үз тормышын корыр вакыты җитсә, ана кеше берничә казын туйга дип саклап торткан. Чөнки пар каз-ул туйның хөрмәтле кучтәнәче. Матур табакка салып казны туй мәҗелесенең түренә чыгарганнар.

Татар халкының милли бәйрәмнәре милли хисләр формалашуга, аларның культурасын, милли горурлык тәрбияләүгә ярдәм итәләр, шул ук вакытта алар милли хисне канәгатьләндерүдә, гамәлгә ашыруда нәтиҗәле чара да булып тора.

Бу гадәтләр югалмасын өчен без аларны онытмаска, хөрмәт итәргә, белергә тиеш. Аларны белсәк, безнең телебез дә югалмас, сакланыр. Шуңа күрә хәзерге заманда бу бик актуаль проблемаларның берсе дип уйлыйм.

**Әдәбият**


1. Мәктәп музеендагы архив материаллары.
2. СалиховП .М.. “Шыгырдан” газетасы материалларыннан, 2010.


## ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ СҮЗ ЯСАЛЫШЫ


Габдрафикова Диана
Алабуга шәһәре Инженер-технология лицее укучысы.
Фәнни җитәкче: Гатауллина М.Г.


Белүебезчә, татар һәм рус телләре – икесе дә грамматик төзелешкә ия булган телләр. Рус теле флектив, ә татар теле агглютинатив телләр төркеменә керә. Гадәттә татар телендә грамматик мәгънә билгеле бер тәртиптә ялганып килүче мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар, ә рус телендә – окончаниеләр (флексияләр, аффикслар) ярдәмендә белдерелә, мәсәлән: мәктәп-ләр – школ-ы, мәктәп-ләр-гә – школ-ам һ.б.

Һәр ике телдә дә сүзләр бер яки берничә морфемадан торалар (уку-чы-лар-ны, рус-ча; под-вод-н-ый, дом-ик). *Морфема* – сүзнең иң кечкенә мәгънәле кисәге. Мәсәлән: укучыларны сүзендә 4, домик сүзендә - 2 морфема бар. Шулардан *уку-укучыларны* сүзенең, *дом – домик* сүзенең реаль мәгънәгә ия булган иң кечкенә кисәге һәм ул *тамыр – корень* дип атала.Ә калган морфемалар өстәмә лексик- грамматик мәгънәләр белдерәләр. Аларны *аффикс* дип йөртәләр.

Татар телендә ясалма нигезле сүз составындагы барлык тамыр морфемалар да үзгәрешсез кала һәм конкрет сүз төркеменә карый, мәсәлән: юл-даш-ны (юл- исем), бүл-мә-гә (бүл- фигыль). Рус телендә исә мондый сүзләрдәге тамырның нинди сүз төркеменнән булуын ачыклавы читен, чөнки ул үзгәрешләргә дучар була, мәсәлән: сил(ь)-н-ый,книж-н-ый һ.б.

Татар телендә дә моңа охшаган очраклар күзәтелә, ләкин ул рус теле дәрәҗәсендә үк булмый һәм гадәттә алар түбәндәгеләр белән аңлатыла:

- тамыр һәм аффикс чигендә ике сузык янәшә килә алмау сәбәпле, тамыр морфемадагы соңгы сузык авазның кыскаруы (төшеп калуы), мәсәлән: тыңла – тыңл(а)-ый, сөйл(ә)-исең һ.б.
- тамыр морфемадагы соңгы саңгырау тартыкның аңардан соң сузык авазга башланган кушымча килгән очракта яңгыраулашуы, мәсәлән: китап- китабы, колак- колагы һ.б.

Кушымчалау – аффиксация – татар телендә сүз ясау һәм чынбарлыкка мөнәсәбәт белдерүнең төп чарасы булып тора. Бу татар теленең башка төрки телләр кебек агглютинатив тел булуыннан килә.

Аффикслар өстәмә лексик һәм грамматик мәгънә өстәүче мәгънәле кисәкләр – рус һәм татар телләренең икесендә дә

- *яңа сүз ясау,*
- *сүзләрнең башка төрләрен ясау,*
- *сүзләрне төрләндерү, аларны бер-берсенә бәйләү* функцияләрен үтиләр. Ләкин монда да аермалар бар. Рус телендә аффиксларның түбәндәге төрләре була: приставка (префикс), суффикс һәм окончание (флексия). Приставкалар һәм суффикслар – яңа сүз һәм аларның төрләрен ясау функцияләрен үтиләр, мәсәлән: *надбавка* сүзендә *над* приставкасы һәм -к- суффиксы – икесе дә сүз ясаучылар; ә *рассказывать* сүзендә -*ыва*- суффиксы төр ясый.

Рус телендәге окончаниеләр нигез составына кермиләр. Алар бары тик төрләндерү функциясен генә үтиләр һә гадәттә сүзнең ахырында киләләр, мәсәлән: *Окно открыто.* Окончаниеләрнең түбәндәге төрләре була:

- лицо (зат) – *пиш-у, пиш-ешь,пиш-ет;*
- падеж (килеш) – *школ-ой, школ-е;*
- род (грамматик женес) – *окн-о открыт-о, школ-а закрыт-а;*
- число (сан) – *он писал,он-и писал-и.*

Татар телендә приставкалар да, суффикслар да, окончаниеләр дә юк. Монда кушымчалар рус телендәге приставка, суффикс һәм окончание функцияләрен үтиләр; һәрбер кушымча бер генә грамматик мәгънә белдерә, мәсәлән: *мәктәп-ләр-нең* сүзендә *–ләр* кушымчасы күплекне, -*нең* иялек мөнәсәбәтен белдерә. Күрүебезчә, һәрбер кушымчаның үз грамматик мәгънәсе бар. Ә рус телендә шул ук грамматик мәгънәләр бер генә окончание белән бирелә ала, мәсәлән: *дом-ов* сүзендә *ов* окончаниесе бер үк вакытта иялек килеше һәм күплекне күрсәтә.

Ике телдә дә сүзнең мәгънәле кисәкләре – морфемалар – билгеле бер тәртиптә урнашалар. Татар телендә тамыр морфемадан соң сүз ясагыч кушымча булса, аннары мөнәсәбәт белдерүченең модальлек, шуннан соң гына мөнәсәбәт белдерүченең бәйләгеч төренә керүче кушымчалар бер-бер артлы бәйләнеп килә , мәсәлән: *эш* (тамыр) – *че* (ясагыч) – *ләр* (мөн. белд. мод.) *–не* (мөн. белд. бәйл.).

Рус телендә дә һәрбер аффиксның үз урыны бар: приставка тамырга хәтле, суффикс – тамырдан соң, окончание – сүз ахырында килә. Сүзләрне төрләндергәндә, окончаниеләр берсен икенчесет алмаштырып килә, татар

телендәге кебек, берсе артыннан икенчесе тезелеп килми, мәсәлән: книг-а (ед.ч) – книг-и (мн.ч).

Татар һәм рус телләрендәге аффиксларның урнашу тәртибе, алрның уртак һәм аермалы яклары түбәндәге таблицада ачык күренә.

| *Татар теле* | - | *тамыр* | *Сүз ясагыч кушымча* | *Мөнәсәбәт белдерүче* | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | *модальлек* | *бәйләгеч* |
| *Рус теле* | *приставка* | *корень* | *суффикс* | *Окончание* | |

Татар телендә барлык төр кушымчалар да, сүзнең алдагы өлешенә карап, нечкә яки калын вариантларда булалар. Мәсәлән: бакча-чы-лар-га (калын), күңел-ле-рәк (нечкә) һ.б.

Сүз ясагыч аффикслар нигезендә ике телдә дә ясалма нигезле сүзләр ясала, һәм яңа сүзләрнең тамыр белән мәгънә уртаклыгы саклана. Мәсәлән: акыл-лы, күңел-ле; писа-тель, грамот-н-ый. Татар телендә дә , рус телендә дә бер үк сүздә берничә сүз ясагыч аффикс килергә мөмкин, мәсәлән: акыл-лы-лык, свиде-тель-ство. Сүз ясагыч аффикслар ялганып ,ике телдә дә сүзләр шул ук сүз төркемендә калырга яки башка сүз төркеменә күчәргә мөмкин, мәсәлән: эш-эшче, дус- дуслык; берёз(а) – березняк, стар(ый) – старость һ.б.

Без өйрәнә торган ике телдә дә, яңа сүзләр ясалуның иң продуктив ысуллары булып аффиксацияләү һәм сүзләр кушылу ысуллары исәпләнә. Рус телендә аффиксацияләүнең 3 төре була: суффикслар, префикслар һәм префикс + суффикс ярдәмендә.

Гомумән, ике телдә дә һәрбер сүз төркемендә яңа сүзләр ясалуның үз үзенчәлекләре бар.

Әдәбият

1. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзьясалышы. – Казан: Мәгариф, 2000.
2. Немченко В.Н. Современный русский язык: Словообразование. – М.: Высшая школа, 1984.
3. Татар грамматикасы: Өч томда – I т. –М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРГА ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ

**Габдрахманова Г.Р.**
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б

Мәктәпнең тәрбия системасында гражданлык-патриотик тәрбия үзәк урынны алып тора: гражданлык, патриотизм, хезмәт сөючәнлек, әхлак

формалаштыру, социаль әһәмиятле кыйммәтләр формалаштыру, кеше хокукларына һәм ирекләренә хөрмәт, Ватанга, гаиләгә, әйләнә-тирә табигатькә мәхәббәт; ихтыяҗларның танып белү мәнфәгатьләрен үстерү.

Патриотик тәрбия укучыларның әхлакый-сәяси сыйфатларын формалаштыру буенча эшнең мөһим юнәлеше. Укучыларда патриотизм хисләрен формалаштыруга әңгәмәләр, кешеләрнең батырлыгы һәм батырлыгы турында китаплар уку, сугышчылар, элекке фронтовиклар белән танышу һәм дуслык ярдәм итә.

Патриотик тәрбия дәресләрендә балаларны үз җирләренең тарихын кадерләргә, аның һәйкәлләрен кадерләргә, батырлыклары белән расланган һәм Туган ил даны Туган кешеләрнең батырлыкларына баш иярге өйрәтергә кирәк.

Татар әдәбияты – уку предметы буларак бик югары танып белү кыйммәтен йөртә: туган телгә мәхәббәт хисе тәрбияләү, гомумкешелек кыйммәтләрен аңлау, югары патриотизм хисе булган шәхес тәрбияләү [Заһидуллина 2000: 83].

Укучыларда патриотизм хисе тәрбияләү – әдәбият фәне алдына куелган төп максатларның берсе. Патриотизм (ватанпәрвәрлек) – грек сүзе, ул Ватаныңны, илеңне һәм халкыңны ятатуны аңлата. Патриотик тәрбия – ватанпәрвәр затларның батырлыгы, таланты, әхлакый сыйфатлары, героик көрәш традицияләре үрнәгендә яшь буын аңына йогынты ясау, үз илеңнең символларына ихтирам һәм хөрмәт уяту ул [Хуҗиәхмәтов 2019: 24]. Хәзерге шартларда балаларда ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү җиңел эш түгел.

Патриотик тәрбия эшен алып баруда укытучылар мөһим роль уйный. Укытучы – ул буыннарны тоташтыручы, белем биреп кенә калмыйча, укучыларга өлкән буыннарның рухи байлыгын җиткерүче дә. Һәр дәрес, бигрәк тә әдәбият дәресләре патриотик тәрбия бирү мәктәбе булырга тиеш. Үткәндәге рухи тәҗрибәне саклап калу, аны бүгенге һәм киләчәк буыннарга җиткерү ниятеннән чыгып, әдипләр еш кына игътибарларын бу тәҗрибәне үзендә йөртүчеләргә юнәлтәләр.

Ватанны хөрмәт итү – якыннарыңны, туганнарыңны, үзең яши торган йортны, урамны, авылны, шәһәрне, анда яшәүчеләрне, эшләүчеләрне ихтирам итү ул. Бүген балаларны хезмәт һәм сугыш ветераннары үрнәгендә тәрбияләү – аеруча мөһим. “Аларны кайдан табарга соң?” – дип әйтерсез. Алар безнең тарихыбызда, сәнгать әсәрләрендә, әдәби әсәрләрдә, хәзерге тормышыбызда.

Урта сыйныфларда патриот әдипләребез – Муса Җәлил, Абдулла Алиш кебек балалар өчен иҗат иткән шагыйрь, язучыларыбызның “Чәчәкләр”, “Кызыл ромашка”, “Тик булса иде ирек”, “Җырларым, “Бер үгет”, ”Имән”, ”Катыйльгә” шигырьләре; И.Газиның “Йолдызлы малай”, Л.Ихсанованың “Лачын кыз”, Г. Әпсәләмовның “Миңа 19 яшь иде”, Г. Кутуйның “Сагыну”, Ә. Еникинең “Кем җырлады?”, М. Юнысның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” әсәрләре зур кызыксыну белән өйрәнелә.

Татар мәктәбенең 5-7 нче сыйныфлары өчен төзелгән эш программаларына күзәтү ясаганда, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә файдаланырлык шактый әсәрләр барлыгы ачыкланды. Мәсәлән, 5 нче сыйныфта Г.Тукайның “Туган җиремә”, “Шүрәле” әсәрләре укыла һәм

өйрәнелә [5-9 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият» фәнен федераль белем бирү программаларына нигезләнеп укыту буенча методик тәкъдимнәр https://mon.tatarstan.ru/metodicheskie-rekomendatsii-7050209.htm].
6 нчы сыйныфта патриотик тәрбия бирү эшен Россия һәм Татарстан гимнын өйрәнүдән башларга мөмкин. Шулай ук Р.Рәкыйповның “Туган тел турында бер шигырь”, Л.Леронның “Фашист очып үтте”, Р.Мөхәммәдиевнең “Беренче умырзая” кебек әсәрләрдә туган җирдә яшәүнең зур бәхет икәнлеге аңлатыла [Электрон хрестоматия 5нче сыйныф https://mon.tatarstan.ru/metodicheskie-rekomendatsii-7050209.htm].

М.Җәлил иҗаты да 6 нчы сыйныфта тирәнтен өйрәнелә. “Батырлык кечкенә булмый” темасында М.Җәлилнең “Сандугач һәм чишмә” балладасы укыла. “Моабит дәфтәрләре”ндәге шигырьләре әле озак еллар дәвамында баларны патриотик рухта тәрбияләү юнәлешендә кулланылалар. Бигрәк тә тәрбия өлкәсендә зур проблемалар хөкем сөргән бүгенге дәвердә.[Электрон хрестоматия 6 нчы сыйныф https://mon.tatarstan.ru/metodicheskie-rekomendatsii-7050209.htm].

7 нче сыйныфта Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәре укыла. Әлеге дәресләр кысаларында туган җир – тормыш мәктәбе икәнлеге балаларга җиткерелә. Язучы җир, туган як белән бәйләнеш, халкының традицияләренә хөрмәт белән карау, крестьян хезмәтенә мәхәббәт, рухи ныклык, әхлакый матурлык кебек сыйфатларын ачып бирә. Әлбәттә, бу матур сыйфатлар укучы күңеленә тәэсир итми калмас. Чөнки туган якның гүзәллеген, аның сихри матурлыгын һәр кеше тоеп үсәдер [Электрон хрестоматия 5 нче сыйныф https://mon.tatarstan.ru/metodicheskie-rekomendatsii-7050209.htm].

М.Мәһдиевнең “Без – 41 нче ел балалары” әсәрендә Бөек Ватан сугышы чорының авыр шартларында педагогия училищесында укучы яшүсмерләрнең көндәлек тормышын, аның формалашуын, дөньяны танып белергә өйрәнүләрен кызыклы ситуацияләр, оста тотып алынган тормыш детальләре һәм үзенчәлекле кеше характерлары аша гаҗәеп җанлы итеп гәүдәләндергән, композицион яктан җыйнак эшләнгән һәм күп бизәкле, җор, үткен тел белән язылган әлеге повесть укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан татар прозасындагы бер яңалык итеп каршы алына [Заһидуллина, 2000: 78].

Шулай ук Х.Туфанның “Агыла да болы агыла...”, Р.Харисның “Кеше кайчан матур була?” кебек шигырьләре дә укучыларга патриотик тәрбия бирүдә игътибарга лаек әсәрләр. 7 нче сыйныфта “Туган телне сайлап алмыйлар” темасын үткәндә Г.Моратның “Туган тел” шигыре өйрәнелә. Г.Кутуйның “Сагыну” нәсере – патриотик тәрбия бирүнең гүзәл үрнәге. “Сагыну” нәсерендә дошманны куып баручы солдатның эчке кичерешләрен, хисләрен аеруча осталык белән тасвирлый.

Нәсер жанры безнең әдәбиятта сирәк очрый.

Патриотик тәрбия, укучыларга белем бирү белән беррәттән, төрле сыйныфтан тыш чараларда: тәрбия сәгатьләре, әдәби кичәләр, шигырь конкурслары, әсәрләрне сәхнәләштерү, очрашулар аша да бирелә.

Ватанга бирелгәнлек хисе тәрбияләүдә туган як тарихын өйрәнү зур ярдәм итә. Үз төбәген, аның тарихын, белмәгән, өйрәнмәгән, аңа битараф

кешене үз туган илен ярата дип әйтеп булмый. Димәк, туган илне ярату, милләткә хезмәт итәргә әзер булу хисләре тәрбияләү өчен туган төбәк материалларын белү әһәмиятле.

Татар халкының тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, милли киемнәре, бәйрәмнәре һәм Республикабызның иҗтимагый тормыш вакыйгалары, символикасы белән даими таныштырып тору гына түгел районыбызда яшәүче төрле милләт халыкларының: рус, удмурт, мари һәм башкаларның үзләренә хас гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен өйрәнү дә бик кирәк. Патриотик тәрбия бирүне әхлак, хезмәт, экологик һәм башка тәрбияләрдән аерып карарга ярамый. Алар үзара бәйләнештә бергә үрелеп алып барылса гына, патриотизм һәм гражданлык хисләре тәрбияләүдә уңышка ирешеп була.

Шулай итеп, бүген безнең төп максатыбыз – сәламәт, нәселебезнең, татар халкының дәвамчыларын тәрбияләү. Җирдәге һәр кешегә үз туган авылы, районы, шәһәре аеруча якын. Ул – аның кечкенә ватаны. Анда кеше беренче мәртәбә табигатьнең, аның янәшәсендәге әйберләрнең матурлыгын күрә, тоя. Менә шушы тәэсирләр аша балада туган якка һәрчак турылыклы булып калу, аның байлыгын арттыру, аны матурайту хисе барлыкка килә. Туган якның табигатен яраткан, аның үсешенә һәм чәчәк атуына булышкан кеше генә чын патриот була ала.

**Әдәбият**


1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәпләрдә татар әдәбиятын укыту методикасы: метод. кулланма. − Казан: Мәгариф, 2000.– 185 б.
2. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен педагогикадан уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2019. – 223 б.
3. Белем бирү порталы Патриотик тәрбия бирү | Опыты и эксперименты: | Образовательная социальная сеть (nsportal.ru)(мөрәҗәгать итү вакыты: 18.10.2023)
4. Электрон хрестоматия. Әдәбият. 5-9 нчы сыйныф https://mon.tatarstan.ru/metodicheskie-rekomendatsii-7050209.htm


## БӨЕК МӘГЪРИФӘТЧЕ НӘҖИП ДУМАВИ ИҖАТЫНДА ЯҢА ДУМА АВЫЛЫ ТАРИХЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ


Газизянова И.И.
В.Г.Тимирясов исемендәге беренче номерлы
Аксубай урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Галиева А.А.


Тарих белән әдәбият аерылгысыз. Һәр әдип үзенең иҗатында туган ягының тарихын, географиясен, этнографиясен, яшәеш – булмышын, шәхесләрен чагылдыра. Әйтергә кирәк, әдәби әсәрләрдә элек без белмәгән, ишетмәгән вакыйгалар шактый гына күләмдә калкып чыга. Шул максат белән мин әдәбиятыбызның бик олы шәхесе Нәҗип Думави иҗатында Яңа Дума

авылы тарихының чагылышы турында белешмәләр туплый башладым. Бурычлар: әдипнең әсәрләрен уку, аның әсәрләреннән Яңа Дума авылы тарихына караган материалларны табу.

Нәҗип Думавиның тормыш һәм иҗат юллары галимнәр тарафыннан өйрәнелсә дә, җавап көтүче сораулар әле күп. Галимәбез Резеда Ганиеваның "Нәҗип Думавиның иҗат сәхифәләре" хезмәтендә әдипнең туган ягы белән бәйләнешен күрәбез. Н.Думавиның "Агач аяк" китабына кереш сүз өлешен филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев язган, анда Н.Думавиның тормышында туган ягы нинди зур роль уйнавы ассызыклана. Яңа Дума авылында яшәп иҗат итүче, язучы Рушания Низамова "Сине сагынып сыкрый наратлар" поэмасында Н.Думавиның тормыш юлын сурәтли. Оныгы Г.Тахтамышева "Н.Думавиның автобиографик язмаларыннан" хезмәтендә әдипнең язмышын авыл язмышы белән тыгыз үреп бирә.

Әдипнең әсәрләре үзенчәлекле булулары, авыл тарихындагы вакыйгаларны ачу буенча бүген дә яңалык алып килүе ягыннан бәяләнә. Минемчә, аның әсәрләре – авторның үзен һәм шул заманның рухи тормышын өйрәнүдә, әдәби мохитен аңлауда бәһаләп бетергесез чыганак та. Шуның өчен тема бүген бик актуаль.

Мәгърифәтче, мөгаллим, мулла, язучы, шагыйрь, матбугатчы, җәмәгать эшлеклесе Нәҗип Думавиның исеме аксубайлылар өчен аерым горурлык хисе тудыра. Яраткан язучыбыз, авылдашыбыз турында эш язарга уйлагач та, мин аның аның әсәрләрен: 2003 нче елда чыккан "Агач аяк"китабын, язучының 120 еллыгына багышлап чыгарылган матбугат язмаларын, Рушания Низамованың "Сине сагынып сыкрый наратлар..."ын, Н. Думавиның 1985 нче елда чыккан "Тормыш сәхифәләре"китабын барларга керештек. Н. Думавиның кайсы гына әсәрен кулга алма, анда матурлыкка, азатлыкка омтылыш сизелә.

Иҗат кешесенең тормыш юлы берникадәр(яки тулысынча) дәрәҗәдә булса да аның әсәрләрендә дә чагыла. Н. Думавиның балачагы Яңа Дума авылы белән бәйле. Чыгышы буенча Дума халкы тирә-як авыллардан килеп-китеп эшләүчеләрдән тупланган диярга була. Соңрак алар, шул "новые дома"ларны салып, биредә бөтенләйгә урнашып калгандыр. 1985 елда, Татарстан китап нәшриятында басылган "Тормыш сәхифәләре" җыентыгына кергән "Кем гаепле?"дигән әсәренең ахырында әдип болай дип язып куйган: "1908 нче сәнә. Карьяи Дума –Дума карьясе, Н.Думавиның туган авылы". Тәпи киткән мизгеленнән соңгы сулышына кадәр Дума авылы белән бәйле булуын әйтә автор.

Н. Думави күпне күргән, авыр тормыш юлы үткән. Ләкин күп язган. Аның «Авыл балаларының янгыр теләве», «Янгыр соңында», «Беренче кар» кебек шигырьләре, «Габдулла», «Зәки», «Мортый белән Мукай», «Бер баланың көнлек дәфтәре» исемле хикәяләре күп еллар татар мәктәбенең татар әдәбияты дәреслекләренә һәм хрестоматияләренә кертелә. Укып чыккач та, мондый нәтиҗәгә киләбез: балалар өчен язылган "Агач аяк" китабына төрле елларда язылган хикәяләренең , шигырьләренең үзәгендә кеше бәхете, инсанның мәгърифәтле, аңлы, алдынгы карашлы булырга тиешлеге мәсьәләләре тора, яшәп килүче җәмгыять тәртипләренең намуслы кешегә каршы юнәлдерелгән

булуы нык тәнкыйть ителә. Иҗатында мәгърифәтчелек темасы үзәк урынны алып торганга да бер дә гаҗәпләнәсе юк! Билгеле инде, мәктәп, уку турында язуны ул үз туган Дума мәктәбе турында язудан башлый.Нәҗипнең әтисе Сибгатулла авылда мулла була. (...Мәктәп эчендә миннән тырыш, миннән зиһенле бала юк иде, һәммә дәресләрдә мин алга чыгам, һәммә сабакларны мин белеп килгән була идем... “Агач аяк” китабы “Зәки” әсәре 67бит).

Әсәрләрендә 19 гасыр ахыры – 20 гасыр башы татар тормышы чагылыш тапкан. Н. Думави әсәрләрендә туган авылымның гади кешеләре язмышы, аларны бәхетле итү, социаль тигезлеккә, гаделлеккә ирешү юллары турында уйлану үзәктә тора. 90 яшьлек Кыям бабай сөйләве буенча, авылда бай кешеләр дә булгалаган, тигезсезлек ачык күренеп торган. Гәрәйнең әтисе Фәиз авылның хәлле генә сәүдәгәре. Күп кенә терлек-туар асрый. 40 лап умартасы бар. Зур гына алма бакчасы сузылган. Фәиз абый, һәр җомгадан соң, Сибгатулла мулланы үзенә кунакка алып килгән.(...Менә җеназа күренә башлады.Үлгән кеше, чынлап та, бай кеше иде.Аның җеназасы артыннан урам тулы халык килә, бик күбесе, толыплар киеп, тарантасларга утырганнар иде...)

Н.Думави халыкның күзен наданлык белән томалаганнар диеп саный. (...Ул хурлаучы балалар бай балалары иде. Анлар сумсалар илә чәй эчеп чыкмышлар, тамаклары тук, күңелләре көр, өстләре бөтен иде.Шуның өстенә мәктәп исемле мөхтәрәм бер урынга гыйлем дигән иң мөкатдәс бер нәрсә өйрәнер өчен баралар иде. Әхлак китаплары һәм кыйраәте төркия укыганда, вакытыңызның кадрен белеңез, фәкыйрь вә мескиннәрне рәнҗетмәгез, һәр эштә гакылыңыз яныңызда булсын... “Мортый илә Мукай” 12 бит).

Н. Думави укып кеше булган балалар турында да матур-матур әсәрләр иҗат иткән. Чөнки Нәҗип үзе авылдашлары белән кышкы салкын буранлы көннәрдә мәдрәсә сәндерәсендә кунып та калгалаган. Габдулла, Зәкиләрнең Дума кешеләре икәнен тәгаенләмәсә дә, безнең авылда да прототиплар бар дип гөманларга кирәк. Белемгә омтылучы акыллы кешеләр турында Зәйдуллин Каниф, Хөснуллин Әмирҗан бабайлар күп сөйлиләр. Габдулланың , Зәкинең образларын күрсәтү, чиста күңелләрен чагылдыру аркылы яхшылык, миһербанлылык темасын ачып бирә алган. Әмма никадәр авыр булса да, язучы милләтнең киләчәгенә, мәгърифәтле халыкның чәчәк атуына ышанып яши. Әнә бит Сибгатулла мулла аны ничек тә укытырга тырышкан. Үзеннән соң авылда мулла булып каласын белгән.

Н. Думавиның “Габдулла” әсәре аерым игътибарга лаек.Автор бу әсәре белән нәрсә әйтергә тели соң? Бу әсәрләрдән нинди фикерләр саркып чыга?

Әсәр әхлакый яктан тәрбия бирүне дә күз алдында тота. Хикәядә гади генә хәлләр, авылның гади генә кешеләре сурәтләнә. 96 яшьлек Харис бабай Закиров түбәндәгеләрне сөйли: “Мин 1906нчы елгы.Без аны күбебез күреп беләбез, күбебез анарда укыган.Миңа 16 яшь булганда , авылыбызда өч мәхәллә иде: берсендә - Мортаза бабай – мулла, икенчесендә - Нотфулла бабай, өченчесендә - Зариф бабай мулла, Сөнгат бабай мәэзин иде. Мулла бабайлар безне укыта иделәр, ә мәэзин бабайлар азан әйтә иделәр.Шул муллаларның, мәэзиннәрнең җитәкчесе булып Нәҗип мулла тора иде. Без аны Ахун бабай дип йөртә идек.” Менә шул бик яхшы кешеләрне әсәрләренә прототип итеп керткән

инде ул. Гаделлек турында да, яхшылык турында да, ярлылык – хәерчелек турында да чын дөресен язган Нәҗип Думави.

Н.Думави китапханә ачтыруда, кичке зурларны укыту эшләрен оештыруда җитәкчелек иттем,дип яза. Дума мәктәбен салырга 1913 елны Байтиряков Рәхимбай акча бирде,1916 елны Кармәт авылындагы хатын-кызлар мәктәбе дә Бузулуктагы Нәгыймә исемле бай тол хатын хисабыннан салынды. Тәрбия мәсьәләсе Н. Думави иҗатының үзәген тәшкил итә. Балаларның кичерешләре, психологиясе, өлкәннәргә охшарга тырышу, тизрәк үсәргә омтылыш , шулай ук оста тотып алынган детальләр аша укучыга җиткерелә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, Нәҗип үз иленнән, туган туфрагыннан аерылса да, күп эшләр башкарырга, Ватанына һәм халкына, аның рухи-мәдәни үсешенә күп файда китерә. Думави кебек зур шәхесләр Дума авылы данын еракларга танытты. Дума мәктәбенә Н.Думави исеме бирелә.Мәктәп музеенда аның тормышына һәм иҗатына багышланган экспонатлар күп урын алып тора(Р. Низамова, Р. Гафиятов, укытучылар коллективы, авыл халкы оештыра).Ул экспонатлар авторның әсәрләрендә очраган әйберләр: самовар, сәке, чабата, кием-салым, тула оек, чапкыч,табагач. Аның әсәрләре дә иске татар тормышының төрле якларын ачып бирәләр. Язучының кайсы гына әсәрен алып карасаң да, аларда халыкның үзеннән алынган детальләр, күренешләр, вакыйгалар, гыйбарәләр. Аларда язучының уйланулары, борчылулары, сызланулары, әрнүләре. Аның әсәрләрендә шул чор кешеләренең тормыш-көнкүреше.

**Әдәбият**

1. Ганиева Р.К. Нәҗип Думави // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3 том. XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

2. Ганиева Р.К. Нәҗип Думавиның иҗат сәхифәләре. – Казан: Изд–во «Отечество», 2003.

3. Думави Н. Агач аяк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

## ТОРМЫШЫМДА МӘҢГЕЛЕК ЭЗ КАЛДЫРУЧЫ КЕШЕМ
**(Укытучы-остаз елына багышлыйм)**

Гайнуллина З.Ш.
Алабуга районы Иске Юраш мәктәбе укучысы.
Фәннижитәкче: Гайнетдинова К.Ф.

Илләр, кешеләр язмышында мәңге онытылмаслык вакыйгалар аз түгел. Әнә шундый вакыйгаларның берсе булган Бөек Ватан сугышын, фашист илбасарларына каршы халкыбызның героик көрәшен бөтен Җир шары хәтердән мәңге җуймас. Кешелек тарихына иң күп канкойгыч сугыш булып кергән Бөек Ватан сугышында Җиңү армиябезгә, халкыбызга дан һәм шөһрәт китерә.

Моннан 78 ел элек, халкыбызның нык ихтыяр көченә, югары әхлак сыйфатларына ия, куркусыз булуын бөтен дөньяга танытып, безнең сугышчылар Берлиндагы рейхстаг өстенә Җиңү байрагы кадый. Сугыш...

Нинди авыр, каһәрле, шомлы сүз бу! 27 миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган...

Сугышның утлы мәхшәре Иске Юраш авылы халкының җилкәсенә дә авыр хезмәт, ачы күз яшьләре булып төшә. Җиңүгә 78 ел үтсә дә, сугыш китергән тирән хәсрәт, күңел ярасы үзен сиздерә. ”Әти” сүзен әйтергә тилмереп үскән сабыйлар, ничә еллар буена олы юлдан күзен ала алмый газиз улын, ирен көткән аналар, сөйгән ярларын көткән кызлар һаман да күңелне әрнетә...

Өлкәннәр сөйләвенчә, әсәрләрдән,әдәби фильмнардан күренгәнчә, тылда картлар, балалар колхоз эшен җигелеп тартканнар. Бу авыр елларда авыл язмышы ил язмышына кушылган. Ирләре, уллары, туганнары яу кырында батырлыклар күрсәткәндә, тылдагы хатын-кызларыбыз үзләрен аямыйча эшләгәннәр дә эшләгәннәр.

Алар арасында минем әбием **Фәйрүзәнең** әнисе дә булган. Без-аларның оныклары, әби-бабаларыбызның тормыш юлы белән якыннан танышырга, аларның кылган изге эш-гамәлләрен тарих битләренә кертеп калдырырга тиеш. Бу–безнең изге бурыч.

1940-41нче елларны карт әбием гаиләсе - Әхмәтовлар Свердловск шәһәрендә үткәрә. Әтиләре Арыслан монда акча эшләп алырга ниятли, күрәсең. Сугыш башлангач, гаилә башлыгы Ватанны сакларга китә, гаиләсе исә кире Юрашка кайта. Бу вакытта әбием (этиемнең әнисе) унике яшьлек үсмер була.

Әхмәтова Фәйрүзә Арыслан кызы (әбием), 1929 елның 15нче мартында беренче бала булып дөньяга килә. Аның әти-әнисе, Арыслангали Әхмәт улы һәм Мәчтүрә Сафа кызы, ишле гаилә булу турында хыялланалар. Өйгә нур өстәп, бер-бер артлы Нургаян, Мирзаян, Хәләмгөл, Мансур туалар. Фәйрүзәгә (әбиемә), иң олы бала буларак, сеңел-энеләрен тәрбияләү вазифасы йөкләнә. “Сугыш вакытында тормыш бик авыр булды. Өйне салам ягып җылыта идек. Саламның күпме генә җылысы чыга инде, тәрәзәләр һәрчак боз белән капланган. Бераз үскәч, без, балалар, бәләкәй арба тартып, урманга утынга йөрдек. Утын дигәне дә инде сынып төшкән ботак-сатаклар. Ул елларда утынга дип зур агачларны кисәргә рөхсәт юк. Өстә киндер күлмәк, аякта чабата. Бишмәтнең дә тышы киндер. Бала-чагаларның кайберләре, өсләренә кием булмау сәбәпле, мәктәпкә укырга йөри алмыйча, мич башында җылынып утыралар иде. Миңа, үземә, шәхсән, Юрашның җиде еллык мәктәбендә укырга насыйп булды.

Җиде еллык мәктәпне бетергәч, күрше Морт авылының урта мәктәбенә йөри башладым. Карлы су вакытында күтәртмәле чабата кия идек, чабата астына ике агач шакмак беркетелә. Ләкин барыбер, су аның эченә керә дә, чыгып та китә иде. Ничек авырмаганбыздыр, бик чыныккан балалар булганбыз инде, күрәсең.”- дип искә ала торган иде әбием мәрхүмә.

Менә шундый авыр вакытларда да дәү әбием югалып калмый. Суда батмый, утта янмый торган кыз була ул. Урта мәктәп белән генә чикләнеп калмый, Алабугадагы «Учительская школа»га укырга керә.

Әбием турында язганда, Ф. Яруллин сүзләре искә төшә: “Язмыш синең тез астыңа китереп сукса – егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса – үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа – күбек

булып өскә күтәрелмә, асылташ булып төпкә бат, ялтыравыңны күреп, чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә – яңгыр тамчыларына кушылып җиреңә төш. Карурманнарда адаштырса – кояшка карап юл сайла. Ташлар белән бастырса – чишмәгә әверелеп ургы. Җиргә күмсә – орлык шикелле тишелеп чык. Җилкәнеңне җилләр екса – йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземнәр генә бәхеткә лаек.” Әйтерсең, бу юллар әбием хакында язылган. Көчле рухлы, сабыр, түзем, нык ихтыяр көченә ия булган ул кече яшьтән үк. Әйе, көчле рухлылар гына максатларына ирешә, түземнәр генә бәхеткә лаек.

Сугыштан соң, 1950 нче елның 15 августында Морт РОНОсы яшь укытучыны, Шүрнәк авылына география укытырга билгели. Солдат кебек, укытучы да көрәшче, ул яшь буынны чын кеше итеп тәрбияләү өчен көрәшә. Геройларның сугышчан үткәне хезмәтләрендә генә түгел, шәхси тормышларында да, мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләрендә дә чагыла. Алар һәркайда гадел һәм принципиаль булырга тырышалар. Балалар күңеленә ачкычны бары тик намуслы кешеләр генә таба ала, ди әтием. Шундыйлардан була аның әнисе.

Укытучы ул- баласына белемне тиеш дәрәҗәдә бирә алмаганы өчен, төннәрен йокламаучы, аның тәртипсезлеге өчен көенүче, шуны кеше итүдә үз өлешен күреп сөенүче. Ул чорда укытучы кеше баланың гына түгел, авылның да тәрбиячесе булган.

Сугыштан соңгы елларда мөгаллимнәргә кытлык булганлыктан, андый белгечлеге булмаса да, немец теле дә укытырга туры килә аңарга Юраш мәктәбендә. Фәйрүзә әбием булганына шөкер итеп утыручылардан булмаган. Алынган белемнәре белән генә канәгатьләнмичә, ул 1965 енче елда, 15 ел укытканнан соң, КГПИның биология факультетын читтән торып тәмамлый һәм биолог белгечлеге буенча диплом ала. Биология, химия фәннәре укыта башлый.

Аның тормыш юлында үзенә тиң яр да табыла. Миңнемулла улы Габделбарый -бабам белән тормыш корып җибәрәләр. Алар биш бала тәрбияләп үстерәләр. Олы кызлары Роза апа Казан медицина институтын тәмамлый. Бүгенге көндә Чаллы шәһәре санэпидемстанциясендә эшли, икенче уллары- Наил, өченче уллары Камил абыйлар автокрановчик булып эшлиләр. Дүртенче балалары Флёра Габделбариевна, Казан пединститутының химия биология факультетын тәмамлап, бүгенге көндә Тукай районы Иштирәк авылы мәктәбендә химия, биология фәннәре укыта. Бишенче уллары Шамил- минем әтием, Казан дәүләт Ветеринария институтын тәмамлап, бүгенге көндә Иске Юраш авылында төп йортта яшәп, Алабуга ветеринария оешмасында участок ветеринар табибы булып эшли. Әйе, мөмкин булганча, югары белем бирергә тырышалар алар балаларына. Һәммәсе тормышта үз сукмагын, үз юлын тапкан, үз оясын корган, балалар үстергән, олы тормыш юлына озаткан. Димәк, нәсел җепләре тиешле юнәлешен алган. Бүгенге көндә ике апам да шул юнәлештә. Олы апам Айгөл әбием кебек укытучы, ә Гөлия апам Казан дәүләт медицина университетының медицина-профилактика факультетының 5-курсында укый. Мин апаларым белән горурланам.Мин дә әбием йөзенә кызыллык китермәм, дип ышандырасым килә.

Әбием мәктәптә таләпчәнлеге, усаллыгы, төгәллеге белән аерылып торган. Гадел усал, чамадан тыш белемле булган ул. Шулай булуга карамастан, укучылары аны нык хөрмәт иткәннәр, яратканнар. Күбесе шул юнәлештәге ВУЗларга юл алган. Әйе, без, укучыларның киләчәге, язмышы укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә. Ә андый алтын йөрәкле кешеләр безнең мәктәбебездә шактый булган.

Әбиемнең хезмәтен укучылар гына түгел, югары даирәләр дә вакытында тиешенчә бәялиләр. Күпләгән мактау кәгазьләре, исемнәре, шул исәптән «Отличник народного просвещения» (1965, 31 декабрь), « За доблестный труд» медальләре. (1966, 1 ноябрь). 41 яшендә төпчеге Шамилне-әтиемне – бишенче баланы табып, 1972 нче елның 5 сентябрендә «Медаль материнства» медале белән бүләкләнә ул. 1979 нчы елда пенсиягә чыга. Озак еллар бер гаилә булып дус-тату яшәдек. Кызганыч: кеше бу фани дөньяга мәңгелеккә килми. Әбием, безне калдырып, бакыйлыкка, мәңгелеккә китеп барды.

Мин фәнни-эзләнү эшемне дәвам итеп, әбием укыткан укучылар белән очраштым, алар белән кызыклы әңгәмәләр кордым. Аларны укучыга да ирештерәсем килә. Шул чорда эшләгән хезмәттәшләре исеменнән Наилә Муллаәхмәт кызы: “Безнең мәктәптә Фәлән Фәләнович дип түгел, якын итеп, апа һәм абый диеп әйтү кабул ителгән иде.Без Юраш мәктәбенә эшкә килгәндә, химия, биология фәннәреннән белем бирүче синең әбиен-Фәйрүзә апа иде, үз эшенең остасы, бик тырыш укытучы буларак танылган иде инде ул вакытта ук.

Үзенә һәм башкаларга нык таләпчән булган Фәйрүзә апа эшләгән дәвердә бик күп яшь укытучыларга методик ярдәм күрсәтте. Аның эшчәнлеге авыр елларга туры килде, 600дән артык бала белем алган мәктәп, утын белән җылытыла торган тузган 13 бинага урнашкан иде. Укучы балаларның 125е, күрше авыллардан килеп, мәктәп яны интернатында яшәп укыды.

Гаиләсендә без аны үрнәк хуҗабикә буларак белә идек. Мәрхүмәнең якты истәлеге безнең күңелләрдә яши һәм яшәячәк. Урыны оҗмахта булсын!”

Тагын бер укучысы Суфия Рифкатовна Хөсәенованың да әбием турындагы җылы сүзләре мине бик нык дулкынландырды. “Көчле характерлы, гаиләсе өчен утка-суга керергә әзер булган, кулыннан бар эш килгән уңган ханым иде. Кул эшләре- тегү, бәйләү, чигү кебек һөнәрләрдә аны уздыручылар булдымы икән? Юктыр. Юраш авылы халкын кыяр утыртып үстерергә дә ул өйрәтте. Минем өчен ул бик хөрмәтле, яраткан укытучым иде. Бүгенге көндә бер көн дә догамнан калдырмыйм.”- дип, искә алды үз остазын.

Менә шундый искиткеч җылы сүзләр ишеттем мин әбием турында. Аның укучылары инде үзләре бүгенге көндә - яулыклы әбиләр. Барчасы да лаеклы ялда. Аларның да өчесе укытучылык һөнәрен сайлаган, гомерләре 36-37 ел Юраш мәктәбендә балаларга белем биргәннәр. Бәлкем, аларның һөнәр сайлавында әбиемнең дә өлеше бардыр. Мин әбием белән горурланам.

Әйе, һәр туган яңа көн, бүгенге бәхетле тормышыбыз өчен без иң элек гүзәл тормышларын биргән каһарманнарга, сугыштан исән-сау кайтып хезмәт иткән батырларыбызга, сугыш вакытында тылда әбием кебек көч куйган ватандашларыбызга мәңге бурычлы. Алар алдында баш исәк тә, чәчәкләр бүләк итсәк тә, алтыннан һәйкәл куйсак та аз булыр кебек. Исәннәрнең кадерен,

бакыйлыкка күчкәннәренең каберен белик!

Быел Укытучы-остаз елы буларак, язмамны бөек педагог Ян Амос Коменский сүзләре белән тәмамлыйсым килә: “Бу дөньяда укытучы хезмәтеннән дә өстен нәрсә юк”. Бөек педагогның бу фикере белән белән мин тулысынча килешәм, ул хаклы. Сабырлык, тырышлык, белем таләп итә торган һөнәр - укытучы хезмәте икәненә мин инандым. Укытучы биргән белем безгә, кошларга канат ничек кирәк булса, шулай кирәк. Аларның хезмәте авыр, катлаулы, җәмгыятькә күп файда китерә. Мин үземне укыта торган укытучыларыма да мең рәхмәтле!

Әдәбият

1. Әби-бабайлар, ветераннарның якыннары белән очрашып сөйләшүдән туган фикерләр.
2. Газета, музей материаллары.
3. “Халык хәтере” сайты.

## ФӘРИДӘ НУРГАЛИЕВНА – МӨГӘЛЛИМӘ, ОСТАЗ ҺӘМ ШАГЫЙРӘ

Галиев С.А.
Алабуга шәһәренең 8 нче урта мәктәп укучысы.
Фәнни җитәкче: Нотфуллина С.Х.

Мин бу хезмәтемне бүгенге Г.Тукайның дәвамчысы булган шагыйрәбез Фәридә Нургали кызы Хәбибрахмановага багышладым. 2023 нче ел – Остазлар һәм укытучылар елы. Фәридә Нургали кызының тамырлары Г. Тукай нәселенә барып тоташа.

Тукай аһәңнәре, аның моңы бүген дә яши. Тукай рухы - буыннардан – буыннарга күчә, яңа иҗади көчләргә илһам бирә. Туган ягым шагыйрәсе, мөгаллимәсе Фәридә Нургали кызы да шушы көчләргә ия.

«Табигать» темасына багышланган шигырьләрне: «Туган ягым - күңел назым», «Табигать гүзәллеге», «Сайра, сандугач», «Тәкыя», «Куш агач», «Көзге моңлану», «Сары камыш», «Хәерле кич телим», «Соңгы кар», «Күңел гаме».

«Табигать гүзәллеге» исемле шигыре – шагыйрәнең хисләрен тасвирлый, Табигатьтәге бар нәрсә аны уйландыра.

Тәүлекнең төнгә авышкан сихри вакытында барган вакыйгалар тасвирлана анда: тал – тирәкләр тирбәлә. Бу гади генә тирбәлү түгел, ә уйга чумган талларның бер халәте. Сандугачлар сайрамый, күктә ай тулган. Күз алдына авыл җиренең билгеле бер урыны – су буйлары килеп баса. Яр читендә ялгыз каен. Аның да моңайган вакыты. Каенны аңлап була: ул ялгыз, шуңа моңая. Гүя, үткән гомерен уйлый. Шул үткәннәр аны моңаерга мәҗбүр итә.

«Сайра, сандугач» шигырендә язгы таң, гөлләр чәчәккә бөреләнгән, чык төшкән. Шул вакытта бакчада сандугач сайрый. Сандугач та шушы чәчәк аткан гөлләрдән илһам җыя. Чәчәкләрнең чәчкәдә вакыты кыска булган кебек, сандугач та июль уртасында сайравыннан туктый. Лирик герой сандугачны җәй буена сайрарга чакыра, чөнки сандугач моңы югалган, табигать бик матур бер

вакытын югалта. Тынлык ятимлек белән чагыштырыла. Шагыйрә җаны өчен ялгызлык – кеше гомерендәге авыр бер халәт. Ятимлек чоры һәр кешене сагалый сыман. Ләкин кешеләр генә моны соңарып аңлый һәм үз җаны аша уздыра башлый.

«Хәерле кич телим» дип башланган шигырендә кеше күңеленә туган җирнең җылысын, чишмәләрнең челтерәве, йолдызларның җемелдәвен, кояшның җылы нурын, сайрар кошларның моңын тели һәр кешегә. Боларның барсы өчен без иң беренче үзенә барсын сыендырган туган җиребезгә рәхмәтле булырга тиешбез. Туган җирне ата – ана белән чагыштыра һәм аның кешегә бер генә бирелүен төшендерә.

Шагыйрә өчен табигать кеше сыман. Андагы бар нәрсә, күренеш шагыйрә өчен газиз, кадерле. Үз күңеле кебек чисталыкны табигатьтәге һәр нәрсәдә күрә белә.

Фәридә Нургали кызы Хәбибрахманова иҗатында табигать үзгә бер урын бизи. Ул тере җан, гүя, кешеләр кебек барсын тоя, барсын үз җаны аша үткәрә һәм үзендә барган тискәре күренешләр өчен борчыла да.

Табигать үзендә яшәүче затларга терәк тә, таяныч та, ышаныч та. Шагыйрә табигатьне тоеп, аннан яшәү өчен илһам алып иҗат итә.

Шагыйрә, мөгаллимә буларак, һәр шигырендә кеше күңелендә туган хисләрне, табигать мизгелләре, фасыллары аша яктырта. Уйланырлык нәрсә дә бар : безне ничек тәрбиялиләр дә, без шулай яшәп китәбез. Күңел байлыгын кечкенәдән сине чорнап алган тирәлек, табигать һәм аның фасыллары да тәрбияли.

## ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Галимбекова Ф. Ф.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева.Р.Б.

Соңгы елларда илдә барган социаль –сәяси үзгәрешләр халыкның милли үзаңын уятуга китерә. Ул, беренче чиратта, милли традицияләрне торгызуга, туган телне һәм мәдәниятне торгызуга һәм саклауга ярдәм итүче милли мәктәпләр булдыру таләпләрендә чагыла.Татар теле һәм әдәбиятының заманча дәресе нинди булырга тиеш? Бу мәсьәлә барлык татар теле укытучылары өчен дә актуаль, аларны мәгарифне модернизацияләү проблемасы борчый.Хәзерге киләчәк буыннын балаларының сүзлек запаслары бик аз, алар сирәк кенә туган телебездә сөйләшәләр, кайбер татар гайләләре дә үзара гайлә эчендә туган телләрен кулланмыйлар. Бу кешеләр туган телне саклау әһәмиятен аңламыйлар. Татар телен укытуга заманча карашлар, беренче чиратта, укытучының ролен үзгәртү белән бәйле. Хәзерге шартларда укытучының укучыларга әзер белем бирүе түгел, ә белем алуга юл күрсәтүе, белем алырга өйрәтүе бик мөһим.

Ф.Ф.Харисов хезмәтеләрендә “технология”, “педагогик технология”, “белем бирү технологиясе” терминнары турында киң язылган. Бу терминнарны татар телен чит тел буларак укытканда да кулланып була, һәм ул мондый

яссылыкта беренче тапкыр тәкъдим ителә. [Харисов 2011: 34] Инновацион технологиянең төп максаты укучының белем алу эшчәнлеген активлаштыруны күздә тоту.

Мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укыту процессы белем бирү характерында гына түгел, ә уңышлы шәхес тәрбияләүгә дә юнәлдерелгән. Минем фикеремчә, стандарт булмаган карарлар кабул итә алырлык иҗади шәхес формалаштырырга тырышырга кирәк.Белем һәм күнекмәләр укучылар тарафыннан катгый эзлеклелектә, әкренләп, авырлык һәм катлаулылык тәртибендә, укучының баскычлар буенча күтәрелүе белән үзләштерелсә, уку уңышлы булачак. Һәр яңа дәрес алдагы дәресләргә нигезләнергә тиеш. Баланың сүз запасын арттыру өчен һәм туган теленә мәхәббәт хисе уяту өчен, дәрестә актив эшчәнлек төрләрен кулланырга кирәк. мәсәлән, татар халык әкиятләрен тыңлау, татар спектакльләрен карау, халык уеннарын уйнау һәм укучылар үткән материалны яңгырату. Сәнгать әсәрләре өстендә эшләргә аерым әһәмият бирергә кирәк. Сәнгать текстларын анализлаганда үз-үзеңне өйрәтү бара, ә бу шәхеснең сөйләм теле формалашуына китерә. Шуңа күрә коммуникатив төркем ысулына өстенлек бирергә кирәк. Төркем составы төрле дәрәҗәдәге белем һәм иҗади мөмкинлекләре булган 5-6 кеше. Балаларга эшнең төрле формаларын тәкъдим итү мөһим: фикер алышулар, рольле уеннар, текстны анализлау, укучы кечкенә генә булса да, иҗади эш башкарганда ул үз-үзенә ышана башлый.

Уен, хезмәт һәм гыйлем белән беррәттән, кеше эшчәнлегенең төп төрләренең берсе. Уенны өйрәтү ысулы буларак, өлкән буын тәҗрибәсен кечеләргә тапшыру өчен кешеләр борынгыдан ук кулланганнар. Уен халык педагогикасында, мәктәпкәчә һәм мәктәптән тыш учреждениеләрдә киң кулланыла. Гомумән, уеннардан аермалы буларак, педагогик уенның мөһим билгесе бар – укытуның ачык куелган максаты һәм аңа туры килгән педагогик нәтиҗәсе ачык рәвештә аерып куела һәм укутанып белү юнәлеше белән характерлана ала.

Дәресләрнең уен формасы дәресләрдә уен алымнары һәм ситуацияләре ярдәмендә барлыкка килә, алар укучыларны уку эшчәнлегенә этәрү, стимуллаштыру чарасы буларак эш итә.

Татар теле дәресләрендә уен технологиясе укучыны дәртләндерә торган метод булып тора. Г.К.Селевко, максатчан юнәлеш буенча,

– дидактик (белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген киңәйтү, белем һәм күнекмәләрне гамәли эшчәнлектә куллану һ.б.),

– тәрбияви (мөстәкыйльлек тәрбияләү, билгеле бер юнәлешләр, дөньяга караш тәрбияләү һ.б.),

– үстерелешле (игътибар, хәтер, сөйләм, фикерләүне, уку эшчәнлеген үстерү һ.б.),

– социальләштерүче (аралашуга өйрәтү һ.б.) уеннарны аера [Селевко 2005: 125]

Дөньяның теләсә кайсы телен өйрәнгәндә кеше аның коммуникатив эшчәнлеген өйрәнергә тырыша. Компьютер яңа техник чара буларак татар телен чит тел буларак укытуның барлык өлкәләренә актив кертелә башлый, үз функцияләрен максатларына, бурычларына, укыту этабына һ.б. бәйле рәвештә

үзгәртә. Татар теле дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне кулланунының нәтиҗәлелеге уңышлы.

Компьютер технологияләрен үзләштерү уку процессын чын мәгънәсендә индивидуальләштерергә, аны укучыга карата гуманлырак итәргә, укуның уңай мотивациясен көчәйтергә, танып белү эшчәнлеген активлаштырырга, укучының да, укытучының да эшенең иҗади составын көчәйтергә мөмкинлек бирә. Традицион белем бирү мәсьәләләрен хәл итү өчен дәрестә текст редакторларын, мультимедия презентациясе системаларын, электрон дәреслекләрне, дистанцион укыту системаларын һәм интернетны кулланырга кирәк.

Укытуның коммуникатив формасын кулланганда укытучының төп рольне үтәми, ул бары тик уку-тәрбия процессын көйли һәм аны гомуми оештыру белән шөгыльләнә, гомуми юнәлешне билгели. Укытучы алдан кирәкле биремнәр әзерли һәм төркемнәрдә фикер алышу өчен сораулар яки темалар төзи, билгеләнгән эш планын үтәү вакытын һәм тәртибен контрольдә тота, консультацияләр бирә, катлаулы терминнарны аңлата һәм җитди кыенлыклар булганда ярдәм итә. Шул ук вакытта укучыларда өстәмә мәгълүмат чыганаклары китаплар, сүзлекләр, энциклопедияләр, законнар җыентыклары, Интернет программалары барлыкка килә. Аларга шулай ук үзләренең һәм иптәшләренең тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итәргә, шул ук вакытта бер- берсе белән аралашырга, куелган бурычларны бергәләп хәл итәргә, конфликтларны җиңәргә, уртак элемтә нокталарын табарга, ә кирәк булганда компромисска барырга кирәк. Шул ук вакытта төркем эшенә аның барлык әгъзалары җәлеп ителүе, инициативаны басу яки бер яки берничә лидерга җаваплылык йөкләү булмавы мөһим. Шулай ук интерактив методикалар өчен төркемнәр биремнәре арасында үзара бәйлелек булу мөһим, ә аларның эш нәтиҗәләре бер-берсен тулыландыра. Яшүсмерләр ешрак бер-берсе белән элемтәгә керә, ә өлкәннәр уңай нәтиҗәләргә ирешү өчен аларның тырышлыкларына юнәлешбирү турында кайгыртырга, консультация бирергә һәм рефлексияне оештыруда ярдәм итәргә тиеш.

### Әдәбият


1. Харисов Ф.Ф,Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы .–Казан : Ак Бүре, 2018. –445 с
2. Селевко Г.К, Энциклопедия образовательных технологий. В 2-х т. Т.1. – М.: Народное образование,2005.


## ӘДӘБИ ТӨР БУЛАРАК ДРАМА


Галишина И.Л.

КФУның Алабуга институты студенты.

Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Драма – эпос һәм лирика белән беррәттән матур әдәбиятның бер төре (драматургия), бердәм хәрәкәт тәшкил иткән вакыйга-күренешләр тормышчан конфликт аша диалог һәм монологларда ачыла торган сәхнә әсәре [Әдәбият

белеме 2007: 52]. Драма бер үк вакытта ике сәнгать төренә – әдәбиятка һәм театрга карый. Эпос һәм лирикадан ул, текстның персонажлар репликалары һәм автор ремаркалары кыяфәтендә бирелү белән аерылып тора һәм, кагыйдә буларак, пәрдә, күренешләргә бүленә. Драмада автор сөйләме минималь күләмдә, ул башлыча, әсәрдә катнашучыларны атаганда, аларга кыскача характеристика биргәндә, күренеш барган урын һәм вакытны билгеләүдә, пәрдә, күренеш башында сәхнә обстановкасын тасвирлауда, геройларның аерым репликаларына шәрехләгәндә, аларның хәрәкәтләрен, ым-ишарәләрен, мимика-интонациясен хәбәр иткәндә яңгырый. Эпос белән чагыштырганда драма тел-сурәтләү чараларын куллану ягыннан чикләнгән. Бит драма әсәрен язганда автор сөйләмендә метафора, чагыштыру, аллитерация, җыеп кына әйткәндә, троплар куллану мөмкин түгел. Драмада вакыйгалар эчке уй-фикерләр аша түгел, ә тышкы эш-гамәлләр аша күрсәтелә. Шулай ук, әсәр күләменә дә билгеле бер чик салына, чөнки ул сәхнәдә билгеле бер вакыт аралыгында (максимум өч-дүрт сәгать) тәкъдим ителергә тиеш. Шуны да әйтергә кирәк: драма борынгы чорлардан ук төрле халыкларның фольклорында һәм әдәбиятында яшәп килгән. Антик греклар, борынгы индеецлар, кытайлар, японнар, Америка индеецлары һ.б.лар үзләренең драматик традицияләрен булдырган. Әлеге әдәби төр үз эчендә “трагедия, комедия һәм драма кебек жанрларга бүленә” [Татар әдәбияты 2006: 47-49]. Аларның һәрберсен кыскача характерлап үтик.

Трагедия – сәхнәдә кую өчен языла торган, сюжеты персонажларны һәлакәткә, кагыйдә буларак үлемгә илтүче әдәби әсәр. Трагедиянең конфликты, нигездә, бик тирән, гомумкешелек мәгънәсенә ия һәм символик. Төп герой, башлыча, газап чигүгә дучар ителә (шул җөмләдән, чарасызлыктан), аның язмышы бәхетсез. Трагедия тексты еш кына пафос белән тулган, ул патетик яңгырый [Әдәбият белеме 2007: 188]. Күп кенә трагедияләр шигъри формада иҗат ителә. Татар әдәбиятыннан моңа мисал буларак Фәтхи Бурнашның “Таһир – Зөһрә” (1917 – 1918), Һади Такташның “Җир уллары трагедиясе” (1921), Кәрим Тинчуринның “Зар” (1922 – 1923), Сәет Шәкүровның “Зөһрә йолдыз” (1968), Әхсән Баянның “Алтын кашбау” (1980 – 1986) һәм “Каракош” (1989 – 1991), Гәрәй Рәхимнең “Аяз көнне яшен” (1983 – 1985), Илдар Юзеевның “Соңгы төн” (1968 – 1972), “Очты дөнья читлегеннән” (1980 – 1991), “Мәңгелек белән очрашу” (1982), “Бәгырь” (1995 – 2001) һәм “Ахырзаман гашыйклары” (2003) трагедияләрен атап үтәргә мөмкин.

Комедиягә килгәндә, аны җентекләп тикшергән һәм шушы темага монографик пландагы хезмәтләр язган Әнүр Исмәгыйлев комедия төшенчәсен болай аңлый: “комедия тискәре күренешне диалоглар формасында фаш итүче драматургик әсәр дигәнне аңлата” [Исмәгыйлев 2011: 229]. Галимнең әлеге аңлатмасы комедиянең тар мәгънәдәге билгеләмәсе булып тора. Киң мәгънәдә комедия ул – “көлкеле хәл һәм күренешләргә нигезләнгән драма әсәре” [Җәләлиева 2005: 106]; трагедиянең антиподы. Комедиядә характерлар, ситуация һәм эш-гамәлләр юмор һәм сатира алымнарын кулланып бәян ителә. Гадәттә, комедия җәмгыятьтәге һәм көнкүрештәге кимчелекләрдән көлә. Ә.И. Исмәгыйлев искәртүенчә, “комедияләр атасы Аристофан,

комедиографлардан Мекандр, Плавт, Теренцийлар; Лопе де Вега, Шекспир, Мольер, Карло Гоцци, Гольдони, Тирсо де Молинолар; Фонвизин, Гоголь, Салтыков-Щедрин, Сухово-Кобылин, Маяковскийлар; Тукайлар, Галиәсгар Камаллар... Саный китсәң, байтак исемнәр, аларның зиһен иңләп бетерә алмаслык иҗат җимешләре, ул иҗатта күз күреме җитмәслек тормыш мәйданы, исәпсез-сансыз вакыйгалар, кешеләр, хәлләр, язмышлар... Саналганнары – комедиография күгендә балкып янган йолдызлар, комедияләр иҗат итүдә иң югары осталыкка ирешкән бөек остазлар, сатира-юмор тарихында чорларны чорларга бәйләгән таулар, гасырларны гасырларга тоташтырган тау түбәләре” [Исмәгыйлев 2005: 54].

Драма – кешеләр арасындагы яки кеше һәм җәмгыять арасындагы җитди конфликтны тасвирлый торган әдәби әсәр. Мондый әсәрдә геройлар (геройлар һәм җәмгыять) арасындагы мөнәсәбәтләр драматизм белән тулы. Сюжет дәвамында һәм дә аерым персонажлар эчендә, һәм дә персонажлар арасында киеренке көрәш бара. Гәрчә, драмада конфликт җитди булуга да карамастан, ул хәл ителергә мөмкин. Әсәрдәге инстрига да шушы шарт белән аңлатыла: герой (геройлар) килеп туган ситуациядән чыга алырмы яки юкмы. Драмага реаль көндәлек тормышны тасвирлау, кешелек яшәешенең “фани” мәсьәләләрен күтәрү, персонажларның эчке дөньясын, характерын тирән итеп ачып бирү хас.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз: әдәби төр буларак драма сәхнәдә кую өчен диалог формасында иҗат ителә торган әсәр. Ул үз эченә трагедия, комедия, драма кебек жанрларны ала.

Әдәбият


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Җәләлиева М.Ш. Әдәбиятта тойгы катламнары: Укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.
3. Исмәгыйлев Ә.И. Комедиянең жанр үзенчәлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 302 б.
4. Исмәгыйлев Ә.И. Сәнгать һәм жанр. – Казан: Сүз, 2011. – 360 б.
5. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. – Тулы. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.


## ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА ИҖАТЫНДА МИЛЛИ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР


Ганиева К.А.
Г.Тукай исеендәге Арча педагогия көллияте студенты.
Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.


Һәр халык өчен үзенең йолалары, гореф-гадәтләре якын. Элек-электән бабайларыбыз аларны буыннан-буынга тапшырып, саклап калырга омтылган.

Тормыш-көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала.

Халык бәйрәмнәре, йолалары кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Милли йолаларыбыз, бәйрәмнәребез милли хисләр формалашуда, милли горурлык тәрбияләүдә әһәмиятле урын тоталар.

Бәхеткә, нинди генә авыр еллар аркылы үтәргә туры килсә дә, минем халкымның да гадәт-йолалары безнең көннәргә хәтле килеп җитә алган.

Милли йола һәм бәйрәмнәрнең рухы безнең әдәбиятыбызда зур урын алып тора. Әдипләребез үз иҗатларында әлеге тема кызыл җеп булып сузылып килә. Шундый әдипләребезнең берсе – Эльмира апа Шәрифуллина. Аның иҗатында без гаиләдәге гореф-гадәтләр, халык бәйрәмнәре, йола, милли рух чагылышларын күрә алабыз.

Милли рух сурәтләүне Э. Шәрифуллина иҗатында берничә юнәлештә карап була. Күзәтүебезне шагыйрәнең “Мәхәббәтнең җиде төсе” китабындагы “Миһербан” чишмәсеннән башлап китик.

Кешелек дөньясына яңа гына бала тудырган Ана кичерешләре белән башланып китә язма. Бәби туу белән үтәлә торган иң беренче йола – аның кендеген кисү. Хәзерге заманда бала шифаханәләрдә туа. Ә бит борынгы заманнардан алып, узган гасырның илленче елларына кадәр авыл җирлегендә бала гап-гади өй шартларында туган. Яңа туган сабыйны бисмиллалы Кендек әбисе кабул итеп ала торган була. Шул заманнарны барлый шагыйрә. Үзенең өч туганының Кендек әбисе булган Шәмсенур әбекәйгә мәдхия җырлый ул:

...Бәби тоткан кендек әбекәем
Ераклашкан саен – янәшә.
Кендекләрне кистең,
Җиргә тектең –
Истәлеккә күчеп, мең яшә![Шәрифуллина 2007: 185]

“Сөюемнән мин бер чибәр идем...” шигырь җыентыгында бала тугач үткәрелә торган икенче йола – бәби мунчасы турында яза шагыйрә. Монда инде Кендек әби инде икенче мөһим бурычны башкара: баланың кендеген кисеп, аны туган җире белән бәйләгәч, ул шул нәнине дөньяга китергән анага кадер-хөрмәт күрсәтә.

Соңгы юлларында бәби мунчасының никадәр һәм ни өчен зур игътибарга лаек икәнен күрәбез:

Мунча кертәләр әбиләр,
Укыйлар теләк-дога.
Шуңадырмы авыллардан
Рәхимле җаннар чыга [Шәрифуллина 2005: 344].

Бу соңгы юлларга никадәр эчке мәгънә салынган! Нәни бала кендек әби кулына килеп керү белән дога сүзләрен ишетә башлый. Кендек әбисе аны чынбарлыкның физик һәм рухи бәла-казаларыннан саклый. Чыннан да, бала

тугач, әгәр бүтән ашыгыч эше булмаса, Кендек әбиләр ана белән бала янынннан китмәгәннәр, аларны саклаганнар. Бәлки бүгенге тормышта кешеләр арасындагы салкынлык, кырыслык, бер-береңнән читләшү, рәхимсезлек кебек хис-тойгылар – тугач та анасыннан аерып алып, биләүгә төреп, аннан читкә, икенче бер бүлмәгә илтеп салуның нәтиҗәседер. Минемчә, шагыйрәнең фикере шуңа кайтып кала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: бала чактан канына сеңгән, күңеленә үтеп кергән милли йолалар шагыйрә иҗатында балачак хәтирәләре булып кына түгел, ә яшәү яме буларак чагылыш таба. Ул аларны эчке горурлык, аларның хәзер дә халык күңелендә онытылмыйча сакланып килүенә куаныч белән, милли сыйфатларын тирән ачып сурәтли.

Эльмира Шәрифуллинаиҗаты турында Рәдиф Гаташ болай дип яза: “Э.Шәрифуллина шигырьләрен башкалар белән бутый алмыйсың: чәчрәп торган хатын-кыз авазы; балаларны, милли гаиләне, әхлак-матурлыкны яклап чаң сугу; камиллеккә, яшәүгә өндәү, иманга чакыру аларда...”.

Моның шулай икәнлегенә без җыентыктагы шигырьләре белән танышып чыккач инандык.

Эльмира Шәрифуллина – үз иҗаты белән киләчәк буынга милли бизәкләребезне, гореф-гадәтләребезне, гомумән, милли рухыбызны илтеп җиткерүне максат итеп куйган милләтпәрвәр шагыйрә ул. Шагыйрәнең үз сүзләре белән әйткәндә, “Кылган эшем җирне сафландырсын, Бер тамчысы булып диңгезнең...” (“Илгә кайтсын” шигыреннән өзек).

**Әдәбият**

1. Шәрифуллина Э. Мәхәббәтнең җиде төсе: повестьлар, эсселар, хикәяләр. – Казан: 2007. – 255 б.
2. Шәрифуллина Э. Зәңгәр эңгер: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 112 б.
3. Шәрифуллина Э. Сөюемнән мин бер чибәр идем... Шигырьләр, поэмалар. – Казан: 2005. – 528 б.

## ИНТЕГРАЛЬ ДӘРЕСЛӘРНЕ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ МЕТОДИКАСЫ (ҖИДЕНЧЕ СЫЙНЫФТА “ЯРДӘМЧЕ ФИГЫЛЬЛӘР” БҮЛЕГЕН ӨЙРӘНҮ МИСАЛЫНДА)

Гарифулина Т.Р.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Хәзерге вакытта уку-укыту процессында интегральлеккә ирешү – заман таләбе. Дөрес, еш кына мөгаллимнәр дәресләрдә башка фәннәр белән предметара бәйләнеш тудыруга омтылалар, әмма интеграль дәрес белән предметара бәйләнеш элементлары булган дәресне тиңдәш төшенчәләр итеп тану дөрес булмас иде. Галим М.М. Шлапакова әйткәнчә, биредә “бөтен – өлеш” схемасы буенча бара [Шлапакова 2010]. Предметара элемтәләрне

гамәлгә ашырганда, тулаем интеграция хасил булмаска да мөмкин.Интеграль дәрес исә тулаем төрле фән, төрле өлкәләрнең керешеп, багланыш-элемтәләр хасил булырлык итеп укытуны күздә тота. Боларның максаты – укучыларда яңа заман кешесенә хас булган фәнни фикерләү сәләтен үстерүгә, дөньяны яңача күзаллавына ирешү. Татар теле дәресләре төрле фәннәр белән интегратив рәвештә укытыла ала. Соңгы еллар вазгыятен, тел вазгыятен күздә тотып, туган тел һәм туган әдәбият дәресләре нигезендә интеграция үзен аеруча аклый дип уйлыйбыз. “Ярдәмче фигыльләр” бүлеген өйрәнүдә бу шул яктан да отышлы: дәреслек авторлары үзләре дә шушы бәйләнешкә нигез салып, мондый бирем тәкъдим итәләр:

- “Татар әдәбияты” дәреслегеннән ярдәмче фигыльләр ролендә килгән мөстәкыйль фигыльләр кулланылган алты җөмлә табып яз [Сәгъдиева 2017: 94].

Дәреслектәге күнегүләрне күзәтү тагын шуны да күрсәтә: “Ярдәмче фигыль” темасын өйрәнүгә караган күнегүләрдә еш кына язучы Гарәфи Хәсәнов әсәрләреннән өземтәләр бирелә. Шуңа нигезләнеп, дәресне шушы әдип иҗатына бәйләп тә интегральлеккә ирешергә була. Дәрес башында укучыларга әдип турында кечкенә текст белән танышырга мөмкинлек бирелә. Алга таба тексттагы ассызыкланган фигыльләрнең башка фигыльләрдән кайсы яклары белән аерылуы турында уйланырга кушыла. Мәсәлән, биографик һәм иҗатына караган фактларны яктырта торган мондый җөмләләрне кулланырга мөмкин: “Гарәфи Хәсәнов XX гасырның утызынчы елларында хикәяләр яза *башлый*. Аңа кадәр татар балалары өчен үсемлекләр, киек кошлар, җәнлекләр дөньясын шулкадәр күпьяклы сурәтләгән язучы булмый *икән*. Аның әсәрләрен табигать белеме, биология һәм зоология буенча энциклопедия дип ихлас әйтә *алабыз*”. Текстны уку язучының портреты һәм китаплары күргәзмәсен карау белән үрелеп барырга мөмкин

Алга таба язучының берәр хикәясе өстендә эш алып барырга мөмкин. Мисал өчен, без “Карт сандугач” хикәясен тәкъдим итәбез. Шуннан өземтә китереп үтик:

– Әйе, шушы карт сандугачны сабый чагында ук күрдем мин. Үсә төшкәч тә оста сайравына таң кала торган идем. Әйе, беренче мәртәбә күңел күзе белән күрү, моңлы һәм шул ук вакыт шат һәм дәртле сайравын күңел биреп тыңлау – мәңге йөрәк түрендә саклана, мәңге онытылмый икән. Әйләнә тирәдәге барлык яшь кошлар һәммәсе дә шушы карт сандугачка колак салды, инде алар ук оста сайраулары белән аны уздырып та җибәрде бугай [Хәсәнов 1981: 73].

Укучыларга тексттагы төшү (төшкәч), идем, икән, җибәрде фигыльләренең ярдәмче фигыль булуын дәлилләргә кушыла. Өй эше итеп Гарәфи Хәсәновның хикәяләренең берсен сайлап алып укырга һәм язучы иҗатының биологик (зоологик) энциклопедия икәнен раслап, эссе (сочинение) язарга кушыла. Иҗади эшләрендә ярдәмче фигыльләрне кулланырга, ассызыкларга да тәкъдим ителә. Вакыт һәм мөмкинлек булганда, әлеге дәреснең биология предметы белән дә интеграциясенә ирешергә мөмкин.

Шулай итеп, “Ярдәмче фигыль” темасын өйрәнү мисалында татар теле һәм әдәбияты дәресләре интеграциясенең кайбер үзенчәлекләре, мондый дәрестә шулай ук биология фәннәре белән дә бәйләнеш тудыру мөмкинлеге булуы каралды. Мондый эш укытуның фәннилеген арттыра, белемнәрне системалаштырырга, логик фикерләү сәләтен үстерүгә, укучыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүгә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1. Сәгъдиева Р.К. Татар теле. 7 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит нәшр., 2017. – 215 б.
2. Хәсәнов Г. Карт сандугач // Казан утлары. – 1981. – №7. – Б. 72-74.
3. Шлапакова М.М. Приемы реализации межпредметной связи в обучении русскому языку // Известия Самарского научного центра Российской академии наук. – 2010. – Т.12. – №3. – С. 371-373.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЭНДӘШ СҮЗЛӘРНЕҢ ГРАММАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Гарифулина Т.Р.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Эндәш сүз – ул сөйләүченең сөйләме төбәлгән зат, предмет яки күренеш атамасы. Грамматик яктан караганда, татар телендә иң еш очрый торган күренеш – баш килештәге исем белән белдерелгән эндәш сүзләр. Мәсәлән:

– Акылың котмы, *Янгузаров*? – дип беркем көтмәгәндә усал кычкырды да, Каюм, болан сымак сикереп, келәткә терәлеп торган киртәләр артында юк та булды [Имамов 2004: 105].

Исемләшкән сыйфатлар исә номинатив вазифа яки экспрессия тудыру вазифасын гына башкармыйлар, аларның гадәттә бәя бирү потенциалы гаять югары була. Игътибар итик:

– Болай атка атланып йөрсәң, үскәч кияү йөзе дә күрмәссең син, *денсез*!.. [Имамов 2004: 94].

Алга таба эндәш сүзләргә хас грамматик категорияләрне карап китик. Ф.Г. Галләмов шундыйлар рәтендә бер составлы булуны атый. “Синтаксик категория буларак эндәш сүзләргә иң беренче бер составлылык хас. Оештыручы үзәк бер генә, һәм ул баш килештәге исем яки исемләшкән сүз төркемнәре (сыйфатлар, тәртип саны, сыйфат фигыльләр, алмашлыклар) белән бирелә” [Галләмов 2009: 105]. Мисалларга мөрәҗәгать итик:

- Теге аның сандыкларында казына башлагач: “Имансыз кулың белән Коръән шәрифкә кагыласы булма, *кяфер*”, – дип, Габидулла хәзрәт каршы төшеп караган каравын [Имамов 2004: 134].

-Сөенегез, *карта ясаучылар*,
Тагын шатлык, тагын тантана!
Туып килгән яңа шәһәрчекне

Төшерәсез булыр картага... [Низами 2005: 29].
(“Тетри тайга”)

Беренче очракта эндәш сүзнең исем сүз төркеме белән белдерелгәнлеген күрәбез, икенче очракта – хәзерге заман сыйфат фигыль белән белдерелә. Ике очракта да эндәш сүз җәенкеләндерелмәгән.

Эндәш сүзләргә хас була ала торган тагын бер грамматик категория – җәенкеләнә алу. Ешрак эндәш сүзләрне җәенкеләндерүче кисәк буларак сыйфат фигыльләр һәм сыйфатлар килә. Мисал карыйк:

Хәтерләсәм кинәт кенә
Шул чактагы дау чорын, –
Әрни-әрни әйтеп куям:
“Хуш, *югалган ваучерым*...” [Низами 2005: 155].
(“Хуш, югалган ваучерым...”)

Кайбер эндәш сүзләргә хәбәрлек, кайберләренә ярымхәбәрлек категорияләре хас була ала. Түбәндәге мисалга игътибар итик:

– Утырыгыз, *җаныйларым*, әйдә, утырыгыз [Имамов 2004: 107].

Бу мисалда эндәш сүз төп җөмлә составында, аның уртасында килә. Бу җөмләдә эндәш сүз ярым хәбәрлекне белдерә, боерык фигыль белән белдерелгән гамәлне эндәш сүз буларак формалашкан “җаныйларым” башкара. Әмма башка очраклар да булырга мөмкин. Әйтик, түбәндәге очракта баш җөмләдәге үтәүче белән эндәш сүз туры килми, һәм мондый очраклар турында галимнәр: “семантик синтаксис күзлегеннән караганда, тулы хәбәрлек белдерелә”, – дип язалар [Галләмов 2009: 107]. Мисалларны карыйк:

– Телең, валлаһи, кычыткан сымак, *хәзрәт* [Имамов 2004: 87].

– И-и, күрде инде башлар, *Әмир абыкаем*! [Имамов 2004: 46].

Зат категориясен карыйк. Бу категория белән нисбәтлелекне тикшерү өчен, түбәндәге мисалны тикшерик:

Син оялма, гаҗәпләнмә, *чишмә*,
Күреп кызның үзеңә иелгәнен, –
Тидерсен ул салкын суларыңа
Үбелмәгән кайнар иреннәрен [Низами 2005: 34].
(“Сөюне көткәндә”)

Әлеге мисалда эндәш сүз сөйләм төбәлгән предметны белдерә, ягъни икенче зат берлек сан грамматик категориясе белән нисбәтле. Моңа ишарә булып төп җөмлә составында син алмашлыгы килүе дә тора, әмма мондый алмашлыкның булуы мәҗбүри шарт түгел.

Сан категориясе белән нисбәтлелеккә дә игътибар итик. Галим Ф.Г. Галләмов язганча, “Бу грамматик категория эндәш сүзләргә шулай ук хас. Ул сөйләм төбәлгән затның, предметның, чыннан да, санын күрсәтә. Әгәр дә сөйләм төбәлгән зат берәү генә икән, ул чагында исем, исемләшкән сүзләр белән бирелгән эндәш сүзләр берлек санда килә” [Галләмов 2009: 109]. Мондый мисалларны шактый еш күзәтергә була:

– Ай-һай, *энекәем*, бик нык ялгышасың [Имамов 2004: 131].

– Качабыз, дисең инде, *Яков дәдәй* [Имамов 2004: 132].

Шулай итеп, грамматик яктан эндәш сүзләр исем яки исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелә, хәбәрлек, зат һәм сан категорияләре белән характерлана, эндәш сүз үзенчәлекләре буларак бер составлы булу һәм җәенкеләнә алуны да атарга мөмкин.

Әдәбият


1. Галләмов Ф.Г. Эндәш сүзләргә хас грамматик категорияләр // Татар синтаксисыннан очерклар. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2009. – Б. 105 – 112.
2. Имамов В. Тозлы яра: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 384 б.
3. Низами Р. Тормыш трамвае: Шигырьләр, поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 238 б.


## УКЫТУЧЫМ ИҖАТЫНДА ТӘРБИЯВИ ЧАРАЛАР


Гарифьянова Р.В.

Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9нчы Зәй мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Хәйретдинова Р.Җ.


Роза Җәмил кызы Хәйретдинова 26 елдан артык гомерен балалар укытуга багышлаган. 26 ел күп тә, шул ук вакытта аз да. Мин “9 нчы Зәй мәктәбе”нә укырга килгәнемә дә өч ел. Укытучым мине беренче көннән үк күреп, шигырь дөньясына алып кереп китте, чөнки ул иҗади кеше. Мин өч ел укытучым канаты астында, ул мине шигырь сөйләү осталыгына өйрәтә, мин елдан - ел шигырь сөйләү техникасын шомартам, шигырь сөйләү үзенчәлекләрен ачам, нәтиҗәләребез дә куандыра. 2021нче елда укытучымның “Ак бүре” нәшриятында “Күңел тәрәзәләре” дип аталган китабы дөнья күрде. Шигырьләрнең тәрбияви ягы әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия. Шагыйрә табигать матурлыкларына укучыларын юнәлтә, дөрестән дә табигать матурлыкларын күргән кешенең начарлык эшләргә кулы бармый. Шигырьләре гади матур тел белән, балаларга аңлаешлы итеп язылган.

Уйнаклап-күбәләкләп,  
Бөтерелеп-әйләнгәләп,  
Сарылып-сырылып  
Бии кар-буран [Хәйретдинова 2021: 21].

Шушы матурлыкка кереп эрисе килә. Матур туган җиребезнинди матур! Һәр ел фасылы кешегә үзенчә тәэсир итә, балачак мизгелләренә илтә, кечкенә малай белән берлектә сары тузганаклы дөнья белән танышасы килә.

Мин дә торам сокланып,  
Гүя сабыйчагыма кайтып.  
Сары тузганаклы болында  
Ауныйсым килә ятып [Хәйретдинова 2021: 18].

Кеше табигатьтән аерылгысыз, аның иҗатында үз хис - кичерешләрен күрсәтүдә табигать күренешләре зур урын алып тора. Авыр

чакларында шагыйрә табигатькә мөрәҗәгать итә, җанына тынычлык эзли һәм ул аны зәңгәр күкләрдән таба да.

Ак хыялларым очар канат өсти,
Зәңгәр киңлекләргә, күккә дәшә.
Мин бит сиңа дус, югарыга оч, ди,
Биеклеккә уз, киңлекләрне коч, ди [Хәйретдинова 2021: 16].

Дуслыкны без уйлаганча, гади итеп күзалламый ул, ә дусның нинди булырга тиешлеген ачыклап бирә, төптән уйлап карасаң, дус “Дуслык кадере” ндәге кебек булырга тиеш тә.

Күңелем ташып җырлар җырлаганда,
Кушылып җырлый белергә дус кирәк.
Ипигә дә акчам бетте дип уфтанганда,
Азаккысын биреп бүлешергә дус кирәк [Хәйретдинова 2021: 5].

Ә язлар ничек матур сурәтләнгән, чөнки шаулы язлар белән сөекле шагыйребез Г. Тукай кайта, тирә-юньгә хуш ис тарата.

Гөрләвекләр кушылып җырлый
«Туган тел»е гимнына.
Сыерчыклар мактап сайрый
Сөекле улы Тукаена [Хәйретдинова 2021: 19].

Туган җирне яраткан кеше генә үз иленең ватанпәрвары була ала дип уйлыйм мин. Бар нәрсә яратудан башлана, ә яратканда никадәр матурлыклар тылсымлы ишекләрен ача, син бар эшкә, укуга җаның-тәнең белән чумасың, күңелеңә хуш килгән шөгыль табасың, бар нәрсә синең кул сузымында була.

Матур ел фасылларым –
Сары көзем, аккышым,
Яшел язым, алсу җәем,
Барысы – туган җирем![Хәйретдинова 2021: 20].

Укытучы апамны еллар узган саен, мәктәп тормышы, балалар дөньясы бөтереп алып кереп китә, укытучы һәрвакыт эзләнүчән укытучы булып кала. Ул безне - укучыларын олы тормышка әзерли һәм киләчәк өчен борчыла, һәр язмыш аның күз уңаенда.

Чал чәчләрен, маңгай сырларын
Күрсәтергә теләмичә, көлемсерәп,
Уйлары белән балачакка кайтып,
Укытучы басып тора, уйга батып.
Бөтенесе – аның күңел көзгесе...
Еллар шавы, гомер җыры өлгесе.
Бу һөнәрдә күпме кеше язмышы!..[Хәйретдинова 2021: 26].

Мин шундый остазым булу белән горурланам. Роза Хәйретдинова югары белемне Алабуга педагогия институтында алган, ул бик тәвәккәл, бик күп бәйгеләрдә катнаша һәм җиңү яулый, аны республика күләмендә дә беләләр. Тагын да озак еллар бергә иңне-иңгә куеп эшләргә, сәхнә киңлекләрен кочарга язсын! Шагыйрәнең күңеле һәрвакыт серле урман булып калсын, иҗат уты дөрләсен!

Әйтелмичә калган
Уйларым бар.
Сөйләнмичә калган
Сүзләрем бар.
Җырланмыйча калган
Җырларым бар.
Монда бар да бар!..[Хәйретдинова 2021: 4].

Укытучым фикере белән мәкаләмне йомгаклыйсым килә: сүзләр әйтә белү – иң зур бәхет, сүзләр таба белү – зур гыйлем, ә матур сөйләм - күңел бизәге. Һәрвакыт бизәкле булыйк!

Әдәбият


1. Роза Хәйретдинова - Мөсәгыйтова Р.Җ.Күңел тәрәзәләре.– Казан: Ак бүре, 2021. – 4-26 б.


## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИНТЕРАКТИВ УЕННАР КУЛЛАНУ


Гыйләҗев Р.Р.
Әлмәт шәһәренең Адымнар-Әлмәт гимназиясе укучысы
Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.


Хәзерге заманда мәктәптә белем бирү һәм укучылар тарафыннан белем алу, интерактив укыту ысулларыннан башка була алмый. Алар теория һәм практиканы бер үк вакытта үзләштерә торган уку мохитен булдырырга мөмкинлек бирә, ә бу укучыларга логик фикерләүне, бәйләнешле сөйләм телен үстерергә, индивидуаль мөмкинлекләрне ачыкларга һәм тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Уен технологиясе теләсә нинди фәнне өйрәнү буенча көндәлек дәресләрне дә кызыклы һәм мавыктыргыч итәргә мөмкинлек бирүче уникаль укыту формаларының берсе. Уенның кызыклылыгы - мәгълүматны истә калдыру, кабатлау, ныгыту яки үзләштерү буенча монотон эшчәнлекне уңай эмоциональ төсмергә әйләндерә, ә уен хәрәкәтенең эмоциональлегеге баланың барлык психик процессларын һәм функцияләрен активлаштыра. Уенның тагын бер уңай ягы - ул белемнәрне яңа ситуациядә куллануга ярдәм итә, шулай итеп, укучылар үзләштергән материал практика аша уза, уку процессына төрлелек һәм кызыксыну кертә.


Дәресләрдә төрле интерактив уеннар, кроссвордлар, шарадалар, ребуслар белән танышып, алар аша белемнәрне ныгыту, кабатлау уңай нәтиҗә бирә. Ләкин һәрвакыт укытучыны гына көтеп утыру дөрес түгел, шуңа күрә укытучыларның хезмәтен җиңеләйтү максатыннан, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә без - сыйныфташлар белән темаларны анализлау, йомгаклау дәресләрендә үзебез төрле интерактив уеннар әзерләп киләбез. Дәресләрдә ул уеннарны үзебез презентациялибез, үткәрәбез.

Бүгенге язмада Фатыйх Хөснинең “Йөзек кашы” әсәрен анализлауда нинди уеннар кулланылганын бәян итәрбез. Бу дәрес өчен без “КЕМ? КАЙДА? КАЙЧАН?” уены формасын кулланырга булдык.

Иң башта язучының фотосын күрсәтеп, тест формасында җавап кабул итәбез. Дөрес җавап булса, алкышлар музыкасы яңгырый.




Аннан соң ребус чишеп, әсәрнең исемен искә төшерәбез. “Йөзек кашы” турында белемнәрне кабатлап киткәч, әсәрнең вакыйгаларын сорау-җавап формасында кабатлыйбыз.




“Йөзек кашы”

Канатлы сүзләр – афоризмнар кулланылган мәкальләрне интерактив презентация формасында ясыйбыз. Ягъни, башта ниндидер сүз урынына сорау билгесе куябыз, бу сүзне белгәч, дөреслеген тикшерү өчен аста яшерелгән рәсемне карыйбыз. Аннан соң бу афоризмнар кемнәрне сурәтләвен ачыклыйбыз.







Соңыннан әсәр геройларын, аларның холык - фигыльләрен тасвирлаучы интерактив кроссворд чишәбез.







| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **Т** | **Г** | | | |
| | А | Ә | А | | | Б |
| В | Й | В | Й | Ч | | А |
| **Ә** | **Д** | **Ә** | **Б** | **И** | **Я** | **Т** |
| С | А | К | Ә | Б | Ш | Ы |
| И | Р | К | Т | Ә | Ь | Р |
| Л | | Ә | | Р | Т | |
| Ә | | Л | | | И | |

Шулай итеп, уенны танып белү эшчәнлеген активлаштыручы, уку-тәрбия процессын камилләштерүгә ярдәм итүче өстәмә ярдәмче чара буларак кулланырга була. Уен эшчәнлеге укучылар алдында фәнни кызыксынуларның киң колачын ача, аларны төрле өлкәләрдә үзләренең белемнәрен арттыру белән шөгыльләнергә кирәклегенә этәрә һәм уен алга таба мөстәкыйль эшчәнлеккә беренче этәргеч булып торачак. Әгәр уенның уку материалын үзләштерүдәге нәтиҗәлелеген бәяләсәк, традицион белем материалын биргәндә 20% - 40% мәгълүмат үзләштерелсә, эшлекле уенда 90% ка кадәр үзләштерелә икән.

Димәк, дәресләрдә төрле интерактив уеннар кулланылып белемнәр бирелсә, ныгытылса, укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге һәм белем бирү материалын үзләштерүе дә үсә дигән сүз. Ләкин бу уеннар күп көч һәм информатика өлкәсендә белемнәр таләп итә. Бу урында укытучыларга да укучылар белән бергә, эшне бүлешеп, ярдәмләшеп эшләү кирәктер, дип саныйм. Бергә, кулга-кул тотынып эшләгәндә генә югары үрләргә ирешеп, белемле шәкертләр әзерләргә була.

Әдәбият


1. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1994. – 405 б.


## РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН ХЕЗМӘТЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП, ТИРӘН БЕЛЕМЛЕ ҺӘМ ГҮЗӘЛ ХОЛЫКЛЫ ШӘХЕС ТӘРБИЯЛӘҮ


Гилманова Р.Р.
Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче:  Минегалиева И.М.


“ Әдәп, тәрбия, гүзәл әхлак
нәзакәтлелек димәктер”.
Ризаэтдин Фәхретдин

Без җәмгыятебездәге һәртөрле кимчелекләр, хәл ителмәгән мәсьәләләр турында ачыктан-ачык сөйлибез, аларны тормышка ашыру юлларын эзлибез. Шулар арасында яшь буынга тиешле тәрбия бирү- аеруча кирәкле һәм җаваплы мәсьәлә. Ул кеше һәм аның киләчәге белән тыгыз бәйләнгән.

**Эшемнең темасы**: Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтләренә нигезләнеп, тирән белемле һәмгүзәл холыклы шәхес тәрбияләү

**Эзләнү-тикшеренү эшенең максаты** галимнең эшчәнлеген тирәнтен өйрәнеп, киң катлау укучыга тарату, популярлаштыру. Бу максаттан чыгып, түбәндәгеләр эшләнде: галимнең язылган әсәрләре җыеп тикшерелде, анализланды.

Эшебезнең алдына куелган **бурычлар**:

- галимнең  әсәрләре белән танышу;

- тәрбия темасын билгеләү, анализлау;
- Р. Фәхретдиннең иҗаты турында фикерләр туплау;

Минем фикеремчә, тәрбиянең нәтиҗәлелеге сизгерлек кимүнең сәбәбе- халыкчанлык принцибы бозылуда, тәрбиядә халык педагогикасын кулланмауда. Укыту-тәрбиядә халык тәҗрибәсенә игътибар итмәү- яшь буынны тормышка хәзерләүдә җитди кимчелек, зур ялгышлык ул.Һәр халыкның үзенә генә хас милли тәрбия системасы бар; аны башка халыктан алыштырып, күчереп файдалану мөмкин түгел.

Тәрбия халыкта туган тел белән бергә барлыкка килгән. Галим Риза Фәхретдинов яшьләргә тормыш өчен зарури булган гомуми белемне ана телендә бирүне хуплый: “ Без хәзер ана телендә укырга һәм аны белмәүдә гаҗизләрбез. Әүвәл, башлангыч мәктәпләрдә, ана телен белдерүдә камил иҗтиһатыбыз (тырышуыбыз) зарурдыр. Аны белгәннән соң, башкаларны белергә ансат булыр. Бер- берсенә юл ачар”.

Мәшһүр затның бу тәгъбирләре белем нигезләренең ныклыгы башлангыч мәктәпләрдә уку-укыту эшенең торышы белән тыгыз бәйләнгән булуын раслый. Галим бик хаклы рәвештә ана телен зур тәрбия чарасы итеп карый.

Тәрбия, кешелекне дәвам иттерү чарасы буларак, табигый шартларда барган. Яшь буын, өлкәннәр белән аралашып, кирәкле күнекмәләргә өйрәнгән, халыкның гореф- гадәтләрен, йолаларын үзләштергән.

Халыкның иң беренче педагогик әсәре- һичшиксез, бишек җырлары. Ул җырларда аналарның өметләре, ышанычлары, баласын рухи һәм физик яктан матур, игелекле, мәрхәмәтле, гадел итеп күрү теләге чагыла. Аналарның йөрәк түреннән чыккан, ана телендә яңгыраган бишек җырлары тәрбиядә башка бернинди чара белән дә чагыштырмаслык һәм алмаштырмаслык хәзинә ул.

Мин үзем, татар баласы буларак, әнкәемнең бишек җырын ишетеп, тыңлап үстем. Мәсәлән,

Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Бәү-бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга җитәр бу.
Абыйлары артыннан
Казаннарга китәр бу,
Казаннарда укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Бишек җырларында, бәетләрдә, экиятләрдә, һәм әйтемнәрдә кешенең нинди булырга тиешлеге чагылдырыла, халык үзе омтылган үрнәкне гүзәл, күркәм сыйфатлар белән бизи.

Әлбәттә, Р.Фәхретдиновның балаларны тәрбияләүдә файдалануга бәйле эшлекле киңәшләре бишек, татар көйләренә бәйле: “Көйләр инсаннары (кешеләрне) үзләренә җәлеп итәләр, халыкларны ерак җирләрдән сөйрәп китерәләр.Ислам дөньясы бу эшне әхлак төзәтү вә гыйффәт (сафлык) тарату хакында вәсилә китерергә тиешле...Безнең бу турыдагы хосуси фикеремез

ошбудыр”,-дип,  галим “Җәвамигуль-кәлим шәрхе” дигән китабында халыкның җыр сәнгатен яклап чыга. Шигъри әсәрләрне, халык көйләрен, театр сәнгатен тирән аңлаучы мәшһүр зат музыкага булган шәхси мөнәсәбәтен түбәндәге фикерләр ярдәмендә укучыга җиткерә: “ Мин үзем музыка тавышын бик яратам, бәгъзы (кайбер) көйләрне озаграк тыңлаганым соңында, хәтта җылыйм, күңелем шулкадәр нечкәрә вә, дөньяга килүем мәсьәләләренә кереп, бөтенләй югалам.Үземнең барлыгымнан һич нәрсәм калмый”.

Халык иҗатында тәрбия юнәлешләренә туры килә торган, кешедәге барлык әхлакый сыйфатлар турында мәкальләр, әйтемнәр бар.Аларны без дә дәрестә еш кулланабыз.

Ананың балага биргән иң зур бүләге- тел.

Кешенең теле аңа дан да китерә ала, хурлык та китерә ала.

Башка кешеләргә изгелек кылырга кулыңнан килмәсә, һич булмаса усаллык кылма. Бу да үзенә күрә бер изгелек.

Әдәпне кемнән өйрәндең?- дип сораганнар берәүдән. - Әдәпсезләрнең әдәпсезлеген күреп, үземә килешмәгән кебек булды да, һаман андый гадәтләрдән сакланып килдем, әдәпле булдым,- дип җавап биргән ул.

Бу уңайдан мин галим Ризаэтдин бине Фәхретдиннең  “Нәсыйхәт” исемле хезмәтеннән өзек китереп үтәм: “ Холкы гүзәл булган кыз бала- бөтен гаиләсе өчен байлык вә бәхеттер,...укыган вә холкын тәрбияләгән кыз- алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр...мондый кызлар карендәш-кабилә өчен генә түгел, бәлки бөтен милләт вә бөтен дөнья халкы өчен дә мактаныч булыр”.

Халык тәрбиясенең төп чарасы- хезмәт. Бала кечкенәдән үк өлкәннәр белән бергә төрле хезмәттә катнашып үсә. Баласы турында ата-ана: “Кул арасына керә башлады инде”,- дип, горурланып сөйли. Мондый ата-аналарның балалары тәртипле дә, кешелекле дә һәм белемгә омтылучан булып үсәләр.

Р.Фәхретдин хезмәтләрендә гыйлемнең кешелек тормышында зур урын тотканын ассызыклый: “Гыйлемне дуст күрү исә аның әһлене хөрмәт итү,халык арасында аны тарату, укучыларга һәм дә мәктәп вә мәдрәсәләргә, укытучыларга мадди вә мәгънәви ярдәмнәр бирүдән яки искедән мирас булып калган көнчелекләр сәбәпле гыйлем әһелләрен дошманлык кылулар вә гайбәтләрне сөйләүләрдән саклану вә гомумән гыйлем юлында булган кешеләр берлә яхшы мөгаләмәдә булудан гыйбарәттер”.

Чын кеше булу өчен, гыйлем белән бергә,күркәм холык һәм кешелекле булу, яшьләрне халыкка тугры хезмәт итәрлек затлар итеп тәрбияләү өчен, мәдрәсәләрдә укыту-тәрбия ысулларын үзгәртеп-кору, алга киткән башка халыклардан өйрәнү, урыс телен дә яхшы үзләштерү зарур, дигән карашны алга сөрә ул.Аның түбәндәге фикерләре бу хакта сөйли: “ Дөнья тормышы өчен дин илә дөнья гыйлемене һәм белмәк лямиздер...Инсан улмак (кеше булу) өчен гыйлем илә күркәм холык кирәктер...”.

Ризаэтдин Фәхретдин шулай ук югары дәрәҗәдә туган халкында яхшы кешелек сыйфатлары тәрбияләргә омтыла. “Холыклары гүзәл булган милләт мотлака (чикләнмәгән) дөньяга өстен вә могтәбәр (хөрмәтле)булачактыр...Гүзәл холыклы милләт бәхетле”,-дип яза галим.

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә, дөрестән дә, Р.Фәхретдиновның хезмәтләре моннан бер гасыр элек язылса да, бүген дә әһәмиятен югалтмаганнар.Аның хезмәтләрендә дистәләрчә гасырлар дәвамында татар гаиләсендә яшәп килгән һәм көндәлек гамәлдә булган халык педагогикасы алымнарына таянып эш итәргә кирәклеген бик җентекләп өйрәтә, төпле һәм кирәкле һөнәри киңәшләрен бирә.

Укыту-тәрбия халыкчан булганда гына көчле тәэсирле һәм уңай нәтиҗәле булыр.

Әдәбият

1. Мәгариф, №1, 2005, 58 - 60 битләр
2. Мәгариф, №3, 2005, 62 - 64 битләр
3. Ризаэтдин Фәхретдин. «Шәкертлек әдәбе». – Казан: “ Иман “ нәшрияте, 2002, 3 – 5 битләр.
4. Ризаэддин бине Фәхреддин. Җәвамигуль-кәлим шәрхе. Казан. “Иман” нәшр., 1995
5. Р.Ш.Шаһиев. Ризаэддин Фәхреддиннең иҗади мирасы. Казан, 2007.

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА АНА ОБРАЗЫ

Гильмутдинов И.И.
Яр Чаллы шәһәренең 19 нчы номерлы гомуми
белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Фатихова С.Г.

Үсеп килүче буынның рухи-әхлакый нигезләрен формалаштыруда әдәбият дәресләренең роле зур, чөнки әдәбият дәресләре - тормыш дәресләре. Матур әдәбият укыганда бала тәэсирләнә, дулкынлана, борчыла һәм шатлана. Роберт Миңнуллин әсәрләре безнең күңелләрдә шундый хисләр уята. Аның шигырьләре тиз отышлы, тирән мәгънәле, балаларга бик тә кызыклы.

Г. Гыйльманов Р. Миңнуллин иҗатының тирән әһәмияткә ия булган бер үзенчәлеген түбәндәгечә билгели: "Әдәбият казанында азмы-күпме кайнаган кеше буларак, төгәл әйтә алам: әдипләрнең асыл талантын билгели торган бер бизмән бар. Ул - аларның өлкәннәр өчен дә, нәниләр өчен дә бердәй талантлы әсәрләр иҗат итә алулары. Андый әдипләр, гадәттә, күп булмый: булганнары тыйнак, самими җан ияләредер... Роберт Миңнуллин әнә шундый шагыйрьләрдән”. Шагыйрь туктаусыз эзләнү нәтиҗәсендә әдәбиятыбызны кәтелмәгән яңа ачышлар белән баетты. Ул өр-яңа образлар, шигъри алымнар алып килде. Аның төрле яктан уйланылган, поэтик яктан зур осталык белән эшләнгән шигырьләре мәктәпләрдә еш яңгырый.

Роберт Миңнуллин шигъриятендә әниләр образына багышланган шигырьләр аерым урын алып тора. Һәрберебезнең күңелләрендә тулып йөргән хисләрне ул гади сүзләр белән әйтеп бирә алган. Шуңа да аның язган һәрбер сүзе, һәрбер юлы безгә якын, кадерле.

Аның шигырьләрен һәрвакыт эчке бер дулкынлану белән укыйм. Алар аналарның бөтен гүзәл сыйфатларын яктырта.

Р.Миңнуллинның олы тормыш юлына басуында, шигърияткә килүендә әнисенең - Гөлҗәүһәр апаның роле бик зур.  Улларын, кызын чын кеше булырга, тормышта үз урыннарын табарга, кыенлыклар алдында югалып калмаска өйрәткән ул. Үзенең истәлекләрендә ул болай дип яза: “Хәзер менә уйлап йөрим: ай-һай авыр булгандыр әнкәйгә. Үзе генә беләдер ниләр күргәнен, ниләр кичергәнен. Ә безгә нәрсә? Якты өй, тәмле аш, җылы караш булса, шул җиткән. Калганы турында олыгайгач кына уйланасың”???.

Әдип “Әнкәйнең ак чәчләре” исемле китабын аналарга карата зур ихтирам белән язган.

Сокланып карап торырлык-<br>
Күзне ала алмыйбыз.<br>
Әнкәйләрнең бөеклеген<br>
Яши-яши аңлыйбыз.???

Татар әдәбиятында Р.Миңнуллин әниләр турында иң күп әсәрләр язучы әдипләрнең берсе булып танылды. “Һаман чибәр минем әнкәй”, “Әнкәйнең ак чәчләре”, “Әнкәй”, “Әнкәмнең догалары” кебек шигырьләрендә әнкәйләргә булган хөрмәт, ярату хисе таң калдыра безне.

Роберт Миңнуллинның әниләргә  багышлаган шигырьләрен укыганда, шагыйрьнең әнисен никадәр ятратканын аңлыйсың. Ананы иң олы ярату белән яраткан кеше генә шундый тирән эчтәлекле, матур шигырьләр иҗат итә ала. Басылып чыккан егермеләп китабы да, туган тел дәреслеге, тормыш дәреслеге буларак, укучыга да, укытучыга да бик кирәк.

Бөтен чор язучылары да үз иҗатларында аналарга дан җырлыйлар. Һәр авторның әсәрендә кадерле әниләребез шундый зур ихтыяр көченә ия, алар барысына да түзәргә әзер, тик газиз балалары гына исән булсын, Кеше дигән исемнәрен югалтмасыннар.

Әниләребезгә тиешле игътибар, дәрәҗә, ярату булганда гына иманлы, миһербанлы, милли җанлы балалар үсәр. Әдәби әсәрләрдәге ана образларына бәя - бүгенге көнне, яшәешебезне аңларга ярдәм итүе белән әһәмиятле.

Әдәбият

1. Миңнуллин Р. М.Талбишек: Шигырьләр. Г. Гыйльманов кереш сүзе. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1995.– Б.6.

2.Даутов Р.Н. Балачак әдипләре: Библиографик белешмәлек. Беренче китап. - Казан: Мәгариф, 2002. – 120 б.

## РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Гильметдинова Ф.Ф.
КФУ ның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Элек татар теле киң кулланылган тел булган һәм буыннан-буынга тапшырылган. Кешеләр үз телләрен саклап калырга тырышканнар. Әмма,

кызганычка каршы, вакыт узу белән татарлар туган телләрен оныта, азрак аралаша башладылар. Мәктәпләрдә рус телендә укыта башлыйлар, барлык мәгълүмат һәм китаплар рус телендә була. Бу шартлар аркасында рус теле татарлар өчен өстенлекле тел булып китә.

Хәзер мәктәпләрдә балалар татар телен өйрәнергә теләми дигән тенденция күзәтелә. Балалар катнаш никахларда туа. Кемнеңдер әтисе-рус, ә әнисе-татар, яки киресенчә булырга мөмкин.  Еш кына ата-аналар балалар белән рус телендә сөйләшә, шуңа күрә бала татар телендә сөйләшә белми. Бу ата-аналарның гаебе.

Балага ике тел өйрәтергә кирәк. Сез моны иртәрәк башласагыз, бала өчен яхшырак булыр. Бу төшенчә икетеллелек дип атала. Икетеллелек - бу ике телнең бер тел коллективы кысаларында бергә яшәве, алар бу телләрне социаль ситуациягә һәм коммуникатив актның башка параметрларына бәйле рәвештә төрле коммуникатив өлкәләрдә кулланалар.

Бер үк вакытта ике телдә сөйләшүче балаларга киләчәктә төрле мөмкинлекләр ачыла, аларның фикерләү эшчәнлеге бер телдә сөйләшүче кешеләргә караганда күпкә тизрәк. Чөнки, ике телдә сөйләшкәндә, балага бер телдән икенче телгә тиз күчә белергә туры килә. Нәтиҗәдә, баланың зур бай сүзлек запасы була, интеллектуаль сәләтләре үсеш ала.

Уңышлы уку өчен ике дәүләт телен - рус һәм татар телләрен яхшы белү кирәк. Ләкин ни өчен хәзер ата-аналар рус телен өйрәнүгә күбрәк басым ясыйлар, ә татар теле икенче планга күчә яки бөтенләй юкка чыга? Татар теле белән бөтенләй кызыксынмаган балаларга ничек ул телне өйрәтергә? Рус телле мәктәпләрдә татар телен укытуның нинди үзенчәлекләре бар? Бу сорауларга мин үз мәкаләмдә җавап бирергә тырышырмын.

Мәктәптә татар телен укыту процессы аеруча рус телле балаларга кыенлыклар тудыра. Укытучы шуны истә тотарга тиеш: татар телен өйрәнү белем бирү характерында гына түгел, ә баланың иҗади һәм уңышлы шәхес буларак үсешенә дә юнәлдерелгән. Әгәр бала үзе теләк белдереп татар телен өйрәнергә теләсә, уку уңышлы булачак. Рус телле мәктәптә татар телен укытуның үз үзенчәлекләре бар. Беренче чиратта, уку, язу һәм сөйләм күнекмәләрен формалаштырырга кирәк. Туган тел-халыкның үзенчәлеген, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калуның бәйләүче звеносы.

Татар телен рус балаларына укыту, татар халкының галим язучысы К.Насыйри хезмәтләрендә аеруча чагылыш тапкан. Галимнәр фикеренчә, бу хезмәтләр, хәзерге заман хезмәтләренә, мәктәптә укыту методикасына ачкыч булып тора.

Рус телле балаларга татар теле дәресен укытканда, укытучы дәресне укыту принципларына нигезләнеп төзи. Бүгенге көндә укыту принциплары турында бик күп фәнни һәм методик хезмәтләр бар.

Системалылык принцибы турында Ф.Ф. Харисов түбәндәгечә яза: «системалылык принцибын тормышка ашырганда, иң элек укучыларның аңында өйрәнелә торган тел бербөтен система (фонетика лексика һәм грамматика яруслары буенча) буларак формалаша, морфология, синтаксис, лексика белән тыгыз бәйләнештә өйрәнелә”,-ди.

Ә менә функциональ-семантик принципны профессор “ материалның функциональ урнаштырылуы һәм бирелеше, телнең төрле яруслары һәм сүзләрнең морфологик класслары исәпкә алыну, шулай ук табигый аралашудагы экстралинвистик факторлар таләп итә”,- дип билгели.

Культурологик (мәдәниятлелек) принцибы турында Ф.Ф.Харисов болай яза: “Дәүләт дәрәҗәсендәге документлар телгә өйрәтүдә культурологик (лингвокультурологик) аспект кирәклеген ассызыклыйлар, әлеге аспект милли һәм шәхси үзаң барлыкка килүдә зур әһәмияткә ия”.

Минимумлаштыру принцибы турында тел белгече түбәндәге мәгълүмат бирә: “Бу принцип телгә өйрәтү этабында сөйләм һәм тел материалын тиешле күләмдә (иң кирәкле өлешен) сайлап алуны аңлата”, –ди.

Уку материалын концентрик рәвештә аңлату принцибын профессор болай аңлата: “Уку материалы чикләнгән цикл буенча концентрларга (этапларга) бүленә”, – ди [Харисов 2015: 37].

Ләкин укытучы алар арасыннан үзенә кирәкле принципларны гына сайлап ала.

Һәр укытучы өчен иң югары бүләк- бала алган барлык белемнәрен практикада куллану. Шуңа күрә без укучыга уку материалын җиңелдән алып авырлыклар арту тәртибендә бирергә тиешбез.Әгәр балага күп күләмдә материал бирсәң, мондый өйрәтү нәтиҗәсез булачак. Бала шулкадәр күп мәгълүмат эчендә югалачак.

Һәр яңа дәрес алдагы дәресләргә нигезләнергә тиеш. Балалар һәрвакыт дәрестә актив катнашсын өчен аларны кызыклы итеп эшләргә кирәк. Уку барышында укучылар татар телендә сөйләмне дөрес кабул итәргә, бер-берсе белән сөйләшә белергә, текстларны укый, аңлый һәм сөйли белергә, шулай ук дөрес, хатасыз язарга өйрәнергә тиеш.

Уку эшчәнлеге вакытында төрле методик алымнар куллану укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштырырга мөмкинлек бирә. Гел традицион дәресләр генә үткәрергә түгел, ә төрле эш формалары белән дә чиратлаштырырга була. Кече сыйныф балалары өчен кечкенә текстларны (әкиятләрне, хикәяләрне) музыкаль формада яңгыратырга мөмкин, халык уеннары белән таныштырырга һәм аларны дәресләрдә уйнатырга мөмкин.

Шулай ук инновацион технологияләрне дә кулланырга мөмкин. Компьютер технологияләрен үзләштерү укытучыларның эшләрен җиңеләйтә, укучыларның уңай мотивациясен көчәйтә һәм аларның танып белү эшчәнлеген активлаштыра. Дәрестә тема белән бәйле видео-дәресләр куерга мөмкин. Балалар кызыксынып бу видеоларны карыйлар, тест биремнәрен эшлиләр.

Берәр әсәрне анализлау дәресләрендә балаларны берничә төркемгә бүлеп була. Укытучы төрле эш формаларын сайлый ала: рольле уеннар, театр кую, дискуссияләр оештыру, төп геройларның рәсемнәрен ясау һ.б. Бала ачыла һәм дәресләрдә актив эшли башлый, чөнки иҗади мохит балалар өчен бик уңайлы һәм кызыклы.

Югары сыйныф балалары өчен инде үз яшьләренә туры килгән эш формаларын сайларга кирәк. Мәсәлән, дәресләрдә театр постановкасын яки әсәрләр фильмын карарга, аннары каралган материалга рецензия язуны сорарга

мөмкин. Балалар үзләрен тәнкыйтьчеләр ролендә хис итә ала. Шулай ук уку материалын биргәндә татар җырчыларының клипларын кулланырга мөмкин. Шуннан соң алардан җырның нәрсә турында булганын, бу видеоны караган вакытта нинди хисләр кичергәннәрен сорарга була. Бу очракта балаларда монологик һәм диалогик сөйләм дә үсә. Галимнәр фикеренчә, бу юл белән телне үзләштерү яхшы нәтиҗәлелеккә китерә. Тел өлкәсендә эшләүче чит ил һәм безнең ил галимнәре коммуникатив технология нигезендә укытуга өстенлек бирәләр. Күп кенә татар методистлары чит телләрдә татар телен өйрәнгәндә бу технологияне кулланалар (Р.З. Хәйдарова, Ф.Ф. Харисов һ. б.). Коммуникатив компетенция сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үзләштерүне күздә тота, тирә-юньдәгеләрнең сөйләмен аңлау һәм үз фикерләрен белдерү буенча белем, күнекмәләр һәм күнекмәләр җыелмасы булып тора. Тикшерүчеләр сүзләренчә, әлеге система сүзлек запасын, сөйләм күнекмәләрен арттыру өчен шартлар тудыра, татар телен өйрәнүгә уңай мотивацияне үстерүгә ярдәм итә. [Зиннәтуллин 2014: 219].

Хәзер татар теле буенча күп кенә конференцияләр һәм олимпиадалар үткәрелә. Укытучы балаларны фән дөньясына кертеп җибәрергә тиеш. "Мин татарча сөйләшәм" республика акциясе, татар теле белеме буенча "Зирәк тиен" төбәкара конкурсы, укучылар өчен фәнни - тикшеренү конференцияләре һ.б. бар. Аларга укытучы ярдәм итә ала. Бала укытучы ярдәмен тоярга тиеш.

Шулай ук рус телле балаларны татар телендә уздырыла торган төрле сыйныфтан тыш чараларда катнаштыру уңышлы нәтиҗәләр бирәчәк. Рус телле балалар татар телендә иркен сөйләшүче балалар белән берлектә театр спектакльләре куя, концертлар үткәрә, җырлар җырлый, бии һәм шигырьләр сөйли ала.

Татар телен саклау - бүгенге көндә төп максатларның берсе дип әйтәсем килә. Татар телен саклау һәм аны куллану татар мәдәниятен һәм аның үзенчәлеген саклауда төп элемент булып тора. Укучылар татар телен үзләштерсен өчен һәм ике телдә аралаша алсын өчен, аларның коммуникатив компетенциясен формалаштырырга кирәк. Бу мәсьәләне уңышлы хәл итүдән чыгып, без татар теле практик һәм интеллектуаль эшчәнлектә чын мәгънәсендә ихтыяҗлы булачакмы-юкмы икәнен әйтә алачакбыз.

Әдәбият

1. Зиннатуллин Р.К. Күпмәдәниятле белем оешмаларында татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту // Поликультурное образовательное пространство Поволжья: интеграция регионального и международного опыта. – Казань: 2014. – С.216-220.

2.Икетеллелек шартларында татар телен укыту // инфоурок URL: https://infourok.ru/statya-na-temu-iketellelek-shartlarynda-tatar-telen-ukytu-4424333.html (мөрәҗәгать итү датасы: 23.10.2023).

3.Рус балаларын татар теленә өйрәтүдә укыту принципларын кулану үзен чәлекләре // Образовательная социальная сеть nsportal.ru URL: https://nsportal.ru/vuz/pedagogicheskie-nauki/library/2018/12/08/rus-balalaryn-tatar-telen-oyrtud-ukytu-printsiplaryn (мөрәҗәгать итү датасы: 23.10.2023).

4. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре // Научные основы обучения татарскому языку как неродному. – Казан: Мәгариф, 2002. –367 б.

## ТАТАР ТЕЛЕН ҮЗЛӘШТЕРҮДӘ УЕН ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

Гильметдинова Ф.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты
Фнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Дөньяны танып белү, белем бирү, уку-язарга өйрәнү, тәҗрибә туплау, тәҗрибә уртаклашу, фән-техника, сәнгать яңалыклары белән танышу, иҗат итү бары тел ярдәмендә генә тормышка ашырыла ала. Тел кешенең барлык иҗтимагый эшчәнлеген оештыра.

Шуңа күрә дә кеше борын заманнан ук балаларны ана теленә өйрәткән, аның телен шомартуга, сүзлек хәзинәсен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда, аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткән. Ана, баласына “тел ачкычы” бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган; үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән, бәетләр, экиятләр сөйләгән.

Балаларны матур итеп үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү, туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә дә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Балаларның авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй фикерләрен тиешле эзлеклелелектә, ашыкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, матур сөйләм үстерү юнәлешендә даими эш алып барырга кирәклеген онытмаска кирәк. Бу максатларны тормышка ашыру өчен тиешле чаралар кулланмый мөмкин түгел.

Укучыларның сөйләм телен үстерүдә, камилләштерүдә, теманы анык итеп аңлауда, мөстәкыйльлек формалаштыруда уен формаларының әһәмияте әйтеп бетергесез. Уен – шөгыльдә алынган белемнәрне ныгыту чарасы да ул. Уен мәктәпкәчә яшьтәге баланың да, мәктәп яшендә дә танып белү эшчәнлеген, иҗади фикерләвен һәм сөйләмен үстерә, уенда бала яки укучы үзе белмәгәнне өйрәнергә, аны эшләргә омтыла. Шуңа да мәктәпкәчә яшьтән башлап үстерелешле уеннар куллану мөһим.

Сөйләмне үстерү – балаларның бәйләнешле сөйләмен (диалогик, монологик) һәм сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру, камилләштерү, сүзлеген баету ул. Сөйләм һәм уен формалары бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгәннәр. Куп уеннар аралашуга корылган, димәк сөйләм зур рольне уйный. Сөйләмнән башка уеннарны тормышка ашырып булмый. Һәр уен сөйләмгә корылган булмаса да, иң элек уенның тәртибен аңлатыр өчен, сөйләм теленә мөрәҗәгать итү шарт. Шуңа күрә дә уен һәм сөйләм төшенчәләре үзара бик тыгыз элемтәдә торалар.

Уеннарның максаты сөйләм үстерү күнекмәләре бирү генә түгел, ә баланың мөмкинлекләренә игътибарлылык, күзаллау, фикерләү, хәтер үсешен тәэмин итүче буларак та бәяләнә. Бу бурычларны үтәү баладан акыл һәм көч

сорый. Өйрәтү бурычының эчтәлеге төрлечә булырга мөмкин: ашыкмау, предметның формасын атау (сүзлекне баету), кирәкле предметны билгеле бер вакыт эчендә табу һәм аны тасвирлау (бәйләнешле сөйләм), җөмләнең сүз тәртибен белү (сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыру һәм камилләштерү), дөрес интонация һәм тавыш көче белән сөйли белү (сәнгатьле сөйләм).

Уеннар ике төрле кагыйдәгә ия булалар: алар – биремне үтәү һәм аралашу кагыйдәләре. Биремне үтәү кагыйдәләренең үрнәге булып түбәндәгеләр тора: бер укучы да атамаган берәр предметны, төшенчәне искә төшерү һәм әйтү, дәреснең асылы булган төшенчәне табышмак аша әйттерү. Ә аралашу кагыйдәләренә чират буенча бер-береңнең фикерләрен тулыландыру яки мөгаллим кушканны үтәү керә: тату уйнау, бер-береңне тыңлау һ.б. Бу кагыйдәләрне үтәү укучыдан түземлелек, тырышлык, яшьтәшләре белән исәпләшүне, үз-үзен дөрес тота белүне сорый. Фикерләү һәм сөйләм үсешен тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү өчен, уеннар сайлауда билгеле бер эзлеклелекне сакларга кирәк.

Тавыштан танып әйтә белү сәләтен үстерүче уеннарны башлангыч сыйныфларда ук яратып уйныйлар. Бу уеннарның төп максаты – укучыга авазларның үзенчәлекле дөньясын ачу. Укучыда тыңлау, авазларның көче, тембры, характеры буенча чагыштыру һәм бәяли белү күнекмәләре формалаша. Ә бу исә мәктәптә нәкъ менә башлангыч сыйныфларда үстерелә барып, югары сыйныфларда тулысынча тормышка ашырыла. Чөнки мәктәпкәчә яшьтә әйләнә-тирәдәге авазлар балалар тарафыннан әле аңсыз рәвештә генә кабул ителә. Авазларны аңлау һәм тыңлау сәләте үзеннән-үзе генә барлыкка килми. Аны башлангыч сыйныфлардан ук максатчан үстерергә кирәклеген һәм моның уен аша җиңелрәк башкарылуын укытучы һәрдаим күз алдында тотарга тиеш [Волкова 2014: 27].

Күпчелек уеннар табышмак характерында булалар, балалар аваз буенча табышмакның җавабын табалар. Иң элек бала үз иптәшенең тавышын таный, аваз чыганагын таба. “Аюны кем уяткан”, “Маэмай”, “Чыпчыклар һәм автомобильләр”. Уенда тавышны таный белү сәләтен формалаштыру һәм камилләштерү өчен ике төп шартны үтәү мөһим. Беренчедән, “серле” авазны башка аваз тәэсирләреннән аерабыз. Моның өчен, авазлы табышмакларны биргәндә һәм аларны ишеткәндә, тынлык урнаштыру әһәмиятле. Бу – уенда катнашучыларның авазга игътибарын туплау һәм бер-берсенең җавапларын бәяләү өчен кирәк. Мәктәп яшендәге балаларга хәтерләрен, уйлау, тоемлау сәләтләрен камилләштерү, үстерү өчен магнитофоннан татар җырчыларының тавышларын тыңлатып, “Җырны һәм җырчыны әйтеп бирү” уеннарын оештыру зарур. Болай эшләү авазларның әйтелешен дөрес итеп кабул итү, хәтерне камилләштерү өчен дә кирәк.

Төсне танып әйтүгә корылган уеннарда бала күрү, ишетү, тоемлау алымнарын үзләштерә, алар, үз чиратында предметларны билгеләре буенча аерырга, чагыштырырга һәм туры килүче сүз белән атарга булышлык итә. Шулай итеп, предметларның тышкы билгеләре турында гомуми күзаллаулары барлыкка килә. Бу уеннар тирә-юньне аңлап кабул итү өчен нигез булып тора.

Уеннар ике төрле өйрәтүне максат итеп куя: максатчан рәвештә төсләрне аерырга өйрәтү, төсләрне дөрес әйтергә өйрәтү.

Беренче очракта, бала предметларның төсләрен чагыштыра һәм сайлап ала. Икенче очракта, балалар кирәкле предметларны табалар һәм аларның төсләрен дөрес сүзләр белән билгелиләр. Төсләр белән таныштыру баланың актив эшчәнлеге һәм алар өчен кызыклы булган предметлар аша алып барыла. Балалар төсләрне аера белсен өчен уенчыкларга һәм предметларга түбәндәге шартлар куела:

Предметлар һәм уенчыклар балада кызыксыну уятырга тиеш.

Уенчыклар ачык төсләрдә булырга тиеш.

“Төсле божралар”, “Төсле тасмалар”, ”Төсле түгәрәк”, “Үз өеңне тап” һ.б. уеннарында нәниләрем төсне белдерүче сүзләрне актив кулланырга өйрәнәләр.

Хәтерне үстерүче уеннарда балалар предметлар арасында бәйләнеш барлыкка китерергә өйрәнәләр. Бу бәйләнеш уен кагыйдәре һәм уен хәрәкәтләре белән бирелә. Баланың зиһенгә алуы бик хисле дә була: ачык төсне, тавышларны, күзгә бәрелеп торган һәр хәрәкәт иткән әйберләрне ярата. “Куян кая качкан?”, “Серле тартма” һ.б. уеннарда максатка ирешү өчен көч җитәрлек авырлыкны җиңеп чыгарга кирәк булганда фикер актив эшли. Теләсә нинди уен оештырганда да гадидән катлаулыга бару мөһим. Берничә уенны бер дәрестә оештырганда, әлеге уеннар арасында бәйләнеш булу мөһим. Бала бер уеннан икенчесенә җиңел генә кереп китәргә тиеш. Дәресне артык авыр уеннан башлау материалы фикер үсешен туктата, балада кызыксыну бетә.

Балалар һәм яшүсмерләр тормышын уеннарсыз күз алдына китереп тә булмый. Уеннар балаларда җитезлек, зирәклек сыйфатлары тәрбияли, физик яктан чыныктыра, ритмлы сүз, хәрәкәт, көй аша бала күңелендә иҗат хисе кабыза, туган ягына, якыннарына мәхәббәт хисләре уята.

**Әдәбият**


3. Альмиева Р. М. Ролевая игра как средство развития фантазии и творчества учащихся // Творческая активность учащихся: поиск, находки, проблемы. – Казань, 1995. – С. 164-169.
4. Васильев В. Проектно-исследовательская технология: развитие мотивации // Народное образование. 2000. – № 9 – С. 177 – 180.
5. Волкова Р., Гарәфетдинова Р. Башлангыч мәктәптә татар телен чит тел буларак өйрәтүдә уен алымнарын һәм методларын куллану. – Казан: Мәгариф, 2014. – 128 б.
6. Саттарова Н. Шәхесне тәрбияләүдә уен // Мәгариф. – 2004. - № 2. – Б. 42-44.
7. Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр // Мәгариф. – Казан, 2002. – № 8. – Б.33-36.
8. Ягъфәров Р.Ф. Уен – күңел бәйрәме: Татар халкының уен фольклоры. – Казан: Мәгариф нәшрияты, 2009. – 160 б.


## ЗАМАНЧА ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Гимранова Э.Ф.

КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче Камаева Р.Б.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә. Укыту-тәрбиянең бүгенге көндәге уңышы укытучының бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып-белү процессы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәнүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле. Әйләнә-тирәне, кешелек дөньясын өйрәнү һәм аны укучыга дөрес аңлату, укучыны тормышка яраклаштыру – укытучылар алдына куелган мөһим бурыч.

Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы да артты. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә [Камаева 2012: 3].

Дәрес – мәктәптә укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы. Ул процесс– укытучы һәм укучының бердәм-эзлекле эшләве. Укучылар зур активлык күрсәткәндә, укытучы аның активлыгын уңышлы оештырганда гына дәресләр нәтиҗәле була ала.

Дәресләрне ничек оештырырга кирәклелек турында укытучылар һәм педагог-методистлар арасында төрле карашлар булды һәм, әлбәттә, дәресләр төрлечә үткәрелеп килде.

Дәрес актив (нәтиҗәле) яки пассив (нәтиҗәсез) булырга мөмкин.

Түбәндәге таләпләргә җавап биргән дәресләрне нәтиҗәле дәресләр дип әйтергә мөмкин:

1) материалның характерына, алда торган бурычларга, укучыларның яшь һәм белем дәрәҗәсенә карап оештырылган;

2) алынган кма конкрет булып, дәреснең максаты һәм өйрәнелә торган теманың гамәли әһәмияте ачык аңлашылган;

3) дәрес өчен сайланган материал аңлаешлы, җиңел үзләштерерлек, укучыларның акыл сәләтен, танып белү активлыгын үстерерлек һәм аларга төрле яклы тәрбия бирерлек булган;

4) тема үткән дәресләрдәге материалга бәйләнешле һәм моннан соң үтелә торганына нигез булырлык итеп бирелгән;

5) эшләү методы һәм алымнары, укыту чаралары, аларның уңышлы чиратлашуы укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндергән;

6) укучылар дәрескә битараф булмыйча, аларның тойгылары һәм эмоцияләре эшкә җигелгән;

7) материалны укучылар яхшы үзләштергән, аны гамәли эшендә файдалана белү һәм тел үстерү күнекмәләре биргән;

8) укучыларда дөньяга караш, тормышта үзенең урынын таба белү һәм башка шундый сыйфатлар тәрбияли алырлык дәресләр.

Укучы актив эшләгән, укытучы аның активлыгын уңышлы оештыра алган дәресләр генә нәтиҗәле була ала [Вәлиева 2000: 66-67].

«Традицион дәрестән аермалы буларак», – дип язган академик М. И. Мәхмүтов, – хәзерге дәреснең төп үзенчәлеге: ул – балаларның акыл сәләтен үстерү. Моның өчен укучыларның фикерләвен, белем алуга һәм хезмәткә теләк-омтылышын үстерү, дөрес мөнәсәбәтләр трбияләү буенча максатчан эш алып барыла. Әлбәттә, зиһенгә алу, дикъкать, күзәтүчәнлек, хәтер, күзаллау, яхшы сөйли белү, физик хәрәкәтләрне үстерү кебек традицион дәресләргә куела торган максатлар да игътибардан читтә калмый» [Мәхмүтов 2016: 69].

Мәктәпләр алдына куелган бурычлар яктылыгында, укыту процессын интенсивлаштыру таләп ителә. Укыту процессын интенсивлаштыру –белем суммасын арттыру белән бергә, белемнең сыйфатын камилләштерү дә ул. Менә шуңа күрә дә укытучыдан дәресләрне укучыларга ныклы белем бирерлек, алган белемен тормышта файдалана алырлык, укучыларның акыл сәләтен үстерерлек һәм аларга төрле тәрбия бирерлек итеп оештыру таләп ителә.

**Әдәбият**


1. Гыйльманов Д.Ш. 2014-2015 нче уку елына татар телен укыту үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2014. – 52б.
2. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: Раннур, 2000. – 456 б.
3. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар Тулыландырылган 2 нче басма . – Алабуга: К(И)ФУ АФ нәшрияты, 2012. – 137 б.
4. Махмутов М.И. Избранные труды: В 7 т. Т.4: Современный урок и педагогические технологии развития мышления/ Сост. Д.М. Шакирова. – Казань: Магариф-Вакыт, 2016. – 375 с.


## ВАХИТ ИМАМОВНЫҢ ПОВЕСТЬ ҺӘМ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ТЕЛ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


Госсамова Т.?

МББУ “Актаныш 1 нче гомуми белем бирү мәктәбе” укучысы

Фәнни җитәкче: Галиева Л.Р.


Татар халкы тамырлары ерак гасырларга барып тоташа торган бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия. Безнең халык үзенең күп гасырлы әдәбияты, сәнгате һәм мәдәниятенең башка тармаклары тарихы белән хаклы рәвештә горурлана ала. Бу тарих кешелек яшәешенә үзенең талантлы шәхесләре, үлемсез әсәрләре, әдипләре, галимнәре белән кереп калды. Халкыбызның әле дә булса милләт буларак саклап килгән асыл сыйфатларының берсе - үткән тарихка һәм үз тамырларына гамьле мөнәсәбәттер мөгаен. Тарих белән бүгенге көн арасында төргәкләнгән озын юллар ята. Ә бу төргәкне сүтүдә, тарихыбызны өйрәнүче, бүгенге көндә әби-бабаларыбызның, җирлегебезнең үткән юлын барлаучы якташ язучыбыз Вахит Имам иҗатына тукталасым килә. Вахит Имам исеме киң мәдәни җәмәгатьчелектә татар тарихын җентекләп өйрәнгән, бүгенге көндә дә

үз эшен дәвам иттерүче тарихи романнар авторы буларак билгеле. Язучы булып, каләмең белән шәхесеңне раслый алу- үзе бер фидакарьлек. Бу көч сирәкләргә бирелгән. Вахит Имам- әнә шундый сирәкләрнең берсе. Язучы каләме еллар агымында чарланган, һәрдаим эзләнергә, яңалык ачарга, дөреслекне расларга, үткәнебез белән горурланырга чакыра ул. Вакыт вакыйгаларны аек акыл, һәрьяклап үлчәүгә салып бәян итә. Язучының тел, стиль үзенчәлекләре дә үзгә. Берничә вварианткa тукталып китик. Мәсәлән: **Вахит Имамның повесть һәм хикәяләрендә фонетик һәм морфологик диалектизмнар.** Сузыклар өлкәсенә караган үзенчәлекләрдән түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин.

-*Ниемә дип атлы казак кебек ишек төбендә таптанасыз әле? Кергән бер кеше артыннан идән сөртергә минем килен булып төшкән чагым түгел.* ("Мосафирлар" 90 нчы бит)

-*На старт.. Ниемә дип ярты метр алга чыгасың, Расих? Хәрәмләшми генә ярыш!* ("Ир канаты" 62 нче бит)

***Ниемә- нәрсәгә***

Монда юнәлеш килешендәге сорау алмашлыгын кыскарту һәм I зат кушымчасы ялгау күренә

Әдәби әсәрләрдә әдәби тел нормаларына туры килмәгән тагын бер күренеш – рус алынмаларын татар сөйләменә яраклаштырып куллану. Мондый сүзләр шулай ук персонажлар телендә генә очрыйлар һәм шактый нык үзгәртелеп әйтеләләр, башлыча фонетик үзгәреш кичерәләр. Аерым бер диалектка яки сөйләшкә генә карасалар да, әлеге сүзләрне, һәр төбәктә үзенчә әйтелгәнгә күрә, шартлы рәвештә диалекталь күренешләр рәтенә кертергә мөмкин.

-*Ничава, бер кичкә кер мичкә, - дип, Сәлимҗан башта сер бирмәскә маташкан иде дә, ике- өч сәгатьтән соң тәмам җегәре бетте күрәсең, чалгысын ташлап, янә әйрән янына юнәлде.* ("Сыйфат карты" 120 нче бит)

***Ничава-ничего***

-*И, бу хәтле расхутланырга кирәкмәс иде, апакаем. Андый киемнәр киеп йөрер чагыммыни?* ("Тол хатыннар" 126 нчы бит)

***Расхутланырга-расходоваться***

*Куркуымнан дер калтырап сикереп торган идем, каршымда прсидәтел Мифтах абзый.*

***Прсидәтел-председатель***

Алынма сүзләрне бозып әйтү нигезендә дә гади сөйләм сүзләре барлыкка килә. Алар ярдәмендә автор образларының гадилеген, хәйләсез наданлыкларын ача алган. Алар белемнәре аз яйсә бөтенләй надан булсалар да, үзләрен белдекле күрсәтү өчен, русча "сөйләшәләр". Мәсәлән: ***"Ыштубы"*** (Чтобы), ***"Лишбе"*** (Лишь бы) ("Ир канаты" 48 нчы бит)

-*Нүжәли шул бөкре карт хаклы булган инде, нүжәли? Ат карарга адәм рәтле кеше юк бит тәки, вәт әкәмәт!* ("Ир канаты" 16 нчы бит)

-*Тәки сагыз булдың, валлаһи. Нүжәли инде мин сиңа дус түгел.* ("Ир канаты" 24 нче бит) ***Нүжәли (неужели)*** сүзен авыл кешесе сөйләмендә рәхәтләнеп куллана.

**Варваризмнарны** – чыганак телдәге үзенчәлекләрен саклаган чит тел сүзләрен куллану, гомумән, В.Имамовка хас үзенчәлекләрнең берсе. Ул аларны юмористик максатларда файдаланган.

Ат ярышына барырга әзерләнгән егетләргә, үзенең мотоциклын өстен күрүче, аны бернинди ат белән дә чагыштырмаучы егет үз көндәшләренә "брат" дип эндәшә.

-*Ну, сүзеңнән танма инде,* ***брат****. Сынап карыйбыз хәзер синең кемлекне. Артта каласы булсаң, белеп тор- синең белән башка сөйләшү юк. (*"Ир канаты" 63 нче бит). "Брат" сүзен (рус сүзе) ул бераз шаянрак тонда, ярышка баскан көндәшенә бераз ачу һәм масаю хисләрен белдерү өчен кулланган. Бу сүзләр сөйләмне чүпләмиләр. Мондый мисаллар аның хикәяләрендә дә очрый.

Язучының әсәрендә алып фигылендәге –**ып** кушымчасы төшеп кала һәм фигыль кыскартылып кулланыла

*Бактың исә, үзләре ялкау хатыннарының сталавайдан апкайткан әчегән кәбестә шулпасына риза булып яшиләр.* ("Мосафирлар" 91 нче бит)

***Апкайткан- алып кайткан***

Киң таралган фонетик күренеш –**иде** ярдәмче фигылендәге **д** авазы төшеп калып, аның урынына **и** авазы куллану. Еш кына бу сүз алдагы төп фигыльгә яки башка сүзгә кушылып, берегеп әйтелә

-*Әслах белән Нурми малайлары янына кергәнием. Кунихка ат илтергә риза булмаганнар.* ("Ир канаты" 22 нче бит)

***Кергәнием – кергән идем***

*Трактор белән рәттән мәктәптә маллар фәнен керт идең син, егеткәем, ак сакаллы карт булырыең.* ("Ир канаты"14 нче бит)

***Булырыең- булыр идең***

Актаныш ягында туып - үскән кешеләргә хас төрле лексик - семантик төркемнәргә караган диалекталь сүзләргә мисалларны күрергә мөмкин:

*Иске сәке былтанлый башлагач, менә, яңасын юнәттем.*

***Былтанлый-селкенә, какшый***

***Юнәттем-юнәлттем, таптым***

Димәк, Вахит Имам – бүгенге көннең актуаль темаларын һәрвакыт күз уңында тотучы публицист.

Әдәбият

1. Әдәбият белеме сүзлеге А.Г.Әхмәдуллин - К. Татарстан китап нәшрияты, 1990
2. "Ир канаты" Вахит Имамов Казан, 1988 ел
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.-К. Татарстан китап нәшрияты, 1979
4. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге Г.Х.Әхәтов -К. Татарстан китап нәшрияты, 1982
5. Халык афоризмнары К.М.Миңнуллин, Х.Ш.Мәхмүтов. Җ.К. Кәлимуллин

"Мәгариф",2002

6. Хәзерге татар әдәби теле Зәкиев Мирфатыйх, Сафиуллина Флера. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМ-КҮНЕКМӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ

Григорьева Е.Н.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

“Дәрес – мәктәптә укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы. Ул процесс– укытучы һәм укучының бердәм-эзлекле эшләве. Укучылар зур активлык күрсәткәндә, укытучы аның активлыгын уңышлы оештырганда гына дәресләр нәтиҗәле була ала” [Вәлиева 2000: 66].

Заманча дәреснең әһәмиятле аспектлары түбәндәгечә формалаша:

1)Дәреснең максатчан һәм мотивлашкан булуы; максатчан һәм мотивлашкан булуы; 2)дәреснең максаты төгәл һәм конкрет булуы, куелган максатка көтелгән нәтиҗәләрнең җавап бирүе, ягъни тәнгәл килүе зарури; 3)дәреснең нәтиҗәлелеге укучыларның билгеләреннән, материалны үзләштерү дәрәҗәсеннән чыгып түгел, ә укучыларның эшчәнлегеннән чыгып бәяләнергә тиеш. Шул ук вакытта дәрестә белем алуның әһәмияте кимеми, киресенчә, булган белемнәрне гамәлдә куллана белүгә игътибар гын аарта; 4)дәреснең яңа белем бирү максаты – укучыларның үзләре алдына мөстәкыйль максат куюлары һәм аңа бару бурычларын билгеләп эшчәнлек оештырулары; 5)заманча дәреснең эшчәнлеккә корылган булуы; 6)яңача корылган дәреснең мәгънәсе – ул белем алу процессы вакытында куелган проблеманың укучылар тарафыннан танып-белү эшчәнлеге аша чишелүе; 7)дәрестә никадәр дәрәҗәдә мөстәкыйль эшчәнлеккә күбрәк урын бирелсә, шул кадәр яхшырак (бу очракта укучылар текст өстендә эшләп проблеманы чишәргә өйрәнәләр һәм мәгълүмати компетенцияләргә ия булалар); 8)заманча дәрес белем бирү процессында дискуссия, видеотәнкыйть, эшлекле һәм рольле уеннар, ачык сораулар кебек эшлекле методлар һәм алымнарның актив кулланылуның белән аерылыптора [Мөхәммәтҗанова 2015: 28].

Дәрестәге эшнең күләме һәм эзлеклелеге дәүләт программасы тарафыннан билгеләнә. Дәреснең максаты укучыларга билгеле бер күләмдә белем бирү генә түгел, программада каралган кадәр күнекмәләр булдыру. Шуңа күрә дәрестә эш өйрәнүне дә, ныгытуны да кабатлауны да үз эченә ала. Дәрестә өйрәнелә торган материал барлык укучылар өчен дә мәҗбүри, шуңа күрә аңлау дәрәҗәсен күзәтү, игътибарда тотуны, бәяләүне таләп итә.

Бәяләү проблемалары хәзерге заман мәгарифенең төп проблемаларының берсе булып тора. Белем бирү казанышларын бәяләүдә заманча дөнья тенденцияләре мәктәп программаларын үзләштерү дәрәҗәсен билгеләүгә түгел, ә укучыларның мәктәптә алган белемнәрен һәм тормыш ситуацияләрендә куллану сәләтен бәяләүгә юнәлтелгән.

Уку нәтиҗәләренә карата таләпләр белем бирү процессын оештыруда сизелерлек үзгәрешләрне күз алдында тота: укытуда системалы эшчәнлек алымына күчү һәм уку нәтиҗәләрен бәяләүдә яңа алымнар булдыру. Контроль – белем бирү сыйфаты белән идарә итү системасының аерылгысыз бер өлеше, укытучы һәр укучыны контрольдә тота һәм бәяләүне оештыра. Куелган билгеләрнең дөреслеге һәм объективлыгы һәрвакыт беренче урында тора. Белем бирү процессының уңышлы эшләве белем бирү максатларының, эчтәлегенең һәм алымнарының ни дәрәҗәдә заманча булуы белән бәйле. Билгеле булганча, укучыларның белемнәрен тикшерү һәм бәяләү максаты – аларның белем сыйфатын, аларның үсеш дәрәҗәсен тәэмин итү дигән сүз.

Хәзерге уку-укыту практикасында уку нәтиҗәләрен бәяләүнең иң еш очрый торган ысулы-белем һәм осталыкны бәяләү.

“Укучыларның белемнәрен бәяләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына: белемнәрнең күләме (билгеләнгән укыту программасы чикләрендә) уку материалының үзләштерелү дәрәҗәсе һәм алынган белемнәрнең ныклылыгы, алынган белемнәрне уку эшендә һәм төрле практик биремнәрдә куллана белү, белемнәрне язма һәм телдән сөйләп бирә белү, укучы тарафыннан ясалган ялгышларның саны һәм характеры” [Хуҗиәхмәтов 2002:160].

Дәреснең һәр этабында уку эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү укучыларга хаталарны бетерү буенча эшне мөстәкыйль планлаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Контроль ысуллары түбәндәгеләр: телдән сораштыру, язма контроль эш, диктант, зачет, мөстәкыйль эш, контроль эш, практик эш, лаборатор эш, тест. Контрольнең традицион булмаган ысуллары да бар. Дәресләрдә тикшерү эшләре һәр темага кроссвордлар, башваткычлар, ребуслар, шарадлар, викториналар да булырга мөмкин. Контрольнең традицион методларыннан тыш, методистлар тарафыннан яңа тикшерү чаралары тәкъдим ителә: кейс, проектлар, портфолио, тестлар. Һәр нәтиҗәнең үзэшчәнлеген бәяләү критерийлары була.

Дәрестә укучыларның үз эшчәнлекләрен бәяли белүләре дә заманча дәрес кысаларында бик мөһим фактор. Аны дәреснең төрле этапларында тормышка ашырырга мөмкин.

Әдәбият

1. Вәлиева Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиева, Г.Ф.Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 455б.
2. Мәхәммәтҗанова А.Х. Татар теле һәм әдәбияты укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар/төз. А.Х.Мөхәммәтҗанова, Р.Б.Камаева. – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. – 68б.
3. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. – 351 б.

## ШКОЛЬНЫЙ УЧЕБНИК КАК СРЕДСТВО РАЗВИТИЯ ПОЗНАВАТЕЛЬНОЙ АКТИВНОСТИ УЧАЩИХСЯ

Григорьева Е.Н.
студент Елабужского института КФУ
Научный руководитель: Камаева Р.Б.

Сегодня нашему обществу нужны самообразованные, саморазвитые личности. Оно немыслимо без чтения, так как основной объем учебной информации школьники получают именно через чтение. К тому же, следует признать, мало прочитать, нужно осмыслить, понять прочитанное. Познание мира не осуществляется без формирования потребности в чтении. Учащиеся не должны получить готовую информацию, где учитель все расскажет и покажет, а сами должны уметь обращаться с учебником по предмету. Если ученик знает, как учиться в школе, как работать с книгой, как получать знания от учителя, как искать и находить нужную информацию, чтобы решить ту или иную проблему, то ему легче будет повысить квалификацию, получить дополнительные знания, что и нужно в жизни.

Сегодня педагог должен объяснить учащимся, что работа с учебником – это важнейшее умение самообразования, и ознакомить их с многими функциями как информационная, систематическая функция, функция закрепления, самоконтроля, интеграции, мотивации и самообразования. Педагог должен уметь убедить, что учебник – его помощник [Хакимова 2019: 2].

Формы познавательной деятельности учащихся многообразны:

1. Индивидуально – обособленная форма учит индивидуальному труду, способствует воспитанию самостоятельности учащихся и служит подготовкой для занятий самообразованием.

2. Фронтальная форма познавательной деятельности. Она предполагает выполнение общих заданий всеми учениками класса для достижения ими общей познавательной задачи.

3. Групповая форма организации познавательной деятельности. Успех осуществления этой формы познавательной деятельности, в первую очередь, зависит от тщательности её подготовки учителем и его умения уделить внимание каждой группе.

4. Коллективная форма познавательной деятельности позволяет разнообразить уроки, создать ситуацию успеха, мотивировать учащихся на самостоятельное добывание знаний. Наличие познавательного интереса к учебному предмету способствует повышению активности учащихся на уроках, росту успеваемости и самостоятельности при выполнении практических и теоретических задач [Гинятуллина 2018: 5].

Рассмотрим содержание школьного учебника и его значение в развитии познавательной активности учащихся на примере учебника 8 класса по татарскому языку (Татар теле) для общеобразовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык как родной) авторами, которой являются Р.К.Сагдиева, Г.И. Хайруллина. В учебнике даны материалы по повторению пройденных материалов в 5-7 классах, изучение синтаксиса, повторение материала,

изученных в 8 классе, в приложении даны словарный материал по антонимам и синонимам.

В соответствии с требованиями ФГОС при формировании коммуникативных умений в учебнике предлагаются задания, которые направляют мысль учеников на создание текста в соответствии с определенной ситуацией, т.е. указывается, почему ставится эта проблема, какова цель высказывания, его возможный адресат. В центре оказываются проблемы общения.

Особое значение отводится в учебниках обучению развернутым устным ответам; обучению устному речевому этикету, обучению орфоэпическим нормам. Именно работа над устными ответами помогает школьникам усвоить язык предмета и готовит их психологически к публичным выступлениям. Необходимо отметить, что в учебниках предусмотрена не только работа со словесной информацией текста. Предлагаются задания, требующие смысловой обработки текстовой информации, поданной в разных формах: работа с таблицами, схемами, рисунками. Предложенные коммуникативно-ориентированные задания способствуют развитию эмоциональной сферы ученика, позволяют ему индивидуально оценивать усваиваемое содержание. [Сагдиева 2020: 19].

На формирование регулятивных, познавательных и коммуникативных универсальных действий нацелена и работа со словарями:

- задания, ориентированные на сопоставление сведений из различных словарей, формируют познавательный интерес к такого рода изданиям;

- информацию, полученную при работе со словарем, ученик может использовать при аргументации своей точки зрения, что развивает речь учащихся, формирует информационно-коммуникативные умения.

Работу со словарем ученик может проводить и самостоятельно, что способствует укреплению его регулятивных универсальных учебных действий.

Культуроведческая компетенция также нашла свое отражение в учебнике. В учебники включены иллюстративные материалы (картины русских и татарских художников). Это помогает ребенку постичь красоту, развивает языковое чутье, воспитывает эстетический вкус.

Работа с учебником даёт возможности использовать разные способы усвоения учебного материала. Система упражнений, справочный материал, богатейший наглядный материал предполагают «пошаговый» характер формирования умений и навыков, нацеливает учащихся на планомерную самостоятельную работу. Удачно реализуются задачи воспитания учащихся, огромную воспитательную нагрузку несут связные тексты и комплекс вопросов и заданий к ним [Сагдиева 2020: 56].

Материалы излагаются очень доступно, последовательно, с постепенным наслоением информации: тексты, диалоги, упражнения на закрепления грамматических, фонетических и лексических анализов, на развитие устной речи (монологической и диалогической). Учебники снабжены иллюстрациями и таблицами, что способствуют лучшему восприятию материала. Авторы учебника руководствуются целью формирования у учащихся коммуникативной

компетенции. А коммуникативность, будучи основным подходом в обучении языку, органически связывает развитие речевых навыков и умений с теоретическим осмыслением языкового материала и способствует системному овладению основами диалогического и монологического общения на изучаемом языке. Предложенные в пособии тематические комплексы упражнений в целом отвечают таким требованиям, как рациональность, последовательность и способствуют формированию у учащихся как лингвистической, так и коммуникативной компетенций.[Сагдиева 2020: 116]

Таким образом, среди многих идей, направленных на совершенствование учебного процесса, одной из самых значимых является идея формирования и развития познавательной активности учащихся в современной школе. Одним из средств развития познавательной активности является умение использовать в учебном процесс школьный учебник. Если учащиеся умеют использовать учебник в процессе получения образования, то это способствует развитию познавательной активности учащихся и реализовать цель изучения татарского языка –развивать личность школьника, его мыслительных, познавательных, речевых способностей,формировать универсальные учебные действия (УУД), ознакомить с доступнымиучащимся способами и приемами самостоятельного изучения языков и культур, в том числе сиспользованием новых информационных технологий; приобщить учащихся к культуре и национальным традициям татарского народа, создать необходимые условия для формирования таких личностных качеств, как доброжелательное отношение, уважение и толерантность к другим народам, компетентность в межкультурном диалоге и стать личностью своего народа.

**Литература**

1. Гинятуллина А. Управление познавательной деятельностью обучающихся при изучении татарского языка и литературы. – https://infourok.ru/doklad-na-temu-upravlenie-poznavatelnoy-deyatelnostyu-obuchayuschihsya-pri-izuchenii-tatarskogo-yazika-i-literaturi-2484692.html (дата обращения: 10.10.2023)

2. Сагдиева Р.К. Татарский язык. 8 класс : учебник для общеобразовательных учреждений / Р.К. Сагдиева. – Казань: Изд-во «Магариф -Вакыт».-Казань, 2020. – 221с.

3. Хакимова Л.С. Учебник как средство развития познавательной и творческой активности учащихся. – https://xn--j1ahfl.xn--p1ai/library/uchebnik_kak_sredstvo_razvitiya_poznavatelnoj_i_tvo_115253.html (дата обращения: 15.10.2023).

## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ – “КРЕСТЬЯН ҖЫРЧЫСЫ”

Гурьева К.С.
Мамадыш шәһәренең Кызыл Тау урта белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Антонова Д.А.

Таҗи Гыйззәт – татар совет драматургиясенә нигез салучыларның берсе. Аның иҗаты һәм театр сәнгате арасындагы мөнәсәбәтләрен шартлыча өч чорга бүлеп карарга мөмкин.

1920-1934 еллар әдипнең иҗат юнәлешен, сәнгатьтәге урынын ачыклау еллары булып тора һәм аның беренче башлангыч иҗат чоры буларак билгеләнә. Ул Таҗи Гыйззәтнең 1920 елның июнь аенда Самара студиясендә белем ала башлап, Академия театрында «Чаткылар» әсәрен куйдыруга кадәрге вакыт аралыгын тәшкил итә [Арсланов, 2023:2].

Бу чорда татар театры эзләнү, географик яктан киңәю чоры кичерә. 1920 елда «татар театрының атасы» Габдулла Кариев үзенең иҗат һәм тормыш юлын тәмамлагач, аның эш принципларын кабул итеп алган Кәрим Тинчурин бөтенләй яңа тип театр төзүне максат итеп куя. Бу коллективта барлык актерлар да, режиссерлар да бертигез булып санала, һәм алар бер үк күләмдә хезмәт хакы ала. Рольләр дә кечкенәгә, зурга бүленми. Билгеле бер актер бүген халык сәхнәләрендә катнашса, икенче көнне ул төп рольдә уйный. Театрның һәр техник, административ яки иҗади проблемалары күмәкләшеп хәл ителә. Шуңа күрә шартлы рәвештә аны «тигезләр театры», «коллектив театр» яки «геройсыз, лидерсыз театр» дип атап булыр иде [Ахтямова, 2023:1].

К. Тинчурин әлеге яңа театр принципларын Самара студиясен тәмамлаучылардан төзелгән труппада тормышка ашыра башлый. Әмма 1921 елда илдә барлыкка килгән коточкыч ачлык, эпидемия труппаның эшен туктата.

Таҗи Гыйззәт үзенең иҗатын әнә шул Самара студиясендә актер ролендә башлап җибәрә. К. Тинчурин булачак драматургка тәүге адымнарын ясарга ярдәм итә, аны сәнгать дөньясына алып керә [Арсланов, 2023:2].

Таҗи Гыйззәт иҗатының беренче чорында зур йогынты ясаган икенче зур шәхес – актер, режиссер Зәйни Солтанов. Ул Самара студиясендә сәхнә теле дәресләрен алып бара. «Бәхетсез гаилә» дип аталган иң беренче пьесасын да Таҗи Гыйззәт беренче булып аңа күрсәтә. Шәкерт белән остаз арасындагы мөнәсәбәтләр, киңәш-табыш итү ТДАТ сәхнәсендә озак еллар буе дәвам итә [Арсланов, 2023:2].

Гомумән, Таҗи Гыйззәт, драматург буларак, театрда туа, шунда үсә, камилләшә, күп кенә артистлар һәм режиссерлар белән аралашып, театрның серләрен үзләштерә. Ул театрның үз кешесенә әверелә, аның шатлыкларын да, кайгы-хәсрәтләрен дә бергә кичерә [Сарымсаков, 1990:109].

Күп еллар дәвамында театр өлкәсендә эшләү дәверендә Таҗи Гыйззәт, рус һәм дөнья әдәбияты классикасы, совет һәм татар драматурглары, шул исәптән үзенең дә әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә катнашып, дистәләрчә истә калырдай, оригиналь сәхнә образлары иҗат итә [Гыйззәтов, 2023:1].

1922 елда әдип үзен драматург итеп таныткан иң беренче әсәрен «Талир тәңкә» исемле драмасын яза. Инде монда ук ул үзәктә революция алды татар авылы тормышының социаль күренешләрен сурәтли, киеренке драматик конфликт нигезендә крестьян образларын гәүдәләндерә. 1923 елның март аенда ул Татар дәүләт театры сәхнәсендә куела. Тамашачылар аны яратып кабул итә

[Гыйззәтов, 2023:1]. Беренче әсәренең шулай уңыш казануы яшь драматургка иҗади дәрт өсти.

1930 елларда Т.Гыйззәт, сюжет сызыкларын драматик яктан тагын да кискенләштереп, әлеге әсәренә бераз үзгәртүләр өсти. Драмада яңа образлар урын ала, яңа вакыйгалар кертелә. Ахырда әсәрнең исеме дә үзгәртелә. Ул «Чаткылар» дип атала башлый. Шушы исем белән пьеса 1934 елдан башлап илдәге бөтен татар театрларын гизеп чыга һәм бүгенгә кадәр сәхнәдән төшми уйнала килә [Гыйззәтов, 2023:1].

Икенче чор 1934-1955 еллар аралыгын тәшкил итә. Бу вакытта Таҗи Гыйззәт иҗатта зур биеклекләр яулаган, халык арасында танылган драматург була. Бүгенге көндә аның иҗат мирасының иң күркәм мисаллары булып торган күп кенә әсәрләре дә нәкъ менә шул вакытта язылган. Шуңа күрә бу аның иң актив эшләгән чоры булып тора [Арсланов, 2023:2].

“Ташкыннар” трилогиясендә Таҗи Гыйззәт крестьян халкының революцион күтәрелешләргә килүен үзенә күрә бер романтик төс белән тасвирлый. Үзе дә крестьян катлавыннан чыккан кеше буларак, моның белән горурлана да шикелле [Сарымсаков, 1990:110].

“Ташкыннар” драмасы аша үзенең максатына юл тота: үзенең уй-фикерләре, кайтып-кайтып үзенә тартып торган темасы татар крестьяннарының зур восстаниесен күрсәткән әсәр яза. Татар крестьяннарының зур күтәрелешен, бер үк вакытта аларның хәтта берничә губерна кузгалышларын да чагылдырырга уйлый. Әмма моның тормышка ашмый калуы кызганыч, ди [Сарымсаков, 1990:110].

Т. Гыйззәт драматургиясе – театр сәнгате алдына шактый авыр бурычлар куйган киң агышлы, иҗади мирас. Аның язучылык каләме чорның актуаль проблемаларына, җәмгыятьтәге, бигрәк тә крестьян халкы арасындагы социаль үзгәрешләргә үтә сизгер булуы белән характерлы. Егерменче еллар ахырында һәм утызынчы елларның беренче яртысында ул авылда социалистик мөнәсәбәтләр урнаштыру, яңа кеше формалашу процессын тасвирлаган өч-дүрт пәрдәле агитацион пьесаларын иҗат итә. Мәсәлән: “Ил үскәндә” (1929), “Көрәш” (1931), “Акташ вакыйгасы” (1932), “Ударник Мохтар” (1932), “Җиңү бәйрәме” (1933), “Фамилиясез тимерче” (1933) һ.б. Үз вакытында бу пьесалар мөһим тәрбияви максаттан күп кенә авыл сәхнәләрендә, колхоз-совхоз театрларында еш куела. Драматург әсәрләрендә авылдагы социаль үзгәрешләрне сәнгатьчә чаралар белән тирәнрәк, тормышчанрак яктыртып осталыгын үстерә бара.

Т. Гыйззәтнең 1935 елда язылган «Мактаулы заман» комедиясе – аның бу темага язылган әсәрләреннән иң уңышлысы. Монда автор шәхси мәнфәгатьләр урынына гомуми максатлар белән яши башлаган колхозчы крестьяннарның реалистик образларын тудыра [5].

1937 елның 5 ноябрендә беренче тапкыр «Ташкыннар» драмасы күрсәтелә, анда театрның актерлык һәм режиссерлык сәнгате чын-чынлап сәхнә реализмына ирешә. Революционерлар-большевиклар кул астында крестьяннарның көрәш эпизодлары күрсәтелә.

Т. Гыйззәт ижатында психологик драма сыйфатларына игътибар итеп, бу проблеманы эшләүгә зур өлеш кертә. Психологик драма язучының геройларның киңәйтелгән, күп планлы характеристикасында мөмкинлекләрен чикләми. Әле үзенең хезмәткә кадәр булган ижатында, 30 нчы еллар башында, катгый шигарьләргә карамастан, яшь драматург геройларның эчке дөньясын тирәнәйтергә омтыла. Аның көндәлек актерлык практикасы да шул хакта сөйли [Абдуллин, 1985:82].

Т. Гыйззәтнең драма әсәрләре үз вакытында ук әдәби һәм театр тәнкыйте, иң мөһиме, тамашачылар һәм укучылар тарафыннан югары бәяләнә бара. Аның милли драматургиябезгә һәм театрыбызга адып килгән яңалыклары һәм тематикага, һәм сәнгатьчелек өлкәсендәге табышларга карый. Иң зур өлеше, күрәсең, шунда: ул сәхнәдә татар крестьяны образын, татар авылы тормышын тулы һәм эзлекле чагылдыручы драматург була. Монда ул прозада Г. Ибраһимов, драмада М. Фәйзи, Ф. Бурнашлар башлаганнарны алга таба үстерә, тулы бер юнәлеш тудыра. Әхмәдуллин А. аны чын мәгънәсендә “крестьян җырчысы” дип атый [Әхмәдуллин 2002: 59]. Чөнки аның әсәрләрендә татар крестьяннарының иҗтимагый тетрәнүләр һәм социаль сугышлар чорындагы тулы бер ачы һәм гыйбрәтле язмышы чагылыш таба.

Шулай итеп, бай иҗаты белән үз чорының җанлы картиналарын тудырган, үзенчәлекле образлар иҗат иткән, XX йөз башы сәхнә әдәбияты традицияләрен 1960 елларга җиткереп, әлеге чорларны дәвамлы бәйләгән Таҗи Гыйззәтнең драматургия тарихында лаеклы урыны бар.

Әдәбият


1. Абдуллин Я., Хусаинов А. Классик татарской драматургии. // Коммунист Татарии. –1985. – № 8. – С. 77-82.

2. Арсланов Г. Үз театрын булдырган әдип. [Электронный ресурс] // Мәдәни Җомга. URL: http://madanizhomga.ru/index.php/news/sh%D3%99hesl%D3%99rebez/z-teatryin-buldyirgan-dip (мөрәҗәгать итү вакыты: 07.10.2023)

3. Ахтямова Г. Не должны забыть Тази Гиззата. [Электронный ресурс] // Национальная библиотека Республики Татарстан. URL: https://kitaphane.tatarstan.ru/gizzat/memories/akhtyamova.htm (дата обращения: 07.10.2023)

4. Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 61.

5. Сарымсаков Ш. Бөек драматург Таҗи Гыйззәт // Казан утлары. – 1990. – № 9 – Б. 109-110.


## МӘКТӘПТӘ СИБГАТ ХӘКИМ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ


Гыйлаҗев А.Л.

КФУның Алабуга институты студенты

Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Тел ул шигърият дөньясында – гаҗәеп корал. Кирәк кадәр сүз хәзинәсе телне яхшы белгән һәр кешедә дә бар. Тирә-як дөньяның никадәр шигъриятле икәнен бик күп кеше тоя ала. Шигърият ул – сүз тукымасына киендерелеп кенә бирелә алмый, бәлки сүз ул – әдип кулында үзе үк поэзия. Әмма образлы сүз кулланышының яки сүз ярдәмендә сәнгатьле образ тудыруның үзенчәлеге һәрвакытта да авторның сәләте яки тәҗрибәсенә генә бәйле түгел. Ул – шигъри мәктәп нәтиҗәсе дә булырга мөмкин.

С.Хәким кебек күләмле шигърияте булган шагыйрь иҗаты – тикшеренүләр өчен кыйммәтле чыганак. С.Хәкимнең тулы бер дәверне колачлаган шигърият көченең сере Тукайлардан, Такташлардан, Туфаннардан мирас итеп алган затлы шигъри телгә ия булуында.

Тел чараларын дөрес сайлап алу, сөйләмне баетуда аларны төрле мәгънә һәм эмоциональ-экспрессив төсмерләр бирү өчен файдалану, кешеләрнең иҗтимагый аралашуында телдәге үзенчәлекләрне система рәвешендә билгеле бер максатка туры китереп сөйләмдә куллана белү принциплары стиль төшенчәсенең төп нигезен тәшкил итәләр.

“Стиль – язучының яшәү шартларыннан, тормыш тәҗрибәсе, яшәешне төшенү дәрәҗәсе, характеры, фикерләү рәвешеннән килеп чыга торган һәм әсәрләрнең тематикасында, сюжет-композициясендә, образлы телендә чагылучы үзенчәлекләр бердәмлеге [Хатипов 2000: 293].

С.Хәким Бөек Ватан сугышына кадәр үк әдәбият мәйданына килеп, хис тойгыларга бай, музыкаль яңгырашлы, сурәтләү алым-чараларын мул кулланып, лирик шигырь, поэмалар иҗат иткән әдип сугыштан соңгы татар поэзиясенең халыкчан юнәлештә үсеп китүенә җитди өлеш кертә. Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлилләрдән килгән матур традицияләрне, чордашы Х.Туфан белән бергә, үзенчәлекле үстереп, эстафетаны бүгенге көн шагыйрьләренә тапшырган С.Хәкимнең шигърият диңгезендә лаеклы урыны бар.

С.Хәкимнең башлангыч чор иҗатында, беренче поэмаларында төсмерләнгән поэтик фикерләү һәм язу стиле, нечкә лиризм, хис-тойгы ихласлыгы, халыкчан образлылык, шигъри формадагы төгәллек һәм пөхтәлек алга таба тагы да камилләшә, сәнгатьчә яңа сыйфатлар белән тулыланып, сугыштан соңгы еллардагы тормыш фәлсәфәсен, әледән-әле алмашынып торган вакыйга-үзгәрешләрнең тарихи мәгънәсен, аларның кеше шәхесендәге чагылышын шигъри образларда калку итеп гәүдәләндергән олы хисле, тирән фикерле, гуманистик рухлы поэзия булып формалаша. Ватан сугышы исә шагыйрьнең гуманистик тойгыларын, ватандарлык хисләрен тагын да тирәнәйтә төшә. Сугыш темасы, гомумән, аның бөтен иҗатында калку итеп яктыртыла. «Курск дугасы» (1948), «Дала жыры» (1948), «Бакчачылар» (1952), «Дуга» (1968), «Күги» (1983) кебек поэмаларында шагыйрь сугыш кырындагы күренешләрне бөтен куркыныч дәһшәтендә җанландырып күрсәтү һәм кеше образларының драматик язмышларын тәфсилле тасвирлау белән бергә кеше һәм сугыш, халык батырлыгы, милләт язмышы турындагы уйланулары, фәлсәфи фикерләре белән үреп бара [Хәсәнова 2017: 75].

С.Хәкимнең гомере буена игътибарын биләп торган мөһим темаларның тагын берсе ул — туган җир темасы. Үзе туып үскән Казан арты төбәгенә, аның табигатенә, кешеләренә мәхәббәт хисе шагыйрьнең бөтен иҗатын озатып бара. Казан арты төбәге шагыйрь күңелендә бөтен Татарстанның, бөтен татар халкының шигъри образы рәвешендә гәүдәләнә.

**Әдәбият**


1. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
2. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен).7 нче с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кисәк/ Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я Гарифуллина, Ә.Н Сафиуллина. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2017. – 143 б.
3. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003 –295б.
4. Хатипов Ф. М. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.


## Ф.ШӘФИГУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТАБИГАТЬ ТЕМАСЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ


Гыйлаҗев С.И.,

Яр Чаллы шәһәренең 7 нче гомуми белем бирү мәктәбе укучысы

Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Татар балалар әдәбиятында кеше һәм табигать гармониясен сөйләү традициясе бик күптәннән килә. Г. Тукайның ничәмә-ничә буын балалар укып үскән һәм гомергә күңелдә калган әсәрләре, Г. Ибраһимовның җыр кебек укыла торган табигать күренешләре, А. Алишның табигать серләрен ачкан матур әкиятләре – болар барысы да соңгы елларда иҗат иткән язучыларга йогынты ясамый калмагандыр, һәм аларның әсәрләрендә табигать белән көрәштән бигрәк, аны яклау, беренче матурлыгы, байлыгы белән саклау мотивлары өстенлек алу да шул традициянең дәвамы булса кирәк.

XX гасырның җитмешенче елларында табигать темасына яңа герой алып килгән язучыларның берсе – Фаил Шәфигуллин. Аның әсәрләрендә укучылар үзләренең эчке дөньяларына якын тормышны күрәләр, үз тиңнәре белән очрашалар, геройларның кичерешләрен бик теләп уртаклашалар, табигать гүзәллеген тоярга өйрәнәләр.

"Язучы Фаил Шәфигуллин, нигездә, юморист буларак танылды. Ә инде гомеренең соңгы елларында ул чәчмә әсәрләр язуга басым ясады. Әмма шигърият аның күңеленнән китмәде", – дип искә ала Эльмира Шәрифуллина.

Фаил Шәфигуллинның үзе исән вакытта ук өч шигырьләр җыентыгы басылып чыга: "Яңа ел бусагасында" (1967), "Гашыйк" (1969), "Дулкынга дулкын" (1977).

Табигать белән кеше мөнәсәбәте, алар арасында гармониягә ирешү мәсьәләләре Фаил Шәфигуллинның шигырьләрендә дә ачык чагыла. Табигать

күренешләрен чагылдыру аша язучы күп кенә проблемаларны чишү максатын куя. Табигать күренешләрен сурәтләү аркылы кешенең сыйфатлары, күңелендәге хисләр яктыртыла. Табигать кешеләрне үзе белән килешеп яшәүләрен тели.

"Кыз һәм табигать" балладасында бу ачык чагыла. Илдә сугыш бара. Кешеләр сугышка китеп баралар. Табигать моны ошатмыйча, Җилгә мөрәҗәгать итә:

"Киттеләр агайлар
Кайтмаслар тиз генә,
Хәзер бу җирләргә
Без хуҗа, без хуҗа.
Таш итеп катырыйк
Җирнең һәр карашын,
Көйдереп бетерик
Бодаен, арышын.
Ач булгач, горур зат
Йә нишли ала соң?
Шуннан соң ул миңа
Баш ими карасын..." [Шафигуллин 2006: 55].

Әтиләренә алмашка кызлары-уллары килә. Табигать моны ошатмыйча, җил чыгара, болытларны җыйный, өермә уйната. Ләкин кыз боларны сизми дә. Ул әтисеннән калган, эшсез яткан тракторны алып, басуларны сөрүгә керешә. Давыл чигенә, басуларда орлыклар тишелеп чыга, игеннәр өлгерә. Табигать тә кыз белән килешеп тына.

"Туып үскән нигез ташларына" шигыре туган якны сагыну белән сугарылган.

Туган як нигезе инде хуҗасыз калган. Кычытканнар өй янын каплап алган, трә-як тынлыкка чумган, тормыш сүнгән. Кычытканнар нигез ташларын җиңгән. Ләкин кешене һаман туган ягы сагындыра, үзенә чакыра, ул аны онытмый.

" Авыру аккошлар күк боек ташлар,
Кем ул әнә, күзләрендә яшь бар.
Сезгә башын салып, ник елый?..
Йөрәгендә лә сез кемнәрнеңдер,
Кемдер күрә сезне төшендә гел –
Туып-үскән нигез онытылмый" [Шафигуллин 2006: 55].

"Сеңелем Марина" исемле поэмасында табигать күренешләре төп геройларның хис-кичерешләрен, аларга хас сыйфатларны ачыклауга ярдәм итәләр. Бу өзектә туган якның матурлыгына соклану, аны сагыну тойгылары өстенлек ала.

"Урамда кыш инде, Марина,
Һәр агач, һәр ботак кар гына,
Ай йөри төннәрен кар ялап,
Ай нәрсә, ул салкын, битараф.
(...) Су өсте яп-якты... көзгедәй.

Җир исе... Кайдадыр, ахры, җәй...
Онытылган зилзилә, давыллар,
Онытылган талчыгу, арулар.
Күп көннәр диңгездә үткәреп,
Рәхәт соң, әй, кайтып барулар.
Каршыда урманнар, тугайлар,
Каршыда якыннар, дус-ишләр.
Каршыда сандугач, тургайлар,
Ал таңнар, ак көннәр, саф кичләр [Шафигуллин 2009: 74-77].

Шулай итеп, Фаил Шәфигуллинның проза әсәрләрендә генә түгел, шигъриятендә дә туган як табигатенә соклану, табигать белән кешенең бәйләнешкә керүе һәм башка шундый мәсьәләләр чагылыш тапкан.

### Әдәбият


1. Аның турында каләмдәшләре // Мәйдан. – 2009. – № 11. – 119 б.
2. Шәфигуллин Ф. Бер малай, өч аргамак: Повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр. – 2005. – 270 б.
3. Шәфигуллин Ф. Сеңелем Марина: Поэма// Мәйдан. – 2009. – № 11. – 74-77 б.
4. Шәфигуллин Ф. Күзләрендә яшь бар: Шигырьләр // Мирас. – 2006. – № 9. – 54-59 б.


## ӘДӘБИ ДЕТАЛЬ ҺӘМ АНЫҢ ФУНКЦИЯЛӘРЕ


Гыйлаҗев А.Л.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.


Татар әдәбияты – татар халкының чал тарихлы бай рухи хәзинәсе, күңел матурлыгы, хисләре сафлыгы һәм матур хыялларының үткәне, хәзергесе һәм киләчәгенең сәнгатьчә чагылышы. Шуның өчен дә кайда гына булмасын – гомуми урта белем мәктәпләрендә, шул исәптә рус мәктәпләрендә, гимназияләрдә, махсус урта һәм югары уку йортларында – татар әдәбиятын укыту, иң беренче чиратта, телебезнең байлыгына һәм киң мөмкинлекләренә, нәфислегенә, халкыбызның, тел осталарыбызның талантына, сәнгатебезнең камиллегенә соклану хисләре тәрбия чарасы ул.

Әдәби әсәрләрне без укып кына калмыйбыз, аларның асылын тирәнрәк аңлар өчен әсәрне анализлыйбыз. Анализ дәверендә әсәрнең идея, тема, проблемасы ачыклана, әдәби геройларның образларына игътибар юнәлтелә һәм әдәби детальләр дә читтә калмыйлар.

Әдәби деталь – ул әдәби образ тудыруда катнаша торган аеруча әһәмиятле, аерып чыгарылган элементлар, әйбер, сызык, хәрәкәт, төс, күренешләр һ.б.

Нинди вазифа башкаруына карап әдәби деталь берничә төргә аерыла:

1. Тышкы деталь (портрет, пейзаж, әйбер)
2. Эчке (психологик) деталь (уй-фикер, хис-кичереш) була.

Әсәрдә тоткан урынына карап:

1. Җентекләүче ( мәгълүмат бирүче, санап китүче) деталь

2. Символик (гомуми бәя бирүче) деталь

Әйбер-детальләр:

1. Аксессуар деталь – кешенең җәмгыяви урынын билгеләүче

2. Характерологик деталь – холык-фигыльгә ишарә ясаучы

3. Культурологик деталь – яшәү рәвеше белән бәйле.

Детальләрнең тагын сюжет детальләре, җентекләүче детальләр, композицион детальләр, символик детальләр, динамик яки статик детальләр дигән төрләре дә бар [2].

Татар язучылары үз иҗатларында әдәби детальләрне еш кулланалар. Мисал итеп Айдар Хәлим иҗатына күз салып киттик.

Айдар Хәлимнең иҗаты күп кырлы. Әдипнең язу манерасы: кырыс реализм, халыкчан бизәкләргә бай җор тел һәм үзенчәлекле сурәтләү алымнары. Кайсы чор турында һәм нинди генә темага язуына карамастан, А.Хәлим кеше шәхеснең катлаулы эчке дөньясын, эш – гамәлләрен гуманистик идея-эстетик карашлар югарылыгыннан торып анализларга тырыша. Аларны реаль чынбарлыктагы милли, тарихи – иҗтимагый тормыш барышындагы катлаулы мәсьәләләр, әхлакый проблемалар белән тыгыз бәйләнештә сурәтләргә тырыша.

Шагыйрь буларак, аның беренче китабы татар телендә 1969 нчы елны Казанда «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылып чыга. Шигърияттә Айдар Хәлим милли рухлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган лирик, лирик-публицистик шигырь цикллары һәм эпик жанрда иҗат ителгән поэмалары, балладалары («Беренчеләр», «Ул елда», «Өмә», «Печән чапканда», «Набат белән Нәфисә турында хикәят», «Яралы бөртек», «Эксперимент-86» һ. б.) белән билгеле. Шагыйрьнең төп поэтик әсәрләре татар телендә 1990, 2001 һәм 2003 нче елларда чыккан җыентыкларында («Йөрәк ташы», «Милли шигырьләр», «Тилергән сиреньнәр» һ.б.) урын алган [3].

«Өч аяклы ат» әсәрен күбебез фильм аша беләбез. Әсәр авыл тормышы турында. Вакыйгалар үткәннәрне искә төшерү белән үрелеп бара. Әсәрдә сугыштан соңгы елларда татар авылы: авылның тормыш-көнкүреше, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр сурәтләнә.

«Өч аяклы ат» повестеның төп герое – Бамбук кушаматлы ат. Моны әсәр үзенчәлекләренең берсе дип санарга мөмкин. А.Хәлим кеш булмаган җан иясен әдәби образга кадәр күтәреп, укучының игътибарын җәлеп итә. Бамбук, бүре, Кәрим, башка образларның хис-кичерешләре болар барысы да әдәби детальләр. Бамбук – ат, төрле авыр эшләрне башкара торган җан иясе. Кәримнең хис-кичерешләре укучыга аның эмоциональ халәтен тоярга ярдәм итәләр. Детальләр әсәрне тулыландыралар һәм укучының игътибарын җәлеп итәргә ярдәм итәләр.

«Татар вакыты» әсәре татар әдәбиятына нык кереп калды. Символ буларак, Мотаһарның татар халкын хәтерләтүе билгеләнә. Әлеге сурәттә милләтнең бүгенге сыйфатына, аның тарихи язмышына тиң тетрәндергеч

хакыйкать чагыла. Сәгать – әдәби деталь булып тора. Ул вакытның үтүен генә күрсәтеп калмый, ә татар халкының язмышын да чагылдыра.

Айдар Хәлим — олы фикер һәм тойгыларны бер-ике сурәт, берничә деталь тирәсенә җыеп кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирү сәләтенә ия. Кыска, тыгыз сюжет кысаларында сурәтләнгән конкрет тормыш күренешенә күңелгә нык тәэсир итәрдәй тирән мәгънә сала белү бик мөһим. Язучының әсәрләре яхшылык белән явызлыкны аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, өмет һәм иман белән яшәргә өйрәтә.

Әдәбият

1. Хәлим Айдар. Өч аяклы ат // Казан утлары . – 1992. – № 6. – 52-101б.
2. Әдәбияттан эш дәфтәре Җәлилова Г.И. [Электрон ресурс] URL: https://gzalilova.narod.ru/adabiyat_deftere/a_t.html (мөрәҗәгать итү датасы: 29.10.2023).
3. Айдар Хәлим прозасы һәм поэзиясе [Электрон ресурс] URL: https://infourok.ru/aydar-hlim-prozasi-m-poeziyase-2930947.html (мөрәҗәгать итү датасы: 29.10.2023).
4. Китап киштәсендә ниләр бар? – Казан утлары. – 2016. – №1. – Б.132-136.

## АФОРИЗМНАР - ХАЛЫК АКЫЛЫ, ХАЛЫК ТӘҖРИБӘСЕ

Закирова А.И.
“Иске Юраш урта гомуми белем бирү мәктәбе” укучысы
Фәнни җитәкче: Юнусова Л. М

Татар халык афоризмнары ул – фольклорның кечкенә күләмле жанрлары. Ә фольклор-халык авыз иҗатының киң һәм үзенчәлекле өлкәсе, һәр кеше әдәбиятның бу тармагы белән таныш. Фольклор ( халык хикмәте, акылы)- теге яки бу халыкның сүз сәнгате –тел иҗаты. Ул халыкның карашын, тормыш-көнкүрешен, теләкләрен чагылдыра. Әлеге термин 19 гасырда барлыкка килә, бары тик 20 гасырда гына әлеге термин татар халкында кулланыла башлый. Ул телдән-телгә иҗат ителә һәм телдән-телгә күчеп яши. Аның үз җаны, үз тормышы бар. Бу иҗатны тудыруда күп төрле милләт кешеләре катнаша.Һәр халыкның иҗаты милли характерда. Бу үзенчәлек аның эчтәлегендә дә, шулай ук формасында да бердәй дәрәҗәдә гәүдәләнә.

Барыннан да элек, фольклор телдән иҗат ителүе һәм телдән-телгә күчеп яшәве белән аерылып тора. Икенче төрле әйткәндә, халык авыз иҗаты ул, сүз-тел сәнгате, телдән чыгарыла һәм телдән сөйләнә яки телдән башкарыла торган иҗат. Халык иҗаты әсәрләре нәкъ менә сөйләнгәндә һәм башкарылганда гына җанлы булып, чын үз тормышы белән яши.

Гасырлар буе халык авыз иҗатының күп төрле тармаклары, жанрлары формалаша. Фольклор берничә төргә бүленә:
- эпик әсәрләр: әкият, дастан, легенда, риваять, мифологик хикәят, мәзәк;

- лиро-эпик: бәет, мөнәҗәт;
- лирик: җырлар;
- афористик иҗат төрләре: сынамыш, әйтем, мәкаль, табышмак, ышанулар, ырымнар, төш юраулар;
- балалар фольклоры: багу поэзиясе, балачак поэзиясе, уеннар;
- йолалар: гаилә - көнкүреш, календарь йолалары.

Һәрбер жанр үзе тагын берничә төргә бүленергә мөмкин. Татар фольклорында халыкның яшәү тарихы, йола-гадәтләре, дөньяга фәлсәфи карашлары, психологиясе һәм менталитеты чагылыш таба. Анда традицион сәнгатьнең барлык төрләре үсеше өчен нигез бар.

Хәзерге вакытта фольклорны өйрәнү бик актуаль, чөнки фольклор милләт тарихын үсеш-үзгәрештә төзүгә, аның үзара бәюына булышлык итә. Фольклор халкыбыз тарихын ачып бирә. Шулай итеп,без үзебезнең тарихыбызны, үсеш-үзгәрешләрне, мирасыбызны тирәнрәк аңлыйбыз. Үткән чорларыбызны мифлардан, легендалардан, әкиятләрдән укып таныша алабыз.

Борынгы кешенең һәр гамәле, һәр адымы дини-мифик карашларга, ышануларга, йолаларга нигезләнгән булган. Бу карашларны, ышануларны, йолаларны дөрес аңлаганда, борынгы чорда гомер иткән ата-бабаларыбызның уй-фикерләренә төшенергә безгә зур мөмкинлек бирелә. Ә безгә үткәннәребезне белү бик мөһим, чөнки милләтнең киләчәге үткәннәр белән һәрвакыт бәйләнештә.

Халык авыз иҗаты әсәрләре - безгә, яшь буынга, белем һәм тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак. Халыкның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы әкиятләре, киң колачлы җырлары, тирән фәлсәфи әйтемнәре, тапкыр һәм үткер мәкальләре, үзенчәлекле ырымнары  һәм башка бик күп төрле иҗат җимешләре безне милли рухта тәрбияләргә, әби-бабаларыбызның үткәнен өйрәнергә зур булышлык итәләр.

Мине татар халык афоризмнары бик кызыксындыра. Аларга тирән һәм үткен фикерне җыйнак, сурәтле итеп әйтеп бирү хас. Шуңа күрә дә мондый әсәрләрне еш кына хикмәт энҗеләре, алтын бөртекләр, фикер җәүһәрләре кебек шигъри исемнәр белән атап йөртәләр.

Татар халкының афористик иҗаты үзенең жанрлар составы ягыннан шактый бай һәм күптөрле. Аларның безгә иң яхшы танышлары — мәкальләр һәм табышмаклар. Әмма болардан тыш әле тагын канатлы сүзләр, әйтемнәр, җор сүзләр, юраулар (ышанулар), сынамышлар, алкышлар, каргышлар, антлар, әзер җаваплар, үртәвечләр, тизәйткечләр дип йөртелә торганнары да бар. Мондый әсәрләр бигрәк тә үзләренең тышкы төзелешләре (кыскалыклары, сурәтлелекләре, ритмлы һәм рифмалы булулары) белән бер-берләренә шактый якын торалар. Әмма шул ук вакытта аларның һәркайсының үзенәгенә хас булган сыйфат-билгеләре дә күзәтелә. Әйтик, мәкаль тормыштагы фактларга һәм вакыйгаларга бәя бирә, төрле-төрле хәлләрдә үзеңне ничек тотарга өйрәтә. Табышмак кешенең тапкырлыгын, зирәклеген, фикерләү сәләтен үстерүгә ярдәм итә, бер үк вакытта күмәкләшеп күңел ачу чарасы да булып тора. Алкышлар, антлар, каргышлар магия-тылсым белән бәйләнгәннәр. Юраулар,сынамышлар һәм ырымнаргакиләчәккә прогноз ясау роле йөкләнгән.

Җор сүзләр, әзер җаваплар, үртәвечләр күбрәк кешеләрне көлдерү максатын алга сөрәләр, сөйләмне бизиләр, аны җанландыралар [Мәхмүтов  2002: 13].

Халык афоризмнарының бер ишләре тормышта турыдан-туры магик вазифа башкара. Алардасүзнең тылсым көче ярдәмендә табигатьтәге «ияләргә», төрле чирләргә, дус яки дошманга тәэсир итү, яхшылыкка каршы изгелек кылу, явыз затларның зыянынннан котылу кебек максатлар алга сөрелә. Шундый жанрларның берсе — алкышлар, ягъни изге теләкләр. Алар кеше тормышында әһәмиятлевакыйгалар булганда, шатлык-куаныч килгәндә, уңышка ирешкәндә һәм башка шундый очраклардахуплау, теләктәшлек белдерү йөзеннән әйтеләләр. Мәсәлән, берәр кеше өстендә яңа кием күргәндә: «Җылы тәнеңдә тузсын!» -  диләр. Берәр төрле эш башкаручылар яныннан: «Алла куәт бирсен!» - дип узалар.

Алкышларга капма-каршы булган каргышлар – алар дошманга юнәлтелгән яман теләкләр. Мәсәлән, берәү икенче кешене: «Гомереӊ буе рәхәт күрмәсәң иде!» — дип каргый, икенчесе «Каргышың казык башына!» — ди. Борынгы кешеләр, алда әйтелгәнчә, мондый теләкләрнең көченә, нәтиҗәсенә чын-чынлап ышанганнар.Бу – кешеләрне яман эшләрдән күпмедер тыеп торган.

Магик вазифа башкара торган афоризмнарның тагын бер төре — антлар. Болары,— бер яктан,үзеңнең хаклыгыңны, гаепсезлегеңне раслау, икенче яктан, бирә торган вәгъдәңнең ныклыгына, бозылмаслыгына ышандыру өчен әйтелә торган гыйбарәләр. Әгәр ант итүченең сүзе ялган булып чыкса, аның башына коточкыч җәза-газаплар төшәргә тиеш була: «Ипи чыраен күрмим!», «Алдашсам җир йотсын!» һ. б. Ант текстлары каргышларга бик якын тора: төп аерма шунда: алар кешенең үз исеменнән, беренче заттан биреләләр, һәм җәза да ант итүченең үзенә билгеләнә.

Ырымнар – ул халык иҗатының магия, ягъни сүз һәм хәрәкәт, йола кодрәтенә ышану белән бәйләнешле борынгы жанры, хыялый көчләргә һәм ияләргә тәэсир итеп, үз теләгеңә ирешү максатында кулланылган сүзләр.Ырымнарның иҗтимагый функциясе кеше ихтыяҗларына хезмәт итүгә кайтып калса да, алар сүз сәнгате әсәре булып исәпләнәләр [Бакиров 2008: 34].

Бездәге «ырым» төшенчәсе русларның «заговор» һәм «заклинание» дигән төшенчәләренә туры килә. Гадиләштереп әйткәндә, ырым ул - борынгы кешенең үз максатына ирешү өчен, сүз һәм хәрәкәт «кодрәтенә» таянып эш итүе, хуҗалык һәм көнкүреш ихтыяҗларын махсус сүзләр һәм йола-хәрәкәтләр ярдәмендә хәл итәргә омтылуы дигән сүз.

Ырымнар туган вакытта ук йола белән тыгыз бәйләнгән булганнар. Менә шуңа күрә дә кайбер фольклорчылар (мәсәлән, В. И. Чичеров) аларны йола фольклоры составында карыйлар да. Ләкин вакыт үтү белән, ырымнарның йола белән бәйлелеге кимегән. Кайчандыр турыдан-туры йола-хәрәкәт белән бәйле текстлар (әфсен-догалар) мөстәкыйль рәвештә дә баш-карыла башлаганнар. Чөнки магик характердагы йола-хәрәкәтләрнең бер өлеше акрынлап онытылган, икенче өлеше исә бернинди текстсыз үзалдында гына яши башлаган (мәсәлән, кыраунны иске чабаталар ыргытып «куу»).

Кешелек һәр адымда табигатьнең стихияле көчләре һәм кодрәте белән очрашкан. Табигать аның өчен чишелмәслек проблема  булып тоелган. Ул аңа

сабыйдай гаҗәпләнеп һәм куркынып караган. Дөньяны, шул исәптән кешенең үз-үзен танып-белү дәрәҗәсе һәм хезмәт үсеше әле түбән булганлыктан, яраклашу һәм тәэсир итү чараларын ул үзенең хыялында - мифларда һәм мифологик фикерләү белән керешкән ырымнарда тудырган[Бакиров 2008: 36].

Шулай итеп, мифлар кебек ырымнар да тирәлеккә хыял ярдәмендә тәэсир итү, табигатьне һәм төрле ия-рухларны кеше ихтыярына хезмәт иттерү максатында туганнар.

Афоризмнар - алар халык күңеленең көзгесе, халыкның уй-теләкләрен, хыял-өметләрен, шатлык-куанычларын гәүдәләндергән фикерләр. Гомумән, афоризмнар халык педагогикасында әһәмиятле урын алып торалар. Яшь буында акыллылык, җорлык, үз-үзеңне матур итеп тота белү, чисталык, пакълек, ашау-эчү әдәбе һәм башка күркәм күнекмәләр тәрбияләүдә халык аларны киң файдаланган. Шуңа күрә аларны өйрәнү бик мөһим.

**Әдәбият**


1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры. -– Казан, "Мәгариф", 2008
2. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. – , 1941.– 188б.
3.Мәхмүтов Х.Ш.  Халык афоризмнары / Мәхмүтов Х.Ш.– Казан, 2002.


## ЛӘБИБӘ ХӨСӘЕНИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ТАТАР КЫЗЛАРЫ МӘКТӘБЕ


Зарипова Д.Р.
Әлмәт шәһәренең17 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Кашипова Н.З.


2023 нче ел - Татарстаныбызда “Укытучы һәм остаз елы” буларак игълан ителү юкка түгелдер. Белем-мәгърифәтне башкаларга тарату татар халкында элек-электән яшәп килгән. Халкыбызның беренче фәлсәфәчеләре, шагыйрьләре, мөгаллимнәре барлык иҗтимагый мәсьәләләрне гыйлем-мәгърифәт юлы белән хәл итәргә омтылган, халыкны белемгә, һөнәргә өндәгән, наданлыкка, гамьсезлеккә каршы чыгарга, татар әдәби телен күтәрергә, хатын-кызларны да укытырга, акылга ирек бирергә кирәклеген күрсәткән. Шушы максатларны тормышка ашыру өчен кыз балаларны укыту өчен махсус мәктәпләр ачу бурычы туган. Ул мәктәпләр искечә укытудан яңача укыту системасына җайлаштырылган булырга тиешлеге дә искәртелгән.Татар хатын-кызларын белемле, мәгърифәтле, мәдәниятлы  итүгә  күп көч куйган ике йолдыз – Ләбибә Хөсәения һәм Фатиха Аитова исемнәре барлык мөгаллимнәргә дә яхшы таныш. Нәкъ менә шушы ике олы шәхеснең тырышлыгы нәтиҗәсендә беренче җәдиди мәктәпләр - кызлар мәктәбенә нигез салынган да инде.

Яшьтән китап уку белән мавыккан,  белемгә омтылган Ләбибә үзе кебек яшь кызларга белем бирүне беренчел изге бурычы итеп санап үсә. 1896 нчы елда данлыклы “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенә нигез салучы Галимҗан хәзрәт тарафыннан Казанга чакырылгач, Ләбибә Маһруй абыстай белән бергә кыз

балаларны укыта башлый, үзе дә белем алуын дәвам иттерә. Биредә белем бирү яңа ысул белән алып барыла. Иске кадими ысул белән укытканда,башта әлифбадагы барлык хәрефне исемнәре белән күңелдән ятлаталар, аннары шул хәрефләрне кушып укырга өйрәтәләр.Ә яңа ысул белән укытканда, бала сүз, иҗек өстендә эшләп, бер ел эчендә бөтен әлифбаны белеп, йөгерек укырга да өйрәнеп өлгерә.

Галимҗан хәзрәтнең тормыш иптәше Маһруй абыстай Галиева Казанда беренчеләрдән булып кызларны яңа ысул белән укытуны башлап җибәрә һәм үз тәҗрибәсен бик белемле, тәҗрибәле мөгаллимә булып формалашкан Ләбибә Хөсәениягә тапшыра.

1904 нче елда Ләбибә мәхәллә байларыннан үз өенең ишегалдына кызлар укыту өчен мәктәп салдыруга ирешә. Бу – Казанда кызлар укыту өчен махсус салынган беренче мәктәп була һәм ул “Ләбибә Хөсәения мәктәбе” дип атала.

Әлбәттә, мәктәпне ачу, кызларны яңача укыту бик авырлыклар белән алып барыла. Казан укыту округы Ләбибәнең мәктәп ачарга рөхсәт сорап барган үтенеченә: “Татар кызлары өчен хәреф таныту, догалар уку, Коръәнне һәм кул эше өйрәнү белән чикләнгән ике сыйныфлы башлангыч мәктәп ачарга гына рөхсәт ителә,” -дип җавап бирә. Соңыннан арифметика буенча 4 гамәл генә өйрәтергә рөхсәт алына. Бөтен укыту эшләрен Ләбибә Хөсәения үзе җитәкли. 1904 нче елда Казан округы аңа укытучылык хокукы алырга тәкъдим итә. Ләбибә, Уфага барып, мөгаллимә исемен юллап, рөхсәт кәгазе алып кайта.Шул көннән мәктәп рәсмиләшкән булып санала, яңа укучылар да кабул ителә. Казан округы рөхсәте белән куелган программаны кызлар бик тиз үтеп бетәләр. Ләбибә, ярдәмче мөгаллимәләре белән киңәшеп, администрациягә белгертми генә, укучыларны өлкәнрәк сыйныф программасы белән укыта башлый. Шулай бишенче сыйныф барлыкка килә, мәктәптә татар теле, математика, география, табигатьне өйрәнү дәресләре кертелә. Эш яшерен оештырылу сәбәпле, бу фәннәр дәресләр расписаниесенә кертелми. Вакытлар узу белән рус теле дәресләре һәм башка фәннәр укытыла башлый. Уку елы тәмамлангач, тантаналы рәвештә имтихан үткәрелә, укучыларга табельләр бирелә. Шул рәвешле, татар кызларыннан беренче җидесе “Мәктәптә укытырга хокуклы татар мөгаллимәсе” дигән таныклык алып чыга.

Мәктәптә дәресләр генә түгел, кызларны кул эшләренә өйрәтү дә яхшы куелган була. Укуны тәмамлаган кызлар арасында оста тегүчеләр, чигүчеләр булуы турында халык арасында хәбәр тарала. Бу хәбәр дә кызларны Ләбибә Хөсәения мәктәбенә тарта. Укытыла торган фәннәр елдан-ел күбәя. Мәктәптә дин дәресләреннән тыш татар, гарәп, фарсы һәм рус телләре, математика, география, табигатьне өйрәнү, анатомия, гигиена, гомуми тарих, Бөек Болгар тарихы, татар тарихы, Россия тарихы, кул эше, сызым-рәсем һәм хор белән җырлау фәннәре укытыла башлый. Әдәби-музыкаль кичәләр дә оештырыла.

Шул рәвешчә, кызлар мәктәбендәге бу фәннәр, кичәләр кызларда дөньяга, тормышка яңа караш тәрбияли. Татар кызлары үзләренең хәлләрен, җәмгыятьтә торган урыннарын аңлый башлыйлар.

Ләбибә Хөсәения бу уңышлар белән генә тукталып калмый. Үз мәктәбендә яңача укытуны гамәлгә кертүдән тыш тагын бер зур теләге була

мөгаллимәнең: үзенең мәктәбен татар мөгаллимәләре әзерләп чыгара торган уку йорты итеп үстерү. Бу теләген тормышка ашыру өчен, Ләбибә Хөсәения данлыклы “Мөхәммәдия” мәдрәсәсеннән яшертен генә мөгаллимнәр чакыртып, өлкән сыйныфта укып та, кече сыйныфларда дәрес бирүче кызларның белемнәрен күтәрү өчен Укытучылар әзерләү курслары оештыра. Аның мәктәбеннән чыккан укытучы кызлар халкыбызны агарту, белемле итү өчен ерак авылларга, төрле шәһәрләргә китеп укыталар, тәҗрибәле укытучылар булып җитешәләр.

Бөек Октябрь революциясеннән соң Ләбибә Хөсәения мәктәбе хатын-кызлар өчен укытучылар әзерләү мәктәбе итеп оештырыла. Ләбибә ханым аның директоры була. 1918-1919 нчы елларда бу мәктәп Хатын-кыз укытучылар семинариясе буларак эшли. 1919-1920 нче елларда ир укытучылар мәктәбе белән берләштерелә.

1909 нчы елда Ләбибә Хөсәения мәктәбендә укытучы дипломы булган бер генә мөгаллимә укытса, 1918 нче елга инде бу мәктәпнең укытучылар составы бөтенләе белән дип әйтерлек югары белемле була. Анда Казан Югары хатын-кызлар курсларын тәмамлаган укытучылардан алып Париждагы Сорбонна университетын тәмамлап Франциядән кайткан укытучыларга кадәр эшли. Укыту Ләбибә апалары өйрәткән яңа алымнар белән алып барыла.

Эстафета дәвам иттерелә. 1909нчы елның 27 августында Казанда икенче татар кызлары мәктәбе ачыла. Бу мәктәпнең директоры – Ләбибә Хөсәения мәктәбенең эш алымнарын, эш барышын өйрәнгән Фатиха Аитова була.

Гомерләрен мәгърифәт эшенә багышлаган бу ике мөхтәрәмә ханым төрле мәсьәләләрдә бергә киңәшеп эш итәләр. Ләбибә Хөсәения мәктәбендә укыган кызларның шактые Ләбибә мәктәбен тәмамлаганнан соң укуларын Фатиха Аитова мәктәбендә дәвам иттерәләр. Аны да тәмамлап, рус мәктәпләренә, рабфакка, институтларга керәләр.

Ләбибә Хөсәения башлаган изге эш аның йөзләгән укучылары аша буыннан-буынга, безнең көннәргә кадәр уңышлы тапшырылып килә. Бүген әлеге мәктәпне тәмамлаучы мөгаллимәләрнең укучылары арасында күренекле артистлар, медальле укытучылар, атказанган табиблар, рәссамнар һәм башка бик күп белгечлек кешеләрен искә алып китәргә мөмкин. Аларның һәркайсы әлеге көннәр дә Ләбибә Хөсәениянең игелекле хезмәте һәм аның олы абруе турында истәлекләре белән бүлешәләр. Мөгаллимә Ләбибә Хөсәениянең татар халкын аңлы, мәгърифәтле итүгә багышланган эшчәнлеге бүгенге укучылар арасында телдән-телгә сөйләнеп, горурлану хисләре тәрбияли.

Әдәбият

1.Фәрхетдинов С.Җ. Сайланма мәкаләләр. – Әлмәт: “Наза” фонды, 2000-83б.

## СУГЫШ ТЕМАСЫН АКТИВЛАШТЫРУДА ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ВӘЗГЫЯТЬ

Ибраһимова М.И.
КФУның Алабуга институтыс студенты
Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.

XX гасыр башы татар әдәбияты галимнәрнең игътибарын күптән җәлеп итте һәм аларны җентекләп төрле аспектларда өйрәнде. Хрониологик яктан бик аз вакыт аралыгында (1905-1917 еллар) күрсәтелгән бу чорга шундый игътибар үзен тулысынча аклый. Хәзерге вакытка кадәр язылган матур әдәбият әсәрләренең саны һәм, бигрәк тә, аларның әһәмияте, классик камиллеге XX гасыр башы әдәбиятының феноменаль күренешенә туры килә. Ф. Бәширов, Р. Ганиева, Д. Заһидуллина хезмәтләрендә чор әдәбиятына (хронологик чикләр, иҗтимагый торышның авторлык, әдәби тәэсире) кагылышлы шактый проблемала рөйрәнелә [Баширов, 2002; Заһидуллина, 2003; 2007; Ганиева, 2005]. Әмма сугыш темасын чагылдыру нисбәтендә бу чорның әдәбияты бик аз өйрәнелгән. Берникадәр вакыт бу бушлык Ф.Бәширов (Бәширов, 2002), Э.Сәлахов (Сәлахова, 2016), Д.Заһидуллина (Заһидуллина, 2019) кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелә, әмма бу хезмәтләр дә теманы һәрьяклап һәм тирән ачуга ирешә дип әйтеп булмый, гәрчә аерым аспектларны яктыртуда аларның әһәмияте зур булса да. Сугыш темасы күренекле шагыйрьләр, чор язучылары иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр дә бераз яктыртыла.

Әйтергә кирәк, соңгы дистә еллар дәвамында гына язучылар иҗатын (Минуллин, 2018) яңа өйрәнүгә юнәлтелгән күп хезмәтләрязыла; (Заһидуллина, 2019). Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, XX гасыр башы әдәбиятында хәрби еманы яктыртуны өйрәнү, беряктан, әдәби процессны тирәнрәк аңларга, аның тарихи чор белән бәйләнешен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Икенче яктан, XX гасыр башында, тулаем дөньяда барган ерткычлыклар турындагы әдәби фильтр белән танышу тынычлык, иминлек кебек кыйммәтләрнең мәңгелек булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Теләсә кайсы чордагы әдәбиятны өйрәнүне ул чор вакыйгалары, тарихи шартлар, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-мәдәни вәзгыять турында фикер алышмыйча алып бару мөмкин түгел. Бу сүзләр XX гасыр башы чорын өйрәнүдә аеруча актуаль булып яңгырый. Бер яктан, бу чор безгә тиңдәшсез яңарыш чоры, милли үзаңны, әдәбият һәм журналистиканың халыкмәнфәгатьләрен уяту, илнең, дәүләтнең прогрессы һәм алгарышы өчен актив көрәш кебек тоела, ләкин шул ук вакытта бу чо рканлы-дәһшәтле вакыйгаларга да бай. Бу вакыйгаларның кайберләре дөнья аренасында бара, ә кайберләре, бигрәк тә Россия халыклары өчен актуаль. Беренчеләрдән булып империалистик сугыш, икенчеләр, әлбәттә, восстание, революция кебек вакыйгалар. Халкыбыз арасында әдәбият көченең артуы боларның барысының да әдәбиятның һәр төрендә (проза, поэзия, драматургия) актив чагылышына китерә. Барыннан да элек, чор вакыйгаларына, тарихи һәм чагыштырмача-тарихи методларга мөрәҗәгать итеп.

XX гасыр башында ук рус-япон сугышын һәм Беренче рус революциясен искә алырга кирәк, тарихи аренада күрсәтелгән ике эре вакыйга кебек. Рус-япон сугышының алдагы тарихыбызга сәбәпләре, нәтиҗәләре, мотивлары һәм йогынтысы бүген дә галимнәрдә зур кызыксыну уята. Без ничек уйлыйбыз,

киресенчә, нәкъ менә бу сугыш безнең барлык бәлаләр башында. Ул бик күп имгәнүләр һәм җитешсезлекләрне ачты, гамәлдәге дәүләт төзелешен тәнкыйтьләү өчен мул туфрак бирде, революционерлар лагерена кирәкгәә тәргечбирде, революцион агымын стимуллаштырды гына түгел, ә аның милли рухы белән сукты да" [Фролов 2018:31]. 1905-1907 еллардагы беренче рус революциясе, үзенә ике ел керүенә карамастан, үзгәрешләр белән барды. Шуңа бәйле рәвештә аның берничә этабын аерып күрсәтәләр:

«Беренче революциянең башы;

- революция 1905 елның язында һәм җәендә;

- беренче рус революциясенең түбәсе (1905 елның октябрь-декабре);

Декабрь кораллы күтәрелеше;

- Революциянең кире кагылуы (1906 - 1907 еллар) [Иерусалим, Марасанова, 2006].

Бу этапларны күрү мөмкин булган саен, революция җиңелү белән тәмамлана, ләкин аны халык өчен, бигрәк тә милләт өчен файдасыз дип атап булмый. Ул татар халкы арасында актив көрәшкә күтәрелергә сәләтле кешеләр булуын, милли үсеш юлында актив хәрәкәтләнергә сәләтле татар улларын һәм кызларын ачыкларга мөмкинлек бирүен күрсәтте. Нәтиҗә буларак, татарларда матбугат иреге, театр сәнгате иреге, музыканың мөстәкыйльүсеше, рәсем сәнгатенең мөстәкыйльүсеше кебек уңай күренешләрне атарга мөмкин. Казан, Оренбург, Мәскәү, Уфа, Петербург һәм башка шәһәрләрдә берничә дистә газета һәм журнал пәйдабулды. Аларның башында Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Закир Рәмиев, Шәриф Камал, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый кебек атаклы шәхесләр тора, һәм бу басмалар аша аларның алдынгы сүзләре халыкка җиткерелде. 1906 елда профессиональ татар театры барлыкка килә. Шулай итеп, XX гасыр башында, Беренче рус революциясе елларында, татар җәмгыяте йокысыз калып, тарихи арена вакыйгаларында катнашырга, ким дигәндә сәяси позицияләрне билгеләргә мәҗбүр була. Ә.Сәлахова тарихи чынбарлыкны өйрәнүдә төрле чыганакларга мөрәҗәгать итүне, аерым алганда, Беренче Бөтендөнья сугышының татарлар тормышына йогынтысын максатчан дип саный, халык авыз иҗаты һәм солдат хатларына игътибар итәргә өнди, болай ди: «Беренче Бөтендөнья сугышының һәм аның кайгы-хәсрәтләрен өйрәнү өчен төп чыганак булып татар газеталары, татар солдатлары хатлары, бәетләр һәм мөнәҗәтләр тора, алар XX гасыр башында нәшер ителгән. Сугыш тарихын өйрәнү дә эпистоляр жанрдагы чыганаклар аеруча зур игътибар җәлеп итә. Хат аша сугышның иң кечкенә детальләрен күрү мөмкинлеге бар "[Салахова 2016:126]. Әлбәттә, галимнең сүзләрендә гаделлек бар, әмма без тормышны чагылдыра торган көзге буларак әдәбият мөмкинлекләрен югары дәрәҗәдә тоту дөрес булыр иде дип саныйбыз. Тагын бер мөһим фактка игътибар итәргә кирәк дип саныйбыз. Югарыда искә алынган тарихи вакыйгалар - безнең ил тарихында, XX гасыр тарихында соңгы канлы һәм дәһшәтле вакыйгалар. Алга таба Октябрь революциясе, Гражданнар сугышы, күмәкләштерү кебек катлаулы чорларны атарга кирәк, әмма алар совет чоры башында, совет идеологиясенә карата әдәбиятта яктыртыла башлый. Ул еллардагы фаҗига турында академик К. Миңнуллин болай дип яза: «Татар язучыларының бер өлеше революцияне

бик нык яклый, икенчеләре үзәктә кала, өченчеләре большевиклар сәясәтен кире кагып матбугатка чыга. Бу елларда Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Муса Бигиев һәм башкалар илне ташлап китәргә мәҗбүр булдылар.

Нәтиҗәләргә килгәндә, XX гасыр башының тарихи аренасында мөһим вакыйгалар - Рус-япон сугышы, Беренче рус революциясе һәм аның белән бәйле восстаниеләр, забастовка, реакция еллары әдәбиятка һәрьяклап йогынты ясый дип әйтергә мөмкин. Бер яктан, бу вакыйгалар зур күләмдә корбаннар таләп итә, икенче яктан – милли үсешкә өмет һәм ышаныч тудыра.

**Әдәбият**


1. Бәшир Ф. XX йөз башы татар прозасы: монография. – Казан: Фикер, 2002. – 287 б.
2. Ганиева Р.К. Шәехзадә Бабич иҗатында романтик мотивлар // Сәгыйть Рәмиев, Шәехзадә Бабич. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 238 – 258.
3. Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2003. – 255 б.
4. Заһидуллина Д.Ф. Әсәргә караш // Казан утлары. – 2019. – №1. – Б. 151 – 155.
5. Иерусалимский Ю.Ю., Марасанова В.М. Первая российская революция 1905 – 1907 годов: учебное пособие. – Ярославль: ЯрГУ, 2006. – 128 с.
6. Миңнуллин К.М. Татар әдәбияты тарихының 8 томлыгын әзерләү тәжрибәсе // Фәнни Татарстан. – 2018. – №3. – Б. 39 – 45.
7. Сәлахова Э. “Каләм әйтә: “Тагы бераз язасы, китә төшсен солдатларның мазасы” (Беренче Бөтендөнья сугышы чоры хатлары) // Гасырлар авазы. Эхо веков. – 2016. – №3-4. – Б. 186 – 197.
8. Фролов И.А. Русско-японская война 1904 – 1905 гг. в отечественной историографии 1904 – 1917 гг: дис. .. истор. наук. – М., 2018. – 294 с.


## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРГА ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ БИРҮ


Ибраһимова М.И.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Соңгы берничә дистә елда мәктәптә хезмәт тәриясе бирү мәсьәләсе шактый каршылыклар, дискуссияләр тууга этәргеч булды, укучыларның хезмәтен куллану тыю шигаре астында, мондый тәрбиянең үтемле алымнарына чикләр салынды. Әмма хезмәт сөючәнлек, тырышлык, маасатчанлык кебек сыйфатларның әһәмияте җәмгыятьтә дә, аерым шәхес өчен дә һаман да үтә югары булуын истә тоту кирәк. Билгеле ки, илебездәге сәяси, икътисади һәм мәдәни вәзгыять ата-ана һәм педагоглар алдына шактый катлаулы тәрбияви бурыч куя: индивидуаль сыйфатлары калку гәүдәләнеш алган, төрле яклап

үсешкә ирешкән, үзендә җаваплылык, хезмәт сөючәнлек, толерантлык, аралашучанлык, авырлыкларга бирешмәүчәнлек кебек сыйфатлар туплаган, акыл һәм физик потенциалын рациональ рәвештә файдалана алырдай иҗади шәхес тәрбияләү. Уку-укытуда Көнбатышка юнәлгәнлек традицион кыймматләребез белән беркадәр бәрелешекә керә. Галимнәр искәртеп киткәнчә, “Көнбатыш мәдәнияте үзенең эчтәлеге белән индивидуалистик, ул шәхестә, индивидта фикри бәйсезлек, күпчелекнең максат һәм бурычларына бәйләнмәгәнлеккә йөз тота” [Андреева 2001: 4]. Татар этнопедагогикасы исә элек-электән хезмәт, шул җөмләдән күмәк хезмәт традицияләре, бер-береңә ярдәм итү, сабырлык, толерантлыкка нигезләнгәнлек белән аерылып торган. Халкыбызның тәрбия тәҗрибәсен инкяр итү милли үзаң үсешенә зыян китерер иде. Шуңа бәйле рәвештә, җиденче сыйныфта Галимҗан Ибраһимовның “Табигать балалары” хикәясен өйрәнүгә аеруча игътибар бирү сорала. Биредә әдип XX йөз башы татар крестьян көнкүрешенә мөрәҗәгать итә. Әсәр хезмәт кешесенең бозылмаган саф тойгылары, көч-гайрәте  романтик күтәренкелек белән тасвир итүе белән җәлеп итә.Сюжет катлаулы түгел: XX гасыр башы татар авылы тормышындагы гадәти вакыйга – ятим карчыкка булышу өчен яшьләрнең өмәгә килүе, ары таба яшьләрнең Шаһи бабай өмәсендә катнашуы тасвирлап бирелә. Әмма шушы өмә фонында романтик башлангыч – ике яшь йөрәкнең бер-берсен яратуда аңлашуы, мәхәббәт өчен авырлыкларны, хезмәт белән сынауны үтәргә әзер торулары да тасвир ителә. Әсәр үрнәгендә укучыларга татар халкының асыл сыйфаты буларак күмәклек, ярдәмчеллек, бердәмлек, тырышлык һ.б. тирәнтен ачыла. Әсәрдәге зур урынны өмә күренешләре җәлеп итә. Дәреслектәге кайбер сорауларга мөрәҗәгать итик:

- Өмә нәрсә ул? Г.Ибраһимов сурәтләгән өмә хәзер була аламы? Ни өчен? [Хәсәнова 2017: 58].

- Булачак эшнең кешедә никадәр күтәренке тойгылар уятуы турында сөйләгез [Хәсәнова 2017: 60].

- “Берүзең кырыкка ярылырга ятканда”, Шаһи бабай өмә ясый. Хафиз һәм башкаларның, үз эшләрен ташлап, өмәгә барулары халкыбызның нинди сыйфаты турында сөйли [Хәсәнова 2017: 64].

Аңлашылганча, укучы шушы сорауларга җавап бирүдә югарыда әйтелгән фикерләргә киләргә тиеш.Өмәгә килү – ярдәм итү генә түгел, авыл халкының ихтирам белдерүе дә әле ул. Әлеге фикер соңгы сорауга җавап биргәндә яңгыратылыр, дип көтелә. Эшнең үтә күп вакытында да Шаһи бабай өмәсенә уникe кеше җыела. Эш шунда: Шаһи бабайны авылда ихтирам итәләр, хәленә керергә тырышалар. Бабайның Ибракаен солдат хезмәтенә алалар, димәк, эшли алырлык кул саны да кими. Җитмәсә, печән алдыннан гына ике алашасын да урлап китәләр. Боларны искә алып, авыл егетләре-ирләре картның чакыруын кире какмый.

Шушы ук сыйныфта өйрәнелә торган “Бакчачылар” (С.Хәким) поэмасы аша да укучыларда хезмәткә мәхәббәт, эшеңне яратып, аның мәгънәсен күңел һәм акыл белән күреп башкаруның әһәмиятен тәрбияли. Хезмәтең җимеше соңрак та күренә ала, әмма аның әһәмияте моннан кимеми, дигән нәтиҗә ясый балалар. “Табигать балалары”нда укучылар күмәк хезмәтнең әһәмиятенә

төшенсәләр, “Бакчачылар” поэмасында аерым кешенең үз хезмәтенә мәхәббәте һәм башкаларда да шул мәхәббәтне уята белүе соклану тудыра. Дәреслек авторлары тәкъдим иткән аерым сорауларга тукталыйк:

- Бакчачының эшкә бирелгәнлеге турындагы юлларны табып укыгыз;
- Алма бакчасы җиңүгә өлеш кертә аламы? Ничек? [Хәсәнова 2017: 87].

Укучылар шуңа игътибар итәләр: Галимҗан Ибраһимов әсәрендә хезмәт ярдәмчеллек акты, авыр физик эшне бергә һәм күңелле башкару һәм шуннан хәтта ләззәт алу турында да иде. “Бакчачылар” поэмасында нәкъ физик хезмәткә игътибар ителми. Биредә максат кую, идеалыңа омтылу һәм шул юлда фидакарь хезмәт итү сәләте турында бәян ителә. Сәлим өчен бакча, алмагачлар үстерү сакраль хезмәт дәрәҗәсенә күтәрелә, үзеңнән соң буыннарга эзеңне калдыру чарасы да булып тора. Сәлим оста бакчачы гына түгел, әсәрдә эш өчен тан атыа йөрүче оештыручы, лидер, әйдәман буларак та ачыла. Сәлимгә хас сыйфатлар заманыбыз өчен дә актуаль булуы дәрестә яңгыратыла.

Шулай итеп, әдәбият дәресләренең хезмәт тәрбиясе бирү потенциалы җиденче сыйныфта өйрәнелә торган әсәрләр мисалында раслана. Әдәбият тырышлыкка гына өндәп калмый, электән хезмәт сөйгән татар халкы белән горурлану хисләрен дә тәрбияли. Әдәбият аша хезмәт тәрбиясе аерымланган хәлдә тормышка ашырылмый. Хезмәт сөючәнлек белән бергә ярдәмчеллек, бердәмлек, башкаларга ярдәм итү сыйфатлары (Галимҗан Ибраһимов, “Табигать балалары”), максат кую, эшеңнең тирән, сакраль мәгънәсенә төшенү, үз эшеңне башкару осталыгына башкаларны да өйрәтү, шулай итеп, Җирдә изгелек арттыруга өлеш кертү идеясе (Сибгат Хәким, “Бакчачылар”) дә укучыларга җиткерелә һәм болар бүген дә актуаль яңгырыйлар.

**Әдәбият**

1. Андреева Л.Г. Трудовое воспитание в русской народной педагогике: дис. ... канд. пед. наук. – Пятигорск, 2001. – 180 с.

2. Хәсәнова, Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче с-ф. Ике кисәктә / Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Н.Сафиуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: “Мәгариф–Вакыт” нәшр., 2014. – 143 б, 135 б.

3. Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я. Татар әдәбияты: 7 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 1 нче кис. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. – 143 б.

## БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫНДА ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Иванова Э.?

Арча шәһәренең Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты.

Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.

Фольклор ( халык авыз иҗаты) термины инглиз сүзләреннән ясалган: folk (халык) һәм lore ( акыл,зиһен). Аның тамырлары ерак үткәннәргә барып тоташа. Элек-электән халык яшәеш һәм табигатьнең асылын, анда кешенең тоткан

урынын аңларга омтылган, аерым күзәтүләрен һәм нәтиҗәләрен, уй-хыялларын төрлечә яктырткан: савыт-сабаларга төшерелгән рәсемнәр, бизәнү әйберләре һәм эш коралларындагы фольклор әсәрләре, аеруча мифлар моның ачык мисалы булып тора. Күп кенә халык авыз иҗаты әсәрләре педагогик карашларга һәм таләпләргә туры килә, аларның теле гади, вакыйгалар балаларга аңлаешлы. Димәк, әби-бабаларыбыз фольклорның бала тәрбияләүдәге әһәмиятен белеп эш иткәннәр, аның ярдәмендә балага тирә-юньне таныргa һәм аңларга да өйрәткәннәр [Ягъфәров 2000: 7].

Балалар фольклоры кысаларына, нигездә, өлкәннәрнең балалар өчен иҗат иткән авыз иҗаты әсәрләре керә. Биредә шулай ук балаларның үз иҗатларын һәм, өлкәннәр өчен язылып та, балалар фольклорына күчкән әсәрләрне кертеп карарга мөмкин.

Функциональ табигатенә һәм уенның үзенчәлегенә карап, балалар фольклоры өч төркемгә бүленә: 1) бала багу фольклоры (бишек җырлары, кузгаткычлар, мавыктыргычлар һәм аларның төрләре, бармак уеннары); 2) хәрәкәтле уен фольклоры (“Кабыргалы-камчылы”, “Ак тирәк”, “Очты-очты”, “Без-без” яки “Кап та коп” уены, “Йөзек яшереш”, “Торма тартыш”, “Убырлы карчык” кебек сүзле-җырлы һәм драматик башлангыч катнашкан уеннар, сынамышлар, шобага әйтешләре); 3) сүз уены яки сүз белән күңел ачу фольклоры (чакырулар, эндәшләр, ияртешләр, юанычлар, әкиятсыманнар, әйтешләр, алдавычлар, тел көрмәкләндергечләр, үртәвечләр, шаян такмаклар) [Ягъфәров 2000: 7].

Багу поэзиясе.

Иң беренче бала очраша торган жанр – бишек җырлары. Бала йоклаганда, бишек җырлары көйләү файдалы. Бишек җырларындагы ягымлы, матур көйләрне, сүзләрне тыңлап, сабыйга анага кушылып җырларга, җырларның сүзләрен кабатларга тырыша, туган телендә сөйләшергә өйрәнә. Бу җырларны борынгы заманнарда ук инде халыкның тәрбияви-гамәли тәҗрибәсе тудырган. Ә үзләре исә шул көйләр нигезендә аналарның, бала багучыларның импровизацияләре төсендә барлыкка килгән.

Ана үзенең нәни кошчыгын күкрәгенә кысып җырлаган. Үз җырында ул үзенең ана булуының бөек сере белән тирән горурлануын һәм шатлануын чаныдырган, нәни баласына иксез-чиксез мәхәббәтен бәян иткән, аңарда үзенең дәвамын, чагылышын күрүенә куанган.

Юаткычлар һәм мавыктыргычлар. Такмак формасында языла, җиңел һәм шаяру формасында әйтелә. Балалар белән матур сүзләр һәм юаткычлар аша аралашу бик файдалы. Бала әле үзе төрле ыгылдаулар, кайвакыт елаулар белән генә безнең белән аралашса да, әни кеше аның белән һәрчак сөйләшергә, аралашырга тиеш. Сабый аңламый дип уйларга кирәкми. Үзенә дәшкәнне, елмайганны, хәтта әни кешенең кәефе булмаганын да ул сизеп тора. («Баланы уятканда», «Баланы юындырганда»).

Уен фольклоры.

Балаларның рухи яктан бай, физик яткан сау-сәламәт булып үсүендә уеннарның әһәмияте зур. Олыларга эштән бушаган вакытларында күңел ачу, ял

итү, вакыт уздыру өчен бер чара булса, бала өчен уен – чын шөгыльгә, тормыш көрәшенә һәм хезмәткә әзерләнү ул.

Җырлы-биюле уеннар нәниләр репертуарында сан ягыннан күп булмаса да, балалар аларны яратып уйныйлар. Бу төр уеннарда музыка, җыр, такмак хәлиткеч роль уйный. Көй уен хәрәкәтләре белән тәңгәлләшә, җыр һәм такмакларның эчтәлеге хәрәкәтләрдә чагылыш таба.

Күңел ачу фольклоры.

Иярмешләр. Кошлар тавышына охшатып авазлар чыгару, җәнлекләр булып сөйләшү, шулай итеп аларның холыкларыннан, тышкы кыяфәтләреннән көлеп, кеше сөйләменең һәм аерым гыйбарәләрнең яңгырашына ияреп кызык табу балаларга хас нәрсә. Бу балалар телендә аерым поэтик әсәрләр формалашуга сәбәпче булган. Аларны иярмешләр дип йөртәләр.

Үртәвечләр. Теге яки бу уңай белән бер-берсеннән көлү, шаярулар балалар характерына хас нәрсә. Әгәр уен яки күмәк шөгыль вакытында берәрсе хәрәмләшсә, балалар гаеплене үрти башлый. Шундый чакларда кулланылышка кергән шигъри әсәрләрне үртәвечләр дип атыйлар.

Такмаклар. Бию вакытында, күңел ачканда җырланып яисә тиз ритм белән речетатив рәвешендә әйтелеп йөртелә торган әсәрләрне такмаклар дип атау кабул ителгән. Балалар телендә башкарылу рәвеше ягыннан бер-берсеннән аерылып торган өч төркем такмаклар бар: бию такмаклары, көйләм такмаклары һәм сөйләм такмаклары. Бию такмаклары, табигый ки, бию-биетү вакытында гамәлгә керә. Алардан аермалы буларак, көйләм такмаклары исә кыска көйләргә җырланып башкарылалар, ә сөйләм такмаклары тиз ритм белән сөйләп йөртелә.

Балалар фольклоры зурлар иҗаты белән турыдан-туры бәйләнештә үскән һәм камилләшкән. Шуның өчен балалар иҗатында гомум фольклорның үсеше һәм яшәеш закончалыкларына хас барлык сыйфатлар да бар.

Соңгы чорда балалар телендә яшәүче халык иҗаты әсәрләре белән кызыксынуның тагын да артуына җитди сәбәп бар. Бу иң беренче чиратта, илебездә тәрбия-укыту эшен камилләштерү. Яшь буынны тәрбияләүнең яңа чараларын эзләү, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяну бурычын куйды. Бу яктан караганда, балалар фольклорын өйрәнү зур гамәли һәм фәнни әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

1. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.

2.Ягъфәров Р. Балалар фольклоры / Татар халык иҗаты // Балалар фольклоры. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2000. – Б. 7-10.

---

## ДАСТАННАР - ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ОЛЫ МИРАСЫ

Ильясов А.У.

Алабуга шәһәренең 8 урта мәктәп укучысы

Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.

Бөтендөнья татар конгрессы 2023 нче елны милли дастаннар елы дип игълан итте. Дастаннар - халкыбызның рухи хәзинәсе, могҗизасы, алар буыннан - буынга тапшырылып килә торган олы мирас, әлеге байлыкны файдалану, килер буыннарга җиткерү милли үзаңны үстерергә, асылыбызны сакларга, горурлык хисләрен тәрбияләргә ярдәм итә. Безнең әби – бабайларыбыз аларның әһәмиятен яхшы аңлаганнар, халык авыз иҗаты – фольклорның бер жанры булган дастаннарны укып үскәннәр, рухи яктан бай, көчле булганнар, беркайчан да авырлыклар алдында сынып, сыгылып төшмәгәннәр.

Татар телендә дастан сүзе ике мәгънәгә ия. Борын-борынзаманда ук халык арасында телдән иҗат ителгән зур күләмле әсәрләрне дастан дипатаганнар. Шул ук вакытта болгар шагыйре Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”(1312 ел), фарсы һәм таҗик шагыйре Фирдәүсинең “Шаһнәмә” (1030 еллар)әсәрләре поэма дип тә, дастан дип тә йөртелә.

Татар халык дастаннарын, гадәттә, берничә төркемгә бүлеп өйрәнәләр: 1) Борынгы әкияти – мифологик эпос (“Түләк”, “Йиртөшлек”); 2) Батырлык дастаннары “Алпамша”, “Аккүбек”, “Идегәй”, “Җик Мәргән”, “Чура батыр хикәяте”;3) Мәхәббәт дастаны ( Кузы Күрпәч белән Баян – сылу”); 4) Китаби дастаннар ( “Йосыф китабы”, “Сәйфелмөлек”, “Бүз егет”, “Ләйлә белән Мәҗнүн”, “Таһир белән Зөһрә") һ.б.

Югарыда саналган китаби дастаннарның барысы да Идел буе татарларының язма чыганакларында яисәхалык арасында элек – электән киң таралган кульязма китапларда сакланып калган. Бу гүзәл традиция, һичшиксез, Болгар чорыннан ук башлана. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы нигезендә барлыкка килеп, халык арасында гаять киң таралган “Йосыф китабы” – моның ачык мисалы |Миңнуллин 2011: 3 |.

“Кыйссаи Йосыф”- “Йосыф китабы” – татар халкының гомер – гомергә җан азыгы булып, яшәү дәрте, рухи көч биреп килгән иң сөекле әсәре, татар поэзиясенең чишмә башы, көзгесе. Ул үзеннән соңгы шагыйрьләргә, халык авыз иҗаты үсешенә көчле йогынты ясаган, җырларда макталган, аның шигъри үлчәвендә бәетләр чыгарылган, көйгә салып, күмәкләп укылган, яшь киленнәр аны кияү өенә күчкәндә, тансык бүләк итеп, сандык төбендә алып барганнар.

Әсәрдә вакыйгалар, персонажларның хәрәкәте илаһи көч тарафыннан алдан ук билгеләнгән тәкъдир – язмыш кушуы буенча бара. Анда мәхәббәттә тугрылыклы булу, кешеләр арасындагы дуслыкны саклау, атаның балага, баланың атага иң югары дәрәҗәдәге ихтирамы һәм җәмгыятьне тотып тора алган һәм аның киләчәктә үсешен тәэмин итеп, халыкны бәхетле тормышка ирештерерлек көчкә ия булган гадел хөкемдар, гаделлек нигезендә идарә итү кебек дөньякүләм мәсьәләләр көчле бизәкләү чаралары, рухи кичерешләргә бай образлар аша хәл ителәләр. Кол Гали кешеләрнең иң изге, тормышчан, дөньяви уйларын сүз дигән кодрәтнең тылсымлы бизәкләренә төреп бирә алган | Хәйруллин 1999 : 331 |.

Татар халкы үзенең яшәү – тереклек итүе дәверендә эпос дастаннарны бик күп иҗат иткән. Мондый ядкарьләр, кулдан язып, күчерелеп һәм таратылып, тарихи үсешнең татарлар өчен үзенчәлекле чорларында халыкка милли үзаңны, милли үзбилгеләнүне саклап калу чарасы булып та хезмәт иткән. Күләмле сөйләмә эпоска караганда, язма иҗат белән шөгыльләнүгә омтылган Идел буе татарларының рухи тормышында китаби дастаннар гаҗәеп популяр булган.Дастаннарның популяр булуын күчереп таратылган кулъязмаларның күплеге дә, зур тиражлар белән басылып чыккан булуы дараслый |Мөхәммәтҗанова 2023 :165|.

Дастаннарда халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Аларда бик борынгы мифология эзләрен, соңрак формалашкан ислам идеологиясе йогынтысын, сүзне хикмәт белән әйтү, элек – электән фольклорга хас традицион образлар, эпик сюжет һәм мотивларны табарга мөмкин. Халкыбызның хәзинәсе булган эпос - дастаннар - яшь буынга милли рухыбызны тапшыруның кыйммәтле чыганагы да. Укучылар мәктәп программасы нигезендә дастан жанрларының тарихы һәм төрләре белән танышалар.Алыплар турындагы архаих, романтик характердагы мәхәббәт дастаннары яисә тарихи дастаннар турында сөйләшү халкыбызның күңелбайлыгын, әхлакый идеалларын, матурлыкка омтылышын күзалларга ярдәм итә | Мөхәммәтҗанова 2023 :166|.

Татар халык эпосы турында сүз башлауга, мәшһүр “Идегәй”дастаны хәтергә килә. Һәм бу бик табигый дә. Дистәләрчә еллар дәвамында катгый тыелган дастан сиксәненче еллар ахырында яңадан халыкка кайтты: ул татар һәм рус телләрендә аерым китап булып та һәм матбугат битләрендә дә басылып чыкты | Миңнуллин 2011: 3 |.

Бу тарихи дастан Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларын, аның сәбәпләрен ачыклый, тарихи аренада зур роль башкарган шәхесләрне халык каһарманы пьедесталына күтәрә. Иң әһәмиятлесе – дастан бабайларның яше, тире, каны тамган, шатлыгы да, бәхете дә, бөтен язмышы да сеңгән туган җир сүзенең асылын аңларга өйрәтә. Әсәр мәкер, хыянәт, ялганның олысы, кечесе юк икәнне төшендерә, дуслык, мәхәббәт хисенең сафлыгын, биргән вәгъдәгә тугрылыкның олылыгын таныта. Явызлык үзе белән явызлыкны ияртә, яманлыкка каршы кылынган яманлык аны үстерә һәм фаҗигагә китерә дип раслый. Дастаннар тормышка карашны киңәйтә, зуррак масштабта фикерләргә, вакытның мәңгелек агышында кеше, аның гамәлләренең мәгънәсен төшенергә өйрәтә | Мөхәммәтҗанова 2023 : 166 |.

Дастанның төп герое – Идегәй халык герое буларак тасвирлана. Ул әкияттәгечә көчле, акыллы, тапкыр, булдыклы ир булып үсә.Кешеләр белән бик якын мөнәсәбәттә тора, алар белән гади генә,уен-көлке сүзләр белән сөйләшә. Ислам диненә хөрмәт белән карый, намаз укый, ураза тота, халык арасында дан казана, зур дәрәҗәгә ия була. Туктамыш ханга, халкына тугры хезмәт итә. Идегәй белән Туктамыш арасындагы каршылыкны хан хатыны Яникә тудыра, шуның өчен Идегәй Туктамышның дошманы Аксак Тимер янына качып китә, аннары үз иленә хыянәт итә. Шулай итеп, ул идеал образ

итеп кенә тасвирланмый. Идегәй әле Туктамыш, әле Аксак Тимер ягына чыга, горур ир бу хәлләргә бик хурлана да, ләкин үзенең гомерен дә саклап калырга тиеш була.Соңрак үз хатасын аңлый, аны төзәтә. Таркалып барган, җимерелгән Алтын Урданы торгыза, гадел идарә итә. Идегәй улы Норадынны югалта, аны югалту Идегәйнең үлемен якынайта. Аның тормышы хыянәтләр, үч алулар белән үрелеп бара.

Дастанның ахырында:"Хан артыннан хан үтереп, сөт урынына кан коеп яшибез икән, алдагы тормышыбыз да нәкъ шундый булачак", - дигән сүзләрне әйтә Идегәйнең чабылган, тәгәрәп киткән башы. Алтын Урда дәүләте татулык, бердәмлек булмаганга таркала. Ә "Идегәй" дастаны дәүләтләр, халыклар, төрле милләт кешеләре арасында дуслык, бер –береңне аңлап яшәү кирәклеген искәртә. Ничә гасыр вакыт узса да, бу әсәр хәзер дә актуаль булып кала, чөнки җир йөзе тыныч түгел, көнчыгыш һәм көнбатыш илләрендә сугышлар бара, бер гаепсез яшь балаларның, кешеләрнең каны коела. Минемчә, "Идегәй" дастанының әһәмияте шунда: ул укучыны , халыкларны, төрле милләт кешеләрен үткәннәргә әйләнеп карарга, үткәнебез белән горурланырга, хата-ялгышлардан арынырга, һәрвакыт дус, бердәм, тату булырга, илебезне күз карасыдай сакларга чакыра.

Гомумән, дастаннар фольклорның нигезен, фундаментын тәшкил итәләр. Аларәкияти –мифологик дастаннардан үсеш алалар. Аннары халыкның батыр уллары турында мәхәббәт белән үрелгән дастаннар туа. Вакытлар үтү белән халык тарихына якынлашкан тарихи дастаннар ("Идегәй") барлыкка килә. Аларда батырлык, матурлык, алар белән янәшә мәхәббәт, халкыбызның озын катлаулы, каршылыклы, шул ук вакытта фаҗигале тормышы тасвирлана. Дастаннар – халкыбызның олы мирасы, рухи азыгы, кайвакыт та күңелне юатучы чара гына түгел, ә шул чорның идеологиясен чагылдыручы әсәр дә. Төрки халыклар дастаннарны яратып укыйлар, хәтердә саклыйлар, үзләренә күчереп алалар.

Дөньяда эпос - дастаны булмаган бик күп халыкларны исәпкә алсак, дастаннарыбызның аеруча зур хәзинә булуына, халкыбызның исә нык тамырлы бөек халык булуына тагын да ныграк инанырга мөмкин. Татар дастаны - тарихи фактларны, татарларның борын – борыннан килгән яшәү рәвешен түкми – чәчми сөйли торган чыганак. Татар - дастанлы халык, ә инде аның китаби дастаннары дәрәҗәсенә җиткерелгәннәре башка бер генә төрки халыкта да юк. Татар дастанының китаби камиллеккә ирешкән булуы - милләтнең аңы, укымышлылыгы, рухи бөеклелеге белән бәйле сыйфат. Бу төр иҗатны халкыбызның асылкыйммәтләреннән берсе дип саныйбыз| Мөхәммәтҗанова 2023 : 167 |.

Шулай итеп, дастаннар – халкыбызның олы мирасы, рухи байлыгы, алтынга тиң хәзинәсе. Әлеге рухи байлыкны уку, өйрәнү,буыннан-буынга тапшыру кешеләрнең, милләтләрнең, халыкның милли үзаңын үстерергә, асылыбызны сакларга, тарихыбызны өйрәнергә, милләтебезгә, туган җиребезгә, телебезгә карата горурлык хисләрен тәрбияләргә ярдәм итә.

**Әдәбият**

1.Миңнуллин К.М., Кәлимуллин Җ.Х., Урманче Ф.И.“Заманалар узган – дастаннар туган: Дастаннар. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2011. - 175 б.

2.Мөхәммәтҗанова Л. Х.Дастаннар – үткәннәрнең сабыр сурәте // Казан утлары. - №3. - 2023.– 194 б.

3. Хәйруллин И.К., Миңнуллин К.М., Мөхәммәммәдиев Р.С. Ул дәрьяда бу дәрья / Борынгы әдәбият. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 1999.– 343б

## РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРДА АУДИРОВАНИЕ КҮНЕГҮЛӘРЕ АША СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ

Исмагилова Г.Р.
КФУ ның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Татар телен укыту методикасы укучыларда коммуникатив һәм лингвистик күнекмәләр үстерүне максат итеп куя. Шушы максатка ирешү өчен аудирование күнегүләренотышлы кулланып була, чөнки дәресләрдә аудиоматериаллар куллану укучыларда телнең интонацион төзелешен үзләштерү, сөйләмне дөрес танып белү һәм кабул итү, авазларны дөрес әйтә белү күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә.

“Аудирование” термины (латинча “avdire”-дан) инглиз галиме Д.Браун тарафыннан кертелгән. Рогова Г.В., Верещагина И.Н. “аудирование” терминына ишетә торган сөйләмне аңлау дигән аңлатма бирәләр [Рогова, Верещагина 1988: 117]. Элегерәк бу термин белән “тыңлау”, “тыңлаганны аңлау”, “телдән әйткәнне аңлау” һ.б атамаларны кулланып әйткәннәр. Димәк, “аудирование” термины авазларны, сүзләрне, сүзтезмәләрне, грамматик калыпларны ишетеп таный белү дигәнне белдерә.

ФГОС аудированиенең төп 3 максатын билгели:

Төп эчтәлекне, мәгълүматны аңлауга корылган аудирование. *(Мәсәлән: Тыңлагыз, текстта сүз нәрсә турында бара?)*;

Эчтәлекне тулылай аңлауга юнәлтелгән аудирование *(Мәсәлән: укытучының әйткәннәрен аңлап бару);*

Информацияне сайлап алып аңлау, ягъни бирелгән тексттан кызыксындырган мәгълүматны яки биремдә күрсәтелгәнне генә аерып алуга һәм аңлауга юнәлдерелгән аудирование *(Мәсәлән: иртәгәгә һава торышы фаразын тыңлагыз. Иртәгә явым-төшемнәр буламы?).*[Коломийцева, Дуванова 2023: 4]

Уку эшчәнлеге төре буларак аудированиеның төп теоретик нигезләмәләрен билгеләү өчен, кечкенә сыйныф укучыларының уку эшчәнлегендә аудирование функцияләрен билгеләргә кирәк. Алар өчәү: яңа мәгълүматны кабул итү һәм аңлау; иптәшләрнең җавапларын тыңлау; сөйләшүне коррекцияләүдә чагыла торган үзконтроль [Вьюшкова 1995: 8].

Нәтиҗәле тыңлауга комачаулаучы берничә төп фактор бар. Л.Н. Вьюшкова билгеләп үткәнчә, «тыңлаучылар гадәттә тыңламыйлар; тыңласалар да, ишетмиләр; ишетсәләр дә, нәрсә дөрес түгел икәнен аңламыйлар»

[Вьюшкова 1995: 8]. Биредә сүз аңлауга комаучанлык китерәторган: игътибар, хәтер, фаразлау һәм аңлау кебек дүрт үзенчәлекле киртә турында бара.

Татар телен өйрәтүнең беренче этабында әйтергә кыенлык тудырган авазларны тануга өйрәткән күнегүләрне куллану мәҗбүри. Мәсәлән, рус телле балаларга татар теленә хас булган [ә], [ж], [ң], [ө], [ү], [һ], [к], [гъ] һ.б авазларның әйтелешенә игътибар бирергә кирәк. Моның өчен махсус шушы авазларның әйтелешенә корылган аудирование күнегүләрен кулланырга мөмкин.

Мәсәлән:

1.Тыңлагыз һәм [ә] авазы кергән сүзләрне атагыз.

*Исәнмесез, мин, кәбестә, кием, рәсем, ишек, малай.*

2.Тыңлагыз һәм [ө] авазы кергән сүзләрне атагыз.

*Көнбагыш, бала, болыт, көмеш, көч,бүләк, сөт, өмет.*

3.Тыңлагыз һәм [ү] авазы кергән сүзләрне атагыз.

*Үлән, бүрәнә, итек, бүләк, бияләй, үлчәү, яулык, сүзләр.*

Сөйләмне ишетеп аңлый белү аралашу компоненты буларак кына түгел, укыту чарасы буларак та кыйммәтле. Аудирование әйтелешне камилләштерү, сөйләм күнекмәләрен үстерү, сәнгатьле укырга өйрәтү, грамматик һәм лексик күнекмәләр формалаштыру максатыннан файдаланылырга мөмкин.

Укытуның башлангыч этабында, укучы бары тик кыска җөмләләр һәм текстлар гына тыңлый, бу очракта ул барысын да аңлап барырга тиеш. Соңрак ул күләмле сөйләмнән торган язмалар тыңлый башлый. Күпчелек очракта алар укытучы яки дәреслекләрнең авторлары тарафыннан тиешле дәрәҗәдә белем бирү өчен җайлаштырылган: акрынрак темпта әйтелә яки берничә тапкыр кабатлана. Укуның максаты исә саклана – укучыдан ишеткәнне тулысынча аңлау таләп ителә.

Лексик күнекмәләр формалаштыру өчен укытучы дәресләрендә түбәндәге аудирование күнегүләрен кулланырга мөмкин:

Тыңлагыз, һөнәрләрне белдергән сүзләрне күрсәтегез.

*Укытучы, тегүче, төзү, табиб, апа, тәрбияче, бала, сату.*

Логик яктан артык булган сүзне билгеләгез.

*Кыю, көчле, куркак, батыр.*

Тыңлагыз, төсләрне белдергән сүзләрне күрсәтегез.

*Яшел, кара, кызу, ак, сары, тәмле, зәңгәр, ачы.*

Грамматик күнекмәләр формалаштыру өчен аудирование күнегүләре:

1.Тыңлагыз, биредә ничә сорау җөмлә булуын күрсәтегез.

*Бүген көн аяз. Тышта яңгыр явамы? Бүген һава торышы нинди? Тышта кар ява.*

2. Тыңлагыз“нинди?” соравына җавап биргән сүзләрне күчереп язгыз.

*Кечкенә, җылы, ята, якты, яшел, бара, яшел, калын.*

3. Тыңлагыз, “нишли?” соравына җавап биргән сүзләрне күчереп язгыз.

*Бара, утыра, укый, бүген, урындык, йөгерә, батыр.*

Ахырда шуны билгеләп үтәргә кирәк, аудирование – аралашуның нигезен тәшкил итә. Аудирование сөйләм культурасына өйрәтә: әңгәмәдәшне игътибар белән тыңларга, сөйләмдә грамматик формаларны аера белергә

өйрәтә. Тел белемнәре һәм сөйләм күнекмәләре татар телен чит тел буларак өйрәтү процессының нәтиҗәлелеген арттыра.Ишетеп аңлау күнегүләре укытучыга дәресне алып бару өчен кирәкле гыйбарәләрне кертеп җибәргә, элек үтелгән материалны кабатларга мөмкинлек бирә, укучыларның хәтерен, игътибарын, фикерләү сәләтен үстерергә булыша.

Әдәбият


1.Вәлиева Ф.С., Саттаров Р.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрендә татар теле укыту методикасы. – Казань: Раннур, 2000. – 455 б.

2.Вьюшкова Л.Н. Учим слушать // Русский язык в школе. – 1995. – №5.– С.8.

3.Камаева Р. Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик. алымнар. – Алабуга: АДПУ нәшрияты, 2010. – 103 б.

4.Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан. –Хәтер, 2001. – 432 б.

5.Коломийцева Е.М., Дуванова О.В., Методические рекомендации «Особенности преподавания предмета «Иностранный язык» в связи с введением обновлённого ФГОС СОО в 2023/2024 учебном году URL:https://docs.yandex.ru/docs/view?tm=1697728324&tld

6.РоговаГ.В., ВерещагинаИ.Н.Методика обучения английскому языку на начальном этапе в средней школе. –М.: Просвещение, 1988.– 224 с.

7.Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – С 206-209.


## ТАТАРСТАН - ЧАСТЬ КУЛЬТУРНОГО МИРОВОГО НАСЛЕДИЯ


Калашник А.А., Минебаева А.Ю.

студенты ЕИ КФУ

Научный руководитель: Габидуллина Ф.И.


Первым государством на территории нынешнего Татарстана была Волжская Булгария, созданная в 9-10 веке нашей эры, тюркскими племенами. В 922 году государственный религией стал ислам. Страна первой в Европе стала выплавлять чугун, была развита культура, образование и многое другое. Страна была сплочённой, сильной, хорошо вооружённой, именно поэтому взять её монголам получилось лишь с четвертой попытки в 1236 году[1].

Булгария вошла в состав империи Чингиз-Хана, а затем стала частью Золотой Орды. После распада Золотой Орды на территории Поволжья в 1438 году образовалось феодальное государство - Казанское ханство. В 1552 году Казань захватило войско Ивана Грозного, Казанское ханство прекратило своё существование и было присоединено к Русскому государству.

Казань становится важнейшим объектом. В 1708 году территория сегодняшнего Татарстана входит в состав огромной Казанской губернии.

В 1920 году провозглашается Татарская Автономная Советская Социалистическая Республика, что стало значительным шагом в воссоздании государственности татарского народа.

30 августа 1990 года была принята и подписана Декларация о государственном суверенитете республики. В марте 1992 был проведен референдум, а 6 ноября 1992 года принята новая Конституция Республики Татарстан, где согласно народному волеизъявлению установили новый государственный статус республики. 26 июня 2007 года был подписан договор " О разграничении предметов ведения и полномочий между органами государственной власти Российской Федерации и органами государственной власти Республики Татарстан"[2].

Территория современного Татарстана входила в состав золотой орды как Булгарский улус, где исповедовали ислам.

Почему же булгары приняли ислам, а не христианство?

Ответ прост: христианство не могли исповедовать по причине того, что булгары не были в тесных торгово - экономических отношениях с христианским народом. Ислам в Булгарию внедрялся стихийно, по причине тесных торговых и экономических связей с мусульманскими центрами Средней Азии. Внедрение ислама в Булгарию шло мирным путём, верхушка булгарского общества этому активно способствовала, она хотела придать своей идеологии всенародный характер. Также сами булгары были заинтересованы в распространении ислама не только среди своего населения, но и соседнего. Поэтому совершались "священные войны" на соседние племена, с целью исламизировать соседский народ.

На сегодняшний день основными религиями в Татарстане являются ислам и православие. А также присутствуют протестантство, католицизм, иудаизм и многое другое. Но, несмотря на множество конфессий, в республике существует баланс, понимание и уважение друг к другу. Государственная политика направлена на всяческое поддерживание всех конфессий, отстаивание интересов и равенство перед законом. В республике построено множество мечетей и церквей. Самой популярной мечетью в Татарстане является мечеть "Кул-Шариф",а церковь - Собор Успения Пресвятой Богородицы. В Республике Татарстан достаточно благоприятная религиозная обстановка. Представители всех конфессий достойно относятся друг к другу[3].

Культура Республики Татарстан очень разнообразна, она располагает богатейшим историко - культурным наследием, воплощает в себе красоты народов республики. В прожитых летах, на страницах энциклопедий запечатлены все значимые события, традиции, ценности и самобытность народа.

Если рассматривать культуру Татарстана более подробно, то немаловажным аспектом является национальные праздники, обряды и обычаи:

1. Зимой популярен праздник Каз-өмәсе, или «Гусиное перо». В старину праздник отмечался чуть раньше (поздней осенью) и заключался в коллективном ощипывании гусей, чтобы заготовить птицу, пух и перо на зиму. В ритуале принимали участие все молодые девушки: они демонстрировали старшим хозяйкам своё мастерство, чтобы заслужить похвалу

2.Сабантуй.

Ежегодный праздник плуга, символизирующий окончание весенних посевных работ, до сих пор остается важной традицией татар. Сабантуй проходит во всех деревнях и городах Республики Татарстан. В этот день собираются вместе все родственники, независимо от того, насколько далеко они живут. Этот праздник любят и ждут дети. Кульминация татарского торжества Сабантуй — проведение соревнований, игр или скачки на лошадях. Также обязательно угощение — каша или по-татарски «ботка».

3. Ураза Байрам - мусульманский праздник окончания священного поста "Ураза".

Частью культуры является и национальная кухня. Татарская национальная кухня богата вкусной выпечкой. Местные сладости — это кулинарная визитная карточка Татарстана. Среди особенностей можно выделить тот факт, что большинство татарских блюд готовится в национальной посуде, казане или котелке. Например, такие как:

1. Бауырсак - пресная сдоба, посыпана сахарной пудрой
2. Өчпочмак - пирожок треугольной формы с мясом, картофелем и репчатым луком
3. Кыстыбый - обжаренная лепёшка с начинкой, чащевсего, картофельное пюре
4. Гөбәдия - круглый пирог, начинка с яйцом, рисом, изюмом и красным томленым творогом «кырт».

Татарский национальный костюм играет важную роль в культуре татарского народа. Костюм обладает ослепительной красотой и передаёт весь колорит нации. Татарский костюм был сформирован на протяжении многих столетий, сохранил и пронёс первоначальный вид до наших дней. В музеях Татарстана можно наблюдать костюмы и их подробный состав:

В женский народный костюм входило: длинная туника, камзол, штаны "ыштан", передник, нагрудник, калфак,а на ногах расписные сапожки, изготовленные из кожи.

В мужской народный костюм входило: тюбетейка, рубаха свободного кроя, брюки и кожаная обувь.

Подводя итог вышеизложенному, можно отметить, что татарский этнос прошел сложный путь своего исторического и культурного развития. Татарстан, сумевший сохранить оригинальность и самобытность культуры страны, является частью мирового культурного наследия.

Литература

1. История, культура, религия. https://tatarstan.ru/about/human.htm (дата обращения 27.10.2023г.)
2. Обычаи и традиции татарского народа. https://kukla-v-podarok.ru/tatarskaja-nacionalnaja-kultura.html (дата обращения 27.10.2023г.)
3. Татары: интересные обычаи и особенности быта. ttps://experience.tripster.ru/articles/tatary-interesnye-obychai-i-osobennosti-byta/#headerh210 (дата обращения 28.10.2023г.)

4. Татарские праздники. https://tatarstan-omsk.ru/Kultura/Tatarskie-prazdniki (дата обращения 28.10.2023г.)
5. Татары. https://tatarlar.info/ (дата обращения 29.10.2023г.)
6. Культура народов Татарстана ttps://rusneb.ru/catalog/000199_000009_003322959. (дата обращения 29.10.2023г.)

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУДА ЗАМАНЧА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Камалиева Р.Р.
Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты
Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача аңлауны таләп итә. Мәктәпләрнең бүгенге бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү. Бүгенге көндә белем-тәрбия бирү процессын тормыш белән бәйләп алып бару зарурилыгы да артты. Дәресләрдә әле моңа кадәр билгеле булмаган чаралар кулланыла, элеккеге метод-алымнар яңара, камилләшә.

Татар теле һәм әдәбиятын яңа технология аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә коммуникатив укыту технологиясе, шәхси якын килү, проект, компьютер технологияләре, сәламәтлек саклау һәм уен технологияләренең роле алыштыргысыз [Харисов 2002: 61].

Укучыны укуга, фикерләргә, сөйләмгә этәрә торган технологиянең берсе –коммуникатив технология. Бу технология баланы үз фикерен әйтә, иптәшләрен тыңлый белергә өйрәтә. Аны тыңлаячакларын, аның әйткән фикерен тыңлап бәя бирәчәкләрен аңлаган, белгән бала материалны укып килмичә, үз фикерен әйтмичә, үзен күрсәтмичә кала алмый. Бу – аңа кызык, бу аңа тормышта үзен табу өчен кирәк. Коммуникатив технология уңайлы психологик атмосфера тудырырга булыша, укучыларда бер-берсенә ярдәмләшеп, килешеп эшләү күнекмәләрен формалаштыра.

Бүгенге көндә белем бирү, иң беренче чиратта, инновацион мәгълүмати-комьютер технологияләре белән бәйле. Дәрестә компьютер технологияләрен куллану, күрсәтмәлелек аша күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә. Укытучының гади сөйләме белән чагыштырганда, матур һәм күп мәгълүматларны үз эченә алган презентацияләр укучының игътибарын үзенә ныграк җәлеп итә, дәрес материалын күз алдына китерергә, төрле модельләр төзергә, таблицалар, тестлар ярдәмендә уку-укыту барышын кызыклы итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Соңгы елларда гамәлгә кергән онлайн-тестлардан куллану эшне тагы да җайлаштыра. Практика күрсәткәнчә,

дәресләрдә компьютер кулланып белем бирү традицион методлардан өстен булуын раслый, укучы дәресләрдә актив катнашучы була. Компьютер программалары укытуны индивидуальләштерүгә ярдәм итә, укучыларның мөстәкыйль эшләүләрен оештырырга мөмкинлек бирә.

Уку-укыту процессы сәламәтлекне саклау технологияләреннән башка була алмый. Һәр дәрестә үткәрелгән физкультминутлар заманча булулары белән беррәттән, сәламәтлекне саклауга юнәлдерелгән булырга тиеш.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә мәдәниятлар аралашуы технологиясен куллану да аерым игътибарга лаек. Әдәбият балаларга тәрбия бирә. Әлеге технологияне куллануның төп максаты гомумкешелек һәм гомуммәдәният кыйммәтләрен үзләштергән, милләт язмышында үз урынын тапкан, аңа битараф булмаган файдалы шәхесләр тәрбияләү. Үз эшчәнлегебездә әлеге технологияне куллану алга куйган максатыбызга ирешүдә, балаларны яхшы кешеләр итеп тәрбияләүдә зур ярдәм итәчәк.

Укытуда уен технологиясен куллану укытучы-укучы мөнәсәбәтен ныгыта, уку-укыту эшчәнлеген җанлы итә. Уен технологиясенең нигезен тәшкил итә торган эшлекле, рольле, имитацион уеннар укучыларның оештыру сәләтен, икътисади фикерләү дәрәҗәсен, экологик культурасын үстерергә ярдәм итә. Урынлы, оста итеп оештырылган уеннар балаларда телгә карата кызыксыну уята[Айдарова 1999: 45].

Һәр балага шәхси якын килеп укыту – иң мөһиме дип әйтер идем. Шәхси якын килү технологиясе – барлык укытучылар коралланырга, белергә тиешле технология. Ул фән буенча һәр укучының уку мөмкинлекләрен ачыкларга, эшчәнлекне балаларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәптә тотып оештырырга мөмкинлек бирә. Һәр укучыны аерым өйрәнеп, бөтен сыйныф белән уңышлы эшләү юлын ача. Укуда артта калучы укучыларга ярдәм итәргә, сәләтле укучылар белән тирәнтен эш алып барырга мөмкинлекләр тудыра.

Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Хәзер балалар бакчасында ук заманча технологияләрне үзләштерү мөмкинлеге тудырылган. Әгәр дә элек мәктәп баласы өчен мәгълүмат чыганагы булып китап һәм мөгаллим торса, бүген ул барлык кызыксындырган сорауларга җавапны интернет челтәре аша да таба ала. Шуңа да хәзерге педагоглар үсмерләрне үз фәне белән кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле хәйләләр уйлап табарга – шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында кулланырга тиеш. Хәзерге көндә мәгълүмати белем чыганаклары уку-укыту системасында аерылгысыз бер тармак булып тора.

Яңа технологияләр буенча эшләү укытучының дәресләрдә төрле позициядән чыгып эшләвен күз алдында тота. Ул режиссёр да, укытучы да, укучы да, билгеле бер эшнең оештыручысы да була.

Мәктәптәге традицион, бертөрле үткәрелгән дәресләр арасында, гадәти булмаган дәресләр үткәрү укчыларның хәтерендә ныграк кала.

Ялкыткыч эш төрләрен һәр дәрестә кат-кат башкаруга караганда кызыклы ачышлар булганы укучының күңеленә тәэсир итә, аң-белемен киңәйтә, иҗади

эзләнүгә теләк тудыра. Шуңа да укучының белем сыйфатын күтәрүдә, иҗади сәләтләрен үстерүдә яңа технологияләрне өйрәнү һәм дәрестә куллану мөһим.

Әдәбият


3. Айдарова С. Белемгә уеннар аша. – Казан: Мәгариф, 1999. – №1. – Б. 40-41.

4. Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр. – Казан:Мәгариф, 2002. – № 8. – Б.33-36.

5. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗәнова Г.М. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда яңа технологияләр. – Яр Чаллы, 2011. – 61б.

6. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогик технологияләр: уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2008. - Б. 54-55.



**Кәбирова И.М.** (С.А.Ларионов исемендәге 2 нче номерлы Чирмешән гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Ганиева Э.З.


## Г. ГЫЙЛЬМАНОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ МОҢЛЫЛЫК СУРӘТЛӘНЕШЕ


Кәримова Т.
Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Низамбиева Р. Р.


Безнең халык кайгы-хәсрәттән, сагыштан, хискә бирелгән, эчке рухи эзләнүләреннән моңланган. Шушы күренешнең мин Г.Гыйльманов иҗатында ачык чагылганын тойдым. Бу эзләнү эшендә авторның бик күп хикәяләре арасыннан мин “Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах” хикәясен өйрәндем.

Әсәрнең сюжет-композициясе – әсәр бер вакыйгадан, ягъни бер сюжет сызыгыннан тора. **Экспозиция**. Ленар электричкадан төшә, күршедәге Бүреле авылында яшәүче әбисенә юл тота. **Төенләнеш**. Юлда ялгызы, соңгы елларда ул якта бүреләр ишәйгән. **Вакыйгалар үстерелеше**. Мәскәүдә конкурста булган вакыйларны искә төшерә. Ленар татарча белмәвеннән каушап кала.Талантлы уллары белән горурланып утырган ата-ана бу минутта бәхетсез, хәтта шомлы-сагышлы кыяфәткә төшә. Шунда Ленарның күңеленә Казанга кайткач, әбисенә бару теләге уяна. Ленар авылга ат юлыннан төшәргә була. Әмма юлында куаклыкның аргы очыннан караңгы тере тасма. **Кульминацион нокта**. Ленар бүреләр өере белән очраша. Кулындагы скрипкада, үзенең йөрәгендә ниндидер сихри көч тоеп, Ленар ярсып уйнарга керешә. Бах музыкасы, аннан моңлы татар көе тарала. **Чишелеш**. Менә алар бердәм кубып, дүртаякларына калкындылар, Ленарга карап килгән эзләре буенча китеп бардылар.

Шунда ук автор ситуациягә бәя дә бирә: «Ленарның үз гомерендә бүре күргәне юк. Мондый хәтәр хәлдә калганы да юк. Шуңа күрә бу хәлдә нишләргә кирәген ул белми. Бүреләр дә белмиләр, ахры. Әнә, алар туктап калдылар,

борылып, авылга таба карап тордылар...». Бу очракта да автор бүреләр мисалында табигатьне җанлы итеп, кешеләштереп бирергә омтыла. Бүреләрдә дә кешеләргә хас хис, акыл бар дигән фикерне алга куя. Иң авыр вакытта Ленарның күңеленә уй килә: «Әллә сөйләшеп карарга мы?» Алай дип әйтергә татарча белми бит ул. Ә болар – татар бүреләре. Димәк, хикәядә күтәрелгән төп фикер туган тел, милли аһәң, милли әдәбият-мәдәният һәм милли тарих белән бәйләнгән булып чыга. Төп фикер икенче, яшерен катламда бирелгән. Ленарның татарча начар белүе дә, әти-әнисенең бу эшкә битарафлыгы да автор тарафыннан тәнкыйть ителә. Ленарны кыргый табигать белән күзгә-күз очрашкан вакытта, «Туган тел» коткарып кала. Әлбәттә, бу вакыйга символик мәгънәгә ия.

**Хикәядәге образлар, аларның эш-гамәлләрен, хис-тойгыларын, әсәрдә тоткан урыны. Кеше образлары**. Ленар-хикәядә төп герой, татар егете. Унынчы сыйныфта укучы, музыка мәктәбен тәмамлаган, консерватория каршындагы махсус училищеда укый. Яшь скрипкачылар конкурсы лауреаты. Автор аны сәләтле, моңлы, талантлы егет итеп сурәтли. Авыр хәлләрдә югалып калмый. Көрәштә аңа татар моңы ярдәм итә.Ул үзен чын ир-егет итеп күрсәтә. Рухи көчне милли моңнардан, туган теленнән, әбисенең күңел җылысыннан таба. Әти-әни, әбисе, укытучы, Иоһанн Себастьян Бах -ярдәмче образлар. Әбисе Ленарга туган телендә сөйләшергә өйрәтүче, җылылык һәм рух чыганагы.

**Җыелма образ**. Туган җир, Бүреләр авылы, Мәскәү шәһәре, Казан, Ходай Тәгалә, Табигать. “Нишләргә? Көтәргә... Ходай Тәгаләгә ышанырга... Табигатьнең үз акылына ышанырга... Аз гына вөҗданы булса, ул Ленарны рәнҗетмәячәк, кыерсытырга да ирек бирмәячәк..”. Бүреләр белән беренче тапкыр очрашканда, Ленар күңеленә менә шундый уйлар килә. Ул алардан ярдәм сорый.

**Табигать һәм әйбер образлары**. Бүреләр, скрипка, юл, төн, караңгылык, кыш, мичтән чыккан төтен, яз. Вакыт белән бәйле образлар символик мәгънә ала. Төн -куркыныч шомлы вакыт. **Юл образы** хикәядә зур урын ала. Вакыйга юлда бара дидек. Без хикәядә автор тарафыннан сурәтләнгән төрле юлларны күрәбез. Мәсәлән, авыл юлы, машина юлы, ат юлы, чана юлы. Һәрберсе дә авылга алып бара. Минем уйлавымча, автор төрле юл образлары аша кеше үтәсе язмыш юлына ишарәли. Ленар үз юлын үзе сайлап ала.Ул олы юлны түгел, ат юлын сайлап ала. Монда мин тирән фикер салынган дип уйлыйм. Ленарга тормышта олы юллар ачылган. Әмма аның күңеле әби-бабасы, әти-әнисе туган, яшәгән кече туган җиргә бару юлын сайлый. Дөрес. Үз туган җиреңне, туган нигезеңне, үз туган телеңне белү мөһим. Татар күңеле, моң, нигез, туган тел, күңел җылысы тарта кеше күңелен. Мичтән чыккан төтен образы да шуңа ишарәли кебек. Әбисе йорты ягыннан төтен баганасы күтәрелүе малайга киләчәккә өмет бирә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: авторны бүгенге көндә мөһим булган тел, милләт, татар халкы, аның яшәеше мәсьәләсе борчый.

Әдәбият

1.Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек / Рәис Даутов. Икенче китап - Писатели нашего детства: Биобиблиографический справочник / Раис Даутов. Вторая книга. – Казан: Мәгариф, 2004. – 286 б.
2. Вәлиулла И. Һәр шагыйрь - бер дәрья: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / – Казан: Татар кит.нәшр.., – 208б.
3.Гыйльманов Г. Тозлы яңгыр: повестьлар, хикәяләр, нәсерләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1993. – 351 б.
4.Корбан Р. Алиш варислары: Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш премиясе лауреатлары әсәрләре/ - Казан: Татар.кит. нәшр.. 2010. – 183б.

## УКЫТУЧЫ ТОРМЫШЫНДА ҮРНӘК ШӘХЕСЛӘР

(“Чал тарихлы мәктәбемнең ак яулыклы остазы”)

Латыйпова А.А.
Актаныш 1 нче урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Рахманова Г.Ф.

“Зур бәхетләр, сызганып, эшкә бирелгәннән килә...”

2023 ел Россиядә “Укытучылар һәм остазлар елы” дип игълан ителде. Шунлыктан быел меңләгән укучылар рәхмәт хисләре белән мөгаллимнәрен искә ала, алар алдында баш ия. Нәкъ менә шушы хисләр укытучы өчен иң зур бәһа булып тора да.

Олы хөрмәткә, ихтирамга лаек остаз, үрнәк, сөекле әни, кадерле дәү әни, бүгенге көндә 37 ел гомерен укытучылык эшенә багышлаган. Аның тормыш юлын, биографиясен өйрәнгәннән соң, үземә гыйбрәте булган вакыйгаларны билгеләп китәргә телибез.

**Әтисе:** Гавис Исмәгыйль улы. Бабасы – Бигашев Исмәгыйль, 2 гильдия купец булган. Әбисе һәм бабасы репрессиягә эләгәләр, маллары тартып алына, йортлары яндырыла. Әбисе төрмәгә ябыла, төрмәдән кайткач бик авыр шартларда яши.

**Әнисе:** Бибинур Закир кызы. Такталачык авылындагы танылган Мутиннар нәселеннән. Бабасы әнисе Бибинурга Закирова фамилиясен бирә. Сәбәбе - репрессия җиленнән саклау.

**Рәйсәлә Гавис кызының нәсел җепләре бик үзенчәлекле шәхесләргә барып тоташа. Аның дәрәҗәле, олугъ шәхес булуында әлеге кешеләрнең роле зур булгандыр дип уйлыйм. Хәзер Рәйсәлә гавис кызының тормышында әһәмиятле роль уйнаган туганнарына тукталып китәсем килә.**

Әбекәе Фәрхенур Дәүләтьяр кызы була. Аның бертуган апасы – Бал әбекәй – аяклы фольклор иде. Ул безгә унар көнгә утырмага килеп, бәетләр, мөнәҗәтләр, табышмаклар, дүртьюллыклар сөйләп-җырлап ушны ала иде. Бал әбиемнең су алганда әйтә торга догасы истә калган, мин аны бүген дә укыйм ди Рәйсәлә апа.

*Аллы-гөлле суларымны таза кылдым, илаһым,*
*Ожҗмах дигән җирләреңнән урын бир дип, илаһым.*
*Тәмуг дигән җирләреңнән азат кылгыл, илаһым.*
*Гөнаһым күп – гамәлем юк, ярлыкагыл, илаһым!*

Әниемнең бертуган абыйсы Килдияр – бик гыйлемле кеше, мәдрәсә бетергән, "Коръән-Кәрим"не яттан белүче була. Империалистик сугышта катнашып әсир кала, туган илгә исән-сау кайтырга насыйп була үзенә.

Килдияр абыйны без Гаяз Исхакыйның танылган хикәясендәге Сөннәтче бабайга охшата идек. Бик чиста, төгәл, сабыр, һәркемгә үрнәк кеше иде. Ишегалларында ямь-яшел чирәм үсеп, уртасында тар гына сукмак булып, көтүгә чыккан-кайткан сарык-бәрәннәре дә, читкә тайпылмыйча, чирәмгә кермичә, әлеге сукмактан гына йөриләр иде. Андагы тәртипкә шакката идек.

Килдияр абый безнең Такталачык авылына үз эшләре белән базарга дип килә, килүен алдан ук белеп, ул килгән кичтә өебезгә авыл халкы җыела иде. Килдияр абый – мәдрәсә бетергән гыйлемле кеше – искиткеч вәгазьләр сөйли. Шул хикәятләрдән "арбасыз чаналар йөрер, чыбыксыз әйберләр белән сөйләшерләр" дигәннәре бүген дә хәтердә калган. Килдияр бабакайны бик яраттым.

Минем әткәем Гависның дингә килүенә Килдияр абыйның мөнәсәбәте зур була. Кечкенә чактан әти белән әниемнең сәке өстенә басып, намаз укыганнарын хәтерлим. Безнең өйдә гает намазлары уза торган иде. Дин ирегә башлангач, әткәем Такталачык авылында искергән мәчетне торгызу эшләрендә катнашып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр авыл имамы вазыйфаларын башкарды.

Әнкәем Бибинур да намазлы булды. Аның тормышы бик гыйбрәтле. 16 яше тулгач, Минзәлә педучилищесына укырга бара. 2 ел бик яхшы укый. Соңыннан ашау-эчүгә харам кергәнгә (ашны дуңгыз салосы белән пешерә торган булалар), училищены ташлап, ачлыктан кайтып егыла. Менә ничек булган мөнәсәбәт хәләл ризыкка! Авылга кайткач, Чалманарат балалар бакчасы мөдире аны тәрбияче итеп эшкә ала. Балалар бакчасы һәм мәктәп эшчеләрен ул елларда төнге колхоз эшенә чыгара торган булганнар. Әнием шунда сабан, тракторга гашыйк булып, трактористлыкка укырга китә. Әтием белән колхоз эшендә танышып, бергә олыгайганчы колхозда эшлиләр, динне дә калдырмыйлар. Әнием – иҗади кеше: әтигә хатларны да шигырь белән яза торган була. Әниебезнең яраткан сүрәсе "Тәбәрәк" иде, яттан сөйли иде, - ди Рәйсәлә Гавис кызы үз әти-әнисе турында.

Менә шундый шәхесләр кулында тәрбияләнеп, Рәйсәлә Гавис кызы олы тормыш юлына аяк баса. Алабуга пединститутының рус филологиясе факультетын бетереп, Актаныш районына рус теле укытучысы булып эшкә кайта. 37 ел Актаныш авылларында тормыш иптәше Шәвәлиев Илгизәр Фәтхел улы белән бергәләп гомерләрен мәгарифкә багышлыйлар алар. Актаныш 1нче урта мәктәбендә эшләгән чагы турында: " Мәктәп рус теле олимпиадаларында районда 9-10 урын алган еллар булды. Республика күләмендә 5 ел рәттән урын алып килдем. Бик теләп эшләдем," –ди Рәйсәлә апа.

Хезмәтенең нәтиҗәсе дә куанычлы: ул РСФСР Мәгариф Отличнигы һәм Татарстанның Атказанган укытучысы исеменә лаек Рәйсәлә Гавис кызы Шәвәлиева.

Рәйсәлә Гавис кызы гаиләдә дә үрнәк әни, бәхетле дәү әни. Җәмәгате Илгизәр Фәтхел улы белән 3 кыз үстергәннәр.Кызлары, кияүләре , оныклары барысы бергә әти-әни нгезенә кайтканда 28 гә җитә. 8 оныгы һәм 2 оныкчыгы бар аларның бүгенге көндә.

Шәвәлиева Рәйсәлә Гавис кызының тормыш һәм хезмәт юлы белән танышканнан соң мин шундый нәтиҗәгә килдем:

1. Кешенең шәхес, кеше булып формалашуында гаилә тәрбиясе зур роль уйный. Гаиләдәге әти-әни, апа-абый тәэсире бик зур.
2. Тормышта зур уңышларга ирешер өчен һәр җирдә дә, бар эштә дә бөтен көчеңне биреп эшләргә кирәк.
3. Үзең башкарган эшеңне яратып башкарырга кирәк. Шул очракта гына син үзеңне бәхетле саныйсың.
4. Кеше нинди генә уңышларга ирешмәсен, аның бәхете гаиләдә һәм үзеннән соң игелекле, белемле буын калдыра алуда.

Рәйсәлә Гавис кызын зыялы ата-ана тәрбияләгән, алар үзләре дә зыялы шәхесләр булып, үзләреннән соң хөрмәткә лаек алмаш калдыру бәхетенә ирешкәннәр. Менә шундый матур шәхесләр яши безнең Актаныш җирлегендә.

## ЯКТАШ ШАГЫЙРЬЛӘР ИҖАТЫНДА ЭНДӘШ СҮЗЛӘР

Мәрданов Н.Р.
Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән
урта гомуми белем мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Мәрданов Р.Ә.

Язучы якташыбыз Шәйхи Маннур Мамадыш редакциясе каршында эшләп килүче әдәби-иҗат берләшмәсенә - “Агымсу” дип исем кушарга тәкъдим итә. Чыннан да, төрле иҗат көчләрен-чишмәләрне үзенә туплаган бу берләшмә агымсуга охшаган. Һәр автор үз юлы, үз җыры белән уртак агымга кушыла. Хәзерге журналистика, шигърият, проза, җыр-музыка өлкәсендә әлеге берләшмәдә канат ныгыткан кешеләрнең күп булуы бер дә гаҗәп түгел. Без моның белән горурлана алабыз.

Әлеге берләшмә аша халыкка танылган җирле шагыйрьләребезнең икесе һәм алар иҗатында эндәш сүзләрнең кулланылышы белән сезне дә таныштырасым килә. Алар, авылдашларым, Нәкыя апа Йосыпова һәм Гаяз Сәләхов. Кызганыч, Нәкыя апа Йосыпова бүгенге көндә безнең арада юк. Әмма аның шигырьләрен без укыйбыз, өйрәнәбез, ә дистәдән артык шигырьләренә көй язылган җырлары бүгенге көндә татар эстрадасы сәхнәсендә яңгырый.

Татар теле дәресләрендә якташ язучыларыбыз иҗатын куллану ике яклы отышлы дип саный укытучыбыз. Иҗат белән танышу аша дәрес темасын төгәлрәк аңлау мөмкинлеге туа дигән фикердә ул. Шуңа күрә эзләнү-өйрәнү форматында түбәндәге эш формаларын тәкъдим итә. Шуларның берсе хакында

тулырак. **Тема:** “Якташ шагыйрьләр иҗатында эндәш сүзләр”. **Максатым:** якташ шагыйрьләр иҗатында эндәш сүзләрнең кулланылышын өйрәнү.

**Бурычым:**

-Нәкыя Йосыпова һәм Гаяз Сәләхов шигъри җыентыкларынан шигырьләр уку;

-шигырьләрдән эндәш сүзләр кулланылган җөмләләрне җыеп алу;

-эндәш сүзләрне төркемләү;

Моңа кадәр мин әлеге шагыйрьләрнең шигырьләрендә төсләр куллану үзенчәлекләрен өйрәнгән идем. Ә хәзер аларның эндәш сүзләрне ничек кулланганнарын карап китик.

Нәрсә соң ул эндәш сүз? Ф.С.Сафиуллина һәм М.З.Зәкиевның “Хәзерге татар әдәдби теле” югары һәм урта уку йортлары өчен тәкъдим ителгән дәреслектә (338 нче бит) мондый аңлатма бирелә. Сөйләм төбәлгән затны белдереп килгән сүз эндәш сүз дип атала. Алар сөйләүченең тыңлаучыга яки гомумән табигать күренешләренә мөрәҗәгатен, мөнәсәбәтен белдерә. Эндәш сүзләр бик күптөрле стильләрдә (хатларда, лозунгларда, речьләрдә, матур әдәбиятта һ.б.) кулланыла. Шулай да аның иң күп кулланылган урыны-диалоглар. Эндәш сүзләр һәрвакыт икенче затка караган җөмләләрдә булалар.

Инде ике җирле шагыйрьнең иҗатын чагыштырып карасак, эндәш сүзләрне куллануары түбәндәгечә:

| **Гаяз Сәләхов шигырьләре** | **Нәкыя Йосыпова шигырьләре** |
|---|---|
| **1.Кеше исемнәре эндәш сүз булып килә.** | |
| - | *Әй,Хәлимә,Хәлимә,*<br>*Кер син минем хәлемә;* |
| **2.Кеше исемнәре янында апа, абый, әби, бабай, энем, сеңлем, туган, туташ, ханым, әфәндем кебек мөрәҗәгатьне, туган-тумачалыкны яки якынлыкны белдерүче сүзләр килеп ясала.** | |
| **3.Кош-корт, хайваннарны атаучы сүзләр эндәш сүз була ала. Кайбер очракларда әлеге сүзләр, кешеләргә карата иркәләү сүзе буларак кулланылырга да мөмкин.** | |
| | *Кайткан кошларым, кабат китмәгез,*<br>*Ерак илләрдә иркен димәгез.* |
| **4.Гомумән кешеләргә карата әйтелә торган сүзләр эндәш сүзләр булып килә.** | |
| *Абый, син бит бу дөньяга,*<br>*Көтеп алган бала булгансың.* | *Ай-һай авыр очу бер канатта,*<br>*Кайт инде, кайт, газиз этием.* |
| *Мин сине эзләрмен,*<br>*Син генә оныта, гүзәлем!* | *Сине көтәм,иркәм,*<br>*Көн дә төштә күрәм.* |
| *Ә ак каен җавап бирде:*<br>*“Чү,сабыр бул,дускаем,* | *Сөрмәләр тартам,җаныем,*<br>*Кашларым каралсынга.* |
| *Шуны аңласаң иде бит,*<br>*Аңласаң иде,картлык!* | *Уйна,дустым,гармуныңны,*<br>*Бармакларың талганчы.* |
| *Рәнҗисеңме әллә,әнием,миңа,* | *Үтте гомер үкенечле,* |

| | |
|---|---|
| *Яннарыңа сирәк кайтканга?* | *Кичер мине,алтмышым.*<br>*Гомер әле туктамасын*<br>*Яши бирик,язмышым.* |
| *Әткәм-әнкәм,сезне искә алам,*<br>*Озак кайтмадым,сагынып калам.* | *Әйдәгез сез,карт агайлар,*<br>*Яшьләр белән сынашыйк.*<br>*Ай молодец,балакаем,*<br>*Бигрәк матур биисең.* |
| **5. Җансыз предметларны, төрле табигать күренешләрен атаучы сүзләр дә эндәш сүз була.** | |
| *Горурланам синең белән*<br>*И туган тел,туган тел.* | *Кирмәнем,синдә калды сөйгәнем,*<br>*Кирмәнем,үтә лә гомерләрем.* |
| *Яратам мин сине, и Кирмәнем.* | *Салкын чишмәм,бөдрә талым,*<br>*Суларыңа барам мин.* |

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: якташ шагыйрьләр иҗатларында шактый гына эндәш сүзләрне кулланалар. Шулай да 2нче төркемгә туры килгән мисаллар табылмады. Тагын шунысын да әйтергә кирәк. Гаяз Сәләхов шигырьләрендә кеше исеме белән бәйле эндәш сүзләр очрамады. Шулай ук җөмләдән тыш килгән эндәш сүзләрне ике шагыйребез үз иҗатларында кулланмаганнар.

Әдәбият

1. Салахов Г.З. Узган гомер-моңлы бер җыр иде..– Алабуга:АБАК,2022.– 51 б.
2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1994. – 405 б.
3. Юсупова Н.М. Чын күңелдән. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2005. – 55 б.

## АВЫЛ ТОРМЫШЫН СУРӘТЛӘҮ ОСТАСЫ БУЛАРАК Р.ТӨХФӘТУЛЛИН

Мәткаримова А.Х.
Әлмәт шәһәре «13нче урта гомуми
белем бирү мәктәбе» укучысы
Фәнни җитәкче: Гарипова А.Ш.

Һәр кешенең туган җире бар. Ә күпчелек өчен бу туган шәһәре, авылы. Татар язучы һәм шагыйрьләренең күбесе чыгышы белән авыл балалары. Шундый авыл балаларының берсе - танылган язучыбыз Рафаил Төхфәтуллин. Ул Арчадан төньякка таба егерме чакрымнар җир китеп урнашкан Яңа Иябашның күршесендә генә Тукай-Кырлай урнашкан. Мәшһүр Казан арты бу! Тукай үз әсәрләрендә дан җырлаган табигатьле Казан арты.

Җир һәм кеше... Алар гел икәү бергә булган, аларны бер-берсеннән аерып карау мөмкин дә түгел. Кеше җирне тыңлаучанрак, мәрхәмәтлерәк һәм уңдырышлырак итә барган. Җир кешеләрне хезмәт сөючән, сабыр һәм түзем булырга өйрәткән, аларның холкын, табигатен үзгәрткән. Һәр җирнең үз табигате булган кебек Казан артында да аерым бертөрле табигать. Анда шактый басынкы һәм тыйнак, ифрат дәрәҗәдә тырыш һәм унган, хезмәт сөючән, җиргә гашыйк кешеләр формалашкан. Рафаил Төхфәтуллин нәкъ шундый кешеләрнең берсе. Аның әсәрләрен укыганда, шул якларның сабыр холыклы эшчән кешеләре белән очрашасың, барыннан да бигрәк, данлы Казан артының үзгә бер сулышын, рухын тойгандай буласың. Р.Төхфәтуллин күп санлы әсәрләренең нигезендә шушы табигать балаларының язмышы ята.

Язучының иҗатында күпчелек сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышы сурәтләнә.  Р.Төхфәтуллин ул - берничә пьеса, унлап повесть, йөздән артык хикәя, очерк, рус һәм татар телләрендә басылган утызлап китап авторы. Аның «Җәйге челләдә», «Авылым хикәяләре», «Йолдызым», «Зәңгәр кыңгыраулар», «Җиләкле аланнар» кебек китаплар зур тиражлар белән басылып, ил күләмендә бәя алалар.

Аларда шул авыр һәм кырыс елларга хас тормыш күренешләре теркәлеп калган: кыйшаеп җимерелергә җиткән терлек абзарлары; ябык сыерлар һәм арык атлар; рәтләп эшкәртелмәгән, шуңа күрә чүп үләне басып киткән иген кырлары...

Болар белән беррәттән тулы канлы, катлаулы характерлар, тормышчан образлар иҗат итә. Ул укучыга җиргә карарга, халыкның матурлыгын гәүдәләндерерлек әйбәт кешеләрне, ат караучылар, балта осталары арасыннан эзләргә өйрәтә.

Әмма күп санлы һәм күп төрле сыйфатлар арасыннан аеруча әһәмиятлесе, иң мөһиме - язучы әсәрләренең тормышчанлыгы. «Р.Төхфәтуллин уз геройларының характерын, холык-фигелен һәм язмышын тормыш шартларына бәйләп, шулардан аерылгысыз итеп күрсәтә алды. Җир һәм кеше, колхоз һәм колхозчы, алар арасындагы мөнәсәбәт, аларның үзара бәйләнеше һәм бер-берсенә йогынтасы - язучы әсәрләренең  буеннан-буена кызыл җеп булып, сузылган төп сыйфат», - дип яза Фәрваз Миңнуллин автор турында.

Рафаил Төхфәтуллин - авыл язучысы һәм туган җирдән беркайчан да аерылып китмәс шикелле. Авылның сугыштан соңгы кыенлыкларын әдәбиятта яшермичә, турыдан-туры ачып салучыларның да беренчеләрдән ул булды. Тормышның чын күренешләрен сүрәтләү әдип иҗатында гаҗәеп бер лирик рух, эчке җылылык, самимлек белән аралаша. Шуның әсәрләренең берсе – «Йолдызым» повесте.

«Йолдызым» повесте үткәннәрне искә төшерү юлы белән язылган. Бу алым кулланып язылганлыгы белән бу повесть авторның тагын бер әсәре булган «Авылдашым Нәби» белән бик охшаш, ләкин аерымлыгы да бар. «Йолдызым» повесте - тирән эчтәлекле, актуаль тема һәм проблематикалы әсәр. Бу повестьнең идея-эчтәлеге дә үзенчәлекле. Ә ул үз чиратында авторның иҗади осталыгына бәйләнгән.

Алда әсәрнең идея-эчтәлеге өстендә сөйләшү алып барырбыз. Иң беренче нинди генә әсәрне кулга алсак та, без аның исеме белән танышабыз. Чөнки нинди исемле булуы бик зур әһәмияткә ия. Һәр кешенең исеме нindидер мәгънәгә ия булган кебек китапның, әсәрнең исеме дә безгә бик күп нәрсә турында мәгълүмат бирә. Автор аны ни өчен шулай атаган? Ул бу исем укучысына нәрсә әйтергә теләгән? Бу сорауларга укучы әсәрне уку процессында җавап таба ала.

«Йолдызым» исеме - символик исем. Йолдыз - күк җисеме. Ул - өмет һәм иман, ышаныч символы. Димәк, әсәрдә дә геройлар өмет, ышаныч, иман белән яшәячәкләр. Һәм бу шулай да.

Р.Төхфәтуллин үз повестен, алда әйтелгәнчә, үткәннәрне искә төшерү алымы белән язган. Әсәр түбәндәге сүзләр белән башланып китә: «Әни, әни, дим! Нигә минем исемне Йолдыз дип куштыгыз?...» Кызының әлеге соравы төп героиня Гөлзифаны үткән тормышын хәтерләргә мәҗбүр итә. «Йолдызым» повесте төп геройның бер көндә гомерен иңли. Без Гөлзифаның бер көн эчендәге уй-хисләре, кичерешләре белән танышабыз, шулар аша үткәндәге бөтен тормышы белән танышып чыгабыз. Әсәрдә җир һәм кеше язмышы мәсьәләсе үзәккә куела, аларның аерылгысыз булуына басым ала.

Бу бәйләнешне күрсәтүче герой - Гөлзифа. Ул үзенчәлекле кеше. Автор бөтен әсәрдәге вакыйгаларны, образларны аның кичерешләре аркылы бирә. Бу әсәрне аңлаешлы, тирән мәгънәлештә ясый.

Гөлзифа - эшчән, тырыш, чөнки ул эштә үсә, чыныга, тәрбияләнә. Бу-авыр, ялгыз, физик хезмәт-сугыш елларында совет хатын-кызларның һичкайчан онытылмаска тиешле батырлыгы. Биредә хезмәтнең романтикасы, матурлыгы, героикасы хакында уйланырга мөмкинлек тә, вакыт та юк. Чөнки башкача була алмый, башкча мөмкин дә түгел. Әгәр Гөлзифалар эшләмәсә, фронт ашсыз, җылы киемсез калачак. Гөлзифаның үзе турында, киенү, ясану кебек уйларына вакыты юк. Аның бар уе тагын да тырышыбрак эшләү генә. Җиңү хакына башкарылган бу батырлык әсәрнең патриотик яңгырашын билгели.

Чыннан да, моннан ике-өч еллар элекке оялчан гына, юка гына Гөлзифа түгел инде ул хәзер. Буйга әллә ни калыкмаса да, бу тыгыз, йомры гәүдәдә ташырга торган көч-куәт һәм сүнмәс дәрт сизәсең. Бармак төпләре уймак-уймак чокырлы бу куллар чыбыркы-дилбегәсен булсын, чалгы-тырмасын, балта-пычкысын булсын, нык итеп, җаен-әмәлен белеп тоталар; кечерәк кенә кытыршы гена бу куллар җил-салкынны уйлап та бакмый, тырналу-сыдырылуны бар дип тә белми...

Авторның хезмәт кешесенә олы ихтирамы бу әсәрдә дә ачык сизелә. Чын кеше - ул хезмәт кешесе, дигән төп фикер потрет билгеләре аша да гәүдәләнә.

Р.Төхфәтуллин героиняның нык характерлы, гадел, дөрес кеше икәнлеге хакында сөйли. Әсәрдә без Гөлзифаның һәртөрле ялганга, хаксызлыкка каршы көрәшкә чыгуына да, мәхәббәттә тугрылык сакчысы булганына да сокланып карыйбыз.

Әсәрдә автор үз идеясын тапшыру өчен башка образларны да куллана. Бу-Мөнир Гарапшин, Шәрәфи абзый, Җиһангирлар. Аларга капма-каршы Мортаза, Хәмдиев, Идрисовлар куелалар. Аларның үзара конфликтлары аша

автор дөреслек барыбер җиңәчәк, ә ялган соң булса да фаш ителәчәген күрсәтә. Ничек кенә авыр булса да, гаделлек өчен көрәшергә кирәк дигән идея үткәрә.

Автор һәр образның үзенә генә хас характерлы якларын тапкан, иң мөһиме, иң әһәмиятлесе шул: ул әлеге образларның фәлсәфәсен, аларның чын йөзен дөрес күрсәтә алган. Уңай геройлары аркылы автор иң четерекле мәсьәләсен берсе булган колхоз авылын аякка бастыру, аны үргә алып менү мәсьәләсен күтәреп чыга. Р.Төхфәтуллин бу кыенлыклар, авырлыклар турында «Йолдызым» повестена кадәр дә яза. Ләкин аның сәбәпләрен бер яклы гына карый. Ә «Йолдызым» повестенда язучы бу мәсьәләне яңадан күтәрә һәм шактый уңышлы хәл итә. Гөлзифалар колхозының язмышы бер заман бик тә әйбәт кешеләр кулына күчә: председатель итеп Шәрәфи абзый сайлана, Гөлзифаның үзен бригадир итеп куялар. ВЛКСМның райком секретаре Мөнир Гарапшин да хәттә искиткеч шәп кеше була. Әмма аңа карап кына Гөлзифалар колхозы алга китми. Р.Төхфәтуллин бары тик бергә, күмәк рәвештә үз-үзеңне аямыйча, тырышып эшләсәң генә, бу эшнең нәтиҗәсе булачак дигән фикер үткәрә.

Әсәрдә тагын кабатланып килгән мәсьәләләрнең берсе Давыт образы белән бәйләнгән. Колхоз эшен ташлап шәһәргә качкан, тегендә-монда китеп, акчалырак эшкә урнашкан кешеләр турында яза Р.Төхфәтуллин. Давыт - каршылыклы образ. Аны тискәре герой дип карау хата булыр иде, чөнки ул беткән җан түгел. Кайчандыр Давыт авылда иң алдынгы укучылардан саналып йөргән. Халык арасында абруе да зур гына үзенең, намуслы һәм әдәпле дә. Кәефе булганда, җир җимереп эшләүдән дә курыкмый, кулыннан эш килә. Әгәр тормыш җай гына барса, кыенлыклар белән очрашырга туры килмәсә, кем белә, бәлки, алар Гөлзифа белән әйбәт кенә яшәгән дә булырлар иде. Ләкин тормыш авырлыксыз булмый. Хатыны белән чагыштырганда аның ихтыяр көче бик зәгыйфь була. Вакытлы кыенлыклардан чыгу юлын алар икесе ике төрле аңлыйлар. Гөлзифә авылны яхшырту, колхозны ныгыту ягында. Тормыш авырлыклары алдында куркып, каушап калган Давыт шәһәргә качып котылмакчы була. Ләкин үзеңнән качып булмый бит. Давыт тиз үзгәрүчән, аумакай табигатьле кеше. Бу - аның эшкә һәм укуга мөнәсәбәтендә дә, кешеләргә мөнәсәбәтендә дә ачык күренә. Давыт кебек, авылдан шәһәргә качып, анда кыенга туры килә башласа, кире авылга кайтырга теләүчеләрне аклап та, аларга ышанып-таянып та булмый дигән автор фикерен күрәбез без Давыт образы аша.

Р.Төхфәтуллин “Йолдыз” повестенда бер генә деталь да, бер генә вакыйга да, бер генә күренеш тә юкка гына бирелми. Бу әсәр лирик буяуларга, мәгънәле, күп сыйдырышлы эмоциональ-психологик детальләргә бай. Мондый детальләр күп очракта табигать бизәкләрен кешенең рухы, эчке дөньясы белән янәшә куеп, сынландыру рәвешендә бирелеләр.

Гөлзифаның омтылышы - бәхет йолдызы - «Йолдызым» повестеның буеннан-буена үтә, бу образ героиняның нык ихтыярлы, максатына ирешүчән булуы хакында сөйли. Икенчедән, буш хыял түгел бу. Аның конкрет чагылышы – халыкка хезмәт итеп, ил-җәмгыять арасында лаеклы урын табу, дан-хөрмәткә

ирешүендә яисә кыенлык белән яулаган гаилә бәхете – кызчыгы Йолдыз образында да күренә.

Тагын әсәрдәге бер детальнең булуы игътибарны үзенә тарта. Гөлзифа үзенең сөйгәненә һәм башка фронтовиклар өчен бияләйләр бәйли. Ул узенең күз нурын түгеп бәйләгән әйберләре белән фронт тормышын әз генә булса да җиңеләйтмәкче була, йорт җылысын өләшергә тырыша. Ә сөйгәненә хәбәр бирү өчен һәр бияләй эченә «Д.Г.» дигән хәрефләрне ефәк җеп белән чигеп куя. Ләкин бу бияләй Давытка эләкми, ә Мөнир Гарапшинга фронтта килеп эләгә. Язмыш үзе алдан ук кисәтеп куйганлыгын Гөлзифә соңыннан гына аңлый. Бу бияләй Мөнир өчен йолдызы кебек үк була. Ул аның авыр көннәрдә, дәһшәтле сугыш вакытларында бердәнбер өмет, киләчәккә ышаныч бирүче әйбере – «йолдызы» була. Автор бу детальләр аркылы кечкенә генә нәрсә дә кеше язмышында зур роль уйнавын күрсәтә.

Р.Төхфәтуллин геройлары өчен туган-үскән җир табигате, тормышларының аерылгысыз, органик бер кисәге. Табигать әсәрнең идея-эчтәлеген бирүдә әһәмиятле өлешләрнең берсе булып тора. Табигатьтәге үзгәрешләр һичшиксез геройланың уй-кичерешләре, хисләре, эчке халәтләре үзгәрү белән бәйле.

«Көндезен җепшетеп, кичке салкын белән чиратып җибәргән аяк асты атлаган саен кетердәп-кетердәп кала, чана табаны эзләре буйлап аккан гөрләвекләр күпереп-күпереп торган челтәрләргә әверелгәннәр, ә якында гына, Ашыт суы ягында, тыелгысыз бер гөрләвекнең һаман да челтерәп акканы ишетелә иде. Елга, узенең бу арымас шат нәни юлдашын тәбрикләгәндәй, куәтле-моңсу ухылдап куя, бу ухылдау кичке тынлыкта еракларга яңгырый; яңгырый да, уң яктагы Чагыл таулары аңа җавап бирәләр, гүя, әйдәгез, бердәмрәк, дип дәрт-куәт авазы салалар кебек иде. Яз, бернигә карамый яз килә иде...»

Бу, әлбәттә, яз килү күренеше генә түгел. Биредә Гөлзифаның күңел халәте дә сизелә. Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә күңел ачкычы булып һәрвакыт табигать күренеше хезмәт итә. Бу очракта без әлеге язны Гөлзифа кичерешләре, аның карашы аша кабул итәбез. Табигатьнең һәр үзгәрүе әсәрдәге вакыйгалар үзгәрүенә ишәрә ясыйлар. Моңа берничә мисал:

1.«Кояш шундый якты, шундый нурлы итеп елмая иде ул көнне, бар кешеләр дә шундый ягымлы, шундый әйбәт иделәр. Кулларга эш төткәзеп булмый, аякларга басып торыр урын табып булмый иде».

2.«...Көн аяз, кояшлы иде бугай, юл ташлары өстеннән бөтерелә- бөтерелә гөрләвекләр челтерәп ага иде шикелле. Ә асфальт тротуарлардан, гүя тирләгән ат сыртыннан, җиңелчә пар күтәрелә иде... Юк, көн һич тә аяз түгел, киресенчә, кап-кара болытлы көн иде, ахры. Гөрләвекләр дә челтерәми, бу шулай Гөлзифаның колаклары чыңлый иде бугай. Көне дә, бөтен дөньясы да томанга чумган иде. Кешеләр шул томан эченнән килеп чыгалар да шунда ук күздән югалалар, тагын күренәләр, тагын каядыр чумып юк булалар...»

Ә бу өзекне укыгач без ниндидер начар, җан өшеткеч вакыйга булуын аңлыйбыз. Бу өлешендә әсәрнең Гөлзифаның үзенең мәхәббәтен югалтуы

сурәтләнә. Аның кичерешләрен, кайгысын бары тик табигать кенә аңлый бу вакытта.

Ләкин автор табигатьтән оста файдалану белән генә чикләнми, ул Гөлзифага ярдәмгә «таныш булмаган дус» кертә. Бу кешенең булуы, аның эмоцианаль ярдәмен тоеп яшәү героиняга каршылыкларга, кыенлыкларга ярдәм итә, яшәргә көч бирә. Ә кешегә башка кешенең ярдәмен тоеп яшәү бик мөһим нәрсә.

«Таныш булмаган дус» үзенә карата Гөлзифадан берни дә өмет итми, барын аның бәхетле булуын гына тели. Ләкин шул ук вакытта кайчан булса да аның мәхәббәтенә лаек булырмын дип яши. Һәм чын да бу түземлелек язмыш тарафыннан бүләкләнә - ул Гөлзифаның иң олы рәхмәтләренә лаеклы.

Автор белән героиняның уйлау, фикерләү рәвешләре, дөньяга карашлары да бер-берсенә бик якыная. Әсәрнең беренче кисәгендә автор белән Гөлзифа уйлары, кичерешләре узара тыгыз аралашкан, шушы алым ярдәмендә төп тема һәм идеяны ачардай барлык иҗади чаралар эшкә җигелә. Әсәрнең икенче өлешенә куйган проблемалар исә башка төрлерәк чаралар сорый - авторның бу өлештә үз сөйләме күбәя.

Әсәр ахырында композицион тигезлек кими башлагандай була, бу Гөлзифа тарихының озагракка сузылуы белән бәйле. Шулай дә әсәрнең азагы оптимистик тоны, повестьның җанлы, табигый сулышы, яңгырашы өзенең ышандыру һәм тәэсир көчен арттыра гына.

Киң психологик анализ тарафдары Рафаил Төхфәтуллин бу повестенда хисләр, уйлар дөньясын эчтән яктырту алымын оста куллана. Бу әсәрнең идея-эчтәлеген бирүдә төп чараларның берсе. Шул ук вакытта автор башка чараларны да оста куллана. Р.Төхфәтуллин сурәтләвендәге күп санлы, мәгънәле деталь-штрихлар героиняның күңеленең олылыгын укучыга җиткерәләр. Кыен язмыш сынауларын үтүче кешегә теләктәшлек, үз итү хисләре белән беррәттән соклану хисләре дә уята.

Әсәрнең эчтәлеге әлеге чаралар ярдәмендә үзеннән-үзенә йомгак кебек вакыйгалар сүтелү рәвешендә ачылып бара. Повесть үзеннән-үзе укылып бара, укучы аңа бары тик ияреп кенә бара төсле. Бу әсәрнең язылу теле белән дә бәйле.

Әсәрнең язылу теле гади, аңлаешлы. Автор повестенда сүрәтләүнең бай булуы әсәрнең яңгыраш көчен тагы да арттыра. Ә бу үз чиратында исә әсәрнең идея-эчтәлеген ачуда зур этәргеч булып тора, повесть төзелешенең камиллегенә китерә.

Бу әсәрне укыгач, аның белән җентекләп танышкач бер нәрсә ачык күренә: сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышы турында язганда, Рафаил Төхфәтуллинның каләме тиңдәшсез иде. «Шул чор тормышы, аның кешеләре хакында никадәр әсәр иҗат итә. Ифрат отылышы әдәби детальләр, тотып-капшап карыйсы килерлек дәрәҗәдә җанлы һәм тормышчан булып чыккан образлар дисеңме, күңелнең әллә кай төшләренә барып җитәрлек җылылык кирәкме, гаять актуаль, барлык кешеләрне борчып-уйландырып килгән мәсьәләләр дисеңме- һәммәсе дә бер аның хикәя, повестьларында»,- дип яза аның әсәрләре турында Фәрваз Миңнуллин.

Чынлыкта да бу шулай. «Йолдызым» повесте - шул тормышка, шул чорга караган әсәрләрнең иң югары ноктасы. Сугыш һәм сугыштан соңгы колхоз авылына караган күзәтүләренең иң мөһим, иң әһәмиятлеләрен автор нигездә шушы әсәргә кертеп бетерә, аның авыл тормышы турындагы борчылу-уйлануларның да иң зур һәм иң төп өлеше шушы повестька сыеп бетә дияргә мөмкин.

Бу әсәрнең идея-эчтәлек ягыннан камил булуында ук күренеп тора. Р.Төхфәтуллин әсәрдә куелган проблема, мәсьәләрләрне чишү рәвешендә әсәрнең идеясын биреп бара. Бу Гөлзифаның тормышы, аның кичерешләре аркылы бирелә. Кеше авырлыкларны, үз җилкәсенә, башына килеп төшкән кайгы-хәсрәтне, кыенлыкларны сыгылмыйча, сынмыйча күтәргәндә генә үз максатына ирешә ала. Бары тик горур рәвештә хакыйкатькә тугры булып, үз намусыңны, вөжданыңны югалтмыйча, тап төшермичә яшәсәң генә бәхетле булырсың дигән идеяны ассызыклый Рафаил Төхфәтуллин.

Повестьның тәрбияви көче дә искиткеч. Төп героиняның сыйфатлары аркылы автор үз укучыларына, иң беренче чиратта, сабыр булырга куша. Юкка гына татар халкы: «Сабыр төбе - сары алтын»,- димәгән бит. Бары тик сабыр кешеләр генә үз теләгәннәренә ирешә алалар. Икенчедән, максатчан булу зарури, әгәр дә кешенең киләчәктә берәр уңышка ирешеп үз теләген тормышка ашырырга уйлый икән, аның һичшиксез үз алдына максат куюы кирәк. Өченчедән, һәрвакыт үз туган җирен, туган туфрагын, кендек каны тамганҗирен яратырга тиеш. Бары синең туган җирең булса гына, син чын мәгънәсендә узеңне бәхетле итеп саный аласың. Түбәндәге шәхси сыйфатлар бүгенге көндә бигрәк тә актуаль. Әсәр шушы ягы белән дә бик кыйммәтле.

Әсәрдә, гомумән алганда, чорның актуаль мәсәльләләре, өлгергән проблемалар күтәрелә, җәмәгатьчелек игътибарын шуларга юнәлтүе күренә. Р.Төхфәтуллин моның белән генә чикләнеп калмый, үзе күтәргән һәр мәсәльәләнең конкрет җавабын һәм чишелешен таба. һәр мәсьәләнең чишелешен дә табарга тырышу аркасында язучы кайбер житди мәсьәләләрне чишү юлларын гадиләштереп,җиңелләштереп бирергә мәҗбүр була. Тик шунысы һичшиксез: повестьның идеясы ачык күренеп тора. Әсәрнең төп идеясы бары тик үз эшеңне, үз туган җиреңне,туфрагыңны яратып үз халкың өчен хезмәт иткәндә бәхетле була аласың дигәннән гыйбрәт. Бу идеяны ачуда, алда әйтелгәнчә, Р.Төхфәтуллин образларны (оста файдалана) табигать күренешләрен, вак детальләрне, вакыйгаларның алмашуын оста файдалана. «Йолдызым» повесте - татар әдәбиятында үз урынын тапкан әсәр.

Әдәбият

1. Миңнуллин Ф. Талантлар юлы – Казан: Татар кит. нәш., 1984.
2. Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында – Татар кит. нәш., 1994.
3. Сверигин Р. Язучының күңел кыңгыраулары. Р.Төхфәтуллинның лирик прозасы турында – Казан: Татар кит. нәш., 1985.
4. Төхфәтуллин Р. Сайланма әсәрләр.– Казан: Хәтер, 2003.

# ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ - БӘЕТ

Мингулова Д.Р.
Әлмәт шәһәренең 17нче урта мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкче: Ибраһимова Г.А.

Татар халык авыз иҗатында бәетләр аерым урын алып тора. Нәрсә соң ул бәет? Тарихи вакыйгаларны, тормыш- көнкүреш ваыйгаларын җыр, шигырь формасында сөйләп биргән халык авыз иҗаты әсәре бәет дип атала. Бәетләр фаҗигале хәлләр уңае белән барлыкка килә. Аларның үзәгендә фаҗигале вакыйгалар ята. Бәет чыгаручы үзенең авыр хисләрен таратырга тырыша. Бәлага эләгүченең истәлегең мәңгеләштерергә омтыла. Бәет кешенең күңеленә кызгану сала һәм көчле уйларга чумдыра. Безнең халкыбыз – хис-тойгыларга бай халык. Бигрәк тә фаҗига, хәсрәт белән бәйләнешле хәлләргә битараф түгел. Бәетләр тарихи һәм тормыш-көнкүреш төрләренә бүленәләр. Алар еш кына язма шигърият традицияләренә таяналар һәм халык арасында да башлыча язма рәвештә, кулъязма китаплар ярдәмендә таралалар. Ягъни бәетләр – язма шигърият белән халык иҗаты очрашкан ноктада торучы иҗат төре. Бәетләрдә вакытсыз вафат булучыларны кызгану, аларның ятим калган балаларына, тол хатыннарына ярдәм итәргә омтылу хисләре өстенлек итә. Кеше гомеренең вакытсыз өзелүе язмыш белән бәйләнә.

Без әдәбият дәресләрендә төрле-төрле бәетләр белән таныштык. Шуларның иң истә калганы “Сак-Сок” бәете. Бу бәет минем күңелемә үтеп кереп көчле хисләр уятты. Дәрестә бәетне укыганда, андагы күренешләр сурәт булып күз алдыма килеп басты. Бәетнең эчтәлеге кызганыч та һәм шул ук вакытта мавыктыргыч та. Аны укып чыккач та, мин бик озак вакыт андагы геройларның язмышлары турында уйланып йөрдем. Үземчә, аларның язмышларын яхшы якка үзгәртәсем килде. Әйе, бу бәет буыннан-буынга яши. Аның эчтәлеге хәзерге көндә дә бик актуаль. Ул үзенең тирән эчтәлеге һәм аянычлы язмышлы геройлары белән җәлеп итә. Аны укыганда һәр укучының күз яшьләре төшәдер. Бу бәет безне нәрсәгә өйрәтә? Минемчә, әниләребезгә мәрхәмәтле булырга, аларны хөрмәт итәргә, үзара дус мөнәсәбәттә яшәргә өнди.

Мин укырга яратам. Минем өйдә китаплар бик күп. Алар арасында бәетләргә дә урын бар. Киләчәктә үземнең балаларыма да бәетләр укырмын, сөйләрмен дип уйлыйм. Бәетләр укуга кызыксынуны арттырырга тырышырга омтылыйк. Бәетләр борынгыдан килгән халык иҗатына хөрмәт һәм халык педагогикасы ярдәмендә ата-анага ихтирам, ярату хисләре тәрбияли. Бу үз чиратында телне саклап калуга да ярдәм итәчәк.

Әдәбият

1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры – Казан, Мәгариф, 2008
2. Хабибуллина З.Н., Гыйлаҗев И.Г. Изложениеләр җыентыгы. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче, рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 2-11 нче сыйныфлары өчен,- Тулы 2 нче басма,. – Казан, Мәгариф, 2003. –239 б.

3. Хабибуллина З.Н., Миңнуллина Р.В. Сочинение язарга өйрәнәбез.: методика һәм үрнәкләр. – Казан. Яңалиф, 2002. – 192б
4. Гыймадиева Н.С. Имтиханнар өчен сочинениеләр – Казан. Яңалиф, 2003. – 136 б.

## М.МӘҺДИЕВ “БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ” ПОВЕСТЕНДА ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

Мостафин А.Р.
Алабуга шәһәренең Инженер-технология лицее укучысы.
Фәнни җитәкче: Төһбәтуллина Р.Г.

Язучы-прозаик буларак М.Мәһдиевнең исеме матбугатта бераз соңрак – алтмышынчы елларның ахырында күренә башлый. 1967 елны «Казан утлары» журналында «Без – кырык беренче ел балалары» исемле беренче повесте дөнья күрә. Ватан сугышы чорының авыр шартларында педагогия училищесында укучы яшүсмерләрнең көндәлек тормышын, дөньяны танып белергә өйрәнүләрен кызыклы ситуацияләр, оста тотып алынган тормыш детальләре, үзенчәлекле кеше характерлары аша гаҗәеп җанлы, самими итеп гәүдәләндергән, композицион яктан җыйнак эшләнгән, сыгылмалы, күп бизәкле, җор-үткен тел белән язылган әлеге повесть, укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан күтәреп алынып, татар прозасындагы бер яңалык буларак бәяләнә. [Мөхәммәт Мәһдиевның биографиясе… интернет-ресурс]

Әле кичә генә басуда хезмәт куйган яшүсмерләрнең физик халәтен (бербөтеннең бер өлеше генә аша), ә рус теле укытучысын (затны атамыйча, күзлеге аша гына), метонимияләр кулланып, урынлы тасвирлый:

“...*Миләр катып калган*, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай. Миләрдә ике-өч кенә тирән сыр бар. Аның берсе — сугыш, канкойгыч сугыш турында. Фронтка икмәк кирәк....Мидә икенче сыр — ашау турында. Кайда гына, кайчан гына авызга кабарлык нәрсә булса, без аны кабарга, йотарга тиешбез. Ә йотарлык әйбер һәр җирдә бар. Табигать бай — үз баласын ул ничек тә саклый. Мидә өченче сыр... Өченчесе — юк. Кичә юк иде...”[3]

“...*Ике пыяла* безне гипнозлагандай итте. Аяклар класска өстерәделәр. Коточкыч тынлык урнашты. ...Нәкъ шул секундта ишек ачылып, аннан *ике түгәрәк пыяла* күренде. [3]

...*Күзлекле* парта арасында йөри башлады. Ул һәр кешенең дәфтәрен алып күз йөртеп чыга. ...”[3]

*“...Күзләр* ниндидер өмет белән Әлтафига *текәлде*. Хәзер нәрсә дә булса булыр... Гыйззәтуллинның *бите ап-ак киндергә әйләнә*: *зәңгәр күзлекнең* бармагы шул фамилия тирәсендә туктап кала.

Ә *зәңгәр күзлек* әйтерсең тырнак астына энә тыга...” [3]

Педагогика укытучысының образы, сыйныф укучыларының һәм Гыйззәтуллинның көтелмәгән халәте чагыштырулар, фразеологик әйтелмәләр белән тасвирлана.

“...Шуның өстенә укытучысы — нечкә аяклы, чандыр яңаклы, *шүрәле бармагыдай* нәзек озын бармаклы ир уртасы бер кеше. Уң кулындагы озын урта бармагын *күзеңә төрәгәндәй* чукый-чукый белем бирә...”[3]

“...Ләкин... ләкин, *күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, диләр*. Гыйззәтуллин бу төчкерү аркасында әле үзенең нәрсәдән котылганын белми иде. Сары сатинлы гәүдә алгарак сузылды. *Озын бармак* класс өстенә таба очты.

Классны *коры яшен суккандай булды*. Сары күлмәкленең зәһәр тавышы яңгырады. *Озын бармак* нәкъ Гыйззәтуллинның каш өстенә атылды. [3]

Гыйззәтуллин, *питон авызына үз ихтыяры белән кереп барган гипнозланган куян шикелле*, берни аңламыйча аның артыннан кабатлый…” [3]

М.Мәһдиев үзенең төп игътибарын тасвирлана торган тормыш, чынбарлык күренешенең әхлакый-фәлсәфи эчтәлеген, каһарманнарының холкы-табигатендәге асыл сыйфатларны, рухи билгеләрне ачуга юнәлтә. Шуңа бәйле рәвештә әдипнең язу стиленең характеры да үзгәрә: кырыс реализм, драматизм, юмор, лиризм, сатира үзара бер-берсе белән гел аралашып, чиратлашып бара. Гомумән, нечкә юмор, ирония, киная, җорлык, халыкчан тапкырлык әдипнең язу стиленә хас иң төп сыйфатлардан саналалар. [3] Моңа ирешүдә ул метанимияләр, чагыштырулар, фразеологик әйтелмәләр, татар халык мәкаль-әйтемнәрен оста куллана.

“...Ләкин Әлтафи немец теле укытучысының бер мәкале беләнаның *авызын каплый:*

*– Чебен дулап тәрәзә вата алмый...*”

“...Шулай Гыйззәтуллинның арадан китүе *күңелләргә шом салды...*”

“...Гыйззәтуллинның күп яшәсә — *ике-өч минутлык гомере калгандыр*. Менә-менә бу кешенең каршында ул кисәк авар. Тагын әйттермәсә генә ярар иде, харап була бит малай...”

“...– Кабатла: мин бөгөн икеле алам.

– Мин бүген икеле алам...

– Шуның белән мин *Гитлер тегермәненә бер чүмеч су салам...*” [Мөхәммәт Мәһдиевның биографиясе…интернет-ресурс]

Язучы кешеләргә, аларның портретларына, холык-фигыльләренә, телгә гаять игътибарлы. Язучы теленең байлыгы турында сүз алып барабыз икән, төпле өйрәнүләр, сүзләрнең яңгырашына, аларның мәгънәсенә, җирле сөйләмнең аһәңен, үзенчәлекләрен тою нәтиҗәсендә авторның рухи дөньясында барлыкка килүен таныргa тиешбез. Ул чор кешеләренең сөйләмен онытмау – язучы теленең йөзен билгеләүдә әһәмиятле роль уйнаучы факторлар.[Фәтхерахманов 1996: 152]

Әдәбият

1. Фәтхерахманов Р. Тормыштан килгән геройлар. /Казан утлары. – 1996 - №10 149-158 б.
2. Мөхәммәт Мәһдиевның биографиясе. - URL: https://goo.su/hGHb
3. Интернет-ресурс https://belgech.ru/

**БҮГЕНГЕ КӨН ЯШЬЛӘР ТЕЛЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ**

Мөбәрәкшина Д.Л.
Әлмәт районы Яңа Кәшер урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Шайхулова А.И.

Телебезнең гомумтөрки пласты турында галимнәр “Алар телнең төп сүзлек фондын тәшкил иткәннәр, шул нигездә телнең сүзлек составы үсә, үзгәрә, камилләшә барган” , - дип язалар. [Сафиуллина 2002 : 62] Шулай да бер генә телне дә, шул исәптән, татар телен дә алынма сүзләрдән башка күз алдына китереп булмый. Алынма сүз – башка телләрдән килеп кергән һәм халык тарафыннан кулланыла торган сүзләр. Билгеле булганча, чынбарлыктагы яңа күренешләр, яңа реалияләр яңа лексик берәмлекләргә ихтыяҗ хасил итә. Һәм бу очракта тел баюының бер ысулы – алынма сүзләрне актив сүзлек запасына кертү. Монда шунысын да искәртеп китү мөһим: билгеле тарихи, иҗтимагый, мәдәни сәбәпләр аркасында, телебездәге алынмаларның зур күпчелеген гарәп-фарсы, рус һәм инглиз теле алынмалары тәшкил итәләр [Химик 1993 : 61]. Яшьләр телендә исә, инглиз теленнән кергән алынмалар бермә-бер күбрәк. Бу шуның белән дә аңлатыла ки, тел байлыгыбызның гомумтөрки пластында хәзерге информацион технологияләргә кагылышлы атамаларны яктырта алырлык бик күп лексемалар очрамый диярлек.

Яшьләрнең күбесе студентлар. Шунлыктан, алар телендәге алынма сүзләрнең шактый өлеше, нәкъ менә уку процессына карый. Күп кенә яшьләрнең кисәтүенчә, мондый сүзләрнең аңлаешсызлыгы яшьләрнең күп укыганлык символы, һәм шуңа күрә дә, чит телдән кергән сүзләр белән баетылган сөйләм, еш кына иҗтимагый престиж дип бәяләнелә. Бу терминнар факультет, уку йорты төренә карап төрле булырга мөмкиннәр. “Хәзерге укучылар телендә *комп, колонка, e-mail* кебек сүзләр, студент яшьләр телендә *телик, шпоры, стипа, вет, пед, мед* кебек сүзләрне ишетергә мөмкин” , дип ассызыклый тел галимәсе Ф.С. Сафиуллина 1999 елда басылып чыккан монографик хезмәтендә. Тик тел заманалар үзгәрү белән үзе дә үзгәрешләргә дучар була. Бүгенге көн студентлар лексикасы ул шактый бай лексик катлам һәм анда яңа лексик берәмлекләр барлыкка килү процессы гаять актив бара. Мәсәлән, әгәр дә укытыла торган дисциплинаның исеме бер генә сүздән торса, ул гадәттә яшьләр сөйләмендә үзгәртелмичә кулланыла: *социология, тарих, риторика* һәм башкалар. Әгәр дә инде ул берничә берәмлектән торса, универбатлар, ягъни университет студентлары сөйләмнәренә кереп киткән алынма аббревиатуралар яки кыскартылган сүзләр, кулланылышка кертелә: *античка* (антик әдәбият), *вышка* (югары математика); аббревиация: *МРЯ* (Рус телен укыту методикасы (методика преподавания русского языка)), *СРЯ* (хәзерге рус теле – современный русский язык)), *МОРЯ* – (методика обучения родному языку), *матан* (математик анализ) һәм эллиптик сүзтезмәләр: *основы* (журналистика нигезләре), *стиль* (татар теле стилистикасы) һәм башкалар. [Ожегов 1983: 266]

Яшь буынның сөйләм процессында да үз-үзләрен тотышы рус халкы, культурасы һәм теле йогынтысы белән характерлана. Аралашканда контактка

керү сәламләүдән башлана. Сәламләшү аралашуда катнашучылардан тора. Сәламләү сүзләренә: *исәнмесез, хәерле иртә, хәерле көн, хәерле кич, әссәламәгаләйкем* керә. Беркадәр гади һәм фамильяр булып *нихәл? саумы?саумысыз? сәлам?* формалары тора. Студентлар арасында рус сөйләме йогынтысында шаян формада *чао! салют! привет!* вариантлары да кулланыла.

Яшьләр телендә укуның төрле стадияләре аерымлана. Югары уку йортында укый башлау, яңа тормыш башлану кебек күзаллана, шунлыктан абитуриентны төрлече исемлиләр: *абита, абитень, абитура*. Беренче курс студентларын, гадәттә, *первак, перваш, первокур* дип исемләсәләр, бишенче-чыгарылыш курста укучыларны *пятак, диплошник* дип атыйлар.

Студент тормышының тагын бер мөһим предметы, ул да булса дәреслек. Кызганычка каршы, бүгенге көн яшьләргә ул торган саен файдасыз әйбер (*кирпичләр киштәсе*), аның артык катлаулы булуыннан җәфа-газап чыганагы (*мучебник, заумник*) һәм хәтта, кулланылышта актуальлеген, "йөз-кыяфәте"н югалткан предмет (*макулатура, сэконд-хэнд*) итеп күзалланыла . Әмма, шул ук вакытта, хәзерге яшьләргә ул белем чыганагы (*акыл, ми, гранит науки*) һәм ярдәмче (*ашыгыч ярдәм, репетитор, решебник*) дә булып тора.

Яшьләр тормышында зачет, контроль эш, имтихан кебек категорияләр зур роль уйныйлар. Алар еш кына куркыныч момент итеп күзаллаhistalar (*лафа тәмам, лотерея)*.

Көнкүреш реалияләргә студентлар тарафыннан бирелгән номинацияләр арасында, тулай торак аеруча, кызыклы тикшерү объекты. Студентлар анны еш кына *тулай торак* дип түгел, ә *общага, общак* дип атыйлар.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклап үтик: хәзерге татар яшьләре теленең лексик составын күбесенчә рус теленнән һәм рус теле аша башка Европа телләреннән кергән алынма сүзләр тәшкил итә. Алар әдәби телдәге сүзләрнең кыскартылуы, берникадәр үзгәртелүе нигезендә барлыкка килгәннәр. [Сафиуллина 1999: 93] Бу сөйләмне актив лексикага кертеп карарга кирәк, чөнки үзкулланылыш даирәсендә, ягъни яшьләр тирәлегендә, әлеге лексика көндәлек кулланылышка ия.

Соңгы елларда җәмгыятьтә күзәтелгән үзгәрешләр моңарчы күрелмәгән күләмдәге матди мәдәният предметларының һәм аларны атаган сүзләрнең гомумкулланылыштан әкренләп чыга баруына китерде. Шул ук вакытта яңа сүзләр һәм әйберләр тормышыбызга ташкын булып килеп керде һәм кулланыла башлады. Җәмгыятьнең әлеге "ачыклыгы" милләтләр арасындагы, шул исәптән милли мәдәниятләрдәге чикләрне "юа", телләрнең лексикасында да, халыкларның тормыш-көнкүрешендә дә охшашлыклар барлыкка килүгә сәбәп була. Әмма телнең лексикасында бер төркем сүзләр гасырлар буена кулланылышта калалар, чөнки алар тормыш итү өчен иң мөһим, беркайчан да әһәмиятен югалтмый торган төшенчә-күренешләрне атыйлар .

Аралашу чарасы буларак тел җәмгыять тормышы белән бик тыгыз бәйләнгән. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр телдә чагылыш таба. Бу нисбәттән, телнең сүзлек составы үзгәрешләргә гаять сизгер. Теге яки бу күренешләрнең, предметларның кулланылыштан төшеп калуы яки, киресенчә, пәйда булуы телдә дә үзгәрешләр китереп чыгара.

Әдәбият
1. Ожегов С.И. Словарь русского языка. – Москва, 1983. – С. 266
2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология ( югары уку йортлары өчен). – Казан: Хәтер, 1999. – Б. 93.
3. Химик В.В. Прагматика молодежного сленга и текст// Эстетическая природа художественного текста, типы его изучения и их методическая интерпретация. Международная конференция-семинар: Тезисы докадов. – СПб., 1993. – С.61-62

## ФГООС ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ

Мөхетдинова А.Р.,Әлмәт шәһәренең
“Адымнар-Әлмәт”гимназиясе укучысы.
Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.

Яңа шартларны кабул итеп, татар телен һәм әдәбиятын укыту яңа алымнар белән өйрәтү һәр укытучының максаты. Яңа төр шартлар укытканда укытучының баларга әзер белемне бирмәвеннән гыйбарәт. Ягьни 80% укучы үзе белем алу өстендә эшләргә тиеш ,ә калган 20% укытучыга йөкләнелә. Укытучы шушы 20% өлештә укучыны белемгә этәрүче ролендә. Ул бары юл күрсәтүче.

ФГООС шартларында татар телен укыту, укытучының үз фәне буенча тирән белемле булуыннан, яңа төр инновацион технологияләрне дәрестә уңышлы куллануыннан, уз фәнен яратып укытуыннан , эффектив методлардан файдалана белуенән гыйбарәт. Татар телен чит тел буларак өйрәнгән бала узенен туган теле, ягъни рус теле аркылы кайбер темаларны чагыштыру аркылы аңлый. Ә икенче яклап караганда ана телендәге кагыйдә башка телдә хата ясарга да этәрә. Мәсәлән, Кем? Нәрсә? соравын алыйк. Рус телендә Кем? соравын барлык җанлы предметлар бирәбез,ә татар телендә бары кешеләргә генә. Мондый мисалларны шактый китереп була. Кыскасы, телләрне чагыштырып өйрәнгәндә, бала куп кенә орфографик, орфоэпик, тыныш билгеләренә бәйле тупас хаталар ясый. Шушы хаталарны киметү максатыннан сүзлек диктантлары яздыру, сүзгә фонетик анализ ясату яки Һәр орфограмманы тикшерүне гадәткә кертү зарур. Дәрестә интерактив такта куллану, иҗади кунегүләр, төсле курсәтмәлекләр, татар теле дәресләрен кызыклы, аңлаешлы итеп кенә калмыйлар, ә кызыксынып өйрәнергә этәргеч бирәләр. Экрандагы онлайн биремнәр, төркем-төркем булып эшләү укучыларны коммуникатив сөйләмгә этәрә. Әйтик, группадагы татар телен белгән бала татар телен белмәгән бала белән татарча сөйләмгә чыга. Укучыга үз яштәшенә татарча мөрәҗәгате бик тәэсирле тоела, аның уз иптәше кебек анлыйсы, сөйләшәсе килә. Рус балаларына татар теле өйрәткәндә, укытучы гел татарча гына сөйләшергә тиеш. Рус телле балалар һәр дәрестә татарча сөйләмгә күнегеп, телне үз итә, аңлый башлыйлар.

ФГООС шартларында татар телен һәм әдәбиятын укытуда иң-иң отышлы булган алымнарны һәм дәресләрдә дәвамлы кулланылган түбәндәге эш төрләрен тәкъдим итәсем килә. Беренчедән, рус телле балаларга телне өйрәткәндә, инновацион яктан  проект дәресләр бик отышлы. Дәрес-дебат, дискуссия алымнары функциональ белемне формалаштыра һәм камилләштерергә ярдәм итә. Икенчедән, аналитик фикерәү күнекмәсе мәглүматлар чылбырыннан  иң кирәклесен сайлап алырга мөмкинлек бирә. Өченчедән, ассоциатив фикерләү уткән материал белән хәзергене, яңаны бәйләп өйрәнүне җайлый. Дүртенчедән, мантыйкка нигезләнеп фикерләү, дәлилле белү белемнәрне билгеле бер эзлеклелеккә сала, нигезле аргументлар, фактларга таянып алган белемнәрнең ныклы булуына җирлек тудыра.

Әйтик, әдәбият дәресендә каршылыклы  мәсәләләр белән бәйле темалар каралганда, “6 эшләпә креатив фикерләү” алымы бик үтемле эш. Чөнки һәр кешенең  теге яки бу нәрсәгә төрле караш, төрле фикер. Җитмәсә алар бик тә каршылыклы һәм бер шәхеснең үзенә генә хас икенчесенекеннән үзгә. Әйткәннәремә өстәп, укытуда түбәндәге методларны һәм яңа төр эш төрләрен тәкдим итәсем килә.







Яңа шартларда татар телен укытуда, әлбәттә, билгеле бер принципларга таянырга кирәклеген онытмау зарур. Ә әлеге принципларда түбәндәге пунктлар

булырга тиеш дип уйлыйм:

- Иң әүвәл укучыларның психик үсеш үзенчәлекләрен истә тоту шарт; Дәрестә һәр укучы үзенең зур роль уйнаганын, аның әйтәсе фикерләренең моһимлеген тоюы;

- Укыту баланың усешенә,формалашуына,камилләшүенә нигезле булуы. Ягьни әзер белем бирү генә тугел, ә мөстәкыйль эзләнергә этәрә торганы, кызыксыну тудырып, максатчан бу мәсъәләне чишмичә туктап калмый торган булуы;

- Дәресләрнең төрлелеге. Үтемле алымнар белән дәреснең үтүе.

- Дәреснең төзелеше. Ягъни дәрес эчтәлеге, этапларының билгеле бер эзлеклектә булуы.

Без тиз үзгәреп торучан тормышта яшибез. Әлеге җәмгыяткә белемле, акыллы карашлы кешеләр кирәк. Менә шундый кешеләр тубәндәгечә эш итәргә мөмкиннәр:

• Үзенең гамәлләренә аек акыл белән карап, төпле фикер йөртә;

• Мөстәкыйль бер төрле фикергә килә һәм нәтиҗәсен алдан чамалый белә;

• Уртаклашып, фикерләшеп эшләүгә сәләтле;

• Үз иле алдында җаваплы аның киләчәге өчен ватанпәрвәр.

Нәтиҗә ясап язганнарыма шуны әйтәсем килә: әлеге җәмгыятькә алда санап кителгән сыйфатларга ия шәхес тәрбияләү өчен, дәрескә сүзсез яңалык кертүне сорый. Ул яңалык белем бирүдә ныклы корал, уңышка ирешүгә дәвамлы юл, нәтиҗәләрнең бары яхшы булачагына ышаныч тудырырлык булырга тиеш.

Әдәбият

1. Җамалетдинов Р.Р. Тел теориясе: уку-укыту ярдәмлеге / Р.Р. Җамалетдинов, Р.С. Нурмөхәммәтова. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2020. – 264 б.

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘ МИЛЛИ ИДЕАЛ

Мукимова Г.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.

Халыкның, аерым кешеләрнең хыял-өметләре, яшәү ориентирлары иң элек халык әсәрләрендә, соңрак, сүз сәнгате үсү белән, әдәби әсәрләрдә чагылыш таба башлыйлар. Милли әдәбиятыбызда да идеалларыбыз камил шәхес образы аша чагылдырыла. Дәверләр үзгәрү, алмашыну тормышның, яшәешнең төрле өлкәләренә җитди үзгәрешләр алып килә, әмма һәр әдәби әсәр үз иҗатчысының, үз чорының әхлакый һәм милли идеалларын чагылдыру вазифасын башкаруны дәвам итә. Тәкъдим ителә торган эштә мондый идеаллар Татарстанның халык шагыйре, журналист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин (1948-2020) шигърияте нисбәтле рәвештә

тикшерелә. Билгеле булганча, Р.Миңнуллин иҗаты адресат ягыннан ике төркемгә аерып карала ала: балалар өчен иҗаты, олылар өчен иҗаты. Мондый әсәрләрне анализлаганда шагыйрь биографиясенә дә тукталып китү сорала: Р. Миңнуллин җаваплы урыннарда, Татарстан Республикасы халык депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вазифаларын башкарганлыктан ул иҗтимагый тормыштагы әхлаксызлык баткаклыгын тирәнтен күрә, аның сәбәпләрен дә ачык аңлый торган шәхес буларак күз алдына килеп баса. Милли проблемалар күп шагыйрьләр иҗатында чагылыш таба, нәкъ менә Р.Миңнуллин иҗатында ул тирәнлеге, конкрет бирелеше, балалар һәм олылар дөньясына юнәлгән булуы белән аерылып тора.

Татар әдәбиятында, гомумән, иҗтимагый һәм сәнгати тормышта кызыклы күренешкә тап булабыз: милли идеал тасвирын аеруча калку итеп тасвирлаган әдипләр ижтимагый һәм сәяси аренада да актив чыгыш ясыйлар. XX - XXI гасырлар мисалында карасак, мондый шәхесләр рәтендә Т.Миңнуллин, Р.Вәлиев һәм, әлбәттә, Р.Миңнуллинны атарга була.

Р.Миңнуллин шигъриятендә милли идеал чагылышы төрле темаларга язылган шигырьләрендә күзәтелә. Алар арасында милли гореф-гадәтләрне тасвирлау һәм саклау темасына караган "Кунак егетләр", "Сабантуй бүген бездә!", "Тәкә", "Урман аша узганда", "Шүрәле" кебек шигырьләрен атарга була. Милли идеал образы атаклы татар шәхесләре образлары бирелеше белән бәйле. Биредә милли идеал чагылышын ике аспектта карарга мөмкин.

Бер яктан, укучы алдында мәртәбәле, татар тормышында, сәнгатендә зур урын калдырган шәхес образлары туа. Мисал өчен, "Солтанморат дигән изге авыл" шигырендә мондый образ буларак Г.Ибраһимов тәкъдим ителә, метафора ярдәмендә ул алтын белән чагыштырыла. Әмма шагыйрь тискәре якка да игътибар итә: әлеге шәхес милләтебез өчен күпме яхшылык эшләсә дә, тиешле кадер-хөрмәт күрсәтелми. Дөрес, аңа багышлаган конференцияләр үткәрелә, китаплары бастырыла, әмма шагыйрьнең нечкә күңеле иң мөһим әйбер - каберенең урынын ачыкланмавы хакында борчыла:

“Каберен дә хәтта табалмыйбыз,
Кайда күмелгәнен белмибез,
Эзләмибез, белмим, ни өчендер,
Оятыбыздан да үлмибез” [Миңнуллин, 2021: 5].
("Солтанморат дигән изге авыл")

Без, татарларны бу яктан бер генә сыйфат аклый ала: каберен белмәсәк тә, туган авылы Солтанморатта әдипне искә алу чаралары үткәрелә. Шагыйрьнең шулай ук Х.Туфан, С.Хәким, Р.Гаташ, Н.Нәҗми кебек шәхесләргә атап язган шигырьләре дә бар ("Аккош", "Яланнарда йөри шагыйрь", "Шагыйрь Рәдиф Гаташ туган авылда туган шигырь", "Шагыйрьнең киңлекләре" һ.б.лар). "Солтанморат дигән изге авыл" һәм башка шигырьләрдә милли идеал буларак шагыйрь образы – Р.Миңнуллин образы да хасил була һәм ул аерым игътибарга лаек. Бу - милли яшәеш өчен борчылучы зат. Аңа шулай ук активлык хас. Аны иң борчыган проблемаларның берсе – татар теленең сакланмавы, үз милләт вәкилләреннән кимсетелә баруы. Шагыйрь яхшы аңлый: милләтне инкыйразга дучар итүнең иң нәтиҗәле юлы – аны туган теленнән биздерү, телне оныттыру.

Татарстандагы тел ситуациясе – икетеллелек – бар дөньяда киң таралыш алган булса да, ике яклы, симметрияле икетеллелекнең әлегәчә бездә урын алган юк. Ә инде мәктәпләрдә татар телен укыту мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән күз уңаена алынгач, шагыйрь аеруча борчыла башлый. Шуңа бәйле рәвештә аның "Бөтен өмет сездә" шигыре языла, аның исеме астына автор "Татарстанның фән һәм мәгариф министры Энгель Нәвап улы Фәттаховка ачык хат", дип искәртеп куя [Миңнуллин, 2021: 73].

Милли идеал Р. Миңнуллин шигъриятендә башкалабыз Казан образыннан гайре күзаллана алмый. Казан башкала гына түгел, анда яшәгән кешеләр буларак та күзаллана. Казанга багышлап язылган шигырьләрендә шагыйрь шул рәвешле метонимия алымын куллана. Казан – шигъриятендә төрле яклап ачылган катлаулы образ. Шагыйрь аны руслашуда, чит әхлакый кануннарны үзләштерүдә гаепли, әмма якынының гаепле якларын гафу кебек, ул да Казанны нинди сыйфатында да яратырга әзер:

“Барыбер газиз шул инде
Чукынган Казаныбыз.” [Миңнуллин, 2021: 30].
("Көндезге Казан")

Биредә үзенчәлекле алым - сүз уйнату кулланылган. Татарларда якыннарны шелтәләгәндә "чукынган" дип әйтү күренеше бар, бу сүз шелтә буларак яңгырый. Әмма тарих сәхифәләреннән беләбез, 1552 нче елдагы мәгълүм вакыйгалардан соң

“Казанның төнге утлары
Илһам - язарыма.
Бәхет телим милләтемә,
Газиз Казаныма.” [Миңнуллин, 2021:22].
("Казанымның төнге утлары")

Шагыйрьнең күп кенә әсәрләрендә лирик кичереш лирик герой аркылы күрсәтелә. Бу очракта аның биографик һәм психологик яктан авторга якынлыгы аермачык сизелә, шагыйрьнең идеаллары, тормыш тәҗрибәсе белән бала күңеленең самимилеге гармоник рәвештә үрелеп бирелә.

Р. Миңнуллинның балаларга атап язылган шигырьләрендә милли идеал Ватанга мәхәббәт белән бәйле. Шагыйрь туган як, туган авылга мәхәббәте, тынычлыкка, дуслыкка өндәү, милли горурлык кебек хис-кичерешләр бала күңеленә хас булган беркатлылык белән җиткерә белә:

“Җирнең иң матур җирендә -
Татарстанда торам мин!
Малайлар һәм кызлар, сезне
Кунакка чакырам мин.” [Миңнуллин, 2004: 125].
( “Кунакка килегез!”)

Шулай итеп, Р.Миңнуллин шигъриятендә милли идеал актив җәмәгать эшлеклесе, милләт үсеше өчен хезмәт итүче, туган телне саклаучы, яклаучы образ буларак күз алдына баса. Шагыйрь иҗатында милли идеал-иҗтимагый актив шәхес. Мондый үрнәкләрне ул татарларның атаклы шәхесләре арасында эзли. Бигрәк тә Г.Ибраһимов кебек иҗатта да, иҗтимагый тормышта да активлык күрсәтүчеләр белән соклана. Икенче яктан, шагыйрь шәхесе үзе дә

шундый идеал буларак кабул ителә. Ул татар теле проблемасын чишү юлларын эзли, татарларда милли рух сүнүе өчен кайгыра, шул ук вакытта татарларга мәхәббәт хисе белән яна. Балалар өчен шигъриятендә милли идеал Ватаны белән горурланучы, әби-бабайлары белән якыннан аралашып үсүче, җирне сөюче, шәфкатьлелек орлыкларын сибүче бала буларак гәүдәләнә.

Йомгаклап, шуны әйтергә була: Р.Миңнуллин иҗатында милли идеал актив, тырыш, миллипәрвәрлек кебек сыйфатларны берләштерә.

Әдәбият

1. Миңнуллин Р.М. Сайланма әсәрләр: балалар өчен шигырьләр, әдәби тәнкыйть, иҗат портретлары, рецензияләр. - Казан: Мәгариф, 2004. - 399 б.

2. Миңнуллин Р.М. Әсәрләр. 7 томда. 1 нче т. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. - 575 б.

3. Миңнуллин Р.М. Мәхәббәтле көзләрем. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. - 615 б.

## УКЫТУЧЫ СУЛЫШЫ

Мөфтиева З.Р.

МБӨББУ “Балалар иҗат йорты  “Салават күпере талантлары” Әгерҗе муниципаль районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.

Фәнни җитәкче:  Нәбиуллина Л.З.

Бала дөньяга килү белән баланың рухи кыйбласы формалаша башлый. Ул бөртекләп, әкрен генә баланың күңеленә үтеп керә. Ул озак еллардан соң гына үзенең җимешен бирә. Ә ул җимеш татлымы, әчеме булуы, нәкъ менә аны чолгап алган кешеләрдән һәм аларның тәрбиясеннән тора. Сабыйлык – ул кеше күңеленең дөньяга гаҗәпләнүе, кешенең эчкерсезлеге, ихласлылыгы, самимилеге, шуклыгы, бунтарьлыгы,  хыялыйлыгы, зирәклеге... Бала үсә, тора-бара әти-әни, әби-бабайлар әкиятләр сөйлиләр. Аларда дуслык, туганлык, батырлык, кешегә карата миһербанлы һәм ярдәмчел булу, әти-әниләр, олыларны хөрмәтләү, кешелекле һәм шәфкатьле булу ассызыклана.

Кешелек иң күңелле, иң шатлыклы мизгелендә дә,  иң кайгылы мәлендә дә шигырьгә, җырга  мөрәҗәгать итә. Балалар әдәбиятының төп бурычы – сабыйларда матурлык, батырлык тойгылары, иманлылык, миһербанлык сыйфатлары тәрбияләү. Бала һәркайчан бала булып кала. Ул ихлас, шаян, наян. Шул шаянлыкны, матурлыкны, ихласлылыкны бары тик чын шагыйрь, чын укытучы булган кеше генә күрсәтә ала. Шундый шагыйрьләрнең берсе – Мөҗәһит (Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улы). Балалар өчен ул – дистәдән артык китап авторы. “Очты, очты...” һәм “Акыллыга сүз әйттем” китаплары “Ел китабы” конкурсында икесе дә икенче урынга лаек була, ә 2007 нче елда “Рухият” фонды тарафыннан үткәрелгән “Балаларга бүләк” конкурсында профессиональ язучылар арасында лауреат исемен ала. Мөҗәһитнең балалар өчен язган шигырьләре теленең авылчан гадилеге, ихласлыгы белән аерылып тора. Аларда катлаулы сурәтләр, башваткыч вакыйгалар юк, әмма һәр

шигырьдә авыл дигән гаҗәеп дөнья өчен генә хас җылылык, кызыклы тормыш детале яки гыйбрәтле бер сабак бар. Нәни геройларның, укучы балаларның һәр сүзендә, тәртибендә, табигатькә, яшәешкә мөнәсәбәтендә шагыйрь-укытучының сүзе, тәртибе, мөнәсәбәте дә чагыла. Шундый олуг хөрмәткә ия укытучы-шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Ул балалар ярата торган укытучы булуы өстенә, күп төрле һөнәргә дә ия: төрле уен коралларында өздереп уйнавы, шамаилләр остасы, балаларга гарәп графикасын өйрәтүе, гаиләнең шәҗәрәсен, туган авылы - Түрешен энциклопедиясен төзүе, гаиләдә акыллы, кайгыртучан, таләпчән әти, бабай булуы белән бергә ул балаларның яраткан шагыйре дә. Туган ил, аның белән горурлану - шагыйрь иҗатының үзәгендә. Кем генә үз авылын яратмый икән? Мөҗәһит Заһитович та туган авылын, туган җирен, туган телен ихлас яратучы шәхес. Түрешнең матурлыгын шагыйрь “Туган авылым”, “Түреш”, “Әй туган ягым” дигән шигырьләрендә күрсәтә:

Түреш - минем туган авыл,
Әткәм,әнкәм сыман авыл.
Шатлык кайгылары белән
Йөрәгемә сыйган авыл.

Ул ел фасылларының үз ямен, тәмен таба белә, һәр агачның, кошның сулышын тоя. Табигать күренешендәге үзгәрешләрне кыскача матур итеп әйтеп бирә алуы белән аерылып тора.

Тукта инде, яңгыркай,
Кояшка да ирек бир.
Кыздырганын күрик бер,
Күлдә сулар керик бер.

“Матур булыйк” дигән китабында тупланган шигырьләре эш сөяргә, кыю булырга, өлкәннәрне хөрмәтләргә, туган телне сөяргә һәм матурлыкны күрергә өйрәтәләр.

Матур булыйк барыбыз да,
Матурлыйк без дөньяларны.
Матур җырлар яңгырасын,
Сөендерик аналарны.

Шагыйрь үз әсәрләрендә бала өчен иң якын кешеләрнең берсе булган Ана образына мөрәҗәгать итә.

Дөньядагы әниләрнең
Иң матуры – минем әни.
Иң уңганы – минем әни.
Иң булганы – минем әни.

Аның шигырләре балаларны гына түгел, олыларны да уйландырырлык. Аның шигырьләрендә кеше үзендә булган уңай һәм тискәре якларны да таба.
Мөҗәһит иҗат тематикасында мәктәп тормышы зур урынны алган. Чөнки ул укытучы кеше, укучылар сулышы белән сулый.

Җөмләнең иясе – әти,
Хәбәре – әниләре.
Ә иярчен кисәкләре –
Аларның нәниләре.

М.Әхмәтҗанов бик хәйләкәр. Ул юмористик, шаян шигырьләре белән шук малай һәм кызларны тәртипкә өйрәтә. Шулай ук дәрестә арган балаларны ял иттереп алырга да онытмый ул:

Куллар арыды,
Бармаклар талды.
Алар да сорый
Әзрәк ялны.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов балаларча уйлый, фикер йөртә белә. Югыйсә ул балаларның керсез күңел дөньясын белеп алырдай шигырьләр иҗат итә алмас иде. Мәче образы безнең татар балалар шигъриятенең үзәгендә яши. Песи – татар балалар шигъриятенең иң яраткан һәм даими герое. Песи – йорт күрке, аның сакчысы, хуҗасының мөлкәтен корткычлардан саклаучы.

“Мәйдан “ журналыны 11нче санында “Курайчы Шүрәле” әсәре басылып чыга. Бу Габдулла Тукайның “Шүрәле” поэмасының дәвамы дип атый. Шагыйрь гади генә әйбердән дә мәгънә таба, без күрмәгәнне күрә белә, табышмаклар иҗат итә. Аның һәр китабына диярлек табышмаклар, тел шомарткычлар кертелә. 2003нче елда “Мәгариф” китап нәшриятында “Акыллы сүз әйттем..” , 2009 нчы елда “Рухият” фонды тарафыннан “Зирәк булу кирәк” исемле табышмак китаплары дөнья күрде. Бу табышмаклар балаларның логик фикерләү сәләтен үстерүгә зур ярдәм итә. Татар халкының милли бәйрәме – Сабантуйга багышланган табышмакларыннан бәйрәм турында кирәкле мәгълүматларны да алып була.

Колакларда чыңлап тора,
Сагындыра ел буе.
Бәйрәмнәрнең бәйрәме ул
Татарның __________. (Сабантуе)
Сабантуй бүләге булып
Җилферди колгаларда.
Көрәшергә тотыналар
Кулларга алалар да. (сөлге)

М.Әхмәтҗанов чын шагыйрь. Мөҗәһитнең күңеле дә яшәү шатлыгы, илаһи якты нур белән тулы. Шигырьләре мәктәп турында, бүгенге малайлар, кызлар турында. Балалар шагыйре балалар арасында булырга тиештер. Югыйсә, бүгенге балалар артыннан ничек җитешмәк кирәк. Аларны ничек аңлап, белеп, тоеп бетермәк кирәк. Ерактан күзәтеп торып кына балалар дөньясына кереп булмыйдыр шул. Мөҗәһит Әхмәтҗанов шигырьләрен балалар тиз истә калдыралар, укырга җиңел, һәр шигырьдә - тәрбия.

Мөҗәһит шигырьләре артында тагын бер кешенең җылы сулышын тоймый мөмкин түгел. Бу сулыш – укытучы сулышы. Ул күзгә күренеп тормый, әмма аны тоймый калып та булмый. Нәни геройларның, укучы балаларның һәр сүзендә, тәртибендә, табигатькә, яшәешкә мөнәсәбәтендә әнә шул укытучының сүзе, тәртибе, мөнәсәбәте дә чагыла төсле. Шулкадәр матур, самими һәм табигый багланышны, берлекне бары тик чын шагыйрь, чын укытучы да булган кеше генә күрсәтеп бирә ала.

Үзенең шигырьләрендә Мөҗәһит татар балалар поэзиясенең бай традицияләрен дәвам итә, үзенең элгәрләреннән иҗади өйрәнә. Аның шигырьләреннән матурлыкны тоярга өйрәнергә һәм рухи яктан бай, әдәпле, тәрбияле булып үсәргә мөмкин. Аның шигырьләрен балалар укып үссә, һичшиксез безнең милләт үсәр, яңа үрләр яулап, нык адымнар белән алга барыр. Минем әйтәсе килгән сүзем: аның шигырьләре мәктәп тормышыннан шаулап – гөрләп, чыңлап торсын иде.


Әдәбият

1. Әхмәтҗанов М. “Акыллыга сүз әйттем”. – Казан “Мәгариф” нәшр., 2003.
2. Әхмәтҗанов М. “Очты,очты...” / Шигырьләр,тел шомарткычлар, табышмаклар – Казан: Татар.кит. нәшр., 2000.
3. Әхмәтҗанов М. “Карга бураны”. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1997.
4. ӘхмәтҗановМ. “Тапкырлар тапмый калмас”. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2017.
5. Татар балалар әдәбияты. Шигырьләр һәм пьесалар. XIX том. – Казан: ТаРИХ, 2003.
6. Татар балалар әдәбияты.Әкиятләр һәм хикәяләр. XX том. – Казан: ТаРИХ, 2003.


## МИЛЛИ ДӘҮЛӘТ ҮЗБИЛГЕЛӘНҮЕ ИДЕЯЛӘРЕ, ТАССР ОЕШУЫ


Мухаметов Р.И.

КФУ ның Алабуга институты магистранты.

Фәнни җитәкче: Нигамаев А.З.


1917нче елгы Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң бөтен Россиядә илнең территориаль төзелеше белән бәйле җитди үзгәрешләр башлана. Бу үзгәрешләр, һичшиксез, Урта Идел буе төбәгенә дә кагыла.

Яңа совет хакимияте 1917 елда Финляндия һәм Польшаның үзбилгеләнү хокукын таный һәм башка халыклар өчен дә милли мәсьәләне гадел хәл итәргә вәгъдә итә. Бәйсезлек алган Польша һәм Финляндия мисалында үз дәүләтләрен һәм илнең башка төбәкләрен төзергә теләк белдерәләр.

Татарларда дәүләтчелек идеясе тирәсендәге төп бәхәсләр милли-мәдәни автономиягә (бу очракта татар дәүләте конкрет территориясез кала) һәм территориаль автономиягә (бу очракта тарихи нигезләнгән территория бүленә) кагылышлы проектлар белән бәйле булган. Шуңа бәйле рәвештә 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли парламент (Милли Мәҗлес) утырышлары башлана. Ноябрь дәвамында парламентка төрле сәяси көчләрдән депутатлар сайлана. Съездда төп тема милли үзбилгеләнү мәсьәләсе була. Озак фикер алышулардан соң парламент Россия республикасы составында Урал-Волга штаты («Идел-Урал Штаты») формасында милли-территориаль автономия идеясен тәкъдим итә. Бу идея Россиянең унитар дәүләттән Федератив төзелешкә күчүен күздә тота.

1 ЭТАП – ИДЕЛ-УРАЛ ШТАТЫ

Штат территориясенә Казан, Уфа, Ырымбур губерналарын тулысынча, шулай ук Пермь, Самара, Сембер һәм Вятка губерналарында татар халкы күпләп яшәгән кайбер өязләрне һәм волостьларны кертү планлаштырыла. Бу шактый зур территориядә улвакытта 7 миллионга якын кеше яши, шуларның 3,7 миллионы – татарлар һәм башкортлар, 2,7 миллионы – руслар, 0,5 миллионы – чуашлар, марилар һәм удмуртлар. Проектны гамәлгә ашыру өчен Милли Мәҗлес Урал-Волга штатын («Идел-Урал штаты») оештыру буенча Коллегия төзи. Әмма проект тормышка ашмый. Беренче сәбәп шунда ки, коллегия, оештыру җыелышына гына таянып, большевиклар белән уртак тел таба алмый. Икенчедән, әлеге проект кысаларында Урта Волга һәм Урал территорияләрендәге татар булмаган халыкларның мәнфәгатьләре турында тулы кайгырту тормышк аашырылмаган. Шуңа күрә проект халык тарафыннан тулы ярдәм тапмый. Шуңа күрә 1918 елның 28 февраленә планлаштырылган Идел-Урал Штатын тантаналы игълан итүне Совет хакимияте сәяси провокация буларак кабул итә.

2 НЧЕ ЭТАП – ТАТАР-БАШКОРТ РЕСПУБЛИКАСЫ

«Идел-Урал Штаты» проекты өзелгәннән соң, бу мәсьәлә буенча инициативаны Совет хакимияте үз кулына ала, ул 1918 ел башында мөселман мәсьәләсенә аерым игътибар бирә. 1918 елның 17 гыйнварында милләтләр эшләре буенча Халык комиссариаты каршында эчке Россия мөселманнары эшләре буенча комиссариат төзелә. Җитәкче итеп оештыру җыелышы депутаты, Мөселман социалистик комитеты рәисе Мулланур Вахитов билгеләнә. Нәкъ менә шушы орган татарларның һәм башкортларның күпчелеген Совет хакимияте тирәсендә берләштерә.

1918 елның 22 мартында «Известия» газетасында Милләтләр эшләре буенча комиссариата эшләнгән «Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы турында»гы Положение басылып чыга. Положениега ярашлы, Татар-Башкорт Совет Республикасы Көньяк Урал һәм Урта Идел буе территорияләре РСФСР составындагы территорияләр дип белдерергә тиеш. Татар-Башкорт Республикасы составына Казан һәм Уфа губерналарын, Ырымбур губернасының башкорт өлешен, Пермь, Вятка, Сембер һәм Самар губерналарының янәшә районнарын кертү планлаштырыла.

Декретка Милләтләр эшләре буенч ахалык комиссары Сталин, секретарь Диманштейн, мөселманнар эшләре буенча комиссар Мулланур Вахитов, комиссариат әгъзалары Шәриф Манатов һәм Галимҗан Ибраһимов кул куялар. Булачак республика чикләре күбесенчә "Идел-Урал Штаты"проектын хәтерләтә. Ләкин бу очракта Совет хакимияте урта Волгада мили дәүләтчелек булдыруны үз контроле астына алачак.

1918 елның май-июнь айларында Татар-Башкорт Республикасы проекты иҗтимагый һәм сәяси даирәләрдә актив тикшерелә. Проект халыкның киң катламы тарафыннан хуплау ала. Әмма бу идея дә тормышка ашмаган. Гражданнар сугышының актив хәрби гамәлләре комачаулый, аның мөһим вакыйгалары нәкъ менә Урта Волгага тупланган, бу, беренче чиратта, Чехословакия фетнәсе. Икенчедән, абруйлы башкорт сәясәтчеләренең бер өлеше татарлар белән бер республикага берләшүгә каршы актив чыгыш ясый.

Алар үзләренең шура башкорт советын җыялар һәм үз мили автономияләрен игълан итәләр.

Шулай итеп, татар-башкорт республикасы проекты да проект кына булып кала. Урта Волга территориясеннән Колчак гаскәрләрен куып чыгарганнан соң гына Совет хакимияте территориаль төзекләндерү мәсьәләләренә кайта. Башкортлар бу хәлгә тиз җавап бирәләр һәм 1919 елның мартында УК автономияле Башкорт Совет республикасын игълан итәләр. Зур амбицияләргә һәм киләчәккә карамастан, татар-башкорт Республикасы идеясе актуальлеген югалта.

3 НЧЕ ЭТАП – ТАССР

1920 елның 26 гыйнварында Мәскәүдә РКП(б) Үзәк комитеты Политбюросында Татар Совет Социалистик Республикасын төзү турында принципиаль карар кабул ителә. Шул ук вакытта булачак республика чикләрен билгеләү өчен Сәхибгәрәй Сәидгалиев җитәкчелегендә административ комиссия төзелә.

1920 елның 20 мартында Халык Комиссарлары Советы Рәисе Владимир Ленин Кремльдә татар республикасын төзү турында фикер алышу өчен революционерны, Татарстан Республикасына нигез салучыларның берсен, 1920-1921елларда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы (ТатЦИК) Үзәк Башкарма комитеты рәисе Бурхан Мансуровны һәм татар республикасын оештыручыны, аның беренче идарә рәисе Сәхибгәрәй Сәидгалиевны кабул итә. 1920 елның февраль ахырында Татар АССР турында Положение басылып чыга. Положениедә шулай УК республиканың булачак территориясе турында да әйтелә. Татар халкы күпләп яшәгән районнарны биш губернада берләштерү планлаштырыла: Казан, Уфа, Самара, Семберһәм Вятка. Положениедә республика составына керергә тиешле волостьлар һәм өйәзе генә түгел, ә кечкенә шәһәрләр һәм авыллар да санала.

Шулай итеп, сәяси картада Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы барлыкка килә. Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты (ВЦИК) һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советының (РСФСР ХКС) 1920 елның 27 маендагы декретына ярашлы рәвештә Автономияле Татар Совет Социалистик Республикасы (АТССР) оештырыла (1937 елның июнендә татар автономиясе советларының гадәттән тыш XI съезды карары белән республика исемендә сүз тәртибе үзгәртелә, Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы (ТАССР) итеп үзгәртелә.

Әдәбият

1. Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш., Измаилов И.Л. Рассказы по истории Татарстана. - Казань: Магариф, 1994, - 272 с.
2. *И. Г. Гиззатуллин, Д. Р. Шарафутдинов.* Мирсаид Султан-Галиев. Избранные труды. — Казань: Гасыр, 1998. — 720 с.
3. *Касимов С. Ф.* Татаро-Башкирская Советская Социалистическая Республика // Башкирская энциклопедия. В 7 т. / глав. ред. М. А. Ильгамов. — Уфа: Башкирская энциклопедия, 2010. — Т. 6. — С. 222. — 544 с.

4. М. К. Мухарямов. Октябрь и национально-государственное строительство в Татарии (октябрь 1917—1920 гг.) — М.: «Наука», 1969
5. Совещания по вопросу о Татаро-Башкирской ССР // Татарская энциклопедия. В 6 т. / гл. ред. М. Х. Хасанов, ответ. ред. Г. С. Сабирзянов. — Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2010. — Т. 5. — С. 366. — 736 с.

## МӘКТӘПТӘ ИҖАДИ ҮСЕШ ТЕХНОЛОГИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП “ИСЕМ” ТЕМАСЫН ӨЙРӘНҮ

Нәбиуллина А.Р.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Бүгенге көндә мәктәпләрдә актив кулланыла торган технологияләрнең берсе булып иҗади үсеш технологиясе тора. Укучыларны иҗади үстерү юлларын эзләүгә атаклы педагог В.В.Давыдов мәктәбенең вәкиле булган профессор, психология фәннәре докторы Ә.З.Рәхимов зур өлеш кертә. Аның тырышлыгы белән 1975нче елда Башкорт дәүләт педагогика институтында педагогик технология лабораториясе ачыла. Бу технология уку-укыту эшчәнлегенең индивидуаль һәм күмәк формалары ситуациясендә укучыларның танып белү сәләтләре формалашу һәм иҗади мөстәкыйльлекләре үсү, нәтиҗәдә иҗади фикер йөртү, үзбелем һәм үзтәрбиягә мотивация үсешенә йөз тота [Иҗади үсеш технологиясе 2004: 49]. Ә.З.Рәхимов иҗади үсеш технологиясе турында болай ди: “Бу – мин уйлап тапкан технология түгел. Миңа башта бик күп халыкларның педагогикасы һәм психологиясе эчендә “йөзәргә” туры килде. Мин һәр методиканың, сөтнең каймагын җыйган кебек, иң нәтиҗәлеләрен генә сайлап алырга тырыштым. Шуңа күрә, иҗади үсеш технологиясен иң яхшы дип әйтә алам” [Җамалетдинова 2003: 56]. Иҗади үсеш технологиясенә нигезләнгән дәресләрнең структур төзелеше традицион дәрес калыпларыннан аерылып тора. Аның төп этаплары:

- Мотивацион-ориентлашу этабы (ун минут);
- Башкару этабы (утыз минут);
- Рефлексия-бәяләү этабы (биш минут) [Буданова 2005: 29].

Әлеге технологиягә нигезләнгән эшне оештыру үзенчәлекләрен “Исемнәрнең килеш белән төрләнеше” темасын өйрәнү мисалында карап китик. Дәреснең беренче этабы – мотивлаштыру-ориентлаштыру этабында укучыларның “Исемнәрнең берлек һәм күплек сан формалары” темасы буенча өй эшен эшләүләре тикшерелә. Дәреснең башкару этабында дәреслек буенча эш алып барыла. Укучыларга дәреслектәге 39 нчы күнегү буенча эшләргә тәкъдим ителә. Укучылар башлангыч сыйныфларда үтелгән мәгълүматны искә төшереп, дәреслек авторларының таләбе буенча күнегү тексты герое Азатка ярдәмгә килеп, татар телендә нинди килешләр барлыгын әйтергә, исемнең кайсы килеш белән төрләнгәнен ничек белеп булганлыгын әйтергә тиеш булалар [Сәгъдиева 2017: 23].

Әлеге этапта этапта укытучы үзе төзегән биремнәрне дә тәкъдим итә ала. Мәсәлән, ул сюжетлы картиналар белән эш булырга мөмкин. Укучыларга сюжетлы картиналар тәкъдим ителә. Без аларны “Бала.рф” китапханәсеннән алырга тәкъдим итәбез. Укучылар рәсемнәргә карап текст язалар. Грамматик бирем башкаралар (мәсәлән, иялек килешендәге исемнәрне билгеләгез). Бирем өстендә эш интерактив мультфильм карау белән дәвам итә. Мәсәлән, Нур Әхмәдиевнең “Басмада” шигыре буенча эшләнгән мультфильмга нигезләнеп ясалган рәсемнәрне кулланырга була [Интерактив китапханә, интернет-ресурс]. Мондый эшнең уңышлы яклары шунда: сюжетлы рәсемнәр белән эшләү укучыларның иҗади фикерләвен үстерә, логик эзлекле итеп мөстәкыйль текст төзү күнекмәләрен үстерә. Үзләренең текстлары оригиналь текст белән туры килү-килмәве дә укучыларга кызык. Грамматик бирем дәрес темасына ярашлы рәвештә тәкъдим ителә. Ул түбәндәгечә яңгырый ала:

- Тексттагы исемнәрнең килешләрен билгеләгез;
- Төшем килешендәге исемнәрне билгеләгез һ.б.лар.

Дәреснең рефлексия-бәяләү этабында укучылар дәрестә эш дәвамында алган яңалыклар турында сүз алып барыла. Яңа мәгълүмат кычкырып та, төркем эчендә дә, эчтән генә дә кабатлана ала. Укытучы шулай ук дәреснең уңышлы һәм уңышсыз тоелган яклары турында да сораштырырга мөмкин. Әлеге этаптагы тагын бер җаваплы мизгел – укучыларның үзләренең эшчәнлекләрен бәяләүләре. Дәрес дәвамында укучылар һәр башкарган эшләрен бәяләп баралар, бәяләү критерийлары аларга таныш – җавапның дөреслеге, тизлеге, җавап телдән яңгыратылса, сөйләмнең сөйләм культурасы таләпләренә ярашлы рәвештә бирелүе һ.б.лар. Дәрес ахырында исә төп бәя чыгарыла. Укучыларның психологик үзенчәлекләрендә аерма булырга мөмкин. Кемдер дәрестә бирелгән бер дөрес җавабына куанып, үзен югары бәяли, кемдер, киресенчә, үзенә карата артык таләпчән була ала. Шуңа күрә, мөгаллим искә төшерә: билгене артык түбәнәйтү дә, хаксыз югары билге кую да объективлыкка зарар китерә, белем алу юлында киртә генә булып тора. Укучыларның эшчәнлеге бәяләнгәч, өй эше бирелә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: иҗади үсеш технологиясе заман мәктәбенә уңышлы үтеп керә, бу өлкәдә шактый ук тәҗрибә дә туплана. Татар теле укытучылары әлеге технологияне кулланып, яңа дәрес эшкәртмәләре төзи һәм методик тәкъдимнәр, шул җөмләдән “Исем” темасын өйрәнү буенча тәкъдимнәр кертә алалар.

Әдәбият

1. Буданова Р. Иҗади үсешкә омтылып // Мәгариф. – 2005. – №9. – Б. 29 – 31.
2. Җамалетдинова З. Иҗади үсеш технологиясе // Мәгариф. – 2003. – №8. – Б. 56 – 57.
3. Иҗади үсеш технологиясе. “Түгәрәк өстәл” янында сөйләшү // Мәгариф. – 2004. – №5. – Б. 49 – 50.

4. Интерактив китапханә. – URL: http://www.бала.рф/ipad/library.html?id=101; мөрәҗәгать итү вакыты: 27.10.2023.
5. Сәгъдиева Р.К., Гарәпшина Р.М., Хәйруллина Г.И. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 6 нчы сыйныф. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2017. – 191 б.

## АЛАР – БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫГЫБЫЗ

Нәҗметдинова А.Ф.
Алабуга Иске Юраш мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.

Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Кешелек дөньясына кайгы-хәсрәт китергән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга җитмеш сигез ел вакыт узса да, аның ачы кайтавазы әле бүген дә үзен сиздереп тора. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Ять-яшь егетләр, кызлар туган җирләрен саклау өчен фронтка китәләр. Күпләренә хәтта әйләнеп кайтырга да насыйп булмаган. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада. Гомерендә бер мәртәбә дә авыз тутырып «әти» дип әйтә алмаган балалар, хәзер инде үзләре әби-бабай яшендә. Канлы ут эчендә йөргән, исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булган чал ветераннарыбыз да инде калмады. Безнең максат - аларның исемнәрен тарих битләренә кертү. Алар безнең халкыбыз тарихында урын алырга лаек шәхесләр. Язмамда утлар, сулар кичкән шундый ветераннарның берсе – минем татар теле һәм әдәбияты укытучысы Клара Федоровнаның әтисе – Козырев Федор Иванович хакында. Минем бүген аның данлы тормыш юлы белән сезне таныштырып китәсем килә.

Яшьлек - кеше гомеренең иң саф, иң гүзәл, иң тынгысыз һәм иң күңелле вакыты. Бик күп еллар үтеп, чәчләренә гомер кышының кыраулары төшә башлагач та, кеше яшьлеген, аның кабатланмас бәхетле көннәрен һәм ул көннәрдә кичергән борчу-шатлыкларын сагына. Ничек кенә булмасын, уфтанып искә алмаган яшьлеген Фёдор бабай. “Язмыш, язмыштан узмыш юк", - дип кенә куя торган булган ул. Әйе, рәхәт булмагандыр ул буынга. Ачлы-туклы тормыш. Берсеннән-берсе авыр физик эш: җир сукалау, урак уру, урман кисү, көтү көтү дисеңме - берсе дә калмаган. “Ике атлары, бер сыерлары була. Әмма коллективлашу елларында барысы да колхозга күчә. Бер сыерлары калган була, анысы да ни сәбәпледер үлә. Шулай итеп, бар булган байлыкка бер кәҗә сатып алып, көн күрә башлыйлар алар. Ничек кенә авыр булмасын, тормыш дәвам итә. Сигез чакрым ераклыктагы Юраш авылына йөреп, 7нче сыйныфны тәмамлый әти. Ул вакытта әле уку латин графикасы нигезендә алып барыла. Авыр булса да, укуын Морт мәктәбендә дәвам итә ул. Укуда һәрчак алдынгылар рәтендә була. Өстәвенә - лидер. Әллә яхшы укуы, әллә үрнәк

тәртибе белән һәммә сабакташы аңарга тартыла. "Белмим, нишләптер, магнитка сарылган кебек җыелалар иде яныма", - дип искә ала иде ул мәктәп, балачак елларын, дип сөйли остазым.

1940 елның кышында үз теләге белән ФЗОга укырга китә Фёдор абый. Киләчәктә чын кеше, нинди дә булса һөнәр үзләштерү була аның бөтен теләге. Барып керү белән, вакытлыча паспорт тоттыралар кулларына. Аннан инде ныклап торып эшкә өйрәтә башлыйлар. Сизелмичә алты ай үтеп тә китә. Бу вакыт эчендә утын кисәргә дә, пычкы кайрарга да, балталар һәм урман кисү өчен яраклы төрле кораллар ясарга да өйрәтәләр аларны. Өйрәнгән эшне күтәреп йөрисе юк. "Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз", ди бит татар халкы. ФЗОның төп өйрәнү оешмасы урман хуҗалыгы участогында була. (Мамадыш районы тирәсе). Шулай көн артыннан көн үтә. Көннәрдән-беркөнне, урман кисеп ятканда, 1941 елның 22 июнендә бөтен урман буйлап сугыш башлану хәбәре тарала. Ул да булмый зуррак  яшьтәгеләрне җыйнап алып та китәләр. Шулар рәтендә мастер-остазлары да китеп бара. Соколкада була бу вакыйга.

1942 елның җәе. Авылга кайтырга туры килә Фёдорга. Күрәсең шундый боерык булгандыр. Авылда урып-җыю эшләре башланган вакыт. Авыл үзенә күрә зур булса да, техника дигән нәрсә юк. МТСтан график буенча районга бер комбайн бирелә. Эшләүче юк. Шулай да өлкән яшьләрдәге Михаил Николаевич Борисов атлы кешене комбайнга утыртып, Фёдорны абыйны аның ярдәмчесе итеп куялар. Кая барасың, карышу дигән нәрсә булырга тиеш түгел. Әмма ярдәмче булып эшләү бәхетенә ирешә алмый ул.18 яшь тулуга, сугышка чакыру кәгазе килеп төшә. Җәяүләп, 45 чакрымны үтеп, Алабуга военкоматына килеп төшәләр берничә егет. Шул ук көнне җәяүләп Можгага озаталар. Ач-ялангач, аякта - чабата. Көч-хәл белән килеп җитәләр. Монда шулай да җылы каршылыйлар: җылы өй, ашарга бәрәңге бирәләр, йокларга - сәндәрә. Ике көн карантин, беркая чыгарга рөхсәт булмый. Шулай да берсе рөхсәтсез өенә кайтып китә. Андый кеше ул вакытта дезертир саналган. Икенче көнне, барысын чокыр кырына тезеп, кулларына мылтык тоттырып, “Бер залптан атып үтерергә”,-дигән боерык бирелә һәм шулай эшләнелә дә. Хәрби кануннар катгый була. Вәхшилек кебек тоелса да, башкаларга сабак булсын өчен эшләнгәндер дип кабул итәсе килә бу кыланышны. Шулай итеп, солдат хөкем җәзасына тартыла.

Кием-салымнар, ашау-эчүләр, кораллар биреп, Сталинград янына җибәрәләр. Полковник приказы буенча Фёдорга, ике иптәшенә  38нче әзерлек полкына юллама бирелә. Командир итеп билгеләнә ул. 1944нче елга кадәр фронтның алгы сызыгын сугышчылар белән тәэмин итеп торалар.

1944нче елның ахырында приказ буенча аның отрядын Балтыйк буена җибәрәләр. Аларны поезд вагоннарына төйиләр (300-350ләп кеше). 2-3 көннән инде Литва территориясендә булалар. Аларның бурычы - Балтыйк илләрен дошманнан арындыру. Бу эш 1945нче елның маена хәтле дәвам итә.

1945нче елның 9 мае. Җиңүне Көнбатыш Двинаның яр буенда автоматтан аткан салютлар белән каршы алалар. 45нең май ахырында тугыз вагон төялгән әсирләр белән Россиягә озатылалар (500 дән артык әсир.). Поезд төнлә генә

барырга тиеш була, ә берничә кеше боларны саклый. Фёдор шунда әсирләр белән җитәкчелек итә. Кулларында автомат, капчыгында берничә граната (ф-1), ә билдә - кинжал. Әгәр ул-бу булса, алар вагонны шартлатырга тиеш булалар. Әсирләрне исән-сау тиешле урынга илтеп тапшыралар һәм Мәскәү комендатурасына керәләр. Аннан аны тагын Муромдагы хәрби офицерлар училищесына укырга җибәрәләр.

Әйләнеп кайтуга, өенә полк командирыннан сугышта күрсәткән батырлыклары өчен рәхмәт хатлары килә. Шулай итеп, Фёдорга сугыштан исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп була.

Кызганычка каршы, Федор бабайның сугыш чорындагы мактау кәгазьләре, медальләре бер урыннан икенче урынга күчеп йөргән вакытта эзсез югала. Ул аны эзләтеп торуны кирәк дип тә тапмый. “Иң мөһиме: үзебез исән-сау”,- дип әйтә торган була ветеран.

Сугыштан соңгы еллар...Авыл хуҗалыгын торгызу бик авыр. Хезмәт авыл кешесенең иң беренче ихтыяҗы булырга тиеш. Алай булмаганда, колхоз тормышын алып барып булмый.Уңыш искиткеч түбән. Шуңа күрә дә хезмәт хакы да юк, бары таякка гына эшли халык. Мул уңыш өчен белем күтәрергә кирәклекле күпләр аңлый, әмма мөмкинлек юк.

Ничек тә үзендә көч табып, Любян техникумына юл ала Фёдор Иванович. Техникумны тәмамлагач, юллама белән Башкириягә җибәрелә. Бу вакытта ул инде гаилә корган, бер баласы да бар. Шунлыктан гаиләсе белән бергә сынау үтәргә туры килә аңа.

1954 ел. Язмыш аны яңадан туган якларына кайтара. Авылда белгечләр җитмәү сәбәпле, аны МТСта баш агроном итеп билгелиләр. Хуҗалыкны фән нигезендә кору өчен, бу белем генә җитеп бетми, әлбәттә. Кешене көчле итүче төп сыйфатларның берсе - хыялның көчле булуы, икенчесе - хезмәт ярату. Тагын бер бик кыйммәтле сыйфат - кешеләргә һәм җиргә ышану.Фёдор Иванович үзенең туры юлдан баруын аңлый. Ул партиягә керә, ил белән, үз халкы белән бергә атларга ышаныч тудырырга тырыша, үзендә зур омтылыш, биеклеккә күтәрелү сизә. Гаилә тормышын да җайлап җибәрә, бер-бер артлы балалар туа, гаилә ишәйгеннән-ишәя. Әмма ишле гаилә булу аның алга куйган максатын тормышка ашырырга комачауламый, киресенчә, аңа көч-дәрт өсти. Читтән торып, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Алты бала атасы 1961 елда югары уку йортын тәмамлап, диплом алып, туган ягында колхоз рәисе булып эшли башлый. Белгечле җитәкче тәҗрибәләрен башлап җибәрә. Арыш, бодай, кукуруз һәм башка культураларга тәҗрибә үткәрә. Колхоз иген-кырлары, басулары аның горурлыгы, ышанычы, шатлыгына әйләнә. Елдан -ел югары уңыш алуга ирешәләр. Бу уңышларга ирешү өчен, бик күп тир түгәргә туры килә аларга. Төн йокылары кача. Әмма көч-дәрт сүнми, сүрелми.

Кемнәр генә булып эшләргә туры килми аңа үз гомерендә, ун елдан артык колхоз рәисе, шактый еллар экономист, прораб та, бухгалтер да булып эшли ул. Кем генә булып эшләсә дә, эшләгән җирләрендә халык күңелендә үзенең эшләгән эшләре белән гел яхшылыкка өнди торган якты йолдыз булып кала. Сугыш ветераны - гомере буе халыкка хезмәт иткән кеше. Ул - авылның иң

атаклы коммунисты. Гомере буе йорт-җирен белми, гомерен ил хезмәтендә уздыра. Ул – туган авылының беренче җитәкчесе дә. Беренче сепараторны да ул алып кайткан, ут-су керттергән, колхозга иң беренче радиолгычны да ул алып кайткан, тегермәннәрне дә ул төзеткән. “Колхозның кай ягына гына килеп чыксаң да, аны хәтерләтә иде”, - дип сөйли торган була авыл халкы. Кызганыч, авыллары гына хәзер җир белән тигезләнгән, бер генә йорты да калмаган.

Безгә дә, халыкка хезмәт итүнең мәңге онытылмый торган җан рәхәте, изге хезмәт булуын аңлата мондый гыйбрәтле язмыш ияләре. Фёдор бабайның гомер юлы күпләргә якты өлге итеп алырлык, меңнәргә үрнәк булырлык. Сүз дә юк, ул халык өчен генә түгел, безнең өчен дә зур маяк. Андыйларның исеме тарихта, һичшиксез, урын алырга тиеш.

Әдәбият

1. Гаилә архивы.
2. Трофимов А.Я. "Наше наследие", 2002, №62; Свод, с. 258-260.

## “ГАРИФ АХУНОВНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ”

Нургатин Р.Р.,Әлмәт шәһәренең
“Адымнар-Әлмәт”гимназиясе укучысы.
Фәнни җитәкче: Тамасова Я.И.

*«Сатмас егет илен алтын көмешләргә,*

*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*

*Алтынны ул чүпкә санар,*

*Иң кыйммәтле күрер Ватанын»*

Татар халкының тарихи үсешендә тирән эз калдырган, бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә багышлаган шәхесләребез бар. Шундыйларның берсе – илленче еллардан башлап, тырыш һәм гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән әдип Гариф Ахунов. Г. Ахунов – күпьяклы, киңкырлы талант иясе.

Казан арты, Арча яклары дөньяга никадәр атаклы кешеләр биргән! Ә менә дөньяга туган көненнән башлап михнәтне күп күргән, әтисез ятимлек ачысын татыган, ачлык-ялангачлык белән күзгә-күз очрашкан, колониядә тоткыннарга бирелә торган баланданың тәмен татыган, хәтта туып-үскән авылының юкка чыгу фаҗигасен кичергән кешенең – шушы өлкән язучы агайның гомере буена тормышка гашыйк булып, кешеләрне яратып яшәве гаҗәп тә, соклангыч та, адым саен замана авырлыгыннан зарланып яшәүчеләр өчен үрнәк тә булып тора.

Гариф Ахунов 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Кече Өчиле авылында (хәзерге вакытта ул авыл юк) крәстиян гаиләсендә туа. Аның әтисе Ахунҗан абзый, авылның беренче совет активистларыннан булып, күмәкләшү чорында ярлы крәстияннәр арасында зур оештыру эшләре алып бара һәм шул эшләре өчен 1931нче елда кулаклар тарафыннан үтерелә. Әтисез калган дүрт баланы әниләре карап үстерә. Күрше Казанбаш авылы мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, Гариф 1940 елда Арча педагогия училищесына укырга керә. Ләкин Ватан сугышы башланып, гаиләнең хәле бик мөшкелләнгәч, Гариф ихтыярсыз эшләнгән бер «җинаяте» аркасында зур бәлагә очрый: колхоз кырыннан өенә рөхсәтсез бер күтәрәм бәрәңге алып кайтканы өчен аны хөкемгә тартып, өч елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Яшүсмер егет хөкем мөддәтен Ерак Көнчыгышта хезмәт белән төзәтү лагеренда уза. Кайткач, 1946 елның көзеннән училищеда өзелгән укуын дәвам иттереп, 1947 елда аны тәмамлап чыга. Аннары, Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә.

Гариф Ахуновның язучы буларак беренче иҗат тәҗрибәләре дә нәкъ менә шушы студентлык елларына туры килә. 1951 елда «Үсү юлы» альманахында яшь авторның «Галләм сорау бирә» исемле тәүге хикәясе басылып чыга. Ул шулай ук газета-журналларда очерклары, рецензия һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән күренә башлый. Шул ук 1951 елда, университетның соңгы курсында укыган чагында, аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар. Мондагы хезмәтен ул университетны тәмамлап чыкканнан соң да дәвам иттерә - алты ел буе анда әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире һәм журналның җаваплы сәркәтибе вазифаларын башкара. Журналда эшләү яшь каләмнең иҗади сәләтен ачып җибәрүдә һәм әдәби осталыкка өйрәнүдә үзенә күрә бер мәктәп ролен үти. Бу елларда ул күп кенә хикәяләрен, беренче күләмле әсәре булган «Яшьлек яме» (1955) повестен иҗат итә. Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Әнвәр Давыдов, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Салих Баттал кебек танылган язучылар турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен һәм иҗат портретларын бастыра.

1978-1986нчы елларда әдипнең өч кисәкле роман итеп уйланыган «Идел кызы» исемле трилогиясенең беренче ике китабы басылып чыга. Әсәрдә автор катлаулы тормыш юлы үткән төп каһарманнарының язмышы аша 1900-1930еллар эчендә Урта Идел төбәкләрендә булып узган зур тарихи вакыйгаларның һәм иҗтимагый-социаль процессларның җанлы картинасын күз алдына китереп бастыра. Кызганычка каршы, язучы иҗат мирасының төп әсәрләреннән булган һәм тарихи үткәнне яңача, чын объектив күзлектән чыгып яктыртуны максат итеп куйган бу трилогиянең өченче кисәге язылмыйча кала.

Сиксәненче елларның икенче яртысында һәм туксанынчы еллар дәвамында әдип, илдә барган демократик үзгәрешләр белән рухланып, үзе кичергән тормыш материаллары нигезендә, авылда үзгәртеп кору чоры вакыйгаларына багышланган «Гомер юлы» романын, «Эт патша», «Соңарган мәхәббәт» исемле кече күләмле ике повестен һәм өч кисәктән торган «Тимерханның күргән-кичергәннәре» дигән документаль әсәрен иҗат итә. Гариф Ахуновның әдәби мирасында Казанда Татар академия театры, К.Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театры, Әлмәт татар драма театры, Минзәлә драма театрлары сәхнәләрендә кат-кат куелып, заманында тамашачының игътибарын җәлеп иткән берничә пьесасы да бар: «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк» (Ф.Мостафин белән бергә язылган), «Чикләвек төше», «Ардуан батыр» (шул исемнәрдәге повестьлар буенча инсценировкалар), «Акчарлаклар» (Ш.Камалның шул исемдәге повесте буенча инсценировка) һ.б. Әдип шулай ук күпсанлы әдәби һәм истәлек язмалары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре («Әдәби язмышлар», «Чишмәләр белән сөйләшү» исемле җыентыклар, 1970, 1985) һәм әдәби тәрҗемә китаплары белән дә укучылар арасында киң таныла. Аерым алганда, ул татар теленә В.Закруткинның «Плавучая станица» («Йөзмә станица», 1953) романын, А.Макаренконың «Педагогик поэма»сын (1957), Рабиндранат Тагор «Хикәяләр»ен (1960), Михаил Шолоховның «Тихий Дон» («Тын Дон») эпопеясының икенче, дүртенче китапларын (1964, 1965), Татар дәүләт академия театры өчен Н.Погодин, А.Островкий һәм башка драматургларның пьесаларын тәрҗемә итә.

Гариф Ахуновның яшь талантлар белән тыгыз элемтәдә булып, аларны үстерүдә күп көч куюы, театрны яратуы, дөнья малына кызыкмыйча, булганына шөкер итеп әкрен генә тормыш тәгәрмәчен тәгәрәтүе, урыс язучыларыннан Валентин Распутин, Сергей Залыгин кебек мәшһүр затлар белән фикердәш, дус булуы, төрле авыл-шәһәрләргә очрашуларга йөрүе дә һәм көн-төн димичә чабулары аның чын мәгънәсендә намуслы, милләт җанлы, халыкчан булуын күрсәтә. Язучылар арасында абруе зур, хәтта урта яшьләрдәге язучыларның да, киңәшләр сорап, Гариф Ахуновка килүләре мәгълүм. Андыйларны да күз уңыннан җибәрмичә, барлап, киңәшләрен биреп тора ул. Изге җанлы, кешелекле диләр андыйлар турында.

Гариф Ахуновның кайсы гына фотосурәтенә күз салсак та, берсендә генә дә елмаймыйча төшкән фотосын очратканым юк минем. Көдрәләнеп өскә караган куе чәчләр, куе кара каш, зур көләч күзләр һәм энҗе кебек тезелеп киткән ак тешләре һәр фотосыннан: “Без монда, 30 безнең Гариф менә шундый ул!” – дип карап торалар. Аның елмаюлы карашы табигать кочагында үскән бу малайның тормышны сөюен раслый, шуңа күрә язучы әсәрләрендә тормышны

сөйгән, максаты булган, табигатьне яклаучы ихлас күңелле образларны бирергә тырыша. Бу – аның күңел халәте. Мәкаләмнең ахырында Аяз Гыйләҗевның бик матур җөмләсен язып үтәсем килә: “Гарифның “эшем бармый әле, тукталдым... кәефем юк” дигән сүзләрен бер чакта да ишеткәнем булмады минем. Гариф белән эш, тырышлык, хезмәт янәшә яшиләр. Әнә шуңа күрә дә ул тормышны ярата белә, тормыш төзүче эш кешесенә аның ихтирамы чиксез...”.

Г.Ахунов шәхес буларак һәркемгә үрнәк. Аның күңел күзе матур. Гариф ага җирдәге матурлыкны күреп, шуны иҗаты белән баетып, укучыларын яраттыра алды. Мин ышанам, әле озак еллар буена Г.Ахуновның әсәрләре кулдан төшмәс, чөнки аларда тормыш, аларда мәхәббәт, яшьлек, яшәү яме кайный.

**Әдәбият**


1. Г.Ахунов. Йолдызлар калка. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1980. – Б.6.
2. Исәннәрнең кайтыр юлы бар // Мәдәни Җомга. – 2000. – 1 ноябрь
3. Гариф Ахунов: язучы турында замандашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б.5.


## Ф.КӘРИМНЕҢ “БЕЗДӘ ЯЗДЫР” ШИГЫРЕ АША УКУЧЫЛАРГА ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ


Нуриева Р.Р.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Нәрсә ул ватанпәрвәрлек, ягъни патриотизм? Интернет челтәренә мөрәҗәгать итсәк, Википедия сайты безгә түбәндәге аңлатманы бирә: ватанпәрвәрлек – туган иленә, халкыңа бирелгәнлек, үзеңнең эшең белән ватаныңның һәм халкыңның мәнфәгатьләрен канәгатьләндереп намуслы хезмәт итү [2]. Димәк, гади сүзләр белән әйткәндә, патриотизм – ул Ватанны ярату, халкыңны ярату. Бу сүз безгә грек теленнән кергән.

Бүгенге көн укучысында бу хисне тәрбияләү өчен татар теле һәм әдәбияты укытучысы үз өлешен кертә аламы? Әлбәттә. Укучыларга патриотик тәрбия бирү максатына ирешүнең бер коралы дип әдәбият дәресләрен атарга мөмкин. Бүгенге шартларда яшь буында патриотик хисләрне уяту җиңелләрдән түгел. Шуңа күрә фәнни эшебезнең актуальлеге югары дәрәҗәдә дип уйлыйбыз. Сәяси тотрыксызлык, халыкара конфликтларның югары ноктага җиткән вакытта яшь укучыда үз иленә, туган ягына мәхәббәт уяту, аңарда башкалар алдында якларга әзер тору хисен уяту укытучылар өчен шактый катлаулы мәсьәлә. Бигрәк тә татар теле укытучылары өчен, чөнки татар теленә булган мөнәсәбәт, кызганычка каршы, бүгенге көндә тиешле дәрәҗәдә яхшы түгел.

Әдәбият дәресләрендә патриотик тәрбия бирүнең төп максатлары түбәндәгеләр:

1) укучыда гражданлык җаваплылыгы тәрбияләү;

2) актив, рухи яктан камил булган шәхес тәрбияләү;

3) укучыларны илебез тарихында булган вакыйгалар белән таныштыру;

4) укучыларны патриот буларак формалаштыру;

Әлеге фәнни эшебезнең максаты – татар әдәбияты дәресләрендә укучыларга патриотик тәрбия бирү ысулларын ачыклау.

Кайсы гына халыкның әдәбиятын алсак та, анда без укучыларга рухи тәрбия бирерлек бай материал таба алабыз. Татар әдәбияты да бу тенденциядән читтә калмый. Нинди генә авторны өйрәнсәк та, аның иҗатында Туган якка багышланган әсәрләрне очратырга була. Бу патриотик тәрбия бирү өчен шактый кыйммәтле материал.

Фәнни тикшерү өчен без 7-11нче сыйныфларны сайлап алдык. Моның өчен "Вакыт-мәгариф" китап нәшрияты җитәкчелегендә бастырылган татар әдәбияты дәреслекләре сайлап алынды.

Әдәбият дәресләрендә патриотик тәрбия бирү максатына ирешү өчен сайлап алырлык авторлар шактый күп: Габдулла Тукай, Фатих Кәрим, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев һ.б.

7нче сыйныф өчен дәреслектә Габдулла Тукайның "Милли моңнар" шигыре тәкъдим ителә[5]. Без бу шигырьне әдәбият дәресендә патриотик тәрбия бирү өчен куллана алабыз. Бөек Тукай язып калдырган шигъри юлларда татар халкының зур тарихи юлда күпме михнәт чиккәнен, ләкин сыгылмавын, бирешмәвен күрәбез. Нинди генә сынаулар үтергә туры килмәсә дә, татар халкы үз моңын, рухи көчен югалтмаган. Әлеге шигырьне укыганнан соң, укучылар белән бу темага әңгәмә оештыру бик кулайлы. Монда милли үзаң да, халкыбызның батырлыгы да, татар теленең матурлыгы да...

Шул ук сыйныфта тәкъдим ителгән Фатих Кәримнең "Бездә яздыр" шигыренә дә игътибар итәсебез килә, чөнки бу шигырьдә халкыбызның Бөек Ватан сугышы елларында фашизмга каршы көрәше, илебезгә язны кире кайтару омтылышы сурәтләнә. Бу илебез тарихында булган мөһим вакыйгаларны яктырту, укучыларда илебез тарихы белән горурлану хисен уяту өчен кулайлы алым.

Әдәбият дәресләрендә ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләүнең тагын бер алымы буларак – укучыларның халкыбызның бөек шәхесләре белән танышуын атый алабыз. Чөнки безнең халык үзенең язучылары, шагыйрьләре, рәссамнары, музыкантлары, драматурглары белән дә дан тота. Әдәбият дәреслекләрендә чәчмә әсәрләр һәм шигырьләр генә түгел, ә бөек рәссамнарыбызның да иҗат җимешләрен очратырга була. Укучыларда илебез белән горурлану хисен уяту өчен бөек шәхесләребнең илебез тарихына керткән өлешләрен күрсәтү зарури. Алар укучылар өчен үрнәк, идеал булырга тиешләр. Үз илен яратып, аның өчен хәтта үз-үзләрен корбан иткән шәхесләр укучыларда горурлану хисе уятырга тиешләр. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары дәрес вакытында нинди дә булса шәхес турында һәр укучыны кызыксындрырлык итеп сөйләргә тиешләр.

Шулай ук укучыларны үзләрен бөек шәхесләр турында мәгълүмат туплау эшенә кертеп җибәрү мөһим. Бу проект эшен үзләштерү өчен дә, фәнни эзләнүләр башкару өчен да, һәм патриотик тәрбия алу өчен дә кулайлы алым.

Түбәндәге сүзләргә йомгак ясап, шуны әйтәсебез килә: мәктәптә патриотик тәрбия бирүнең кулайлы ысулы булып – әдәбият дәресләрен билгеләргә була. Чөнки укучылар әсәрләр, шигыйрьләр, шәхесләр аша бик күп мәгълүмат ала алалар. Туган җирне ярату, үз халкың белән горурлану кебек хисләрне матур әдәбият текстлары аша кабызырга мөмкин. Ә бөек шәхесләрнең халкыбыз өчен кылган гамәлләре ярдәмендә укучыларда үз илең өчен янып яшәү теләген уятырга мөмкин.

Әдәбият

1. Әхәт Садриев.Патриотлар тәрбиялибез.“ Мәгариф” журналы №3, 2010.
2. Ватанпәрвәрлек // Wikipedia URL: https://tt.wikipedia.org/wiki/ [Электрон ресурс] Ватанпәрвәрлек (мөрәҗәгать итү датасы: 25.10.23).
3. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.
4. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1994. – 405 б.
5. Хәсәнова Ф.Ф. Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек. 7-нче сыйныф. – Казан: “Мәгариф-Вакыт”, 2017. – 143 б.

## ЧЫН БӘХЕТНЕ БИРӘ ТИК ГЫЙЛЕМ ГЕНӘ, БАШ ИЯЛӘР ҺӘРВАКЫТ БЕЛЕМЛЕГӘ.

Нуруллина И.А.
Лениногорск шәһәренең 4 нче урта гомуми
белем бирү мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкчесе: Нуруллина З.С.

“Утыз Имәни исемен югалтырга ярамый. Аның шәхесен һәм әдәбиятыбызны бизәрлек иҗатын без бүгенге һәм киләчәк буынга танытырга тиеш. Утыз Имәнинең тирән фәлсәфи әсәрләрендәге кайбер юлларны ятлап, муенга бөти итеп тагып йөртерлек. Әмма аның хакында сөйләшүләр галимнәр арасында, тар даирәдә генә калмасын иде. Утыз Имәни исемен матбугатта, телевидениедән ешрак яңгыратырга кирәк. Халкыбыз үзенең улы – нинди фикер иясе барлыгын белергә лаек”. КДУ профессоры Хатыйп Миңнегуловның шагыйрь һәм дин гыйлеме белгече, мөгаллим Габдерәхим Утыз Имәнигә карата әйтелгән әлеге сүзләрен бүгенге конференциянең цитатасы итеп кулланырга мөмкин.

XVIII гасыр азагында дөньяга килгән Габдерәхим Утыз Имәнине галимнәр татар әдәбияты тарихында ике гасырны тоташтыручы рухи күпер дип атый. Әдип гомеренең төрле елларында, төрле вакытларда йөздән артык әсәр язган. Аларның шактый өлеше гарәп һәм фарсы телләрендә. Әсәрләре арасында

шигырьләреннән тыш тел, фәлсәфә, әхлак-хокук, сәүдә-экономика, медицина, астрономия мәсьәләләренә караган гыйльми хезмәтләр дә була. Әдипнең шигъри әсәрләреннән киң даирәгә иң мәгълүм булганы – «Мөһимматез-заман» («Заманның мөһим билгеләре») поэмасы. Ул аерым китап булып беренче мәртәбә 1889нче елда басылып чыга. Әсәр, тулысы белән әхлак мәсьәләләренә багышланып, кешеләрдә булган кимчелекләрне тәнкыйтьли, аларны белемле-мәгърифәтле булырга, үзара тату яшәргә, сабыр һәм инсафлы, әдәпле булырга, олыларга һәм кечеләргә, гарипләргә һәм мохтаҗларга мәрхәмәтле булырга чакыра. Күргәнебезчә, болар барысы да әхлакый сыйфатлар. Димәк, күңеленә шушы сыйфатлар хас икән, ул нурлы һәм якты булачак. Менә каян килә икән ул хәзерге вакытта кулланышка кергән сүзләр: нурлы өй, нурлы йөз.

Әсәрләрендә әдәплелек, акыл белән эш итә белү кебек сыйфатлар “иман” төшенчәсе белән бер дәрәҗәгә куеп карала. Күп кенә шигырьләренең тематикасы - иман, әдәп, акыл, таза күңел. Идеясе - һәр кеше өчен бу тормышта мәңгелек рухи кыйммәтләр булуы зарур. Мәсәлән, “Үгет” шигырендәге түбәндәге юлларга игътибар итик:

Үгет кермәс кешегә бирмә үгет,
Өйрәтмә син мине, дип, сүгәр ул эт.
Иманлы булса, тынлар үгетең ул,
Колак салмаса әгәр, тукта, сак бул.
Агармыйдыр юган белән кара таш,
Үгет алмас кешеләр шуңа охшаш...

“Гаварифез - заман” (“Замана укымышлылары” (бүләкләре) поэмасы да шул ук проблемаларны яктыртуга багышланган. Әдип укымышлы, белемле кешеләрне мактый, наданнарны тәнкыйтьли. Ул күп төрле чаралар һәм сурәтләр ярдәмендә, гыйлем, белем төшенчәләренең эчтәлеген, кеше өчен әһәмиятен, тормыштагы урынын гәүдәләндерә:

Син гыйлем тупла, наданлыктан уян,
Ахирәт көнне надан – эттән яман.
Бел: гыйлем нур ул, сине нурландырыр,
Ә наданлык – ут, сине ул яндырыр...

Г.Утыз Имәни фикеренчә, белем - кеше идеалының зарури сыйфаты, бәхет ачкычы. Утыз Имәни белем төшенчәсен һөнәр, эш-гамәл белән тыгыз бәйләнештә карый. Шагыйрь карашынча, хакимият ияләренең, кеше белән идарә итүчеләрнең белемле, һөнәрле булулары зарури. Авторның идеалы – белемле, укымышлы, гадел, киң күңелле, сабыр, тәрбияле, әхлаклы кеше. “Белем һәм акыл”, - ди автор – кешене кеше итә, әгәр бу сыйфатлар юк икән, ул – хайван мисалында”. [Г.Утыз Имәни 1986: 43]

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.
Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,
Баш ияләр һәрвакыт белемлегә.

Шагыйрь халыкны мәгърифәтле итү планын алга сөрә. Әлбәттә, Г.Утыз-Имәни бар халыкны үз мәктәбенә укытырга утырта алмый. Бу эшне башкарырлык

әзерлекле укымышлылар тормышта юклыгын да ул яхшы белә. Шул ук вакытта, хәзерге тормышта, сабыйлардай гаҗиз, — белемсез, надан габи (аңгыра) булып калырга да ярамый. Ул аңлы, гавариф булуны, — мәгърифәтле булуны һәркемнең үзенә намус эше итеп йөкли. Г.Утыз-Имәни дөньяви белемне күз алдында тота. Моны ул, бөтен катгыйлыгы белән «Тохфәтел горабәэ…» (Читтә йөрүчеләргә - гарибләргә - бүләк...) әсәрендә җәмәгатьчелек алдына куя:

…Гыйльме заһирдыр сәңа нуре чыраг,
Би гыйлем бу суфи Хакдин күп ерак…
…Бәс, быйлә күр гыйльме заһире, әй дәдә,
Улма, һәргиз, бу гыйлемдин сән җөда…

Күрәсең, нәкъ шул гыйлемне булдыруда, ул — муллалар хөкемендә калмаска, гыйлемне-белемне — үзе, аерым, үз алдына мөстәкыйль өйрәнүне һәркем алдына бурыч (фарыз) итеп куя. Бу юлда нинди тапкырлыклар, тырышлыклар күрсәтү тиешлеген, «Гаварифез-заман» әсәрендә үзенең чит илләрдә — горбәттә нинди кыенлыклар кичереп, тырышлыклар күрсәтеп күренекле галим булып җитешүе мисалында күрсәтә. [Г.Утыз Имәни 1986: 196]

Габдрәхим Утыз Имәни әл-Болгари күпкырлы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге, бай иҗат мирасы белән зур хөрмәткә һәм ихтирамга лаек шәхес. Аны халкыбыз тарихында — бөек шәхес, шигърияттә — яңа сүз әйтүче каләм иясе, иҗтимагый фикер тарихында яңа карашларга күпер салучы дип таныйлар.

Әдәбият


1. Борынгы татар әдәбияты.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.
2. Г.Утыз Имәни. Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 397 б.
3. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Раннур, 2002.
4. Шәрипов Ә. М. Габдерәхим Утыз Имәни., Татар әдәбияты тарихы, т1. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1984. – 564 б.


## МАТУР ӘДӘБИЯТ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ АНЫКЛАГЫЧЛАР ҺӘМ АЛАРГА ОХШАШ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ


Проскурина Р.И.
КФУның Алабуга институты магистранты
Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина


Бүгенге көндә баш кисәкләргә – ия һәм хәбәр, иярчен кисәкләргә – аергыч, тәмамлык, хәл һәм аныклагыч, модаль кисәкләргә эндәш һәм кереш сүзләр керә. Сүзләр бәйләнешенә мөнәсәбәттә караганда, хәбәрлекне генә белдерүче кисәкләр буларак, ия һәм хәбәр беренче дәрәҗәле кисәкләр булалар, ягъни алар сөйләм оештыруда беренче дәрәҗәдәге рольне уйныйлар. Үзара тәгълләүле мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең ияртүчесе буларак, аергыч, тәмамлык һәм хәл икенче дәрәҗәдәге кисәкләр, чөнки сөйләм оештыруда икенче дәрәҗәдәге

рольне уйныйлар. Аныклаулы бәйләшештәге сүзләрнең ияртүчесе буларак, аныклагыч өченче дәрәҗәдәге рольне уйный.

Беренче һәм икенче дәрәҗәдәге җөмлә кисәкләре башлангыч сыйныфтан ук өйрәнелә, ә аныклагыч белән татар мәктәпләренең татар төркемнәрендә укучылар җиденче сыйныфта гына таныша.

Ияртүче кисәктән соң килеп, аңа аныклык кертә торган кисәк аныклагыч дип ала. Аныклагычлар җөмләдә төрле сүз төркемнәре белән бирелгән кисәкләрнең мәгънәләрен төгәлләп, аныклап киләләр [Зәкиев, 1999: 19].

Аныклагычлар темасын мәктәп программасында өйрәнгән чакта, укучылар белән матур әдәбият әсәрләреннән мисаллар өстендә эшләү үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. Беренчедән, укучы алган белемнәрен гамәлдә кулланырга өйрәнә. Икенчедән, татар теле дәресендә предмет-ара бәйләнеш саклана.

Аныклагычларны күп кенә классик язучыларыбыз үз әсәрләрендә яратып кулланалар. Без игътибарыбызны Әмирхан Еникинең һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләренә юнәлттек. Бу ике язучы да кайнар хисле, җор телле әдипләр. Алар күп санлы хикәяләре, повестьлары һәм әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре белән күпләргә якын. Әдипләрнең әсәрләрен уку җиңел, күңелле. Бу язучыларның әсәрләренең стиленә карап, сүзләр, фразеологик әйтелмәләр, сүз формалары, аныклагычлар, сүзтезмәләр, җөмлә төрләре уңышлы кулланылганлыгын әйтә алабыз.

Әсәрләрне уку барышында аныклагычларны күзәттек. Ике язучы да аныклагычларны шактый күп кулланган. Аныклагычлар җөмләләрне тагын да тулыландыра, төгәл, аңлаешлы, матур яңгырашлы итә. Укучыларның сөйләм телен үстерүгә ярдәм итә.

Ә.Еники белән М.Мәһдиевнең аныклагычны куллануда уртак һәм аермалы яклары да бар. Уртак ягы түбәндәгедән гыйбарәт: алар икесе дә аныклагычны күп куллана. Аермалы ягы булып язучыларның төрле аныклагычлар куллануын әйтә алабыз. Ә. Еники үзенең хикәясендә күбрәк фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычларны куллана. Мәсәлән: *Син, Нургали, азык кытлыгыңнан чыгасың килсә, үзең башлап артыннан йөр.* Шулай ук ул фигыльләр белән бирелгән аныклагычларны да куллана. Мәсәлән: *Ул аның өстәл янына чыгып басуын күргәч тә чыраен сытарга мәҗбүр булды: юк, рәхим көтми иде ул аңардан.*

М.Мәһдиев күбрәк фигыльләр белән бирелгән аныклагычларны кулланган. Аның “Мәңгелек яз” дигән китабының беренче битендә үк бу төр аныклагычлар шактый күп кулланылган. Мәсәлән: *Райкомнан бу урынга тәкъдим иткәндә Рәифкә әйттеләр: Гарафиевның дәрәҗә бик зур, син яшь кеше, менә синең партшколада алган белемең шунда сыналачак.* Аның әсәрләрендә фигыльдән башка сүзләр белән бирелгән аныклагычларны да күзәтергә була. Мәсәлән: *Гәр Хуторга бер финанский йорт кирәк – уку йорты булсын.*

Мәгънә күләме аныкланмыш мәгънәсе белән бер үк булган аныклагычның аныкланмышка ярашмаган очракны ике язучы да сирәк кулланган. Мондый очракны табуы авыр булды.

Нәтиҗәдә, Ә.Еники да, М.Мәһдиев та аныклагычларны урынлы һәм уңышлы кулланган дип әйтә алабыз. Аныклагычларны язучылар әсәрләренең телен баету, аһәңле итү максаты белән кулланган. Бу – укучының тел байлыгын арттыра, матур итеп сөйләргә өйрәтә. Ә дөрес һәм матур итеп сөйли белү – кешенең гомуми культуралылыгының бер билгесе.

Бу язучыларның әсәрләрендә җөмләләрнең тыгызлыгы, аларның төрле әйләнмәләр, кереш сүзләр һәм аныклагычлар белән тулыланганы күренә. Гомумән, Ә.Еники һәм М.Мәһдиев матур әдәбият стилен үстерүдә зур эш башкарган.

Матур әдәбият әсәрләрендә аныклагычлар еш һәм урынлы кулланыла. Без моңа Ә.Еники, М.Мәһдиев әсәрләрен тикшерү нәтиҗәсендә инандык. Татар язучылары үз әсәрләрендә аныклагычларны уңышлы кулланалар. Аныклагычларны әсәрләрдә куллануның төп максаты булып әсәр телен аһәңле, аңлаешлы ясау.

Әдәбият


1. Еники Ә. Кичке шәфәкъ: повестьлар / Ә. Еники; ред. Я. М. Халитов; рәс. В. В. Фомин. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989. – 384 б.
2. Зәкиев М.З. Татар грамматикасы III том. Синтаксис. Казан: ФИКЕР, 1999, 148 б.
3. Мәһдиев М. Мәңгелек яз: роман, повесть / М. Мәһдиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 336 б. Мәһдиев, Мөхәммәт Сөнгат улы. Торналар төшкән җирдә: лирик повесть / М. Мәһдиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 224 б.


## УКЫТУ АЛЫМЫ БУЛАРАК ДИСКУССИЯ


Сәхәбетдинова Ә.Б.,
КФУ ның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Галимнәр фикеренчә, “Хакыйкать, фикерләр түгел, ә белем өстенлек иткән бәхәсләрдә туа” [Радецкий 2016].

Дискуссия (лат. discussio карау, тикшерү) 1. Бәхәс, нинди дә булса мәсьәләне әңгәмәдә, җыелышта, матбугатта тикшерү 2. Проблеманың гомуми чишелешен булдырырга ярдәм итүче уртак эшчәнлекне оештыру ысулы. 3. Укучылар хакыйкатьне коллектив эзләүгә кертеп, уку процессының нәтиҗәлелеген арттыручы укыту ысулы.

Дискуссия – бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү һәм фикер алышу ысулы. Хәзерге вакытта ул укучыларның инициативалылыгын, рефлексив фикерләүне үстерүне стимуллаштыручы белем бирү эшчәнлегенең иң мөһим формаларының берсе булып тора. Уку дәресләрендә дискуссияне даими куллануның мөһимлеге бәхәссез. Белемнәрне ныклы үзләштерү һәм аларны гамәли эшчәнлектә куллану мөмкинлеген аңлау өчен материалны уку һәм өйрәнү генә түгел, ә аның турында башка кеше белән фикер алышу да кирәк. Аралашу, диалог – һәр кеше өчен мөһим ихтыяҗ. Бары тик диалог кына

укытучы һәм укучыларга уку процессында хезмәттәшлек итәргә мөмкинлек бирә.

Бәхәсле проблеманы тикшергәндә, һәр як, әңгәмәдәш фикеренә каршы чыгып, үз позициясен дәлилли. Дискуссия укучыларда тәнкыйди фикерләү үсешенә дә ярдәм итә. Тәнкыйди фикерләү – кешенең фикерләү өчен таяныч ноктасы, идеяләр һәм мәгълүмат белән аралашу ысулы. Димәк, яңа мәгълүмат белән танышканда, укучы уйланырга, бу материалның төгәллеге һәм кыйммәте турында нәтиҗәләр ясарга тиеш [Заһидуллина 2000].

Шулай итеп, дискуссия бик катлаулы сөйләм формаларының берсе, аны үзләштерү өчен алдан әзерлек һәм мәгълүматны җентекләп сайлап алу кирәк.

Дәрес-дискуссиядә укучылар актив катнаша, әмма укытучының позициясе дә мондый дәреснең мөһим өлеше булып тора. Педагог укучыларны дискуссия алып бару кагыйдәләре белән алдан таныштырырга, материалны сайлап алуда ярдәм итәргә, проблемалы сораулар куярга, фикер алышуга тон куярга, дискуссиядә катнашучылар арасында элемтә урнаштырырга, дәрес вакытында дуслык шартларын сакларга тиеш.

Укытучы роле:

− проблемалы өлкәне анализлау, проблемаларны аерып чыгару, төп проблеманы формалаштыру, бурычларны кую;

− максат кую һәм эшчәнлекне планлаштыру;

− үзанализ һәм рефлексия (проблеманы чишүнең уңышлылыгын һәм нәтиҗәлелеген анализлау).

Укучы эшчәнлеге:

− кирәкле мәгълүматны эзләү, аны системалаштыру;

−төрле, шул исәптән стандарт булмаган ситуацияләрдә белем, күнекмәләр куллану;

− үз позициясен һәм карашын яклый белү;

− коллективта эшли белү;

− ирекле аралашуда сөйләм үсеше.

Дискуссия үткәргәндә мәҗбүри шартлар:

− катнашучыларның төрле карашларына хөрмәт;

− туган каршылыкларны бергәләп чишү юлларын эзләү.

Проблема куелганнан соң фикер алышуның төп этабы булып фикер алышуны оештыру тора. Укытучы алдан уйланырга һәм фикер алышу формасын тәкъдим итәргә тиеш [Королева 2022:34].

Дәрес-дискуссияне оештыруның берничә формасы бар.

Дебат − ике як арасында актуаль темалар буенча ачык структуралы һәм махсус оештырылган фикерләр алмашу. Бу бәхәстә катнашучыларның бер-берсен түгел, ә өченче якны үз хаклыгына ышандыруга юнәлдерелгән фикер алышуның бер төре.

Түгәрәк өстәл − ниндидер мәсьәләне тикшерүне оештыру ысулларының берсе . Бу ысул түбәндәге билгеләр белән характерлана:

1) фикер алышуның максаты фикер алышуга кагылышлы идеяләрне һәм фикерләрне гомумиләштерү;

2) түгәрәк өстәлдә катнашучыларның барысы да оппонентлар ролендә чыгыш ясый (башка катнашучыларның фикерләре турында түгел, ә фикер алышу мәсьәләсе турында фикер белдерергә тиеш);

3) фикер алышуда катнашучыларның барысы да тигез хокуклы; беркемнең дә үз ихтыярын һәм карарын диктантларга хокукы юк.

Симпозиум − ул берәр төрле гыйльми мәсьәлә буенча оештырылган киңәшмә. Симпозиумда катнашучылар үз карашларын белдерүче хәбәрләр белән чыгыш ясыйлар, шуннан соң экспертларның сорауларына җавап бирәләр. Симпозиум яңа фикерләр үсешенә, аларны яклауда ярдәм итә [Гуманитарные технологии 2011: 386-387].

Укыту ысулы буларак дискуссия белем бирү процессында укучыларның фикерләвенә һәм тәртибенә уңай йогынты ясый, аларда җаваплылык һәм аңлылык үсешенә ярдәм итә.

Әдәбият


1. Бим-Бад Б.М. Педагогический энциклопедический словарь. – М., 2002. – С. 72
2. Гуманитарные технологии преподавания в высшей школе: учеб.- метод. пособие/ кол.авторов: под. ред. Т.В.Черниковой. – М.: Планета, 2011. – 496 с.
3. Радецкий Ф. “Афоризмы и размышления о спорах” URL: https://proza.ru/2016/10/01/1717 (Мөрәҗәгать итү вакыты: 11.10.2023)


## Х. Х. САЛИМОВ − ПЕДАГОГ, ГАЛИМ, ОСТАЗ


Сәхәбетдинова Ә.Б.
КФУның Алабуга институты студенты
Җитәкче: Габидуллина Ф. И.


Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты бик бай тарихка ия, ул үз диварларында күп кенә күренекле һәм бик талантлы шәхесләрне күргән, шуларның берсе – Хәлил Хәлим улы Сәлимов(1947-2006).

Хәлил Хәлим улы 1947 елның 30 сентябрендә Апас районы Дәвеш авылында туган. 1966 елда Апас урта мәктәбен алтын медаль белән тәмамлый һәм Казан дәүләт университетының механика-математика факультетына укырга керә, ике айдан соң тарих-филология факультетына күчә, татар теле һәм әдәбияты факультеты студенты була; 1971 елдауниверситетны кызыл диплом белән тәмамлый. 1975 елда татар телләре кафедрасы буенча аспирантурага тәкъдим ителә. Бөтен дөньяга танылган төрки телләр профессоры Д.Г. Тумашева җитәкчелегендә "Татар авазларының спектраль анализы" темасына кандидатлык диссертациясе яклый. 1999 елның маенда бу талантлы галим "Татар теленең просодик системасы" темасына докторлык диссертациясе яклый. Аның докторлык диссертациясе татар теленең академик

грамматикасының бер өлеше булып тора. 2000 елның апрелендә аңа профессор исеме бирелә.

Докторлык диссертациясен яклаганнан соң ул берничә ел Казан дәүләт университетында укыта, ә аннары Алабуга дәүләт педагогика институтына күчә, башта укытучы, ә аннары доцент вазифасын үти,тарих һәм лингвистика кафедрасын җитәкли. Гомеренең соңгы елларында Хәлил Хәлим улы Алабуга дәүләт педагогика институтының татар телләре факультеты профессоры була.

Кафедра мөдире буларак, ул татар филологиясе кафедрасын үстерүгә һәм популярлаштыруга зур өлеш керткән. Сәлимов югары уку йорты студентлары өчен уку программалары һәм дәреслекләр әзерләүгә игътибар бирә. Филология факультетының уку планына яңа дисциплиналар кертелә, һәм, булачак профессор фикеренчә, югары белем бирүэчтәлегекүпкә яхшыра.

Хәлил Хәлим улы бөтен гомерен татар тел белемен, татар халкының мәдәниятен һәм халык мәгарифен үстерүгә багышлый. Татар һәм төрки тел белеме өлкәсендә фәнни һәм педагогик кадрлар әзерләүдә аның хезмәтләре зур роль уйный. Ул еш кына докторлык диссертацияселәре яклауда рәсми оппонент буларак чыгыш ясый.

Профессор Сәлимов мәктәпләрдә туган телне укыту проблемалары белән биккызыксына. Ул теоретик лингвистик тикшеренүләрне университетта гына түгел, ә мәктәптә укыту процессында куллануны хуплый. Хәлил Хәлим улы туган телне өйрәнү процессында укучыларның тирән фикерләү һәм үзләренең ничек фикер йөртүләрен аңлау сәләте үсеш ала дип ышанган. Бу − туган телнең бәхәссез гомуми белем бирү миссиясе. Шулай итеп, туган тел бүген дә белем һәм үсеш процессында мөһим тема булып кала.

Сәлимов үзенең фәнни хезмәтен укытучы эшчәнлеге белән уңышлы гына бергә алып бара. Аның татар тел белеме һәм төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы буенча лекцияләре лингвистларны әзерләү өчен зур әһәмияткә ия була.

Х.Х.Сәлимов татар теле академик грамматикасының берничә бүлеге авторы булып тора (“Фонетика”, “Фонология” һәм “Просодия”). [Татар грамматикасы] Татар фонетикасы XX гасырның 20 елларында У.Байчура, Г.Шараф, В.Богородицкий кебек танылган галимнәр киткәч, бик тиз үсеш ала, ләкин, тулысынчадиярлек,онытыла. 30-70нче елларда бу өлкәдә җитди хезмәтләр басылмый. Х.Х.Сәлимовның казанышы татар тел белемендә бу фәнне торгызу була. Ул үзе артыннан татар фонетикасы, фонологиясе, просодиясе, саннары һәм орфографиясе буенча мәкаләләр һәм монографияләр калдырган.

Профессор Х.Х.Сәлимов – беренче булып татар теленең орфографик сүзлеген төзүче авторларның берсе, сүзлек республиканың берничә шәһәрендә, шул исәптән Казанда да басылып чыга. 2000нче еллар башында татар теле буенча беренче тестлар җыентыгы (“222 тест”) басылып чыга. Сәлимовның татар орфографиясе буенча хезмәтләре татар тел белемендә аерым урын алып тора. Бу хезмәтләрне студентлар да, укытучылар да татар теле дәресләре вакытында, шулай ук курс эшләре һәм чыгарылыш квалификация эшләре язганда актив кулланалар.

Моннан тыш, күп еллар дәвамында Сәлимов лексикология, лексикография, тел теориясе һәм сәнгатьле уку буенча курслар алып бара. Ул студентларына фәнни белемнәр генә биреп калмый, фикерләү культурасын да тәрбияли.

Хәлил Хәлим улы Сәлимов, талантлы галим һәм педагог, үзенчәлекле фикерләүгә ия, ул татар филология фәнен үстерүгә зур һәм мөһимөлеш керткән шәхес буларак билгеле.

Әдәбият


1. Сәлимов Х.Х.Latin əlifbası: яңа кагыйдәләр, яңа таләпләр, яңа бурычлар // Мәгърифәт, № 43.
2. Сәлимов Х.Х.Latin əlifbası // Мәгърифәт, № 44; Латинча ничек язарбыз.// Татарстан. – 2000. – №1.
3. Салимов Х.Х. Фонетика. Фонология. Просодика/Татарская грамматика. Т. I (руковод. проекта М.З. Закиев). – Казань, 1993. 1995, репринт первого издания 1993 г. Вт. изд. Казань: ТӘhСИ, 2015 г. – 512 с.
4. Сәлимов Х.Х Latin əlifbası: яңа кагыйдәләр, яңа таләпләр, яңа бурычлар // Мәгърифәт, № 43; Latin əlifbası // Мәгърифәт, № 44; Латинча ничек язарбыз.// Татарстан. – 2000. – №1.


## ТОЛЕРАНТЛЫК СЫЙФАТЛАРЫ БУЛДЫРУДА, ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ


Сөнгатуллина Л.
Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты
Фәнни җитәкче: Шаһиева Д.Г.


Татар халкының иге-чиге булмаган әдәбият дәрьясы, шигърияте, нәфис тә, камил дә булган туган телебез, халкыбызның матур гореф-гадәтләре, күңел җәүһәрләре, тәрбия йолалары бар. “Татар балалар әдәбияты” дәресләрендә туган телебезгә ихтирам һәм аны үстерүгә, саклап калуга өйрәнәбез.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен һәркем яратып укый, аңа ышана, йөрәкләре аша уздыра, хис-тойгылар аша кабул итә. Без кечкенәдән үк экиятләр тыңларга, укырга яратабыз, мәзәкләрне җылы итеп кабул итәбез, мәкальләр һәм табышмаклар белән эш итәргә өйрәнәбез; бер-беребезгә табышмаклар әйтешеп уйныйбыз һәм үз арабызда җиңүчеләрне билгелибез. Халык авыз иҗаты әсәрләре һәрберсе нинди дә булса тәрбияви әһәмияткә ия. Мәсәлән, толерантлык сыйфатлары тәрбияләүдә, тел дәресләрендә яки дәрестән тыш чараларда халык иҗаты әсәрләреннән файдалану әһәмиятле урын алып тора. Толерантлык – ул кешеләргә карата түземле, кешелекле, шәфкатьле булу; башка милләт халыклары белән дус, тату яшәү.

Элек-электән татарлар башка халыклар белән аралашып яшәгәннәр, төрле мөнәсәбәтләр корганнар. Бу – алар арасында дуслык, татулык, бердәмлек сыйфатлары тудырган. Бүгенге көндә дә төрле милләт укучылары бер

коллектив булып укыйлар. Безнең Арча педагогия көллиятендә дә җиде төрле милләт вәкиле белем ала. Без бер-беребез белән дус, тату яшәргә һәм аралашырга тырышабыз. Моның өчен көллияттә бер-беребезгә карата ачык, толерант булу, хөрмәт белән карау кебек сыйфатларны булдырырга һәм тәрбияләргә тиешбез. Үз халкың мәдәниятен белмичә, икенче милләт халкы мәдәниятен өйрәнү җиңел түгел, киресенчә, туган халкыңның мәдәниятен белү, икенче халык мәдәниятен тирәнрәк үзләштерергә ярдәм итә. Шуңа күрә көллияттә бер-беребез белән аралашканда, иң беренче чиратта, безнең өчен якын һәм кадерле булган гореф-гадәтләребез, бәйрәм-йолаларыбыз белән бәйләп, аларны башка халыклар мәдәнияте белән чагыштыру - мәдәниятләр арасында бәйләнеш тудыруга, үзеңнең традицияләреңне һәм кыйммәтләр системасын саклап калып, башка телдә сөйләшүче күршеңнең мәдәниятенә карата толерант мөнәсәбәт булдыруга ярдәм итә.

Безнең халыкта бик мәртәбәле бер әйтем бар: бердәмлектә – көч. Әйе, бердәм булсак, бер-беребезгә авыр чакта ярдәм кулы сузсак, җәмгыятебездәге вакыйгаларга битарафлык күрсәтмәсәк, төрле милләт халкына, аларның гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карасак, шул чагында без – көчле халык.

Толерантлык сыйфатларын формалаштыруга һәм үстерүгә ярдәм иткән халык авыз иҗаты әсәрләреннән берсе – мәкальләр. Аларда тормыш тәҗрибәсе, дөньяга карашы, тирән акылы, әхлак нормалары чагылыш таба. Тапкыр, телгә бай кешеләр сөйләм барышында мәкальләрдән оста файдалана беләләр. Мәкальне тыңлаганда да мәгънәсен ашыкмыйча, төрле яктан уйлап, нинди очракта әйтелгәнен чамалап хәтергә алырга, аннан соң урынлы гына сүзгә кыстыра белергә кирәк. Мәкаль ямь һәм куәт бирә. Ямь ул, димәк, сүзне матурлау алымы була, куәт булгач, анда кешене сүзгә ышандырырлык көч тә була. Мәсәлән, дуслык турындагы мәкальләрне сайлап, бер-беребезгә карата дуслык җепләрен тагын да ныгытырга мөмкин.

Табышмаклар да укучыларга өстәмә мәгълүмат бирә, тормышны танып-белергә өйрәтә, игътибарлылык, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияли, тел байлыгын, фикерләү дәрәҗәсен арттыра. Белем һәм тәрбия бирү, телне үстерүдә, толерантлык сыйфатлары тәрбияләүдә табышмаклар әйтешү уңышлы. Бу - иҗади активлыкны күтәрә, фикер үткенлегенә, сүзләрне урынлы файдалану осталыгына карата соклану тәрбияли.

Халык авыз иҗатыннан әкиятләрне аеруча яратып укыйбыз. Аның сәбәбе – әкиятләр оста иҗат ителгән, формасы эчәлегенә туры килгән булуында һәм табигатенең балалар табигатенә якын торуында. Толерантлык сыйфатларын үстерүне истә тотып, төрле халык әкиятләрен сәхнәләштереп күрсәтү отышлы була. Без моны "Татар балалар әдәбияты" дәресләрендә еш кулланабыз.

Толерантлыкны тәрбияләүдә җырларның да әһәмияте зур. Халкыбыз җырлары – күп төрле бизәкләрдән торган моңлы, аһәңле үзе бер дөнья. Җырларда дуслык, матурлык, туганлык, халыкның кунакчыллыгы, татулык, бердәмлек, эчке хисләр, тойгылар һ.б. чагыла.Туган якның халык талантлары белән таныштыру, эстетик тәрбия бирү максатыннан чыгып, безнең көллияттә "Халык җырларын иң оста башкаручы", "Җыр – кешенең юлдашы" кебек әдәби-музыкаль кичәләр, "Татар халык җырлары" фестивале үткәрелеп килә.

Бәйрәм программасы өчен җырлар сайлаган вакытта җырның эчтәлегенә һәм музыкаль-сәнгатьчә бизәлешенә дә игътибар ителә.

Халык авыз иҗатын өйрәнгәндә, бәет һәм мөнәҗәтләрнең дә әһәмиятле урын алып торуын әйтеп китәргә була. Чөнки бу әсәрләр татар халык иҗатына гына хас милли жанр булып торалар. Яшь буынга белем һәм толерантлык сыйфатларын тәрбияләүдә, бу әсәрләрнең мөмкинлекләре бик зур. Бәетләрне халыктан язып алу – безне башка кешеләр белән аралаша алырга, бер-беребезсе белән якынайтырга ярдәм итә.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен дәрестән тыш чараларда дөрес кулланып, толерантлык сыйфатлары тәрбияли белү зур тырышлык, осталык таләп итә. Шуңа күрә көллиятебездә дәрестән тыш эшләр: атналыклар, язучылар белән очрашулар, иҗат түгәрәкләре, газеталар чыгару, китап укучылар конференцияләре үткәрү, халык авыз иҗаты буенча төрле кичәләр, диспутлар, викториналар үткәрү игътибар үзәгенә куелган һәм даими башкарылып тора. Бу күпмедер күләмдә толерантлык сыйфатларын үстерә, кызыксыну уята. Шулай ук хәзерге заман таләпләреннән чыгып, мәдәни культура формалаштыруны үстерү өчен, республикакүләм фәнни-гамәли конференцияләр уздыру, төрле проектлар яклау юнәлешендә эш алып барырга мөмкин. Мәсәлән, “Толерантлык тәрбияләүдә мәктәпнең гаилә белән эшчәнлеге”, “Татар мәктәбе – милләткә куәт бирүче учак ул”, “ Башка милләт халыкларын да хөрмәтли бел!” кебек темаларны тәкъдим итәргә була. Без милләтебез белән горурланырга, телебезгә, тарихыбызга, халкыбызга ихтирам белән карауч шәхесләр булыга тырышабыз. Көллиятебездә үткәрелгән милли чаралар тирә-якны танырга, матурлыкны күрергә, тормышны тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр. Безне иҗади эшләргә, әдәпле, кешелекле, тәртипле, миһербанлы, ярдәмчел, киң күңелле булырга өйрәтә.

Әдәбият:

1. Хәбибуллина З.Н., Фәрдиева Х.Г. 5-11 нче сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр.-Казан: 2000.-243 б.

2.Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Класстан тыш һәм мәктәптән тыш тәрбия эшләре/ Ә.Н.Хуҗиәхмәтов.-Казан: Матбугат йорты, 2001.-640 б.

3. Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасы: теория һәм практика/ М.М.Шәкүрова, А.Ф.Йосыпов. Казан дәүләт ун-ты, Татар филол.һәм тарихы фак-ты.- Казан дәүләт университеты, 2009.-165 б.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУНЫҢ ПРОБЛЕМАЛЫ АСПЕКТЛАРЫ

Тазова Р.Р.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.

Озак вакыт татар телендә белем бирүче гомуми белем бирү учреждениеләрендә татар әдәбиятын укытуда җитди проблемаларның берсе булып теоретик материалга җитәрлек игътибар бирелмәве тора. Билгеле

булганча, мәктәп курсында әдәби-теоретик белем һәм әдәби уку бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән. Мәктәп курсында иң катлаулысы-теоретик төшенчәләрне һәм терминнарны аңлау һәм үзләштерү. Моның өчен дәреслекләрдә формасы буенча кыска теоретик материал кирәк. Укучы теге яки бу теоретик төшенчәнең билгеләмәсен өйрәнергә генә түгел, ә үзендә, укытучысыз, яңа белемнәр һәм күнекмәләр алу, әдәби текстны, аерым язучыларның иҗатын һәрьяклап анализлау, образларга характеристика бирү, вакыйгаларны бәяләү, әдәби процессның үзенчәлеген билгеләү сәләтен үстерергә тиеш. Шулай итеп, татар әдәбияты дәресләрендә өйрәнелә торган аерым теоретик әдәби төшенчәләр нәфис әсәрнең эчке структурасын анализлау белән бәйле булырга тиеш. Бу, үз чиратында, укучыларның логик һәм иҗади фикерләүләрен үстерүгә, аларның күзаллауларын киңәйтүгә, милли-сәнгать традицияләре турында күзаллауларны баетуга ярдәм итә.

Нәкъ менә шундый принцип буенча Д. Ф.Заһидуллина, Н. М. Йосыпова, Ф. Ф. Хәсәнованың үрнәк эш программасы төзелгән. Бу программаның үзенчәлеге шунда ки, ул теоретик базага юнәлдерелә. Мәсәлән, 5 нче сыйныфта укучыларда фольклор һәм әдәбиятының жанр табигате турында күзаллаулар формалаштыру күздә тотыла. Шуңа бәйле рәвештә, халык авыз иҗаты үрнәкләрен жанр үзенчәлеге күзлегеннән өйрәнү күздә тотыла. 6 нчы сыйныф материалы образ системасы тирәсендә тупланган. Укучылар ел дәвамында тәкъдим ителгән әсәрләр контекстында образның үзенчәлеген, образларның төрләрен, эпик, лирик, драма әсәрләрендәге образларның үзенчәлекләрен өйрәнәләр, геройларның характеристика серләрен аңлыйлар. 7 нче сыйныфта әдәби төрләр һәм жанрлар төп тема булып тора, беренче планга нәфис текстлар мисалында татар әдәбиятының жанр парадигмасы үзенчәлекләрен өйрәнү чыга. 8 нче сыйныф материалы стиль төшенчәсе тирәсендә тупланган. Укучылар язучы стиле, чор стиле төшенчәләрен әдәби текстлар һәм аерым авторларның иҗаты контекстында өйрәнәләр, шуның аша аларда татар әдәбиятының гомуми үзенчәлекләре һәм татар сүз сәнгатенең милли стиле үзенчәлекләре турында күзаллау формалаша [Заһидуллина 2017: 41-59].

Д. М. Абдуллина һәм Г. Н.Мөхәрләмованың үрнәк эш программасы шундый ук принцип буенча төзелгән. Аларның программасының төп эчтәлекле линияләре булып 5-7 нче сыйныфларда тәкъдим ителгән “халык авыз иҗаты”, “татар әдәбияты”, “әдәбият теориясе” тора. 5 нче сыйныфта фольклор, аның жанрлары, шулай ук әдәби жанрлар турында алдан мәгълүмат бирелә. 6 нчы сыйныф материалы образ төшенчәсе тирәсендә туплана: лирик әсәрдә образны булдыру алымнары, фантастика әсәрләренең образлы системасы, аллегорик образлылык, автобиографик һәм биографик әсәрләрдә образ системасының үзенчәлекләре, хикәя һәм повесть жанрында образлылык, Лиро-эпик һәм драматик әсәрләрдә образлы система. 7 нче сыйныф материалы тулысынча татар әдәбиятындагы төрләр һәм жанрлар тирәсендә тупланган [Абдуллина 2022: 7-8].

Татар әдәбиятын өйрәнгәндә укучылар сәнгать әсәрен үзләре анализларга өйрәнәләр, аларда әдәби әсәрне аның эчтәлеге һәм сәнгать формасы бердәмлегендә кабул итү формалаша, нәтиҗәдә чагыштыру, гомумиләштерү,

сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү, мөстәкыйль сораулар бирү, үз фикерләрен дөрес җиткерү күнекмәләре камилләштерелә.

Мәктәптә татар әдәбиятын укыту алгоритмына кагылышлы икенче төп проблема сүз сәнгате тарихын өйрәнү белән бәйле. Әдәби әсәрләрне, халык авыз иҗаты үрнәкләрен, әдәби иҗатны үзләштерү аша 5-8 нче сыйныфларда әдәбият тарихын өйрәнүгә, ягъни сүз сәнгатен сәнгать үсеше буларак кабул итүгә күчү гамәлгә ашырыла. Д. Ф.Заһидуллина, Н. М. Йосыпова, Ф. Ф. Хәсәнованың үрнәк эш программасы буенча татар әдәбияты тарихы 9-11 нче сыйныфларда өйрәнелә. Мәктәп әдәби белем бирүенең концентрик структурасына күчү һәр этапның тәмамлануын күздә тота. Шуңа күрә 9 нчы сыйныфта татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре фонында сүз сәнгате тарихына экскурсия үткәрелә, аның максаты–укучыларда аның үсешенең төп тенденцияләре турында гомуми күзаллау формалаштыру [Заһидуллина, 2017: 43-54].

Әлеге программада 10-11 нче сыйныфлар өчен татар әдәбияты курсы хронологик принцип буенча төзелгән һәм милли сүз сәнгатенең тарихи үсешен системалы күзаллауны булдыруга, “борынгы заманнардан бүгенге көнгә кадәр милли әдәбиятның үсеш юллары турында тулы һәм системалы күзаллауны формалаштыруга” юнәлдерелгән [Бадриева 2017: 20].Шуңа бәйле рәвештә югары сыйныфларда татар әдәбиятын хронологик үсештә үзләштерү, аерым авторларның иҗатын һәм аларның әсәрләрен әдәби-эстетик процесс һәм чорның тарихи-мәдәни тормышы контекстында, әдәби чорларның үсеш системасында өйрәнү актуальләштерелә. Шуңа күрә мондый контекстта укучылар теге яки бу классикның иҗатының эстетик кыйммәтен билгеләргә, теге яки бу чорның әдәби процессының үзенчәлеген ачыкларга, татар классикларының әсәрләрен Ватан һәм дөнья әдәбияты контекстында бәяләргә, үз карашларын оппонентларның фикерен исәпкә алып расларга һәм исбатларга, рефератлар, докладлар әзерләргә, аерым темалар буенча әсәрләр язарга, шулай итеп үз укучыларын камилләштерергә тиеш әдәбият белеме анализының кабул итү, күнекмәләре һәм күнекмәләре. Шуның нигезендә, 10 нчы сыйныф материалы урта гасырлардан алып XX нче гасыр уртасына кадәр татар әдәбияты тарихы тирәсендә туплана, ә 11 нче сыйныфта XX нче гасырның икенче яртысында – XXI нче гасыр башында татар әдәбияты тарихын өйрәнү күздә тотыла.

Г. Н.Мөхәрләмова, Д. М. Абдуллина төзегән үрнәк эш программасында 10-11 нче сыйныф материаллары хронологик принциптан читкә китә һәм концентрик принципка юнәлдерелә. Мәсәлән, “кеше югары кыйммәт буларак”, “кеше һәм гаилә”, “кеше һәм милли характер”, “кеше һәм җәмгыять”, “кеше һәм тарих”, “кеше һәм табигать” кебек тематик блоклар тәкъдим ителә [Абдуллина 2021: 12]. Әлбәттә, бу юл татар әдәбиятын укытуны һәм укучыларның әдәби материалны үзләштерүен шактый җиңеләйтә, әмма сораулар тудыра: укучыларда татар әдәбияты тарихына һәрьяклап карау булырмы, алар аның байлыгын, үсеш үзенчәлеген күз алдына китерә алырлармы? Шул ук вакытта монда үз өстенлекләре дә бар, бу мәктәп курсында татар әдәбиятын өйрәнүгә мотивациянең үсүенә китерергә мөмкин, чөнки

хәзерге вакытта укучылар арасында татар әдәбиятын укуга мотивациянең һәм кызыксынуның кимүе күзәтелә, бу, бер яктан, укучыларның көндәлек тормышта әдәби белем бирүнең әһәмиятен аңламаулары, икенче яктан, белем бирү программасының катлаулылыгы белән бәйле. Шулай итеп, 10-11 нче сыйныфларда татар әдәбиятын концентрик өйрәнү уку материалын җиңеләйтергә мөмкинлек бирә һәм XX– XXI нче гасыр әдәбияты белән бәйле материалны арттырырга мөмкинлек бирә.

Әдәбият

1. Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. Төп гомуми белем бирүнең 5-9 сыйныфлары өчен “Туган (татар) әдәбияты” фәненеңтуган (татар) телендә укыту гомуми белем бирү оешмалары өчен үрнәк эш программасы. – Казан, 2020. – 83 б.

2. Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. Урта гомуми белем бирүнең 10-11 сыйныфлары өчен “Туган (татар) әдәбияты” фәненең үрнәк белем бирү программасы. – Казан, 2021. – 93 б.

3. Бадриева Р.Р. Татар телен һәм татар әдәбиятын укыту концепциясе, 2017. – 23 б.

4.Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М., Хәсәнова Ф.Ф.Татар телендә укыту гомуми белем бирү оешмалары өчен “Татар әдәбияты” фәненең үрнәк эш программасы. – Казан, 2017. – 100 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫНДА АЛЫНМАЛАРНЫҢ РОЛЕ

Талыпова Л.Н.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина

Дөньядагы һәрбер телнең сүзлек составы – зур тарихи үсеш нәтиҗәсе. Халык, милләт тарихы үсә барган саен, теленең тарихы да киңәя. Иҗтимагый үзгәрешләр – тарихи вакыйгалар, аралашу даирәсе киңәю һәм башкалар – тел үсешенә дә йогынты ясыйлар.

Мәгълүм булганча, тел дигән хәзинәнең берничә төрле баю ысулы бар. Иң киң таралганы – телнең үз хәзинәсендәге сүзләрнең тамырларына төрле кушымчалар ялгау. Бу ысул белән тел байлыгының иң зур өлеше ясала. Мисал өчен “матур” дигән гүзәллекне, күркәмлекне белдерүче сыйфатка –лык кушымчасы өстәп, абстракт төшенчәгә ия булган сүз – матурлык сүзен ясыйбыз. “Бер” дигән санга –дәм кушымчасы өстәсәк, тату, дус дигән мәгънәгә якын торган бердәм сыйфаты барлыкка килә, үз чиратында –лек кушымчасы әлегә сыйфатларга ия булуны белдерүче исем ясый.

Билгеле булганча, телнең яшәеш-үсеше экономия принцибына нигезләнгән. Иске сүзләргә яңа мәгънә өстәп лексиканы баету ысулы шушы принципка тугрылыклы рәвештә эшли. Халкыбыз тарихында кайбер сүзләр, конкрет төшенчәләр юкка чыгу сәбәпле, әйләнештән төшеп калганнар. Мәсәлән, ханнар, вәзирләр, тарханнар, урядниклар кебек администрация,

хакимият башлыклары безнең республикада инде күптәннән юк. Димәк, әлеге сүзләрнең телдә кирәге дә калмый. Әмма хаклык өчен әйтергә кирәк, халык әкиятләрендә, фразеологик әйтелмәләрдә, мәкаль-әйтемнәрдә, тарихи хезмәтләрдә бу сүзләр очрарга мөмкин. Кайбер очракларда исә, ниндидер төшенчә юкка чыкса да, аны атаган сүз хәзер икенче бер төшенчә, икенче мәгънә белдерә башлый. Хәзерге вакытта, мәсәлән, шәкерт дигәндә без мәктәп яки вуз укучысын күзаллыйбыз. Элеккерәк чорларда исә шәкерт дип муллада укыган баланы атаганнар.

Лексикабызны баюның чираттагы ысулы – яңа сүз уйлап табу. Гадәттә неологизмнар, тарихи үсеш нәтиҗәсе буларак, яңа төшенчәләр, яңа күренешләр, яңа һөнәрләр һ.б.ларны атау өчен барлыкка киләләр, еллар узу белән яки сөйләмнән төшеп калалар, яки киресенчә, нормага кереп, неологизм булудан туктыйлар. Кайчандыр “глобаль”, “оптималь”, “слайд”, “инвестор”, “бизнес” кебек сүзләр неологизм саналсалар, хәзер аларны башкалар алыштыралар: лизинг, каршинг, бренд, картридж, дубликат, инновация, интеграция һ.б.лар.

Телебез составында яшәүче сүзләрнең бер төркеме исә башка телләрдән алынган, берникадәр үзгәрешләр кертелеп яисә бернинди үзгәрешсез алар татар кешесенең норматив сүзлек составында яшәп киләләр.

Безнең милләт вәкилләре татар әдәби телендә аралаша. Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы чорларга – төрки халыкларның барсы өчен дә уртак булган төрки телгә барып тоташа. Бу телдәге сүзләрнең күпчелеге җәмгыятьтә, кешенең тормыш-көнкүрешендә иң әһәмиятле төшенчәләрне белдереп киләләр. “Алар телнең төп сүзлек фондын тәшкил иткәннәр, шул нигездә телнең сүзлек составы үсә, үзгәрә, камилләшә барган” [Сафиуллина, Зәкиев, 2002: 62], дип язалар гомумтөрки сүзләрнең роле хакында Ф.С.Сафиуллина, М.З. Зәкиев.

Бер генә халык та изоляцияләнгән хәлдә яши, үсә алмый. Борынгырак чорда кабиләләр, аннан соң илләр, дәүләтләр бер-берсе белән тыгыз аралашып яшиләр. Шуның нәтиҗәсендә татар теленә дә башка телләрдән алынмалар килеп керә. Алынмалар дигәндә, “халыкларның аралашуы нәтиҗәсендә бер телдән икенчесенә күчкән башка тел элементлары (сүз, морфема, синтаксик конструкция), шул исәптән бер тел элементларының икенчесенә күчү процессы”н аңлыйлар [Галиуллина, 2007: 55]. Телнең сүзлек составына чит тел элементлары, берәмлекләре килеп керүен Р.Юсупов түбәндәгечә аңлата: “Туган телнең теге яки бу төшенчәне белдерерлек үз сүзе булганда, чит телдән сүз алынмый. Төшенчәне тәгъбир итәрлек сүз табылмаганда гына, туган телнең үз җирлегендә төрле юллар белән яңа сүз ясала. Яңа сүз ясалу мөмкинлеге булмаганда, икенче тел сүзе кабул ителә” [Юсупов, 2003: 8]. Бер халыктан матди байлык элементлары алышканда аерым сүзләр керсә, икенче халыктан сәясәткә, дингә, сәүдәгә, тормыш-көнкүрешнең башка өлкәләренә караган алынма сүзләр керәләр. Татар әдәби теленә Көнчыгыш халыклары белән төрлечә тарихи бәйләнешкә керү, аралашу җирлегендә һинд, кытай телләреннән кергән сүзләр дип галимнәр түбәндәгеләрне атыйлар: алма, әрдәнә, җиз, сан, тәңре, энҗе, хан, чәй, дәү, дию һ.б.лар. Монгол теленә түбәндәге сүзләр нисбәт

ителә: чаган, нарат, нокта, дилбегә һ.б.лар. Фин-угор телләреннән кергән алынмаларның саны да шактый: миләш, ылыс, поши, камбала һ.б.лар.

Барлык алынма сүзләрдән гарәп-фарсы алынмалары күләмнәре һәм кулланылыш дәрәҗәләре буенча аерылып торалар. Алар бүгенге көндә дә телебезнең сүзлек составының аерылмас өлешен тәшкил итәләр, ә инде XX йөз башына кадәр аеруча да актив кулланылышта йөргәннәр.

Актив кулланылышта булган алынмаларның тагын бер зур төркеме – рус теленнән һәм рус теле аркылы башка телләрдән кергән алынмалар. Аларның зур өлешен нигездә рус теле аша кергән латин, грек, француз, испан, итальян алынмалары, кайбер голланд сүзләре, инглиз теленнән кергән сүзләр, алман теле алынмалары телебез составында берегеп калып, актив сүзлек составын тәшкил итәләр. XX гасырның соңгы ике дистә елында рус теленнән һәм аның аша Европа телләреннән алынган алынмалар саны бермә бер арта бара һәм тормыш-көнкүрешнең барлык өлкәләрен иңли. Бу процесс фәндә дә махсус рәвештә өйрәнелә башлый. Мәсәлән, 1999 нчы елда гына шушы темага кагылышлы ике кандидатлык диссертациясе яклана.

Шунысы игътибарга лаек: рус теле аша телебезгә кергән алынмаларның күбесе, аеруча XX йөзнең ахыргы ике дистәсендә һәм аннан соңгы елларда кабул ителгән сүзләр күп халыкларның уртак лексик фондын барлыкка китерә. Ф.С.Сафиуллина искәртеп киткәнчә, уртак лексик фондка кергән сүзләр милли телләрнең фонетик, аерым очракларда морфологик “кием”нәрен кияләр. Мәсәлән, әзербайҗан телендә телевидение – телевизиіа, экскурсия – экскурсиіа, космическая станция – космик стансиіа, комсомолец – комсмолчу, факультет – факүлтә, фабрика – фабрик; татар телендә газета – гәҗит (газет, гәзит), квартира – квартир (фатир), секунда – секунд, минута – минут, фанатичный – фанатик, гуманистический – гуманистик, аграрный – аграр булып йөри [Сафиуллина, 1999: 73].

Аерым очракларда телдә рус алынмасына параллель рәвештә аның татарча эквиваленты да кулланылышта йөри. Мәсәлән, герб – герб, тугра; аргумент – аргумент, дәлил; арена – арена, мәйдан; трибуна – трибуна, мөнбәр; указ – указ, фәрман; автономия – автономия, мөхтәрият; дебаты – дебатлар, фикер алышулар, бәхәсләр һ.б.лар. Гадәттә бу очракларда татар сүзе яки әдәби сүз буларак урнашып бетмәгән була, яки ул рус вариантыннан мәгънә төсмере белән аерыла.

Алынма сүзләргә мөнәсәбәт төрле яклы булуын да искәртеп үтәргә кирәк. Кайбер телләрнең, мәсәлән, белорус, украин, казахларның интернациональ сүзләрдән ваз кичеп, аларны үз лексикасына якынрак сүзләр белән алыштырырга омтылып караулары билгеле. Әмма бу һәрвакытта да уңышка китермәде.

Интернациональ сүзләрдән баш тартып, татарча сүзләр ясап карау татар телендә дә булды. Мәсәлән, симптом урынына авыру билгеләре, диагноз урынына авыруның төрен билгеләү, отпор урынына типке, физик (физический) урынына тәнви һ.б.лар тәкъдим ителделәр, әмма халык тарафыннан алар кабул ителмәде.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып, шундый фикергә киләбез: алынма сүзне куллану-кулланмау мәсьәләсе һәр очракта конкрет хәл ителергә тиеш. Татар телендә эквиалент сүз булмаса, калькалаштыру ысулы белән файдалану мөмкинлеге дә булмаса гына аерым телдән әзер сүз кулланылышка кертелергә тиеш.


Әдәбият

1. Галиуллина Г.Р. Татар теле лексикологиясе: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә. Югары сыйныф укучылары һәм студентлар өчен. – Казан: Мәгариф, 2007. – 95 б.
2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.
3. Сафиуллина Ф. С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б.
4. Юсупов Р. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 222 с.


## КҮПТЕЛЛЕ БЕЛЕМ БИРҮ ШАРТЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ


Тимофеева Т.В., “Адымнар-Алабуга”
күптелле белем бирү комплексының
туган тел һәм әдәбияты укытучысы,
Алабуга институты магистранты
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.


Рәсәй – бай тел мирасы булган зур ил. Аның территориясендә рус, татар, чуаш, удмурт, башкорт һәм башка күп кенә милләт вәкилләре яши. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган, татар халкының милли теле булган татар теле таралышы буенча Россиядә икенче урынны алып тора [4].

Тел ул – бербөтен халыкның гомуми җанына сеңеп калган, аның гореф-гадәтләрендә, йолаларында, бәйрәмнәрендә сакланган, буыннан-буынга тарих чылбыры булып үрелеп барган кадерле мирас. Бүгенге көндә татар теленең киләчәге куркыныч астында, чөнки туган телдә сөйләшүче балалар саны көннән-көн кими. “Теле барның – иле бар”, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Тел бетә икән, милләт тә яшәүдән туктый, дигән сүз.

Телебезне саклауда ата-аналарның гына түгел, туган тел укытучыларының да өлеше зурдан. Татар әдәбиятында ата-бабаларыбызның тарихы, милләт язмышы чагыла, ә татар телендә халыкның матур сөйләме һәм эчке дөньясы саклана. Гомергә милләт анасы булып саналган татар хатын-кызлары тудырып үстергән мәшһүр татар әдипләребезнең гасырлар аша чынбарлыкны, тормышны, күзаллап язып калдырган әсәрләре әле бүген дә актуальлеген югалтмыйлар. Укучылар шул әсәрләр аша татар халкының үткән бөек тарихы белән танышалар, татар теле дәресләрендә сөйләмнәрен камилләштерәләр, татар теленең үзенчәлекләрен үзләштерәләр. Димәк, бүгенге

көндә укытучылар алдында зур бурыч тора – телне киләчәк буынга сеңдереп, аны телле милләт итү.

Бүгенге көндә күптелле белем бирү дөнья һәм Рәсәй мәгариф киңлеген үстерүнең әйдәп баручы юнәлешләренең берсе дип игълан ителгән. Поливәдәни белем бирүнең күптелле моделен эшләү, беренче чиратта, Рәсәй Федерациясе субъектларында туган телләрне саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән. Ул тар этномәдәни проблемаларны хәл итү күзлегеннән генә түгел, ә күпмилләтле Рәсәй дәүләтенең табигый поливәдәни нигезен саклау контекстында да мөһим бурычларның берсе булып кала [Ялалов 2020: 62].

Бүген белем бирү процессының үзәгендә актив һәм үз-үзен оештыра алучы, кирәкле мәгълүматны үзлегеннән эзләп таба һәм анализлый, аны киләчәк тормышта куллана белүче укучы тора, ә укытучы уку мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итәргә ярдәм итүче тьютор ролен башкара [Бойцова 2014: 171]. Шуңа күрә белем бирү процессын укучы дәрестә актив булырлык, кызыксынып һәм мавыгып шөгыльләнә, үз-үзен бәяли алырлык итеп оештыру бик мөһим. Шуңа бәйле рәвештә, заманча мәктәп алдына укучыларның күпкырлы белем алуы өчен шартлар тудыру, тиз үзгәрүче дөньяда ориентлаша белгән, конкурентлыкка сәләтле булган шәхес тәрбияләү бурычы куела. Нәкъ менә шундый максат белән “Яңарыш” Республика фонды Рәсәй Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә рус, татар һәм инглиз телләрендә белем бирүне тәэмин итүче заманча мәктәп моделе булган “Адымнар” күптелле белем бирү комплексы проектын гамәлгә ашыра башлады [Шаймиев 2021: 1].

Күптелле алты комплекстан торган кластер 2020-2022 елларда этаплап формалашты [Ялалов 2020: 62-63]. “Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл” дип аталган беренче полилингваль комплекс 2020 елның 1 нче сентябрендә Казанда инглиз телен тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерелгән 165 нче урта мәктәп базасында үз ишекләрен ачты. Казанда икенче күптелле комплекс 2021 елда “Казан – XXI гасыр” торак комплексында урнашкан 178 нче лицей базасында урын алды. “Адымнар-Алабуга” күптелле белем бирү комплексы 2021 елда Алабугада 10 нчы мәктәп базасында ачылды. Дүренче комплекс Яр Чаллыда 2022 елда эшли башлады. 2022 елда Түбән Каманың 32 нче гимназиясе базасында бишенче күптелле комплекс үз ишекләрен ачты. Татарстанда “Адымнар” күптелле белем бирү комплекслары арасында алтынчысы – 2022 елның 1 нче сентябреннән эшли башлаган “Адымнар-Әлмәт” комплексы.

Күптелле мәктәп укытучысы, яңа буын вәкилләренең үзенчәлекләрен исәпкә алып, үз эшендә укучыларның мотивациясен арттыру, дәрестә уңай хезмәттәшлек атмосферасы тудыру, кызыксындыру чараларын куллана. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен кызыклы, заманча, мавыктыргыч үткәрүдә, уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләүдә уңышлы файдаланыла торган яңа чаралар – цифрлы технологияләрне куллануга нигезләнгән интерактив кушымталар популяр. Мәсәлән, башлангыч сыйныфларда укучы балалар өчен татар теле дәресләрендә “Сүзләр дөньясында” дигән беренче иллюстрацияләнгән, тавышлы, үстерешле интерактив әсбапны куллану бик отышлы. Күптелле белем бирү комплексында укучы балалар өчен бу бигрәк тә актуаль,

мавыктыргыч һәм файдалы кулланма, чөнки сүзләр татар, рус, инглиз телләрендә бирелгән. Әлеге әсбап биш бүлекне берләштерә тора: "Алфавит", "Темалар", "Этикет", "Уеннар", "Сүзлек". Балалар татар хәрефләре; "Мин", "Минем гаиләм", "Хайваннар", "Һөнәр", "Урамда", "Кибеттә", "Төсләр һәм саннар" һ.б. темаларга караган 500 сүз; танышкан вакытта, гафу үтенгәндә, ризалык белдергәндә, баш тартканда әйтелә торган сүзтезмәләр белән таныша алалар; алган белемнәрен уеннар белән ныгыталар [6].

"Аваз" проекты алфавитны һәм Идел буе халыклары арасында иң күп кулланыла торган сүзләрне уен формасында үзәштерергә ярдәм итә. Күптелле комплексның беренче сыйныф укучылары алфавит өйрәнгән вакытта теге яки бу сүзнең татарча, русча варианты белән генә түгел, мордва, чуаш, удмурт һ.б. телләрдәге тәрҗемәләре белән дә таныша алалар. Әлеге сайтта "Меморина", "Парын тап", "Тасвирлама аша бел" кебек төрле кызыклы уеннар да бар [1].

"Tatarschool.ru" – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча эшләнгән, татар теле дәреслекләренә мультимедия кушымталары урнашкан белем бирү ресурсы. Электрон кушымталар укытучыларга дәресне эш төрләре белән баетырга, укучыларны уку предметы белән кызыксындырырга, мотивацияләрен арттырырга ярдәм итсә, укучыларга исә дистанцион рәвештә үзлекләреннән дәрестә үзләштергән материалны ныгытырга, белемнәрен сынап карарга мөмкинлек бирә. Мультимедиа кушымталары, биремне уңышсыз башкарган очракта, индивидуаль эш темпын сайлап, аны берничә тапкыр эшләп карарга мөмкинлек бирә [5].

Татар теле дәресләрендә уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләүдә LearningApps, Nearpod, Socrative онлайн платформалары ярдәмендә кызыклы уеннар, викториналар һәм сораштырулар төзергә мөмкин. Google Form, Plickers, Quizizz, Quizlet сервислары – кызыклы тестлар, сораштырулар, анкеталар ясаганда укытучының алыштыргысыз ярдәмчеләре. Мондый интерактив кушымталар белән дәреснең актуальләштерү, белем һәм күнекмәләрне ныгыту, рефлексия этаплары чын мавыктыргыч уенга әверелә, укучыларның кәефе, мотивациясе күтәрелә, көндәшлек рухы барлыкка килә [Трегубова 2021: 136].

Әдәби уку дәресләрендә "Бала" интерактив мультимедиа китапханәсе [3], "Татармультфильм" анимацион студиясе [7] төшергән мультфильмнар уңышлы кулланыла ала. Монда татар халык әкиятләре, Г. Тукай шигырьләре, А. Алиш әкиятләре мотивлары буенча ясалган мультфильмнар табарга була. Алар укучыларны дәреснең темасы белән кызыксындырга, дәреслектән укыган әсәрләрне яхшырак истә калдырырга ярдәм итәләр.

Шулай итеп, Татарстанның күптелле белем бирү инициативасы Россия Федерациясенең киләчәген формалаштыруга, тел төрлелеген саклауга, халыклар арасында милләтара татулыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Күптелле комплексларда укучылар башка телләрне генә өйрәнеп калмыйча, үзләренең туган телләрен дә өйрәнәләр, үстерәләр, камилләштерәләр. Балаларны берничә телдә аралашырга өйрәтеп, җәмгыять мәдәни үзара аңлашуга, когнитив үсешне арттыруга һәм инклюзив җәмгыять формалаштыруга ярдәм итә. Безнең бурычыбыз – туган телебезне,

тарихыбызны, гореф-гадәтләребезне балаларга өйрәтеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү.

Әдәбият


1. Аваз. – URL: http://аваз.бала.рф/about (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023).
2. Бойцова Е.Г. Формирующее оценивание образовательных результатов учащихся в современной школе // Человек и образование. – 2014. – № 1 (38). – С. 171-175.
3. Детская мультимедийная библиотека. – URL: http://www.balarf.ru/ipad/index.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023).
4. Татар теле // Википедия, Ирекле энциклопедия. – URL: https://ru.wikipedia.org/wiki/Татарский_язык (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023).
5. Образовательный ресурс TATARSCHOOL.ru. – URL: http://tatarschool.ru (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023).
6. Сүзләр дөньясы. – URL: http://www.balasuzlek.ru/tt (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023).
7. Татармультфильм. – URL: http://tatarmultfilm.ru/cartoons (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023).
8. Трегубова Ю.А. Формирующее оценивание образовательных результатов учащихся в современной школе / Ю.А. Трегубова, М.А. Мосина // Пермский педагогический журнал. – 2021. – №12. – С. 130-138.
9. Шаймиев М.Ш. Полилингвальное образование – требование времени // Актуальная педагогика. – 2021. Спецвыпуск. – С. 1-2.
10. Ялалов Ф.Г. Педагогика полилингвального образования // Научный Татарстан. – 2020. – № 2. – С. 58-71.


## ТУГАН АВЫЛЫМ БИЗӘКЛӘРЕ


Фазлиева З.Р.

Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укучысы.

Фәнни җитәкче: Гыйләҗева А.Ф.


Туган як, туган җир, туган авыл... Сиңа бик якын да, бик кадерле дә бит алар, чөнки монда синең ата-бабаңның нигез туфрагы. Һәрбер кеше туган ягы, туган авылы, тарихы, мәдәнияте турында уйлана, кызыксына.

Безнең Ямаширмә халкы  элек-электән гүзәллек тудырган. Уңган хатын-кызларыбызның бизәп эшләнгән чүәк, читекләре, күңел җылысын биреп чиккән сөлге,  кулъяулык, укалы калфак, түбәтәйләре  күз явын ала. Бүгенге көндә әлеге байлык -  тиңсез хәзинә.

Күп гасырлык тарихны сыйдырган милли киемнәр  -  татар халкының үткәнен бүгенгесе белән тоташтыручы күпер. Алар әби-бабаларыбызның йөзен чагылдыручы асылташлар булып балкый. Халкыбызның үзенчәлекле чигү

төрләрен барлау һәм бүгенге көндә чигүче авылдашларымның кул эшләре белән танышуны мөһим дип саныйм.

Эзләнү – тикшеренү эшенең объекты: Ямаширмә авылының тарихы белән танышу; технология дәресендә, “Оста куллар” түгәрәгендә татар халкының милли киемнәрен, аларны бизәүдә киң файдаланган тамбур, шома чигү, энҗе-мәрҗәннәр кулланып, калфак, түбәтәйләр чигәргә өйрәнәбез. Мин әлеге төр кул эше белән кызыксындым һәм күп кенә сорауларга җавап эзли башладым.

Хезмәтнең максаты: туган авылымның тарихын өйрәнү, татар халкының милли киемнәрен чигү тарихын, төрләрен ачыклау һәм тегү, чигү технологиясен хәтердә яңартып кул эшләремдә куллану.

Минем туган авылым - Ямаширмә. 1552 нче елда Казан ханлыгы яулап алынган вакытларда Казан гына түгел, Казан Арты да сугыш мәйданына әйләнә, татар авыллары җир белән тигезләнә, кырлар таптала. Казанга 40 километрдан якынрак булган татар авыллары җирләреннән куыла. Алар исәбенә Ямаширмә дә кергән. Колониаль сугыш нәтиҗәсендә күп авыллар бушап кала, җәннәт дип аталган Казан Арты Россия империясенең икътисади, социаль һәм милли басымы астында хәерче бер төбәккә әверелә.

Халыкта сакланган риваятьләр буенча, элекке бабаларыбыз Әширмә авылында яшәгәннәр. Авыл тау өстендә булганга, һәр яктан күренеп торган. Аста тирән чокыр булган. Чынлап та, Әширмә атамасына кергән "ширмә" сүзе сулы чокыр, тирән чокыр дигән төшенчәне аңлата. [Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт. -Казан: Тат. кит. нәшр., 1992].

Авылыбызда тырыш, эшчән, уңган, бар эшкә дә булган, алтын куллы кешеләр яши. Игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгән. 1958 нче елда авылда Арча милли аяк киемнәре тегү фабрикасның бер цехы булган әртил ачыла.Монда чүәк, башмак, читек башы һәм балтырлары каеп тегелә. Хатын-кызларыбызның кул эшләре бар халыкның күңелен җәлеп итә..

Авылыбыз тарихы бай, кызыклы, мавыктыргыч. Мин аның белән горурланам. Авылыбыз яшәсен, үссен, яшәрсен!

Минем туган ягым - Ямаширмә. Авылыбызда элек-электән алтын куллы хатын-кызларыбыз читек, чүәк, түбәтәй, калфаклар эшлиләр, күлмәк, камзулларга сәйләннәр белән матур бизәкләр чигәләр. Гомәр Бәширов “Туган ягым-яшел бишек” әсәрендә Ямаширмә авылын болай тасвирлый:

“Ямаширмә - минем малай чакта тегү тегеп йөргән авылым. Кызлары, киленнәре кышларын Казан байларына читек кайыйлар. Ямаширмәнең хәллелерәк кызлары белән яшьрәк киленнәре кием-салымның яхшысын, яңача теккәнен киделәр. Бишмәт булса, син аларга “бикламат” дип аталган, озын итәклесен, нечкә биллесен тегеп бир. Аннан да бигрәк яшел йә зәңгәр плүштән җикет тектерергә бик һәвәс иделәр. Биле нечкә, җиң очлары тар булсын, иңбашлары бөрмәләнеп, күпереп торсын...”.Хәзерге көндә әлеге һөнәр онытмыйлар, яшьләр аның дәвамчылары.

Оста куллы апаларыбыз – Радания һәм Ләйсән апа. Гомер юлындагы төрле эшләрдә хезмәт итсә дә, яшьлектә кабынган чигү сәнгатенә булган мәхәббәте сүнмәгән, сүрелмәгән. Аларның куллары белән эшләнгән баш киемнәрне һәркемне таң калдыра. Авылыбызда шундый милләттәшләрем,

авылдашларым булганда, халкымның күңел бизәкләре югалмый, киләчәк буынга тапшырылачак.

Эшне язу барышында, түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

1. Туган авылымның тарихы белән таныштык;

2.Татар халкының милли кием, чигү тарихы бик еракка барып тоташуын белдек;

3. Калфак, түбәтәй тегү һәм чигү тәртибен өйрәндек;

4. Авылыбыздагы чигүче кешеләрне барладык.

Белгәнебезчә, татар халкы нинди генә авырлыклар күрмәсен, үзенең гореф-гадәтләрен, йолаларын, искиткеч кул эшләрен күңел түреннән чыгарып ташламаган. Без, 21 нче гасыр буыны, боларның барысын да түкми-чәчми киләчәк буыннарга илтеп җиткерергә тиешбез. Шул вакытта гына татар халкы милләт буларак яшәр, рухи яктан тагын да баер, дип өметләнәсе килә.

Әдәбият


1. Ф.Г. Габдуллина “Вышиваем сами. Бисер”, Казань, “Тарих”,- 2003

2. Н.Сергеева. "Татарская вышивка", Казан, "Магариф", 2005.

3. Очерки истории Высокогорского района республики Татарстан – Казань: Изд-во “Мастер Лайн”, 1999. – 368 с.

4. Р.Ә. Шакирҗанов Ямаширмә мәктәбе – мәгърифәт чишмәсе. Татар мәгарифенең үсеш юллары. – Казан: “Новое знание” ЯАЖ, 2005.-204 б.


## АЙДАР ХӘЛИМ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӨНӘРИ ЛЕКСИКАНЫҢ ЧЫГАНАКЛАРЫ


Фазуллин Р.А.

Алабуга шәһәренең Инженер-технология лицее укучысы.

Фәнни җитәкчесе: Смирнова Г.Д .


Гомумән татар сүзләре кебек үк, татар һөнәри лексикасы да чыгышы белән берничә чыгынакны үз эченә ала. Әби-бабаларыбыз арасында һөнәрчелекнең борынгыдан чәчәк атуын искә алганда, борынгы чордан ук барлыкка килгән һөнәри лексиканың күп булуына алшарт булып тора. “Археологик казылмалар Идел Болгары шәһәрләрендә кара металлургия, тимерчелек, зәркән, бронза кою, чүлмәк ясау, күн, агач эшкәртү кебек җитештерү өлкәләре һәм һөнәрләренең булуын раслый”, – дип яза И.Ә. Гафаров. – Археология мәгълүматларына караганда, болгар осталары аркылы балта ярдәмендә эшкәртелгән тактаны киң файдаланганнар, пычкыны да белгәннәр. Алар бүрәнәләрне чөй белән һәм терсәкле тоташтыру алымын да файдаланганнар һәм моны бик оста башкарганнар. А.Хәлим әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, әдип кулланган профессионализмнарның чыганакларын билгелик. Татарның борынгыдан, гомумтөрки телдә үк формалашкан, берегеп калган сүзләрдән түбәндәгеләр теркәлде:

*Яктыдан яктыракка өндә!*

*Ян!*
*Соңлама, төнгә көн **сиплә**!*
*Ян!*

Икенче мисал:

*Халык телендә “тастымаллык” дип аталган шадра тукымадан, **кулдан,** эре **атлатып тегелгән** һәм әле беренче тапкыр гына киелгән ак күлмәк, кызыл кижҗеле кыска киндер ыштан белән өстен-башын бөтәйтеп алган һәм шул ыштаны белән бодырдан торып барлык ихатаны кызыл әләм кебек кызарткан Канәгать, тәкате бетеп, ачык ишеккә кычкырды.*

Тагын бер мисал:

*Ул **сызымга** билгесен сала да,*
*Бөкләштереп тыга куенга*.

Телебезнең сүзлек составында урын алган һөнәри лексиканың бер өлеше тарихыбызның төрле чорларында килеп кергән һәм телдә берегеп калган *алынма сүзләр пластын* тәшкил итә. Мондый лексемаларны өч төркемгә бүләргә була: гарәп-фарсы атамалары, рус атамалары, көнбатыш европа телләреннән кергән атамалар. Мисалларга мөрәҗәгать итик:

*1. Орлык киптерү өчен **зерноскладларым, хранилищеларым** минем болай да җитәрлек.*

2. *Күпләр сөрән салган иде, имеш, **горюче-смазочные** да җитәрлек булды.*

3. *Бүген авылда кулак булу өчен **посевной площадь, удобрение, механизация** гынаҗитми*.

Күренгәнчә, һөнәри лексиканың күпчелек өлеше я татарның үз җирлегендә, үз сүз байлыгы хисабына ясалган, я рус һәм көнбатыш европа телләреннән кергәннәр. Гарәп-фарсы телләреннән кергән һөнәри лексика юк диярлек. Без моны шуның белән аңлатабыз гарәп-фарсы сүзләре теребезгә Шәрекъ илләре белән багланышлар нәтиҗәсендә кергәннәр. Бу мөнәсәбәтләрнең күбесе әдәбият, мәдәният, сәнгать, дин белән бәйле. Шуңа күрә мондый сүзләр дини, мәдәни тематикага караган әсәрләрдә, мәкаләләрдә еш очрый. Әйтергә кирәк, А.Хәлим әсәрләрендә дин әһелләре лексикасы шактый еш очрый. Мәсәлән:

1. *Аңа, **мәзин** баласына, **ислам кануннары** ана сөте, бишек җыры белән сеңдерелгән, **Иман шарты, Коръән Кәрим сүрәләре, догалыкларны** да яхшы хәтерли, **Аллага шөкер**, тел дә тидертми*.

2. *– Карчык, без **кыйбланы** дөрес сайлаган булганбыз микән? – диде Гарифулла, калушларын киеп, каз тәпиле **намазлыгын** җыештырып маташкан Өммегөлсемгә.*

Мәдәният, сәнгать өлкәсендә дә гарәп-фарсы алынмалары кулланыла. Боларны язучы, музыкант, журналист профессияләре белән бәйләнештә карарга мөмкин. Мәсәлән:

*1. Хөрмәтле **баш мөхәррир**! Күптән түгел генә архивымны актарганда, бер кулъязмага тап булдым*

2. *Күңелләргә хуш киләсең,*

***Маэстро.***
*Күгең – кояш, баш өсләрең*
*Аяз тора.*

Кайбер профессионализмнар *алынма сүз + татар сүзе* моделе буенча ясалганнар. Мәсәлән:

*Гомере буе **процент исәбенә** колхозны сауган Процент Галләм, авыл батракларыннан бердәнбер азамат, моңа алданып, “Минем үз фикерем бар!” – диеп колхоздан аерылып чыккан иде, малай.*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: А.Хәлим әсәрләрендә кулланылган һөнәри лексика чыганагы буенча берничә типка карый. Күп кенә сүзләр татарның үз сүзлек хисабына барлыкка килгән, алар арасында кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр, тезмә сүзләр өстенлек итә. Гарәп-фарсы алынмалары исә бары дини лексика һәм мәдәният белән бәйле сүзләр арасында гына очрыйлар. Һөнәри лексикага караган сүзләр арасында рус алынмалары күп очрый. Алар да кушымчалау я тамырлар кушылу юлы белән ясалганнар. Кайбер сүзләр алынма *көнбатыш европа сүзе + татар сүзе (*кайбер вакытта – *мөстәкыйль алынма сүз + ярдәмче фигыль)* калыбында оешканнар.

Әдәбият


1. Гафаров И.Ә. Болгар – Казан тарих көзгесендә. – Казан: Мәгариф, 2005. – 54 б.
2. Хәлим А. Колмак җыя кызлар: шигырьләр, балладалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 42 б., 44 б.
3. Хәлим А. Кыйбла: Хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. –20 б., 31 б., 278 б.
4. Хәлим А. Беренчеләр. Индустриаль эскизлар. – Казан: Матбугат йорты нәшр., 1998. – 35б.
5. Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 65.
6. Хәлим А. Яшисебез килә!: сайланма публицистика (1957 – 2008) // кереш сүз авт.Р.Бәшәр. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 596.
7. Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 30.


## ЖЫРЛАР – ХАЛЫК ТАРИХЫ


Фатыхов К.М.

Яр Чаллы шәһәренең 42 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.

Фәнни җитәкче: Сабирова А.Х.


Халыкның поэтик иҗаты тудырган күптөрле әсәрләрдә аның гасырлар дәвамында тупланган тормыш тәҗрибәсе, рухи дөнҗясы, зирәк акылы чагылыш таба. Мондый әсәрләр шушы тутыкмас байлыкны саклап һәм буыннан буынга күчерә килеп, безнең көннәргә кадәр китереп җиткергәннәр. Җыр халыкның көнкүреше белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Кеше кайда гына булмасын, ни генә

эәләмәсен, җыр һәрвакыт аның белән бергә яши, ул – кешенең аерылгысыз, тугры дусты, ышанычлы юатучысы һәм киңәшчесе.

Җырлар – “җанлы, якты, бизәкле, халыкның бөтен тарихын ачып салучы хакыйкый халык тарихы, – дип яза Н.В. Гоголь. – Тарихчы алардан сугышның көнен һәм сәгатен, төгәл урынын адлатуны, аның барышы һәм нәтиҗәсе турында мәгүлүмат эзләргә тиеш түгел, бу яктан яңа җырларның бик азы гына ярдәм итәр. Әмма тормыш-көнкүреш дөреслеген, характерлар ярсуын, халыкның хис кичерешләре, борчылу-газаплары, бәхет-шатлыкларының бөтен төсмерләрен, нечкәлекләрен өйрәнергә, үткән гасырларның рухына төшенергә, бербөтен һәм аның аерым-аерым өлешләренең гомуми үзенчәлеген, табигатен аңларга теләсә ул бик тә канәгать булыр. Аңа халык тарихының бөтен биеклеге ачылыр [Миңнуллин 2003: 11].

“Әдәбият белеме сүзлеге”ндә җыр төшенчәсенә мондый аңлатма бирелгән: “Җыр – халык лирикасының иң киң таралган төре, сүз-текст белән көй-музыканың үзара үреләенә нигезләнгән, җырлап башкаруга исәп ителгән поэтик жанр яки шуңа караучы әсәр” [Әдәбият белеме сүзлеге 1990: 228]. Җырларның төп функциясе халыкның һәм шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыруга кайтып кала. Шушы үзенчәлегеннән чыгып, Г.Тукай аларны “халык күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер” дип атаган.

Җырны беренче булып уйлап тапкан кеше, мөгаен, «менә мин җыр иҗат иттем әле» дип уйламагандыр да. Ул кошлар сайраган, агач шаулаган, җил искән кебек, табигый итеп, үзе дә сизмәстән җырлап җибәргәндер. Хис-кичереш булып җырның сүзләре дә, көе дә берьюлы күңеленнән түгелгәндер. Әмма ул дөньяның яктырып, киңәеп киткәнен сизми калмаган. Бу матурлыкны тагын да кабатлыйсы килеп, якын кешесенә, туганнарына, дусларына да җырлап күрсәткән. Шулай итеп җыр, канатлы кош кебек, дөньяга таралган. Иң матурлары, башкалар да яратып тыңлаганы, кушылып җырлаганы күңелләрдән-күңелләргә күчеп, камилләшә барган. Анадан балага, буыннан буынга тапшырылып, халыкның уртак байлыгы булып безнең көннәргә килеп җиткән.

«Әни» дип теле ачылганчы ук, һәркем әнисенең бишек җырын ишетә, шулай итеп баланың күңел күзләре ачыла, матурлыкны, моңны таный башлый. Шуннан башлап кешене гомере буена җыр озатып йөри, якын сердәш тә, ышанычлы дус та һәм киртәләрне-чикләрне үтә торган хәбәрче дә ул җыр. Җыр ул музыка һәм шигърият кушылмасы, аларның бергә тәңгәл килүләре.

Татар халкының җыр мирасы күп төсле бизәкләрдән тукылган моңлы, шигъри бер дөнья булып күз алдына килә. Җырның хискә,мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенге көннәр аһәңе дә тирән булып уелган.

Җыр кешенең эчке дөньясының, аның хисләрен һәм кичерешләрен чагылдыра. Халык иҗаты әсәрләрнең бу төре лирик жанрга керә. Җырлар элекке тормышның авыр һәм күләгәле якларын чагылдыру белән генә чикләнмиләр. Аларда яңа рухи хисләр, шәхес азатлыгы, халык идеаллары белән сугарылган изге теләкләр дә чагылалар. Хезмәт кешесе эксплуататор сыйфатлар

тарафыннан изелеп, авыр газаплар чигеп яшәгән вакытларда туган җырларда да уфтану, сыкрану, төшенкелеккә бирелү кебек хисләр өстенлек алып тормыйлар. Дөрес, җырларда иске тормыш күренешләре, шул чорларда яшәгән кешеләр башыннан кичкән кайгы-хасрәтләр еш кына телгә алына. Борынгы җырларның кайберләренә өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелү, язмышка яки "хак тәгалә" көченә сыену кебек мотивлар да күренгәләп куя. Татар җырларына да төшенлек мотивлары ислам дине йогынтысы астында, социаль һәм милли изелү аркасында килеп кергән булуы шик тудырмый.

Җырларда халыкның үз өстенә төшкән авырлыклар, кыенлыкларны җиңеп чыгарга, авыр, газаплы тормышны җиңеләйтергә омтылуы, аның киләчәккә матур өмет теләкләр белән яшәве ачык чагыла:

Арслан киек, ай, сикермәс
Каршысында биек тау булса [Надиров 1988: 5].

Җырларны халык тормышының реаль чагылышы, кеше күңелендәге хисләрнең матур яңгырашы, яктырлышы дип атарга мөмкин.

Шул рәвештә, җырларда кешенең бай рухи кичерешләре, аның тормышка булган актив мөнһәсәбәте чагыла. Бу хәл бигрәк тә сюжетлы җырларда ачык күренә: аларда, бәетләрдәге кебек үк, иҗтимагый тормыш һәм көнкүрештә булган билгеле бер вакыйга яки хәлне сурәтләү максат итеп куела. Ләкин тормыш вакыйгаларын сурәтләүдә бәетләр белән җырлар арасында бик зур аерма да бар. Билгеле булганча, бәетләрдә аерым бер кеше, нинди дә булса бер төркем яки бөтен халык башыннан кичкән берәр вакыйга турында, күбесенчә, шул хәлне күргән яки белгән икенче берәү тарафыннан сөйләнә. Җырларда кешенең реаль тормыш вакыйгаларына карата булган эчке хисләре, шәхси кичерешләре, уй һәм фикерләре, карашлары гомумиләштерелеп, ләкин һәркем күңеленә ярардай итеп әйтелә.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең башка төрләре белән чагыштырганда, җырлар халык арасында иң күп таралган булулары белән аерылып торалар. Тормышның бик күп төрле якларын яктыртулары һәм тирән эчтәлекле булулары белән дә халык авыз иҗаты әсәрләре арасында алар күренекле урынны тоталар. Халык үзенең меңнәрчә җырларында тигезлекне, хокук һәм шәхес иркен яклап чыккан. Дуслык, туганлылык, батырлык һәм бердәмлек кебек мәсьәләләрендә дә татар халык җырларында зур урын бирелә.

**Әдәбият**


1. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 238 б.
2. Миңнуллин К.М. Һәр чорның үз жыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.
3. Надиров И. Татар фольклор мирасының фәнни җыелмасы// Татар халык иҗатының хәзерге торышы. – Казан, 1988. – 87-94.


## Н.КАШТАНОВ – МЕДИЦИНА ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАНЫЛГАН ШӘХЕС


Феткуллова А.К.,
Чувашия Республикасының

беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Айзатуллова Р.Р.

2023нче елның 26 апрелендә беренче номерлы Шыгырдан урта гомуми белем бирү мәктәбендә истәлекле очрашу булды. Мәктәпне 62 ел элек тәмамлаган укучысы, Петр фәннәр Академиясе академигы, табиб пульмонолог, язучы, Татарстан Республикасының Язучылар берлеге әгъзасы, Россия һәм Татарстанның Журналистлар берлеге әгъзасы Нәкыйп Каштанов укучылар белән очрашуга килде.

Нәкыйп Фәсхетдин улы Шыгырдан урта мәктәбендә укыган вакытын җылылык белән искә алды, ихтирам белән укыткан укытучылары турында сөйләде. Бу мәктәпнең аның киләчәк тормышында зур роль уйнавына басым ясады. Галим яшьләргә үз максатыңа ирешү өчен тырышып укырга,ялкауланмаска, актив яшәү рәвеше алып барырга киңәш итте. Автор укучыларны үзенең китаплары белән таныштырды. Аның медицина буенча 10 хезмәте, 35 шигырьләр һәм хикәяләр китабы бастырылган, күбесе рус теленә дә тәрҗемә ителгән. Очрашумиңа бик ошады. Нәкыйп Каштанов турында күбрәк беләсем килде. Үзем ишеткәннәрдән башка, иитернеттан аның турында мәгълүмат тупладым, китапханәләрдәге аның китаплары белән таныштым.

Чувашстан Республикасының кечкенә Батыр районы татар әдәбиятына Фәтхи Бурнаш, Кави Латыйп, Дамир Гыйсметдин, Җәүдәт Сөләйман, Рөстәм Сүлти кебек шәхесләрне биргән. Әлеге әдипләр янына Нәкыйп Каштанов исеме өстәлүе – минем өчен горурлык.

Нәкыйп Фәсхетдин улы Каштанов 1942 елның 8 гыйнварында Чувашстан Республикасының Батыр районы Кыр Бикшиге авылында туа. Туган авылы мәктәбендә җиде сыйныф белем алгач, үзләреннән җиде чакрым ераклыктагы Шыгырдан авылы мәктәбенә йөреп, унны тәмамлый. Романтик табигатьле егет, Әстерхан якларына китеп, берникадәр вакыт балык промыселында, аннары Уфа шәһәрендәге кирпеч заводында эшләп кайта. 1961 елда армиягә алынып, дүрт ел Ак диңгез Хәрби флотында гаскәри хезмәтен уза.

1965 елда белеем алырга омтылу егетне Казанга алып килә. 1965–1971 елларда ул Казан дәүләт медицина институтында укый. Институтны тәмамлагач, табиблык эшен Чистай шәһәренең Үзәк район хастаханәсендә башлап җибәрә. 40 елдан артык ул Казанда Республика клиник хастаханәсендә үз белгечлеге буенча хезмәтен дәвам иттерә.

Н.Каштанов балачактан ук шигырьләр язу белән мавыкса да, аның исеме көндәлек матбугатта студент елларында гына күренә башлый. Баштарак ул медицина темаларын яктырткан язмалары белән катнаша. Җитмешенче еллар ахырыннан исә «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»), «Татарстан яшьләре» газеталарында, «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналларында, «Идел» альманахы битләрендә даими басыла килгән шигырьләре, хикәяләре белән исемен таныта. Шул вакыттан бирле аның табиблык һөнәри хезмәте әдәби иҗат эше белән янәшә бара.

Н.Каштанов – балалар прозасында да актив иҗатитә. Аның балалар өчен язган шигырьләре «Шәһәргә килгән Аю» дигән гомуми исем белән Татарстан

китап нәшриятында 1992 елда аерым китап булып басылып чыга. Язучының 1997 елда дөнья күргән «Айгөлнең туган көне» исемле икенче шигъри җыентыгы да балалар яратып укыган китапларның берсенә әверелә. «Төлке» операциясе» (1995), «Ак күгәрчен күктә уйный» (1999), «Тылсымлы курай» (2001) кебек китапларындагы повестьлар, хикәяләр, әкиятләр, мәзәкләр укучылар тарафыннан җылы каршы алына. Кайбер кыска хикәяләре, шигырьләре мәктәп дәреслекләренә дә кертелә.

Иҗат адымнарының ныклы икәнен тоеп алгач, өлкәннәр өчен дә яза башлый ул. «Казан утлары», «Идел» журналларында, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан» гәҗитләрендә хикәя-повестьлары, шигырь бәйләмнәре чыга. 1999 елны «Абак» нәшрияты саллы гына проза китабын нәшер итә. Нәкыйп Каштанов - әдәбиятка соңлабрак килгән әдип. Бәлки моңа аның холык-фигыле дә тәэсир итми калмагандыр. Салмак ул, төпле ул, һәр хәрәкәтен алдан уйлый, җиде тапкыр үлчәгәннән соң гына кистереп әйтә, кистереп яза. Әдәбиятка, гадәттә, гуманитар белем алганнар килә. Нәкыйп Каштанов - табиб. Тән дәваларга тиеш булып та, җан дәвасыннан битәр тазалык булмасын аңлапмы, урау сукмак белән, ләкин үз сукмагы буйлап әдәбиятка килгән ул. Мөгаен, ул җаны белән үк табибтыр. Төгәл диагноз куйганнан соң гына дәваларга керешкән кебек, иҗатында да башта ул нәрсә, ничек язарга кирәклеген ныклап өйрәнә, аннан соң гына кулына каләм аладыр. Табиб ялгышырга тиеш булмаган шикелле, иҗатта да ул ялгышлардан саклана. Яңа табадан төшкән әсәрләренең суынганын көтә, кат-кат төзәтә, төзәтеп тә күңеленә хуш килмәсә, дусларына укытып карый, киңәшләшә, бәхәсләшә. Әсәрләренең (гүя пациентларының) сау-таза икәненә инангач кына дөньяга чыгара.

Соңгы елларда ул лирик яңгырашлы, иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлекле, үзенчәлекле метафораларга бай шигъри әсәрләр иҗат итү юнәлешендә дә нәтиҗәле эшли. Аларның шактый өлеше язучының төрле нәшриятларда басылып чыккан «Сәйлән», «Язмыш орчыгы», «Күкләргә кунмый тузан» кебек җыентыкларында урын ала.

Һәр каләм әһеле диярлек үзенең тезмә әсәрен: “Киләчәктә шигырем, бәлки, җырга да әверелер әле!” – дигән якты уй-өмет белән яза. Әгәр дә шул шигырьдә “сандугач теле” аһәңнәре яңгыраса, ул, һичшиксез, җырга әверелә! Көйче-композитор иң элек сүзләренең сыгылмалылыгына, яңгырашына һәм, әлбәттә, мәгънәви көченә, идеясына игътибар итә. Җырчы исә шагыйрь белән композиторның уртак иҗади әсәрен үз күңеле, үз йөрәге аша үткәреп, аңа кабаттан җан өрә, тылсымлы моңы белән сугара.

Нәкыйп Фәсхетдин улының шигырьләре көйгә дә салынган. 2011 елда бастырылган “Сөю елгасы” китабында 30дан артык җыры тупланган. Күпчелек җырның көен күренекле композитор Марс Нәҗип улы Кәшипов яза. Шулай ук җыентыкка Риф Гатауллин,  Рамил Курамшин, Илфат Дәүләтшин, Рәйсә Имамиев, Камил Хәсәнов, Мәсгут Исхаков, Ильяс Гыйлаҗетдинов тарафыннан көйгә салынган җырлар да кертелгән.

Н.КаштановТатарстан матбугатында әдәби очерклары, публицистик язмалары белән даими катнаша килә. Туган тел, милләт язмышы, татар

халкының гореф-гадәтләре, рух белән тән сәламәтлеге проблемаларына, әдәбият-сәнгатькә кагылышлы мәкаләләре аны киң кырлы каләм иясе итеп таныта. Ул шулай ук медицина өлкәсендә фәнни тикшеренүләр алып барган һәм гамәли нәтиҗәләргә ирешкән табиб-галим буларак та үз даирәсендә билгеле шәхес.

Н.Каштанов – 2000 елдан Татарстан Язучыларберлеге әгъзасы.

Фонендоскопны кулыннан төшерсә дә, Нәкыйп Каштанов табиблыгыннан китә алмаган булып чыкты — ул фәнни мәкаләләр яза, диагностикага кагылышлы фәнни ачышларын таныту белән шөгыльләнә.

Нәкыйп Каштанов хәзер лаеклы ялда. Соңгы елларда туган ягына — Чувашиянең Батыр районы Кыр Бикшиге авылына багышланган китап язу белән шөгыльләнгән. “Тарихны саклап калу һәм киләчәккә җиткерү буенча да эшлисе эшләр шактый. Бу кызыксыну безнең нәселдән килә, дип әйтсәң дә була. Әтидә дә бар иде ул, Зәйнәп апа да шактый эш эшләде. Кешеләр турында очерклар язды, белгәнен, өйрәнгәнен кәгазьгә төшереп калдырды. Әти исә сугышта йөргәннәрен, үзе белгән кадәр нәсел турында мәгълүмат, колхоз тормышы, анда безнең нәселнең эшчәнлеген язып калдырды. Ул бәетләрне дә шактый җыйган иде. Хатларында безгә багышланган шигырьләр, җырлар язылган. Әтисугышка 1942 елдаалынганбулган. Боларбарысы да шул юнәлештә тагын да материал тупларга этәрде. Авыл тарихы китабына мәгълүмат кырык ел җыелды. 854 битлек авыл тарихы китабы узган ел басылып чыкты. Китапта авылның килеп чыгышы турында документаль мәгълүмат, һәр чорда авылда булган вакыйгалар, кешеләр, аннан чыккан шәхесләр турында очерклар, фольклор материал, авылда үстерелгән үсемлекләргә кадәр бирелгән. Язучы Фәтхи Бурнашның, академик Миначевның да безнең нәселгә каравы ачыкланды.», - дип сөйләде Н.Каштанов.

Нәкыйп Фәсхетдин улы Каштанов үзенең әсәрләре белән безнең рухи дөньябызны баета, анда якты маяклар кабыза, безгә яшәү юлында ярдәм итәрдәй рухи ориентирлар булдыра. Ул әсәрләр безгә ышанычлы юлдаш булып тора.

Әдәбият


1. Каштанов Н.Ф. Нәселебез мәрҗәннәре. – Казан:Сүз, 2011. – 334 б.
2. Каштанов Н.Ф.Сөю елгасы. – Казан:Сүз, 2011. – 64 б.
3. Каштанов Н.Ф.. – Казан:Сүз, 2011. – 64 б.
4. https://madanizhomga.ru/
5. Каштанов Н.Ф белән әңгәмә.


## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА АЛКЫШ ЖАНРЫ


Фәләхова Вероника

Саба районы Шәмәрдән бистәсе Үсеш лицее укучысы.

Фәнни җитәкче: Сабирова Р.Ә.


“Хәерле имин көннәр, “эшләрегез уң булсын”, “Ходай ярдәм итсен”, “Ходай тел ачкычлары бирсен”, “уңышлар юлдаш булсын” диган изге

теләкләрне без еш ишетәбез.Әлеге изге теләкләр халык авыз иҗатының бер төре –алкышлар.

Алкыш жанры - татар фольклорында бүгенгә кадәр аз өйрәнелгән, әлегә галимнәрнең игътибарыннан читтә калып килгән жанрларның берсе. Бу жанрга караган әсәрләр татар фольклор җыентыкларына кертелсә дә, әлегә кадәр алкышлар тирәнтен өйрәнелмәгән. Шуңа даәлеге жанр бездә кызыксыну уятты һәм фәнни эшебезнең темасын,“Халык авыз иҗатында алкыш жанры” дип атадык.

Максатыбыз - татар халык авыз иҗатының йола поэзиясе жанры алкышлар белән танышу һәм аларның әһәмиятен билгеләү.

Максаттан чыгып, түбәндәге бурычларны куйдык:1)әлеге теманы өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләре белән танышу; 2)төрки халыклар иҗатында алкышларның кулланылу дәрәҗәсен ачыклау;3)алкышларны башкарылу үзенчәлекләренә карап төркемләү;4)алкышларның кеше тормышындагы әһәмиятен билгеләү.

Тикшерү объекты итеп, “Халык афоризмнары” ,“Балалар фольклоры”, “Халык авыз иҗаты” җыентыклары алынды.

Алкышлар барлык төрки халыкларда һәм монгол телендә сөйләшүче халыкларда очрый. Бу сүз изге теләк, фатиха дигәнне аңлата.

Алкыш жанры - борынгы жанр, аның тарихы мәҗүсилек чорларына ук барып тоташа. Төрки халыклар борынгы заманнардан ук шигъри сүзнең көчен югары бәяләгәннәр. Борынгы кешеләр сүзләрнең сихри көчкә ия булуына, табигать стихиясенә дә йогынты ясый алуына һәм кешенең теләкләрен һәм өметләрен тормышка ашыра алуына ышанганнар. Мәсәлән, мәҗүсилек чорына караган “Күк Тәңрем! Синең көчең куәтең, көдрәтең артсын!” алкышы, Ислам дине кабул ителгәч, хезмәткә карата әйтелә торган “Алла куәт бирсен!” яки “Алла ярдәм итсен!”, “Җиңеллеген бирсен!” алкышлары да магик көчкә ышануны күрсәтеп тора. Бүгенге көндә әйтелә торган “Ходай тел ачкычлары бирсен”, “Укытучыларның күзенә сөйкемле күрен”, “Башыңа зиһен бирсен!” алкышларының формалашуы Болгар чорына барып тоташа.Һәр чорның үз алкышы.

Алкышлар кеше тормышында әһәмиятле вакыйгалар булганда, шатлык-куаныч килгәндә, уңышка ирешкәндә һәм башка шундый очракларда хуплау, теләктәшлек белдерү йөзеннән әйтеләләр. Әйтик, берәр кеше өстендә яңа кием күргәндә: “Җылы тәнеңдә тузсын!” — диләр. Берәр төрле эш башкаручылар янынннан: “Алла куәт бирсен!” —дип узалар. Юлга чыгучыларны: “Йөргән аягың савапка бетсен!” яки “Юлың ак сөттәй булсын!” кебек сүзләр белән озатып калалар.

Башкарылу үзенчәлегенә карап татар фольклорында һәм телдә сакланып калган алкышларны төп ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төр алкышлар көнкүрештә әйтелә.Аларны «Көнкүреш алкышлары», яки «Теләкләр» дип йөртәләр. Алар күләме белән кечкенә, берничә сүздән тора һәм, кагыйдә буларак, тотрыклы текстлар. Мәсәлән,

*Ашың-чәең тәмле булсын.*
*Аягың җиңел булсын.*

*Аяк-кулың сызлаусыз булсын, күңелең сырхаусыз булсын*

Икенче төр алкышлар календарь яки гаилә көнкүреш йолалары составында башкарыла торган текстлар. Аларны “Йола алкышлары” дип йөртәләр.

Аерым йола белән бәйле алкышлар, бары шул йола вакытында гына башкарыла. Календарь йолалар белән бәйле алкышлар аерым кешегә генә түгел, илгә, халыкка имин тормыш теләүгә юнәлтелгән. Мәсәлән, Нәүрүз, Нардуган, Карга боткасы кебек календарь бәйрәмнәрдә һәр йортка кереп бәйрәм боткасы өчен ризык яки бәйрәм уңаеннан бүләк җыючылар рәхмәт әйткәндә алкыш әйтәләр:

Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез уңсын,
Күкәй кебек тук булсын

Балалар тууы, туй йоласы, кунакларны каршы алу һәм озату йолалары белән бәйле алкышлар – гаилә йолалары. Алар күпчелек очракта берничә юлдан,хәтта берничә строфадан торырга мөмкин.Мәсәлән, туй йоласы алкышы:

Гомерлек мәхәббәт бирсен,
Бетмәс дәүләт бирсен,
Акылларыгыз ашсын,
Бәхетләрегез ташсын,
Һич яманлык булмасын,

Яңа туган балага, яңа гаилә коручыларга атап әйтелгән алкышларда аларга бәхетле имин гомер теләнә. Яңа туган балага карата иң еш кабатлана торган алкыш: ***«Тулы бәхете, тәүфигы, үз ризыгы белән килсен!».*** Шулай ук баланың тәрбияле булуын, әхлак ягыннан камил кеше булып үсүен, ягъни тәүфикъллы булуын телиләр.***Бәхетенә тәүфыйгы булсын***”, ***“ Тәүфикъллы бул, тигез канатлы – ата-аналы булып үс!»*** дигән теләкләр шундыйлардан.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: 1) алкышларда җәмгыять һәм гаилә кыйммәтләре, гомумкешелек өчен мөһим әхлакый кыйммәтләр алга чыга; 2)алар милли этикетны өйрәнү өчен дә әһәмиятле чыганак булып тора; 3)изге теләкләр яттан өйрәнелми, кәгазьдән укылмый, алар могҗизалы рәвештә эчке яктан туалар, акылга ирешәләр, матур фикерләргә формалашалар һәм авыздан иркле җыр белән (шигырь формасында) агалар.

Әдәбият


1. Безертдинов Б.Н. Древнетюркское мировоззрение «тэнгрианство»-179б.
2. Закирова И.Г. Әүвәл башлап ни бетте.-Казан: ТӘҺСИ, 2017.-152бит.
3. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар. Йолалар/ Г.Гыйльманов хикәяләвендә.Казан: Татар.кит.нәшр.,1996.-338б.
4. Татар халык авыз иҗаты. Балалар фольклоры/ төзүчесе Рәшит Ягфәров. Казан: татар.кит.нәшр.,1993.
5. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 319 б.

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ПАТРИОТИЗМ ТЕМАСЫ

Фаррахова Л.Ф.,
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.

Нәрсә соң ул патриотизм? «Патриотизм — ул үз ватаныңа, үз халкыңа, үз милләтеңә, уз телеңә, үз халкыңның культурасына һәм милли традицияләренә мәхәббәт». [Совет патриотизмы турында ... интернет-ресурс] Җәмгыятьтә ватанпәрвәрлекнең тарихи элементлары булып туган җиргә, телгә, үз халкының иң яхшы милли традицияләренә бәйлелеге тора, алар совет җәмгыятендә башка халыкларга хөрмәт, пролетар интернационализм, гомуммилли горурлык белән баетыла башлаган.

Әдәбият һәм язучылар һәрвакыт җәмгыять тормышында төп рольләрнең берсен уйнаганнар һәм әле дә уйныйлар, җәмгыять фикерен һәм кешеләрнең карашларын формалаштыруга, дөньяда сәясәт, икътисад һәм мәдәният вакыйгаларына йогынты ясарга сәләтле реаль көч булып торалар. Тарихи фәнгә тулаем объектив якын килү, халыкның патриотик аңын формалаштыруда язучылар иҗатының роленә, аерым алганда, иҗтимагый процесслар үсешенең яңа тенденцияләрен ачыкларга мөмкинлек бирә. Биредә үткән тәҗрибә шактый файдалы була.

Татар әдәбияты, үзенең күп гасырлык казанышларына таянып, бик зур үсеш юлы үтә, мәгърифәтчелектән тәнкыйть реализмына һәм романтизмга таба сикереш ясый. Реалистик юнәлеш Г.Тукай поэзиясендә, Г.Камалның романнарында, повестьларында, комедияләрендә һәм драмаларында, Ф.Әмирхан, Ш.Камал иҗатында ачык чагыла. Төрле иҗади эзләнүләр белән беррәттән, барлык авторлар татар халкының киләчәге, аны кабатланмас теле һәм менталитеты белән милләт буларак саклап калу турындагы уйларны берләштерәләр. Әлеге чор язучылары үзләрен илебезнең чын гражданнары итеп таныта. Гаяз Исхакыйның милләт язмышы өчен кискен хәвеф белән сугарылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дип исемләнгән публицистик әсәрен ассызыклап үтәсе килә. Әсәрдә дини фанатизм, кешеләрнең милли проблемаларга битарафлыгы һәм тормышның ямен күңел ачуда гына күрү нәтиҗәсендә җимерелгән XIX гасыр ахыры - XX гасыр башы татар җәмгыяте тормышы күрсәтелә. Татар әдәбиятында Исхакый беренчеләрдән булып үз милләтенең киләчәге мәсьәләсен кузгата һәм аны шундый мескен хәлдә күз алдына китерә. Язучы фикере буенча милләт яшәешенең проблемасы - аның чорында иң мөһиме. Гадбулла Тукайның «Милләткә» дигән шигырен дә игътибарсыз калдырырга мөмкин түгел. Анда лирик герой үз халкына, үз милләтенә чиксез, тирән мәхәббәт хисләре кичерә. Суфичылык мотивы - мәхәббәттән акылдан язу - милләткә мәхәббәт мотивына трансформалаша һәм хисләр ташкыны дәрәҗәсен ассызыклый: бу мәхәббәт - дөньяда иң югары кыйммәт, ә үз халкыңа хезмәт итү - югары ләззәт һәм бәхет. Яшь Тукайның беренче шигырьләрендә үк традицион образлар барлыкка килә, ә милләт проблемалары (акрын үсеш һәм артта калу) турында сөйләшү мәгърифәтче, мөселман, шагыйрь һәм битараф

булмаган кеше позициясеннән алып барыла. Тукай әсәрләре дөньяның дини картинасын дөньяви күренешкә үзгәртә һәм патриотизм формалаштыруга хезмәт итә. [История татарской литературы нового времени 2003]

XX йөз башында татар совет әдәбиятында Х.Такташ, Х.Туфан, М.Җәлил, С.Баттал, Ш.Маннур һ.б. яңа исемнәр пәйда була. Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе» белән башланган, соңрак К.Тинчурин, Н.Исәнбәт, Т.Гыйззәт, Х.Вахит, А.Гыйләҗев драматургиясендә дәвам иткән драматургия күтәрелеше була. Күп кенә язучылар үз иҗатларында халык тормышының тирәнлеген тикшерергә омтылуда социалистик реализм кысаларыннан котылалар, аларның әсәрләре стилистик сурәтләү-сәнгатьләү чараларның күптөрлелеге белән аерылып торалар. [XX гасыр башы татар әдәбияты һәм публицистикасы 1966]
1941-1945 еллардагы татар әдәбияты сугыш вакытында халык кичергән хисләрнең бөтен гаммасын тапшыра. Бу татар халкын бөтен дөньяга таныткан М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндә, Ф.Кәримнең романтик-патриотик поэзиясендә, Н.Баян, Н.Арсланов, Ш.Мөдәррис иҗатларында, Г.Әбсәләмов, И. Гази һәм башка язучыларның прозасында чагылыш тапкан. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» лирик циклы аерым игътибарга лаек. Күп кенә шигырьләрдә лирик герой - тоткын. Аның өчен төп кыйммәтләр - ирек, туган җир һәм халык белән рухи бәйләнеш, ана һәм туган ил турында хәтерләү. Монда көчле һәм кыю татар герое образы торгызылган, ул үз иле, халкы һәм аның киләчәге өчен гомерен биргән. Шул ук юнәлештә сугыштан соңгы татар әдәбиятында кешенең концепциясе үзгәрә: төп герой образы төрки-татар героик эпосы структурасында торгызыла. Җәлилнең лирик циклы халык җырларына, милли кыйммәтләргә (туган җиргә, гореф-гадәтләргә) һәм татар геройларының идеаллаштырылган образларына әйләнеп кайтуга ярдәм итте. [Совет Татарстаны язучылары 1986]

Сугыштан соңгы еллар әдәбиятенә килгәндә, Аяз Гыйләҗевнең 1962 елда язылган «Өч аршин җир» повесте - туган җиргә, туган якка тугрылык идеалының ачык мисалы. Мирвәли бай гаиләдә туа, әмма әтисендә батрак кебек яши. Егет атасының ихтыярына каршы сөйгән кызы Шәмсегаянга өйләнә. Совет хакимиятенә үч итеп үз гаебен кичерә алмаган гамәл кыла: авыл халкына бик кирәк булган гаиләсенең икмәк йортын яндыра. Бер яктан, Мирвәли белән Шәмсегаян язмышлары - иҗтимагый тетрәнүләрнең кешене өйдән, җирдән, милли үзаңнан мәхрүм итүе, аны мәхрүм итүгә этәрүенә дәлил. Икенче яктан - автор укучы алдына туган җире һәм туганнары - иң кыйммәтле байлыгы булган татар образын ача.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без - кырык беренче ел балалары» дигән әсәре сугыш елларында яшүсмерләрнең тормышы турында. 1 октябрьдә колхоз кырларыннан аерылган малайлар һәм кызлар педагогия училищесына укырга киләләр. Повестьның беренче битеннән үк һәр бәяләү һәм фикерләү "кырык беренче ел балалары" фикере буларак кабул ителә. Баштарак төрле авыллардан җыелган тәртипсез балалар повесть ахырына, 1946 елга, укытучы булырга һәм тормышларын укуга багышларга әзер шәхес булып җитешәләр.

1980 еллар ахыры - 1990 еллар башы әдәбияты татар милләтен, аның дәүләтчелеген торгызу, мәдәниятне һәм телне саклау өчен көрәш мәйданына

эверелә. Әсәрләрендә халыкның киләчәге өчен борчылу чагылган язучылар барлыкка килә, реализм милли төсмер ала башлый. [История татарской литературы нового времени 2003]

Мәктәптә балага патриотик тәрбия бирү турындагы мөһим мәсьәләгә килгәндә, татар теле һәм әдәбияты бу өлкәдә зур роль уйный. Укучылар Советлар Союзы Герое булган Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан һәм Бөек Ватан сугышында катнашкан тагын күп кенә татар шагыйрьләре һәм язучыларының Ватанга һәм үз халкына мәхәббәт белән сугарылган кыю әсәрләрендә үсәләр.Патриотизм һәм гражданлык хисен тәрбияләүдә туган тел һәм әдәбият укытучысы зур роль уйный. Минем фикеремчә, яшь буынны патриотик тәрбияләү өчен әдәбият зур мөмкинлекләргә ия.

Тел һәм әдәбият дәресләре укучыларда әхлак тәрбияләүдә чиксез роль уйный, минемчә. Милли каһарманнар мисалларында, рухлары белән безгә якынрак булган бабаларыбыз телендә патриотик тәрбиягә ирешү җиңелрәк. Бигрәк тә укучыларның күңелләренә милли каһарманнар турында язылган әсәрләр якын: сугыш хәрәкәтләре вакытында яшь буынның героизмына багышланган Ибраһим Газинең «Йолдызлы малай» хикәясе, Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повесте, Шамил Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» повесте, Габдрахман Әпсәләмовның «Миңа унтугыз яшь иде» повесте, Ләбибә Ихсанованың «Лачын кыз» хикәясе, Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» хикәясе һәм тагын күп кенә шигырьләр һәм прозаик әсәрләр.

Әдәбият


1. Гайнуллин М.Х. XX гасыр башы татар әдәбияты һәм публицистикасы.– Казан, 1966.
2. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. Казан, 1986.
3. История татарской литературы нового времени. Казань, 2003.
4. “Совет патриотизмы турында” https://kazanutlary.ru/j-archive/journal-materials/1947-5/sovet-patriotizmy-turynda (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.10.2023)


## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРГА ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ БИРҮ


Фаррахова Л.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты.
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


Әдәбият дәресләренең шәхескә юнәлгән универсаль уку гамәлләрен, тәрбияви аспектны тормышка ашыруда мөмкинлекләре аеруча күп булуы бәхәсләр уятмый. Сүз куәте укучыларның аңына гына түгел, күңеленә, җанына да тәэсир итә, кыйммәтләр системасына да йогынты ясый. Шуңа күрә әдәбият дәресләрендә өйрәнү өчен алынган әсәрләр төрле яктан тикшерелә. Заманча дәреслекләрдә экологик тәрбия бирү куәтенә ия булган әсәрләргә дә игътибар

бирелә. Бу – илебез, дәүләтебез алып барган сәясәткә дә ярашлы булып тора, аерым алганда, җәмгыятьнең һәр әгъзасының экологик культурасын үстерү бурычлары “Россия Федерациясен 2030 нчы елга кадәр экологик үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең нигезләре” [Основы государственной политики ... интернет-ресурс] документында карала. Киләчәккә омтылган фән – экология фәне. Ул табигатьне, йортыбызны киләчәк буынга кешеләр яшәешенә кирәкле бөтен нәрсә сакланган килеш тапшыру өчен бик мөһим. Экологик белем бирүнең һәм мәгарифнең төп максаты - экологик культуралы шәхес булдыру. Аңлашыла ки, табигатьне саклау юлында актуаль гамәлләр фәнни нигездә биология, география кебек предметларны укыту дәвамында тикшереләләр. Әмма шунысы ачык аңлашыла: экологик тәрбия даими һәм системалы рәвештә алып барылганда гына уңай нәтиҗәгә китерә ала. Экологик белем һәм тәрбия бирү укучыларда әйләнә-тирә дөньяга сакчыл мөнәсәбәт булдыруны күздә тота һәм шуның белән бергә аларның эчке дөньясын камилләштерүгә ярдәм итә. Димәк, мәктәп шартларында бары табигать фәннәренә караган предметлардан гына түгел, башка фәннәр, шул исәптән әдәбият дәресләренең дә экологик тәрбия бирү потенциалыннан максатчан файдалану сорала.

Табигатькә яхшы мөнәсәбәт формалаштыру, аны саклау максатлары һәм мотивлары, эшчәнлекнең һәм үз-үзеңне тотуның экологик максатка ярашлы стратегияләрен сайлау әзерлеге - барлык укытучыларның бурычы. Татар әдәбияты дәресләрендә шулай ук табигатьнең бөеклеген, матурлыгын, кешенең хайваннар һәм үсемлекләргә сакчыл мөнәсәбәттә булырга тиешлеген күрсәтү бик мөһим. Дәресләрдә укучылар “Табигатькә китерелгән зыянны нәрсәләрдә күрәсез?”, “Табигатебезне саклау өчен кешеләргә сез нәрсә киңәш итәр идегез?” дигән сорауларга җавап табарга тиеш. Экологик белем һәм тәрбия бирү табигать дөньясына экскурсияләр үткәрмичә мөмкин түгел. Иҗади иншалар үткәрү, экскурсияләрдән соң экология темасына әңгәмәләр оештыру әдәбият укытучыларын методик ысулы булып тора. Мондый иҗади эшләр, беренчедән, игътибарлы булырга ярдәм итә, икенчедән, табигатькә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләүгә уңай йогынты ясый. Экология буенча белемнәрне бәяләү өчен, укучыларга инша язарга тәкъдим ителә. “Матур язгы көн”, “Язгы урман”, “Урман – кешенең дусты”, “Язның истә калган бер көне” кебек темалар тәкъдим ителә. Мондый эшләр ярдәмендә табигатькә сакчыл караш формалаша һәм экологик бурычларны хәл итү юлларын күз алдына китерү мөмкинлеге булдырыла. [Формирование экологической культуры …интернет-ресурс].

Татар әдәбияты традицион рәвештә һәрвакыт табигать дөньясы белән янәшә бара. Анда табигать тасвирламасы төрле мәгънәгә ия: пейзаж лирик геройның рухи дөньясын сурәтли, ул аның уйлары белән аваздаш була; табигать тасвирламасы кеше тормышы белән капма-каршы буларак бирелә. Әдәбият укучыларга табигать дөньясының образлы һәм фәнни тасвирламасын чагыштырырга, дөньяны күзаллауны образлы һәм логик кабул итү арасындагы аерманы аңларга мөмкинлек бирә.

Җиденче сыйныфта Р.Фәизовның “Бер күбәләк” фантастик хикәясе өйрәнелә. Сюжет буенча, Инар һәм аның әтисе “үткән заман” лифтында 20000 елекке Җиргә сәяхәт итәләр, малай бик кызыгып, шундагы күбәләкләрне тота,

“аучылык” вакытында берничәсен харап та итә, ягъни вакыт сәяхәтендә катгый тыелган канунны боза. Сәяхәттән соң яңадан үз заманнарына кайтканда, алар тирәлекне танымыйлар: алар яшәгән матур йортларны салам тораклар, гүзәл табигатьне зәгыйфь һәм саргайган куаклар, матур апаны җыерчыклы әби алыштырган. Болар барсы да – үткән заман табигатенә Инар китергән зарар нәтиҗәсе.

Дәреслектәге түбәндәге сорауларга җавап бирү экологик тәрбия бирү ягыннан әһәмиятле:

–Ни өчен әсәр “Бер күбәләк” дип исемләнгән? Геройның исеме күбәләк түгел бит?

– “Үткән заман”да булган кешегә нинди таләпләр куела? [Хәсәнова 2017: 125-126].

Укучыларга әсәр тексты белән эшләргә, Инардагы комсызлык, аучылык инстинктының акылдан югары торуы турындагы тасвирларны уку сорала. Әсәр балаларны табигатькә үтә сак булырга өйрәтә.

Шушы ук сыйныфта өйрәнелә торган икенче әсәр – Галимҗан Гыйльмановның “Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса” хикәясен өйрәнгәндә, укучылар экологик үсеш, табигатьне саклау миссиясенә алынгансың икән, акыл белән, фәннилеккә, шул өлкәдәге компетентлы кешеләрнең сүзенә таянып эшләргә кирәклеген танырга булыша. Укучылар ике малайның – Хәлим белән Сәлимнең гамәлләрен чагыштыралар. Икесе дә кош оялары ясыйлар. Сыннар ясап, күргәзмәләрдә катнашкан Хәлимнең оясы искиткеч матур, ә Сәлим оясыннан бераз ояла да хәтта. Әмма матурлыкка омтылу трагедиягә китерә. Хәлим оясын кошларның үзенчәлекләрен белеп бетермичә ясый, кош оясы тишеге янында басма ясамый, канат чыгар вакыты җиткәч, очарга өйрәнергә теләгән кош балалары җиргә төшеп һәлак булалар. Автор Хәлимне үтә тискәре образ итеп тасвирламый. Бу вакыйга аның өчен гомерлек сабак була, аның күзләрендә мәңге бетмәс моң урнаша.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: әдәби әсәрләр аша укучыларны табигатькә сакчыл карарга, үзеңне кулланучы буларак хис итмәскә; табигать кануннарын белеп эш итәргә кирәклегенә төшенәләр.

Әдәбият


1. Основы государственной политики в области экологического развития Российской Федерации до 2030 года (утв. президентом РФ в 30.04. 2012 г.). – URL: http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_129117; (мөрәҗәгать итү вакыты: 19.10.2023).

2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1994. – 405 б.

3. Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Сафиуллина Ә.Н. Татар әдәбияты: 7 нче сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. Ике кисәктә. 2 нче кис. – Казан: Мәгариф - Вакыт, 2017. – 135 б.

4. Хусаинов З.А. Формирование экологической культуры учащихся национальной школы на основе знаний татарского народа о природе // Научное

обозрение. Реферативный журнал. – 2016. – № 1. – С. 69-103; URL: https://abstract.science-review.ru/ru/article/view?id=648 (мөрәҗәгать итү вакыты: 19.10.2023).

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ҖАЕК ЧОРЫ ИҖАТЫНДА ЖУРНАЛИСТИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Фәсхетдинов И.Р.
Арча районы Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкчеләр: Шиһапова Г.Х., Салахова И.Г.

Җаек еллары – Тукай иҗатының чәчәк аткан чоры, шунда ул шагыйрь булып җитешә, шунда аның публицистик каләме чарлана. Шулай бәяләү, бер уйлаганда дөрес тә, чөнки нәкъ менә Тукай яшәгән чорда җәмгыятьтәге каршылыклар Апушны олы шагыйрь, журналист, көрәшче иткән. Гәрчә ул Кырлайны “дөньяга күзем ачылган урын” дип язса да, Кырлай аның балачак дөньясына күзе ачылган урын. Ә Җаек – булачак шагыйрьнең чынбарлыкка күзе ачылган урыны. Ул монда чын тормышның үзе белән очраша һәм хаклык эзләгән шагыйрь күңеле бик күп каршылыкларга очрый. Тукайның Җаек чоры иҗаты белән якыннанрак танышкач шундый нәтиҗәгә киләсең: шигырьләрен аласыңмы, чәчмә әсәрләренме – һәркайсында диярлек шул чорны, яшәешне камчылау, усал итеп көлү.

Кырлайдан Җаекка күчү, билгеле инде, Габдулланың тормышында кискен борылыш барлыкка китергән. Шагыйрьнең кыска гына гомеренең унике еллап чамасы өлешен алып торган Җаек тормышы әдәбият белгечләре тарафыннан беравыздан иҗатындагы мөһим бер чор буларак каралып өйрәнелә.

Билгеле, Тукайның даирәсе дә, тормыш шартлары да аның дөньяга карашын формалаштыруда зур роль уйныйлар. Мәдрәсәдә ул Коръәнне, ислам дине нигезләрен яхшы өйрәнә, гарәп әдәбияты белән таныша, мәдрәсәнең баш имамы Мотыйгулла хәзрәттән гыйльме гаруз дәресләре ала. 1902 елның җәендә Истанбулдан качып Уральскига килгән төрек студенты Габделвәли Әмрулла белән дуслаша, аннан төрекчә өйрәнә, төрек һәм Европа әдәбиятлары турында берникадәр күләмдә мәгълүмат ала. 1903 елның июлендә К. Мотыйгый Г.Тукай һәм алдынгы шәкертләр хуплап каршы алган “Әл-мәгариф” исемле кулъязма газета чыгара. Тукайның монда бер әсәре дә урнаштырылмаган, әмма аның бу газетаны укып баруы билгеле. Шушы елларда ук аның беренче шигъри тәҗрибәләре, мәкаләләре барлыкка килә, кайберләре мәдрәсәдә 1904 елда Камил Мотыйгый Төхфәтуллин тарафыннан чыгарыла башлаган кулъязма «Әлгасрел-җәдит» (1905 елның май аенда туктала) исемле журналда дөнья күрә. Тукай – бу журналны язучыларның берсе, журнал идарәсендә редколлегия әгъзасы. “Әдип” дип аңа беренче мәртәбә шушы журналда мөрәҗәгать ителә. Шушы кулъязма журналның 11 санында Г.Тукайның “Җәһаләт вә сәфаләт” (“Наданлык һәм түбәнлек”) мәкаләсе “Каилел хак” имзасы белән урнаштырыла.

1905 елгы революциядән соң Җаекта Камил Мотыйгый нәширлегендә демократик рухлы газета-журналлар чыга башлый. Г.Тукайга матбугатта юл ачыла. “Фикер” газетасын чыгаруда катнашу,  шунда наборщик, конторщик, журналист, корректор булу, ”Әлгасрел-җәдит” журналын нәшер итүдә булышу аның шагыйрь һәм шәхес  буларак өлгерүен тизләткәндер. 1905 ел аның өчен тулы иҗади ел. Ул ноябрь, декабрь айларында “Фикер” һәм “Нур” газеталарында 224 юл шигырь бастыра. 1906 елның беренче яртысында бу санны 500 гә җиткерә. Ә инде 1906 елның урталарыннан 1907 елның көзенә кадәр меңнән артык шигъри юл, иллегә якын мәкалә һәм фельетон язганы исбатланган.  1906 елның беренче алты аенда Тукай “Әлгасрел-җәдит”нең һәр санында икешәр-өчәр шигырь, ә “Фикер“ газетасында җиде шигырь бастыра. Боларга хикәяләр, рус классиклары әсәрләренең тәрҗемәләрен дә өстәсәң, шагыйрьнең ничек канатланып иҗат итүе аңлашыла**.**

Бишенче-алтынчы еллардагы шагыйрь иҗаты публицистик аһәң белән өрелгән, сәяси темалар белән сугарылган, авторитетларны санга сукмаучы ачы сатирик юнәлешле булуы күзгә ташлана. Тукайның журналистлык эшчәнлеге белән дә тыгыз бәйләнгән әлеге юнәлеш аның иҗатында соңгы елларга кадәр дәвам итә  һәм үстерелә.

Г. Тукайның журналистик эшчәнлеге гаять күпьяклы. Беренчедән, ул прогрессив татар матбугатын оештыручыларның иң атаклыларыннан.

Икечедән, Г. Тукай матбугат турында бик кыйммәтле һәм кызыклы фикерләр калдырган. Ул матбугатның җәмгыятьтәге урыны, вазыйфалары, сыйныфлыгы, халык белән бәйләнеше, эш алымнары хакында тирәнтен уйланган, шул уйлануларын җае килгән саен кәгазьгә төшерә барган. Ул фикерләр матбугат турындагы  карашларны үстерүгә өлеш булып кергән. Г. Тукайны без хаклы рәвештә матбугат тарихчысы дип тә атый алабыз.

Алты томлык Академик басманың 3 нче томында бирелгән мәкаләләр белән танышкач, Г.Тукайны Җаек чорында язылган мәкаләләрендә берничә теманы аерып карап була: милләт язмышы өчен борчылу, мәгърифәтчелек идеяләрен тарату, дини-фанатик муллаларны тәнкыйтьләү, илдә барган сәяси вакыйгалардан хәбәрдар булу һәм үз фикерен ачык итеп күрсәтү, хатын-кыз проблемасын күтәрү, татар дөньясында, шәһәрдә булган барлык яңалыкларны күзәтү һәм халыкка җиткерү, аерым шәхесләргә багышланган мәкаләләр, тәрҗемәләр һ.б

Әмма матбагалар ябыла икән, дип төрле газеталарда хәбәрләр басылып өлгерә. Тукай  үзе дә бик борчыла, ләкин ул газета  укучыларын “Фикер”дә, “Әлгасрел-җәдит”тә элекке юнәлештә чыгуларын дәвам иттерәчәкләр, дип тынычландырырга ашыга. Тик яңа нәширлектә ике ай эшләгәч, ике матбага да эшләүләреннән туктый. 1907 елның 29 маенда типография сатыла, 21 яшьлек Тукай өчен бу йөрәксенеп, дәртләнеп чапкан атны көтмәгәндә, кисәк кенә туктаткандай бер халәт була. Бу инде аның өметен кисү була. Тукай рухи һәм матди  яктан авыр хәлдә кала.

Җаек еллары – Тукай иҗатының чәчәк аткан чоры, шунда ул шагыйрь булып җитешә, шунда аның публицистик каләме чарлана. Ул “ бишенче елны бер көнне таң белән уянып” үзенең журналистлык эшчәнлеген “Безнең татар

үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?" , "Тотса Мәскәүләр якаң", "Юбилей мөнәсәбәте илә", "Милләтче", "Кемнәрнең нәрсә дисәң котлары чыга", "Кыямәт көне" исемле мәкаләләре А.Бахның "Царь-голод, яхуд Ачлык-патша", Л.Памирцевның "Сугыш һәм Дәүләт думасы" исемле тәрҗемәләре белән башлый. Иҗат итү дәверендә Г.Тукай әдәби тәнкыйтьне формалаштыруга да үзеннән мәгълүм өлеш кертә. Каләме шактый шомарып, сүзләренең тәэсир көче артып, 1906 елларда публицистик һәм тәнкыйди мәкаләләр яза башлаган шагыйрь тиз арада тугры сүзле, принципиаль, усал тәнкыйтьче буларак таныла. Ул вакытлы матбугат битләрендә XX гасыр башы татар җәмгыятен борчыган төп проблемаларга үз фикерен күрсәтә.

Быел бөек Тукаебызның тууына 137 ел. Шул кадәр вакыт үтсә дә, аның тормыш юлы, иҗаты белән кызыксыну арта гына.

Г.Тукайның журналистик эшчәнлеге галимнәребез тарафыннан җентекләп өйрәнелә. Төрле тәхәллүсләр (псевдоним) астында басылган әсәрләре алты томлык Академик басмада тупланган. Әйе, шагыйрь мирасын өйрәнүгә күп хезмәт куела. Ләкин Габдулла Тукай иҗаты һәм шәхесе торган саен яңа яклары белән ачыла бара, һәм без аның әсәрләрен кат-кат укыйбыз, өйрәнәбез. Бу – табигый, чөнки Тукай иҗаты – ул төпсез хәзинә.

Шагыйрь тормышы һәм иҗаты белән кызыксына башлагач, мин шундый нәтиҗәгә килдем: милләт яшәешенә Габдулла Тукай кебек зур йогынты ясаган, газиз халкының күңеленә шулай тирән үтеп кергән бүтән шәхес әлегә күренми. Һәм мин үземнең Тукайның дөньяга күзе ачылган Кырлайда укуым белән горурланам.

Әдәбият


1. Әгъзамов Ф.И. Тукай-журналист.-Казан: Тат. кит. нәшр., 1986.- 271 б.
2. Габдулла Тукай. Әсәрләр: 6 томда.- Академик басма.-Казан: Татар.кит. нәшр., 2011- 3 т.: мәкаләләр, фельетоннар, хикәяләр(1904-1906)/төз., текст., иск. һәм аңл. Әзерл. З.Р.Шәйхелисламов.-2015.-415 б.
3. Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы.- Казан:Татар.кит. нәшр., 2003.-271б.
4. Гайнанова Л. Ни өчен Тукайның беренче китабы басылып чыкмаган?// Татарстан.1998.-№7.- 86-87 б.
5. Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра: әдәби тәнкыйть, хикәяләр.-Казан: Татар.кит. нәшр., 2003.-192 б.
6. Гыйләҗев Т. Тукай – тәнкыйтьче//Мәгариф.-2011.-№4.-9-11б.


## ТЕЛЕБЕЗНЕН КИЛӘЧӘГЕ-БЕЗНЕҢ КУЛЛАРДА


Фәтхуллина А.
Алабуга шәһәренең Инженер-технология лицее укучысы.
Фәнни җитәкче: Агмалова Э.Э.


Әйе, телне бөек хәзинә, байлык, диләр. Ә табигатьтәге һәрнәрсә үз урынында, үзенчә байлык түгелмени? Һәркайсының үз үлчәү-бәяләү берәмлеге.

Җәмгыятьтә урын тоткан һәр тел турында, бәлки, гади генә итеп болайрак әйтеп буладыр: тел - ул иксез-чиксез, төпсез-кырыйсыз, хисапсыз-бәясез...

Ә үзебезнең татар теле дип йөртелгән Туган телебез ни хәлдә соң бүген? Заманында халыкара телләрнең берсе булган, хәзерге көндә дә бөтен дөнья күләмендә сөйләшер, аралашыр өчен уңай 10-15 тел арасында саналган, җәмгыять яшәеше барышын бөтен тулылыгы һәм нечкәлекләре белән чагылдыра алырлык бихисап сүз байлыгы булган Ана телебезнең бүгенгесе ничек тә, киләчәге ничегрәк булырга охшый? Сораулар катлаулы һәм авыр.

Әгәр телне милли үзаңны билгеләүче бер төп күрсәткеч, дип саныйбыз икән, безнең хәлләр бүгенгә мактанырлык түгел. Халкың тулысы белән үз телендә сөйләшә икән, ул — тулы милләт, яртысы сөйләшә икән - ярым-йорты милләт, ә биштән бере сөйләшсә...

Ананың балага биргән иң зур бүләге - тел. Шуңа да ул байлык, хәзинә санала. Ә бүләкне, байлыкны, хәзинәне кадерләп саклый алу, кубәйтә-ишәйтә алу үзе бер батырлык сорый. Файдасын күреп яши белмәгәндә, тиз исраф итү, югалту бик җиңел аны. Һәр халык үз тарихын, үз рухын, җыр-моңын сакламакчы, үзенең яңа токымнарына тапшырмакчы. «Теле барлар халык булган, теле юклар балык булган» дигән сүзләр юктан тумаган. Әлбәттә, иҗтимагый күренеш буларак, тел объектив кануннарга буйсынып яши. Субъектив факторның, хәтта бик теләгәндә дә, роле ул хәтле зур була алмый. Әгәр тел сау-сәламәт икән, ул телдә җәмгыятьнең бөтен катламнары сөйләшә: ил башы да, бомж да, сырхау кеше дә, мәхбүс тә, шагыйрь дә... Тел үзенең иҗтимагый функциясен тулы кимәлдә башкара алганда гына мөмкин хәл бу. Әгәр тел кешенең тормыш ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә алмый икән, ул аны кирәксенми, яхшы дигәндә дә, аңа битараф кала.

Тел - диңгез. Бер ясканып кына аның тирәнлегенә төшеп, киңлекләрен иңләп бетереп булмас. Күңелдә сызланып йөргән уй-зарларны бер читкәрәк куеп, «ниләрэшләргә, ни гамәлләр кылып була» дигән сорауларга җавап эзләп карау дөресрәктер. Китапта безнең тарих, безнең тел, безнең язмыш. Китап - татар өчен яшәү символы ул! Тел хәзинәсе сагында торган язучыларыбыз моны яхшы аңлый. Татарстанның халык язучысы Н.Фәттах болай язган: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китапларязарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым». Мондый хис әдипләрдә генә түгел, үзен татар дип санаган һәр кешедә булырга тиеш!

Киләчәкнең башы бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнендә -
оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
матур итеп туган телеңдә!

Әдәбият
1.Әдәплелек дәресләре.-Казан: Мәгариф,2000. –103б.
2.“Түгәрәк уен” журналы. – 2011, - №1.

# РАФИС КОРБАН ҺӘМ РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ

Хадиев А.Р., “Университет” гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Сәхәбиева Г.Х.

Татар әдәбияты тарихында Габдулла Тукай иҗаты аерым урын алып тора. Ул – татар шигъриятенең генә түгел, милләтенең дә символы. Шуңа күрә бүгенге көндә дә аның тормышы, иҗаты шагыйрьләр күңелендә илһам уты кабыза. Рафис Корбанның “1913 ел. Апрель. Тукай” шигыре дә шундый илһам нәтиҗәсе. Шигырь Тукай тормышының бер өлешенә – соңгы көннәре, иҗатының бөеклегенә багышлап язылган. Әсәрдә авыру, якынлашып килүче үлем мотивлары өстенлек итә. Текстта сүзнең авыру шагыйрь турында баруын искәртеп ютәл, чахотка, тын бетү кебек сүзләр еш кулланыла:

Китәр чахоткалы черек яздан
Һәм һәр язда кайтар сагынып [Корбан, 2004: 83].

Рафис Корбан Габдулла Тукай иҗатына күзәтү ясагандай, шагыйрь шигъриятендә әйдәп баручы мотив булып мәхәббәт, пейзаж түгел, ә бәлки халык тормышы, аның авыр хәле, мәнфәгатьләре, авырлыктан коткару юллары тора дип белдерә:

Бар шатлыгың – халкым, халкым, диеп,
Күкрәгеңдә тибә асыл кош [Корбан, 2004: 83].

Әсәрдә Габдулла Тукай иҗаты белән интертекстуаль бәйләнешләр дә күзәтелә. Мәсәлән, шигырьдә мондый юллар бар:

Тик тарсынып тимер читлек эчен
Канаткан ул көчле канатын [Корбан, 2004: 83].

ГабдуллаТукайның “Өзелгән өмид” шигырендәге юлларга күз салыйк:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да җиһангаят яраткан Раббысы [Тукай дөньясы, интернет-ресурс].

Тукай үзен җиһангаят яраткан дигәндә, биографиясенең әрнүле-кызганыч сәхифәләрен, әнисеннән, әтисеннән аерым, үги булып үткәрергә мәҗбүр булган балачак елларын күз уңында тота; милләт алгарышы өчен күпме көрәшеп тә башкарган эшен азсына. Тормыш, тарихи сәбу эшнең зур, нәтиҗәле булуын күрсәтә. Ят җиһан бүгенге көн шагыйре тарафыннан тимер читлек, дип атала, ә шушы тормыш белән көрәшүне – канатны канату гыйбарәсе аңлатыпкилә. “...Һәр язда кайтыр сагынып” [Корбан, 2004: 83] юллары белән язучы апрель саен Габдулла Тукай туган көненең кадерләп уздырылуы, тантаналы чаралар оештырылуын ассызыклый.

Роберт Миңнуллинның “Тукайга багышланган күргәзмәдә” шигырендә атаклы шагыйрь иҗаты турында тәфсилле мәгълүматлар, лирик геройның татар милләте хәятендә ГабдуллаТукайның роле турындагы лирик-фәлсәфи уйланулары юк. Лирик герой күргәзмәдәТукайга багышланган картиналар арасында йөри һәм кызыклы нәтиҗәгә килә: Тукай сыннары, рәсемнәренең күплеге гаҗәеп түгел, чөнки һәр татар улы-кызының үзТукае була:

Һәркемнең үзТукае шул
Беркемгә дә биргесез!
Эзлим мин дәТукаемны –
Ул әлегә билгесез [Миңнуллин 2007: 393].

“Әллүки” шигырендә Роберт Миңнуллин интертекст кулланып укучысын Габдулла Тукайга һәм аннан да ераграк кайчандыр бөек татар шагыйрен “Әллүки” әсәрен язарга этәргән беренчел чыганак – халык җырына илтә:

Моң агыла, моң кагыла җанга –
Әллә тылсым инде, әллә көй?!
НәкъТукайны тетрәндергән кебек,
Тетрәндерә мине “Әллүки”!

Роберт Миңнуллинның “Әллүки” шигыренең лирик герое фикеренчә, әллүки бөек татар шагыйренең күңелен һәм иҗатын, шулай УК халыкның тарихын һәм аның көчле рухын аңлауга ачкыч булып тора. Тукай Роберт Миңнуллин өчен, беренче чиратта, халыкның күңеленә тирәнтен төшенгән шагыйрь. Үзенең кыска гомере эчендә ул уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен халык күңелендә гасырларга калырлык итеп белдерә алган, ә Роберт Миңнуллинның “Тукай минем яшьтә үлгән...” шигыренең лирик герое Тукай яше белән “кыенсына-кыенсына” саубуллашырга мәҗбүр. Моны аңлау лирик геройны кырыс үзбәягә китерә, чөнки Тукай аның өчен үзенә күрә санау ноктасы, әхлакый һәм поэтик камертон булып тора:

Төбәп карый күңелемә
Рәсеменнән япь-яшь даһи –
Минем яшьтә җиткән аңа
Даһи булыр өчен бакый!
Ә мин янам, янам, янам...
Юк әлегә башка чарам.
Кыенсына-кыенсына,
Тукай яшен узып барам.

Шул рәвешле, хәзерге татар шигърияте вәкилләре Рафис Корбан һәм Роберт Миңнуллин Габдулла Тукай шәхесе һәм шигърияте белән даими диалогта торганнар. Әсәрләрендә аның кабатланмас образын тудырырга омтылганнар.

Әдәбият

1. Батулла Р. Апуш – Тукай (кыйсса) // Казан утлары. – 2011 – № 4. – Б. 6 – 89.
2. Корбан Р. Яра: шигырьләр, җырлар, тәрҗемә әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 282 б.
3. Миңнуллин Р. Әсәрләр. 7 томда. 1 нче т.: шигырьләр, тәрҗемәләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2007. – 575 б.
4. Тукай дөньясы. “Өзелгән өмид”. – URL: Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. Т. 2. Шигырьләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2006. – 367 б.

# ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ Ф. ЯРУЛЛИН ӘСӘРЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ

Хәбибрахманова Ф.Б. Арча шәһәренең
Г.Тукай исемендәге Арча
педагогия көллияте студенты.
Фәнни җитәкче: Нуриева М.А.

“Әдәби уку”– башлангыч мәктәптә төп гуманитар предметларның берсе, чөнки укучы әдәби уку ярдәмендә башка предметларны да үзләштерү мөмкинлегенә ия була. Бу фән кече яшьтәге мәктәп баласына һәрьяклы белем бирә. Укучының аңы дөньяны дөрес күзаллый алырлык уяу була. Бары тик югары аң тәрбияләп кенә әйләнә-тирәне дөрес аңларга өйрәтергә мөмкин.

Ф. Яруллин әсәрләре балаларга гына түгел, өлкәннәр өчен дә тәрбияви чыганак булырлык көчкә ия. Язучының әсәрләре башлангыч сыйныфлар программаларына ук кертелгән. Иҗатын өйрәнүгә бик аз вакыт бирелүгә карамастан, бүгенге кырыс заман таләпләре, нәкъ менә Ф. Яруллин кебек әдәп-әхлак, намус, вөҗдан, туган телебез, табигатебез, халык язмышы турында борчылып язган автор иҗатын өйрәнүне көнүзәк мәсьәләләргә куя.

Фәнис Яруллинның сабыйлар, нәниләр һәм мәктәп балалары өчен язылган әсәрләре сан ягыннан бик күп, сыйфат ягыннан – бик тә үзенчәлекле.

Автор балаларның рухи дөньясын, уй-кичерешләрен, катлаулы максат-хыялларын, психологиясен, аларның фикерләү үзенчәлекләрен, бик яхшы белә, сизә, тоя. Әсәрләрен язган вакытта ул үзен нәкъ балаларча тота белә: урын өстендә булуына карамастан, Фәнис Яруллин шул сабый-нәниләр белән бергә уйнап, көлеп, йөгереп йөргәндә яки рәхәтләнеп алар белән сөйләшеп утырганда, мавыктыргыч әңгәмә корганда язадыр сыман.

Ф. Яруллинның балалар өчен язган шигырьләре укучыларны балачагына кайтара, уйландыра; сагыш рәшәләренә алып кереп китә; күктәге салават күперләре буйлап йөгертә. Аның шаян шигырьләре рәхәтләнеп көлдерә; тирән эчтәлекле хикәяләре дөньяның гыйбрәтле хәлләрен йөрәк аша уздырырга ярдәм итә.

Язучының әкиятләре, башка авторларныкыннан аермалы буларак шигъри телле, образлы сөйләмгә бай булулары белән аерылып торалар. Әкиятләрендәге эчке рифмалар, вакыйгаларның үсә барып, герой рухы белән укучы җанының берләшүе әкиятләргә сихри күтәренкелек бирә, әкият геройларының тышкы кыяфәтләрен сурәтләгәндә образлык өстенлек итә.

Әкиятләрнең функциясе, хикәяләрдән аермалы буларак, мавыктыру, баланың хыялын үстерү, күңелен баету, гаделлеккә омтылу хисләрен көчәйтү, гаделлеккә бару юлындагы каршылыклы киртәләрне җимерүдә акылның, зиһеннең, хәйләнең, тапкырлыкның, батырлыкның кеше тормышында никадәр зур роль уйнавын бала җанына сеңдерә барудан гыйбәрәт. Әкияткә тирән фәлсәфә дә, сабыйларча беркатлылык та сыя. Аның әкиятләрендәге үзенчәлек – ул тормышчанлык, ягъни аның әкиятләре, күпчелек очракта, хикәягә тартым булуны әйтергә кирәктер.

Ф. Яруллин экиятләрнең башлам өлешенә зур игътибар бирә. Аның иҗатында бертөрлелектән качарга тырышу бар. Язучы экиятләрендә ялкаулар, алдакчылар, кире беткәннәр һичбер вакыт максатларына ирешә алмый.

Фәнис Яруллин әсәрләре башлангыч сыйныф программасында бик сирәк очрый диярлек. Күбесенчә шагыйрьнең әсәрләре әдәп-әхлак, яхшылык, әти-әниләр турындагы бүлекләрдә очрый.

Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәпләренең 1-4 нче сыйныфлары өчен атар әдәби уку дәреслекләрендә:

төзүче авторлары: Г.М. Сафиуллина, Ф. Хәсәнова, Г. Мөхәммәтҗанова.

Беренче сыйныфта Фәнис Яруллинның “Саескан” әкияте, “Хыялый чебеш” шигыре өйрәнелә.

Икенче сыйныфта “Белмәмештә кунакта” бүлегендә Ф. Яруллинның “Ике кеше”, “Эшнең аның берние юк”, дәреслек-хрестоматияда “Яз”, “Композитор чыпчыклар” шигырьләре бирелгән.

Өченче сыйныфта Ф. Яруллинның “Хәйләкәр куян”, “Мактану бәласы”, “Тылсымлы ачкыч” әсәрләре укыла.

Дүртенче сыйныфта “Буар елан” әкияте тәкъдим ителә.

Галимнәр, дәреслек авторлары тарафыннан әлеге әсәрләр бик уңышлы сайланган. Ф. Яруллинның бу әсәрләрендәге гади, аңлаешлы, тасвирлаулы, төзек, логик шигъри телле нәни укучысының сөйләм телен үстерүгә, камилләштерүгә һәм баетуга зур өлеш кертә. Әлеге әсәрләрнең төп үзенчәлеге шунда ки, алар балалар психологиясен, күңел серләрен бик яхшы белгән безнең заман шагыйре тарафыннан иҗат ителгәннәр.

Фәнис Яруллин иҗаты әдәби уку (башлангыч сыйныфларда) дәресләрендә тирәнтен өйрәнелми, әлбәттә, моның өчен вакыт та җитмәс иде. Шуңа күрә Фәнис Яруллинның тормыш юлын һәм иҗатын сыйныфтан тыш чараларда да тирәнтен өйрәнүне дәвам итәргә мөмкин.

Шулай итеп, әдәби уку дәресләрендә Ф. Яруллинның әсәрләре белән танышу – бик әһәмиятле һәм кызыклы эш. Бу эш зур осталык таләп итә. Әһәмиятле, чөнки язучының шигырьләрен укып, балалар үз туган теленең матурлыгын, тел бизәкләрен тоярга өйрәнә, үз иленең патриоты булып үсәргә омтыла, туры фикерле, юмор хисен аңлаучы булып тәрбияләнә. Лирика дөньясындагы аһәңлелек, юмор дөньясындагы осталык серләренә төшенергә дә автор әсәрләре ярдәмгә килә. Аның тормышы да балалар өчен үрнәк, аның дөньясы серле, үзенә тартып тора.

Әдәбият

1. Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фында эшләүче укытучылар өчен дәреслек . – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2013. – 215 б.

2. Г.М.Сафиуллина, Ф.Ф.Хәсәнова, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова: рәссамы Ф.Ризаева. Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 3 нче с-фы өчен д-лек. 1 нче кисәк. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2013. – 135 б.

3. Ф. Яруллин. Серле дөнья: экиятләр, хикәяләр һем повесть/ Ф.Яруллин – «Матбугат йорты» нәшр., 2013. – 464 б.

# ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ С КОМПОНЕНТОМ «САРЫ/YELLOW» («ЖЕЛТЫЙ») В ТАТАРСКОМ И АНГЛИЙСКОМ ФОЛЬКЛОРЕ

Хусаенова А.С.
МБОУ “СОШ №7” г.Набережные Челны
Научный руководитель: Миннахметова Р.Р

Символика цветов во многих языках, особенно европейских, схожа, и это частично облегчает их понимание. Многие цветовые символы пришли к нам из далёких времён. И, может быть, раз они так долго сохраняют своё значение, стоит задуматься о глубине культурного наследия человечества, величии любого языка.

В татарской и английской фразеологии также получила отражение народная символика цвета.

Желтый цвет во фразеологии встречается крайне редко. Преобладание отрицательных значений в семантике этого цвета можно объяснить неприятными ассоциациями, возникающими в сознании человека. С другой стороны, негативное отношение к желтому цвету сложилось ещё в древности. В исследуемых текстах татарского и английского устного народного творчества фразеологизмы с желтым цветом встречается редко. В татарском фольклоре, в основном, в значении *сохнет/саргая* (лицо становится желтым):

Карчыга йонын коядыр,
канатларын кагынып;
Бәдриҗамал *саргаядыр,*
үз әнкәсен сагынып.”/
Бадриджамал сохнет (букв. *желтеет***)**, тоскуя по своей матери.

(“*Җиде кыз бәете*”. Ф.И.Урманче. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр).

“Кич утырып каләм юндым
Бохараның камышыннан,
Ак йөзләрем *сары булды* (букв. стало желтым)
Сагынуныңсагышыннан.”

*(“Ак йөзләрем сары булды*”. Ф.И.Урманче. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр)

Йөрәккәйләремне *сары алды* (җыр). (Урманче Ф. И. Татар халык иҗаты).

Ишекләрдән кердем мин ай кебек
Сыгылып сәлам бирдем тал кебек,
Сез кодаларым килеп кергәч,
*Җаным эреде сары май кебек* (букв.душа растаяла, как желтое масло) (*“Безнең илдә сезне мактыйлар” И.Н.Надиров.*).

Ялгыз кыз бик сагына, бик *саргая (Каракош // Татар халык әкиятләре / төз.: Хәмит Ярми, Халидә Гатина)*

*Сабыр төбе–сары алтын* [Мәхмүтов 1987: 339].

Сафура – *сары* ком буранын кубара (әйтем)
Хәлләрен ничек белермен, йокыда төштә күрермен,
Читтә *саргаеп үләрмен*, ерак китте газиз башым.”

[Урманче 2000: 124].

Кич утырып каләм юндым Бохараның камышыннан,
*Ак йөзләрем сары булды* сагынуның сагышыннан [Урманче 2000: 125].

Сагынудан *сары булды ак чыраем,*
Туган илгә истәлеккә ни бирәем.” [Урманче 2000: 126].

Күгәрченем, сиңа әйтәм, тыңла минем сүземне;
Мәгълүм ит туганнарыма: *сары басты йөземне.*
Сагыну хәле кыен эштер, йөзләремне *сары алмыштыр*
Балалардин аерылу пәйгамбәрләрдин калмыштыр.
[Урманче 2000: 126].

Ялгыз ана уйлый-уйлый йөзенә *сарылар төшкән,*
Ананы һич онытмагыз, күкрәк сөтен имезеп үскән.
[Урманче 2000: 141].

Тәмам *саргайды* инде. Бабай кайтты. Кайтты да күрде – егет *саргайган(Татар халык әкиятләре “Мәрмәр тавы башында”)*[Ярми 1990: 378].

Ялгыз кыз бик сагына, бик *саргая (Татар халык әкияте “Каракош”)*

Желтый цвет в некоторых фразеологических единицах английского языка обозначает отрицательные качества человека: yellow dog – (букв.«желтая собака») – подлый, трусливый человек, to have a yellow streak (букв. «чтобы была желтая полоса») – речь идет о трусливом, робком человеке.

Цвет выступает для человека как одно из элементарных и одновременно значимых зрительных ощущений. Цветовое восприятие объектов окружающего мира является важным аспектом познавательной деятельности человека. Названия цвета, выступающие стержневым компонентом многих фразеологических оборотов, характеризуются древностью происхождения, широкой употребительностью, многозначностью и большими сочетательными возможностями. В силу своей семантической природы они привносят во фразеологизмы эмоционально-экспрессивное качество и образность.

**Литература**

1. Английская сказка Jackthe GiantKiller (Джек-убийца великанов) [электронный ресурс] URL:https://tonail.com/английская-сказка-jack-the-giant-killer/ (дата обращения: 04.10.2023).
2. Грин Ю. 10 цветных идиом английского языка [Электронный ресурс] URL: https://preply.com/ru/blog/10-tsvetnyh-idiom-anglijskogo-yazyka/ [дата обращения: 29.09.2002]
3. Литвинов П.П. Англо-русский словарь наиболее употребительных фразеологических выражений. – М.:”Яхонт”, 2001. – 400 с.
4. Надиров И.Н., Абдуллин Я.Г., Госманов М.Г. Татар халык авыз иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 562 б.
5. Урманче Ф.И.. Тарих мең дә сигез йөз дә: Бәетләр, мөнәҗәтләр. – Казан: Мәгариф, 2000. – 143 б.
6. Ярми Х.Татар халык әкиятләре / төз.: Хәмит Ярми, Халидә Гатина. – Казан: Раннур, 1999. –442 б..

# АЛАБУГА ТӨБӘГЕНДӘ ЯШӘҮЧЕ ШАГЫРЬЛӘРЕБЕЗ

Хуҗина З.А.
Алабуга шәһәре 8 нче урта мәктәп укучысы
Фәнни җитәкче: Шакирова Л.М.

“Алабуга төбәгендә яшәүче шагыйрьләребез” дип исемләнгән бу хезмәтнең тамырлары бик тирәнгә барып тоташа,чөнки күп еллардан бирле милләтебез өчен көчләрен кызганмыйча яшәгән шәхесләребез бар. Алар тыйнак кына үз эшләрен намуслары кушканча башкара. Бүтәнчә булдыра да алмыйлар. Шуларның берничәсе турында әйтеп китәсе килә.

Алабугабыз тарихында үз эзләрен салучы бу шәхесләр аның бүгенгесе, үткәне, киләчәге белән кызыксына.Халыкның яшәеш шартлары өчен, сәламәтлеге өчен борчыла.Кулларыннан килгәнне милләте өчен эшләп калдырырга тырыша.

Гөлзадә Хаҗи кызы  Әхтәмова

Үз исемнәрен халык күңеленә салып килүче тыйнак һәм тырыш шәхесләр була. Без Гөлзадә апаны шундый шәхесләр исемлегенә кертер идек, чөнки Алабуга, аның тирә-юнендә яшәүчеләр өчен күпме игелек орлыкларын чәчеп яши белде ул.Үз-үзен тотышы, кешеләргә карата игътибарлы булуы аны башкалардан аерып торды.Үзе белгән кешеләргә карата да аерым якын мөнәсәбәттә булды ул.Үз итеп, яратып эндәште,күңелләренә үз юлын сала белде . Аның белән сөйләшүе дә,аралашуы да шуңа бик  җиңел һәм рәхәт.

Күпме шигырьләр, поэмалар иҗат итте. Әле һаман иҗат эшендә ул. Армый- талмый эшли,яңа әсәрләр тудыра. Бу кадәр көчне Аллаһ үзе аңа бүләк иткәндер. Аның әсәрләре дә үзенә тартып тора, чөнки алардан үзгә бер җылылык бөркелә. Укыган саен яңа ягы белән ачыла алар. Халкына әйтер сүзен шулай гади генә итеп җиткерә ала шагыйрә

Гөлзадә апаның Алабуга тарихына кагылышлы  хезмәтләрен генә алсак та ,аларда моңа кадәр әле тарихта билгеле булмаган мәгълүматлар тупланган. Нинди генә кичә яки үткәрелә торган башка чара булмасын ,син аларсыз әйтәсе сүзеңне дәлилләп бетерә алмыйсың. “Тукта, бу турыда Гөлзадә апа ничек дип әйткән иде?”- дип шуларны кабаттан укый,өйрәнә башлыйсың. Ә шагыйрәнең үзенә боларны туплау һәм дәлилләп язар өчен  никадәр хезмәт куярга кирәк булгандыр...

Гөлзадә апа бер дә тик торуны белми. Яза,газета битләрендәге шигырьләрендә халкына, туган җиренә карата ул гына әйтә белгән фикерләр чагыла.Үз гомерен халкына хезмәт итүгә багышлаган шәхесләр, беләм, башкача яши алмыйдыр. Аллаһыбыз аларга башка көч һәм яшәү максаты сайлаткан. Һәр көн үтә торган юлларыннан да кешеләргә әйтерлек фикерләр эзләтә, аларны башкаларга җиткерә алырлык илһам бирә.Гөлзадә апага шундый язмыш бирелгән[Әхтәмова 2020:74].

Фәридә Нургали  кызы Хәбибрахманова

Арча төбәгендә Нургали һәм Хәмдия гаиләсендә өченче бала булып, кечкенә бер кыз дөньяга аваз сала. Аңа Фәридә дип исем кушалар. Фәридә -

берданбер, алтын, көмеш, зөбәрҗәт мәгънәсендә аңлатыла. Ул кечкенәдән үк әнисенең беренче ярдәмчесе була.

Тормыш Фәридә Нургали кызын уңнан да, сулдан да сыный. 3 яшьтә әтисез, 15 яшьтә әнисез кала ул, ләкин сынмый, сыгылмый.

Аның иҗат юлы мәктәп елларыннан ук башлана. 3 нче сыйныфта язылган беренче шигырен "Яз килде" дип атый. Яшүсмер чагында язылган "Яшьлек", "Такмаклар" исемле шигырьләре укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. 1986 нчы елда Татарстан радиосыннан аның "Йөрәгем белән сөйләшү" шигырен Ирек Баһманов укый.

Мәктәпне тәмамлау белән, Алабугага мәдәният училищесының китапханә бүлегенә юл тота һәм ныклап белем алырга керешә.

Диплом алгач, яшь белгеч туган ягына, Арчага юл тота. Ул район мәдәният бүлегенә эшкә урнаша. Башта методист, аннан соң инспектор булып эшли.

Төрле конкурсларда, җәмәгать эшләрендә, үзешчән сәнгатьтә катнашырга да вакыт таба. Егерме елдан артык "Рәйхан" ансамблендә катнашып лауреат исемен алуда зур тырышлык куя. Ул ансамбль белән Төркиягә кадәр барып җиттә. Төрекләр аны иң чибәр ханым дип, аңа югары бәя бирәләр.

Фәридә Нургалиевна ун елдан артык "Чулман" әдәби берләшмәсен җитәкли.Шуның өстенә әле ул "Бердәм Россия- хатын-кызлар клубы" каршында оешкан Татар хатын-кызлар клубы "Ак калфак"ның да җитәкчесе. "Мәйдан" журналы хезмәткәрләре белән очрашуда да актив катнаша. Училищеда китапханә бүлеге мөдире, өйдә яраткан хатын, әни, дәү әни барысына да җитешергә каян көч ала торгандыр дип, кайчак шаккатып куясың.

Фәридә Нургали кызының шигырьләре тормышка, табигатькә мәхәббәт, лирикага бай. Шигырьләре кыска булса да тирән мәгънәгә ия. Ул аларда туган ягын сагыну, гомер, язмыш, табигать турында уйлана. Укучысына үз фикерләрен җиткерә[ Әюпов 2011:11].

Фазыл (Фердинант улы) Шәех

Алабуга шәһәре. Чулман буйлары. Ак мәчетебез. Аларның исеме белән күпме кешенең язмышы бәйләнгән. Фазыл Шәех тә шуларның берсе.Тормышында килеп туган авырлык аны шушы җир белән бәйли.Һәм ул монда яшәп кала.Сукырлар җәмгыятендә эшли башлый һәм шунда хезмәт юлын дәвам итә. Иҗаты да шулар белән бергә үрелеп бара. Күңел күзе белән күргәннәрен шигырь юлларына күчерә.Язмыш сынаулары адында югалып калмаган шәхес рухи яктан үсә, камилләшә бара.

Алабуганың язмышына шулай аның да язмышы килеп бәйләнә.Шәһәрдә барган бер генә вакыйгадан да читтә калмый ул, бер генә яңалыкны да битараф кына кабул итми. Яза, эзләнә, үз фикерен башкаларга җиткергә тырыша.Һәр нәрсәгә карата үз сүзен әйтә белә торган шәхес булып өлгерә.Гаилә кора,кызын тәрбияләп үсерә.Татар иҗтимагый үзәгенә йөри. Аның эшчәнлегенә актив катнаша.Татар халкы яшәсен,телен үстерсен өчен канатланып иҗат эчендә кайный.

Фазыл Шәехнең шигырьләре тупланган җыентыклар да бүген шәхси китапханәбезне тулыландырып тора. Алар безне туган илебезне, халкыбызны, гореф-гадәтләребезне яратырга өйрәтәләр. Халыкның гореф-гадәтләре яшәгән җирдә генә киләчәк көнебезгә ышаныч,яшәвебезгә өмет яши.Гыйлемле булып,гыйлем алырга омтылып торуыбыз да моның төпле дәвамы булып тора.

Алабуга шәһәре, аның һәр урыны,шагыйрьнең йөрәк тибеше белән бәйле. Шуңа алабугалылар зур игътибар,олы ярату белән искә алалар аны.Язылганнары укыла,шигырьләре ятланыла,иҗаты барлана, мәктәпләрдә аңа багышланган әдәби кичәләр, викторина, аның шигырьләрен сәнгатьле сөйләү бәйгеләре үткәрелә...

Ф.Шәех әдәбиятка ашыкмыйча,кабаланмыйча шигъриятнең көчен,укучыларга тәэсир итешен төшенеп җитеп килә.Ул кирәгеннән артык катлаулы шигъри детальләр эзләп язмый.Гади,әмма игътибарны җәлеп итә алырдай бизәкләр табып иҗат итә.Туктаусыз уйлана эзләнә [Шәех 1996:5].

Татар теленең бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшкәндә, язучылар, шагыйрьләр, аларның иҗатын өйрәнү үзгә бер әһәмияткә ия.

Һәрберсенең үз язмышы, үз иҗаты, халкына әйтер үз сүзе. Ул сүзләр һәрберебезнең йөрәгенә барып җитәргә дә тиеш. Шуңа күрә бу эшебездә Алабуга язучылары һәм шагыйрьләренең иҗатына тукталдык. Алар янына Алабугада яшәп, аның халкының сәламәтлеге өчен көрәшкән шәхес - Алабуганың бердәнбер хатын – кыз хирургы – Тәския Мөхәммәт кызы Сабированы да өстәдек. Чөнки кемдер сүз белән, кемдер кулына скапель тотып яшәү өчен көрәшә.

Нинди генә һөнәрдә булса да, алар милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында көрәшүчеләр[ Шәех 1996:5].


Әдәбият

1.Гөлзадә Әхтәмова “Зәңгәр хыял”, 2000, 74-75б.
2.Әюпов Дамир “Каршылыклы язмышлар”,Алабуга, 2011, 11 с.
3.Фазыл Шәех “Дала тулпары”, 1996, 5-6 б.


## ХӘЗЕРГЕ ЯШЬЛӘР ТОРМЫШЫНДА МАТБУГАТ ФЕНОМЕНЫ


Шайхетдинова К.Р.,
КФУ ның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.


Хәзерге вакытта да матбугат яшьләр өчен актуальлеген югалтмый. Әмма газета-журнал формасындагы иске матбугат түгел, ә интернеттагы матбугат популяр. Басма матбугат урынына акрынлап интернет матбугат килә. Бүгенге дөньяда интернетның роле шактый зур, әмма традицион массакүләм мәгълүмат чаралары үзяшәешен сакларга омтыла. Күп санлы технологияләр медиага зур йогынты ясыйлар. Хәтта күптән түгел генә киңкүләм мәгълүмат чараларында зур ачыш булган кебек тоелган телевизорлар, радио да акрынлап актуальлеген югалтабара. Телефоннар һәм компьютерлар өстенлек ала. Хәтта күп кенә

журнал-газеталар да басмада гына түгел, цифрлы мәйданчыкларда да бар.Ни өчен интернет матбугатны алыштырды?

Интернетның газета-журналларга һәм телевидениегә өстенлек бирүенең сәбәпләре шактый. Барыннан да бигрәк, бу интернетның мөмкинлекләре зур булуы белән аңлатыла. Шулай ук актуаль мәгълүматны интернетта бик тиз табып була. Басма матбугаттагы  яңалыклар укучыларга берничә көнгә соңга калып барып ирешә. Интернетта мәгълүматның күләме дәчагыштырмачазуррак. Бер генә телевизор да, газета-журналда да интернетта булган мәгълүмат юк. Интернет-чиксез мәйданчык. Интернеттагы мәгълүмат кулланучыга төрлечә бирелә. Басма матбугаттабез текст һәм рәсемнәр генә күрә алабыз. Интернетта шул ук мәгълүматны укып кына калмыйча, тыңлап, видеоматериаллар карарга, дуслар белән шунда ук фикер алышырга да мөмкин. Интернетның мөһимлеге - мобильлек. Газета-журналларны үзең белән йөртү дә уңайсыз, аларны зур күләмдә урамга яки башка урынга алып барып булмый. Интернетны дөньяның теләсә кайсы почмагында кулланырга мөмкин, мәссәлән: диңгездә, ял иткәндә, эштә дә.

Берничә ел элек яшьләр арасында иң популяр басмаларның берсе Elle Girl (Эль Герл) журналы иде. Журнал йолдызларның тенденцияләре һәм стиле, яшьләр брендларының яңа коллекцияләре һәм стилистларны сайлау турында язды; актуаль образлар булдыру, мастер-класслар, тематик шопинг-сайлауларны тәгъдим итте. Журналда сораштыруларда катнашырга, гороскоп белән танышырга, кызыклы һәм файдалы тестлар узарга, яраткан блогерлар һәм башкаручылар белән эксклюзив әңгәмәләр карарга мөмкин иде. Журнал яшьләр мәнфәгатьләренә игътибар һәм дизайн белән аерылып торды. Ләкин хәзерге вакытта бу журнал да бастырылмый, интернет сайтларында гына бар.

“ВПШ” (Бөтен хакыйкать шоу) - иҗтимагый бит яки, гадирәк әйткәндә, Вконакте социаль челтәрендәге паблик, ул 2014 елда барлыкка килгән. Басма башлыча блогсфера, сәясәт һәм мода яңалыклары турында яза. Берничә тапкыр блогерлар арасында конфликтларның беренче сәбәбе һәм эксклюзив мәгълүматның беренче чыганагы була. Бу пабликта иң популяр блогерларның шәхси тормышлары, аларның үзара элемтәләре турында фикер алышалар. Шулай ук “ВПШ” да блогерларның язылучылар ясаган фотолары куела. Интернетта яшьләр өчен бик күп кызыклы платформалар бар.

Газет-журналларда яшьләр өчен кызыклы булган материаллар тиз арада бастырылса, аларны җәлеп итәргәмөмкин булыр иде. Мәсәлән, социаль медиа яңалыклары, блогерлар, хәзерге артистлар турында яңалыклар. Хәзерге вакытта заманча блогерлар һәм артистлар,кызыклы постлар(мемнар), узара мөнәсәбәтләр турында постлар яшьләр арасында бик популяр.Әмма боларның барысында басма матбугатта бастырсаң да, матбугат интернетны алыштыра алмаячак.

Гомумән нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: интернет барлыкка килү сәбәпле, басма матбугат яшьләрнең кызыксынуын күпмедер дәрәҗәдә югалтты. Яшьләр өчен, мөгаен, беркайчан да басма матбугат интернетны алыштыра алмаячак. Заман үзгәрә, технологияләр үзгәрә, кешеләрнең кызыксынулары һәм ихтыяҗлары үзгәрә. Басма матбугат бар иде, булачак, ләкин ул ел саен

күпмедер дәрәҗәдә актуальлеген югалта, шуңа күрә матбугатны яшьләргә якынайту өчен яңа алым һәм чаралар эзләргә кирәк.

Әдәбият


1. "ВПШ" - что это за паблик? URL: https://fb.ru/article/323966/vpsh---chto-eto-za-pablik (мөрәҗәгать итү датасы: 19.10.2023).
2. Лисовский В.Т. Социология молодежи: СПб: Изд-во С.-Петербургского университета, 1996. 26 б.
3. Молодежная пресса в РФ URL: http://lemoon.ru/molodezhnaya-pressa-v-rf/ (мөрәҗәгать итү датасы: 15.10.2023).
4. ElleGirl - онлайн журнал для девушек | ELLEGIRL URL: https://www.ellegirl.ru/ (мөрәҗәгать итү датасы: 24.10.2023).


## ХӘЗЕРГЕ ШАРТЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ


Шайхетдинова К.Р.,
КФУ ның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.


*“Тел - халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын мең еллар буена үзенә сеңдереп килеп, безнең заманнарга җиткергән чиксез кадерле хәзинә”*

*Г.Б. Бәширов*

Тел – ул халыкның байлыгы, нәкъ телдә татар халкының рухы, җаны ята. Ләкин соңгы берничә елда шәһәр яшьләре арасында татар телен куллану көнкүреш дәрәҗәсендә һәм гаиләдә генә аралашу белән чикләнә, шәһәрләрдә төп коммуникатив функцияне рус теле башкара. Авыл җирлегендә татар теле төп аралашу теле ролен саклый, әмма урбанизация темплары һәм телнең авыл районнарында гына булуы телнең бөтен киңлекләрдә саклануына һәм үсешенә мөмкинлек бирми. Татар авылларында яшәүчеләр, белем алу, акча эшләү, перспективалар эзләү максатыннан, зур шәһәрләргә күченәләр.

Әлбәттә, массакүләм мәгълүмат чаралары турында онытырга ярамый. Татар телендә газета журналлар авыл җирлегенең өлкән буыны өчен актуальрәк булып кала. Әмма соңгы вакытта өлкән яшьтәгеләр дә, начар күрү сәбәпле, газетага караганда телевизорны өстенрәк күрә башлады

Туган телебезнең әкренләп юкка чыгуын аңлау бик күңелсез иде. Ләкин соңгы еллардатуган телебездә чаралар ешрак үткәрелә башлады.“Яңа Татар мәдәнияте” термины актив кулланыла. Аның күпчелек вакыйгалары Казанда бара. Яңа татар мәдәниятенең иң танылган проектлары: “Мин татарча сөйләшәм” – татар телен популярлаштыру акциясе. Ул Г.Тукайның туган көнендә үткәрелә. “Печән базары” – татар дизайны һәм шәһәр мәдәнияте фестивале. “Tat Cult Fest” – заманча музыка, сәнгать фестивале. “Ачык университеты”ның белем бирү проекты 2019 елда IT форумы һәм “Акыл фабрикасы” татар проектлары нигезендә булдырылган. Проект кысаларында өстәмә белем бирү курслары, төрле юнәлешләр буенча татар телендә лекцияләр

үткәрелә. Бу проектлар Бөтендөнья татар яшьләре форумы актив катнашында оештырыла һәм үткәрелә. Сәнгатьнең аерым төрләре һәм жанрлары буенча популяр проектлар: Яңа татар юморы КВН Татар лигасы “Әйдә, шаяРТ” һәм стэндап “Шалт, Мөхәммәтҗан”. “Моң” театр мәйданчыгы спектакльләрнең, перформансларның яңа формалары белән экспериментлар үздыра, сәнгать буенча лекцияләр үткәрә.

Моннан тыш, татар блоглары, “Вконтакте”, “YouTube” һәм башка платформаларда подкастлар актив үсеш ала. Алар арасында: “Татар көндәлеге”, “Кызык-Мызык”, “Татарча подкаст” подкасты, “Лимон”–“Ялкын” журналы подкасты, “UT” һәм башкалар. Курслар, яшь татар блогерлары мәктәпләре үткәрелә.

Теләге булган һәркемгә татар телен бушлай өйрәнергә тәкъдим итәләр. Әйтик, КФУ һәм республика мөселманнары Диния идарәсе вакыт-вакыт Бушлай татар теле курслары оештыра. Алар Казанда, Алабугада һәм Чаллыда уза. Олимпиадачыларны әзерләгән татар теле укытучылары өчен махсус грантлар бар.

Ел саен тәрбияләнүчеләр тел культурасын саклауга юнәлдерелгән муниципаль һәм төбәк конкурсларында катнашалар, мәсәлән: “Сәләтле бала”, “Мин яратам сине, Татарстан!”, “Сәяр-фест”, “Төрле халыклар бер республика”, “Нэни йолдызлар” һәм башкалар. Татар теле һәм әдәбиятына мәхәббәт спектакльләрдә, экиятләрдә һәм укучылар конкурсларында катнашу аша тәрбияләнә. Ел саен “Уңыш бәйрәме”, “Туган телем”, “Туган тел көне”, “Татар теле атналыгы” һәм башка традицион чаралар үткәрелә.

Җәйге ял вакытында балалар өчен “Сабантуй”бәйрәменең оештырыла. Яз көне “Нәүрүз”бәйрәме билгеләп үтелә. Туган тел көне үткәрелә. Бу көнне без туган телне һәм татар телен генә түгел, әбарлык укучыларның да туган телләрен билгеләп үтәбез. Туган телләрдә китаплар күргәзмәсе, рәсемнәр конкурсы, туган телдә укучылар конкурсы, ачык дәресләр оештырыла. Туган телдә иң яхшы укучыны сайлыйлар. Мондый бәйрәм туган телгә карата ярату һәм хөрмәт тәрбияләүдә мөһим урын алып тора.

Әлбәттә, татар теленең киләчәге яшь буынның нинди стратегия сайлавына бәйле: гаиләдә сөйләшәчәкме, уку йортларында өйрәнәчәкме һәм аны үз тормышының төрле өлкәләрендә кулланачакмы. Хәзер татар телен балачактан ук тәрбияләүнең бик күп ысуллары бар: балаларга экиятләр тыңларга, татар телендә мультфильмнар карарга, гаиләдә сөйләшергә, туган телдә хәбәрләр тыңларга, музыка тыңларга һәм башкалар. Барысы да үзебездән тора.

Әдәбият

1. Вопросы сохранения татарского языка // АНО “Татарский центр академической науки” URL: https://tat.center/research/voprosy-soxraneniya-tatarskogo-yazyka?utm_referrer=https%3A%2F%2Fyandex.ru%2F (мөрәҗәгать итү датасы: 13.10.2023).

2. Наил Гыйльман: “Будущее татарского языка все равно зависит от нас” // Интернет-газета “Реальное время” URL:

https://realnoevremya.ru/articles/253648-nail-gyylman-buduschee-tatarskogo-yazyka-vs-ravno-zavisit-ot-nas (мөрәҗәгать итү датасы: 18.10.2023).
3. Сохранение и развитие татарского языка глазами татарстанской молодежи: предложения и проекты //Oriental Studies URL: https://kigiran.elpub.ru/jour/article/view/1195(мөрәҗәгать итү датасы: 10.10.2023).

# “М.МӘҺДИЕВ ИҖАТЫНДА МӘДӘНИ МИРАС САКЛАНЫШЫ”

Шакирова И.И.
Арча районы Утар-Аты төп гомуми белем төп мәктәбе укучысы
Фәнни җитәкчесе: Касыймова З. Г.

Мөхәммәт Мәһдиев-безнең якташ язучыбыз, горурлыгыбыз, Татарстан Республикасының халык язучысы. Аның һәр әсәре белән әле танышып бетмәсәм дә, язучының “Без-41 нче ел балалары” әсәренең өзекләрен укыганнан соң, мин Мәһдиевиҗатын анализларга булдым. Үземнең максатым итеп, Мәһдиев иҗатында мәдәни мирас сакланышы кайсы яклардан ачыла икәнлеген ачыклауны куйдым. Нәрсә соң ул мирас? Ул кешедән кешегә, әби-бабайдан балаларга күчеп килүче иң кадерле әйбер. Димәк, мәдәни мирас дигәндә, без билгеле бер халыктан киләчәк буыннарга күчеп килгән, әһәмияткә ия булган мәдәни чараларны, гореф-гадәтләрне, традиция, йолаларны күз алдында тотабыз. Шулай ук бәйрәмнәребез дә безнең рухи мирасыбыз, байлыгыбыз булып тора. Мәдәни мирасыбызны без күз карасы кебек сакларга, өйрәнергә, киләчәк яшьләренә дә тапшырып калдырырга тиеш булабыз.

“Без-41нче ел балалары” повесте -Мөхәммәт Мәһдиевнең иң беренче әсәре.Анда сугыш чоры балаларының сугыш елларындагы белем алулары, җиңүгә керткән зур өлешләре, колхоз тормышы, авыл кешеләре сурәтләнә. Яп-яшь малайлар-кызлар, тырышып-тырышып укытучы булырга әзерләнәләр. Уку аларга җиңел генә бирелми, тамаклары туйганчы ашый алмау-иң үзәкләренә үткәне була. Ләкин 12-14 яшьлек балалар авырлыклардан куркып калмыйлар, чын егетләр-кызлар булып үсеп җитәләр, тормышта һәрберсе үз урынын таба.

Әлеге әсәрендә Мөхәммәт Мәһдиев татар халкына хас булган бик күп яшәү рәвешләрен сурәтли. Ул авыл кешеләренең йорт-җирләрен безнең күз алдына картина кебек китереп бастыра, табигатен олылый. Язучы без хәзерге вакытта музейларда гына күрә торган авыл мичен, анда ипи, коймак, бәлешләр пешерүне шулкадәр оста итеп яза, шул вакыттагы ризыкларны ашап карыйсы килә башлый!

Мин үзем дә авыл баласы, ләкин бакчада үсә торган бәрәңгегә игътибар да иткәнем юк!Бәрәңге сабагының исе була икәнен уйлап та караганым юк икән! Җәен печән җыйнау вакыты бездә дә бар, ләкин ул Мөхәммәт абый язып калдырганча түгел шул инде...

“Без-41 нче ел балалары” әсәрендә кызык та, кызганыч та булган урыннар бик күп. Мин, бик яратып, “Таңнар кайда да матурдыр...” бүлеген укыдым. Язучы бу бүлектә авыл тормышын тулысы белән ача. Авыл кешеләренең характерлары авылның табигатенә карап төрле була икәнен раслап бирә.

Мәсәлән, ул зур сулы авыллар белән сусыз авылларның халкын чагыштырып бирә. Урман буенда яшәгән кешеләрнең холкы бөтенләй башка була икән. Автор бик тәмләп авыл мунчасы, мунча миллеге әзерләүнең бөтен шартын яза.

Менә хәзер мәктәптә укучы егетләрнең күбесе сызгыра белми. Минем бу турыда уйлап та караганым юк иде. Булек белән танышкач, мин моның сәбәбен бик тиз аңладым, хәзер авылларда ат калмаган, ат көтәсе, ат эчертәсе юк икән. Шуңа күрә егетләр дә сызгырырга өйрәнми калалар икән!

Язучы үз әсәрендә авылларда сакланып калган төрле йолалар, гореф-гадәтләрне шулкадәр матур итеп сурәтли, бу йолаларны бүген дә уздырып карыйсы килә башлый. Көлдә бәрәңгене дә Мәһдиевчә пешереп ашыйсы килде, анысын этиемә кушарга булдым.

Язмамны да “Таңнар кайда да матурдыр...” әсәрендәге сүзләр белән тәмамлыйсым килә. Бу сүзләр буген дә бик зур әһәмияткә ия, дип уйлыйм мин.

“...Юк, мондый табигате булган, мондый чыдамлыгы булган халык беркайчан да, беркемгә дә кол булмас! Мондый таңы, мондый һавасы булган халык иң зур бәхеткә- ирекле, тук тормышка лаек”.

Әдәбият

1. М. Мәһдиев. Әсәрләр. 10 томда / Собрание сочинений. Том 10.-Казан: Татар китап нәшрияте, 2019.

## КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕН ҮСТЕРҮГӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

Шафикова Г.Ф.
Алабуга медицина училищесының 4 нче курс студенты.
Фәнни җитәкче: Шарипова З.З.

Кәрим Тинчурин татар милли культурасын үстерүгә зур өлеш керткән күренекле шәхесләр йолдызлыгында иң якты йолдызларның берсе булып җемелдәп тора. Драматург, прозаик, шагыйрь, журналист, педагог, режиссер һәм артист буларак, ул һәр өлкәдә югары уңыш яулый. Аның әсәрләре, һәр чын сәнгать җимеше кебек, бүген дә бик актуаль яңгырыйлар.

К. Тинчурин татар әдәбиятының кискен борылыш елларында иҗат итеп, аны классик драмалар, сатирик комедиялар, мелодрамалар, хикәяләр белән баетты.

Әсәрләрендә халык тормышындагы һәр әһәмиятле үзгәрешне, һәртөрле матур башлангычны вакытында күреп алып, бөтен көче белән яклап, аның үсүенә, ныгуына һәр яктан ярдәм итү, булышу К.Тинчурин иҗатының төп сыйфатларыннан берсе.

Әдип беренче хикәяләрендә кара реакция елларында вак буржуаз иллюзияләренең җимерелүен, вак буржуазия интеллегенциясенең аһ-зарын, куркаклыгын, өметсезлеккә бирелеп, демократик идеаллардан ваз кичүен, хәтта аерым өлешенең царизмага, реакциягә яраклаша башлавын чагылдыра. Интеллегенция вәкиле үзенең элекке идеалларына ышанмый башлаган,

тормышта аның бернинди максаты калмаган, ул инде хәзер “милләт” дип тә, “халык” дип тә лаф ормый. Аның хәзер бар эшчәнлеге гамьсезлккә, ваемсызлыкка бирелеп, әкият, тузга язмаган могҗизалар сөйләп күңел ачу, кәеф-сафа коруга кайтып кала [Тинчурин 1987: 252].

К.Тинчурин – комедия жанрында да чын оста. Бу яктан аның “Ак чирбик” (1915) хикәясе аеруча характерлы. Хосусый миллекчелек психологиясен тирән анализлап, автор татар мещаннарының вакчыл теләкләрен ача.

Тирән драматизмлы хикәяләр авторы буларак, К .Тинчурин “Хәкимҗан агай” (1916), “Искәндәр” (1917) хикәяләрендә беренче бөтендөнья сугышы фаҗигаләре аерым шәхесләр язмышы аша эмоциональ үтемле, тетрәндергеч экспрессив тасвирлый.

Язучының әсәрләрендә татар буржуазының холык-фигыле дә бик ачык чагыла: ул аларның вак җанлы һәм культурасыз булуыннан, тупаслыгыннан ачык көлә, контрреволюцион уйдырмаларны фаш итә, хурлыклы җиңелүләрен җанлы картиналарда сурәтләп бирә. Үзе өчен генә яшәүче вак җанлы интеллегентларны аяусыз тәнкыйтьли. Шул ук вакытта хезмәт халкы тормышындагы авырлыкларны тирән кичерә.

Татар сәхнәсендә музыкаль драма жанрын үстерүне хуплаган һәм бу юнәлештә күп эшләгән кеше Кәрим Тинчурин булды. Тамашачының музыкаль әсәрләргә сусавын һәм мәхәббәтен яхшы тоеп эш итте. Драматургия өлкәсендәге иҗаты белән дә, театр эшлеклесе, оста җитәкче һәм режиссёр буларак та, җырчы-артист сыйфатында да ул музыкаль драма жанрын нигезләүгә һәм үстерүгә үзеннән зур өлеш кертте.

Халык мәхәббәтен казанган үлемсез әсәр, татар җанының иң нечкә кылларын тибрәткән асыл пьеса – әлбәттә, “Зәңгәр шәл”. Утыз җиденче елда К.Тинчурин сәер рәвештә кулга алынгач, бу асыл пьеса хакында унтугыз ел буе беркем бер сүз дәшми [Тинчурин 2003: 178]. Тик шулай да аның исеме халык хәтерендә җуелмаслык булып калган икән. 1956 елда, Кәрим Тинчурин аклангач, “Зәңгәр шәл”не Шириуздан Сарымсаков сәхнәгә куя. Театр өчен күңелсез еллар була бу. Тамашачы спектакльләргә йөрми. Спектакль унбиш көн эчендә, элекке, иске костюмнар белән генә әзерләнә. Һәм гаҗәп хәл, тамашачы “Зәңгәр шәл”гә агылып йөри башлый.

Кәрим Тинчуринның тел-стиле шактый үзенчәлекле, хикәяләрендә бик уңышлы кулланылган сүрәтләү чаралары сөйләмне баетуда әдәби әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә зур роль уйныйлар.

Кәрим Тинчурин хикәяләренең теле гади, хикәяләрендә кулланылган чагыштырулар, мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр персонажларның фикерләрен төгәл итеп бирүгә булышалар. Аларны дөрес һәм урынлы куллану Кәрим Тинчурин стиленең үзенчәлеген билгели.

Йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: Тинчурин мирасы башкаручылык сәнгатендә, режиссерлар һәм драматурглар иҗатында да үзенең шифалы йогынты ясавын дәвам иттерә. Кәрим Тинчуринның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге әдип үзе исән чагында ук югары бәя ала. Бүгенге көндә исә аның әсәрләре еш укыла, сәхнәләштерелә.

Әдәбият

1. К. Тинчурин. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТаРИХ, 2003. – 495 б.
2. К. Тинчурин. Әсәрләр. 3 томда. 3 том. Проза, әдәбият-сәнгать турында мәкаләләр – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 512 б.
3. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе / Ф.М.Хатипов. – Казан: “Раннур” нәшр, 2002. 352 б.

## ТАТАР ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ.

Шайхутдинова А.Л.
Әлмәт шәһәренең 17 нче урта мәктәп укучысы.
Фәнни җитәкче: Махиянова Р.М.

Үз халкыңның улы яки кызы булу өчен аның гореф-гадәтләрен йолаларын, җыр-моңнарын, күп гасырлы тарихын, әхлак, тәрбия тәртипләрен ана сөте белән сеңдереп үсү кирәк. Татар халкында: Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс, - дигән гыйбарә яши.

Халык бәйрәмнәре – шул халыкны милләт итеп берләштерә торганчараларның берсе. Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык, милли хисләр культурасын тәрбияләргә ярдәм итеп кенә калмыйлар, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү дә тудыралар. Әгәр дә халык бәйрәмнәре югала, юкка чыга икән, бу инде аның рухи байлыклары саега баруын чагылдыра. Халык бәйрәмнәре һәр кешенең йөрәк түрендә саклана, чөнки җыр, бию, яңа көйләр башкару, очрашу – танышулар шушы көннәрдә була. Алар аны кайда гына булса да, үз авылына, төбәгенә тартып тора.

Кешелекнең иң зур байлыгын милләтләр тәшкил итә. Һәр милләт үз теле, мәдәнияте белән яшәешне бизи, баета һәм үзе дә башка халыклар белән аралашып үсә, алга китә.Мин үзем татар телен, халкымның йолаларын, гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен хөрмәт итәм. Минем авылда әби белән бабаем да бу бәйрәмнәр турында, гореф-гадәтләр турында сөйлиләр. Мәктәптә татар теле укытучылары бедән берлектә “Сабантуй”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы” кебек бәйрәмнәрне үткәрәбез. Шәһәребездә ел саен зурлап “Сабантуй”, “Нәруз”, “Карга боткасы”, “Ураза”,” Гает” бәйрәмнәре үткәрелә. Шуңа күрә мин миңа таныш һәм якын булган “Татар халык бәйрәмнәре.” дигән теманы алырга булдым.

Татар халык бәйрәмнәре ел фасылларына бәйле "Сабантуй”, "Нәүрүз”, "Сөмбелә”, "Карга боткасы”бәйрәмнәренә, ислам диненә бәйле "Корбан гаете”һәм "Рамазан” бәйрәмнәренә һәм каз өмәсе, балага исем кушу, яңгыр теләү, орлык чыгару кебек йолаларга бүлеп йөртәләр.Букүркәм традицияләр бик борынгы заманнардан ук, буыннан- буынга күчеп, безнең чорга килеп җиткәннәр.

Милли бәйрәм-”Сабантуй” бәйрәме турында язасым килә. Аның меңеллык тарихы бар. Сабантуй бәйрәме Идел буе Болгары дәүләтендә уздырылган булган. Идел буе Болгары Ислам динен кабул

иткәнче Мәҗүсилек чорында Сабан туеның максаты, мөгаен, уңыш рухларын юмалау белән, хәтта яңа елда яхшы уңыш булсын өчен булган, ләкин хәзер ул халыкның күңелен ачу максатыннан гына бәйрәм ителә.Сабантуй бәйрәме хәзерге вакытта язгы кыр эшләре беткәч, хезмәт бәйрәме буларак үткәрелә."Сабантуй" җитәргә 1-2 көн кала яшь егетләр һәр өйдән бүләк җыеп йөргәннәр. Өй саен кереп, бүләк җыюны сөрәнгә чыгу дип атаганнар. Ә сөрәнче – сабан туена бүләк җыючы булган. Безнең якларда яшь киленнәр сөрәнгә бик матур чигелгән сөлге, ә яшь кызлар күз явын алырдай итеп чигелгән кулъяулык биргәннәр. Яшь киленнәрдән алган сөлге иң кыйммәтлесе булып саналган. Килен аны шушы йоланы истә тотып, үзенең бирнәсендәге иң матур бизәкле сөлгедән әзерләгән. Яшьләр, бала-чагалар милли киемнәр киеп, гармунда уйнап, җырлап һәр бүләк биргән кешегә "Ай, рәхмәт" дип әйтеп йөргәннәр.

"Сабантуй" бәйрәменә тәмле ризыклар пешергәннәр, туганнары, дуслары кунакка килгән.

Сабантуй бәйрәмендә ат чабышлары иң абруйлы ярыш булып саналган Иң матур сөлгеләрнең берсе ат чабышындаҗиңүчегә бирелгән. Татарча көрәш, ат чабышы, йөгерү, сикерү кебек уеннар бикборынгыдан килгән. Соңрак капчык киеп йөгерү, капчык сугышы, чүлмәквату, колгага менү уеннары гадәткә кергән. Көрәшчеләр һәм җайдакларүзләренең көчен, осталыгын, батырлыгын күрсәтә торган булсалар,җырчылыр һәм музыкантлар бу бәйрәмдә үзләренең талантларын күрсәткәннәр.Хәзер дә бу бәйрәм заманча, зурлап үткәрелә. Авыл эшчәннәренең эшен мактау, зурлау, аларга рәхмәт әйтү белән башланып китә. Ә калган уен -көлке, милли уеннар традиция буенча үткәрелә.

Без дә мәктәптә уку елы ахырында "Сабантуй" бәйрәме үткәрәбез. Безнең бәйрәм чын "Сабантуй" бәйрәменнән аерылып тора, ләкин төп тарадицияне сөйләп күрсәтәбез. Безнең 17 нче мәктәптә төрле милләт балалары укый.Монда татарлар, руслар, чуашлар, таджиклар, керәшен татарлары да бар. Без үзара тату яшибез.Төрле милләтләрнең милли бәйрәмнәрен үткәрәбез һәм нинди милләт укучысы булуына карамастан бик теләп катнашабыз. Һәрбер укучы сабантуйда катнашып, үз сәләтен күрсәтергә тырыша.Кем бии, кем җырлый, кемдер ярышларда катнашып, үзенең көчен күрсәтә.

Татар халкының икенче милли бәйрәме - "Нәүрүз" бәйрәме турында язасым килә. Нәүрүз сүзенең мәгънәсе фарсыча "яңа көн" дигәнне аңлата. Нәүрүз көн белән төн тигезләшкән чорга – 21-22 мартка туры килгән.Нәүрүзҗиткәч, авылның иң чибәр, иң уңган кызын сайлап, " Нәүрүзбикә" дип игълан итәләр. Учак якканнар һәм шулпа әзерләгәннәр,ә учак әйләнәсендә кызлар, егетләрәйләнгәннәр. Бу көнне Нәүрүзбикә хөрмәтенә төрле ярышлар үткәрелгән. Укучы балалар өйдән - өйгә кереп нәүрүз әйтеп йөргәннәр. Алар такмакны әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр.

Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез,
Хәер – дога кылабыз,
Аш – сый көтеп торабыз,
Нәүрүз мөбәрәкбад.

Без мәктәптә “Карга боткасы” бәйрәмен үткәрәбез. Милли ризыклар пешереп, ботка пешереп, бер-беребезне сыйлыйбыз, үзебез дә сыйланабыз. Әти -әниләребез бик теләп, безгә булыша. Бик күңелле бәйрәм итәбез.

Татар халкының борын- борыннан безнең чорларга кадәр килеп җиткән дини бәйрәмнәрнең берсе- Ураза гаете.Мөселманнар ай буе ураза тота, гөнах эшләүдән, гайбәт сөйләүдән, начарлык эшләүдән тыела. Бары изге эшләр эшләп, дога укып,күңелен чистарта, ач тору әле ул сәламәтлек өчен дә файдалы. Мәктәптә дә кайбер укучылар ураза тота, мин бик шат.

Рамазан гаетендә кардәшлек-туганлык хисләре иң югары ноктага җитә. Туган-тумача бер-берсенә кунакка йөрешә, балалар ата-аналар янына барып, хәлләрен белешә, хөрмәт күрсәтә... Бәйрәм бер-берсенә үпкә тоткан кешеләрне татулаштыру көченә ия. Мөэминнәр Рамазан гаетендә бигрәк тә мохтаҗларның, ятим вә үксезләрнең күңелен күрергә тырышырга тиешләр. Моның савабы бик зур... Гает – сөенеч, шатлык һәм күңел ачу көнедер. Бу көнне иртән иртүк тәмле ризыклар пешереп, туганнарны, күршеләрне, дусларны сыйлаганнар. Ирләр мәчеткә тәравихка баралар.

Ураза гаетеннән соң 70 көн узгач татар халкының иң зур бәйрәме - Корбан ае башлана.Корбан бәйрәме Мәккәгә хаҗ кылу тәмамланган көнне башлана һәм 3-4 көн дәвам итә. Бәйрәмнең беренче көнендә хаҗ кылучылар корбан чалалар. Корбан чалуның да үз тарихы булган. Риваятьләргә караганда, Ибраһим пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләгә чиксез бирелгәнлек билгесе итеп үзенең улы Исмәгыйльне корбан итеп чалмакчы булган. Әмма Аллаһы Тәгалә, Ибраһимны кызганып, аңа сарык бәрәне җибәрә һәм аның улын коткарып кала. Шуннан соң һәр мөселман кеше шушы вакыйга истәлегенә корбан чалырга тиеш була... Әлеге бәйрәм көннәрендә, догалар кылып, корбаннар чалу дәвам итә. Бәйрәм табыннарына дин әһелләре һәм башка кунаклар чыкырыла. Коръән укыла, изгелеккә өндәп вәгазьләр сөйләнә.

Шәһәребез дә бу ике бәйрәм зурлап, тиешенчә үткәрелә. Без, яшьләр, милли йолаларны, бәйрәмнәрне күреп үсәбез. Яшьтән үк безнең каныбызга, хәтеребезгә сеңеп бара. Киләчәктә милли бәйрәмнәрне, гореф-гадәтләрне, традицияләрне югалтмыйча саклау- безнең изге бурыч. Мин үзем татар кызы буларак, бу бурычны үтәүгә өлеш кертергә тиеш дип уйлыйм.

Әдәбият

1. Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары.-Казан: Татар.кит.нәшр., 1996
2. Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре.-Казан: Татар кит. нәшр., 1992

## УКУЧЫЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ

Шәрифуллина А.И.,
КФУның Алабуга институты магистранты.
Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.

Хәзерге тормыш укучыдан телне яхшы белүне, төрле ситуацияләрдә төрле кешеләр белән аралашу сәләтенә ия булуны таләп итә. Шуңа күрә, фикерләрне телдән һәм язма рәвештә бер-бер артлы белдерү, язылганнарны анализлау һәм камилләштерү сәләтен үстерү, һәм фикер алышу соравы буенча компетентлы фикер белдерү сәләте укучыларның телдән үсешенең һәм психик активлыкның иң мөһим юнәлешләренең берсе.

Практика шуны күрсәтә: хәзерге мәктәп укучылары, бик теләпкомпьютерлар һәм телефоннар ярдәмендә аралаша, аралашуда сленг сүзләрен һәм аббревиатураларны, кыскартылган сүзләрне күбрәк кулланалар, еш кына тере, мәдәни сөйләмне мимика һәм ишарәләр белән алыштыралар. Мондый балаларга мөстәкыйль рәвештә телдән һәм бигрәк тә язмача эзлекле текст булдыру кыен. Шуңа күрә, без ышаныч белән әйтә алабыз, мәктәп укучылары арасында мәдәни аралашу проблемасы бүгенге көндә иң мөһиме. Якын киләчәктә нәкъ коммуникатив компетенция профессиональ әзерлектә һәм хезмәт эшчәнлегендә төп роль уйный башлаячак.

Татар теле дәресләрендә текст белән эшләү укучыларның иҗади потенциалын үстерергә, аларның сүз байлыгын тулыландырырга һәм сөйләм сыйфатын күтәрергә мөмкинлек бирә. Текст – татар теле дәресләрендә сөйләм мохитен булдыру өчен нигез. Татар телен өйрәнгәндә текстны куллану мәктәп белеменең мөһим проблемаларын чишүне тәэмин итә, укучыларны туган телнең рухи байлыгы һәм матурлыгы белән таныштыру, сүзгә сак һәм уйлы караш тәрбияләүгә булышлык итә[ Пирогова2014: 231].

Сыйныфта текст белән даими эш, безнең фикеребезчә, татар классик әдәбияты әсәрләренә нигезләнеп башкарылырга тиеш. Классик әдәбият мисалларына мөрәҗәгать итү – шәхесне үстерә торган сөйләм мохитен булдыруның бер чарасы, укучыларга текстлар төзү техникасын булдыруда эффектив чара ул.

Тәҗрибә күрсәткәнчә, текст белән эшне оештыруның түбәндәге формалары һәм ысуллары иң кулайлары санала ала: комплекслы һәм лингвостилистик текст анализы, сочинение-фикер йөртү, текстны редакцияләү, төрле диктантлар, миниатюр текстлар белән эшләү, төрле уен ситуацияләре...

Дәресләрдәбез комплекслы текст анализы кебек эш төренә аеруча өстенлек бирәбез. Орфографик яктан кызыклы һәм төрле синтаксик структураларны үз эченә алган текстларны сайларга тырышабыз. Бу – Ш.Мәрҗәни, Г.Тукай, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Н.Гыйматдинова, М.Кәбиров һ.б. сүз осталарының фәһемле, тәрбияви потенциалы көчле булган әсәрләреннән өзекләр.

Мисал өчен теләсә нинди сөйләм текстының анализы өчен үрнәк план:

1. Текстны экспрессив уку.
2. Сүзлек эше.
3. Текстның темасы.
4. Текст идеясы.
5. Текст төре.
6. Текст стиле.

7. Экспрессив сөйләм чаралары һәм аларның роле.

Миниатюр текстлар белән эшләү, ике текстны чагыштыру нәтиҗәсендә, укучылар, текстны кабул итү һәм концепциясен аңлау аша үз текстларын, сочинениеләрен булдырырга өйрәнәләр.

Әйтик, "Безнең гаилә" темасын өйрәнгәндә укучылар гаиләләре турында хикәя төзеп сөйләгән вакытта түбәндәге терәк схеманы куллана алалар

*Безнең гаилә*

| Сөйләү планы | Терәк сүзләр,сүзтезмәләр |
|---|---|
| Гаиләдә кемнәр бар? | Әти,әни,апа,абый,сеңел,эне,дәү әти,дәү әни |
| Гаилә кайда яши? | ... шәһәрдә, ... авылда |

Мондый терәк таблицаларны куллану балаларның сөйләмен оештыру өчен уңай нәтиҗә бирә.

Текстлар, тел өйрәнү буенча программа нигезендә һәм үзләштерелгән лексик берәмлекләр санын күздә тотып, әлеге уку периодына туры килерлек итеп сайланыла.

Текстны өйрәнү өч этаптан тора: текст белән танышканчыга кадәрге этап, текст белән танышу этабы һәм текст белән танышканнан соңгы этап.

1 нче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнергә тиешләр, шул рәвешле әлеге этапта әсәрнең авторы турында мәгълүмат бирү һәм лексик-грамматик биремнәрне үтәү эше башкарыла. Күнегү төрләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: рәсем (картина) белән эш; ассоциация һәм фаразлар; сорау - җавап бирү; төп сүзләр белән эш; текст төзү һ.б.

Укучылар текстны берникадәр лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнгәч, текстның үзен укырга күчәргә мөмкин. Бу дәресләрдә, нигездә, турыдан-туры текстны уку, текст өстендә эшләү буенча күнегүләр системасы өстенлек итә. Сүзлек белән эшләүгә басым ясала. Текстны укуның өч төре кулланыла: укытучы артыннан уку; өлешләп уку; үзлектән уку.

Текст өстендә эшләгәндә, түбәндәге күнегүләрне кулланырга мөмкин: текстны рольләргә бүлеп уку; бирелгән сорауларга тексттан туры килгән җөмләләрне табып уку; бирелгән җөмләләр арасыннан текст эчтәлегенә туры килгән җөмләләрне табу; аерым җөмләләргә сорау кую; текстта булган грамматик категорияләргә анализ ясау.

Текст белән танышканнан соңгы этапта текст эчтәлеге һәм аңа салынган әхлакый проблема буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла. Бу дәресләрдә тексттагы лексик-грамматик материал сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелә, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм этабына чыгалар. Аңлашылганча, тел өйрәтү процессында татар теле һәм әдәби уку дәресләре үзара шартлы бәйләнештә булалар.

Текст белән танышканнан соңгы этап: текстның планын төзү; микротемаларга атама бирү; кыскарту яки гадиләштерү; вакыйгага бәя бирү;

дәлилләү, аргумент китерү; яңалык җиткерү; хикәяне дәвам итү; яңа чишелеш бирү; проблеманың сәбәбен табу;

Күнегү төрләре: текстны кыскарту; сюжетны үзгәртү; текстка исем бирү; дефиниция (синонимнарны һәм антонимнарны табу); үзгәртеп сөйләү; камилләштерү; реклама ясау; яңача тәмамлау; төрле заманда (заттан) сөйләү; образларга бәя бирү; ситуатив күнегүләр башкару[Сафиуллина1994: 350].

Татар һәм, бигрәк тә, рус балаларына татар һәм инглиз телләре дәресләрендә текстларга мөрәҗәгать иткәндә, беренче чиратта, шигъри текстлар белән эшне түбәндәгечә оештырабыз:

- шигъри әсәр тактага ( интерактив тактага) языла яки битләргә язылып, балаларга таратыла;
- актив кулланылмый торган сүзләрнең тәрҗемәсе шигырьдән соң бирелә;
- актив кулланыла торган сүзләр сүзлеккә язылып, яңа сүзләр өстендә эш алып барыла;
- шигырь CD язмада яки укытучының үрнәк укуында тәкъдим ителә;
- шигырьнең эчтәлеген аңлау дәрәҗәләрен белү максатыннан чыгып, эчтәлеге буенча алдан проблемалы сорау куела;
- шигырьдәге әйтелеше авыр булган фразалар хор белән яки төркемләп әйтелә;
- шигырьне укытучы укып күрсәтә;
- шигырьне 1-2 яхшырак укучы бала укый;
- кирәк булса, текст русчага тәрҗемә ителә яки тәрҗемәсе укыла;
- шигырьне сәнгатьле уку өстендә эш башкарыла;
- өйгә эш итеп шигырьне ятлап килергә, эчтәлеген үз сүзләрең белән сөйләргә яки эчтәлеге буенча сораулар төзергә бирелә.

Өй эшләре биргәндә балаларның иҗади мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итә торган эшләр бирергә тырышабыз: текстка иллюстрация ясарга; презентацияләр ясап килергә; кроссвордлар төзеп килергә; текстны дәвам итәргә; текстка план төзергә; билгеле бер темага шигырь, 5-6 җөмләлек эссе язып килергә.

Гомумиләштереп әйткәндә, текстлар куллану телнең мөмкинлекләрен, байлыгын, яңгырашын, үзенчәлекләрен күрсәтергә һәм, телне йөртүче халыкның мохитен аңлап, шул телнең көндәлек лексикасын үзләштерергә ярдәм итә. Хатлар, тәбрикләмәләр язу, җырлар, фразеологик әйтелмәләр, мәкаль һәм әйтемнәр, вакытлы матбугаттан алынган текстлар өйрәнү дә, халыкның телен, мәдәният үзенчәлеген өйрәнүгә этәргеч бирә һәм кызыксыну уята.

Әдәбият

1. Пирогова О. Е. Чтение художественной литературы как средство формирования языковой личности. // Вестник ТвГУ. – Серия «Филология». 2014. – №1. – С. 231-235.
2. СафиуллинаФ.С.Хәзерге татар әдәби теле.– Казан: Мәгариф,1994. – 405б.

**БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ**

Шәрифуллина Зөһрә
“Адымнар - Алабуга “ күптелле белем бирү комплексы укучысы
Фәнни җитәкчеләр: Комиссарова Ф.Г, Данилова З.С.

Без, бүгенге буын яшьләре, борынгы тарихлы һәм бай мәдәниятле Татарстан Җөмһүриятенең чиксез киңлекләрендә яшәвебез белән бәхетле.

Минем чыгышым Татарстан Республикасындагы ЮНЭСКО канаты астына алынган тарихи- мәдәни объектлары турында. Болгар тарихи археологик комплексы, Казан Кремле, Зөя утрау шәһәрчеге Успение соборы,Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләре -болар барысы да мәдәният һәм табигать һәйкәлләре. Алар Берләшкән Милләтләр Оешмасының Мәгариф, Фән һәм мәдәният буенча ЮНЕСКО саклавында тора.

Чыгышымның максаты-Татарстан Республикасындагы ЮНЭСКОга кертелгән тарихи- мәдәни объектларының мөһимлеген укучыларга җиткерү.

“Үз-үзен хөрмәт иткән халык тарихи мирасын торгызырга тиеш”,-дип белдердеТатарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы.

*Беренче булу бервакытта да җиңел түгел. Шулай да нәкъ менә беренчеләр, кабатланмас булып, тарихта үз урыннарын алалар һәм милләт хәтерендә калалар. Төрки-татар дәүләтләрен төзегән Атилла, Кубрат хан, Казан ханлыгының нигез ташларын салучы Олуг Мөхәммәд һәм, ниһаять, Минтимер Шәймиев - хәзерге Татарстан Республикасын оештыручы, бөек тарихлы татар дигән милләтнең горур исемен дөнья күләмендә ишеттерүче. Безне хәзер таныйлар, фикерләребезгә колак салалар, исәпләшәләр. Без аяк терәп: “Мин - татар!..” дип горурланып әйтәбез, рәхәтләнеп, туган телебездә аралаша алабыз.Минтимер Шәрип улы - үзен бөтенләе белән туган милләтенә, республика халкына багышлаган шәхес.*

ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә 2000 елда Казан Кремленең тарихи-архитектура ансамбле, 2014 елда – Болгар тарих-археология комплексы, 2017 елда – Успенья соборы һәм Свияжск утрау-шәһәрчеге монастыре кертелде. Бу Татарстанның Беренче Президенты, ЮНЕСКОның Игелекле ихтыяр илчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев, Федераль хакимият органнары ярдәме, шулай ук республика предприятиеләре һәм безнең гражданнар күрсәткән ярдәм нәтиҗәсендә мөмкин булды.

ЮНЕСКО канаты астына кертү безнең өчен бик отышлы хәл. Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән тарихи истәлекләр ЮНЕСКО яклавы һәм күзәтчелеге астында була.Ул истәлекләргә беркем дә кагыла алмый һәм, иң мөһиме, аларның торышы һәрдаим тикшерелеп тора, ягъни, телисеңме-теләмисеңме, аларны төзек һәм бөтен итеп саклауның барлык шартларын үтәргә тиешсең. Тарихи ядкәрләргә бер бөртек тә зыян килмәскә тиеш!

ТурСтат аналитик агентлыгы мәгълүматлары буенча, Казан Кремле тарихи-архитектура комплексы туристлар арасында ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары популярлыгы буенча Мәскәү белән Санкт-Петербургтан кала, өченче булып тора.*Бүген дә олуг киңәшчебез* Минтимер Шәрипович *“Яңарыш” фондын оештырып ватаныбызның киләчәге ышанычлы һәм якты*

*булсын дип яши.*2001 елның июнендә ЮНЕСКОның генераль директоры Коитиро Мацуура М. Шәймиевкә мәдәни-тарихи хәзинәләрне саклауга зур өлеш керткән өчен Әбугалисина исемендәге көмеш медаль тапшырды.2004 елның февралендә Президент икенче дәрәҗә «Ахьдз-апша» ордены белән бүләкләнде.2005 елның мартында Россия Федерациясе һәм ЮНЕСКО арасында хезмәттәшлеккә шәхси өлеш керткән өчен диплом һәм «Россия — ЮНЕСКО»ның истәлекле медале белән бүләкләнде.Республикабызда мәгариф, фән һәм мәдәниятне саклап калу мәсьәләсе буенча актив эш дәвам итә.Күптелле белем бирү учреждениеләрен булдыруның моңарчы күрелмәгән программасы кабул ителде. 2019 елның февраленнән “Яңарыш” Республика Фонды РФ Мәгариф министрлыгы ярдәмендә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә күптелле белем бирү комплекслары булдыру проектын гамәлләштерүне башлады.Республикада инде 6 «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» комплексы булдырылды. Алар ике дәүләт (рус һәм татар) һәм халыкара инглиз телләрендә сыйфатлы белем бирүче заманча мәктәпнең кирәкле моделе булып торалар.

2020 елда ЮНЕСКОның Россия Федерациясеннән башлангыч исемлегенә яңа объект – Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләре кертелде. Бу - тулаем ил өчен уникаль күренеш, Татарстан фәненең дөньякүләм мәдәни мираска керткән өлешен күрсәтүче бөтенләй яңа номинация.

Бүгенге көндә Җир шарында 1000нән артык тарихи-мәдәни объект ЮНЕСКО канаты астына алынган. Аларны дөнья күләмендә күзәтеп торалар һәм саклыйлар. Әлеге исемлектә бүгенге көндә Россиядә 29 объект бар, шуларның өчесе - безнең республикада. Алар - кыйммәтле хәзинәгә ия булган мәдәни мирас. Чыннан да, бу тарихи- мәдәни объектлар күңелләрдә милләтебез өчен горурлык хисе тудыра.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: *бүгенге көндә тарихи мирасыбызны, милли гореф-гадәтләребезне, сәнгатебезне онытмыйбыз икән, димәк милләт яши, милләт яшәгәч тел яши, ягьни тормыш дәвам итә.* “Адымнар- Алабуга” коплексында бу максаттан төрле *матур чаралар әледән - әле үткәрелеп тора, ягъни р*рухикыйммәтләрне саклауга һәм ныгытуга мәктәбебездә зур игътибар бирелә.

## РЕНАТ ХАРИС ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ

Юнусова З. Н.,
“Университет” гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.
Фәнни җитәкче: Сәхәбиева Г.Х.

Тукай образына Ренат Харис та еш мөрәҗәгать итә. Шигырьләрендә ул Тукай белән поэтик диалог алып бара. Мәсәлән, “Тукай бакчасында” шигырендә автор Габдулла Тукайның “Гаиләсенә җиһанның ник китерден ят кеше?” юлларын эпиграф итеп ала. Көнчыгыш һәм дөнья шигърияте өчен традицион саналган бакча образы Ренат Харис шигырендә гадәти булмаган

ракурста – кышкы бакча итеп тәкъдим ителә. Биредә традицион бакча гөлләре урынына кар образы килеп керә:

Тукай бакчасында кар сибәли,
вак һәм җылы – яңа он сыман...
Тегермәнче кебек, телгә салып,
әвәләргә хәтта ымсынам.

Тукай бакчасы ап-ак, әкияти итеп күз алдына килә, шул ук вакытта бакчаның аклыгын ассызыклап яңа он белән чагыштыру уңдырышлылык төсмере кертә. Әкияти кар, ап-ак җир образлары контекстында Тукай бакчасы язучы шигъриятенең матурлыгын, әхлакый чисталыгын һәм уңдырышлылыгын гәүдәләндереп, бөек татар шагыйре поэзиясе метафорасы булып китә. Шигырьнең икенче строфасында бу метафора үстерелә, тагын да баетыла:

Ә кар эри керфегемә тиеп –
төшкән чагында ук чыланган...
Әллә ул да нәни Тукай кебек
ят булганмы чиксез җиһанга?..

Йолдызлар сибелгән һәм тынгысыз җир тормышына битараф булган традицион җиһан, галәм, Космос образы, Ренат Харис шигырендә керфеккә тиеп эри торган кар образы белән тулылана. Пейзаж тасвиры белән башланган шигырь, көтелмәгән "ул (кар – искәрмә безнеке) да нәни Тукай кебек / ят булганмы чиксез җиһанга" чагыштыруы белән, Габдулла Тукай шигъриятен яхшы белгән, шигырьнең эпиграфына чыгарылган юлларны аныклый алган аз санлы укучыларга гына аңлаешлы фәлсәфи әсәрләр рәтенә күчә. Өченче строфада Тукай бакчасы шагыйрь-классик поэзиясенә тагын бер штрих – трагизм өстәүче буларак күзаллана:

Тукай бакчасында кар сибәли...
Ак япмада тора бар агач...
Әллә нишли күңел, керфектәге
тамчы аша күккә карагач...

"Шигърият – бакча", "шигырьләр – күңел гөлләре" традицион метафорасы Ренат Харис тарафыннан "Шагыйрь турында шигырь" әсәрендә күренекле шагыйрьләр – Рудакый, А.С.Пушкин, Гарсиа Лорка, Назыйм Хикмәтнең драматик язмышлары мисалында кире кагыла. Алар арасында Габдулла Тукайның сәяси үткен поэзиясе дә атала:

Тукай ишеген,
Газраилдән узып,
Жандармнар какмас иде... [369].

Язучы шигъриятендә – Тукай, беренче чиратта, әхлакый, рухи һәм поэтик хәллелек үлчәме буларак тәкъдим ителә. Бу фикер авторның һәм дә күләмле әсәрләрендә (поэма, либретто), һәм дә поэтик миниатюраларында һәм хәтта юмористик аспектта үткәрелә ала. Мисал өчен, "Тукай боза" шигыренә күз төшереп үтик:

Бакыр Тукайга шигырьләр
укыйбыз без кызып-кызып...
Бер тәнкыйть сүзе әйтмичә

Бетерә ул безне бозып... [Харисов 2006: 104].

Әлеге миниатюрада күренекле татар шагыйре – Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан ел да үткәрелүче шигърият бәйрәменең җыйнак образы тудырыла һәм шул ук вакытта осталарча актуаль проблема – конструктив тәнкыйть булмау проблемасы күтәрелә. “Тукай туган көнне һәр ел кояш...” шигырендә шигърият бәйрәме темасы пейзаж сурәтеннән киңәйтелгән метафора аша фәлсәфи гомумиләштерүгә кадәр үсә. Иртәнге кояшның язгы яңгыр белән алышынуы төсле, Тукай поэзиясе дә кояш кебек шагыйрьләргә юл яктырта һәм яңгыр шикелле аларның “тамырларын” чылата:

Тукай туган көнне һәр ел кояш.
Ә төштән соң бик еш – яңгырлар.
Тукай кояш булып ымсындыра
Һәм сут суза шигъри тамырга [Харисов 2006: 229].

“Каурый каләм” циклындагы “Тукай” шигырендә Казан урамнары буйлап Габдулла Тукай бара. Күпер ташлары Шагыйрьнең авыр адымнарын күтәреп тора алмыйлар.

Гомумиләштереп шуны әйтергә мөмкин: шигырьләрендә Ренат Харис татар поэзиясе классигы Габдулла Тукай образына шигърияткә фидакарь хезмәт эталоны, югары әхлак гәүдәләнеше буларак мөрәҗәгать итә. Шагыйрь әсәрләрендә Габдулла Тукай мирасының хәзерге әдәбиятның үсеше өчен әһәмияте дә ачыклана.

Габдулла Тукай биографиясе – дөнья әдәбияты тарихындагы иң драматик биографияләрнең берсе. Болай караганда, шагыйрь узган гомер юлы озын түгел. Аның төп урыннары: Кушлавыч – Кырлай – Өчиле – Казан – Уральск (Җаек) – яңадан Казан... Ләкин шул авыллар, шул шәһәрләр арасында күпме кичереш-фаҗига ятканын күзаллавы да авыр. Шул ук вакытта шул авыллар, шул шәһәрләр арасы Апушны олы Тукай итеп җитешүенә нигез сала да инде. Тукай кичергән ятимлек ачысы, назга тилмерү һәм якты карашка рәхмәтле була белүен аңлар өчен, нәкъ менә аның тормыш юлын сурәтләгән матур әдәбият әсәрләренә мөрәҗәгать итү кирәк. Күзәтүләребез күрсәткәнчә, прозада Тукай турындагы әсәрләрнең беренчесе Габдулла Тукайның үзе тарафыннан иҗат ителгән автобиографик повесте. Шулай ук Әхмәт Фәйзи каләме астыннан чыккан “Кечкенә Апуш” әсәрендә дә Тукай образы үзәктә тора, әлеге әсәр шагыйрь биографиясенең билгеле бер этабы белән якыннанрак таныштыра, Габдулла Тукайны бөек әдип кенә түгел, гади кеше буларак сыйфатларын тулырак күзалларга ярдәм итә, кечкенә Апуштан олуг Тукайга үсешендәге аерым тенденцияләрне күрсәтә. Шулай ук, татар әдәбиятында Габдулла Тукайга багышланган күпләгән әсәрләр рәтендә, Рабит Батулланың “Апуш – Тукай” кыйссасы, Ркаил Зәйдулланың “Шул булды эш...” драмасы, Камил Мостафинның “Юлның дәвамы”, Рафис Корбанның “1913 ел. Апрель. Тукай”, Роберт Миңнуллинның “Тукайга багышланган күргәзмәдә” шигырьләрен һәм күп кенә башка әсәрләрне атап үтәргә мөмкин.

Әдәбият гыйлемендә Тукай образын үзәккә куйган әсәрләрне фәнни яссылыкта өйрәнүгә Ф.И. Габидуллина, А.Ф. Ганиева, Ә.М. Закирҗанов,

Н.М. Йосыпова, И.С. Мансуров, Э.Ш. Сәлимҗанова, Д.Р. Фәрдиева кебек галимнәр өлеш кертә.

Хәзерге татар шигърияте ндә Тукай образы Рафис Корбан, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис кебек шагыйрьләр иҗатында урын ала. Һәр язучы Тукайны билгеле бер тормыш моментында гәүдәләндерә. Әйтик, Рафис Корбанның "1913 ел. Апрель. Тукай" шигырендә Тукайның соңгы көннәре тасвирлана. Рафис Корбан Тукайның соңгы көннәрен үзенчә күзаллап, шул ук вакытта тарихи фактларга, әдип биографиясенә нигезләнеп, сәнгати итеп, укучыга тасвирлап бирә алган. Роберт Миңнуллинда Тукай образы Тукайга багышланган картиналарга нисбәтле ачыла, автор һәр рәсем авторының, гомумән һәр кешенең үз Тукае булуга басым ясый. "Әллүки" шигырендә Роберт Миңнуллин Тукайны үзенә халыкның их яхшы сыйфатларын җыйган милли герой буларак ача. "Тукай минем яшьтә үлгән..." әсәрендә автор Тукайның кыска гомере эчендә башкарылган эшләре белән соклана, аны даһи дип атый. Ренат Хариста Тукай образын ачуга табигать образлары ярдәм итә. Әйтик, "Тукай бакчасында" шигырендә автор метафорага мөрәҗәгать итеп, Тукай шигъриятен бакча дип атап, бу бакчаның уңдырышлылыгын искәртә. Шулай ук, язучы иҗатында Тукай шигърияте кояшка, яңгырга тиңләнә ("Тукай туган көнне һәр ел кояш...").

Җыеп кына әйткәндә, хәзерге шигърияттә Тукай образы – милли горурлык символы.

Әдәбият


1. Батулла Р. Апуш – Тукай (кыйсса) // Казан утлары. – 2011 – № 4. – Б. 6 – 89.
2. Корбан Р. Яра: шигырьләр, җырлар, тәрҗемә әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 282 б.
3. Миңнуллин Р. Әсәрләр. 7 томда. 1 нче т.: шигырьләр, тәрҗемәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 575 б.
4. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. Т. 2. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 367 б.
5. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. Т. 3. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 367 б.


## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНЕҢ ТЕМАТИК ТӨРЛЕЛЕГЕ


Юнусова Э.Ф.
КФУның Алабуга институты студенты
Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф. И.


Фәндә XX нче гасыр ахыры - XXI гасыр башы татар әдәбияты белән тыгыз бәйләнгән шагыйрь - Роберт Миңнуллин иҗатын өйрәнүгә аерым кызыксыну булуы табигый. Роберт Мөгәллим улы Миңнуллин иҗаты хәзерге татар әдәбиятында аерым урын алып тора. Яңарыш дип аталган чорда - 1970-нче елларда әдәбиятка килгән шагыйрь әсәрләре бүгенге көндә актуальлеген югалтмый. Аның поэзиясе узган гасырның икенче яртысында татар интеллигенциясенә хас булган әхлакый, этик, социаль-фәлсәфи эзләнүләрне

чагылдыра. Танылган әдәбият тәнкыйтьчеләре, шагыйрьләр һәм язучылар аның иҗаты турында күп сөйләделәр. Әйтергә кирәк, яшь шагыйрь әсәрләренә беренче әдәби тәнкыйть җаваплары С. Хәким, И. Юзеев, Ф. Хөсни, Ш. Галиев, К. Нәҗми кебек классиклар тарафыннан бирелә. Алар шагыйрьнең беренче шигырьләренең зур сәнгать потенциалына игътибар итеп, аның беренче әсәрләренең поэтик системасын формалаштырган образларның һәм мотивларның әхлакый һәм иҗтимагый әһәмиятен күрсәтте.

Р.Миңнуллинның искиткеч әдәби дебюты башланганнан алып, аның хезмәте әдәбият тәнкыйтьчеләре, тел белгечләре арасында зур кызыксынулар уятты. Алар арасында: М. Әхмәтҗанов, Ф. Галимуллин, Т. Галиуллин, Г. Гыйльманов, М. Вәлиев, Р. Мостафин, Р. Рахман, Р. Сарчин, М. Сахапов, Ф. Урманчеев, Н. Хисамов, А. Шарипов, Н. Юзиев, Ф. Яхин һ.б. Шунысы игътибарга лаек: узган гасырның 70-80 нче елларыннан башлап, татарлар гына түгел, рус, башкорт язучылары, шагыйрьләре һәм тәнкыйтьчеләре дә Р. Миңнуллин поэзиясенә аерым игътибар бирә башлады: М. Львов, С. Михалков, М. Пляцковскийлар шагыйрь иҗатына бәя бирде.

Р.Миңнуллин шигърияте төрле гуманитар өлкә галимнәренең игътибарын җәлеп итүе һәм төрле фәнни тикшеренүләр чыганагы булуы игътибарга лаек. Тупланган фәнни тәҗрибәне системалаштыру ихтыяҗы Р.Миңнуллинның 60 еллыгына багышланган Халыкара фәнни-практик конференцияне үткәрү өчен этәргеч булды. Конференция материаллары хәзерге татар әдәбияты һәм Роберт Миңнуллин" исемле җыентык формасында бастырылды, анда Идел-Урал өлкәсе галимнәре мәкаләләре урын алган.

Билгеле булганча, табигать шагыйрьләрне күптән рухландырып, теләсә нинди әдәбиятның лирик системасында көчле урын алып тора. Шунысы игътибарга лаек: Роберт Миңнуллинда туган табигать темасы гражданлык-патриотик темалар белән берләшә, бу безне кызыксындырган авторның Г. Тукай, Х. Туфан, С. Хәким, Һ. Такташ, А. Атнабай, Н. Нәҗми, А. Ахматова, Б. Пастернак кебек рус һәм татар лирикларының шигъри дөньялары белән трансформатив диалогының дәлиле. Шунысын да әйтергә кирәк, Р. Миңнуллинда лирик герое табигый мохиттә таркалу тенденциясе хас. Шагыйрьнең пейзаж лирикасы герое әйләнә-тирә дөньяны табигать рәсемнәре аша аңларга омтыла, чынбарлык кеше белән тыгыз бәйләнгән.

Туган авыл пейзажларында лирик герой табигать белән тулы гармония тоя, монда шагыйрь үзен галәмнең бер өлеше дип саный, аңы галәм белән кушыла: Табигатькә нигә үпкәләргә? Үз кануны аның, үз эше… Гомер фасыллары шикелле үк, Ел фасылларының көчеше. Р. Миңнуллин шигъриятендә ел фасыллары элементларының ландшафт дифференциациясе кызык: ул Миңнуллин поэзиясенең романтик юнәлешен ачык күрергә мөмкинлек бирә. Фасыллар темасы турында уйлану шагыйрьне кеше яшәеше һәм табигатьнең аерылгысызлыгы идеясенә китерә. Өстәмә сюжетлар саны ("Кара ташлар", "Төнге пейзаж") да арта. Аларда төп хикәянең универсаль-архетипаль характерын бирүче мифологик башлангычның көчәюен күрергә мөмкин.

Шагыйрь иҗатында барлык ел фасыллары күрсәтелгән. Р. Миңнуллин пейзаж шигырьләрендә тудырган образлар символик. Шагыйрь өчен көз - кайгы, өметсезлек, ләкин шул ук вакытта илһам. Көзге начар һава торышы образлы рәвештә лирик геройның психологик халәтен күрсәтә. Кыш - акылның салкынлыгы; шагыйрь эстетик яктан кышкы карның чисталыгы, кар бөртекләре белән хәрәкәтләнә, хәрәкәтләре белән туңган дөнья статикасын җиңә, хисләр шагыйрьнең мәхәббәт теләкләре белән бәйләнә. Р. Миңнуллин чишмәсе, Г. Тукайдагы кебек, яңадан туу, яшьлек, җан чәчәкләре символы. Табигатьнең уянуы белән беррәттән, шагыйрьгә иҗади илһам да килә. "Яз" шигырьләренең мотивлары - шагыйрьнең бөтен поэзиясенең семантик ачкычлары ("Дөнья яшәргәндә", "Яңарыш" һ.б.). Алдагы шагыйрьләр белән диалогик идеясын дәвам итеп, Р. Миңнуллинның Х. Туфан мирасына тугры калуы һәм табигатьне гуманлаштыру һәм рухиләштерү традициясен дәвам итәргә омтылуы турында әйтергә кирәк. Р. Миңнуллин иҗатында без функциональ мәгънәдә Х. Туфан лирикасы образларына (чәчәкләр, агачлар, аккошлар һ.б.) охшаган берничә табигый образ табабыз, ләкин һәр шагыйрь аларга үзенчәлекле эчтәлек бирә. Х. Туфан глобаль категорияләрне өстен күрә ("Мәңгелек", "Космос", "Матурлык", "Кайгы" концептлары), аларны ак каеннар, чәчәкләр, кошларның билгеле образлары аша җиткерә. Югарыда әйтелгәннәрне раслаучы ачык мисаллар Роберт Миңнуллинның "Дөнья яшьләнгәч", "Кояш котү", "Печән", "Каеннарны сеңелләр дип саныймын", "Таллар, тупыллар", "Кайту", "Сөн бу талсыз буламы", "Сөн дулкыннары", "Хан тавы", "Моңсу чиркәү", "Балачак тегермәне" һ.б.

Р. Миңнуллинның сәнгать дөньясы сизгер һәм материаль яктан тулы. Ул табигатьнең барлык элементларын, "беренчел" (табигый) һәм "икенчел" объектларны, кеше кулы белән үзләштерә. Р. Миңнуллин шигырьләрендәге табигать гуманлаштырылган, эчтәлеге укучы өчен якын һәм аңлаешлы. Чын рәссам кебек, ул күренешләрдә характеристиканы, эчтәлекне аңлый. Р. Миңнуллин кешенең эчке дөньясын сүзләр белән генә тасвирламый, ул лирик герой тәҗрибәсен таныш табигать күренешләре аша җиткерергә тырыша. Автор үз әсәрләрендә поэтик параллелизм, контрастлар һәм чагыштырулар техникасын кулланып, кеше җанының табигатькә, табигатьнең кеше җанына үтеп керүен психологик яктан ышанычлы сурәт формасында ясый.

Р. Миңнуллин шигъриятендәге киләсе олпат тема - мәхәббәт лирикасы. Шунысы игътибарга лаек: Р. Миңнуллин шигъриятендә пейзаж лирикасы мәхәббәт лирикасы белән үрелеп китә: Кышлар буе көттем, белгән кебек, Ак канатлы парлы төркемне. Сине миңа язлар алып килде Яз кошлары белән бер көнне… Мәхәббәтне язлар алып килде, Агыйделдә бозлар акканда. Дөнья якты - әллә яратканга, Әллә гөлләр чәчәк атканга?! Р. Миңнуллин шигырьләрендә мәхәббәт офыкларын киңәйтә торган яңа мотивлар бар: чиксез диңгез, чиксез таулар, чиксез күк. Алар яңа мәхәббәт мәйданнарына әйләнәләр. Алар чиксезлеге аркасында, хәзерге тормышның бетмәс мәхәббәтен һәм авторның дәртләрен җиткерә. Шагыйрьнең мәхәббәт шигърияте шуны раслый: мәхәббәт табышмагын чишү аның өчен йөрәк эше. Барлык татар поэзиясе фонында да шагыйрьнең мәхәббәт турындагы шигырьләре мөстәкыйль һәм

оригиналь. Чагу мотивлар һәм образлар аның индивидуальлегендә аерым роль уйныйлар: Шатлыкларым күңел тулы иде, Шатлык идем, инде сагыш мин. Шатлык кына теләп, шатлык кына, Аклык кына, Бу җырымны сиңа багышлыйм!

Без мәхәббәт темасы беренче чиратта ир-ат һәм хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәтләр нигезендә кабул итәргә күнеккән. Мәхәббәт турындагы әсәрләрнең күпчелеге бу турыда. Ләкин Р. Миңнуллин үзенең "Әле соң түгел…" китабында мәхәббәт темасына багышланган шигырьләр бүлеген "Игелек" шигыреннән башлый. Игелек төшенчәсе, беренче карашка, турыдан-туры мәхәббәт белән бәйләнгән, аның "классик" аңлавы юк. Мәхәббәт киңлегенә кереп, игелек аның төп координаталарының берсенә әверелә. Игелеккә, аның җанны саклаучы көченә ышанып, автор үзенең сәнгать системасында төп әһәмияткә ия булган яхшылык идеясын раслый. Игелекне автор хезмәт буларак аңлый. Беренче чиратта ул - җанны баетучы рухи хезмәт. Җанның мондый хезмәте кешене тынычландыра, тышкы дөнья белән гармония бирә: "Сез ир-егет икән әгәр, Эш тотсын кулыгыз. Кулыгыздан килгән кадәр Игелек кылыгыз". Әхлакый кредо буларак, игелек, аның барлыкка килүе Р. Миңнуллин өчен тормышның алыштыргысыз шарты булып тора: Игелекле эшләр һава кебек кирәк. Бу - әсәрнең әхлагы, аның алдагы тексты поэтик дәлилләр чылбыры буларак бирелгән. Шагыйрь еш кына шигъри материалны оештыруның шундый логик ысулына мөрәҗәгать итә - дәлилләр чылбыры аша - бу авторның раслаган хакыйкатьнең бәхәссезлегенә, һәм әсәренең югары әхлакый асылына дәлил. Бу җәһәттән, Роберт Миңнуллин рус поэзиясенең традицияләрен "саклый". Моның өчен кеше тормышының рухи һәм әхлакый нигезләрен раслау һәрвакыт беренче урында тора. Мәхәббәт - игелек, ул матурлык, ул тормышның тулы хисе белән җанны ныгыта.

Шул рәвешле, Р. Миңнуллин лирикасы тематик яктан бик бай. Шунысы әһәмиятле: шагыйрьнең кайсы гына әсәрен алма, анда төрле темалар органик рәвештә бер-берсенә бәйләнеп китә һәм шул рәвешле тулы образлы бер картина тудыра.

Шагыйрь кайсы гына жанрда иҗат итүгә карамастан, үз кыйбласына туры кала һәм Кеше шәхесе, милләт, нәсел, Ватан, туган җир, ана кебек изге төшенчәләргә дан җырлый. Р. Миннуллин поэзиясенең төп характеристикасы - туган җиргә, аның махсус билгеләренә, тарихи вакыйгаларга һәм кадерле гыйбадәтханәләргә карата чиксез хөрмәт хисе чагылыш тапкан. Шагыйрь кешеләр язмышында үз язмышын күргән, шуңа күрә барлык мөһим сорауларны алар белән бергәләп чишәргә омтыла.


## Әдәбият

*Чыганаклар*

1. Баянов Ә. Тау ягы повесте: повестьлар һәм лирик парчалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. - 280 б.
2. Җәлил М. Алтынчәч // Әсәрләр: дүрт томда: 2 т.: шигырьләр, либреттолар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. - 592 б.
3. Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр // Әсәрләр: 8 томда. Казан: Татар. кит.

нәшр., 1975. 2 т. - 478 б
4. Миңнуллин Р. М. Әсәрләр : 7 томда. Казан: Татаркитнәшр, 2007.
*Фәнни әдәбият*
5. Галиуллин Т. Тәнкыйть һәм әдәби процесс / Т.Галиуллин // Казан утлары. - 1984. - № 11. - 162 б.
6. Әдәбият (XX йөзнең 30-90 елларында татар әдәбияты): Татар урта гомуми белем мәктәпләренең 11 нче с-фы өчен д-лек /А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н. Галиуллин һ.б. Казан: Мәгариф, 2000. - 335 б.
7. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев. - Казан: Мәгариф, 2004. - 247 б.
8. Мостафин Р., Йосыпова Н. Муса Җәлил // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 5 т. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. - Б. 264-286 .
9. Мөлеков М. Г. Әдәбият белеменә үз карашы белән // Хәзерге татар әдәбияты һәм Роберт Миңнуллин 16 октябрь 2008 г. Казан, 2008. - 344 б.
10. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда: 6 т.: 60-90 нчы еллар әдәбияты /Абилов Ш., Әхмәдуллин А., Галимуллин Ф. - Казан: Раннур, 2001. - 458-479 б.
11. Хәсәнова Ф. Ф. Сатира һәм юмор остасы // Хәзерге татар әдәбияты һәм Р. Миңнуллин 16 октябрь 2008 г. - Казан, 2008. - 344 б.

## ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНЕҢ СҮЗЛЕК СОСТАВЫНДА АЛЫНМАЛАР

Ягудина Р.Р.
КФУның Алабуга институты 2 курс студенты
Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина

Һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Шуңа күрә алынмалар, кабул ителгәндә, мәгънә ягыннан да, фонетик һәм грамматик яктан да үзгәреш кичерәләр. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендәге авазлар арасында шактый зур аерма булганлыктан, рус сүзләре, татарчага кабул ителгәндә, иң беренче чиратта аваз ягыннан үзгәреш кичергәннәр. Алынмаларның үзгәрү дәрәҗәсе кайсы чорда һәм нинди юл белән кабул ителүгә бәйле. Борынгырак алынмалар фонетик яктан күбрәк үзгәрсәләр, соңрак кабул ителгән алынмалар нигездә үзгәрмәгән [Кәримуллин 1997: 190].

Сөйләм теле аша кергән алынмалар зуррак үзгәрешләргә дучар булганнар. Язма тел аша кергәннәре кимрәк дәрәҗәдә үзгәргәннәр яисә бөтенләй үзгәрмәгәннәр. Борынгырак чорда сөйләм теле аша кереп, төрле үзгәрешләр кичергән алынмаларга мондый сүзләрне кертергә мөмкин: *җәл, шәл, эскәтер, кәбестә, каравам, пумала, сумала, салам, мунчала, фатир, мич, кесәл, ситсы, буразна, ызба, әбәт, чегән, пинҗәк, эшләпә, бүрәнә, арыш, уҗым, камыт, өстә*л. Шул ук вакытта рус телендә дә татар теле сүзләре бар. Әлбәттә, аларның саны татар телендәге рус алынмаларыннан күпкә кимрәк.

Хәзерге көндә тормышның барлык өлкәсе алга бару сәбәпле, яңа төшенчәләр барлыкка килеп кенә тора һәм ул сүзләргә яңа татарча сүз табу, аңа билгеләмә бирү ихтыяҗы туа. Яңа сүзләр, яки татар теленең үз җирлегендә, яки

булган сүзлеккә таянып ясала, яисә калькалаштырыла, яисә гел үзгәртелмичә, әзер килеш кенә телгә килеп керә.

Сүзне иҗат итү, телгә берәр яңа сүз кертү – бик катлаулы эш. Бу эшне башкарганда, хаталар һәрвакыт килеп чыгып торырга мөмкин. Боларны булдырмас өчен бик уйлап эш итәргә кирәк була.

Яңа иҗат ителгән сүз төп ике таләпкә җавап бирергә – кешегә аңлашыла торган һәм туган телнең лексик-семантик нормаларын бозмаска мәҗбүр. Кызганычка каршы, безнең телдә бу таләпләр үтәлеп бетмәгән очраклар күп. Соңгы елларда чыккан кайбер  дәреслекләрдә, матбугат битләрендә сәер, аңлашылмый торган сүзләр еш очрый. Мәсәлән: *санак – компьютер, боралак – вертолет, сайлак – меню, басак – принтер, буйау – тонер, төймәсар – клавиатура, буяк – картридж*, һ.б.

Кайбер очракларда телнең бөтен нечкәлекләрен белеп бетермәү сәбәпле, сүзләр дөрес мәгънәдә кулланмаска, телнең нормаларын бозарга мөмкин. Мәсәлән:

“Биредә *ирекleләр һәм активистлар* белән эшләү ... оештырылачак” (“Кама таңы”). Монда сүз ирекле (свободный) дигәнне аңлатмый, бәлки үз үз теләге белән эшләүчеләр турында сүз бара, әлбәттә. “Биредә *теләгән кешеләр һәм активистлар*...” дөресрәк булыр иде.

“Бу көннең барлыкка килүе тарихы бик кызыклы һәм *хисчән*” (радио тапшыру, 2023 ел). Татар телендә гомумән “*хисчән*” дигән сүз юк.

“Татарстанның *кече* һәм зур елгаларында”... (радио тапшыру, 2023). Бу очракта *кече* сүзе дөрес кулланылмаган. *Кече* сүзе кемнәндер яшьрәк дигәнне аңлата. Бу очракта *кечкенә* сүзе туры килер иде.

“Сара Садыйкова залында... үткәрелә..../ Дөрес вариант: “Сара Садыйкова концертлар залында... үткәрелә”  (радио тапшыру, 2023)

Гомумән, туган телебезнең лексик нормалары бозылуының сәбәбе булып – дөрес итеп тәрҗемә итә белмәү тора. Тәрҗемәчеләр һәр телнең үз нормаларын, үзенчәлекләрен белмәү сәбәпле шундый тупас хаталар ясарга мәҗбүр итәләр [Юсупов 2003: 15].

Телнең чисталыгын саклау кешенең нәкъ үзеннән һәм үз-үзен контрольдә (сөйләм дөрес булудан) тотудан тора. Билгеле булганча, татар теленең сүзлек составы, лексик-семантик нормалары еш кына урынсыз рус сүзен кертү белән дә бозыла. Гади сөйләмдә, хәтта әдәби телдә дә, төрле масса күләм чараларда(газета, журнал битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында) татар телендә берәр сүзне аңлатыр өчен төрле гарәп-фарсы, рус сүзләрен куллану гадәте бик еш күренә.

Тел, белгәнебезчә, статик рәвештә генә тормый, ул һәрдаим берәр нинди дә булса үзгәреш кичерә, чөнки аңа күптөрле факторлар йогынты ясый: тышкы (экстралингвистик) һәм эчке (үз теле). Рус телчесе И.А. Бодуэн үзенең бер мәкаләсендә кызыклы хәлгә гаҗәпләнә: тел күпме генә телне үзгәртә алырлык вакыйга булмасын, тел барыбер дә тиз үзгәрми, ә үзенең кадерен, кыйммәтен, бердәмлеген саклап кала.Аңа да карамастан, монда гаҗәпләндерерлек хәл юк. Чөнки телнең төп функциясе ул – кешеләрнең бер-берсен аңлау чарасы. Һәм

тел үзенең бердәмлеген саклый алмаса, ул үзенең төп функциясен башкара алмас иде.

Әдәбият

1. Каримуллин Ә. Тел – милләтнең сакчысы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 256б.
2. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2003. – 223 б.

## ЭЧТӘЛЕК

1. **Арсланова А.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.) **Экологик тәрбия бирүдә уеннарның роле.**

2. **Антонова А.Г**. ( ученица 9 класса МБОУ “Родниковская СОШ” Алексеевского муниципального района. Научный руководитель: Рахматуллина Р.Р.). **Башня Сююмбике в Казани.**

3. **Арсланова Энже.** (Актаныш 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Солтанова И.Р. ). М**илли җанлы шагыйрь (Фарсель Зыятдинов шигъриятендә милли проблемаларның чагылышы).**

4. **Ахунҗанова М.И.** (Алабуга шәһәре Инженер-технология лицееның 8 нче сыйныф укучысы.Фәнни җитәкче:Әхмәдуллина Р.Ф.). **Тәмле телле булыйк!**

5. **Әхмәдгалиев Ш.Р. (**Алабуга шәһәренең 8 нче гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Тимофеева Л.Г.). **Гөлзада Әхтәмова иҗатында Габдулла Тукай образы.**

6. **Әхмәдиева А.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Әхлак һәм әхлакый тәрбия турында төшенчә.**

7. **Әхмәдиева Р.Ф**. (Алабуга шәһәренең 10 нчы күппрофильле лицей укучысы. Фәнни җитәкче: Нуриева З.М.). **Болгар – үткәннәрдән киләчәккә күпер.**

8. **Әхмәтиҗанова Р.И. ( КОЛЛЕДЖ)**

9. **Әхмәтҗанова Х.Д**.( Арча районы Утар-Аты төп гомуми белем төп мәктәб нең 7 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Касыймова З. Г.). **М.Мәһдиев иҗатында мәдәни мирас сакланышы буларак җырлар.**

10. **Әхмәтшина И.И**. (Лениногорск шәһәренең 4 нче урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Мортазина А.Ф.). **Татар әдәбияты дәресләрендә һәм дәрестән тыш чараларда Р. Фәхреддин әсәрләренең яшь буынга әхлак тәрбиясе бирүдәге әһәмияте.**
11. **Әхтәмҗанова А.И.** (Алабуга шәһәре Инженер-технологик лицейның 8 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Шакирҗанова Н.Г.). **Фольклор – күңел көзгесе.**
12. Бадикова А.А.
13. **Басырова Д.В.** (Алабуга районы Иске Юраш урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Юнусова Л. М.) **Батырлыкның юл башы.**
14. **Бәдертдинова А.Р.** (“Сарман гимназиясе”нең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Матзянова Р.Г., Нәҗметдинова Ч.М.). **Дими-Тарлау гөрләп яши икән, йолкынмаган, димәк, тамыры...**
15. **Борһанова Л.И**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.) **Татар халык мәкальләрендә кушма җөмләләрнең кулланылышы.**
16. **Бугрова В.Д.** (Алексеевскийның 2 нче номерлы гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Васильева А.В.). **Казан шәһәре тарихы/ История города Казани.**
17. **Вагизова А.И**. (“Сарман гимназиясе”нең 11 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Матзянова Р.Г., Нәҗметдинова Ч.М.).**Туган авылым – гүзәл Сарманым.**
18. **Вәлимухаметов К.И. (**Әлмәт шәһәренең “Адымнар-Әлмәт гимназиясе” укучысы. Фәнни җитәкче: Даутова А.Х**). Әдәбияттан класстан тыш эшләр.**
19. **Вахитова Л.Р.** (Беренче номерлы Шыгырдан урта мәктәп укучысы. Фәнни җитәкче: Мтеева З.Ш. ). **Балаларны татар халкының йола,гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре үрнәгендә тәрбияләү.**
20. **Вәлиева В.Ф. (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И. ). **Хәзерге татар хикәясе: тема төрлелеге һәм жанр үзенчәлекләре**
21. **Вәлиева В.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.) **Традицион булмаган татар теле дәресләре.**
22. **Вәлиева К.А**. (Арча шәһәренең Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты. Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.). **Уен технологиясе аша балаларны татар теленә өйрәтү.**
23. **Вәлиева Р.Р**. (Әгерҗе районы, Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләре: Вәлиева Г.М., Нәбиуллина Л.З.). **Авылым бәетләре.**
24. **Габдрафикова Диана**, (Алабуга шәһәре Инженер-технология лицееның 9 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гатауллина М.Г.). **Татар һәм рус телләрендә сүз ясалышы.**
25. **Габдрахманова Г.Р.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларга патриотик тәрбия бирү.**

26. **Газизянова И.И**. (Аксубай районы В.Г.Тимирясов исемендәге беренче номерлы Аксубай урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Галиева Ә.Ә.). **Бөек мәгърифәтче Нәҗип Думави иҗатында Яңа Дума авылы тарихының чагылышы.**

27. **Гайнуллина З.Ш.** (Алабуга районы, Иске Юраш мәктәбенең 7нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.**). Тормышымда мәңгелек эз калдыручы кешем.**

28. **Галиев С.А** (Алабуга шәһәренең 8 нче гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Нотфуллина С.Х) **Фәридә Нургалиевна – мөгаллимә, остаз һәм шагыйрә.**

29. **Галимбекова Ф.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар теле дәресләрендә инновацион технологияләр.**

30. **Галишина И.Л.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.) **Әдәби төр буларак драма.**

31. **Ганиева К.А**. (Арча шәһәре, "Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте", студенты. Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.). **Эльмира Шәрифуллина иҗатында милли гореф-гадәтләр.**

32. **Гараева И.И**. (Алабуга шәһәре, 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләре: Сәхәбиева А.М., Мутифуллина Г.Р.). **Фразеологизмнардагы һәм фразеологик әйтелмәләрдәге калькалар.**

33. **Гарифулина Т.Р. (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Интеграль дәресләрне оештыру һәм үткәрү методикасы (7 нче сыйныфта "Ярдәмче фигыльләр" бүлеген өйрәнү мисалында).**

34. **Гарифуллина Т.Р**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.). **Татар телендә эндәш сүзләрнең грамматик үзенчәлекләре**.

35. **Гарифьянова Р.В**. ("Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9нчы Зәй мәктәбе". Фәнни җитәкче: Хәйретдинова Р.Җ). **Укытучым иҗатында тәрбияви чаралар .**

36. **Гилманова Р.Р**. (Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Минегалиева И.М.). **Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтләренә нигезләнеп, тирән белемле һәм гүзәл холыклы шәхес тәрбияләү.**

37. **Гилметдинов И.И.** (Яр Чаллы шәһәре 19 нчы номерлы гомуми белем бирү мәктәбенең 10 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Фатихова С.Г.**). Роберт Миңнуллин иҗаты мәктәптә.**

38. **Гильметдинова Ф.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Рус телле балаларга татар телен укыту үзенчәлекләре**.

39. **Гильметдинова Ф.Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина). **Татар телен үзләштерүдә уен элементлары.**

40. **Гимранова Э. Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Заманча татар теле дәресе үзенчәлекләре.**

41. **Госсамова Т**. (Актаныш 1 нче гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Галиева Л.Р.). **Вахит Имамовның повесть һәм хикәяләрендә тел-стиль үзенчәлекләре.**
42. **Григорьева Е. Н.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар теле дәресендә укучыларның белем - күнекмәләрен бәяләү.**
43. **Григорьева Е. Н.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Укучыларның танып-белү активлыгын үстерү чарасы буларак мәктәп дәреслеге.**
44. **Гурьева К.С**. (Мамадыш шәһәренең Кызыл Тау урта белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Антонова Д.А.). **Тажи Гыйззәт – "Крестьян җырчысы".**
45. **Гыйлаҗев А.Л.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **7 сыйныфта С.Хәким иҗатын өйрәнү.**
46. **Гыйлаҗев А.Л.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф. И.). **Әдәби деталь һәм аның функцияләре.**
47. **Гыйлаҗев С.И. (**Яр Чаллы шәһәренең 7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче; Камаева Р.Б.). **Ф.Шәфигуллин шигъриятендә табигать темасының чагылышы.**
48. **Закирова А. И.** (Алабуга районы Иске Юраш урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Юнусова Л. М.). **Афоризмнар – халык акылы, халык тәҗрибәсе.**
49. **Зарипова Д.Р.** (Әлмәт шәһәренең 17 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы.Фәнни җитәкче: Кашипова Н.З.). **Күренекле мөгаллимә Ләбибә Хөсәения эшчәнлеге һәм беренче татар кызлары мәктәбе.**
50. **Ибраһимова М.И.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү.**
51. **Ибраһимова М.И. (** КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.). **XX гасыр башы татар әдәбиятында сугыш темасын активлаштыруда иҗтимагый-сәяси вәзгыять.**
52. **Иванова (АРЧА)**
53. **Ильясов А.У**. (Алабуга шәһәренең 8 урта мәктәп укучысы.Фәнни җитәкче: Якупова Ф.М.). **Дастаннар - халкыбызның олы мирасы.**
54. **Исмагилова Г.Р**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Рус телле укучыларда аудирование күнегүләре аша сөйләм телен үстерү.**
55. **Калашник А.А., Минебаева А.Ю.** (КФУның Алабуга институты студентлары. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И**.). Татарстан – часть культурного мирового наследия.**
56. **Камалиева Р.Р**. (Арча шәһәре, "Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте" студенты. Фәнни җитәкче: Шиһабеддинова Г.Х.). **Татар теле һәм әдәбиятын укытуда заманча педагогик технологияләр.**

57. **Кәбирова И.М.** (С.А.Ларионов исемендәге 2 нче номерлы Чирмешән гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Ганиева Э.З.). **Чирмешән авылы тарихы.**

58. **Кәримова Талия**, (Әгерҗе районы, Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең , 9 нчы А сыйныфы укучысы. Фәнни җитәкче: Низамбиева Р.Р. ). **Галимҗан Гыйльмановның "Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах" хикәясендә хикәядә татар яшәеше, татар күңеле өчен хас булган моңлылык сурәтләнеше.**

59. **Латыйпова А.А.** (Актаныш 1 нче урта мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Рахманова Г.Ф.). **Укытучы тормышында үрнәк шәхесләр ("Чал тарихлы мәктәбемнең ак яулыклы остазы").**

60. **Марданов Н.Р.** (Мамадыш районы Урта Кирмән урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Марданов Р.А). **Якташ шагыйрьләребез иҗатында эндәш сүзләр.**

61. **Мәткаримова А.Х**. (Әлмәт шәһәре 13нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гарипова А.Ш.). **Авыл тормышын сурәтләү остасы буларак Р.Төхфәтуллин**.

62. **Мингулова Д.Р.** (Әлмәт шәһәренең 17нче урта мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчесе: Ибраһимова Г.А.). **Халык авыз иҗаты - бәет.**

63. **Мостафин А.Р.** (Алабуга шәһәренең Инженер-технология лицее укучысы. Фәнни җитәкче: Төһбәтуллина Р.Г.). **М.Мәһдиев "Без – кырык беренче ел балалары" повестенда тел-сурәтләү чаралары.**

64. **Мөбәрәкшина Д.Л.**(Әлмәт районы Яңа Кәшер урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Шайхулова А.И.). **Бүгенге көн яшьләр теленең үзенчәлекләре.**

65. **Мөфтиева З.Р**. ("Балалар иҗат йорты "Салават күпере талантлары" Әгерҗе районы Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе базасында 9 нче Б сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Набиуллина Л.З.). **Укытучы сулышы.**

66. **Мукимова Г.Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.). **Роберт Миңнуллин шигъриятендә милли идеал.**

67. **Мухаметов Р.И**. (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: Нигамаев А.З.). **Милли дәүләт үзбилгеләнүе идеяләре, ТАССР оешуы.**

68. **Нәбиуллина А.** (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина). **Мәктәптә иҗади үсеш технологиясенә нигезләнеп "Исем" темасын өйрәнү**

69. **Нәҗметдинова А.Ф. (**Алабуга районы Иске Юраш мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гайнетдинова К.Ф.). **Алар – безнең горурлыгыбыз.**

70. **Нургатин АЛМАТ**

71. **Нуриева Р.Р.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Ф.Кәримнең "Бездә яздыр" шигыре аша укучыларга патриотик тәрбия бирү.**

72. **Нуруллина И.А.**(Лениногорск шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкчесе: Нуруллина З.С.) **Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә, баш иярә һәрвакыт белемлегә**.

73. **Проскурина Р.И.** (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина). **Матур әдәбият әсәрләрендә аныклагычлар һәм аларга охшаш берәмлекләрнең кулланылышы**

74. **Сәхәбетдинова Ә.Б**. ( КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар теле укыту алымы буларак дискуссия.**

75. **Сәхәбетдинова Ә**.Б. (КФУ ның Алабуга институты студенты.Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.)**.** Х. Х. **Сәлимов – педагог, галим, остаз.**

76. **Сөнгатуллина Л.** (Арча шәһәре Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең 2 нче курс студенты. Фәнни җитәкче: Шаһиева Д.Г). **Толерантлык сыйфатлары булдыруда халык авыз иҗаты әсәрләренең әһәмияте.**

77. **Тазова Р.Р.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар әдәбиятын укытуның проблемалы аспектлары.**

78. **Талыпова Л.Н. (**КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Ә.С.Хәйруллина). **Татар теленең сүзлек составында алынмаларның роле**.

79. **Тимофеева Т.В.**

80. **Фазлиева З.Р**., (Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең 8 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Гыйлаҗева А.Ф.). **Туган авылым бизәкләре.**

81. **Фазуллин Р.А**. (Алабуга шәһәренең Инженер-технология лицее укучысы. Фәнни җитәкче: Смирнова Г.Д.). **Айдар Хәлим әсәрләрендә һөнәри лексиканың чыганаклары.**

82. **Фатыхов К.М. (**Яр Чаллы шәһәренең 42 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы.Фәнни җитәкче: Сабирова А.Х.). **Җырлар – халык тарихы.**

83. **Феткуллова А.К**. (Чувашия Республикасының 1 нче номерлы Шыгырдан урта мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче Айзатуллова Р.Р.). **Н.Каштанов - медицина һәм әдәбият өлкәсенлә танылган шәхес.**

84. **Фәләхова В.Б.** (Саба районы Шәмәрдән лицее "Үсеш" мәктәбенең 9 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Сабирова Р.Ә.). **Татар халык авыз иҗатында алкыш жанры.**

85. **Фәррахова Л. Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Даутов Г.Ф.). **Татар әдәбиятында патриотизм темасы.**

86. **Фәррахова Л.Ф.** (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Татар әдәбияты дәресләрендә укучыларга экологик тәрбия бирү.**

87. **Фәсхетдинов И.Р**. (Арча районы Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбенең 9 сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Шиһапова Г.Х., Салахова И.Г.) **Габдулла Тукайның Җаек чоры иҗатында журналистик эшчәнлеге.**

88. **Фәтхуллина А**. (Алабуга шәһәренең Инженер-технология лицее укучысы. Фәнни җитәкче: Агмалова Э.Э.). **Телебезнең киләчәге –безнең кулларда**.

89. **Хадиев А.Р.** (КФУның Алабуга институты “Университет” гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Сәхәбиева Г.Х.). **Рафис Корбан һәм Роберт Миңнуллин шигъриятендә Тукай образы.**

90. **Хәбибрахманова Ф.Б**. (Арча шәһәре, “Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте”студенты. Фәнни җитәкче: Нуриева М.А.). **Әдәби уку дәресләрендә Ф.Яруллин әсәрләрен өйрәнү.**

91. **Хисматова К.Р. (**Алабуга шәһәренең 8 нче гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Гайсина Г.Г.). **Габдулла Тукай.**

92. **Хусаенова А.С.** (МБОУ “Средняя общеобразовательная школа №7” г.Набережные Челны. Научный руководитель: Миннахметова Р.Р.). **Фразеологизмы с компонентом «сары/yellow»(«желтый») в татарском, английском фольклоре.**

93. **Хузина З.А. (**Алабуга шәһәренең 8 нче гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Шакирова Л.М..). **Алабуга төбәгендә яшәүче шагыйрьләребез.**

94. **Шайхетдинова К.Р**.(КФУ ның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф.И.). **Хәзерге яшьләр тормышында матбуган феномены.**

95. **Шакирова И.И**.( Арча районы, Утар-Аты төп гомуми белем төп мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы. Фәнни җитәкче: Касыймова З. Г.). **М.Мәһдиев иҗатында мәдәни мирас сакланышы.**

96. **Шафикова Г.Ф**. (Алабуга медицина училищесының 4 нче курс студенты. Фәнни җитәкче: Шарипова З.З.). **Кәрим Тинчуринның татар мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше.**

97. **Шәйхетдинова А.Л**. (Әлмәт шәһәренең 17 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы. Фәнни җитәкче: Махиянова Р.М.) .**Татар халык бәйрәмнәре.**

98. **Шәйхетдинова К.Р**. (КФУ ның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Камаева Р.Б.). **Хәзерге шартларда татар телен саклау һәм үстерү.**

99. **Шәрифуллина А.И.** (КФУның Алабуга институты магистранты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.). **Укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру чарасы буларак татар теле дәресләрендә текст белән эшләү.**

100. **Шәрифуллина Зөһрә** (“Адымнар – Алабуга” күптелле белем бирү комплексының 10 нчы сыйныф укучысы. Фәнни җитәкчеләр: Комиссарова Ф.Г, Данилова З.С.). **Без тарихта эзлебез.**

101. **Юнусова З.Н**. (КФУның Алабуга институты “Университет” гомуми белем бирү мәктәбенең 10 сыйныфы укучысы. Фәнни җитәкче: Сәхәбиева Г.Х**.). Ренат Харис шигъриятендә Тукай образы.**

102. **Юнусова Э.Ф**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Габидуллина Ф. И.). **Роберт Миңнуллин шигъриятенең тематик төрлелеге.**

103. **Ягудина Р.Р**. (КФУның Алабуга институты студенты. Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ә.С.). **Татар һәм рус телләренең сүзлек составында алынмалар.**

Сборник научных статей  XIV Всероссийской науно-практической конференции «Татарский язык и литература. история:
прошлое, настоящее и будущее»
Редактор
*А.С.Хайруллина*

Компьютерная верстка

Дизаин обложка

Подписано в печать __________
Бумага офсетная: Печать цифровая
Формат 60х84 1/16 Гарнитура «Times New Roman»
Усл. п.л. _____Тираж 100 экз. Заказ  № _____
Отпечатано в типографии
Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37